# ЗӨЛФӘТ ХӘКИМ

# Телсез  күке

ПЬЕСАЛАР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-2
ББК 84 (2Рос=Тат)-6
Х86

**Хәким З.З.**

Телсез Күке: пьесалар / Зөлфәт Хәким.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.— 480 б.— 2000 д.— ISBN 978-5-298-01578-3
Китапка драматург З.Хәкимнең татар театрларында куелып уңыш казанган әсәрләре туплап бирелде.

ISBN 978-5-298-01578-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Хәким З.З., 2007

# ТЕЛСЕЗ КҮКЕ

*(Театраль роман)*

Үлүченең көне җитмәсә, үтерүченең кулы җитмәс.

*Татар халык мәкале*

Кылыч җимергән нәрсәне каләм төзәтә ала.

*У.К.Кекконен*

Всякая национальность есть богатство единого братски объединенного человечества, а не препятствие на его пути.

*Н.А.Бердяев*

Әҗәлдән котылып булмаса да, чигереп була.

*Татар халык әйтеме*

Нация не может погибнуть, кроме как от самоубийства.

*Р.У.Эмерсон*

...Кара урманнарда ике алмагач,
Алмалары саен бал тама;
Ике күзләремдә сиксән керфек,
Керфекләре саен кан тама.

*Татар халык җыры*

*Мин күптән инде Телсез Күке турында сөйләргә җыенам. Гәрчә ул вакыйга миндә озак еллар яшәсә дә, моңарчы аны сезләргә бәян итәр өчен, күрәсең, миндә эчке өлгерү җитенкерәмәгәндер. Бәлки, Вакыттан тагын нинди дә булса яңалыклар, кичерешләр, төзәтмәләр көткәнмендер.*

*Соңгы еллар тормышыбызга төрле үзгәрешләр вә өстәмәләр кертте. Инсаният дөньясына да, шул ук вакытта һәрбер аерым кешенең яшәешенә дә. Әлбәттә, минем бәяныма да.*

*Югыйсә туган-тумачам, дус-ишем, таныш-белешем хакында түгел бу вакыйга, ләкин, ни гаҗәп, ул кешеләрнең язмышына һич кенә дә битараф кала алмыйм, бу минем хәлемнән килми. Алай гына да түгел, вөҗүдемдә бер сәер тойгым бар — гүя мин аларның үткәннәрен үзем дә күргәнмен вә кичергәнмен.*

*Тип-тигез генә сөйләп бирермен дип ышандыра алмыйм. Чөнки Телсез Күке турында мәңге сөйләп һәм мәңге җырлап туймаслык.*

*Аллага тапшырып бәянымны башлыйм.*

КАТНАШАЛАР:

Зәйнуллин Зариф Хәбибрахман улы — Чулман буе татары.
Галиәкбәр улы Зыятдин (бабасы Якуб) — Финляндия татары.
Кәшифә — Зарифның сөйгәне, соңыннан хатыны.
Хәбиб — Финляндия татары, яшь егет.
Назимә — Зарифның оныгы.
Зимин Федор Семенович — НКВДның Особый отдел офицеры.
Лебедев Анатолий Евсеевич — өлкән лейтенант, рота командиры.
Шаталов Иван — рядовой, урыс.
Рассуханов Аслан — рядовой, чечен.
Севрюгин Михаил — рядовой, урыс.
Яхно Сергей — рядовой, яртылаш украин.
Зиновьев — 25—27 яшьләрдәге ир-егет.
Солдатлар, тоткыннар, хәрби әсирләр һ. б.
Конвоирлар, надзирательләр.
Корреспондент кыз, оператор егет: телевидение хезмәткәрләре.

# БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Алты йорттан һәм төрле каралты-курадан торган урман хуҗалыгы. Иң иске йортта Телсез Күке кушаматлы Зариф карт яши. Аның өй эче ярым караңгы. Бөтенләй буш өй дисәң, ялгыш булыр. Тимер карават, иске телевизор, кыршылып беткән шкаф, өстәл, урындык кебек җиһазлар монда әле кеше яшәрлек икәнне күрсәтә. Бөтен нәрсә тәртипсез рәвештә. Өстәл күчкән, урындык ауган, кием-салым төрле почмакка чәчелгән. Чүпрәк сумка күтәреп, Зариф кайтып керә. Баскан урынында катып, ул бик озак өй эченә карап тора. Сумкасын стенадагы кадакка элеп куйгач, иң беренче чиратта барып шкафтагы тартманы ачып карый. Аның төбеннән бер документ кисәге ала. Беркавым аңа карап торганнан соң кире урынына куя. Ашыкмыйча гына бүлмәсен тәртипкә китерә башлый. Өстәлне стенага таба күчерә, ауган урындыкны торгыза, аунап яткан күлмәкләрен җыеп карават башындагы сандык өстенә ташлый. Шкаф тартмаларын кат-кат ачып карый, андагы вак-төякне барлый. Тышта урман хуҗалыгының этләре буза куптарып өрергә тотыналар. Йорт каршына җиңел машина килеп туктый. Ләкин Зариф моңа игътибар бирми, өйнең бер почмагыннан икенчесенә әрле-бирле йөри. Кинәт өй ишеге ачыла һәм бусагада пөхтә кыяфәтле, кара костюмлы, ак күлмәкле, галстуклы ир-егет пәйда була. Култык астына күн папка кыстырган. Егерме биш-егерме җиде яшьләрдәге бу кешегә үзенең ыспай киеме бигүк ятыш булмаса да, аның муенындагы галстугы ничектер бер табигый элемент рәвешендә түше буйлап корсагына таба сузылып төшкән.

Көтелмәгән кунак *(актерларча куелган тавыш белән).* Добрый день! Здравствуйте! *(Аның тигез итеп янга таралган сары чәченә, янып торган зәңгәр күзләренә һәм авыз чите белән елмаюына карагач, бу исәнләшүдә дикторларга хас коры сәламләү һәм ясалма ягымлылык кына түгел, ә берникадәр ихласлык та барлыгы, исәнләшүендә, ничек кенә булмасын, барлык вөҗүде катнашуы абайлана. Шулай булгач, теләсә нинди халәттә мондый сәламләүгә җавап бирмәү мөмкин түгел.)*

Зариф *(бүлмә уртасында басып торган килеш).* Исәнме. *(Инде әллә кайчаннан бирле сөйләшмәү сәбәпле, тавышы карлыгып чыга. Дымлы күзләрен ишек катындагы кешегә төбәп, аның кем икәнен чамаларга тырыша.)*

Кунак *(хуҗаның каты күз карашыннан уңайсызланып ишек катында тора).* Вы встревожены? Сейчас все поймете. *(Картка таба атлый.)*

Зариф. Син кем?

Кунак *(үтә дә итагатьле тавыш белән).* Прошу прощения, я по-татарски не понимаю.

Зариф *(фәкать киреләнү өчен генә).* А я по-русски не понимаю.

Кунак. Прошу вас, не волнуйтесь... и не бойтесь меня.

Зариф *(татарча акцент белән сөйләшә).* Я тебя не боюсь!

Кунак. И не сердитесь, пожалуйста. Зря вы горячитесь... Я из милиции. Капитан Зиновьев... Вот удостоверение... *(Куен кесәсеннән алып документын күрсәтә.)*

Зариф *(таныклыкка бөтенләй күз салмый, Зиновьевның үзенә текәлеп карап тора).* Зачем приехал?

Зиновьев. По поводу ограбления.

Зариф. Какого ограбления?

Зиновьев. В связи с ограблением вашего дома.

Зариф. Никакого ограбления нет.

Зиновьев. Зариф абы, зачем вы упрямитесь?

Зариф. Откуда знаешь про ограбление? Я никому не сообщал.

Зиновьев. Вас ограбили. И не один раз. Ваш дом уже несколько раз грабили.

Зариф. Мне наплевать. У меня нечего воровать. У меня ничего нет. Если хотят, пусть грабят. Я никому не буду сообщать. *(Караваткa утыра.)*

Зиновьев. Разрешите присесть. *(Урындыкка утырып Зарифны җентекләп күзәтә.)* Да, вы человек гордый. Нелюдимые они все гордые. Сообщать о своих неприятностях вам несвойственно. В этот раз я подождал две недели и... Думаю, может, старик все же заявит в милицию, но понял, что от вас этого не дождешься. Ну так вот, подождал я две недели, и решил сам приехать.

Зариф *(аптыраган кыяфәт белән)*. Какие две недели?

Зиновьев *(үтә җитди булырга тырышып)*. Вас последний раз две недели назад ограбили, так?

Зариф *(тонык кына тавыш белән)*. В последний раз меня сегодня ограбили. Я ходил в Субай, в магазин за сахаром. Прихожу — все перевернуто.

Зиновьев *(гаҗәпләнү төсе белән)*. Надо же! Значит, я как раз вовремя! Просто поразительно! Ужас какой! Я-то думаю, две недели уже прошло, не заявляет, дай сам съезжу... Еще и сегодня грабанули?! Вот те на!

Зариф. А про то ограбление откуда узнал?

Зиновьев *(папкасында актарына)*. Субаевские рассказали, как вас постоянно грабят, а вы за помощью не обращаетесь. Мне вот интересно стало... *(Зарифка текәлә.)* А почему вы в милицию не сообщите?

Зариф *(авыз чите белән генә көлемсерәп куя)*. Какой толк от этого! Вы все равно порядок не сможете навести.

Зиновьев *(бераз усал булып кыланып)*. Ну, конечно, если все будут молчать, как вы... Я имею ввиду про преступления...

Зариф *(тыныч кына һәм шул ук вакытта нык тәэсир итәрлек тавыш белән)*. Меня в счет уже не надо брать, мне жить недолго осталось.

Зиновьев *(ягымлы булырга тырышып)*. Не спеши помирать, абы.

Зариф *(эчке куәте сизелерлек иттереп)*. Вор, который забирается в мой дом, он жалок и ничтожен, и, наверняка, не проживет столько, сколько прожил я. Мой дом грабят, а ведь ценного у меня ничего нету. Кое-что уже, правда, утащили. *(Иске тумбочка өстендә торган телевизорга ишарәләп.)* Телевизор оставляют, потому что черно-белый. Наверно, думают, что не показывает.

Зиновьев *(күзләрен чекерәйтеп)*. А что украли?

Зариф *(берниди борчылусыз һәм һич кенә дә уфтанмыйча)*. В прошлом году два раза грабили... Тогда дубленку, валенки, радиоприемник и еще кое-чего из барахла. Новое ведро, топор, помнится, уперли. Две недели назад из сарая две лопаты унесли, а из дома новую кастрюлю эмалированную и новую кожаную фуражку. *(Кашларын нык җыерып.)* Вот фуражку жалко, потому что мне ее моя любимая внучка подарила.

Зиновьев. А в этот раз?

Зариф *(як-ягына каранып).* Никак не пойму. В этот раз вроде бы порылись и все. Ну ведь брать-то уже больше нечего.

Зиновьев *(папкасыннан кәгазьләр алып)*. Заявление писать будете?

Зариф. Нет.

Зиновьев. А кого подозреваете?

Зариф. Я вообще никого ни в чем не подозреваю. Я не такой человек. Думаю, один из самых плохих качеств — это подозревать.

Зиновьев *(бераз кырысланып)*. Но в данном конкретном случае можно и нужно подумать, кто бы мог это сделать.

Зариф. Не знаю.

Зиновьев. Кто-то из посторонних или из местных?

Зариф. Отсюда недалеко есть Серебряное озеро. Там лечебная вода. Туда много всякого народу ездит...

Зиновьев *(нәрсәнедер исенә төшергән кыяфәт белән)*. Да, да, да, да.

Зариф. А дорога из города как раз мимо нашего лесного хозяйства проходит. Вот и наведываются сюда. Раз дома нет хозяина, значит, можно зайти, порыться.

Зиновьев. Здесь шесть хозяйств. Других не грабят?

Зариф. Не знаю. У них постоянно кто-нибудь дома есть. Наверно, к ним не залезают.

Зиновьев. А вы совсем один живете?

Зариф. Да.

Зиновьев. Здесь вроде собаки сильно лают, когда посторонний в лесхозе появляется.

Зариф *(куәтле тавыш белән)*. Вор он ни бога, ни черта ни боится. Разве же он побоится какой-то собаки!

Зиновьев. Ну а соседи что, невнимательные такие? Говорите же, что кто-нибудь да у них дома остается.

Зариф *(сөйләшүдән туя башлый)*. Я прожил много лет и сам на свои вопросы ответить не могу. А ты меня про соседей спрашиваешь.

Зиновьев *(тәрәзә ягына күз салып).* Да, хоть и лес, хоть и лесное хозяйство, но все же очень неспокойно у вас здесь. Это Серебряное озеро кишит всяким сбродом — там и бандиты, там и наркота, там все... Здесь опасно.

Зариф. А где не опасно?

Зиновьев. Впрочем, да.

Зариф. В этом мире везде опасно.

Зиновьев. Почему в Челны не поедете жить, к сыну?

Зариф *(Зиновьевка карап тора)*. Про сына тоже узнал?

Зиновьев *(уңайсызланган булып кылана)*. Да, я на всякий случай кое-какую информацию взял о вас.

Зариф *(канәгатьлектән тавышы көрәя)*. У меня прекрасный сын. У него отличная семья. Невеста хорошая. Внучку же я больше всего на свете люблю. Они меня умоляют, чтобы я переехал к ним жить.

Зиновьев *(аптырап)*. Так в чем же дело?

Зариф *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Не могу. Я здесь родился, здесь жизнь прожил. Отсюда и до Субайского кладбища недалеко.

Зиновьев. Ну, вы опять...

Зариф. Там моя жена Кашифа похоронена. Я каждый день на ее могилу хожу.

Зиновьев. Ну ведь из Челнов на это кладбище можно иногда приезжать.

Зариф. А я каждый день к ней хожу.

Зиновьев. Понятно. Когда в Субае спрашивал, все вас называют то Күке Зариф, то Телсез Күке. Күке — это кукушка?

Зариф. Да.

Зиновьев. Телсез — это немой? То есть Немая Кукушка?

Зариф *(ачуы килә башлый)*. Да, да, да. Больно уж ты любопытный.

Зиновьев *(читенсенгән булып)*. Видимо. Профессиональная привычка. А почему Кукушкой прозвали?

Зариф. Это кличка нашего рода. А меня Немой Кукушкой прозвали, потому что у меня часто приступы бывают. Тогда у меня язык отнимается. Говорить не могу. Поэтому Немая Кукушка.

Зиновьев *(зур кызыксыну белән)*. Ну, почему всетаки Кукушка?

Зариф *(усал тавыш белән)*. Ты не те вопросы задаешь, капитан.

Зиновьев *(картның ачулы кыяфәтеннән бераз каушый)*. Прошу прощения. Тогда давайте по делу. Значит, по факту ограбления не хотите писать заявление?

Зариф *(коры гына)*. Нет, не вижу надобности.

Зиновьев *(ялагай тавыш белән)*. Можно все-таки еще вопрос, не совсем относящийся к моему визиту?

Зариф *(башын читкә борып сөйләшәсе килмәгәнне күрсәтмәкче була)*. Спрашивай.

Зиновьев. Я слышал, вы были участником советско-финской войны 1939—1940 годов.

Зариф *(тонык кына тавыш белән)*. Да.

Зиновьев. Участвовали в Великой Отечественной войне, из рядового стали офицером и полным кавалером орденов славы? Это правда?

Зариф *(тавышын күтәреп)*. Правда.

Зиновьев. А где все это?

Зариф *(нәфрәтләнеп)*. Что «это»? Ордена?

Зиновьев. Куда все подевалось? Вы ведь даже ветераном войны не числитесь нигде. Вы ведь к тому же и ранения имеете?

Зариф *(кыза башлый)*. Да, ты все правильно разузнал. К тому же я и в советских лагерях сроки мотал.

Зиновьев. Ну ведь вы можете теперь восстановиться!

Зариф *(җикереп)*. Что я могу восстановить?!

Зиновьев. Права участника двух войн, инвалида... права на льготы... Возможно, и реабилитацию получите. Вы же все-таки герой!

Зариф *(кырыс тавыш белән)*. Ты молод еще. В человеке человека надо восстановить. А не побрякушками обвешиваться. И реабилитировать должен каждый человек сам себя. А начинать нужно с прощения. Самому просить прощения и прощать.

Зиновьев *(саклык белән генә сорый)*. А ордена Славы у вас украли?

Зариф *(битарафлык белән)*. Нет, их у меня не украли. Да я даже участником войны сегодня не числюсь. Ну разве это важно? Мне ничего не нужно. Я скоро к моей Кашифе уйду, в мир иной.

Зиновьев *(нык гаҗәпләнә һәм кызыксынудан туктый алмый)*. Неужели в этом мире уже больше ничто вам не мило?

Зариф *(тавышын йомшартып)*. Внучку я безумно люблю. Она на Кашифу очень похожа. Ради нее я еще в этом мире немного побуду. *(Тагын кинәт усаллана.)* А все остальное для меня уже померкло.

Зиновьев. Ну а если восстановить все, может, интереснее стало бы жить?

Зариф. Ты опять про льготы и ордена?.. Ничего этого мне не нужно. Вот если бы я узнал, что человек один в те далекие годы не умер в сталинском бараке, мне было бы намного легче. Если бы мне сообщили, что он вернулся на родину и сегодня жив-здоров, я бы просто был счастлив. А если бы еще мне сказали, что этот человек простил и прощает меня, то жизнь земную я счел бы законченной и небесмыссленной.

Зиновьев *(алгарак сузылып)*. Кто этот человек?

Зариф *(җикереп)*. Ты мне надоел!

Зиновьев *(сискәнеп куя)*. Простите, пожалуйста. *(Кәгазьләрен кире папкасына тутыра.)* Действительно, я кажется утомил вас. *(Урыныннан кузгала.)* Я пойду.

Зариф *(коры гына)*. Иди. И не сердись на меня.

Зиновьев *(ясалма ягымлылык белән елмая)*. Ну что вы! Чудной вы человек, Зариф абы.

Зариф. Какой есть...

Зиновьев *(картның тынычланганын сизеп, сорарга җөрьәт итә)*. А припадки у вас... Вы немеете когда у вас неприятности и сильно огорчены?

Зариф *(Зиновьевның күзләренә карап)*. Да.

Зиновьев *(аның күз карашыннан качар өчен як-ягына карап)*. Мне кажется, что ограбив ваш дом, нельзя вызвать в вас припадок.

Зариф *(һаман Зиновьевка текәлеп карап тора)*. Нет, это не может быть причиной моего потрясения.

Зиновьев *(кинәт картның күзләренә карый)*. А что может вас сильно потрясти?

Зариф *(яман усал тавыш белән)*. Молодой человек! А вот ваши расспросы действительно могут меня из себя вывести!

Зиновьев *(картның каты нәфрәтләнүеннән шүрли)*. Простите. Я хотел, наоборот, помочь вам хоть как-нибудь.

Зариф *(кызуы артып)*. Ты не похож на человека, способного помочь такому, как я.

Зиновьев *(картны юмалау нияте белән)*. Вы зря так... Не надо меня обижать.

Зариф *(җикереп)*. А ты разве баба, чтобы обижаться?!

Зиновьев *(үзен кулга ала һәм тыныч кына тавыш белән)*. Вы же меня совсем не знаете.

Зариф *(кычкырып диярлек)*. А зачем мне тебя знать?!

Зиновьев *(курка һәм ишекне ача)*. Ну что ж, по факту ограбления все равно можем к вам явиться в любое время. Может быть, я сам. А может, другой наш сотрудник. Вы хорошенько посмотрели — что в этот раз унесли? Из документов ничего не пропало?

Зариф *(кычкыра)*. Ничего не пропало! И вообще меня никто никогда не грабил! Понял?!

Зиновьев. Понял. До свидания! Всего доброго!

Зариф *(кычкырып)*. Хуш! Прощай!

Зиновьев чыгып китә.
Музыка. Зариф тынычлана алмый, бүлмә буйлап арлы-бирле йөри.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

90 нчы еллар. Санкт-Петербург каласы. Татарларның сабантуй бәйрәме.
Музыка. Җыр-бию. Тантаналы ыгы-зыгы.

Корреспондент кыз *(видеокамерага карап сөйли)*. Хөрмәтле телевизор карауучылар! Мөхтәрәм милләттәшләребез! Иң күңелле, иң затлы бәйрәмнәребезнең берсе — Сабантуй — Русиянең икенче башкаласы дип саналган Санкт-Петербург каласында аеруча күтәренке рух вә илһам белән уздырыла дисәм, бер дә ялгыш һәм арттырып әйтү булмас, мөгаен. Санкт-Петербургның үзендә яшәүче татарлар өчен генә түгел, башка милләт культурасын ихтирам итүче барлык кешеләрнең, әлбәттә инде, илнең төрле төбәкләреннән, хәтта чит илләрдән килгән кан кардәшләребезнең олуг бәйрәме бу!

Корреспондентның тавышы ерагая. Җыр яңгырый. Назимә матур күлмәктән, иңенә җиңел сумка асып салмак кына атлый. Кәефе начар булмаса да, йөзендә сагыш бар. Каядыр читтәрәк көрәш ярышына комментарий бара. Бәйрәмнең икенче тарафыннан ат чабышына чакыру яңгырый. Кайсыдыр яктан урыс телендәге игъланнар да ишетелә. Барлык тавышлар бер сабантуй авазына әверелеп һавада яңгырап тора. Назимә борчылып як-ягына карана. Аны җәйге җиңел костюм кигән бер егет күзәтә. Назимә моны абайлап ала да, аның зыялы икәнен чамалап, шундук мөрәҗәгать итә.

Назимә *(тавышындагы каушау төсмерләрен җиңә алмый)*. Извините... Можно вас спросить?

Егет *(елмаеп)*. Син татар кызы бугай?

Назимә *(аптырап кала)*. Әйе.

Егет *(ягымлы тавыш белән)*. Алайса, зинһар, татар телендә әйт сүзеңне.

Назимә *(ниһаять, үзен кулга ала)*. Гафу итегез. Мин сездән сорамакчы идем... Монда берәр ничек телефоннан шылтырата торган урын юк микән?

Егет *(ваемсыз гына)*. Бар, нишләп булмасын.

Назимә *(ялварулы тавыш белән)*. Зинһар, әйтегез.

Егет. Минем телефоннан шылтырат. *(Кесәсеннән мобильный телефонын чыгарып бирә.)*

Назимә *(каушый).* Чын әйтәсезме... *(Телефонны ала, кнопкаларга карап тора.)*

Егет *(җитдиләнеп)*. Бир, үзем җыям номерны. Син әйтеп тор. *(Телефонны ала.)* Кая шылтыратасың?

Назимә. Монда, Петербургтагы бер кызга. Шуның мобильнигына. *(Номерны әйтә.)*

Егет *(номерны җыя.)* Мә, сөйләш. *(Үзе шундук кызның сөйләшкәнен ишетмәс өчен читкә китә.)*

Назимә *(телефонны ала).* Алло! Ирина! Это опять я —Назима из Казани. Мы договаривались созвониться. Здравствуйте!

Ирина *(телефоннан).* Здравствуйте! Родители из Ростова не скоро приедут.

Назимә *(нык дулкынлана)*. Знаете, Ира, думаю, с твоими родителями мне встречаться нет необходимости. Мне бы с Анатолием Евсеевичем повидаться и поговорить.

Ирина. Назима, милая, боюсь, не получится.

Назимә *(менә-менә елап җибәрергә тора)*. Почему?

Ирина. Думаю, вам будет бесполезно с моим дедом встречаться, так как он в очень тяжелом состоянии.

Назимә. Он в больнице?

Ирина. Да.

Назимә *(тавышы калтырый башлый)*. А мне нельзя к нему в больницу сходить?

Ирина. А зачем? Он вашего деда Зарифа не помнит. И того финского солдата тоже не помнит. Откуда ему помнить про какого-то финского пленного. Откуда он знает что с этим финном произошло, что с ним сделали, как убили, и убили ли вообще. Он даже не помнит уже, что, когда и как с ним самим случилось. Неужели вы мне не верите! У него памяти-то уже нет. Я ведь долго расспрашивала про вашего деда, но он никого и ничего не помнит. Ну раз так, то зачем вам приходить к нему и тормошить его память.

Назимә. Да, вы правы. Но у меня все же к вам одна просьба есть.

Ирина. Слушаю.

Назимә. Мой дед Зайнуллин Зариф просит у него прощения. *(Елый.)* Он считает себя виноватым перед вашим дедом Лебедевым Анатолием Евсеевичем и просит простить великодушно. А за что, за какие грехи они сами, наверно, знают.

Ирина. Хорошо, Назима, вы только успокойтесь, ради бога, не плачьте. Знаете что, приходите ко мне ночевать. Что это вы там будете в гостинице жить. Гостиница есть гостиница. У меня в любом случае уютнее будет.

Назимә *(һаман елый)*. Нет, спасибо. Я вечерним поездом в Казань возвращаюсь.

Ирина. Не плачьте, пожалуйста. Ну успокойся, ради бога.

Назимә *(кулъяулыгы белән күз яшьләрен сөртә)*. Извините, пожалуйста, за беспокойство.

Ирина. Ничего, ничего. Вы сами на меня не сердитесь. Дед, ей-богу, лежит почти в беспамятстве.

Назимә. Да, я верю вам.

Ирина. Вы, значит, вечером уже уезжаете?

Назимә. Да.

Ирина. Ну что ж, доброго пути! Счастливо доехать вам!

Назимә. Спасибо. До свидания! *(Елый.)*

Ирина. До свидания!

Егет *(килә).* Авыр әңгәмә булды мәллә?

Назимә *(телефонны егеткә биреп).* Юк ла, үзем шундый елак мин. Күңелем тулды. *(Битен кулъяулыгы белән сөртә.)*

Егет *(борчылып)*. Мин берәр ничек ярдәм итә алмыйммы?

Назимә. Ярдәм иттегез бит инде. Рәхмәт. *(Йөзеннән газап төсе һаман китми.)*

Егет. Проблемагызны хәл итә алмыйммы соң?

Назимә. Юк.

Микрофонын алга сузып корреспондент килеп җитә. Оператор шундук Хәбир белән Назимәне төшерә башлый. Назимә борчылып чәчләрен төзәткәли.

Корреспондент кыз *(операторга).* Тукта, төшерми тор. *(Хәбир белән Назимәгә.)* Сездән интервью алырга мөмкинме? *(Үзе беркемгә тын да алырга ирек бирми интервьюга әзерләнә башлый.)* Сез менә мондарак басыгыз... Ә сез... менә сезне төшергәндә теге пейзаж күренебрәк торсын... Туктагыз әле, сез

якынрак басыгыз, әнә теге колганы да күрсәтик. Шулай гына торыгыз. Башта мин камерага берничә сүз әйтәм, шуннан соң сезгә сораулар бирермен.

Егет. Ярар.

Назимә *(егеттән сорый)*. Минем күзләрем шешенгәндер бит... елагач? *(Сумкасыннан көзге алып карый, чәчен төзәткәли.)*

Егет *(ягымлы елмаеп)*. Юк, юк, бик гүзәл. Син әле яңа гына йокыдан уянган сабый бала кебек гүзәл.

Корреспондент кыз *(яңгыравыклы тавыш белән кызу-кызу сөйли)*. Хәерле көн, хөрмәтле телевизор караучылар! Исәнмесез, газиз милләттәшләребез! Санкт-Петербург каласында сабантуй бәйрәме гөрли. Бәйрәмнәрегез мөбарәк булсын! Сабантуйда катнашучылар белән сөйләшеп аласыбыз килә. *(Назимәгә таба борылып мөрәҗәгать итә.)* Гафу итегез, сезнең исемегез ничек?

Назимә *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Назимә.

Корреспондент. Сез Санкт-Петербургның үзендә яшисезме?

Назимә. Юк, мин Казаннан, Татарстанның башкаласыннан килдем.

Корреспондент. Махсус сабантуй бәйрәменә мәллә?

Назимә *(әле һаман тынычлана алмый)*. Юк, бер бик мөһим эш белән килгән идем. Менә сабантуйга туры килдем.

Корреспондент. Әлбәттә, сез моңа бик шаттыр?

Назимә. Әйе.

Корреспондент. Бәйрәм ошыймы?

Назимә *(елмаерга тырышып)*. Бәйрәм бәйрәм инде. Бик күңелле, бик күркәм.

Корреспондент. Казан сабантуе көчлерәкме, әллә мондагысымы? Аерма бармы?

Назимә *(тавышы бераз ныгая)*. Сабантуй һәркайда сабантуй инде ул. Иң мөһиме кешенең үз күңелендә бәйрәм булырга тиеш, минемчә.

Корреспондент. Казанда эшлисезме, укыйсызмы?

Назимә. Укыйм. Педагогия институтында, татар теле бүлегендә.

Корреспондент. Сер булмаса, нинди җилләр сезне бу калага алып килде?

Назимә *(бик моңсу тавыш белән)*. Бабамның сугыштагы иптәшен эзләп килгән идем. Кызганыч, ул инде бик карт һәм авыр хәлдә хастаханәдә ята.

Корреспондент. Алай икән. Әңгәмәгез өчен рәхмәт. *(Егеткә мөрәҗәгать итә.)* Күренеп тора ки, сез Санкт-Петербург егете.

Егет *(якты елмаеп)*. Ялгышасыз. Мин Финляндиядән килдем. Хельсинкидан.

Корреспондент. Финляндиядән?! *(Тагын ниндидер сорау бирмәкче була, ләкин җитешми — егет сүз ала.)*

Егет. Әйе. Мин шунда туып үстем.

Корреспондент *(бик гаҗәпләнә)*. Шулаймыни-и-и?! Фин татары!

Егет *(үпкәләмичә генә битәрләп ала)*. Нишләп сез барыгыз да фин татары дисез?! Финляндиядә яшәүче татар. Һәрхәлдә, Финляндия татары дип әйтегез.

Корреспондент *(үзен бик тә гаепле сизеп)*. Гафу итегез, гафу итегез. Исемегез ничек?

Егет. Хәбиб атлы.

Корреспондент. Хәбиб әфәнде, сез сабантуй кунагы гынамы, әллә шулай ук башка эшләр белән дә килдегезме?

Егет. Бизнес буенча миңа еш килергә туры килә. Петербургка да, Мәскәүгә дә, Татарстанга да. Бу юлысы да Петербургтагы кайбер эшләремне сабантуй вакытына махсус туры китердем. Иң яраткан, күңелемә иң хуш килгән бәйрәм бу минем. Хәер, һәр татар кешесе өчен шулайдыр инде. *(Назимә егетнең Финляндия татары икәнен ишеткәч сискәнеп китә. Башта бик сөенә, аннары башына килгән ниятен кире кагып, телен тыярга карар кыла.)*

Корреспондент. Финляндиянең үзендә татарлар шулай ук сабантуй бәйрәмен уздыралардыр?

Егет *(горур тавыш белән)*. Әлбәттә.

Корреспондент *(камерага карап)*. Менә, хөрмәтле телевизор караучылар! Финляндиядә туып үскән кан кардәшебез туган телебездә ничек камил сөйләшә. Бу, һичшиксез, безнең милли бәйрәмебезгә аерым бер ямь өсти. *(Егет ягына борыла.)* Әле озак буласызмы Санкт-Петербургта?

Егет. Юк, мин инде сабантуйга кадәр үк эшләремне төгәлләдем. Иртәгә Хельсинкига юнәләм.

Корреспондент. Менә сез Татарстанның үзендә генә түгел, татар яшәгән башка төбәкләрдә дә еш буласыздыр. Татар халкы турында, аның бүгенге хәләте хакында нәрсә әйтә аласыз?

Егет *(җитди кыяфәт белән)*. О-о-о, сез бик зур сорау бирдегез. Мин татар халкының гап-гади бер вәкиле, шуңа күрә мин барлык милләт хакында сүз әйтергә үземне компетентлы һәм вәкаләтле түгелмендер дип саныйм.

Корреспондент *(киң итеп елмая)*. Рәхмәт! Сез Хельсинки егете Хәбиб һәм Казан кызы Назимә шушы Санкт-Петербург сабан туенда таныштыгызмы?

Егет *(сораудан канәгать булып елмая)*. Әйе.

Корреспондент. Менә бит! Шушындый бөек бәйрәмдә нинди матур очрашу-кавышулар насыйп була кайберәүләргә. Әңгәмәгез өчен рәхмәт! Сау булыгыз! *(Камера экранына карап.)* Мөхтәрәм милләттәшләр! Бәйрәм дәвам итә. Яшәү дәвам итә. Әйдәгез, барып ат чабышына күз салыйк. *(Китәргә җыеналар.)*

Егет. Сау булыгыз!

Назимә. Сау булыгыз! *(Корреспондент һәм оператор күздән югалалар.)*

Егет *(Назимәгә карап тора).* Менә корреспондент ярдәмендә таныштык та бугай инде. *(Көлә.)*

Назимә *(кинәт шатланып көлеп җибәрә).* Әйе, бер-беребез турында инде кайбер мәгълүматларны хәзер беләбез. *(Аларның икесен дә аңлатып булмый торган күтәренкелек, шатлык һәм илһам биләп ала. Рәхәтләнеп көләләр.)*

Егет *(кызга туп-туры карап)*. Димәк, син — Назимә?

Назимә *(ояла)*. Әйе. Ә сез, димәк, Хәбиб?

Хәбиб. Әйе. *(Көлә.)* Күңелле килеп чыкты.

Назимә. Сез чынлап та фин татарымы?

Хәбиб *(берниндиачусыз, ләкин җитди кыяфәт белән)*. Мин фин татары түгел. Мин Финляндия татары.

Назимә *(каушаулы тавыш белән)*. Гафу итегез.

Хәбиб *(кызның каушавын күреп тиз генә аны тынычландырырга тели).* Гафу үтенерлек нәрсә юк әлегә. Борчылма бер дә.

Назимә. Сез инде минем белән «син» дип сөйләшә дә башладыгызмыни?

Хәбиб. Бездә кешегә «сез» дип эндәшмиләр. Татарлар элек-электән бер-берсенә «син» дип мөрәҗәгать иткәннәр. Русиядә генә ул, имеш, ихтирам йөзеннән, «сез» дип сөйләшәләр. «Син» дип мөрәҗәгать итү яхшырак, якынрак бит инде, шулаймы?

Назимә. Килешәм. Гаҗәп! Минем беренче мәртәбә фин татарын... гафу... Финляндиядә яшәүче татарны очратуым. Андагы татарлар турында ишетеп кенә белә идем.

Хәбиб *(шатлыгы бөтен кыяфәтенә чыга)*. Минем дә бүгенге көнем могҗизалы булып чыкты — беренче мәртәбә мондый гүзәл Казан кызын очратуым.

Назимә *(сынаулы караш һәм серле тавыш белән)*. Чибәр татар кызларын күп күргәнсездер инде — Татарстанда да, башка тарафларда да. Казанда булганыгыз бардыр бит?

Хәбиб *(ихлас күңелдән әйтә).* Бар. Казан кызларын да күргәнем бар. Ләкин синең кебек гүзәлне беренче тапкыр күрүем.

Назимә *(кинәт җитдиләнә)*. Үләм! Битем яна. *(Кул арты белән яңакларына кагыла.)*

Хәбиб *(як-ягына, күккә карап ала, аннары кызга карап елмая)*. Бик эссе бүген.

Назимә *(ни әйтергә белми)*. Сез... син татарча әйбәт сөйләшәсең.

Хәбиб *(горур тавыш белән).* Татар бит мин! *(Кызга сокланып карап тора.)*

Назимә *(күзләрен яшереп)*. Ник алай текәлеп карыйсың?

Хәбиб *(елмаеп).* Татар бит мин! *(Көлә.)*

Назимә. Анда, Финляндиядә, барыгыз да шулай яхшы сөйләшәсезме татарча?

Хәбиб. Тырышабыз. Карале, Назимә, Петербургка ни йомыш белән килгәнеңне ишеттем шикелле, әмма аңламый калдым.

Назимә *(кыяфәте тагын сагышлана)*. Бабамның полкташын эзләп килгәнием. Фин сугышында аларның рота командиры Ленинград кешесе булган — Лебедев Анатолий Евсеевич. Бабам шуны табарга кушкан иде.

Хәбиб. Таптыңмы соң?

Назимә. Оныгы Иринаны гына табып очрата алдым. Ә бабасы инде урын өстендә.

Хәбиб. Алай икән.

Назимә *(каядыр бер ноктага карап)*. Ә совет-фин сугышында Финляндия татарлары сугышканмы?

Хәбиб *(тавышында горурлык яңгырый)*. Әлбәттә. Ничек инде Туган ил өчен сугышмыйсың?!

Назимә *(уйчан кыяфәт белән)*. Сезнең Туган ил — Финляндия бит инде ул?

Хәбиб. Шулай. *(Тизрәк бу җитдилектән һәм сагышлы тоннан арыныр өчен тавышын күтәрә һәм ягымлылыгы шундук йөзенә чыга.)* Минем бер тәкъдимем бар: әйдә бу темага сөйләшмик. Бүген бәйрәм. Барлык татарларның бәйрәме.

Назимә (*гафу үтенгән сыман)*. Әй, минем кәефем арыганнан бозылды, шуңа күрә сөйләшүемнең атасы-анасы юк.

Хәбиб *(кинәт)*. Синең ашыйсың киләме?

Назимә. Бераз килә.

Хәбиб *(ягымлы итеп елмая)*. Кызлар «бераз килә» дисә, ул инде чынлап та килә дигән сүз. Әйдә, берәр җирдә берәр нәрсә алып утырып ашыйк.

Назимә *(елмаерга тырыша).* Әйдә.

Китәләр. Музыка яңгырый. Җыр ишетелә. Музыка һәм шатлыклы авазлар фонында сабантуй күренешләре. Бераздан Хәбиб белән Назимә пәйда булалар.

Хәбиб. Бәлки, тагын берәр көн Санкт-Петербургта булырсың?

Назимә. Юк, Хәбиб, миңа Казанга кайтырга кирәк.

Хәбиб. Минем сине җибәрәсем килми.

Назимә. Үзең дә иртәгә Хельсинкига кайтып китәсең инде.

Музыка. Бер-берсенә бик озак карап торалар.

Хәбиб *(визиткаларын бирә)*. Менә минем адресларым. Менә телефон номерларым. Мөмкинлегең булса, шылтырат. Хат язсаң да була. Синең телефоның бардыр бит?

Назимә. Мин бит Казанның үзенеке түгел. Казанга Чаллыдан килдем мин. Чаллыда телефоным бар, ә Казанда бер әбидә фатирда торам. Биримме соң адресларымны, Чаллыдагы телефонымны?

Хәбиб *(сөенеп)*. Әлбәттә. Ник аны сорап торасың!

Назимә *(кабаланып сумкасыннан блокнот белән авторучка ала, тиз-тиз Казандагы һәм Чаллыдагы адресын, Чаллыдагы телефон номерын язып бирә)*. Менә яздым. Мин әле бер ярты ай чамасы Казанда булам, аннары Чаллыга кайтып китәм.

Хәбиб *(кыздан күзләрен алмый)*. Бер дә аерылышасы килми.

Назимә. Минем дә. *(Үзен кая куярга белми.)* Уф, битем яна!

Хәбиб. Эссе бит.

Назимә. Шылтыратыгыз... Шылтырат.

Хәбиб. Син дә. Без хәзер бер-беребезне беләбез, без инде бер-беребезне тиз табачакбыз.

Назимә. Тик... онытырсың син мине.

Хәбиб *(нәрсәнедер исенә төшергән сыман талпынып)*. Ә мин тиздән тотам да Казанга килеп төшәм! Син Чаллыңа кайтып киткәнче үк. Бәлки, шуннан Чаллыга бергә кайтырбыз.

Назимә. Уф, тагын битем яна.

Хәбиб. Көне бик эссе.

Назимә *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Миңа кузгалырга кирәк.

Хәбиб *(шулай ук чак кына ишетелерлек тавыш белән)*. Мин сине озатып куям.

Китәләр. Музыка. Сабантуй тавышлары беркавым гөрләп тора да, сәхнә караңгылана. Төрле утлар балкый. Самолет утлары да җемелди. Өстән шәһәрне күзәткән күренешләр дә балкып ала. Төнге кала күренешләре. Төрле-төрле музыка яңгырап ала. Төрле телдә сөйләшкән тавышлар ишетелә. Телефоннан сөйләшкән тавышлар берсен-берсе каплап яңгырый. Бу тавышлар отыры кими. Эфирда Хәбиб белән Назимәнең телефоннан сөйләшүләре ишетелә.

Хәбиб *(телефоннан сөйләшкән тавыш)*. Алло! Назимә! Исәнме? Бу — мин — Хәбиб, Хельсинкидан шылтыратам.

Назимә. Исәнме! Ничек таптың институт номерын?

Хәбиб. Аның бер авырлыгы да юк. Кайсы телефонга чакырдылар соң сине?

Назимә. Декан бүлмәсендәгенә. Минем институтта икәнемне каян белдең?

Хәбиб. Күңелем сизде.

Назимә. Үзең әйбәт кенә кайтып җиттеңме?

Хәбиб. Аллага шөкер. Петербургта хушлашканыбызга нибары ике көн узды, ә минем өчен егерме ел узган сыман булды инде. Син минем күз алдымнан һич кенә дә китмисең.

Назимә. Шулаймы... Ә мин сине бүген төшемдә күрдем.

Хәбиб. Ничек итеп?

Назимә. Бик матур итеп. Монда мин иркенләп сөйләшә алмыйм.

Хәбиб. Ник?

Назимә. Кеше күп.

Хәбиб. Тиздән Казанга киләм. Очрашабызмы?

Назимә. Әлбәттә. Мин әле йә бүген, йә иртәгә иптәш кызымның телефоныннан сиңа шылтыратырмын.

Хәбиб. Ярар.

Музыка көчәя. Музыка тавышы кимегәч, эфирда тагын егет белән кызның сөйләшкәннәре ишетелә.

Назимә. Казанда коеп яңгыр ява. Кешеләр тегендә-монда чабыша.

Хәбиб. Бездә кичә яуды яңгыр.

Назимә. Шул сезнең яңгыр килеп җиткәндер инде монда.

Хәбиб. Әйе. Җил иссә дә, яңгыр яуса да, кояш елмайса да — болар барысы да безнең тарафтан, минем теләгем белән синең Казаныңа җибәрелә. *(Көләләр.)*

Назимә. Безнең бер районда давыл булып узды — агачлар ауган, берничә йорт җимерелгән... Анысын да син җибәрдеңме?

Хәбиб. Юк, юк, анысын мин түгел. Анысын башка кеше юллагандыр. *(Көләләр.)*

Назимә. Мин сине тагын төшемдә күрдем.

Хәбиб. Ничек итеп?

Назимә. Әйтмим.

Хәбиб. Ә мин сине бик сагындым. Шундый күрәсем килә.

Назимә. Чын әйтәсеңме?

Хәбиб. Шушындый ерак арадан ялган сөйлиләр димени?

Назимә. Минем бөтен битем яна... Ут кабынамы инде!

Хәбиб. Эсседер.

Назимә. Коеп яңгыр ява, дидем бит.

Музыка көчәя. Вакыт-вакыт эфирда бер-бер артлы һәм берсен-берсе бүлә-бүлә тавышлар яңгырап куя:

— Мин сине сагындым!

— Мин дә сине сагындым!

Музыка.

— Бүген Казанда көн якты.

— Бездә дә чалт аяз көн.

Музыка.

— Бүген төшеңдә күрдеңме мине?

— Әйтмим әле менә!

Музыка.

— Хельсинкига кунакка кил!

— Син бит үзең тиздән Казанга киләм дидең.

— Әйе, килеп бөтен Татарстанны айкап йөрисе бар әле.

Музыка.

Хәбиб. Петербург сабан туендагы очрашуыбызның һәр мизгеле хәтеремдә, һәр сызыгы, һәр чагылышы күз алдымда, һәр хәрәкәтең һәм балкышың күңелемдә.

Назимә. Кичә озак шылтыратмый торгач, мин бик борчылдым. Көне буе үземне кая куярга белмәдем.

Музыка.

Хәбиб. Мин сине шундый сагындым!

Назимә. Андый җыр бар. Беләсеңме?

Хәбиб. Беләм. *(Җырлап күрсәтә.)* Мин сине шундый сагынды-ы-ы-ым.

Назимә. Сизәсең микә-ә-ән шу-у-у-уны-ы-ы... *(Көлешәләр.)*

Алар телефоннан сөйләшкәндә эфирда шулай ук татар, фин, рус телләрендә Хельсинкидагы, Мәскәүдәге, Казандагы дикторларның вакытны, һава торышын һәм башка төрле көн саен кирәк мәгълүматларны әйткән авазлары ара-тирә яңгырап куя.

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Зариф өе. Тагын бүлмәсенең асты өскә килгән. Шкаф тартмалары ачык. Зариф башын куллары белән кысып караватта утыра. Ыңгыраша. Аның өянәге купкан һәм телсез калган. Сикереп торып шкаф тартмаларын актара. Янә караватына барып утыра да ыңгырашып башын куллары белән кыса. Көтмәгәндә өйнең бер почмагында 1939 елгы хәрби форма кигән фин солдаты пәйда була. Ул әкрен генә Зариф утырган якка карап өйнең бер почмагыннан икенчесенә атлый. Зариф башын күтәреп аңа карап тора. Ул өендәге өрәктән һич кенә дә курыкмый. Гомумән бу күренеш аны аптыраашта калдырмый — ул аны тып-тын гына күзәтә.

Фин *(авыз чите белән генә елмаеп)*. Ничек фин солдаты монда килеп чыккан дип аптырама, Зариф. Мин инде хәзер кайда телим, шунда йөрим.

Зариф *(чыраена газап чыгарып)*. Ы-ы-ы-ы-и-и-и...

Фин *(елмая)*. Алай нык кайгырма, Зариф. Күз чыгып, баш бетмәгән.

Зариф *(нидер әйтмәкче булып ыңгыраша)*. А-а-а-ы-ы-ы-и-и-у-у-у-ы-ы-ы...

Фин *(җитдиләнеп)*. Нәрсә булды соң сиңа? Тагын телең югалдымыни?

Зариф. А-а-а-и-и-и-е-е-е-ы-ы...

Фин. Үтәр, үтәр, анысы да үтәр.

Зариф. М-м-м-м...

Фин. Бу дөньяда барысы да, бөтенесе дә үтә. Бу дөньяда һәрнәрсәнең чиге, азагы бар.

Зариф. Ы-ы-ы-и-и-и-о-о-о-ы-ы-ы...

Фин. Кайгырма! Ул документның кемгә кирәге бар инде хәзер?!

Зариф. М-м-м-м...

Фин *(елмая)*. Их, Телсез Күке, Телсез Күке! Хәтерлисеңме, син мине теге вакытта яклаганда, минем хакта «телсез күке» бит ул дигән идең.

Зариф *(авызын кыйшайтып елмаерга тырыша)*. А-а-а-а-и-и-и-ы-ы...

Фин *(кайгылы тавыш белән)*. Их, Зариф, Зариф, нигә һаман үзеңдә җан газабын асрыйсың?!

Зариф. Ы-ы-ы-а-а-а...

Фин солдаты әкрен генә, гүя йөзеп, өйнең стенасы аша юкка чыга. Зариф өрәк югалган тарафка карап тора да тагын куллары белән башын кысып ыңгыраша. Зиновьев керә.

Зиновьев *(акцент белән татарча исәнләшә)*. Исянмесез! *(Зариф аңа төссезләнгән күзләре белән карап тора.)* Что?! Опять?! *(Түргә уза, бүлмә буйлап йөренә, як-ягына карана.)* В этот раз что украли?

Зариф. М-м-м-м... *(Калтырана.)*

Зиновьев *(картка игътибар белән карап тора)*. Понятно. Язык отнялся. Очередной приступ. «Скорую» вызвать?

Зариф *(«Юк» дигәнне аңлатып баш чайкый)*. Э-э-э-э-э...

Зиновьев. Давай я тебя сам в больницу повезу. Устрою в хорошее отделение, к хорошему врачу.

Зариф *(ыңгырашып баш чайкый)*. Ы-ы-ы-ы...

Зиновьев. Что-то очень нужное украли в этот раз?

Зариф *(«Әйе» дигәнне аңлатып баш кага)*. А-а-а-и-и-и-ы-ы-ы...

Зиновьев *(як-ягына каранып)*. Что именно?

Зариф дәшми.

Заявление будешь писать?

Зариф баш чайкый.

Что же тебя так потрясло? *(Элек телевизор торган тумбочкага карап тора.)* У тебя телевизор был. Старый, черно-белый. Утащили?

Зариф баш кага.

Очень жалко?

Зариф баш чайкый.

Ну да, из-за телевизора ты болеть не будешь, не такой ты человек. Что же еще украли у тебя?

Зариф дәшми.

Может быть, тебе стало известно, кто тебя грабит?

Зариф башын чайкый.

Ох-ох-ох... *(Урындыкка утыра.)* Жаль, что нельзя с тобой поговорить. Надолго это у тебя?

Зариф дәшми.

Приступ надолго, что ли, посещает? Немеешь надолго?

Зариф дәшми. Төссез күзләре белән Зиновьевка карап утыра, бераз калтырана.

Лекарства-то есть хоть какие-нибудь?

Зариф башын чайкый.

А нужны какие-нибудь лекарства?

Зариф башын чайкый.

Странный ты старик! Странный, странный, очень странный! *(Зиновьев урындыкка утырып папкасын актарырга тотына.)*

Бүлмәдә тагын 1939 елгы фин солдаты пәйда була. Ул стена аша үтеп керә һәм, йөзгән сыман, әкрен генә, Зариф ягына карап, өйнең бер почмагыннан икенчесенә юнәлә. Бу өрәкне Зиновьев күрми, ул Зарифка гына күренә.

Фин. Һәй, Зариф, һаман тынгылык бирмиләр үзеңә, әйеме. *(Зариф аңа карап тора, ә Зиновьев исә өрәкне күрми дә ишетми дә.)*

Зиновьев. Скучно будет без телевизора-то.

*(Зариф аңа игътибар итми, әкрен генә атлаучы өрәккә карап тора.)*

Фин *(Зиновьевка кашларын җыерып карый)*. Зариф, нәрсә мыгырдый ул?

Зиновьев *(кыяфәтен усалландырып)*. Ну, сволочи, даже старый телевизор унесли! Ты из-за телевизора, может быть, все-таки, так сильно расстроился?

Зариф *(Зиновьевка шактый вакыт карап тора).* Ы-ы-ы... *(«Юк» дигәнне аңлатып башын чайкый. Тагын өрәккә карап ката.)*

Фин *(Зиновьевка ачулы караш белән карый)*. Зариф, нәрсә быкырдый бу сәер кеше? Мин урысча аңламыйм бит.

Зиновьев. Зариф абы, все же протокол необходимо составить.

Зариф «кирәкми» дигәнне аңлатып баш чайкый.

Ну, что ты такой упрямый!

Фин. Нишләп сиңа бәйләнә ул, Зариф? Ник җавап бирмисең? *(Зариф ыңгырашып куя.)* Әй, син телсез калдың бит әле, онытып җибәргәнмен. Үтәр, үтәр. Өянәгең дә үтәр, телең дә кайтыр, Алла боерса. Ә бу кешегә телевизор өчен кайгырам дип әйт тә инде, шул ялган белән котыл. Нәрсә төпченеп утыра ул! *(Ачуланып.)* Чыгарып җибәр үзен тизрәк!

Зиновьев. Ну тебя же и впредь будут вот так грабить. Они появляются только тогда, когда тебя дома нет, да?

Зариф аңа карап тора.

Фин *(нәфрәтләнеп)*. Нәрсә кирәк аңа?

Зиновьев. Я хотел спросить, когда ты дома, воры не появлялись? Подозрительных людей не замечал в лесхозе, около дома?

Зариф башын чайкый.

Фин *(Зиновьевка ымлап)*. Зариф, игътибар белән кара әле, кемгә охшаган ул?

Зариф Зиновьевны җентекләп күзәтә.

Зиновьев *(картның күз карашыннан бераз югалып кала)*. Что ты, Зариф абы, на меня так смотришь?

Фин. Кара, кара. Берәр кешене хәтерләтмиме ул сиңа?

Зиновьев *(кәгазьләрен папкасына тутыра)*. Ну что ж, мне кажется, что ты не нуждаешься в помощи и не горишь желанием помочь милиции.

Фин *(таләпчән тавыш белән)*. Зариф, куып чыгар син аны! Юньле кешегә охшамаган. Ярый, үзеңә кара, киттем мин. Озак чирләмә, Зариф, тизрәк терел. Сау бул! *(Стена аша чыгып югала. Зариф ул киткән тарафка карап тора.)*

Зиновьев *(торып бүлмә буйлап атлый.)* У лесничего телефон есть. В случае надобности можешь позвонить вот по этому телефону.

Телефон номеры язылган кәгазь кисәген өстәлгә куя. Зариф Зиновьевка карап тора. Зиновьев аның кыза башлавын чамалый. Зариф кинәт сикереп тора да барып ишекне ача. Зиновьев аның ни теләгәнен аңлый һәм ишеккә таба юнәлә. Ишек катында туктап картка карый.

Я же тебе добра желаю. Хочу помочь.

Зариф Зиновьевны этеп чыгарып җибәрә һәм ишекне шапылдатып яба. Авыр музыка. Зариф өйнең түренә атлый.

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Яр Чаллы шәһәре. Вокзал. Ике авыр сумка күтәреп Назимә басып тора. Сумкаларын җиргә куя. Сәгатенә карап ала. Ыгы-зыгы. Шау-шу. Кеше авазлары, автобус тавышлары аша төрле яктагы киосклардан чуар музыка яңгырый. Дикторлар бер-бер артлы игъланнарын әйтеп торалар.

— С первой платформы отправляется автобус «Набережные Челны — Казань» рейсом на 8.30. Тугызынчы яртыдагы «Яр Чаллы — Казан» автобусы беренче платформадан кузгала.

— Готовится посадка на автобус «Набережные Челны — Заинск» рейсом на 9.00. Платформа — шестая. Сәгать тугызда китәчәк «Яр Чаллы — Зәй» автобусына алтынчы платформада утырту башлана.

— Водитель мензелинского автобуса, зайдите в диспетчерскую! Водитель мензелинского автобуса, срочно зайдите в диспетчерскую!

— Объявляется посадка на автобус, следующий рейсом «Азнакаево». Отправка в 9.15, с пятой платформы. Унынчы унбиш минутта кузгалачак Азнакай автобусына утырту башлана. Бишенче платформа.

— Водитель мензелинского автобуса, не слышите, что ли?! Зайдите в диспетчерскую! По-русски не понимаете, что ли?! *(Диспетчерскаяда үзара сөйләшкәннәре тышка ишетелеп тора.)* Гуля, скажи по-татарски, а то заколебал. *(Чәрелдәвек тавыш белән Гуля кычкыра.)* Минзәлә водителе, ишетмисең, что ли, диспетчерскига кер!

Назимә диспетчер тавышы килгән якка карап куя да, сумкаларын алып, читкәрәк барып баса. Беркавым торганнан соң ул ерактарак зур портфель тоткан бер кешене күрә һәм таң кала.

Назимә *(үзалдына)*. Әллә саташам инде... Күземә генә күренәме... Ул бит инде бу, ул! *(Теге кеше бу якка таба килә башлагач, Назимә дә аңа таба атлый.)* Әйе, нәкъ үзе! *(Каршылыклы хисләр кичерә, нишләргә белми — сөенергәме, көенергәме. Ләкин һичшиксез куану, шатлык өстенлек ала. Ул тирә-якны яңгыратып кычкыра.)* Хәбиб! *(Хәбиб үзенә эндәшкәннәрен ишетеп як-ягына карый һәм шундук Назиманы абайлап ала.)* Хәбиб!

Хәбиб *(Назиманы күреп ала һәм аның янына йөгерә)*. Назимә?!

Назимә *(шатлык катыш каушау белән)*. Хәбиб, синме бу?

Хәбиб *(шулай ук аптырашта кала, шуңа да карамастан чиксез шат)*. Мин. Ә бу — синме?

Назимә *(ни уйларга да белми)*. Ник, күрмисеңмени? Син... ничек монда килеп эләктең?

Хәбиб *(чиксез куанып)*. Хәзер мин сиңа барысын да аңлатам. Иң элек сиңа карап торыйм әле. *(Назимәгә карап тора.)*

Назимә *(оялып)*. Әй, бик җентекләп карама әле.

Хәбиб. Ник, ярамый мәллә?

Назимә. Кыяфәтем өчен оялам. Йокым туймады бүген.

Хәбиб *(ихлас күңелдән)*. Син тагын да чибәррәк хәзер.

Назимә *(гаҗәпләнеп һәм аңларга тырышып)*. Өченче көн Хельсинкидан шылтыратканда шулай тиз арада Чаллыга килеп чыгасыңны әйтмәгән идең.

Хәбиб *(Назиманы сокланып күзәтә)*. Син дә бит бүген Чаллыда буласыңны хәбәр итмәдең.

Назимә. Әйе шул.

Хәбиб *(шатлыгын бөтен кыяфәтеннән күрсәтеп)*. Карале, тагын нинди могҗизалы көн! Тагын сине очраттым!

Назимә *(сынаулы караш белән карап)*. Син мине күрергә дип махсус килмәгәнсеңдер бит?

Хәбиб. Минем ике төп эшем бар бу килүемдә. Берсе — Зыятдин бабамның әманәтен үтәү, икенчесе, әлбәттә, синең белән очрашу. *(Кызга карап туя алмый.)* Бик сагындым мин сине.

Назимә *(үпкәле тавыш белән)*. Син бит мине Казанда булырга тиеш дип уйлагансыңдыр. *(Бераз тынычланып.)* Иптәш кызларымнан шылтыратып сорадыңмы?

Хәбиб. Дөресен әйтәм, шылтыратып белешеп тормадым. Беренчедән, мин иң элек мондагы эшемне тәмамласам яхшырак булыр дидем. Аннан соң Казанда иркенләп синең белән бергә булырбыз дип өметләндем. Икенчедән, алдан кисәтмичә генә килеп чыгуым сиңа берникадәр сюрприз булыр дип тә уйладым. Ә син үзең телефоннан сөйләшкәндә ник әйтмәдең Чаллыга кайтып китәсеңне?

Назимә. Кичекмәстән кайтырга кирәк булды. Әни чакырды: бабаң авырый, кайт тизрәк, диде. *(Тәмам төшенкелеккә бирелә.)* Мин сине бүген дә төшемдә күрдем.

Хәбиб. Очрашасы булганга күргәнсең бу юлы. *(Кызның пошаманга калуына борчыла башлый.)* Нишләп кәефең төште? Син шат түгелме әллә?

Назимә *(Хәбибкә карап, аның ничек монда килеп чыгуы турында уйланып бимазалана)*. Шат. Ләкин әллә ничек килеп чыкты.

Хәбиб. Тормыш гел минутлап-секундлап төгәл бармый инде ул. Көтелмәгән мизгелләр дә килеп чыга. Безнең беренче очрашуыбыз да әллә ничек килеп чыкты бит.

Назимә. Әйе шул.

Хәбиб *(ихлас күңелдән)*. Мин сине шундый сагындым.

Назимә *(кыюсыз тавыш белән)*. Мин дә.

Хәбиб. Синең автобусың ничәдә китә соң?

Назимә. Сәгать унда.

Хәбиб. Минеке ничәдә икән?

Назимә. Син соң хәзер кая юл тотасың?

Хәбиб. Назимә, миңа бит Субай дигән авылга барырга кирәк.

Назимә *(тагын да ныграк гаҗәпләнеп)*. Субайга?!

Хәбиб. Әйе. Билетны кайсы кассадан алырга икән?

Назимә *(аптырашта калып)*. Субай автобусының үзендә кондуктор сата билетны. Ник анда барырга булдың соң син?

Хәбиб. Безнең нәсел чыгыш белән шуннан бит.

Назимә *(шаккатып)*. Чын әйтәсеңме?!

Хәбиб. Әйе. Башта инде, әлбәттә, сине Казанга озатып җибәрәм. Ә Субайга ничәдә китә икән автобус?

Назимә *(чиксез гаҗәпләнеп)*. Ике сәгать саен йөреп тора.

Хәбиб *(якты елмаеп Назимәгә карап туймый)*. Их, Назимә, Назимә! Карале син очрашуыбызны! *(Җитдиләнә.)* Син генә шат түгел бугай.

Назимә *(үзен кая куярга белми)*. Шат мин, шат. Тик... мин тәмам югалып калдым әле... Миңа әйтмичә килеп төшүең... Казанга түгел, Чаллыга...

Хәбиб. Соң, аңлаттым бит инде. Хәзер сине Казанга озатып җибәргәч, Субайга барып кайткач, туп-туры Казанга китәм — әлбәттә, иртәгә инде. Каршы булмасаң, туп-туры синең яныңа киләм. Кунакханә мәсьәләсен хәл итеп куячаклар анда. Син миңа Казанны күрсәтерсең. Казан турында минем сине сөйләтәсем килә. Яме. Субайга автобус кайсы тоштән китә соң?

Назимә *(саклык белән генә әйтә)*. Борчылма. Мин дә бит Субайга кайтам.

Хәбиб. Нәрсә дидең? *(Ышанмый тора.)*

Назимә *(үзен кулга алып һәм кыюрак тавыш белән)*. Минем Казанга барышым түгел. Мин хәзер Субайга кайтып барам.

Хәбиб *(илһамланып)*. Чын әйтәсеңме?

Назимә. Бабам чирли, шуның янына кайтып килергә кирәк.

Хәбиб. Бабаң шундамыни?

Назимә. Шунда.

Хәбиб. Димәк, бергә барабыз Субайга?!

Назимә. Шулай килеп чыга инде.

Хәбиб *(бәхетле икәнен яшерми)*. Карале, ә, могҗиза өстенә могҗиза!

Назимә *(сынаулы караш белән карап тора)*. Шикләнә башладым әле мин синнән.

Хәбиб. Ник?

Назимә. Егетләргә бик ышанырга ярамый ул.

Хәбиб. Назимә, бәгърем, син ташла әле мондый уй-хисләреңне!

Назимә. Ә хәзер Субайга кемнәргә барасың?

Хәбиб. Минем бабай чыгышы белән шул авылдан. Гәрчә анда инде бер туганнарыбыз булмаса да, юлга мин бабамның васыятен үтәргә дип чыктым. Әманәт дип атасаң да ялгыш булмас. Бабамның бабасы яшәгән нигезне, һич тә булмаса, шул нигез урынын табып баш иярга тиешмен. Димәк, синең бабаң Субайда яши?

Назимә. Субайдан ерак түгел.

Хәбиб. Нык авырыймы?

Назимә. Менә баргач күрәм инде. Син Субайда кунасыңмы?

Хәбиб. Күз күрер. Барып җитик әле. Аннары, миңа әле Субайдан да арырак бер җиргә барып кайтырга туры киләчәк. Автобус Субайдан соң кая бара?

Назимә. Кире Чаллыга китә. Ә син Субайдан ары тагын кая барырга җыенасың?

Хәбиб. Урманга. Анысы да мәрхүм бабамның гозере.

Назимә *(сискәнеп)*. Нинди урманга?

Хәбиб. Урман хуҗалыгына. Ничек атала әле ул урман? Бәрәкәт урманы дипме?

Назимә *(сагаеп)*. Әйе. Ә син... каян беләсең?

Хәбиб. Бабам сөйләде. Субайдан ерак түгел бит ул?

Назимә. Бер чакрымнан да кимрәк. Субай авылына терәлеп тора диярлек.

Хәбиб. Күке тавышлары да авылга ишетелеп торамы?

Назимә. Әйе, ишетелеп тора.

Хәбиб. Күкеләр һаман күпме анда?

Назимә *(каушый)*. Элек күбрәк булган.

Хәбиб. Урман хуҗалыгы һаман да бармы соң?

Назимә. Бар. Кая китсен ул. Сиңа урман хуҗалыгы ник кирәк соң?

Хәбиб. Субайның үзендә туган-тумачабыз булмаса да, ул тирәдә бер туганыбыз бар безнең. Мәрхүм бабам аны да эзләп табарга кушты. Тик менә миңа мәгълүм түгел — исәнме ул, юкмы. Исән булган суpәттә һаман да шул урманда яши микән, әллә башка тарафлардамы?..

Назимә *(киеренкелек белән)*. Кем соң ул?

Хәбиб. Бәлки, ишеткәнең бардыр: Күке Зарифы.

Назимә *(котсыз калып)*. Күке Зарифы?!

Хәбиб. Әйе.

Назимә *(нык дулкынланып)*. Исән ул!

Хәбиб. Син аны беләсең алайса?!

Назимә *(кычкырып диярлек)*. Беләм!

Хәбиб. Кайда яши ул?

Назимә. Шунда. Лесхозда.

Хәбиб. Кайда? Мин урыс сүзләрен аңламыйм.

Назимә. Шунда инде... Урман хуҗалыгында. Бәрәкәт урманында.

Хәбиб. Димәк, исән?!

Назимә. Исән!

Хәбиб. Син бик нык каушадың. Һаман миңа үпкәлисең бугай, әйеме?

Назимә *(нишләргә белми — сөенергәме, көенергәме)*. Юк, Хәбиб, үпкәләмим. Киресенчә, менә болай көтмәгәндә килеп чыгуың, бәлки, яхшырактыр да.

Хәбиб. Нишләп Зариф бабайны телгә алгач нык каушадың?

Назимә. Чөнки Күке Зарифы — минем бабам. Мин хәзер шуның янына кайтып барам.

Хәбиб *(канатланып)*. Менә сиңа мә! Син — Зариф бабайның оныгы?!

Назимә. Әйе, әйе.

Хәбиб. Төш дисәң, төш түгел бу! Әкияткә дә охшамаган! Син миңа үпкәләмә генә, зинһар.

Назимә. Юк. Ни өчен? *(Тынычлана башлый.)*

Хәбиб. Бәлки, бабаңны кушаматы белән атаганым өчен ачуың чыккандыр?

Назимә. Юк ла. Кушаматның нәрсәсе бар инде аның. Тик аны хәзер Күке дип кенә түгел, Телсез Күке дип тә атыйлар.

Хәбиб. Ник?

Назимә. Соңгы вакытта аның коточкыч өянәкләре кузгала. Тотлыга башлый. Торымнан-торымга телсез кала. Бөтенләй сөйләшә алмый. *(Күз яшьләрен көчкә тыеп тора.)* Өстәвенә шушы көннәрдә тагын бер күңелсез вакыйга булды. Өенә тагын караклар кергән. Субай зиратына, Кәшифә әбинең каберенә дип чыгып киткән. Кайтуына өенең астын өскә китергәннәр.

Хәбиб. Кәшифә — синең әбиеңме?

Назимә. Әйе.

Хәбиб. Кәшифә әби исән түгел икән...

Назимә. Син аның турында да ишеткәнең бар мәллә?

Хәбиб. Бар. Мин сиңа барысын да сөйләрмен.

Назимә. Бабай көн саен аның кабере янына бара. Алар шулкадәр бер-берсен яратканнар. Андый мәхәббәт китапларда гына була торгандыр.

Хәбиб. Каян белдең өен басканнарын, чирләвен?

Назимә. Хуҗалык җитәкчесенең телефоны бар. Шул шылтыратты. Хәле авыр чакта бабай врачлар да чакыртмый, әти-әнигә дә кайтыгыз дими, бары тик мине генә чакыра. Назимә кайтса, терелә мин, ди ул. Һәм чынлап та шулай. Мин кайтып бераз аның белән утыргач, аның өянәге бетә, теле ачыла башлый, берничә минуттан теле бөтенләй рәтләнә, сөйләшә башлый. Әти белән әни дә кайтырлар иде дә... Әти Красноярскида командировкада. Әнине эшеннән җибәрмәделәр. Менә үзем генә кайтам.

Хәбиб. Әле синең кеше дәвалау сәләтең дә бар икән.

Назимә. Мин бабамны гына дәвалый алам. Мине бик нык ярата ул. Кәшифә әбиемә охшаганмын мин. Шушы хәтле охшасаң да охшарсың икән дип шакката. Әбием яшь чакта җырлаган җырларны җырлатып ардырып бетерә.

Хәбиб. Үзе генә яшиме?

Назимә. Берүзе.

Хәбиб. Карт кешегә ялгыз яшәү... бигрәк тә урманда... бигүк дөрес түгелдер инде.

Назимә. Калага китәсе килми аның. Әти белән әни ялыналар. Мин ялынам — юк, китми урманыннан. Инде караклар бер ун тапкыр басканнардыр йортын.

Хәбиб. Ничә хуҗалык соң анда?

Назимә. Алты-җиде бугай.

Хәбиб. Ә караклар каян килә?

Назимә. Каладан. «Көмеш Күл» дигән шифалы сулы бер күл бар — шунда йөри шәһәр халкы. Юл нәкъ шул бабай торган тирәдән уза. Аның инде урлар нәрсәсе дә калмады. Бу юлысы иске телевизорын алып чыгып киткәннәр. Аклы-каралы телевизор. Юньләп күрсәтми дә иде инде.

Хәбиб. Ай-яй, начар икән.

Назимә. Туктале, минем бабай ник кирәк булды соң сиңа?! Шуны сорамыйм да.

Хәбиб. Ашыкма, Назимә, барысын да сөйләрмен. Зариф бабай турында, мәрхүмә Кәшифә әби турында да кайчан кемнән ишеткәнемне сөйләрмен. Тагын әллә нәрсәләр беләм әле мин. Ашыктырма. Минем хисләрем ташый. Шуңа күрә ашыктырма. *(Ул чыннан да каушый. Ләкин Назимәне очрату шатлыгы барыбер өстенлек ала.)*

Назимә. Чыннан да, могҗиза өстенә могҗиза! *(Назимә дә Хәбибне очратуына чиксез шат икәнен аңлый башлый — кәефе бераз күтәрелә.)* Мин дә сиңа автобуста барганда бабам белән әбиемнең яшь чакларын, ничек бер-берсен яратканнарын сөйләрмен.

Хәбиб. Ярар.

Назимә *(сискәнеп.)* Әй, әнә бит безнең автобус! Әйдә тизрәк! *(Сумкаларын күтәрә.)*

Хәбиб *(кызның кулыннан сумкаларын тартып ала).* Мин күтәрим. Киттек!

Хәбиб белән Назимә автобуска таба юнәләләр.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Утызынчы еллар ахыры. Зариф белән Кәшифәнең яшь чаклары. Алар икесе дә бәхетле. Аланда көлешә-көлешә куышып йөриләр.

Зариф *(Кәшифәне куып тота да кочакламакчы була).* Тоттым бит!

Кәшифә *(ычкынмакчы булып бәргәләнә).* Җибәр! Кулың кул түгел. Көрәк хәтле. *(Якында гына кәккүк кычкыра башлый.)* Тс-с-с. Кәккүк кычкыра. *(Туктап тыңлыйлар.)*

Зариф *(кәккүк тавышын саный).* Бер, ике, өч, дүрт...

Кәшифә *(кулы белән егетнең авызын томалый).* Санама.

Зариф. Ник? *(Кәшифәнең кулын ике куллап, кош тоткандай, саклык белән назлый.)*

Кәшифә. Куркам.

Зариф. Нәрсәдән?

Кәшифә. Саннардан гомумән куркам мин.

Зариф *(елмаеп).* Гомумән куркак син.

Кәшифә. Әйе шул. *(Җитди кыяфәт белән.)* Миңа кайтырга кирәк.

Зариф *(канәгатьсезлек белдереп).* Иртә бит әле.

Кәшифә. Синең белән урманда йөргәнемне белсә, әти мине бәреп үтерә.

Зариф. Син саннардан түгел, әтиеңнән куркасың.

Кәшифә. Әти бит ул.

Зариф *(бераз ачуланып).* Урманда йөрми, кайда йөрик тагын?! Авылыгызга килергә кушмыйсың бит миңа. Шпион шикелле урман авызыннан сезнең Субай авылын күзәтеп, борма-борма юлдан кайчан минем Кәшифәм килер икән дип зарыгып көтеп ятам.

Кәшифә *(үчекләп).* Читен булса, көтмә!

Зариф. Ник авылыгызга килүемнән куркасың?

Кәшифә *(башын аска иеп).* Оялам.

Зариф. Бер-беребезне яраткач, аны кешеләр сизсә дә, берни юк инде.

Кәшифә *(җитди кыяфәт белән).* Миңа беркөнне әти әйтә: «Кызый, сине лесник малае белән күргәннәр»,— ди. «Нинди лесник?» — дип әйтеп ташладым. «Башыңны җүләргә салма, бездә лесник берәү генә — Күке Хәбибрахманы,— ди.— Шуның башкисәр малае белән урманда икегезне күргәннәр,— ди.— Смотри!» — дип йодрык селкеп янады. Җир тишегенә кереп китәрдәй булдым.

Зариф *(кашларын җыерып).* Башкисәр булырлык нишләгән әле мин?!

Кәшифә. Авылыбызга килгән саен берәрсе белән сугышып китәсең бит.

Зариф. Егетләрегез шундый бәйләнчек булгач...

Кәшифә. Дөресен әйткәндә, авылыбызга килүеңә мин шуңа күрә каршы да.

Зариф. Нәрсәгә күрә?

Кәшифә. Авылыбыз егетләре сине дошман иткәнгә.

Зариф. Син — Субай авылының иң чибәр кызы. Шуңа көнләшеп гел мине кыйнамакчы булалар алар.

Кәшифә. Аңа түгелдер. Син үзең кыргый. Алар белән рәтләп сөйләшә дә алмыйсың. *(Көлә.)* Урман кешесе урман кешесе инде ул.

Зариф. Көл әйдә, көл.

Кәшифә *(серле итеп елмая).* Минем синнән күптән сорыйсым килә...

Зариф. Нәрсә сорыйсың килә?

Кәшифә. Нишләп сезнең кушаматыгыз «Күке»?

Зариф *(коры гына).* Белмим. Урманда яшәгәнгәдер.

Кәшифә. Кызык... Күке Хәбибрахманы... Күке Зарифы! *(Үчекли.)* Әй, Күке Зарифы-ы-ы, ишетәсеңме?! Ачуың киләме?

Зариф. Юк. Нишләп минем ачуым килсен. Субайда акылга тулы кеше юк бит анда. Субай кешесенә мин бераз скидкә ясыйм, ачуланмыйм да, үпкәләмим дә. *(Рәхәтләнеп көлә.)*

Кәшифә. Аһ, әле син шулаймы?! Димәк, мин дә тулы түгел?! *(Зарифны егарга тырыша.)*

Зариф *(көлә).* Соң, акылга зәгыйфь булмасаң, урман хәтле урманга килеп йөрер идеңмени?!

Кәшифә *(Зарифны ныграк җилтерәтергә тотына).* Аһ, оятсыз! Нәрсә дип торган була бит! Моннан соң эземне дә атламыйм!

Зариф *(көлүдән туктый).* Алайса, мин үләм. *(Кыяфәте җитдиләнә. Кәшифәне иңнәреннән коча.)* Минем һәр көнем сине генә уйлап үтә, җанкисәгем!

Кәшифә *(Зарифның күзләренә карап тора).* Мин дә бит гел сине генә уйлап йөрим, тиле булсаң да.

Зариф *(Кәшифәне тәмам кочагына ала).* Синнән башка бу дөньяның бер генә дә яме булмас иде.

Кәшифә. Көн туса, минем ике күзем сезнең урман ягында инде. Әйтерсең лә минем өчен яшәүнең бөтен мәгънәсе шул тарафларда. *(Зарифның куенынннан шуып чыга.)*

Зариф. Әле син белмисеңдер...

Кәшифә. Нәрсәне?

Зариф *(горур һәм шул ук вакытта шөбһәле тавыш белән)*. Мине тиздән армиягә алачаклар.
Кәшифә *(кинәт моңсуланып)*. Ишеттем инде.
Зариф. Каян ишеттең?
Кәшифә. Авылда сөйләштеләр. Авылыбыздан китәсе егетләрне атаганнан соң, сине дә әйттеләр. Шунда йөрәгем жу итте. Минем әле моңарчы ышанасым килмәде. Үзең бу хакта әйтмәгәч, бәлки, китмәссең дип уйлап йөрдем. Димәк, армиягә алачаклар, дөрестән дә?
Зариф. Әйе.
Кәшифә *(сөмсере коела)*. Бик ямансу булачак икән. *(Шаярырга тырыша, ләкин бик моңсу килеп чыга.)* Урманда бер күке кимеячәк. Күкеләрнең берсе кычкырмый торачак икән урманнан авылыбыз ягына.
Зариф *(башын читкә борып)*. Сиңа кызык...
Кәшифә *(кинәт елап җибәрә)*. Аптыраганнан шаярам мин, Зариф. Мин инде үземне кая куярга белмим. Өйдәгеләр дә ник борчылуымның сәбәбенә төшенделәр, ахрысы. Куркам мин никтер!
Зариф. Нәрсәдән куркасың?
Кәшифә. Син барасы армиядән куркам! Җибәрәсем килми анда сине!
Зариф. Кирәк бит, кирәк. Егет кеше солдат булырга тиеш ул.
Кәшифә. Синсез бик ямансу булачак. Мин сине шундый сагыначакмын.
Зариф. Сагынып туйгач мине онытмассыңмы соң?
Кәшифә *(елаудан туктый)*. Тиле. Сине онытырлыкмы соң?! Мин сине өзелеп сагынып, зарыгып көтәчәкмен.
Зариф. Хат язарсыңмы?
Кәшифә. Әлбәттә. Ә син?
Зариф. Мин дә вакыт булган саен, җай чыккан саен сиңа хат язармын. Мин сине инде киткәнче үк сагынырга өлгердем.
Кәшифә. Мин дә инде аерылышканчы ук күңелемдә сиңа бер хат яза башладым.
Зариф. Мин матур яза белмим инде, гаеп итмәссең. *(Елмая.)*
Кәшифә. Ничек язсаң да, ничек әйтсәң дә — минем өчен барысы да матур.
Зариф. Рәхмәт.

Кәккүк кычкыра башлый.

Кәшифә *(саный башлый)*. Бер... ике... өч... дүрт... биш.
Зариф *(кулы белән кызның авызын каплый)*. Санамыйк.
Кәшифә *(егетнең кулын үзенең битенә тигезә)*. Ярар, санамыйк.
Зариф. Кәшифә!
Кәшифә. Ә?
Зариф. Теге җырны җырла әле.

Кәшифә җырлый.

Күбрәк сана, кәккүк, күбрәк сана,
Санга сугып санар саннарны,
Гомер дисбесенең төймәләрен —
Икәү бергә узар елларны.

Күп санама, кәккүк, күп санама
Башка төшәр хәсрәт саннарын;
Өметләрем инде бер өзелсә,
Сине бүтән тыңлый алмамын.

Саный кәккүк үзе белгән көйгә
Айлы төнне, алсу таңнарны;
Ә йөрәкләр үз көенә тибә
Санламыйча сансыз саннарны.

*(Саннар)*

Кәккүк кычкыруын дәвам итә.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Зариф карт самавыр куеп йөри. Назимә белән Хәбиб килеп керәләр. Зариф аларга карап тора. Назимәне күреп елмая.

Назимә *(карт янына йөгереп килә)*. Бабай! Мин кайттым! *(Бабасын елый-елый кочаклый.)* Тагын чирләдеңмени?
Зариф. А-а-а-ы-ы-и-и-ы-ы...
Назимә. Тагын өеңне бастылармы?

Зариф *(шатлыктан күзләре яшьләнә, кызының чәчләрен сыпыра).* К...к...к...ы-ы-ы...
Назимә. Кызым дип әйтмәкче буласың, беләм.
Зариф *(«Әйе» дигәнне аңлатып баш кага).* К...к...к-ы-ы-ы...
Назимә. Бабай, терелә башларга кирәк. *(Елмаерга тырыша.)* Болай ярамый.
Зариф *(авызын кыйшайтып елмаймакчы була)*. А-а-а-ы-ы-и-и...
Назимә. Син бит һәрвакыт мин кайткач тереләсең.

Зариф «Әйе» дигәнне аңлатып баш кага.

Синең бит мин янында булганда телең ачыла, сөйләшә башлыйсың.

Зариф *(Назимәне иңеннән кочып караватка утырта. Үзе янәшә утыра да кызыннан күзләрен алмыйча карап тора. Шатлыгы бөтен кыяфәтенә чыга).* К...к...кы-ы-ызы-ы-ым...

Назимә *(чиксез шатланып)*. Менә бит, бер сүзне инде әйттең. Самавыр куйдың мәллә, бабай?

Зариф. А-а-а-и-и-ие-е-е.

Назимә. Бик әйбәт. Без сиңа күчтәнәчләр алып кайттык. *(Йөгереп барып сумкаларны актара, төрле төргәкләр чыгара. Бу вакытта Хәбиб нишләргә белми аптырап тора. Ул һаман ишек катыннан китми.)*

Зариф *(Хәбибкә таба атлый).* М-м-м... с-с-с-ине-е... ты-ты-тыа-а-аныйм.

Хәбиб *(Зарифка таба атлый һәм ике кулы белән картның калтыранган кулын тотып күрешә).* Исәнме, Зариф ага!

Зариф *(егетне җентекләп күзәтә).* Ат...т...т...тыңны-ы-ы оныт-т-тым.

Назимә. Бабай, юк, юк, сиңа таныш кеше түгел бу.

Зариф. К...к...айда к...к...күрдем...

Хәбиб *(каушый һәм картны җентекләп күзәтергә тырыша, ниндидер таныш сызыклар, сыйфатлар эзләгән сыман карый)*. Юк, бабай, без синең белән таныш түгел.

Назимә. Бабай! Син утырып кына тор әле. Хәзер чәй әзерлим. *(Самавыр белән мәш килә.)* Ничә чәйнек алып кайтып бирдем инде үзенә. Тефаль да, нимеснекен дә. Юк, самавырдан башка бернәрсәне танырга теләми. Хәер, аның инде бөтен чәйнекләрен урлап бетерделәр бугай.

Зариф *(урындыкка утыра, егетне һаман җентекләп күзәтә).* М-м-мин с-с-сине б-б-беләм... Оныт-т-т-тым гына. *(Аның һәрбер әйткән сүзе газап белән, авырлык белән чыга.)*

Назимә *(табын әзерли-әзерли).* Бабай, бераз тынычлан. Мин сине ашатам-эчертәм башта. Аннары ул егетнең кем икәнен салмак кына аңлатырмын. Йә үзе аңлатыр.

Зариф *(кызына мөрәҗәгать итә)*. К-к-кияү т-т-т-түгелдер бит?

Назимә *(оялып)*. Юк.

Хәбиб. Чыннан да, соңрак кем икәнемне аңлатырмын. Ерактан килдем мин. Хәбиб атлы булам.

Зариф *(хәтерендә казынып йөзен сыта)*. Н-н-н-нишләп соң йөзең т-т-таныш? Мин б-б-б-беләм б-б-бит сине.

Хәбиб *(дулкынлануын яшерер өчен башын читкә бора).* Мин дә беләм сине, Зариф ага. Мин синең янына махсус килдем.

Зариф. М-м-м-илициядән т-т-түгелме?

Хәбиб. Юк, милициядән түгел.

Назимә. Өеңне баскач, милиция килдеме соң?

Зариф. Әйе.

Назимә *(килеп бабасының аркасыннан кага)*. Бабай, маладис, кичкә тәмам телең ачылып җитәчәк. Мин сиңа шундый шәп дарулар алып кайттым — төрле үләннәрдән, бернинди химиясез.

Хәбиб. Өеңне талаганга бик каты авырып киттеңме?

Зариф *(газаплы тавыш белән)*. Әй, б...б...балала-а-а-ар... М-м-миндә б-б-бер ды-ды-дыкуминт сак-к-к-клана иде... Шуны урлаганнар.

Назимә. Кайсы документыңны урладылар, бабай?

Зариф. Фе-фе-еин-е-е-е-я-я.

Хәбиб. Нәрсә дисең, бабай?

Зариф. Фе-фен..нән-дия...

Хәбиб. Финляндия?

Зариф *(башын кага)*. Т...т...тарыныкы.

Хәбиб. Финляндия татарыныкы?

Зариф *(тиз аңлауларына куанып елмая)*. А-а-а-и-и-и-е-е-е.

Хәбиб. Бик кадерле документ идемени?

Зариф. Әйе.

Назимә *(пышылдап).* Хәбиб, әлегә кем икәнеңне әйтми тор. Нык каушавы ихтимал. Соңрак, яме.

Хәбиб. Ярар.

Назимә *(кычкырыбрак бабасына мөрәҗәгать итә)*. Бабай, Хәбиб вакыты җиткәч үзе сөйләр: кем икәнен дә, ник килгәнен дә, яме. Төпченми тор, зинһар.

Зариф. Ярар. Ашыкт...т...т...ы-ы-ырмыйм. Үзе ашык...к...к..ма-а-а-аыса...

Хәбиб. Мин беркая да ашыкмыйм. Мин сине күрергә, синең белән сөйләшергә дип махсус килдем.

Зариф *(авырлык белән аңлата)*. Аның ды-ды-дыа-а-к...к...к-у-у-ументы м...м...и-и-индә... чакта әле к...к...кү-ү-үүңелем...м...м...мдә өмет бы-бы-быа-а-ар иде... М...м...мин сезгә ял ит...т...ткәч, т...т...телем рәт...т...тләнгәчрәк бы-бы-быа-а-арысы-ы-ын ды-ды-да-а-а сө-ө-өйли-и-им.

Музыка. Назимәнең тагын күз яшьләре тәгәри. Хәбибнең дә күңеле тула. Ул Зарифны иңеннән коча да, башын читкә борып, күңеле тулганны күрсәтмәскә тырыша.

Музыка.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Зарифның сөйләгәне эфирда яңгырый.

Зариф: Армиягә китәр көн дә килеп җитте. Китәргә берничә көн кала урманда һәр таныш агач белән, үзем утырткан һәрбер үсенте белән хушлашып йөрдем. Мең тавышлы һәм мең шифалы урман авазын тыңлап туймадым. Чит җирләрдә колагымда яңгырап туган якны күңелемдә булса да якынайтып торыр бу сихри авазлар дип уйладым. Субайдан да ике егетне алдылар армиягә. Минем аларның икесе белән дә сугышканым бар иде. Ә менә солдатка китә башлагач, бернинди үзара дошманлык, бернинди үпкә-нәфрәт калмаган иде беребездә дә. Кәшифә мине озата барганга алар фәкать якты күнләшү белән безнең өчен куанып кына карадылар. Кәшифә дә мине озата баруына, миңа карата булган хисләрен яшермәве белән хәтта горурлана да иде шикелле. Чөнки ул инде ата-анасыннан да, авылдашларыннан да мине яратуын яшерми иде. Аның янәшә булуы еракка һәм озакка китүемне күпмедер вакытка бөтенләй оныттырды.

Инде минем туган-тумачам һәм Субай егетләрен озатучылар ерактан кулъяулыклар болгап калганда, Кәшифә әле һаман минем белән янәшә атлады. Без башкалардан арттарак калып бардык. Әйтәсе сүзләр, җиткерәсе хисләр шулкадәр күп иде ки, алар барысы да буылып бер төенгә тупланды да, без бер-беребезгә бер аваз да сала алмый шактый вакыт тып-тын бардык.

Кәшифә *(кулъяулык бирә)*. Сакла, яме.

Зариф. Ярар. *(Кулъяулыкны кесәсенә тыга.)*

Кәшифә *(үпкәле тавыш белән)*. Ник фоторәсемемне сорамыйсың?

Зариф. Бармыни?

Кәшифә. Инде оныткан да. Мин сиңа вәгъдә биргән идем бит рәсememне бүләк итәм дип. *(Кулындагы төргәгеннән саклык белән генә рәсемен алып Зарифка бирә.)*

Зариф *(шатлыгы йөзен балкыта)*. Рәхмәт, Кәшифә!

Кәшифә. Әле тагын бер әйбер бирәм мин сиңа. *(Төргәгеннән пәке алып бирә.)*

Зариф. Бусы да миңамы?

Кәшифә. Сиңа булмый, кемгә булсын инде.

Зариф *(пәкене чалбар кесәсенә тыгып куя)*. Рәхмәт яусын! *(Кызны кысып кочаклый.)*

Кәшифә. Ул хәтле каты кысма, тиле! Барып җитү белән хат яз. *(Юлдан атлыйлар.)*

Зариф. Язармын. Син мине көт кенә.

Кәшифә. Мин сине инде менә хәзер үк көтә башладым.

Зариф. Көткәндә вакыт озак бара инде ул.

Кәшифә. Армиядә сезне тик тотмаслар, анда бигүк сагышланып утырырга вакыт та булмас.

Зариф. Әйе, солдатка тынгылык юктыр инде ул.

Кәшифә. Ә мин быел педучилищега керергә җыенам.

Зариф. Миңа бу турыда әйтмәгән идең.

Кәшифә. Әллә ничә тапкыр әйтергә җыендым. Моңарчы икеләнеп йөргәнгә әйтергә ашыкмадым. Хәзер инде, син дә армиягә киткәч, һичшиксез укырга кереп карыйм. Вакыт та, бәлки, тизрәк узар. Аннары, минем укытучы буласым килә. Шундый хыялым бар.

Зариф. Укуга чумып мине онытмассыңмы соң син?

Кәшифә. Менә карыйбыз инде, нәрсә кыйммәтрәк — укумы, синме. *(Көлә.)*

Зариф *(шелтәле тавыш белән)*. Синең шул көлү булыр инде!

Кәшифә *(кинәт моңсулана)*. Син исән-сау әйләнеп кенә кайт, Зариф. Синең армиягә китүең, бәлки, синең белән минем өчен әһәмиятледер.

Зариф. Ник алай дисең?

Кәшифә. Бер-беребезнең кадерен белү, ныграк ярату өчен аерылышып тору, бәлки, кирәктер дә. *(Тагын кинәт көлә башлый.)* Субай халкы да бераз ял итәр үзеңнән. Урманнан Күке Зарифы килми башлагач, авылыбызда сугышучы да юк, дип сөенерләр. *(Кычкырып көлә.)*

Зариф *(шелтәләсә дә елмая)*. Һаман көләсең син миннән.

Кәшифә *(тагын да кычкырыбрак көлә)*. Көлми нишлим соң?! *(Көлә-көлә истерикага бирелә. Көлүе кинәт елауга күчә. Ул сулкылдап-сулкылдап елый башлый.)* Белсәң иде, сине ничекләр җибәрәсем килмәгәнне. Мин бит инде әллә ничә көн эти-әнидән качып елыйм да елыйм. *(Туктыйлар.)*

Зариф *(кочаклап юата)*. Кәшифә, акыллым, болай ук кирәкми. Елау ярый, ләкин болай ук түгел.

Кәшифә *(сулкылдый-сулкылдый)*. Мин бит һәрвакыт үземнең борчылуымны, газабымны киметер өчен синнән көлгән булам.

Зариф *(юмалап)*. Көл, көл миннән. Чынлап та көләрлек бит. Авылыгызга синең яныңа барган саен егетләрегез белән сугышып кайта идем бит. Берсендә бөтенләй билдән тиң шәрә тән кайтып киттем. Чөнки күлмәгемне киярлек түгел — ертылып чүпрәк кисәгенә әверелгән иде. *(Икесе дә көлә башлыйлар.)*

Кәшифә *(күз яшьләре аша көлеп)*. Инешкә төшеп сине юындырдым әле мин анда.

Зариф. Әйе шул. *(Рәхәтләнеп көлешәләр.)*

Кәшифә *(көлүдән туктап)*. Канга баткан идең бит син анда.

Зариф. Булса ни. Аның каравы син мине мамыктай кулларың белән инештә юындырдың. *(Кәшифәнең тагын күз яшьләре ага башлый. Зариф аның ничек булса да күңелен күтәрергә тырыша.)* Хәтерлисеңме, безнең кушаматыбыз белән кызыксынган идең?

Кәшифә. Ничек кызыксынган идем?

Зариф. Нишләп безнең кушаматыбыз «Күке» дип сораган идең.

Кәшифә. Әйе.

Зариф. Әйтимме?

Кәшифә. Әйт.

Зариф *(җитди тавыш белән сөйли)*. Безнең нәсел урманда яшәгән бит инде — бабамның бабасыннан алып. Минем әти бәләкәй чакта (дүрт-биш яшьлек булгандыр), күке тавышы ишетелгән якка таба киткән. Күке кычкыра да кычкыра икән. Әти һич кенә дә таба алмый. Кайдадыр якында гына да шикелле, ә үзе һаман күренми. Шулай агач башларына карый-карый йөри торгач адашкан бу. Бик озак эзләгәннәр этине. Инде көн кичкә авышкач, бабай Субайга төшеп халыктан ярдәм сораган. Бөтен авыл халкы белән урманны капшый торгач этине тапканнар. Елап шешенеп, инде тәмам тавышсыз калып зур агач төбендә калтыранып утыра икән. Шактый ерак кергән булган урман эченә. Нишләп монда кереп адаштың, дип сорагач, күкене эзләдем, дип җавап биргән. Шуннан соң эти мәңгегә Күке Хәбибрахманы булып калган. Хәзер инде миңа да күчте ул кушамат. Күке Зарифы булып йөрим. Һәм һич кенә дә гарьләнмим. *(Елмаеп Кәшифәгә карый.)* Тынычландыңмы?

Кәшифә. Тынычландым.

Эрактан *(кычкыралар)*. Зариф! Әйдә тизрәк, соңга калабыз!

Зариф. Хуш, Кәшифә!

Кәшифә. Исән-сау әйләнеп кайтуыңны көтәм!

Эрактан *(кычкыралар)*. Зариф!

Зариф. Үпкәләткән чакларым өчен гафу ит!

Кәшифә. Нинди үпкәләткән чаклар инде ул! *(Үзе елый, үзе елмаерга тырыша.)*

Эрактан *(кычкыралар)*. Зариф!

Зариф. Кәшифә!

Кәшифә. Зариф! *(Кочаклашалар.)*

Зариф. Хуш! *(Йөгерә.)*

Музыка. Караңгылык урнаша. Еракта, офык сызыгында прожектор утлары уйнаклый. Радиоалгычтан төрле дулкыннарны эзләгән тавышлар килә. Төрле телләрдә дикторлар сөйләве, бөтендөнья музыкасы берсен-берсе алыштырып эфирда яңгырап тора.

Молотов — Председатель Совнаркома и народный комиссар иностранных дел СССР:

...В особом положении находятся наши отношения с Финляндией... Советско-финская граница «нависла» в 32 километрах над Ленинградом, и с этим нельзя мириться... Сообщение западной прессы, будто СССР требует себе город Випури (Выборг) и северную часть Ладожского озера — это чистый вымысел и ложь... (Речь Молотова в Верховном Совете 31 октября 1939 г.)

Радиодулкыннар үзгәрә.

Эркко — министр иностранных дел Финляндии (фин телендә):

...Требование СССР касается якобы отдаления границы у Ленинграда на несколько километров. Но с точки зрения Финляндии, это русский империализм... Всему есть свои границы. Финляндия не может пойти на предложения Советского Союза.

Буденный:

...Держите, товарищи, порох сухим, возьмите свои клинки, готовьте коней к большим боевым походам... (Из статьи в «Правде» к 20-летию Первой Конной армии — 19 ноября 1939 г.)

Сталин:

...Нам придется воевать с Финляндией... (Высказывание на военном совете.)

Каяндер — премьер-министр Финляндии (фин теләндә):

...Поскольку на переговорах трудно было найти общую платформу, они пока прервались. Об этом следует сожалеть, так как Финляндия искренне желает поддерживать хорошие отношения со всеми соседями. (Из речи 23 ноября 1939 г.)

Молотов:

...Советско-финские переговоры начались недавно по нашей инициативе. Что являлось предметом этих переговоров? Нетрудно понять, что в современной международной обстановке, когда в центре Европы развертывается война между крупнейшими государствами, чреватая большими неожиданностями и опасностями для всех европейских государств, СССР не только имеет право, но и обязан принимать серьезные меры для укрепления своей безопасности...

...Наши предложения финнам:

1. Отодвинуть на несколько десятков километров границу на север от Ленинграда (в обмен на вдвое большую территорию в Советской Карелии);

2. Аренда территории у входа в Финский залив для размещения военно-морской базы;

3. Обмен нескольких островов, а также части полуостровов Рыбачий и Средний в Баренцевом море на вдвое большую территорию;

4. В случае принятия своих основных предложений СССР готов отказаться от возражений против вооружения Финляндией Аландских островов.

Эркко — министр иностранных дел Финляндии (фин теләндә):

...Финляндия не может пойти на предложение Советского Союза и будет защищать любыми средствами свою территорию, свою неприкосновенность и независимость...

Кэрк — Главнокомандующий Королевскими Вооруженными силами Великобритании (инглиз теләндә):

...«Линию Маннергейма» никакая армия не в состоянии разбить.

Шомлы музыка.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

1939 ел. Совет-фин сугышы. Кыш. Фронт. Карелия муентыгы. «Маннергейм линиясе» алдындагы урман. Бар дөньяны ап-ак кар баскан. Бер рота совет солдатлары килеп туктый.

Лебедев. Рота! Стой, раз-два! Напра-во! Товарищи солдаты! Финны яростно сопротивляются. Ожидается их контрнаступление на нашем участке. Оборону занимаем на опушке. Но необходима предельная осторожность — в лесу на деревьях, в подвешенных гамаках устроились так называемые «кукушки». Это финские снайперы. Многие из них готовы к смерти, и они презирают и страх, и смерть. Так что и даже в тылу мы имеем опасность. Ожидается подкрепление. Так как на нашей базе имеется важный груз с сопровождающими его людьми. Должен сказать, отступать мы не имеем права. Все. Больше нечего сказать. Думаю, непонятного ничего нет. Рота! Равняйсь! Смирно! Десять минут перекур. Вольно! Разойдись!

Үзенең блиндажыннан капитан Зимин килеп чыга.

Зимин. Анатолий Евсеевич, помнишь, мы с тобой приметили пять человек?

Лебедев. Помню.

Зимин. Дай мне их.

Лебедев. Товарищ капитан, у меня и так людей мало. Сейчас я их выделить вам никак не могу.

Зимин. За эти секретные снаряды отвечаю я — представитель особого отдела НКВД капитан Зимин. Понял?!

Лебедев. В том то и дело, что теперь за сохранность этих снарядов более ответственен я — командир роты старший лейтенант Лебедев. У вас двенадцать человек...

Зимин. Они все считаются военными, но они физики и химики — сотрудники научно-исследовательских институтов. А пять солдат я у тебя прошу, чтобы они прочесали лес вокруг базы. Меня эти «кукушки» сильно тревожат. Заодно эти ребята могли бы разведать удобные места для хранения снарядов.

Лебедев. Финских снайперов именно возле базы нет, это точно. Чуть подальше «кукуют», это правда. *(Уйланып тора.)* Ладно, ребят все же я вам дам.

Зимин. Спасибо. Я минут через десять вернусь. Пусть ждут меня здесь. *(Китә.)*

Лебедев. Рота! Становись! Равняйсь! Смирно! Рядовой Шаталов!

Шаталов. Я!

Лебедев. Рядовой Рассуханов!

Рассуханов. Я!

Лебедев. Рядовой Севрюгин!
Севрюгин. Я!
Лебедев. Рядовой Яхно!
Яхно. Я!
Лебедев. Рядовой Зайнуллин!
Зариф. Я!
Лебедев. Кого я назвал — выйти из строя на два шага! *(Биш солдат чыгалар.)* Вы остаетесь в распоряжении капитана Зимина. Командиром отделения назначаю Шаталова.
Шаталов. Есть!
Лебедев. Ждите Зимина. Он сейчас подойдет. Рота! Нале-во! Шаго-о-о-м марш!

Рота китә. Калган биш солдат ауган агач ботакларына утырышалар.

Яхно *(гәҗит кисәгенә махорка төрә)*. Что, склады будем охранять?
Севрюгин. Хрен его знает. Ты мне оставишь покурить?
Яхно. Оставлю. Ваня! Слышь, Шаталов, зачем нас оставили? *(Тәмәкесен тирән итеп суыра.)*
Шаталов. Не знаю. *(Куен кесәсеннән саклык белән генә ниндидер сигарет чыгара. Иснәп карый.)* Пахнет здорово!
Севрюгин. Трофейные?
Шаталов *(сигаретын кабыза)*. Да, настоящая финская сигарета.
Севрюгин. Еще есть?
Шаталов. Последняя.
Яхно. Вань, ты че, не слышишь?
Шаталов. Чего тебе?
Яхно. Зачем нас выделили, для чего здесь оставили?
Шаталов. Ты что, глухой! Я же тебе сказал: не знаю.
Яхно. Раз тебя старшим назначили, думал, знаешь.
Севрюгин. А этот капитан... как его...
Шаталов. Зимин.
Севрюгин. Этот Зимин из НКВД? *(Тынлык.)* Шаталов, че молчишь-то?
Яхно. Да, да, из Особого отдела. Есть такие отделы... И не говори громко.
Шаталов. Разговорчики прекратить! Болтаете много.
Яхно. А че не поболтать-то?! Может быть, мы в последний раз вот так разговариваем. *(Тәмәкесен Севрюгинга бирә. Севрюгин тирән итеп тарта башлый.)*
Рассуханов *(гел кавказ акценты белән сөйләшә)*. Что ты хочешь сказать?
Яхно. А то, дорогой мой Асланбек Рассуханов, думается мне, что нас тоже «кукушками» сделают.
Рассуханов. Как это?
Яхно. Посадят на макушки деревьев. И ежели вдруг роте придется отступать, то мы в тылу у финнов окажемся. И должны будем финнов поодиночке на мушку брать.
Севрюгин. Говорят, эти финские снайперы все из гражданского населения.
Яхно. Я тоже слышал.
Рассуханов *(уйга калып)*. Мы же тоже из гражданского населения.
Севрюгин. Говорят, иногда целым батальонам голову поднять не дают.
Яхно *(кинәт җанланып)*. А правда, что за сбитие «кукушки» без разговоров дают орден Красного Знамени, а то и Героя?
Севрюгин *(бик хәбәрдар кеше кыяфәте белән)*. Нет, за одного снайпера Героя не дадут.
Шаталов *(каты һәм кырыс булырга тырышып)*. Разговорчики!
Рассуханов. А ты, Шаталов, не знаешь, что делать будем?
Шаталов *(кырт кисеп)*. Дождемся Зимина. Он все объяснит. *(Сигаретын сүндерә. Аның калган яртысын саклык белән кесәсенә тыга.)*
Севрюгин. Скорее всего, мы этих... ученых охранять будем.
Яхно. Баллистиков, что ли?
Севрюгин. Слушай, а что это они здесь хотят делать? Снаряды какие-то не такие...
Яхно. Наверно, новый тип снарядов хотят испытать.
Севрюгин. На финнах, что ли?
Яхно. Нет, на нас.
Шаталов *(ачуланып)*. Разговорчики! Откуда про новый вид снарядов знаешь?
Яхно. Слышал.
Шаталов *(як-ягына карана)*. Вот что я тебе скажу: держи язык за зубами, понял?!
Яхно. Понял.

Шаталов. Зайнуллин!
Зариф. Я!
Шаталов. Я обратил внимание, что ты один любишь по лесу гулять. Как свободное время появляется, ты где-то там бродишь, поешь...
Рассуханов. Так он же в лесу родился, в лесу вырос.
Шаталов. Я не с тобой разговариваю. Просто это опасно. Не только для Зайнуллина, но и для всех. Впредь никуда не отлучаться!
Зариф *(гел татар акценты белән сөйләшә)*. Ладно.
Севрюгин. Не «ладно», а «есть» надо отвечать.
Яхно. Как тебя зовут?
Зариф. Зариф.
Яхно. Меня Сергеем звать.
Севрюгин. Зариф... *(Күзләрен чекрәйтеп.)* Странное имя.
Зариф. А что странного в моем имени?!
Севрюгин. Впервые слышу.
Шаталов. Женат, что ли?
Зариф. Нет.
Шаталов. А невестка-то осталась?
Зариф. Да.
Шаталов. Ее как зовут?
Зариф. Кашифа.
Севрюгин *(мыскыллы елмаю белән)*. Ну и имена у вас. Язык можно сломать.
Рассуханов *(ачулы тавыш белән)*. Да, твой язык можно сломать, потому что он у тебя деревянный. Что ты к нему всегда пристаешь?
Севрюгин. Ты че, поговорить, пошутить нельзя, что ли!
Яхно *(тыныч кына)*. А он татар не любит.
Севрюгин. Кто тебе сказал? *(Ямьсез иттереп авызын кыйшайта.)* А вообще-то их есть за что не любить. Триста лет монголо-татарское иго было.
Яхно *(тавышын күтәрә)*. Ты кончай. Это когда было-то?!
Шаталов *(җикереп)*. Разговорчики!
Севрюгин *(зарланып)*. Что «разговорчики»! Нас выделили и хотят какое-то серьезное задание дать. А людей-то подобрали не совсем совместимых!
Рассуханов *(Севрюгинны өнәмәгәнен яшермичә)*. Ты сам просто такой. Ты сам никого не любишь. Вот и ноешь сидишь. Чего тебе всегда не хватает?
Севрюгин. На серьезное задание надежных людей нужно посылать.
Зариф *(чак кына ишетелерлек итеп)*. А из нас кто тебе не нравится?
Севрюгин *(кистереп әйтә)*. Ты не нравишься!
Зариф *(сабырлыгын җуймыйча тыныч кына сорый)*. А что тебе во мне не нравится?
Севрюгин *(гасабиланып)*. Людей сторонишься — вот что не нравится. С такими в одной группе патрулировать опасно.
Зариф *(сабырлыгын саклап)*. А еще кто-нибудь тебе здесь не нравится?
Севрюгин. Че пристал?!
Рассуханов. Он на меня подозрительно смотрит.
Севрюгин *(тавышын күтәреп)*. Да, угадал!
Рассуханов *(шулай ук тавышын бераз күтәреп)*. За то, что намаз читаю?
Севрюгин *(нәфрәтле тавыш белән)*. Нет! За то, что еще недавно всем народом мятеж поднимали.
Яхно *(Севрюгинның тик торганда кызып утыруын ошатмый)*. А ты откуда знаешь?
Севрюгин. А у меня в Грозном родня живет. *(Тәмәкесен ташлый. Төкерә.)*
Рассуханов *(кычкырмыйча, ләкин яман усал тавыш белән)*. Я советую тебе не горячиться, а то ты у меня сейчас совсем остынешь.
Севрюгин *(кычкырып диярлек)*. А ты меня не пугай! Здесь больно-то кинжалом не помахаешь!
Рассуханов *(үзен кулга ала)*. Если бы сейчас не война, я бы тебе глотку перегрыз!
Шаталов *(ни әйтергә белми)*. Ну, что вы, ребята, в самом деле! Так не пойдет.
Яхно *(Севрюгинга)*. Послушай, ты... как тебя зовут, забыл?
Севрюгин. Михаилом.
Яхно *(ачуланып)*. Миша, ты давай не кипятись. Не забывай, что ты на войне. Вот после войны приедешь к себе в Воронеж, и там матерись и кувыркайся сколько душе угодно. Ты себе врагов не наживай на пустом месте, понял.
Севрюгин *(гаҗәпләнүле тавыш белән)*. А че ты их защищаешь, сибиряк?!

Шаталов *(җикерә)*. Хватит! Вы уже мне надоели! Действительно, по-моему, не то отделение сформировали.

Яхно *(барысын да тынычландырасы килеп)*. Да все нормально. Просто морозно, голодно, поэтому нервишки шалят.

Рассуханов *(тыныч кына)*. Зариф, не обращай на него внимания. И правда, у него нервы не в порядке.

Зариф *(барысы да чак кына ишетерлек итеп, ләкин инандырырлык куәткә ия тавыш белән әйтә)*. Он просто дурак!

Севрюгин *(сикереп тора)*. Что ты сказал?! *(Тешләрен кысып Зарифка таба килә.)*

Зариф *(торып баса)*. Что слышал!

Севрюгин *(яман усал кыяфәт белән)*. Повтори!

Зариф *(Севрюгинның кызуына бер дә аптырамыйча)*. Ты дурак!

Севрюгин. Да я тебя...

Севрюгин йодрыгын төйнәп кизәнә. Зариф читкә тайпылып кала да Севрюгинның ияк астына сугып җибәрә. Севрюгин әллә кая барып төшә. Беркавым тора алмый ята. Беркем дә Зарифтан мондый кыюлыкны һәм мондый җегәрне көтмәгән була. Шуңа күрә барысы да катып кала.

Шаталов *(нишләргә белми, аптырагач кычкырып куя)*. Рядовой Зайнуллин!

Севрюгин *(ияген капшый-капшый, көч-хәл белән яткан җиреннән тора да, кырыйда яткан күсәкне эләктереп алып, Зарифка таба килә)*. Убью!

Яхно *(аны чалып ега һәм өстенә ята)*. Остановись! Нас и так, может быть, вот-вот убьют.

Зимин килә.

Шаталов. Строиться! *(Барысы да кабаланып тезеләләр. Севрюгинга торып басарга ярдәм итәләр.)* Равняйсь! Смирно!

Зимин. Вольно, вольно, товарищи бойцы! В честь чего драку устроили? Или перед боем с финнами между собой тренируетесь? *(Сәгатенә карап.)* Шаталов! Сейчас вас накормят, потом явитесь ко мне по-одному. *(Китә.)*

Шаталов. Есть!

Яхно. Интересно, за драку накажут?

Шаталов. Не знаю.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Зимин үзенең землянкасында солдатларны берәм-берәм кабул итә.

Зимин *(кычкыра)*. Яхно!

Яхно керә.

Яхно. Товарищ капитан! Рядовой Яхно по вашему приказанию прибыл!

Зимин. Садись, Яхно! Покурим давай. *(Папирос бирә.)*

Яхно *(Зимин каршысына утыра, папиросны ала)*. А можно я потом покурю. Я только что покурил.

Зимин. Конечно, можно. *(Яхно папиросны бүрегенең колакчыны астына кыстыра.)* Ты у нас сибиряк? *(Елмая.)*

Яхно. Так точно. С Енисейска.

Зимин. Красноярский край?

Яхно. Так точно.

Зимин. Не знаешь, зачем выделили вас? *(Серле караш белән Яхноны күзәтә.)*

Яхно. Никак нет, не знаю.

Зимин. Финны перешли в наступление. Есть опасность остаться в окружении. У нас тут есть кое-что ценное. Вам предстоит патрулить вокруг наших складов. Заодно прочесывать. Разведчики финские, снайпера вокруг нас шуршат. А если финны серьезно пойдут в наступление, в случае окружения, придется все уничтожить самим.

Яхно. Что уничтожить?

Зимин. То что находится на нашей базе. Чтобы врагу не досталось.

Яхно. Понятно.

Зимин *(тавышын әкренәйтеп)*. Я тебе все это откровенно сказал, потому что, как мне кажется, ты — среди всех самый надежный.

Яхно *(гаҗәпләнеп)*. А с чего вы взяли, что самый надежный?

Зимин. Ты наполовину украинец?

Яхно. Так точно.

Зимин. Значит, кто-то из твоих предков из ссыльных или каторжан. Ты только не обижайся. А сибиряк из бывших ссыльных — это самый настоящий и крепкий сибиряк. И потом, ты хороший охотник, не так ли?

Яхно *(аптыраишта кала)*. Откуда вы все знаете?

Зимин. Про что?

Яхно. Ну, про все.

Зимин. Что охотник хороший — командир роты сказал. Остальное сам знаю. Я по долгу службы все про вас должен знать. И что ты настоящий парень — тоже знаю. Охотник он другим и не может быть.

Яхно. Для охоты времени мало было. Я на лесосплаве работал. Сплавщик я.

Зимин. Поэтому ты такой мускулистый. В группе подобрались нормальные ребята?

Яхно *(сагаеп)*. Нормальные.

Зимин. Каково у них настроение? Пессимизм кто-нибудь высказывает?

Яхно. Никак нет, нормальные ребята!

Зимин. Ну, а на счет этой военной компании что говорят? Ну, кто-нибудь высказывался, что, мол, ненужная война и т. д. Не осуждают политику нашего правительства?

Яхно. Никак нет!

Зимин *(күзләрен кыса төшеп)*. А что за ссора у вас возникла?

Яхно *(белмәмешкә салышып)*. Никакой ссоры нет.

Зимин *(елмая)*. Ну, хорошо. Жалоб нет?

Яхно. Никак нет!

Зимин. Можешь идти.

Яхно *(сикереп тора).* Есть!

Зимин. Пусть зайдет Зайнуллин!

Яхно. Есть! *(Чыгып китә.)*

Зариф керә.

Зариф. Товарищ капитан! Рядовой Зайнуллин по вашему...

Зимин *(якты елмаеп).* Кил, утыр.

Зариф *(Зиминның татарча сөйләшүенә гаҗәпләнә).* Вы...

Зимин *(акцент белән, вата-җимерә булса да, татарча сөйләшә).* Утыр, утыр. Тартасың киләме?

Зариф *(капитан каршына килеп утыра).* Никак нет... Юк. Мин тәмәке тартмыйм.

Зимин. Дөрес. Тартма. Мин беләм татарча... аз гына. Мин басмачыларга каршы сугыштым. Туркестанда. Мин чекист. Өйрәндем сөйләшергә. Сезнең телләр охшаган.

Зариф *(капитанның татарча белүенә сөенә)*. Әйе. Төрки телләр бит.

Зимин *(ягымлы тавыш белән)*. Хәлләр ничек?

Зариф. Әйбәт.

Зимин. Син яхшы мәргән диләр?

Зариф *(иңнәрен сикертеп)*. Раз әйтәләр икән, димәк, яхшыдыр.

Зимин. Урман кешесеме син?

Зариф. Әйе.

Зимин. Командир роты сине отличный стрелок ди.

Зариф. Әйе, мин төз атам.

Зимин. Профессияң кем?

Зариф. Урман хуҗалыгындагы бригадада эшләдем мин. Урманны чистартып, үсентеләр утыртып, кыскасы, урман караучы булып инде.

Зимин. Ник аерым группага алдырдык сезне, беләсеңме? *(Сынаулы караш белән Зарифны күзәтә.)*

Зариф. Бу тирәне сакларгадыр дип уйлыйм.

Зимин. Тәк, тәк... *(Кинәт сорап куя.)* Беркем дә кыерсытмыймы?

Зариф *(аптырап)*. Юк!

Зимин *(елмая)*. Син — аю. Сине җәберләргә куркыныч. *(Кыяфәте кинәт җитдиләнә.)* Фронттагы обстановкадан канәгатьсезлек белдерүчеләр юкмы?

Зариф *(катгый итеп)*. Юк!

Зимин *(тавышын әкренәйтә)*. А мин Севрюгин канәгатьсезләнә дип ишеттем...

Зариф. Юк, ишеткәнем юк.

Зимин *(гаҗәпләнгән булып кылана)*. А син аны паникерство өчен кыйнамадыңмыни?

Зариф *(бераз каушый)*. Юк, юк. Ул миңа төрттереп, бәйләнеп сөйләште. Шуңа ачуым чыкты да... суктым. Виноват! Мин җавап бирергә әзер.

Зимин. Миңа синең кыю ихласлыгың ошый. *(Чак кына ишетелерлек тавыш белән.)* Син анда паникалы сүзләр сөйләүчеләр булса миңа әйт, яме. Гомумән, егетләрнең настроениеләрен күзәтебрәк йөр. Бу безнең жиңүебез өчен кирәк. Партиягә каршы... анда... Сталинга каршы берәр сүз әйтүче булмасмы. Син бит аңлыйсың, андый настроениеләр гаскәрне какшата.

Зариф *(ышанычлы һәм нык тавыш белән)*. Безнең арада куркак кеше дә, тегенди-мондый әвеш-тәвеш кеше дә юк. Минемчә, без барыбыз да — сез үзегез сайлап алган кешеләр. Безнең арада паникерлар да, партиягә тел-теш тигезүчеләр дә юк.

Зимин *(ягымлы тонга күчә)*. Әйе, әйе. Син мине дөрес аңла — сезгә ышанмаудан түгел бу сорауларым. Безнең объект бик әһәмиятле. Монда бик каты дисциплина кирәк. *(Кинәт Зарифның күзләренә карый.)* Минем кем икәнемне беләсеңдер бит?

Зариф. Беләм.

Зимин. Нинди отделдан икәнне?

Зариф. Так точно, беләм.

Зимин. Ничек уйлыйсың, финны җиңәбезме?

Зариф *(кыюланып)*. Җиңәбез, иптәш капитан!

Зимин *(елмая)*. Молодец! Бар.

Зариф. Есть! *(Кузгала.)*

Зимин. Анда әйт, Севрюгин керсен!

Зариф. Есть! *(Чыгып китә.)*

Севрюгин керә.

Севрюгин. Разрешите!

Зимин. Заходи.

Севрюгин. Товарищ капитан, рядовой Севрюгин по вашему приказанию прибыл.

Зимин. Садись, Севрюгин. Как дела? *(Севрюгинның битен җентекләп күзәтә.)*

Севрюгин. Да так... *(Урындыкка утыра.)*

Зимин. Как?

Севрюгин *(капитанның күз карашыннан шүрләп як-якка каранып куя)*. Финны, говорят, наступают.

Зимин *(сагаеп)*. А кто это говорит?

Севрюгин. Все говорят.

Зимин *(кызып китә)*. Не наступают они! Брехня это! Мы им скоро такой птичий базар устроим. Вся Скандинавия перьями покроется. *(Кинәт тынычлана.)* В роте какова обстановка, как думаешь?

Севрюгин *(артык җитдиләнүдән борын тишекләре киңәя)*. В самой роте-то неплохо... И командир хороший... А вот... Вообщем, ну ладно...

Зимин *(алга таба иелә төшеп)*. Нет, нет, ты договаривай. В роте неплохо... А где плохо?

Севрюгин *(гасабиланып)*. Ладно, скажу. А то точно, кроме меня, никто не скажет. Вот группу выделили, вокруг этой базы патрулировать. Пять человек. Из каких соображений таких людей подобрали, не понимаю?!

Зимин. Говори, говори...

Севрюгин. Я против воли командира роты, конечно, претензий иметь не должен, однако ж...

Зимин *(ишетелер-ишетелмәс тавыш белән)*. Так, так... Кто тебе не нравится в группе?

Севрюгин. Этот... Зайнуллин и...

Зимин. И еще кто?

Севрюгин. Чеченец-то этот...

Зимин. Рассуханов?

Севрюгин. Так точно — Рассуханов.

Зимин *(күзләрен чекерәйтеп)*. Интересно, что в них такого ты запреметил?

Севрюгин *(кырт кистереп)*. Это ненадежные люди!

Зимин. Почему? Потому что нерусские?

Севрюгин *(нәфрәте йөзенә чыга)*. Да нет... Черт с ними, что нерусские они... Этот Рассуханов намаз читает...

Зимин. Пусть молится, раз в Аллаха верит.

Севрюгин. Верующий человек, неизвестно, как может себя повести, когда врага встретит.

Зимин. Ты не лишен тонкости. А Зайнуллина за что невзлюбил?

Севрюгин *(тәмам кыюланып китә)*. Дикий он какой-то. Он же в лесу родился, в лесу вырос. Толком не общается. Во время перекуров уединяется, песню какую-то свою мурлычит. Мне кажется, группа должна быть компанейской, дружной и без странных людей.

Зимин *(серле итеп елмая)*. А дрались сегодня с Зайнуллином по какой причине? *(Сынаулы караш белән карап тора.)*

Севрюгин *(ачу катыш аһ-зарлы тавыш белән)*. Он ни за что ни про что меня ударил. Он дурной какой-то. Вот и ходи теперь с ним по лесу. Неизвестно, кто в тебя выстрелит — финский снайпер с ветки, или этот татарин сзади.

Зимин *(коры гына)*. Ну, это ты лишку дал. Зайнуллин не из таких — он не будет стрелять из-за угла. Но в твоих соображениях есть кое-что правильное. Молодец, что такой наблюдательный и переживаешь за судьбу группы. Кури. *(Папирос бирә.)*

Севрюгин *(папиросын Зимин папиросыннан кабыза).* Будь моя воля, я бы их вообще в армию не брал.

Зимин *(күзләрен чекерәйтеп)*. Кого?

Севрюгин. Нерусских.

Зимин *(нотык сөйләгән тавыш белән)*. Нет, Севрюгин, так нельзя. Если одни русские будут погибать на войне, то что же это получится. Ты с Воронежа, ты настоящий русский. Мне понятно твое настроение и все то, что ты сказал. Я этих людей подобрал, а не командир роты. Зайнуллин хорошо ориентируется в лесу, хороший охотник и отличный стрелок. Физически мощный. *(Севрюгинның иягенә карап елмаеп куя.)*

Севрюгин *(сабыйларча акланырга тотына)*. Да если бы ребята не помешали, я бы его отлупил как следует.

Зимин. Ладно, ладно. Рассуханов — кавказец. Хорошо владеет кинжалом. Как кошка может незаметно подойти к противнику. И злости в нем много. Просто не надо с ним спорить. А воин он хороший. Ты — хороший лыжник. Очень нужный человек именно сейчас, в этих условиях. Ты, как я знаю, детей тренировал?

Севрюгин. Да, я детский тренер по лыжам.

Зимин. Яхно — крепкий сибиряк. Прекрасный охотник. Шаталов — одессит. Уже это о многом говорит. Физически выносливый. Мы специально выделили вас таких — сильных, выносливых. *(Тавышын әкренәйтеп.)* А что можешь про Яхно сказать?

Севрюгин. Он нормальный, но почему-то заступается всегда за этого татарина, и за того чеченца.

Зимин *(ягымлы тавыш белән)*. Ну и нормально. Все равно надо будет дружить. Думаю, все хорошо будет. *(Сынаулы караш белән карап.)* А Шаталов чем не нравится?

Севрюгин *(сискәнеп куя)*. Да вы что! Он среди всех самый лучший. Вы не подумайте, не потому что он старшим назначен. Хороший мужик!

Зимин *(тыныч кына)*. Я тебе советую найти общий язык со всеми. Дело у нас общее. Охранять вы будете очень важный объект. *(Пышылдап диярлек.)* Но тем не менее я тебя благодарю за некоторую наблюдательность. Иметь кое-какие сомнения — это тоже неплохо. Дружить необходимо со всеми, и со мной в том числе. Вижу — ты настоящий патриот. Ты будь наблюдательнее и запоминай, о чем говорят в группе, особенно пристальнее всмотрись в Рассуханова.

Севрюгин *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Хорошо.

Зимин. А так, об этой военной кампании Рассуханов не говорил ничего, не высказывал недовольств?

Севрюгин. Высказывал. Ругал командование.

Зимин *(алга таба иелеп)*. Какое командование? Роты? Полка? Дивизии?

Севрюгин. Вообще генералов. Мол, бездарные они все.

Зимин. Так, так... А Зайнуллин?

Севрюгин. Тот вроде ничего такого не говорил... Он же молчит. Но ненадежный он.

Зимин *(тагын тыныч интонациягә күчә)*. Ничего, ничего, помиритесь. Не деритесь больше. Еще впереди бои предстоят. Нормальная группа у вас. *(Тавышын әкренәйтеп.)* Но ты все же подслушай о чем говорят, чем дышат... Понял?

Севрюгин. Так точно!

Зимин. Можешь идти.

Севрюгин *(урыныннан кузгала).* Есть!

Зимин. Позови Рассуханова!

Севрюгин. Есть! *(Чыгып китә.)*

Рассуханов керә.

Рассуханов. Товарищ капитан...

Зимин *(елмаеп каршы ала)*. Проходи, садись, Аслан. *(Кул биреп күрешә.)* К морозам привык?

Рассуханов *(капитан каршысына килеп утыра)*. Привыкаю. Валенок только нет.

Зимин *(борчулы интонация белән)*. Да, что-то там про валенки забыли. Понимаю, тебе труднее, чем другим. У вас в Грозном таких холодов не бывает...

Рассуханов. Я с Гудермеса.

Зимин. Ну, Гудермес с Грозным почти рядом. *(Рассухановка игътибар белән карап.)* А еще какие жалобы есть?

Рассуханов. У меня вообще жалоб нет. Насчет валенок я не жалуюсь, а просто говорю, что в валенках было бы теплее.

Зимин *(ягымлы тавыш белән)*. Да, конечно. Я очень рад, что в наших рядах находится представитель гордого и смелого кавказского народа. Конечно, там у вас еще сложностей много... Горные жители у вас с советской властью не очень-то ладят... Ну их же немного... Подстрекатели, враги народа они везде и всюду есть. К сожалению, пока. Но есть у каждого народа вот такие орлы, как ты. Кем работал до армии?

Рассуханов. Чабаном.

Зимин *(саклык белән генә сорый)*. Что на этой базе находится, знаешь?

Рассуханов *(битараф тавыш белән)*. Не знаю. Мне никто не говорил.

Зимин *(кинәт сорап куя)*. Севрюгин достоин быть в вашей пятерке, как думаешь?

Рассуханов *(сорауларның берсенә дә аптырамый)*. Ну, если взяли, что вы у меня спрашиваете! Значит, достоен.

Зимин. В экстремальной ситуации не подведет?

Рассуханов. Не знаю. Мы недавно познакомились.

Зимин. А как думаешь, почему он не смог Зайнуллину сдачи дать?

Рассуханов *(белмәмешкә салышып)*. Какой сдачи?

Зимин. Ну, когда они подрались.

Рассуханов *(аптыраган булып кылана)*. А что, они дрались, что ли? Я не видел. И никто не говорил мне, что они подрались.

Зимин *(кул селти)*. Ну, да, наверно, просто боролись, играли. Я хочу тебе сказать... Тебя здесь все очень уважают. Поэтому и ты будь со всеми пооткровеннее и дружелюбнее. *(Елмая.)*

Рассуханов. Хорошо.

Зимин. Можешь идти.

Рассуханов. Есть! *(Торып баса.)*

Зимин. Позови, пожалуйста, Шаталова!

Рассуханов. Есть! *(Чыгып китә.)*

Шаталов керә.

Шаталов. Разрешите!

Зимин. Да, да, пожалуйста.

Шаталов. Товарищ капитан, рядовой Шаталов, старший выделенной группы, по вашему приказанию прибыл.

Зимин. Садись, Ваня, поговорим. Куришь?

Шаталов. Курю. Никак не могу бросить. *(Капитан каршысына утыра.)*

Зимин *(папирос бирә)*. На войне особенно трудно бросить.

Шаталов *(папиросын кабыза)*. Да, вам лучше знать. Вы и до этого навоевались.

Зимин *(авыр сулап куя)*. Было дело. *(Кыяфәтенә борчылу төсе чыга.)* Ну что, Иван, ситуация тебе понятная? Доверие тебе оказано большое. К сожалению, подкрепления не видать. Короче, на произволе судьбы можем оказаться. Вам предстоит прочесать окрестность, поискать удобные места для этих снарядов. Здесь хранить их опасно. Ну а в случае окружения придется взорвать.

Шаталов. Что с этими учеными-то будете делать?

Зимин *(эченнән генә сүгенеп куя)*. Да какие это ученые! Просто специалисты по этим новым снарядам. Что с ними... Раздадим им по винтовке. Назад их отправлять бессмысленно. И потом приказано: быть здесь. И им тоже.

Шаталов. Ясно.

Зимин. Ребята как?

Шаталов. В каком смысле?

Зимин. Устраивают тебя?

Шаталов *(капитанның күзләренә карамаска тырышып)*. Нормальные. Привыкнут друг к другу — все хорошо будет. До армии у меня в бригаде такие головорезы собрались. Я на заводе бригадиром слесарей работал. Со временем как одна семья работали.

Зимин. Но тут не Одесса, не завод и не слесарная бригада. Идет военная операция, как говорится, кампания... Хотя это настоящая война. Здесь, Ваня, люди друг к другу могут и привыкнуть и наоборот. Тем более, когда разные люди подобраны. Ты толковый парень, надеюсь, сможешь сколотить кулак.

Шаталов *(зарлы тавыш белән)*. Товарищ капитан, а что, вместо меня офицера не могли найти, что ли?

Зимин *(кырысланып)*. Откуда?! Тыл далеко. Людей мало осталось. Откуда тут лишний офицер возьмется? Разве что с неба Рассуханов своими молитвами у Аллаха выпросит какого-нибудь старшего лейтенанта.

Шаталов. Товарищ капитан, извините, но я не могу ему запретить читать молитвы.

Зимин. А и не надо. Пусть молится. Скажи откровенно: кто из этих четырех, на твой взгляд, самый благонадежный?

Шаталов *(уйга кала)*. Ну, в роте я их уже знал хорошо... *(Пауза.)* Думаю, Яхно и Зайнуллин.

Зимин. А остальные?

Шаталов. Товарищ капитан! Я ответил просто как старший этой группы. Думаю, они все надежные, просто они разные. Не знаю почему, но от души я бы мог поговорить прежде всего с Яхно и Зайнуллиным.

Зимин. Зайнуллин же нелюдимый и дикий! *(Текәлеп карап җавап көтә.)*

Шаталов. Нет, он очень тонкой и доброй души человек. Просто к нему правильный подход необходимо иметь.

Зимин *(җаваптан канәгать калып)*. Кстати, командир роты Лебедев когда его рекомендовал, тоже очень хорошо отозвался. И Яхно тоже охарактеризовал только с положительной стороны.

Шаталов. Ну вот...

Зимин *(кинәт сорый)*. А за что Зайнуллин избил Севрюгина?

Шаталов *(елмаерга тырыша)*. Да ерунда это, детские потасовки. Больше их не будет. *(Җитдиләнеп.)* Я постараюсь.

Зимин *(кырыс тавыш белән)*. Дисциплина прежде всего, Шаталов! Если вдруг не справишься — бегом ко мне!

Шаталов. Есть! Но, думаю, все будет в порядке. *(Папиросны сүндереп көл савытына сала.)*

Зимин *(тавышын әкренәйтеп)*. С Рассухановым как отношения?

Шаталов. Хорошие.

Зимин. Не ругает советскую власть?

Шаталов. Никак нет. Ругается, что валенок нет.

Зимин *(елмая)*. Ну, что валенок нет, я сам тоже ругаюсь.

Шаталов. Да, худо без валенок.

Зимин. Вас накормили?

Шаталов. Так точно.

Зимин. Начинайте первый обход. Внимательно осмотрите все вокруг, все деревья. Вполне возможно, что финские снайперы находятся и здесь поблизости.

Шаталов *(торып баса)*. Да, эти «кукушки» очень опасны.

Зимин. Так вот, первый обход посвятите поимке «кукушек».

Шаталов. Есть!

Зимин. У меня все. Вопросы имеются?

Шаталов. Пока нет. Когда вернемся с обхода, думаю, появятся.

Зимин. Хорошо. Как вернетесь, сразу ко мне!

Шаталов. Есть. *(Кузгала.)* Разрешите идти!

Зимин. Идите. Спокойной вам «прогулки»!

Шаталов. Спасибо. *(Чыгып китә.)*

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Карелия урманы. Бик салкын. Биш кешелек группа патрульдә йөри. Винтовкаларын кысып тотып, як-якка, агач башларына, куак араларына карый-карый әкрен генә баралар. Кайдадыр еракта бомбалар, снарядлар шартлавы ишетелә, пулемет тыкылдавы һәм винтовкадан аткан тавышлар яңгырап куя.

Яхно *(ерактагы тавышларга колак салып тыңлап тора)*. Совсем уже где-то рядом стреляют.

Севрюгин. Значит, финны наступают. Если бы наши наступали, то стрельба так близко не слышалась бы.

Шаталов *(гасабиланып)*. Разговорчики! И вообще, говорите шепотом.

Рассуханов *(кавказ акценты белән сөйләшә)*. Да никого здесь нет. Сюда через линию нашей обороны они никак не могут проникнуть.

Яхно. А ты, что, не слышал про их лыжные группы? Они где угодно и когда угодно могут появиться.

Зариф *(татарча акцент белән сөйләшә)*. Да тихо вы! Смотрите лучше по сторонам!

Яхно. Страшно, Зариф?

Зариф. А тебе?

Яхно. Есть чуть-чуть. Но на лучшее хочется надеяться. С нашей-то мощной армией разве их допустят до сюда?!

Зариф. Я человек лесной. Но всегда лес для меня был самым спокойным местом, хоть и волков у нас много. Вот уж не думал, что буду остерегаться людей в лесу.

Севрюгин. Ты на своих кулаками махать силен. А теперь что-то заговорил не по-храбрецки.

Зариф. Не страшно мне, Севрюгин, нет. Просто задача у нас не совсем понятная, да и в положении мы в каком-то неопределенном.

Яхно. Это точно. Самое страшное — это неопределенность.

Рассуханов. Хватит болтать! Зариф, ты сам просишь молчать, а сам громче всех заговорил.

Зариф. Молчу. Молчу. Все.

Шаталов. Видите поваленное дерево? Там присядем, отдохнем. Сначала вокруг обойдем, на всякий случай. *(Ауган агач кәүсәсе тирәсендәге куакларны, агачларны тикшереп киләләр.)*

Севрюгин. Миша, вытаскивай махорку.

Шаталов. Отставить! Курить нельзя!

Севрюгин. Это что, мы до базы так и не покурим?

Шаталов *(коры гына)*. Потерпишь.

Яхно *(як-ягына каранып)*. Да, если бы не война, то места, конечно, здесь красивые.

Рассуханов *(уйчанланып)*. Эти леса и так красивые, несмотря на войну.

Севрюгин. Небось, горы-то красивее?

Рассуханов. Все по-своему красиво.

Шаталов *(сагаеп)*. Слышите, волки завыли. *(Бүреләр улаганы ишетелә.)*

Севрюгин. Здесь, наверно, много такого хищного зверья водится.

Яхно. Самый страшный хищник для нас сейчас — финская «кукушка».

Шаталов. Это точно. Волк хоть воет — услышать можно. А эта «кукушка» она даже и не кукует.

Рассуханов. Немая кукушка, значит.

Шаталов. Нет уж, не немая она, коли может засадить пулю тебе промеж глаз.

Яхно *(ачуы килеп)*. Кончайте страшные вещи рассказывать.

Севрюгин. Винтовки у них, говорят, специальные, снайперские.

Рассуханов. Да, отчаянные люди эти «кукушки», если в тылу врага на деревьях сидят.

Яхно. Такие же люди, должно быть. Приказали, вот и сидят там. Говорят, это смертники. То есть, они уже на верную погибель согласились и сидят стреляют, пока их не уничтожат.

Севрюгин. А у нас в армии есть «Кукушки»?

Шаталов. Снайперы-то есть. Но на ветках им незачем сидеть. Мы — мощная армия, мы их так разбомбим вместе с их кукушками и гнездами.

Яхно *(көлемсерәп)*. У кукушек вроде бы своих гнезд не бывает.

Зариф *(авызын кыйшайтып)*. У финских, наверно, есть.

Рассуханов. Ты, Иван, говоришь — мощная армия... Валенки не могли дать.

Севрюгин *(чечен егетенә нәфрәт белән карап куя)*. Замучил своими валенками!

Яхно *(авыр сулап)*. Костер бы разжечь.

Шаталов *(боеру тавышы белән)*. Нельзя!

Зариф көлеп куя.

Рассуханов. Че, Зариф, надо мной смеешься?

Зариф. Нет, над собой. Севрюгин спрашивает: есть ли у нас в армии «Кукушки»? А у меня кличка Кукушка. И у отца тоже. «Күке» по-татарски.

Шаталов *(кызыксынып)*. А за что такую кликуху-то дали?

Зариф. Отец, когда маленький был, услышал голос кукушки, пошел по лесу искать ее. И заблудился. Потом отца искали всей округой.

Рассуханов. Нашли?

Зариф. Нашли. Вот с тех пор прозвали Кукушкой.

Яхно. Интересно.

Шаталов. А у тебя, Миша, прозвище было какое-нибудь?

Яхно. Было, но не скажу. А то постоянно дразнить будете. А у тебя у самого?

Шаталов. «Боцман» моя кличка. Из-за того, что отец был боцманом. И потом, я то фуражку его на улицу вынесу, то бинокль старый. Иногда наряжусь его старьем и выхожу во двор. Вот и заслужил кличку.

Зариф. Аслан, а у вас есть клички.

Рассуханов. Нет, у нас только у собак есть клички. *(Тын калалар.)*

Шаталов. Ну ты сказанул! Выходит, Зариф и я — сродни собакам.

Рассуханов. Нет, я не это хотел сказать.

Яхно. У Севрюгина, наверно, сильная кличка была.

Севрюгин *(канәгатьсезлек белән)*. А почему у меня сильная кличка должна быть?

Яхно *(елмаеп)*. Ну у тебя и фамилия звучная.

Севрюгин *(үпкәләгән сыман итеп)*. Не было у меня никогда клички.

Яхно *(үчекләп)*. У вас там вблизи Воронежа ни озер, ни рек, ни морей. Откуда у тебя такая фамилия — Севрюгин?

Севрюгин *(пафос белән)*. Там у нас все есть!

Яхно *(күзләрен чекерәйтеп)*. А клички имеют только хорошие люди. В народе говорится, что к нехорошему человеку и прозвище не пристает. *(Көлә.)* Не обижайся, Сережа, зачем ты такой взвинченный и обидчивый!

Севрюгин *(читкәрәк борылып)*. Не обижаюсь я. Боцман — ладно. А Кукушка — это что, хорошая кличка, что ли?! Между прочим, кукушка птенцов своих не высиживает, бросает в чужих гнездах. И вообще у русских много поверья на счет кукушки. И по-моему, ни в одном из них кукушка счастье не приносит.

Шаталов. Например, какие поверья?

Севрюгин. У нас говорят: если кукушка летает по деревне, то это к пожару.

Яхно. А че это кукушка по деревне должна летать, она в лесу должна летать. И потом, почему это именно кукушка тебе счастье должна принести?

Шаталов. Погоди, погоди. Еще что говорит народ про кукушку?

Севрюгин. Вообще, кукушка, кукующая после Петрова дня — не к добру: к пожару, к неурожаю, падежу скота. «Когда кукушка линяет, пусть хозяйка бережет яйца». Или вот еще: «Если весною кукушка в первый раз «окукает» прямо в глаза — на весь год слезы».

Яхно. Ты просто все плохое о кукушках собираешь. Бабушка мне говорила: «Если весной ты услышишь первую кукушку справа, удача будет сопутствовать тебе, если слева — удача покинет тебя на весь остаток года». И еще: «Услышишь кукушку справа — загадай желание и оно исполнится».

Шаталов. А ты, Зариф, че молчишь? У самого кликуха Кукушка, а сам не защищается.

Зариф. У нас говорят: «У рано прокуковавшей кукушки после голова болит». Между прочим, все люди у кукушки спрашивают, сколько им жить осталось.

Шаталов *(йөзен караңгылатып)*. Да, финская кукушка прокукует один раз — значит, самое большее — одна минута осталась.

Рассуханов *(ачуланып)*. Шутка не командирская у тебя.

Зариф. А у вас, Аслан, что о кукушках говорят?

Рассуханов *(гасабиланып)*. Что, вам больше не о чем разговаривать, что ли?! Зачем вам эти кукушки!

Севрюгин. Правильно. Что-то у нас все темы к финским снайперам тянутся.

Шаталов. Прошу прощения, я тоже вспомнил одно поверье про кукушку. «Ранняя кукушка (прежде листа на дереве) ворам неудача»

Барысы да көләләр.

Яхно. Одессит же. И поверье у тебя одесское.

Шаталов *(татлы елмаеп)*. Ах, как я по Одессе соскучился. Вы тоже все скучаете. *(Моңсулана.)* Но мне вдвойне тягостнее, наверно. Вы все неженатые. Все это впереди у вас. А у меня жена и двухлетний сын там остались. *(Кинәт үтә җитдиләнә.)*

Зариф. Ничего, скоро разобьем финнов и разойдемся по домам. Думаю, это долго длиться не может.

Рассуханов. Ну да. Надеялись за пару недель справиться. Замерзаем уже второй месяц.

Севрюгин. А ты хотел чтобы как на курорте было?

Яхно *(җикереп)*. Ну что ты опять поперек начинаешь встревать! Слово, что ли, нельзя сказать!

Шаталов. Не орите! Вас, наверно, за километр слышно.

Яхно *(тавышын әкренәйтеп)*. Слышь, Иван, а что ты слышал про эту 44-ю дивизию?

Шаталов. Про какую?

Яхно. Которая в окружение попала и почти полностью погибла. Кто чудом смог выйти из окружения, тех сразу НКВД арестовал.

Шаталов *(кырыс тавыш белән)*. Нам нельзя много знать!

Яхно. Говорят, обвинили во всем командира дивизии... Виноградов, кажется, фамилия... Его, по закону военного времени, перед строем расстреляли.

Севрюгин. Это кто тебе такие подробности докладывал?

Яхно. Слышал. В роте говорили. Я же не ты! Слух имею и немного ума. А ты все ходишь и на каждого обижаешься, придираешься ко всем по пустякам. А что творится на фронте — тем ты не интересуешься.

Севрюгин. Иван тебе сказал: много нельзя знать... Это может тебе боком обернуться.

Яхно *(кызып)*. Что ты на всех все время сердишься? Вот за что ты на меня-то обижаешься?
Севрюгин *(тыныч кына)*. Не сержусь я. И не обижаюсь на бестолковых людей.
Шаталов. Вот я смотрю на вас и жутко становится. Вы — бойцы Красной Армии. Перед нами задача: бить белофиннов во имя безопасности Родины. Партия, товарищ Сталин, весь советский народ оказал нам великую честь — обезопасить северные рубежи родной страны. А вы ведете себя как малолетние дети. И разговорчики у вас, действительно, бестолковые. Посерьезнее надо быть!
Рассуханов. Если людям не дать поговорить и пошутить, в таком темном лесу с ума можно сойти.
Шаталов *(ачуы килә башлый)*. Рассуханов, так ты не согласен с тем, что я сказал?
Яхно. Не горячись, командир, обещаем — будем посерьезнее.
Севрюгин *(Шаталовка ялагайланып)*. Нет, пусть Рассуханов ответит: согласен он с тем, что сказал Иван?
Рассуханов *(усал тавыш белән)*. Когда меня таким тоном спрашивают, мне не хочется отвечать.
Севрюгин *(кызып китә)*. Ты злой, потому что не успел скрыться в горах, чтобы в армии не служить.
Рассуханов *(нәфрәтле тавыш белән, ләкин үзен кулга алып).* Зато я никому задницу не лизал и не буду, как ты.
Севрюгин *(иптәшләренең һәрберсенә карап чыга)*. Ничего себе! Ты что себе позволяешь?!
Шаталов *(боеру тавышы белән)*. Прекратите! Опять до драки дело дойдет!
Севрюгин *(теш арасыннан ысылдап)*. Ты еще пожалеешь о том, что сказал.
Зариф *(барысын да тынычландырырга тели)*. Ваня, послушай, здесь все правильно понимают политику партии, и с тем, что ты сказал, все согласны. И Аслан тоже.
Яхно. Да, мы так скоро перегрыземся между собой. И волков не надо будет, и «кукушки» не потребуются.
Шаталов. Кончайте ребята грызть друг друга. Да, неопределенность она, конечно, сильно давит. Но это не значит, что мы между собой бодаться должны. Придем на базу, успокоимся, отдохнем. А сейчас, давайте-ка, по баночке тушенки откроем!
Севрюгин. Давно пора.
Зариф. Вот это — дело.

Барысының да кәефләре күтәрелә.

Рассуханов. Может быть, ругаемся из-за того, что голодные?
Яхно. Может быть.

Тушенка банкаларын ачалар.

Зариф *(күтәренке рух белән)*. Да никто не ругается... Что уж...
Шаталов. Рассуханов, опять только хлеб будешь есть?
Рассуханов. Тушенка из свинины. Нельзя мне. Мне хлеба больше дайте.
Зариф. Я уж после войны... после демобилизации не буду тушенку есть... И намаз буду читать.
Шаталов *(ашый-ашый сөйләшәләр)*. У татар ведь вера тоже мусульманская?
Зариф. Да.
Яхно. А мечети у вас есть?
Зариф. Почти не осталось. *(Тынлык.)* Все хорошо будет!
Шаталов *(кәефе күтәрелгәнне барысына да күрсәтеп)*. Если Зариф говорит, значит, нормально будет. Ты молодец, Зариф! Ты настоящий мужик. Главное, что в тебе ценю я: ты психуешь только когда это необходимо. А так твоей выдержке позавидовать можно.
Рассуханов. Нас еще в настоящем бою никто не проверял.
Шаталов. А тогда, возле речки два дня отстреливались. Что, разве не настоящий бой? Это хороший урок, и там уже видно было кто на что способен.
Рассуханов. Финны в окопе, и мы в окопе. Друг друга не видим. Стреляем куда-то в их сторону. Это не настоящий бой.
Яхно. А настоящий бой что, по-твоему?
Рассуханов. Настоящий бой — это когда видишь глаза противника. И он вооружен, и ты вооружен. Решают мгновения — или ты, или он.
Шаталов. Ну, Аслан, здесь несколько другие условия, чем на Северном Кавказе.
Севрюгин. Фин он не допустит, чтобы ты ему в глаза заглядывал.

Көләләр.

Это барану, когда его режешь, можно в глаза посмотреть.

Көләләр.

Зариф. Ты смотри, настроение поднялось. *(Киерелеп куя.)*

Яхно *(банка төбен кашык белән кыра)*. Это тушенка свое дело делает.

Севрюгин. Эх, покурить бы.

Шаталов. Потерпи. До базы совсем уже недалеко. *(Торып баса.)* Короче, ребята, встать! Попрыгали! *(Сикергәләп ала.)*

Егетләр теләр-теләмәс кенә утырган урыннарыннан торалар.

Идем до базы, встречаемся с Зиминым...

Рассуханов. Потом?

Шаталов. Зимин скажет, когда следующий обход. Думаю, ночью еще раз придется пройтись.

Винтовкаларын иңнәренә асып кузгалалар.

Зариф. А кроме нас еще кто-нибудь будет патрулировать?

Шаталов. Вряд ли. Людей нет.

Яхно. Спать-то когда-нибудь будем, наверно?

Шаталов. Да, когда-нибудь, наверно, будем.

Севрюгин. А мороз-то все крепчает. Сорок градусов есть поди?

Яхно. Тридцать пять где-то...

Шаталов. Но на днях обещают сорок пять-пятьдесят градусов.

Яхно. Ни хера себе!

Шаталов. Перезиму-у-уем!

Урман эченә кереп югалалар. Каяндыр урман караңгылыгыннан Зарифның тавышы ишетелә.

Зариф. Шаталов! Товарищ командир!

Шаталов. Что?

Зариф. Я ножик оставил. Разреши сбегать. Подарок невесты.

Шаталов *(шулай ук урман эченнән)*. Сбегай. Мы пока пойдем. Догонишь нас. Окоченели уже. Идти надо.

Зариф. Я быстренько.

Зариф ял иткән урынга йөгереп килә. Пәкесен шактый вакыт эзли. Ниһаять, таба һәм чиксез сөенеп пәкене чалбар кесәсенә тыгып куя. Шуннан соң куен кесәсеннән кульяулыкка төрелгән рәсемне ала. Чишеп карый.

Зариф *(рәсемгә карап)*. Кәшифә. Чак кына югалтмадым син биргән пәкене. *(Елмая. Рәсемне кульяулыкка төреп кесәсенә тыга. Як-ягына карана.)* Урман урман инде ул! *(Кинәт кәефе күтәрелә, иркен итеп сулыш ала. Шуннан соң якындагы агач ботагына винтовкасын элеп куя да, ауган агачның җайлырак урынына утырып, күн итеген сала һәм ыштырын җайлап яңадан урарга тотына. Җырлый. Чын күңелдән, рәхәтләнеп татарча җырлый. Саклык турында да, сугышта икәнлеген дә онытып иркенләп җырлый.)*

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә;
Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым куш каен,
И-и, аерылмаек, дускаем.
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк дөнья күтәргә.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И-и, аерылмабыз, дус булсак.

Кара да гына елан, ай, туз башлы,
Йөридер лә камыш буенча;
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым куш каен,
И-и, аерылмаек, дускаем.
Ялгыз гына башым, юк юлдашым,
Йөримен лә язмыш буенча;
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И-и, аерылмабыз, дус булсак.

*(«Иске кара урман».*
*Татар халык җыры)*

Зариф икенче көн итеген салгач, аның артындагы агачлар арасыннан иелә-иелә фин солдаты килеп чыга. Аның киеме яртылаш кына хәрби. Фин солдаты икәнне аның бүрегеннән, кокардасыннан, каешыннан һәм коралыннан белеп була. Бәйләнгән свитер өстеннән җылы тун кигән. Ул шыпырт кына барып Зарифның винтовкасын ала да иңенә аса, үзенең винтовкасын исә Зарифка төбәп әкрен генә аңа таба атлый. Зариф бу вакытта әле һаман җырлый һәм фин солдатын күрми дә, ишетми дә. Фин солдаты бер урында басып катып кала һәм гаҗәпләнеп аның җырлавын тыңлый. Җыр тәмамланганчы фин солдаты Зарифның артында тыңлап басып тора. Әле күн итекләрен кигәч тә Зариф җырлап утыра.

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Нинди юллар белән үтәрбез?
Карурманны үткән чакта
Кисеп алдым куш каен,
И-и, аерылмаек, дускаем.
Дус-иш белән бергә эш иткәндә
Теләкләргә тизрәк җитәрбез.
Карурманны үткән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И-и, аерылмабыз, дус булсак.

Җырлап туктагач, Зариф артында кемнеңдер басып торуын сизеп ала. Әкрен генә башын винтовкасын элгән агачка таба бора. Винтовкасы юклыгын күргәч сикереп тора да артында торучы фин солдатына алды белән борылып баса. Винтовкасын төбәп торучы фин хәрбиен күргәч, Зариф тораташ булып ката. Ул нишләргә белми. Күз кырые белән тирә-яктагы ботакларга, таякларга карый — ничек тә булса дошманны бәреп егу җаен чамалый. Шул ук вакытта фин аны шундук атып үтерер дә төсле тоела. Бәлки, әсир итеп алып китәр дип тә уйлый. Уйлар өере курку хисе белән катыш үрелеп аны баскан урынына гүя бәйләп куя. Фин телендә сорау бирсә, ничек аңлармын, дип уйлый ул. Урысча белмидер инде. Ә бәлки, беләдер... Менә хәзер атып җибәрер дә, бөтен дөнья караңгылыкка төшеп китәчәк. Кәшифә аның һәлак булуын белерме-юкмы? Әти-әни ничек кичерер бу кайгыны? Бу уйлар яшен тизлегендә чигә аша сызгырып үтеп тордылар. Бу кадәре ваемсыз, саксыз булырга ярыймы инде! Ничек инде үземне коралсызландырырга ирек бирдем шушы чандыр гына финга?! Югыйсә мин аны бер сугуда үтерә алам бит... Фин солдаты бер сүз дәшми карап тора. Зарифка сәер тоела — фин солдаты бернинди нәфрәтсез, хәтта елмаеп карап тора шикелле. Аңарда бернинди дошманлык юк сыман, киресенчә, дустын очраткан сыман елтырый күзләре. Әй, бу шулай тоела гына... Кызылармеецны әсир иткәнгә сөенә. Моның өчен командиры аны бүләкләр. Берәр медаль бирер, отпускыга кайтарыр. Фин солдаты винтовкасын төбәгән килеш Зарифка таба атлый. Зарифның җаны-тәне буенча калтырану тагын бер дулкын булып уза һәм бөтен вөҗүденнән тир бәреп чыга. Ләкин көтмәгәндә төшләрдә генә була торган хәл килеп чыга. Фин солдаты ап-ак тешләрен күрсәтеп шундый якты итеп елмая һәм... татарча эндәшә.

Фин *(елмая)*. Шәп җырлыйсың! *(Үзе һаман Зариф алай-болай каршылык күрсәтмәсен дип винтовкасын төбәп тора.)*

Зариф *(ялгыш ишеттем микән әллә дип уйлап)*. Ә?

Фин *(чын күңелдән сокланып)*. Матур җырлыйсың, туган!

Зариф *(каушаудан ни әйтергә белми)*. Мин... пәкемне онытып калдырганмын.

Фин. Мин сине шул пәкеңне кесәңә тыгып куйган моментта инде атып үтерергә әзерләнгән идем. Курокка басам гына дигәндә, җырлый башладың.

Зариф *(финның татарча сөйләшүе бераз хәл бирә)*. Сездә җырлап торган кешене атмаска дигән приказ бармы әллә?

Фин. Мин дошманны атып үтерә алам, ләкин татар җырына ата алмыйм мин.

Зариф. Кем соң син?

Фин. Фин солдаты. Үзем теләп кулга корал алган кеше мин.

Зариф. Татарча сөйләшәсең... Әллә син дә төрекмән басмачыларына каршы сугыштыңмы?

Фин *(көлемсерәп)*. Син әсир төшкәч тә шаярасың... Ошыйсың син миңа.

Зариф. Урыс кешесенең татарча сөйләшкәнен ишеткәнем бар, ә менә фин кешесенең татарча сөйләшүен беренче мәртәбә ишетүем. Хәер, гомумән финнарны минем плакатларда гына күргәнем бар.

Фин. Мин сине очратуыма бик шат.

Зариф *(басынкы тавыш белән)*. Сине әсир итсәм, мин дә шат булыр идем.

Фин. Пәкең калганмы? *(Зур кызыксыну белән Зарифны күзәтә.)*

Зариф. Әйе. Пәкем калган. Ни... Карел урманында татарча сөйләшүче кеше килеп чыгар дип уйламаган идем. Синең кыяфәтең дә татарныкына охшаган.

Фин. Мин бит чып-чын татар!

Зариф. Алайса, син мине атмассың инде.

Фин *(елмаеп)*. «Кара урман»ны болай әйбәт җырлаучыны атмыйм инде мин.

Зариф *(ни уйларга белми)*. Хәзер алып китәсеңме мине?

Фин. Әлбәттә.

Зариф. Кая?

Фин. Үзебезнең якка. Син Татарстаннанмы?

Зариф. Әйе.

Фин *(көлә)*. Кызык, кызык! Татар кешесен очраттым! Әле җырлап утыра!

Зариф. Син финнар ягына чыккан кеше мәллә?

Фин. Алай мине үпкәләтүең ихтимал.

Зариф. Юк, юк, минем сине үпкәләтәсем килми. Сине үпкәләтү миңа зыян гына китерәчәк. Татар кешесе... Карале, юри фин формасын киеп разведкага йөрисеңдер... Кайсы полкныкы син?

Фин. Мин сорау алырга тиеш синнән. Мин бит сине кулга алдым. Мин Финляндияне СССР агрессиясеннән саклаучы. Сездә ополченец диләр безнең кебекләрне. Мин Финляндиядә яшәүче татар.

Зариф. Ә-ә-ә. Минем ишеткәнем бар иде фин татарлары турында.

Фин. Мин фин татары түгел, Финляндиядә яшәүче татар.

Зариф. Ничәү соң сез анда?

Фин. Без анда бик күп.

Зариф. Аңлашылды. Сез, татарлар, Советлар Союзына каршы сугышасызмыни?

Фин. Финляндия — безнең туган илебез. Аны саклау, аның бәйсезлеге өчен сугышу — безнең бурычыбыз.

Зариф. Берүзең монда нишләмәкче буласың? Бер-ике кешебезне үтерерсең дә, үзең харап булачаксың бит.

Фин. Ялгышасың. Без урман тутырук. Барыбер без җиңәчәкбез!

Зариф. Син Финляндиядә туып үстеңмени?

Фин. Әйе.

Зариф. Без икебез дә татар кешеләре. Бер киңәш биримме?

Фин. Тыңлыйм.

Зариф. Син мине хәзер атып үтерсәң, безнекеләр ишетеп килеп җитәчәкләр һәм сине тотачаклар. Син мине җибәр. Мин синең турыңда беркемгә дә әйтмәм.

Фин. Юк, мин сине җибәрмим. Үзебезнең якка алып китәм.

Зариф. Сиңа минем өчен герой исемен бирмәсләр барыбер.

Фин. «Герой» нәрсә дигән сүз әле ул?

Зариф. Каһарман.

Фин. Юк, миңа каһарман исеме кирәк түгел. Мин сине финнар ягына алып чыгам. Финляндиядә син кешеләрчә яши башлаячаксың. Син ул СССРда кол халәтендә яшисең, синең туйганчы ипи ашаганың да юк бит.

Зариф. Аңламадым.

Фин. Мин сине үзебезнең якка алып китәм. Финнар татарларны бик ихтирам итәләр, ышан миңа.

Зариф *(ялварулы тавыш белән)*. Җибәр син мине.

Фин *(көлә)*. Юк, болай шәп җырлагач, алып китәм мин сине үзебезнең якка.

Зариф. Ә мин теләмәсәм?

Фин. Теләмәсәң теләмисең инде. Мин бит сине әсирлеккә төшердем.

Зариф. Татар кешесе буларак җибәрә аласың бит инде...

Фин. Финляндиядә син үзеңне кешеләрчә хис итәчәксең.

Зариф. Кызык кеше син. Финляндиядә совет власте урнашкач, мин ничек җавап тотармын?

Фин. Анда беркайчан да совет власте урнашмаячак. Без сезне барыбер җиңәбез! *(Винтовкасын икенче иңенә асып куя.)*

Зариф. Димәк, син «күке»?

Фин. Кем?

Зариф. Син.

Фин. Нинди «күке»?

Зариф. Син снайпермы?

Фин. Әйе.

Зариф. Без сезне «күке» дип атыйбыз. Урысча «кукушка». Менә, ике «күке» очраштык. *(Елмаерга тырыша.)*

Фин *(усал кыяфәт белән)*. Әйе, ишеткәнем дә, укыганым да бар. Әйе, безне советлар шулай атыйлар, агач башларыннан атканга күрә. Әмма арттырып сөйлиләр: имеш, фин снайперлары, ягъни «күке»ләр, гел агач башында утырып шарт-шорт атып торалар. Пропаганда өчен, мескенрәк итеп күрсәтер өчен күбрәк сөйлиләр шулай дип. Ярар, «күке» дип атасыннар. Әмма без агач башында гына утырмыйбыз, кайдан җайлы, шуннан атабыз. Һәм безне беркем мәҗбүр итми.

Зариф. Рәхмәт, миңа атмаганың өчен.

Фин. Һәй, туган, әйтәм бит, татар җырына ата алмыйм мин. Шул татар җыры безне Җир шарының әллә кай тарафларында саклады да инде.

Зариф. Анысы дөрес.

Фин. Димәк, «күке» дип үртисез безнең снайперларны?

Зариф. Мин гомерем буе Күке кушаматы белән йөрим әле.

Фин. Исемең ничек?

Зариф. Зәйнуллин Зариф Хәбибрахман улы. Күке Зарифы дип тә йөртәләр.

Фин *(көлә)*. Нәрсә, син дә агач башыннан кешеләр үтереп йөргән идеңме әллә?

Зариф. Юк. Әтиемнең кушаматы ул.

Фин. Мин Галиәкбәр улы Зыятдин булам. Бабам Якуб, сәүдәгәр буларак, дөнья гизгән. Финляндиядә куыш корган. Минем әтием Финляндиягә килгәндә әле кечкенә бала булган.

Зариф. Татар телендә яхшы сөйләшәсең. Барыгыз да шулаймы?

Фин. Әйе. Син Татарстанның кайсы төбәгеннән?

Зариф. Син Татарстанны белмисеңдер.

Фин. Һәрхәлдә, үзебезнең нәсел чыккан якларны беләм — бабам сөйләве буенча, әлбәттә.

Зариф. Сез дә чыгышыгыз буенча Татарстаннанмыни?

Фин. Атам ягыннан Татарстанныкы, анам ягыннан Нижгарныкы. Бабай Нижгар кызына өйләнгән.

Зариф. Атаң ягыннан чыгышың Татарстаннанмы чынлап та?!

Фин. Әйе, Субай авылыннан минем бабам.

Зариф *(шакката)*. Субайдан?! Мин дә бит шуннан. Субайның үзеннән түгел, бер чакрым арада гына урман хуҗалыгыннан. Бәрәкәт урман хуҗалыгыннан.

Фин *(таң кала)*. Чын әйтәсеңме?!

Зариф *(шатлык белән)*. Минем яратып йөргән кызым Субайдан. Анда Актүбә, Тоба, Каенлы, Имәнле авыллары бар әле...

Фин *(илһамланып)*. Әйе, әйе, минем ул авыллар турында ишеткәнем бар. Димәк, без әле синең белән якташлар да. Бәлки, туганнардыр да?

Зариф *(җанлана)*. Бәлки. *(Кул биреп күрешәләр.)*

Зыятдин *(ихлас күңелдән)*. Ай-яй матур җырлыйсың. Бу бит халык җыры — «Кара урман».

Зариф. Әйе. Халык җырларын да беләсең, ә!

Зыятдин. Әле сез белмәгәнне дә кайчак беләбез без. 1913 елда Мәскәүдә «Мандолина» исемле ноталы җыр китабы чыккан иде. «Кара урман» җырында анда мондый юллар да бар. *(Җырлый.)*

Кара гына урман, ай, артыннан
Болыт кына килә, ай, күкерәп;
Карурманнан чыккан чакта,
Атым керми елгага,
Эх, берлек кирәк дөньяда.
Заманалар авыр, михнәтләр күп,
Күтәрә лә, ай, калын ла күкерәк;
Карурманнан чыккан чакта,
Атым керми елгага,
Эх, берлек кирәк дөньяда.

*(“Кара урман”.*
*Татар халык җыры.)*

Зариф *(гаҗәпләнеп һәм сокланып)*. Карале, син үзең дә бик моңлы җырлыйсың.

Зыятдин. Чөнки без якташлар. *(Рәхәтләнеп көләләр.)*

Зариф. Өстәвенә икебез дә күкеләр. *(Җитдиләнеп.)* Зыятдин, син миңа гомеремне бүләк иттең бит.

Зыятдин. Ташла! Татар җыры саклап калды сине! *(Зарифны иңеннән кагып.)* Киттекме безнең якка?

Зариф. Юк, Зыятдин! Әйдә безнең якка! Барысын да аңлатырбыз. Синең тамырларың Татариядә икәнне исбатлап булыр.

Зыятдин. Ни сөйлисең син?!

Зариф. Ватаныңа кайтасың килмимени?

Зыятдин. Минем Ватаным икенче тарафта, Зариф. Дөресен әйтәм, минем сине җибәрәсем килми. Тик әсир буларак түгел. Якташым, кан кардәшем, җырдашым буларак якын син миңа. *(Зарифның винтовкасын бирә.)* Мә.

Зариф *(винтовкасын алып)*. Хәзер мин атырмын дип курыкмыйсыңмы? Яки әсир итәрмен дип?

Зыятдин. Юк, курыкмыйм. *(Ерактагы тавышларга колак салып тыңлап тора.)* Ишетәсеңме, фронт ягыннан гөрселдәүләр ишетелә. Сезнекеләр һич кенә дә «Маннергейм сызыгы»н үтә алмыйлар. Хәлегездән килмәячәк тә. Кан коела. Бер кирәксезгә, сезнең җүләр канечкеч Сталиныгыз аркасында күпме кеше харап була.

Зариф *(кинәт ачуы кабара)*. Син алай сөйләшмә инде! Якташ дип тормам.

Зыятдин. Мин хаклы түгелмени?!

Зариф *(шундук үзен кулга ала һәм тынычлана)*. Күңелем, ничектер, тынычланып куйды әле. Шушы кан коешта кара урманда ике татар очрашсын әле. Бер-берсенә мылтык төзәсәләр дә, гаҗәеп күренеш бит бу! Мин һаман ышанып җиталмыйм әле. Зыятдин, хушлашыйк. Рәхмәт сиңа! Безнекеләрнең мине эзләп килеп җитүләре ихтимал. Сине аннары җырлап кына коткарып булмаячак. *(Китәргә әзерләнәләр.)*

Зыятдин *(инде киттем дигәндә генә)*. Ә син бу җырны беләсеңме?
Зариф. Кайсы?
Зыятдин. Менә моны... *(Татар халык җырын җырлый башлый.)*
Зариф. Нишләп белмәскә! *(Зариф та аңа кушылып җырлый.)*

Йөгердем, җитәлмәдем лә,
Сикердем читәннәрен;
Ни булгандыр телләремә —
Сау бул дип әйтәлмәдем.

Урманнарда йөргән чакта
Адаштым юлларымны;
Күңелем нечкә —
җылармын дип,
Сузмадым кулларымны.

*(Татар халык җыры.)*

Кинәт төрле яктан, винтовкаларын төбәп, Шаталов, Яхно, Рассуханов, Севрюгин килеп чыгалар.

Шаталов *(бик кычкырмыйча гына)*. Бросай оружие!

Зыятдин белән Зариф сискәнеп китәләр.

Яхно. Не понятно, что ли, оружие бросьте!
Зыятдин. Нәрсә диләр?
Зариф. Винтовкаларны ташларга кушалар. *(Зыятдин винтовкасын агачка сөяп куя да берничә адым артка чигенә.)*
Севрюгин. А ты, урод, не понял?! Финн понял, а ты нет?! Сука! Бросай винтовку!
Шаталов. Тихо, не ори. Брось винтовку, Зайнуллин!

Зариф винтовкасын ташлый.

Яхно. Руки вверх!
Севрюгин. «Руки вверх!» — сказано было!

Зариф кулларын өскә күтәрә. Аңа карап Зыятдин да кулларын күтәрә.

Шаталов. Рассуханов, обыщи финна! Ты, Яхно,— Зайнуллина! Севрюгин, будь начеку, чтобы со стороны еще кто-нибудь не подошел!

Зыятдин белән Зарифны тентиләр. Зыятдинның пистолетын, үткен пычагын һәм зажигалкасын алып Шаталовка бирәләр.

Документы и другие предметы заберите пока себе!

Яхно — Зарифның кесәсендәге әйберләрне, Рассуханов Зыятдинныкын ала.

Яхно *(чыраен сытып)*. Аслан, на, засунь к себе в карман, не хочу я в свой карман вражьи вещи совать. *(Зарифның кесәләрендәге вак-төякне Рассухановка бирә.)*
Рассуханов. Давай. *(Ике татарның да әйберләрен алып үзенең кесәләренә сала.)*
Севрюгин *(тешләрен кыса-кыса)*. Песенки поете, да! Дерьмо! «Кукушки» ... мать вашу! Разрешение попрошу и сам застрелю обоих!
Шаталов. Тихо, не шуми. Отойди. *(Зарифка.)* Где обучался финскому?
Зариф *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Я не знаю финского.
Яхно. А на каком пели, разговаривали?
Зариф. На татарском. *(Кинәт җанлана. Иптәшләренә аңлата алырмын дип өметләнә.)* Ребята! Я вам все объясню. Он меня видел, и не стал стрелять в меня, понимаете...
Яхно *(таләпчән тавыш белән)*. А ты почему не выстрелил в него?
Зариф *(өзгәләнеп)*. Ну, он же не убил меня, зачем я его буду убивать.
Севрюгин. Почему в плен не взял?
Зариф. Это он сзади подкрался и взял меня в плен.
Зыятдин *(Зарифка борылып)*. Син мине әсир иттем дип әйт, яме. Алайса харап итәләр сине. Мине әсир иттем дип әйт.
Яхно *(сүгенеп)*. Ну-ка, кончай там по-своему бубнить!
Шаталов. Да! Будете переговариваться, по затылку будете получать. Все! Пошли. Яхно, сзади пойдешь. Рассуханов, Севрюгин — по бокам, я впереди. Арестованных срочно Зимину доставим. Не наше дело разбираться. *(Зыятдин белән Зарифны алып китәләр.)*

Севрюгин *(урман эченнән)*. Как это не наше дело?! Этого Зайнуллина сам прикончу!
Шаталов *(урман эченнән җикергәне ишетелә)*. Замолчи!

Авыр музыка. Сәхнә караңгылана.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Түрдә Зиминның блиндажы. Блиндаж кырыенда Шаталов, Севрюгин, Яхно, Рассуханов тәмәке тартып утыралар.

Яхно. Я думаю, он наш перебежчик.

Шаталов. Черт его знает.

Яхно. И, наверно, Зариф его знал.

Рассуханов *(борын астыннан мыгырдый)*. Разберутся.

Севрюгин *(кызып китә)*. А я думаю — этот... слов не могу подобрать... ублюдок... Зайнуллин — как пить дать, финский шпион! *(Тәмәке төпчеген ыргыта, төкерә.)*

Шаталов *(ачу белән)*. Погоди брызгать слюной. Допросят, заставят все рассказать. Специальные органы для этого есть.

Севрюгин *(башын читкә борып)*. Органы-то есть. А вот рядом вражина ходил. Из одного котелка, можно сказать, жрали.

Зимин *(блиндаж эченнән эндәшә)*. Шаталов, зайди!

Шаталов блиндажга керә.

Шаталов. Товарищ...

Зимин *(шундук бүлә)*. Кончай, времени нет. Садись. Что скажешь?

Шаталов *(утыра)*. Ну что... По дороге Зайнуллин рассказал, что к нему подкрался финский снайпер, который оказался по национальности татарином.

Зимин. А до этого на передовой Зайнуллин как себя вел?

Шаталов. Воин отважный... Тогда-то он показал себя как настоящий солдат... Ну, я не знаю... А тут с врагом сидеть и песни петь... *(Уйга кала.)* Думаю, его расстреляют.

Зимин *(күзләрен кысып)*. А тебе не жалко будет его?

Шаталов *(аптырап)*. Кого?!

Зимин. Зайнуллина.

Шаталов *(кискен тавыш белән)*. Нет! Потому что идет война, а на войне нет времени жалеть.

Зимин. Иди. Пусть Рассуханов зайдет.

Шаталов. Есть. *(Чыгып китә.)*

Рассуханов керә.

Зимин. Заходи быстрей, садись, времени мало! *(Рассуханов килеп урындыкка утыра.)*

Зимин *(солдатка шактый вакыт карап тора)*. Что можешь сказать о случившемся?

Рассуханов *(тыныч кына тавыш белән)*. Здесь ничего такого, думаю, нет. Встретились два татарина. Просто воюют они один — за свою Родину, другой — за свою.

Зимин *(кыҗрап)*. Ну, если так, то они должны были стрелять друг в друга! *(Алга таба сузылып.)* Если бы ты чеченца на финской стороне увидел, то не стал бы убивать? А?

Рассуханов *(капитанның күзенә карап)*. Чеченцев нет на финской стороне.

Зимин. Ну а если бы были, стал бы с ним сидеть и распевать песни?!

Рассуханов. Я сегодня боец Красной Армии и служу как положено. А что было бы, если бы... не надо так думать.

Зимин *(беркавым тып-тын утырганнан соң)*. Иди.

Рассуханов. Есть! *(Кузгала.)*

Зимин. Позови Яхно!

Рассуханов. Есть! *(Чыгып китә.)*

Яхно керә һәм тиз генә барып Зимин каршына утыра.

Зимин *(папирос кабыза)*. Плохи дела, Яхно.

Яхно *(корыч тавыш белән)*. Расстрелять обоих и все!

Зимин *(папиросын суырып Яхнога игътибар белән карый)*. Ты же всегда защищал Зайнуллина, когда между собой грызлись...

Яхно *(нәфрәтләнеп)*. А кто знал, что он такой?!

Зимин. Какой?

Яхно. Ну так... с финской «кукушкой»... по-братски.
Зимин *(күзләрен чекерәйтеп)*. Но они одной национальности.
Яхно *(кыҗрый)*. Ну и что! Мне наплевать какой национальности! Враг есть враг!
Зимин *(папиросын көл савытында сыта)*. Правильно. Можешь идти.
Яхно *(урыныннан кузгала)*. Есть!
Зимин. Позови Севрюгина!
Яхно. Есть! *(Чыгып китә.)*

Севрюгин керә.

Зимин. Садись.
Севрюгин *(утыра)*. Ну что, я предупреждал вас! Я его сразу раскусил. И ножик он специально оставил. *(Тавышын әкренәйтеп.)* Завербованный он.
Зимин *(аңламаган булып кылана)*. Кто?
Севрюгин *(гаҗәпләнеп)*. Как кто! Зайнуллин!
Зимин. Давно?
Севрюгин. Откуда я знаю! Их еще не расстреляли?
Зимин *(тавышына искиткеч сабырлык салып)*. А зачем спешить?! Сначала им язык развяжем, потом передадим куда следует... Каждый получит то, что заслуживает.
Севрюгин *(кыҗрый)*. Да расстрелять их, и дело с концом!
Зимин *(землянка почмагының бер ноктасына текәлеп)*. А какой толк их расстреливать?! Может быть, очень ценные сведения через них добудем. А? *(Севрюгинга карап утыра.)*
Севрюгин *(капитанның күз карашыннан шүрли)*. Не знаю.
Зимин. Иди!
Севрюгин. Есть! *(Чыгып китә.)*

Якында гына снарядлар шартлый башлый. Пулеметтан, винтовкадан аткан тавышлар, кычкыру, ыгы-зыгы куба. Тирә-як караңгылана. Солдатлар чабыша. Носилкалар белән яралыларны ташыйлар. Рота командиры Лебедев күренә.

Зимин *(кычкыра)*. Товарищ Лебедев! Что там?
Лебедев *(Зиминга таба килә)*. Наша артиллерия обстреливает. Но на ощупь. Правильно наводить нет возможности, сквозь лес ничего не видно.
Зимин. Подмога вроде идет.
Лебедев. Давно уже обещают.
Зимин. А там что вообще происходит?
Лебедев. Нам разрешили немного отступить. Ну а финнов накрыли там.
Зимин. Понятно.
Лебедев. Снаряды-то успели замаскировать?
Зимин. Да так, как могли. Но не очень надежно. Дай бог, чтобы наши первыми сюда успели. Финны подойдут, сразу найдут — у них чутье звериное.
Лебедев. Ученые-то живы?
Зимин. Все живы-здоровы. *(Көлә.)* Но страху натерпелись. Я им оружие раздал. Некоторых никак стрелять не можем научить.
Лебедев. Еще бы дня два продержаться. Потерь очень много. Я прошу, товарищ Зимин, отдать моих пятерых ребят мне обратно. Они мне там очень нужны. Мы же опять туда поползем.
Зимин *(уйланып тора)*. Хорошо, я тебе отдам ребят, но не пять человек, а только четверых.
Лебедев. Почему?
Зимин. Скажи, положа руку на сердце — что ты про своего Зайнуллина можешь сказать, кроме того, что уже говорил?
Лебедев. Из второго отряда?
Зимин. Да.
Лебедев. Зариф?
Зимин. Зариф.
Лебедев *(инандырырлык тон белән)*. Отличный боец! Помню, на передовой он лучше всех воевал.
Зимин *(теләр-теләмәс кенә әйтә)*. Он арестован.
Лебедев. Не понял?! Кто?
Зимин. Зайнуллин из твоей роты.
Лебедев *(кашларын җыерып)*. За что?
Зимин *(авыр сулап куя)*. С финской «кукушкой» тайком встречался.
Лебедев *(аптырап)*. Не может быть!

Зимин *(Лебедевка ачуланып карый)*. Не может быть, говоришь?! А не боишься так утверждать?

Лебедев *(Зиминга карап тора)*. Где он?

Зимин. Вон в той землянке.

Лебедев. Я должен увидеть его.

Зимин. Иди, охрана пустит тебя.

Лебедев *(басынкы тавыш белән)*. А остальных отправь, пожалуйста, обратно в роту. *(Зариф янына китә.)*

Зимин. Хорошо. *(Кычкырып.)* Шаталов!

Шаталов. Я!

Зимин. Забирай своих ребят и бегом в распоряжение заместителя командира роты!

Шаталов. Есть!

Шаталов, Рассуханов, Севрюгин, Яхно иелә-иелә йөгерәләр. Якында гына бер-бер артлы снарядлар шартлый. Солдатлар йөгерешәләр. Яралыларны носилкаларга салып ташыйлар. Ыгы-зыгы. Акырыш-бакырыш. Төрле командалар яңгырый. Сәхнә йә яктыра, йә кинәт караңгылана. Зимин блиндажга кереп кача. Авыр музыка. Снарядлар шартлавы бераздан тына. Лебедев күренә. Блиндаждан аның каршысына Зимин чыга.

Лебедев. Я поговорил с ним. Он мне все рассказал.

Зимин. Я знаю, что он тебе рассказал. И ты думаешь, ему можно верить?

Лебедев. Я его хорошо знаю. Он бесстрашно вел себя под вражеским огнем.

Зимин *(җикереп)*. А что он любил отлучаться, притворяться нелюдимым, что он прогуливался один при каждом удобном случае — этого ты не замечал?!

Лебедев *(усал тавыш белән)*. Попрошу не повышать на меня голос!

Зимин. А что на наш секретный объект уже который день ведется вражеский артиллерейский огонь — это-то ты замечаешь?

Лебедев. Хочешь сказать — это Зайнуллин наводку делает?

Зимин. Разберемся.

Лебедев. Ни за что этому не поверю. Я помню, как он пришел в роту, как начал службу, как вступил в первый бой! У меня к тебе предложение... просьба... Давай это дело утрясем здесь, у себя. Пленного финского татарина оформим как пленного, а Зайнуллина отдай мне.

Зимин. Ты не боишься, что на тебя тень может пасть?

Лебедев. На меня, товарищ капитан, может пасть вражеский снаряд — вот этого я, скажу откровенно, боюсь, а теней бояться не имею права, потому что я выполняю ответственную задачу.

Зимин *(авызын кыйшайтып)*. Ну-ну.

Лебедев *(сабырлыгын җуймаска тырышып)*. Мы с вами должны доверять друг другу, Федор Семенович. Мы не первый день одну задачу с вами выполняем. И эти склады мы с вами отстоим, они не достанутся врагу. Закруглим это недоразумение прямо сейчас. Не надо никуда сообщать.

Зимин. Анатолий Евсеевич, а что, если все гораздо глубже. Что, если он завербован еще до армии? А что, если вокруг нас паутину плетут вот такие сородичи и земляки?! А что, если твои Зарифы уже про наши реактивные снаряды сообщили маршалу Маннергейму, шведам, англичанам, всем-всем...

Тирә-якны бомбага тота башлыйлар. Ерактан кычкыралар.

Ерактагы тавыш. Товарищ старший лейтенант!

Лебедев *(үтенеп сорый)*. Прошу вас, товарищ капитан, не губите парня! Я побежал. *(Урман эченә кереп югала. Зимин блиндажга таба юнәлә.)*

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә урталайга бүленгән. Бер яктагы кечкенә землянкага Зыятдинны ябып бикләп куйганнар. Икенче яктагы землянкага Зарифны бикләгәннәр. Сәхнә түрендәге калкулыкта Зимин үзенең блиндажында нәрсәдер язып утыра. Сикереп тора да, кызу-кызу атлап, Зыятдин янына керә. Зыятдин җир идәндә утыра.

Зимин *(керә дә Зыятдинга карап тора, аннары тыныч кына эндәшә)*. Встань. *(Зыятдин карап утыра. Зимин кул ишарәсе белән аңлата.)* Встань! *(Зыятдин торып баса.)* Теперь ты уж запомни русское «встань». Фамилию, имя, отчество назови.

Зыятдин *(фин телендә әйтә)*. Мин русча аңламыйм.

Зимин *(Зыятдинны башыннан аягына кадәр җентекләп күзәтә)*. Хочешь, чтобы я с тобой по-фински говорил?! *(Тынлык.)* Ты кто?

Зыятдин *(фин телендә әйтә)*. Тәрҗемәчесез сөйләшә алмам мин сезнең белән.

Зимин *(Зыятдин тирәсендә әйләнеп йөри)*. Ладненько. Общий язык мы с тобой все равно найдем. *(Кинәт татарчага күчә.)* Фамилияң, исемең ничек? *(Зыятдинның каршысында туктап күзләренә карый.)*

Зыятдин *(капитанның күзенә карарга курыкмый)*. Минем документта барысы да язылган.

Зимин *(акцент белән, вата-җимерә татарча сөйләшә)*. Кайсы дивизиядән, ничәнче полктан?

Зыятдин. Мин үз теләгем белән, үз ирегем белән сугышам.

Зимин. Ополченец? *(Тынлык.)* Без алган территориядә яшисеңме?

Зыятдин. Хельсинкидан мин.

Зимин. Бу яктан качкан дезертир түгелме соң син?

Зыятдин *(көлемсерәп)*. Мин сиңа бер начар сүз дә әйтмәдем, ә син мине мыскыл итәсең.

Зимин. Кайчаннан бирле сугышасың?

Зыятдин. Беренче тапкыр Хельсинкины бомбага тотканнан соң ук җыенып чыгып киттем.

Зимин. Син күзәтчеме, әллә «күке»ме?

Зыятдин. Мин туган илен яклаучы фин гражданы. «Күке» дип мине тагын мыскыл итәсең.

Зимин *(ямьсез итеп елмая)*. Сезнең Зариф үпкәләми бит Күке дигәнгә. Аның да кушаматы Күке.

Зыятдин. Фин снайперларын «күкеләр» дип пропаганда йөзеннән сөйлисез бит сез. Имеш, агач башында утырырга фәрман биргәннәр, үлгәнче шуннан атып утыралар. Ә асылда исә мин, мәсәлән, агач башыннан да, теләсә кайдан да ата алам.

Зимин *(ясалма ягымлылык белән, ләкин яман усал итеп)*. Инде күпме аттың?

Зыятдин. Әле бер кешегезне дә үтерергә җитешмәдем.

Зимин. Нинди задание белән монда йөрисең?

Зыятдин. Аңламыйм?

Зимин *(кычкырып)*. Нишләп йөрисең монда?

Зыятдин *(башын югары тотып)*. Агрессорга каршы сугышып.

Зимин. Зарифтан башка тагын кемнәр белән элемтәдә?

Зыятдин. Мин беркем белән дә элемтәдә тормадым. Ә Зариф ул — сезнең каһарман. Ул зур батырлык күрсәтте. Мине әсир итте. Сезгә мөһим түгелмени — солдатыгыз фин снайперын әсир итте.

Зимин. Ул сине пленга алды, да?

Зыятдин. Әйе.

Зимин *(тагын килеп Зыятдинның күзләренә карый)*. Ә миңа башкачарак сөйләделәр.

Зыятдин *(туп-туры карап)*. Белмим, ничек сөйләгәннәрдер, ул мине әсир итте.

Зимин *(землянка буйлап йөри)*. Кем кемне әсир иткәндер, анысы вак мәсьәлә. Миңа Зариф кызыклы нәрсәләр әйтте инде. *(Пауза.)* Беләсең килсә, фин разведкасы белән элемтәдә торуын сөйләде ул миңа.

Зыятдин *(көлә)*. Ышанмыйм. Ничек инде элемтәдә тора алсын ул Татарстанның бер урман хуҗалыгыннан килгән татар егете.

Зимин *(кинәт Зыятдинның каршысына килеп баса)*. Ә син каян беләсең аның Татарстаннан, урман хуҗалыгыннан икәнен?

Зыятдин. Үзе әйтте. Без бит аның белән сөйләштек.

Зимин. «Кукушка» буларак күпме кешебезне үтердем дисең?

Зыятдин. «Күке» буларак та, кеше буларак та беркемне үтергәнем юк әлегә.

Зимин. Нишләп?

Зыятдин. Ничек инде «нишләп»?!

Зимин. Тып-тын гына килмәкче идеңмени безнең базага?

Зыятдин. Мин сезнең базагыз хакында белмәдем. Очраган совет солдатларын атып үтерергә дип йөрдем мин. Аучы мәргән кебек. Бу — СССР территориясе түгел. Бу — безнең ил. Бу — Финляндия!

Зимин. Ә Зарифны ник атып үтермәдең?

Зыятдин. Татарча җырлаганын ишеттем.

Зимин *(авызын кыйшайтып башын чайкый)*. Ышанмыйм! Син аның җырлаганын ишеткәнсең — атмагансың... Ничек сине кулга алды соң ул?

Зыятдин. Шулай килеп чыкты. Мин аның татар икәнен аңлагач, янына килдем, соңыннан атып үтерермен дип. Шул чакны ул винтовкасын эләктереп алды да мине коралсызландырып кулга алды. Менә шулай әсир төштем.

Зимин. Алдыйсың бит син.

Зыятдин. Ышанмасаң ышанмыйсың инде.

Зимин. Гаҗәп, ничек син Финляндиядә яшәп татарча яхшы сөйлисең?!

Зыятдин. Син дә бит урыс башың белән татарча хәйран әйбәт сөйләшәсең.

Зимин *(горур тавыш белән)*. Мин Ватанны дошманнардан саклый-саклый өйрәндем татарча сөйләшергә!

Зыятдин *(мыскыл итеп елмая)*. Бөтен дөнья белән сугыша-сугыша йөз телдә өйрәнерсең әле син сөйләшергә.

Зимин *(кинәт кыяфәте коточкыч төскә керә)*. Син шаярасың... Но тиздән шаяру түгел, хәтта уйлый да алмый башлаячаксың. Әмма ләкин башта кем икәнеңне, нәрсәләр белүеңне тезеп-тезеп сөйләп бирерсең миңа. Мондагы агентурагызны ачып бирәчәксең! *(Чыгып китә.)*

Зыятдин җир идәнгә утырып кала. Зимин икенче землянкага — Зариф янына керә. Зариф җир идәндә кырын яткан һәм уйга баткан. Зимин кергәч әкрен генә торып баса.

Зимин *(землянканың бер башыннан икенчесенә атлый)*. Сөйлә.

Зариф. Нәрсә сөйлим?

Зимин. Дөресен.

Зариф. Мин сезгә инде барысын да сөйләдем. Мин завербованный түгел. Чит ил шпионы түгел мин. Дезертир түгел, качарга җыенмадым. Бернинди фин разведкасы белән элемтәдә тормадым. Сатлыкҗан түгел мин... Тагын нәрсә сөйлим? Гаебем юк дип саныйм. Кабатлап әйтәм: ул снайпер миңа атмады — бу бит аның безне дошман итмәве. Аның үз илендә мылтык белән йөрергә хакы бар лабаса! Мине бит югыйсә атып үтерә ала иде, мин сизми дә калган булыр идем. Шуңа күрә сез аны каты хөкем итәргә тиеш түгел. Ул беркемне дә үтермәгән. Җибәрегез аны.

Зимин. Ул бит җибәргәч үтерергә может.

Зариф. Менә мине үтермәде бит! Ә мин — кызыларм еец киеменнән. Атмады бит!

Зимин. Менә шунысы сәер — нишләп атмады ул сиңа?

Зариф. Дөресен әйтәм: татарча җырлавымны ишеткәнгә атмаган.

Зимин *(җикереп)*. Ә русча җырлаган булсаң, атар иде, шулаймы?

Зариф *(өзгәләнеп)*. Иптәш капитан! Татарча җырласам да, мин — Кызыл Армия солдаты. Мине атып үтермәве аның язмышын җиңеләйтсен иде. Сез үзегез минем урында булсагыз, һәм дә снайпер сезне үтермәсә, сез аны дошман итәр идегезме?

Зимин. Миңа каршы корал күтәреп йөргән кеше хет атсын, хет атмасын, ничек кенә карама — барыбер миңа дошман ул. Синең кличкаң Күке... Ул да фин «күке»се... Моны ничек аңлатырга?

Зариф *(газаплы кыяфәт белән)*. Нишләп ышанмыйсыз сез миңа?!

Зимин *(авызын кыйшайтып елмая)*. А ул миңа бөтенләй башкача әйтте...

Зариф. Ничегрәк?

Зимин. Безнең базадагы яңа төрле снарядлар хакында информация килде, диде. Кем хәбәр итте, дигәч, безнең агентура, диде. *(Зарифка текәлеп карап тора.)*

Зариф. Сез ул агентура мин дип уйлыйсызмы?

Зимин. Инде дошманны юк итәргә яки пленга алырга тырышмавың гына да куркаклыкка, хыянәткә тиң. Ә гомумән асылда синең кем икәнлегеңне әле без ачыклаячакбыз.

Зариф. Әллә нәрсәләр ягарга маташмагыз инде миңа. Әйе, куркаклыкта, фин снайперын әсир итмәүдә мине, әлбәттә, гаепли аласыз. Мин бөтенләй гаепсез түгел инде, килешәм. Әмма ләкин Зыятдинның гаебе юк.

Зимин. Ничек инде дошманның гаебе булмасын?! Дошман дошман ул!

Зариф. Миңа гына түгел, биш кешенең берсенә дә атмаган бит ул — шуны аңлагыз сез!

Зимин *(тешләрен шыгырдатып)*. Син мине нәрсәне ничек аңларга өйрәтмә! Пәкесен онытып калдырган, видишь ли... Ялгызлык ярата... Нелюдимый... Нелюдимый татарча ничек?

Зариф. Аралашмаучан.

Зимин. Аралашмаучан...

Зариф *(куркуын җиңеп сөйләшә)*. Минем өчен дә сәер, могҗизалы вакыйга бу. Мин безгә каршы сугышучы татарны, якташымны очратырмын дип төшемдә дә күрмәс идем... Ничек кенә булмасын, мин ул кешегә рәхмәтле.

Зимин. Ни өчен?

Зариф. Мине атып үтермәгәне өчен.

Зимин *(үчекләп)*. Ул да сиңа рәхмәт әйтә — предатель, сатлыкҗан булуың өчен.

Зариф *(кинәт кабарган нәфрәтен тыя алмый)*. Син мине алып чыгып пистолетыңнан маңгаема ат, ләкин андый сүз әйтмә миңа!

Зимин *(кыҗрап)*. Син миңа койрыгыңны күтәрмә! Каян беләләр финнар безнең складлар турында, аңлашылды. Әйтәм җирле, шушы якка аталар да аталар, аталар да аталар. *(Землянка буйлап йөренә.)*

Зариф. Командованиенең тинтәклеге аркасында ул. Солдатларның гаебе юк. Алдан снарядлар китереп өеп куеп, аның специалистларын монда кайчаннан бирле җәфалап... Ә ата торган пушкалары күренми дә күренми. Кем инде алгы линиягә секретный корал илтеп ташлый да бер ротага сакларга куша?!

Зимин *(көлемсерәп)*. Бик акыллыланып киттең... *(Зарифның каршысына килеп баса.)* Бик хуп! Сине сөйләтергә әйбәт бу!

Зариф *(башын читкә бора)*. Мин сөйлисен сөйләдем инде. Бүтән әйтер сүзем юк.

Зимин. Димәк, теге «күке» и... *(Зарифка бармагы белән төртә.)*... бу Күке очраклы рәвештә очраштылар?! Кызык, кызык... Ә син нишләп ул фин снайперын пленга алдым дип әйтмисең?

Зариф *(Зиминга туп-туры карап)*. Чөнки мин аны әсир итмәдем.

Зимин *(мыскыл итеп елмая)*. Ә бит синең шулай дип әйтергә мөмкинлегең бар иде. Котылырга бердәнбер чараң иде бу синең.

Зариф. Нишләп мин алай алдашыйм... Аннары, барыбер күргәннәр бит безнең бергә сөйләшеп утырганны.

Зимин. Ну, сөйләшеп утырганны күрү әле ул... Зыятдин бит әйтә: Зариф мине әсир итте, ди. Зариф — ул сезнең героегыз, диде.

Зариф *(шакката)*. Ничек инде!

Тышта тагын ыгы-зыгы куба, фин самолетлары оча башлый. Берничә җирдә бомба шартлый. Еракта исә каты сугыш бара, анда ату тавышлары бер дә тынмый. Зимин чыгып китә, Зариф землянка буйлап ары-бире йөрергә тотына. Зимин үзенең блиндажына таба юнәлә. Кереп утыра да нәрсәдер яза башлый. Лебедев керә.

Зимин. Ну и как?

Лебедев. Потери большие. Лейтенанта из 44-й дивизии встретил.

Зимин. Что говорит?

Лебедев. Рассказывал, что творилось там. *(Урындыкка утыра.)*

Зимин. Как у него фамилия?

Лебедев. Не помню. Интересно, как у нас с запасами?

Зимин. Продовольствия у нас мало. Боеприпасы, ты знаешь, тоже на исходе. Но подкрепление вот-вот будет, надеюсь, успеют.

Лебедев. Но финны как раз на нашем участке собираются наступать.

Зимин. Не успеют.

Лебедев. А если успеют?

Зимин. В первую очередь склады взрываем. А дальше видно будет.

Лебедев. А может на другом участке пойдут...

Зимин. Нет, они именно на нашем направлении пойдут.

Лебедев. Почему так уверен?

Зимин. Потому что эти финны про нашу базу знают.

Лебедев. Догадываться могут... Если даже про склады знают, они же не знают что за «товар» у нас здесь находится.

Зимин. Почему ты уверен, что не знают. Знают они про нашу базу, знают... И что у нас секретные снаряды хранятся — тоже знают.

Лебедев. Что пленный говорит?

Зимин. Все расскажет, никуда не денется.

Лебедев. Зайнуллин как?

Зимин. Тоже расколется.

Лебедев *(командирларга хас кискенлек белән)*. Невиновен он!

Зимин *(шундый ук интонациядә җавап бирә)*. «Кукушка» он! По широко распространенному русскому народному поверью, дорогой ты мой, кукушка — это постоянный оборотень.

Лебедев. Что-то не слышал.

Зимин. Ты коренной ленинградец, потому и далек от народа и его поверья тебе неведомы. Есть мнение, что кукушка и ястреб — одна и та же птица, принимающая по своему желанию, то вид кукушки, то вид ястреба.

Лебедев. Не так уж я далек от своего народа, как ты думаешь. Я тоже знаю о кукушках кое-что. *(Утырган урыныннан тора.)*

Зимин. Например?

Лебедев. Кукушка натощак окукукает — не к добру. Скоро бойцов кормить нечем будет. Как бы не пришлось, как в соседних дивизиях, дохлую конину жрать.

Зимин *(боерулы тавыш белән)*. Перестань!

Лебедев *(кычкыра)*. Что, «перестань»! Там наши солдаты кипятят конские копыта и пьют этот гадкий сок. Там людей умирает больше от холода, чем от вражеских пуль!

Зимин *(Лебедевка якын килеп кычкыра)*. Замолчи!

Лебедев *(тешләре арасыннан)*. Не кричи на меня! Не имеешь права!

Зимин *(үзен кулга алырга тырышып)*. Я не имею права?!

Лебедев *(истерикада)*. Я еще знаю о кукушках! «При первой кукушке брякни деньгами, чтобы водились».

Зимин *(кинәт тынычлана)*. Успокойся, старший лейтенант!

Лебедев *(еш-еш сулап)*. Я спокоен, капитан. Отпусти Зайнуллина!

Зимин. А финна?

Лебедев. Он — военнопленный. Дальше видно будет.

Зимин. Зайнуллин — арестованный. Я должен держать его под стражей и сдать куда следует после некоторых формальностей. Я тебе советую быть осторожней, Анатолий Евсеевич. Ты сам себя можешь погубить, заступаясь черт знает за кого.

Лебедев. А если докажется, что он невиновен?!

Зимин. Как невиновен! Он струсил, он не действовал так, как положено бойцу Красной Армии. Это равносильно предательству! Это уже точно! А о сотрудничестве с финнами предстоит еще тщательно разобраться. Не был ли он завербован еще у себя там в Татарии. Земляки... мать вашу!

Лебедев. А тот финн не наш перебежчик, не красноармеец бывший?

Зимин. Не похож на перебежчика. Просто у него форма такая... Не армейская. Теплый свитер, шерстяные носки... У него кокарда и ремень только финские. Но тем не менее, он — финский воин.

Лебедев. Среди пленных их много встречается в такой одежде.

Зимин. А они резервистам униформы не успели пошить. Да и экономят они — на ремни да на кокарды только тратятся. Теплый свитер, носки домашней вязки, тулуп — вот эта неуставная форма ихняя называется «каяндеркой».

Лебедев. В честь ихнего премьер-министра Каяндера, что ли?

Зимин. Да. Поэтому, если увидишь в лесу человека в простой одежде, это солдат финской армии.

Лебедев. Да, не думал я, что финны так будут биться.

Шактый вакыт тыштагы гөрселдәүләргә колак салып сөйләшми утыралар

Зимин. В местности хорошо ориентируются, сволочи.

Лебедев. Целые дивизии наши в окружении погибают.

Зимин. Ну, это ты брось. Окружили несколько дивизий и все. На войне всякое бывает.

Лебедев. Наших-то больше погибает.

Зимин. Ты боевой командир, ты уже показал себя геройски. А вот то, что сейчас сказал — это паникерство.

Лебедев. Мне людей жалко.

Зимин. Не тебе одному жалко людей.

Лебедев. Мне кажется, надо выведать у этого снайпера информацию о дислокации их войск на нашем участке, не тратя времени на другие подозрения и догадки.

Зимин. Дорогой мой, об их дислокации мы знаем все. Меня интересует теперь их разведывательные связи. В этом деле ты мне не мешай, старший лейтенант!

Лебедев. А как себя чувствует научно-технический персонал?

Зимин. Нормально. Сегодня они будут перетаскивать снаряды в другое место. Людей не дашь?

Лебедев. Не могу.

Зимин. Погребов не хватает. Придется несколько землянок под погреба перестроить. Когда этих «кукушек» отправим куда следует — вот тебе еще две ямы освободятся.

Лебедев *(ялварулы тавыш белән)*. Федор Семенович, я понимаю... У вас служба такая... Но мне кажется, что вы порой врагов ищете не там или совершенно в пустом месте.

Зимин *(коры гына)*. Анатолий Евсеевич! Врагов мы будем искать везде и всюду! И будем находить! И будем уничтожать!

Лебедев бер сүз дә әйтми, чыгып китә. Якын тирәдә снарядлар шартлый. Яктылык һәм караңгылык бер-берсен алыштырып тора. Тынлык урнашкач, Зимин янына Зыятдинны алып керәләр. Зимин Зыятдинның зажигалкасы белән әле кабызып, әле сүндереп уйнап утыра.

Зимин *(зажигалканы күрсәтеп)*. Синекеме?

Зыятдин. Минеке.

Зимин *(Зыятдинның паспортын актара)*. Бабаң кайчан киткән Финляндиягә?

Зыятдин. XIX гасырда.

Зимин. Соңгы тапкыр туганнарың кайчан безнең илдә булганнар?

Зыятдин. Унҗиденче елга кадәр.

Зимин. Профессияң?

Зыятдин. Мин төрле калаларда тукыма кибетләре тотам.

Зимин *(паспортны куеп Зыятдинга карый)*. Тиздән күрәбез инде келәмнәреңне. Ә син безнең төрмәләрне, лагерьларны күрәчәксең. Әлбәттә, анда тукымалар, паласлар, чигүле кашагалар юк. *(Елмая.)* Шунда кычкырачаксың инде «ку-ку, ку-ку» дип.

Зыятдин *(үзен кыю һәм тыныч тота)*. Минем телем бар. Әйтәсе сүземне сүз белән әйтермен.

Зимин. Син миңа килеп эләккәнең өчен язмышыңа рәхмәт укырга тиешсең.

Зыятдин *(көлемсерәп)*. Рәхмәт укырга?!

Зимин. Син көлмә! Күптән түгел безнең күрше полктагы егетләр сезнең бер «күке»гезне тотканнар. Беркемгә әйтмичә, беркая тапшырмыйча, тотканнар да үзләре хөкем иткәннәр. *(Зыятдинга карап тора.)* Нигә сорамыйсың нишләткәннәр дип?

Зыятдин. Нишләткәннәр?

Зимин. Ул снайперыгызның хәтта исем-фамилиясен дә сорап тормаганнар, тотканнар да бәкегә салып батырганнар. *(Зыятдинга карап тора.)* Бигрәк коточкыч үлем, әйеме? Бәкедә батып үлү... Ай-яй... *(Кинәт сорап куя.)* Тагын ничәләп кешегез йөри бу тирәдә?

Зыятдин *(башын югары тотып)*. Белмим. Урманда әллә кемнәр, әллә нәрсәләр йөрер... «Кара урманның карыны киң», кем әйтмешли. Мин — үзем генә. Ниндидер полкныкы да түгел, бернинди фәрман буенча да түгел, вөҗданым кушуы буенча сугышырга киттем.

Зимин. Белә-ә-әм мин нинди максат белән монда йөрүеңне.

Зыятдин. Зарифның язмышы ничек хәл ителәчәк?

Зимин. Анда синең ни эшең бар! Ул да «күке». Аңа да келәмнәр, коверлар күрү насыйп булмас дип уйлыйм.

Зыятдин. Ул дошман снайперын әсир иткән кеше. Сез аны каһарман дип командованиегезгә хәбәр итәргә тиешсез.

Зимин *(үчекләп)*. Тагын нәрсәләр эшләргә тиеш мин — бәлки, өстәп әйтерсең?

Зыятдин. Дошман снайперын әсир иткән кешене бездә данлыйлар.

Зимин. Ә ул үзе баш тарта: мин аны кулга алмадым, ди. Тора-бара әле тәгаен ихлас күңелдән сөйли башлаячак.

Зыятдин. Мин аңладым: син тирәнрәк сәбәпләр эзлисең. Ниндидер шпиономания белән үзеңне дә, безне дә җәфалыйсың. Ә сәбәп гап-гади. Ул да татар, мин дә татар. Чыгышыбыз белән якташлар.

Зимин *(текәлеп карап тора)*. Сез бераз бер-берегезгә кыяфәт белән дә охшагансыз.

Зыятдин. Әйе шул. Бер үк җырлар җырлыйбыз, бер үк телдә сөйләшәбез...

Зимин. Но сез бит фронтның төрле якларында сугышасыз. Сиңа үзегездә рәхмәт әйтерләр иде мәллә, менә шушындый ситуация килеп чыкса?

Зыятдин *(тыныч кына)*. Бездә кешене аңлый беләләр.

Зимин *(шулай ук тыныч кына)*. Ә бездә аңлата беләләр. *(Кычкыра.)* Уведите!

Конвой Зыятдинны янә кечкенә землянкага алып китеп бикләп куя.Зимин янына Зарифны алып киләләр. Зариф кергәндә, Зимин аның пәкесе белән уйнап утыра.

Зимин *(пәкене кулында әйләндергәләп)*. Шушы ножикны онытып калдырган идеңме?

Зариф. Әйе.

Зимин. Ничек әле татарча?

Зариф. Пәке.

Зимин. Пәке. Шуны алырга дип бардың инде алайса?

Зариф. Әйе.

Зимин *(пәкене шалтыратып өстәлгә ташлый)*. Нишләп үзең генә бардың пәкеңне эзләргә? *(Зарифка игътибар белән карый.)* Урманда куркыныч. Нигә берәрсен үзең белән иптәшкә алмадың?

Зариф. Без ул урыннан ерак китмәгән идек. Аннары, без ул тирәне инде әллә ничә кат тикшердек.

Зимин *(кинәт сорап куя)*. Ничә тапкыр очраштыгыз фин разведчигы белән?

Зариф. Шул беренче тапкыр очрашуыбыз инде ул.

Зимин *(сорауларны тиз-тиз бирә)*. Аңарчы ничек элемтәдә тордыгыз?

Зариф. Нинди элемтәдә? Ни сөйлисез сез?!

Зимин. База турында финнар каян беләләр соң?

Зариф. Кем әйтте беләләр дип?

Зимин. Нишләп гел безне бомбага тоталар да гел безгә пушкалардан аталар?!

Зариф. Алар бөтен җиргә аталар, монда гына түгел.

Зимин *(гасаби киеренкелеккә чыдый алмый, кыза башлый)*. Ник дөресен сөйләмисең? Барыбер заставят ведь, паскуда, барысын да сөйләргә!

Зариф *(тавышын күтәреп)*. Мин дөресен сөйләдем. Мин инде туйдым. Тагын бер кат кабатлыйм. Мин сатлыкҗан түгел! Мин фин шпионы түгел! Мин завербованный түгел! Мин диверсант түгел! Минем бердәнбер гаебем: милләттәшем мине үтермәгәч, мин дә аңа кул күтәрмәдем.

Зимин *(шундук тынычлана башлый)*. Димәк, синең аны пленга алырга или үтерергә җаең, мөмкинлегең булган?

Зариф. Соңыннан, танышкач, янәшә утырып сөйләшкәндә мөмкинлегем булгандыр, бәлки. Чөнки ул минем винтовкамны миңа кире бирде. *(Өзгәләнеп.)* Ничек мин аңа атыйм инде, үзегез уйлап карагыз!

Зимин *(читкә карап)*. Син башыңны җүләргә саласың, мине дә җүләргә санныйсың, ахрысы. Дошман белән кочаклашып җырлап утыручыны, әлбәттә, менә хәзер үк, шушында ук атып үтерергә кирәк. Тик минем күңелем сизә — җепләр ераккарак һәм тирәнгәрәк сузылган монда...

Зариф *(әкрен генә)*. Ул миңа атмады.

Зимин *(җикереп)*. Башка кеше булса атар иде!

Зариф. Белмим. Ләкин бит башка кеше булмаган анда, мин булдым. Мин — кызылармеец. Ә ул мине үтермәде. *(Кычкырып җибәрә.)* Мине гаепләгез: куркаклыкта, хыянәттә, теләсә нәрсәдә, ә ул кешене әллә нинди җепләр суза-суза гаепләмәгез!

Зимин *(авызын кыйшайтып, күзләрен чекерәйтеп)*. Сиңа атмады дип аның башыннан сыпырыйммы әллә?!

Зариф *(җан ачысы белән)*. Сугыш булса да, кешеләр бит инде без!

Зимин. Кешеләр?! Ул кеше түгел! Ул — «күке»!

Зариф *(газапланып)*. Ярар, «күке» булсын. Ләкин ул «телсез күке»! Ул атмады. Димәк, ул — «телсез күке».

Зимин *(өстәлдәге кәгазь өемен актара)*. Икегез турында да тирәнтен тикшерүләр алып барылачак. Архивларны күтәрәчәкләр. Татариянең Субай тирәсен капшаячаклар. Кемнең ата-бабасы кем булган. Кем ничек кайда кемнәр белән аралашкан. Кемнәр кемгә хат язган. Кем белән кем кайда һәм кайчан очрашкан. Бөтенесен актарачаклар. Аңладыңмы?

Зариф. Аңладым.

Зимин *(Зарифны башыннан аягына кадәр күзәтә)*. Син инде бик арыгансың.

Зариф *(авыр сулап)*. Әйе, арыдым мин.

Зимин *(күзләрендә чиксез нәфрәт чагыла)*. Ә бит әле бу — башы гына, Күке Зариф! *(Кычкыра.)* Уведите! *(Зарифны янә теге землянкага илтеп ябалар.)*

Музыка. Гөрселдәүләр тагын кабатлана. Еракта солдатлар йөгереп үтә. Яралыларны күтәргән санитарлар күренә. Төрле командалар ишетелә. Зимин блиндажында нәрсәдер яза да яза. Музыка көчәя.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Кечкенә генә землянка. Зыятдин белән Зарифны икесен бергә ябып биклэп куйганнар. Бүрәнәләрне буйга ярып ясалган өстәлдә керосин лампасы яна. Зариф белән Зыятдин, стенага сөялеп, янәшә утыралар.

Зыятдин. Ничек икебезне бергә ябарга булдылар икән?

Зариф *(тавышындагы калтырауны җиңә алмый)*. Димәк, тиздән безне алып чыгып атачаклар.

Зыятдин. Ә сине нәрсә өчен?

Зариф. Финнарга хезмәт иткән дип уйлыйлар.

Зыятдин. Бездән сорау алган кеше акылга зәгыйфь, ахрысы.

Зариф. Син: «Зариф мине әсир итте»,— дип, мине коткарырыга уйлаган идең мәллә?

Зыятдин. Әйе. Минем алай дип әйтүем ярдәм итмәде инде алайса?

Зариф *(беркавым тып-тын утыралар)*. Бер караганда безне җәзасыз калдырырга тиеш түгелләр инде. Ни дисәң дә, сугыш бара бит.

Зыятдин. Белүемчә, сезнең илдә бер генә җәза бар.

Зариф *(авыр сулап куя)*. Безнең илдә бер генә җәза түгел...

Зыятдин. Сагынасыңмы туган якларыңны?

Зариф *(күзләрен йомып елмая)*. Сагынмаган кая ул.

Зыятдин. Субай хәзер дә матур авылмы?

Зариф. Искиткеч! Кәшифә шул авылныкы бит.

Зыятдин. Зәй елгасы ерак түгел аннан, шулаймы?

Зариф *(башын Зыятдин ягына бора)*. Әйе. Син каян беләсең?

Зыятдин *(елмаеп сөйли)*. Әтием сөйли иде. Бабам бигрәк озак-озак итеп сөйли иде. Әти кечкенә вакытта киткәннәр бит инде алар, шуңа күрә бабам сөйләгәннәре кызыграк иде. Әти күп нәрсәне хәтерләми. Бабай сөйли-сөйли дә җылый. Аннары җырлап ала. Тагын сөйли.

Зариф. Алай икән...

Зыятдин. Ташлы Таудан бөтен тирә-як күренеп торамы?

Зариф *(татлы елмаеп)*. Әйе.

Зыятдин. Бәрәкәт урманы күкеләренең кычкырганы Субайга ишетелеп торамы?

Зариф *(көлә)*. Әйе, ишетелә. Күке, күке...

Зыятдин *(көлә)*. Синең кушаматың Күкеме?

Зариф. Әти бәләкәй чакта адашкан. Ник болай урман эченә кердең, дип сорагач, күке тавышы артыннан бардым, күкене эзләдем, дигән. Шуңа Күке дигәннәр безне. Зимин сине кеше түгел ул, «күке» ди. Мин әйтәм, атмагач «телсез күке» була бит инде ул.

Зыятдин. Ничек кенә мыскыл итмиләр мине монда! «Күке» генә түгел, хәзер инде «телсез күке» икән мин. *(Көләләр.)*

Зариф *(йөзенә кинәт сагыш йөгерә)*. Атарга идең, Зыятдин, атарга идең! Хәзер мин дә җәфаланмас идем, син дә үзегезнең урманнарыгызда саф һава сулап йөрер идең.

Зыятдин *(Зарифка карап елмая)*. Җырламаска идең.

Зариф. Җырламыйча да булмый шул. *(Кинәт җанлана.)* Ай-яй, малай, минем Кәшифәм җырлый ул! Минем Кәшифәм кебек моңлы җырлаучы кызлар татарда бүтән юктыр. *(Куен кесәсеннән кулъяулыкка төрелгән фоторәсемне ала. Сокланып карыйлар.)*

Зыятдин. Бигрәк чибәр. *(Кәшифәнең җырлаганы ишетелә.)*

Һаваларда очкан кошкайларның
Кунганнарын күрдем киртәгә;
Мәхәббәтем көчле, янган утлар төсле,
Сүнмәс, бәгърем, иртә дә, кичтә дә.

Һаваларда очкан кошкайларның
Күңелле икән шаулап үтүе;
Авыр икән, дуслар, сөйгән ярны озату,
Тагы да авыр сагынып көтүе.

Һаваларда очкан кошкайларым,
Әйтегезче сагынып көтүем,
Аны уйлый-уйлый, күзем йокы алмый,
Йокысыз төннәрем үтүен.

*(«Кошларга».Татар халык җыры)*

Зариф. Кайда гына юк икән татар. Бер караганда куанычлы күренеш, ә икенче караганда...

Зыятдин. Бер-беребезгә каршы сугышып йөрибез, димәкче буласыңмы?

Зариф. Алай гына түгел... Сугыш бит ул кайчан да булса бетә барыбер.

Зыятдин. Һәрнәрсәнең азагы, чиге бар.

Зариф. Газапның дамы?

Зыятдин. Газапның да чиге булырга тиештер. *(Пауза.)* Мин бит аңладым синең күңелеңдәниләр кайнаганны. Татарга газапсыз яшәү ярамыйдыр инде ул.

Зариф. Яратмыйлар татарны, яратмыйлар, Зыятдин туган!

Зыятдин. Кайда, сездәме?

Зариф. Ә кайда татарны яраталар?

Зыятдин. Беренчедән, татарны яратмыйлар, дип әйтмәс идем. Икенчедән, кайдадыр яратмыйлар икән, ә нишләп әле татарны яратырга тиешләр? Яратырлык итсен татар үзен. Бүгенге татар халкы турында дөньяда белмиләр дә, беләселәре дә килми.

Зариф. Таралып, сибелеп беткән халык үзен яраттыра аламы соң?

Зыятдин. СССРда татарны яратмаслар инде ул. Кайчандыр кот алып торган халыкны ничек яратсыннар. Тирәнрәк уйлап баксаң, кайсы халык кайсысын ярата соң? Әле тегендә сугыш кабына, әле монда... Әле теге халык корал белән тегесенә күтәрелә, әле монысы кылыч кайрый.

Зариф. Шулай инде...

Зыятдин. Ә сездә кайсы халыкны ныграк яраталар соң? Бөтен төрмәләрегез, лагерьларыгыз тулды — милләтенә карап тутырмыйлар бит.

Зариф. Барыбер, төрле тарафларга сибелеп бетмәсәк, көчлерәк булыр идек шикелле.

Зыятдин. Бүген Сталин көчле, Гитлер көчле. Төрле сәбәпләр аркасында таралды безнең халык дөнья буйлап. Исән калыр өчен китүчесе дә булгандыр, яхшырак тормыш эзләүчесе дә булгандыр, үзен кеше дип хис итәр өчен китүчесе дә булгандыр. Халык язмышы халык язмышы инде ул. Аны без синең белән җырда гына җырлый алабыз. Ә сезнең илдә татар михнәтне күп күрде инде ул. Әле алда күрәселәр күпмедер!

Зариф. Барыбыз да авыр тормыштан котылу нияте белән чит илләргә китеп, җиңелрәк тормыш эзләп дөнья буйлап йөрсәк, без бөтенләй беткән булыр идек, бәлки?

Зыятдин. Әйтүе кыен. Бәлки, халык газабында мәгънә бардыр. Бәлки, яктылык эзләп, гүзәллектән мөкиббән китеп йөрсә бөтен халык — үзенең асылына кире кайта алмыйдыр. Синең этиең күке артыннан йөреп адашкан... Син бу турыда сөйләгәч, Скандинавия халыкларының бер риваяте искә төште. Имеш, бер үсмер егет һавада очкан бер шундый гүзәл кошны күреп таң кала. Кош моны сизгәндәй якындагы агач ботагына килеп куна. Егет бу кошның гүзәллегеннән, аның сайравыннан һушсыз кала. Егетне котырткандай, кош урман эченәрәк очып керә. Егет, башын өскә күтәреп, коштан күзләрен алмыйча бара да бара. Кош беркавым туктап сайрый да, тагын куе урманның эченәрәк очып китә. Егет исә бар дөньясын онытып шул кош артынан бара да бара. Ул вакытны да, узган араны да инкарь итә. Инде бик озак баргач, кош югарырак очып китә һәм күздән югала. Ә үсмер егет адаша һәм кире кайтыр юлны таба алмый. Гүзәл кош артыннан барып, ул кире кайта алмый. Шуның белән тәмам. Моның мәгънәсе бит болай: чит гүзәллеккә омтылып үзеңне югалтуың ихтимал, адашып үзеңнең асылыңа кайта алмавың ихтимал.

Зариф *(өстә ишетелгән гөрселдәүләрне тыңлап)*. Сезнең Субайда туганнарыгыз калдымы соң әле?

Зыятдин. Анда Әүхәди Һадиулласы дигән агайны беләсеңме? Бик карттыр инде ул хәзер...

Зариф *(җанланып)*. Беләм, беләм! Аның улы Саматны да, Самат абыйның кызы Гөлчирәне дә бик яхшы беләм.

Зыятдин. Менә шул Һадиулла бабайлар безнең ерак туганнарыбыз була инде. Башка туган-тумачабызны кулаклар дип барысын да сөргәннәр. *(Йөзе кинәт караңгылана.)* Шулай дип ишеттек.

Зариф. Менә ничек икән...

Зыятдин. Нижгар якларында булганың юктыр?

Зариф. Юк.

Зыятдин. Анда әбием ягыннан туганнарыбыз шактый.

Зариф. Алай икән. *(Землянкада авыр тынлык урнаша.)*

Зыятдин *(Зарифның кәефен күтәрергә ниятләп)*. Кәрәкә чишмәсенең суы тәмлеме?

Зариф *(елмаеп)*. Искиткеч.

Зыятдин. Җиләк хәзер дә күпме?

Зариф. Каен җиләге күп була бездә. Шомырт, чикләвек мул була. Хәер, елына карап.

Зыятдин. Сазлы күл төнбоеклар чәчәк аткач сап-сары буламы?

Зариф. Әйе.

Зыятдин. Ә урман эчендәге Көмеш күлнең суы һаман да шифалымы?

Зариф. Безнең якта су гомумән шифалы. *(Шаккатып.)* Карале, боларның барысын да бабаң сөйләдеме?

Зыятдин. Әйе.

Зариф *(кинәт канатлана)*. Зыятдин туган! Синең Ватаның Зәй буйлары, Чулман буйлары! Синең туган ягың Субай җирләре! Әйдә, безнең якка чыгарга сора!

Зыятдин *(аптырап карап тора)*. Аңламадым?

Зариф *(ялварып)*. Зиминга әйт: сезнең якка чыгам, чөнки минем тамырларым Татариядә дип әйт.

Зыятдин. Акылдан яза башладың мәллә?!

Зариф *(Зыятдинны җилтерәтә)*. Синең тамырлар шунда — Татарстан җирендә бит! *(Кинәт хәлсезләнә.)* Без шулай гына котыла алырбыз, мөгаен.

Зыятдин. Мин синнән мондый тәкъдимне көтмәгән идем.

Зариф *(ыңгырашып)*. Харап булабыз бит. Син дә харап булачаксың бит.

Зыятдин. Юк, Зариф, минем ике ватаным бар. Берсе Казан иле, берсе Финляндия. Миңа СССР Ватан булалмый. Мин андый үтенеч белән пычранасым килми.

Зариф *(ачуы килә)*. Туктале, ничек килеп чыга соң бу! Син татарча җырлап-моңаеп утырган буласың, ә үзең корал күтәреп шул җыр-моң туган илгә каршы сугышасың!

Зыятдин *(тавышын күтәреп)*. Мин ул җыр-моң туган илгә каршы сугышмыйм! Мин үземнең Финляндиямне яклыйм!

Зариф *(ярсып)*. «Үзеңнең Финляндияңне»?! Кешедә ике Ватан була аламы соң?

Зыятдин *(кычкырып)*. Финляндиягә сугыш игълан иткән ил ул синең дә, минем дә Ватаным булалмый! Бүтән кычкырма миңа! *(Күзләрен йома.)*

Зариф *(хәлсез тавыш белән)*. Сездәге татарлар барысы да Кызыл Армиягә каршы сугышамы?

Зыятдин *(шулай ук көчсезләнгән тавыш белән)*. Мин белгәннәре барысы да. Һәм моның белән чиксез горурланалар. *(Тынлык урнаша.)*

Зариф. Без, татарлар, бер-беребезгә каршы сугышабыз булып чыгамыни?! Синең бабаң җылый-җылый сөйләгән җир синең өчен изге түгелме?

Зыятдин. Син бер нәрсәне аңлап бетермисең, Зариф туган... Минем бабам туган изге җиргә каршы сугышмыйбыз без. Шул бабаларыбызның җирен таптаган, мыскыл иткән аждаһага каршы сугышабыз.

Кайдадыр өстә гөрселдәүләр көчәя. Шул тавышларга колак салып беркавым сөйләшмичә утыралар.

Зариф *(кулын Зыятдинның иңенә куя)*. Мин кызып киттем, ахрысы. Зинһар, ачуланма. Мин сиңа мең рәхмәтле — исән калуым өчен.

Зыятдин *(үчекләп)*. Исән калуым өчен... Ә алда сине хурлау һәм төрле мыскыллаулар көтсә, мине каргамассыңмы?

Зариф. Юк, Зыятдин, юк!

Зыятдин. Ә син миңа ачуланма, яме.

Зариф. Ярар.

Зыятдин. Син кем булып эшләдең?

Зариф. Урман үстерүчеләр без нәселебез белән. Ә син?

Зыятдин. Без нәселебез белән сәүдәгәрләр.

Зариф. Хельсинки матур шәһәрме?

Зыятдин. Шундый гүзәл кала! Тик менә бомбага тоталар аны соңгы вакытта.

Зариф. Гаиләң бармы?

Зыятдин. Бар. Хатыным, алты яшьлек улым.
Зариф. Хатының татармы?
Зыятдин. Әлбәттә.
Зариф. Исеме ничек?
Зыятдин. Гөлтаң.
Зариф. Матур исем. Ә улыңның аты?
Зыятдин. Раиф.
Зариф. Хатының татарча сөйләшәме соң?
Зыятдин. Миннән дә әйбәтрәк сөйләшә.
Зариф. Улың?
Зыятдин. Улым да татарча сиптерә генә.

Зариф. Гаҗәп! *(Хыялланып.)* Мин шуны уйлап куйдым әле... Алай-болай, могҗиза булып, исән калсак... Суд булыр бит инде. Хөкем иткәндә гаепләребез коточкыч дип тапмасалар, исән калырбыз, иншалла. Менә, исән калсак... Барыбер Финляндияне Кызыл Армия алачак, СССР составында булачак бит инде бу тирә... Бер-беребезне эзләп табарбыз... Субайга кайтырсыз. Кунакка йөрешербез.

Зыятдин. Күңелеңнең күтәрелүе бик әйбәт. Тик шуны әйтәсем килә. Шулай да син тилереп барасың бугай. Беркайчан да Финляндияне буйсындыра алмаячаклар. СССРныкы булмаячак безнең ил! Без барыбер җиңәбез! «Маннергейм сызыгы»н үтә алмый сезнең танклар. Безгә барыбер башка илләр дә ярдәм итәчәк. Ул ит чабучы Сталинга Финляндияне Европа бирмәячәк.

Зариф *(тагын кабынмакчы булып)*. Син, туган, авызыңны чамалап ач әле! Ату син бигрәк... теге... чаманы бел әле син... Синең каршыңда башкачарак уйлаучы кеше утыра... *(Шулай да үзен кулга алып тынычлана.)*

Зыятдин. Сез барыгыз да корбаннар. Сезне кызганырга гына кирәк. Кеше сөякләре өстендә, кан сеңгән җирдә гөлбакча үстерү мөмкин түгел. Ул сезнең СССР үзенең нәфрәте белән тончыгачак, үзенең канында үзе батачак.

Зариф *(көчкә тыелып)*. Юк, Зыятдин, син мине үтермәгәч тә, миңа әллә нәрсәләр әйтергә хакың бар дип уйлыйсың, ахрысы.

Зыятдин *(елмаеп Зарифны иңеннән коча)*. Ачуың киләме миңа?
Зариф *(башын читкә борып)*. Нишләп килмәсен!
Зыятдин *(илһамланып)*. Зариф, җырла әле, туган!
Зариф *(киреләнеп)*. Юк, дошманга җыр җырлап утырырга мин...
Зыятдин. Алайса, үзем җырлыйм. *(Җырлый. Зариф та түзми, кушылып җырлый башлый.)*

Утырдым көймә түренә,
Карадым су төбенә;
Су төбендә асылташ,
Әсир булды газиз баш.

Безнең илләр кайда, диеп,
Кыр казыннан сорадым;
Кыр казлары кыйгылдагач,
Утырдым да еладым.

Өй башында күгәрчен
Укый «Әлхәм» сүрәсен;
Без дә болай булмас идек,
Ходай язган, күрәсең.

*(«Әсирләр моңы».*
*Татар халык җыры)*

Беркавым тып-тын утыралар.

Зариф. Син миңа үпкәләмә инде, Зыятдин!
Зыятдин. Син дә үпкәләмә!
Зариф. Карале, шулай да дөресен әйт әле — монда махсус максат белән килмәгән идеңме соң син?
Зыятдин. Кайда ул «монда»?
Зариф. Безнең база янына?

Зыятдин. Монда дошман базасы барлыкны сизеп кенә килдем мин. Миңа монда килеп сезнең базаны күзәтеп йөрергә беркем дә кушмады.

Зариф. Ә монда нәрсәләр барлыгын белмисеңмени?
Зыятдин. Нәрсә булсын инде. Хәрбиләрнең нәрсәсе булырга тиеш — шулдыр инде.
Зариф. Димәк, бу база турында мәгълүматлар синдә юк?

Зыятдин. Юк. Ә нәрсәләр бар соң монда?

Зариф. Нәрсә булсын инде! Бетле солдатлардан һәм сасы землянкалардан башка ни булсын! Тагын бер сорау бирсәм, ачуланырсың инде...

Зыятдин. Сора.

Зариф. Ничә кешебезне атып үтердең?

Зыятдин *(сорауны ошатмый, шулай да коры гына җавап бирә).* Әле берне дә үтерергә өлгермәдем. Җай чыкмады.

Зариф. Без бишәү йөргәндә, син безне күзәтеп тордыңмы?

Зыятдин. Әйе. Тик агач башыннан түгел, куаклар арасыннан. Сез базагызга кайтып китәргә җыенганда гына, мин агач башына мендем. Сез ашап утырганда, мин инде берегезгә төбәгән идем винтовкамны. Инде атып җибәрәм дигәндә, ул никтер кырыйга янтайды — миңа җайсыз булды. Атмадым, чөнки тигезә алмас идем. Аннары, сез бер-бер артлы кузгалгач, иң арттагыгызга төбәгән идем. Якында гына бер кош пырхылдап очып китте дә игътибарымны җәлеп итте. Шул арада барыгызны да агачлар каплады.

Зариф *(уйга калып).* Иң артта Шаталов бара иде. Ходай саклаган Шаталовны. Ә без ашап утырганда... башта син кайсыбызга төбәгән идең икән? Кырыйга янтаючысы кем иде икән? Тасвирлап бир әле.

Зыятдин. Сиңа нигә инде ул?!

Зариф. Белмим, никтер бу сорау кинәт тынгылык бирми башлады.

Зыятдин. Ниндирәк солдатка төбәгәнемне тасвирлап биримме?

Зариф. Әйе.

Зыятдин. Дөресен әйтимме?

Зариф. Дөресен әйт.

Зыятдин *(Зарифка туп-туры карап).* Сиңа төбәгән идем.

Зариф *(мондый җавапны көтмәгән булган).* Нишләп менә нәкъ миңа? *(Калтыранып ала.)*

Зыятдин *(тыныч кына).* Арада иң зур гәүдәлесе син булгангадыр, мөгаен. Аннары, син снайпер өчен бик җайлы утыра идең — буеңны төп-төз тотып.

Зариф *(чыраен сытып).* Димәк, син мине үтерә алгансың?!

Зыятдин. Мин сине пәкеңне эзләп килгәч тә үтерә ала идем.

Зариф. Димәк, без барыбер дошманнар синең белән?

Зыятдин. Үзең өчен үзең хәл ит анысын. Дошман итсәң дошман итәсең инде.

Зариф *(милләттәшенә бик озак карап тора).* Зыятдин! Ничекләр дошман итим соң мин сине! Бу турыда сөйләшеп утырыр вакытмыни! Бу мизгелдә исән, икенчесендә — юк. Казынып утыруда ни мәгънә!

Зыятдин. Бездә менә бу җырны бик яраталар. *(Җырлый. Аңа Зариф та кушыла.)*

Кара кашым, йолдызым,
Энҗе тешем, гөл йөзем;
Ак чыраең, кыйгач кашың,
Галиябану, сылуым иркәм,
Күреп туймыйдыр күзем.

Йөгерә-йөгерә җыя алмадым,
Җир җиләге пешкәндә;
Һушсыз булып егылып ятам,
Галиябану, сылуым иркәм,
Син исемә төшкәндә.

Энҗе яка, чын ука
Җиргә төшсә, уала;
Сине күрсәм, күз алдымда,
Галиябану, сылуым иркәм,
Күңелләрем юана.

*(«Галиябану».*
*Татар халык җыры)*

Җырның уртасында базаны фин самолетлары бомбага тота башлый. Землянка җимерелә һәм аның өстендә ачыклык хасил була. Башта Зариф белән Зыятдин почмакка посып башларын куллары белән каплап утыралар. Төтен белән тузан бераз таралгач, алар землянканың түшәме җимерелеп ачылган икәнне абайлыйлар. Өсләренә коелган балчыкны каккалап, өскә чыгалар. Тирә-якта беркем дә юк. Дөньяны караңгылык баскан. Гөрселдәгән тавышлар ишетелеп тора. Тирә-юньдә бөтен нәрсә җимерелгән, агачлар ауган. Төтен сулышны буа. Гөрселдәүләр еraktarak ишетелә башлый.

Зариф *(як-ягына каранып).* Финнар һөҗүм итә. Әллә безнекеләр качканнар инде?

Зыятдин *(кабаланып сөйли)*. Зариф! Ходай безгә шанс бирә. Йөгерик безнең якка. Бу якта харап булабыз икебез дә. Без синең белән монда беркемгә бернәрсә исбатлый алмаячакбыз. Син моны үзең дә беләсең.

Зариф *(ары-бире сугыла)*. Тукта, корал эзлик башта.

Зыятдин *(йөгереп барып Зарифны түшеннән эләктереп җилтерәтә)*. Вакыт әрәм итмик, киттек тизрәк!

Зариф. Киттек! *(Финнар позициясе ягына кача-поса йөгерәләр.)*

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Сәхнә әйләнә. Урман. Музыка. Бара торгач Зыятдин белән Зариф урман авызына килеп чыгалар. Туктап хәл алалар. Якында гына финнарның оборона сызыгы сузылган. Инде финнарның йөргәннәре дә күренә. Фин телендә сөйләшкәннәре ишетелә. Төрле командалар яңгырый.

Зыятдин *(шатланып)*. Әнә безнекеләр!

Зариф *(бер дә куанмыйча)*. Әйе, сезнекеләр.

Зыятдин *(фин телендә кычкыра)*. Егетләр! Безгә атмагыз! Без үзебезнекеләр!

Финнар ягыннан *(фин телендә)*. Әйдәгез, күренегез! Без аңларбыз кем икәнегезне. Әкрен генә килегез монда таба!

Зариф *(катгый карарга килеп)*. Ярый, туган, шушында хушлашыйк.

Зыятдин. Аңламадым!

Зариф. Син бар.

Зыятдин *(котсыз калып)*. Ә син?

Зариф. Мин кире кайтам.

Зыятдин. Кая?

Зариф. Үзебезнекеләр янына.

Зыятдин *(ачуланып җикерә)*. Үзебезнекеләр! Алар сине бетерәчәкләр анда!

Зариф *(җан сызлавын көчкә җиңеп ыңгыраша)*. Мин кире кайтам. Дошман ягына чыкмыйм мин.

Зыятдин *(ялынып, ялварып)*. Котылдык бит инде!

Зариф. Нәрсәдән?

Зыятдин *(Зарифны җиңеннән йомарлап тота)*. Мин сине беркая җибәрмим. Киттек безнекеләр ягына!

Зариф *(үзенең көчле кулын кискен хәрәкәт белән ычкындыра)*. Мин дошман янына чыгарга сатлыкҗан түгел!

Зыятдин чайкалып чак кына егылмый кала.

Зыятдин. Дошман?! Хәзер сиңа кем дошман соң? Минме? Әллә теге канечкеч НКВД капитанымы? Син, ниһаять, үзеңне кеше дип хис итәчәксең. Син бит белмисең Финляндиядәге кешеләрне. Әйдә киттек дим мин сиңа!

Зариф *(ныклы тавыш белән)*. Минем туган илемдә атам-анам, Кәшифәм бар. НКВД капитаны канымны эчә дип, мин алар өчен сатлыкҗан буласым килми.

Зыятдин *(елардай булып)*. Тфү! Син бит туп-туры үзеңнең үлемеңә таба кайтачаксың. Атып үтермәсәләр дә, башың төрмәдә чериячәк бит синең!

Зариф *(тыныч кына)*. Мин төрмәдә утырырга әзер. Үләргә дә әзер. Мин сатлыкҗан түгел.

Зыятдин *(нәфрәтләнеп китеп бара, аннары кире килә)*. Соңгы тапкыр әйтәм: әйдә фин ягына!

Зариф. Юк!

Зыятдин. Һай, тиле кеше булып чыктың син, Зариф!

Зариф. Рәхмәт сиңа! Мин мәңге бурычлы сиңа, Зыятдин!

Зыятдин. Нәрсә өчен рәхмәт?!

Зариф. Мине урманда атып үтермәгәнең өчен.

Зыятдин. Нинди рәхмәт?! Хәзер кире кайтсаң, минем өчен синең башыңны бетерәчәкләр. Кире кайтсаң, теге капитаннар атып үтерәчәк!

Зариф. Барыбер рәхмәт, туган!

Зыятдин *(нишләргә белми)*. Һай, тиле кеше булып чыктың син, туган!

Зариф *(ихлас күңелдән)*. Рәхмәт сиңа!

Зыятдин *(үгетләүнең мәгънәсе юклыгын аңлап баскан урынында катып тора)*. Үзеңә рәхмәт!

Зариф. Мин сиңа бернинди яхшылык эшләмәдем.

Зыятдин. Җырың өчен рәхмәт! Чын кеше булуың өчен рәхмәт! Дөньяда күп түгел мондый кешеләр. *(Кочаклашалар.)* Хуш, туган!

Зариф. Хуш!

Зыятдин. Бәлки инде, бүтән күрешмәбез.

Зариф *(елмаерга тырышып)*. Очрашсак та, бер-беребезгә мылтык төбәп очрашмасак иде. Туктале... Минем сиңа бер үтенечем бар. *(Куеныннан кулъяулыкка төрелгән Кәшифәнең рәсемен ала, аны ачып карап тора.)* Минем язмыш инде хәл ителгән. Мә, ал әле Кәшифәмнең рәсемен һәм кулъяулыгын. Кулъяулыкны да ул биргән иде. Мине барыбер атарлар инде. Сакла, рәсемне дә, кулъяулыкны да.

Зыятдин *(тагын өзгәләнеп ялынырга тотына)*. Әйдә киттек фин ягына! Үзе атачаклар ди, үзе кире кайтмакчы була, тинтәк!

Зариф *(кырт кисеп)*. Булды! Күп сөйләшмик! Хуш!

Зыятдин. Тиле! Инде котылдык дигәч... *(Рәсемне алып кулъяулыкка төрә һәм үзенең куен кесәсенә тыга.)*

Зариф. Бар.

Тагын бер тапкыр ирләрчә каты итеп кочаклашалар да икесе ике якка юнәләләр. Музыка.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Базада эш кайный. Снарядларны ашыга-ашыга каядыр күчерәләр. Ящиклар ташучы солдатлар ыгы-зыгы килә. Тезелешеп солдатлар узып китә. Төрле командалар һәм ашыктыру боерыклары яңгырап тора. Яралылар күренә. Ыгы-зыгы. Күтәреп бүрәнәләр ташыйлар. Кыскасы, ярдәмгә тулаем
бер полк килеп җиткән һәм базаны ныгыту эшләре кайный.Уртада, бернигә ригаясез булып, Зариф каткан кар өемендә утыра. Бөтен кыяфәтендә битарафлык. Аның барлыгын әллә сизеп, әллә сизмичә, яныннан солдатлар үтеп китә. Аңа караучы да юк. Зарифны исә бу һич кенә дә гаҗәпләндерми. Берникадәр вакыт узгач, ул хезмәт иткән рота кешеләре кайта. Яралылыр бик күп. Йончыганнар, арыганнар, көч-хәл белән атлыйлар. Зариф рота командиры Лебедевны күреп ала. Лебедев та аны абайлый, ләкин күрмәмешкә салыша. Зариф торып командиры янына бара.

Зариф *(карлыккан тавыш белән).* Товарищ командир! Товарищ старший лейтенант! Я не предатель. Я вам всю правду рассказал.

Лебедев *(Зарифка карап куя да башын читкә бора)*. Я-то тебе верю.

Зариф. И какой из меня шпион, сами подумайте.

Лебедев *(Зарифка карап тора)*. Я верю тебе. Это все, что я могу.

Зариф. Спасибо.

Лебедев. А где «кукушка»? Улетела?

Зариф. Сбежал, наверно. Я без сознания был.

Лебедев *(авыр сулап куя)*. Эх, Зариф, Зариф!

Зариф. Меня скоро, наверно, расстреляют. Я ползком залез в разваленный блиндаж капитана Зимина. Там паспорт этого финского снайпера лежал. *(Куенынннан Зыятдинның паспортын алып Лебедевка суза.)* Возьмите.

Лебедев *(паспортка карап тора)*. Зачем он мне. *(Бераз уйлангач.)* Хотя, дай-ка, пригодится. *(Зыятдинның паспортын алып шинель кесәсенә тыга.)*

Зариф. Простите меня.

Лебедев бер сүз дәшми китеп бара. Бу вакытта Рассухановны носилкада күтәреп баралар. Зариф аның янына йөгереп килә. Санитарлар туктап ял итәләр.

Зариф *(әкрен генә эндәшә)*. Аслан!

Рассуханов *(башын Зариф ягына бора).* Да. *(Карап ята)*. Зариф?..

Зариф. Я. *(Аслан янына тезләнә.)* Куда тебя ранило, Аслан?

Рассуханов *(газаплы чырай белән)*. В ногу. Страшная боль.

Зариф *(елмаерга тырышып)*. Ничего, потерпи. Санчасть рядом. Туда тоже подмога прибыла.

Рассуханов. Не знаешь, какая ужасная боль! *(Ыңгыраша.)*

Зариф. Пройдет, пройдет. На, там в госпитале похвастаешься перед медсестрами... *(Кесәсеннән пәке һәм зажигалка чыгара, аларны Асланга бирә.)* На, возьми.

Рассуханов *(пәке белән зажигалканы ала).* Ножик же тебе невестка подарила.

Зариф. Да, она подарила.

Рассуханов. Так оставь у себя ее подарок.

Зариф. Меня же судить будут скоро.

Рассуханов *(зажигалканы әйләндергәләп карый)*. Зажигалка финская?

Зариф. Да. Этого... финского снайпера?

Рассуханов. А кто тебе эти вещи вернул?

Зариф. Я залез в разбомбленный блиндаж Зимина... Там все это валялось.

Рассуханов. А этот финн и вправду татарин?

Зариф. Да. Его дед из соседнего села.

Рассуханов. Спасибо за ножик и зажигалку. *(Зариф пәке белән зажигалканы аның шинель кесәсенә тыгарга ярдәм итә.)*

Зариф. Дай Аллах, чтобы быстрее твоя рана зажила.

Рассуханов. Спасибо. Думаю, после госпиталя увидимся. Нашу роту же не расформируют?

Зариф *(кинәт караңгыланып)*. Мы с тобой уже не увидимся, Аслан.

Рассуханов. Почему?

Зариф. Меня, наверно, расстреляют. Аслан! Я свой! Я и не шпион, и не предатель! Никакой я не враг! Я свой!

Рассуханов күзләрен йома. Ыңгыраша.

Рассуханов. Я знаю, Зариф. *(Ыңгыраша.)* Больно мне.

Санитарлар аны күтәреп алып китәләр. Алар сөйләшкән арада, Шаталов белән Севрюгин кайталар. Агач кәүсәсенә утырып тәмәке көйрәтәләр. Зариф әкрен генә алар яныннан уза. Тегеләр Зарифка карамаска тырышалар.

Зариф *(алар яныннан узганда туктый)*. Ребята, я не предатель! Я свой!

Тегеләр читкә карап тәмәке тарталар.

А где Яхно?

Шаталов. Погиб Яхно. Из пулемета насквозь прошили.

Зариф читкәрәк китә дә карга утыра. Базада эш кайный. Ыгы-зыгы дәвам итә. Зариф уйга чумып утыра. Бераздан Зимин ике солдат ияртеп килә. Солдатлар кораллы. Зиминның кыяфәте яман усал.

Зимин *(кобурасыннан пистолетын чыгара)*. Встать! Руки за спину!

Зариф торып баса, кулларын артка куя. Конвойлар аны алып китәләр. Алар артыннан Зимин үзе дә бара. Музыка.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Авыр музыка. Сәхнәдә тоткыннар күренә. Болар — Сталин лагере тоткыннары. Эфирда Зарифның тавышы яңгырый.

Зариф: 1940 елның март аенда совет-фин сугышы тәмамланды. 12 мартта СССР белән Финляндия арасында килешү төзелде. Бу хурлыклы сугышта кем җиңгәнне әйтүе кыен. Әлбәттә, бездә Финляндия җиңелде диделәр. Алар территорияләрен югалттылар. Сталинга акча түләделәр. Ләкин минем бөтен уй-кайгыларым кешеләр турында. Кешеләр, кешеләр... Күпме яшь гомерләр өзелде Карел урманнарында. Күпмесе өшеп үлде, күпмесе ачтан җан бирде. Фин пулеметлары күпме кешенең җанын кыйды. Финляндия үзе дә корбанны күп бирде. Ләкин СССРның югалтулары коточкыч иде.

Карелия урманнарының агачлары кышкы салкында шыкраеп каталар да сәер һәм шомлы авазлар чыгаралар. Игътибар белән тыңласаң, бу күптөрле тавышлар сихри, тантаналы һәм шул ук вакытта күңелгә авыр булып баса торган бер көйгә әверелә. Бу шомлы, моңлы һәм бәгырьне кыса торган көй шунда мәңгегә ятып калганнарга багышланган соңгы җыр булып яңгырый шикелле.

Мине көнбатыш шпионы дип тә, көнчыгыш шпионы дип тә исбатлый алмадылар. Фин снайперы белән җырлап утырганым өчен ун ел бирделәр. Шул Карелиядән ерак түгел лагерьларның берсендә мин ун ел гомеремне калдырырга тиеш идем.

Бу вакытта сәхнәдә тоткыннар эшли. Аларның кыяфәтләре дә, йөрүләре дә өрәкләрнеке сыман.

Мин үземә бирелгән җәзага түзәргә әзер идем. Күз алдымда һәрвакыт атам-анам, Кәшифәм булдылар. Алар алдында мин җавапны ничек тотармын?! Алар турында уйлаганда җанның сызлавына чыдарлык түгел иде. Ләкин түзәргә, түзәргә, исән калырга, яшәргә, гаепсез икәнемне ничек тә булса исбатларга дип үземә гел тукып тордым.

Тик шулай да шушы зольмәт эчендә бер шатлыгым бар иде: Зыятдин — мине исән калдырган миһербанлы җан — үз ягына чыгып котылды бит. Минем аркада ул да харап була дип башта бик кайгырган идем. Ул инде Хельсинкида гаиләсе белән чөкердәшеп яшидер, үзенең паласларын сатып рәхәтләнеп ятадыр дигән уй мине куандырып торды.

Срогымның бер елдан артыгын утырдым инде... Тагын тугыз ел чамасы калды... Беркемгә хат язмадым, язсам да барып җитәр иде микән?! Атам-анам ут йотып яталардыр... Ә Кәшифә... Кәшифә мине ун ел буе көтмәс дип уйладым мин. Җан газабымны сөйләргә сүзләр җитмәс, җиткән сурәттә дә аны тәфсилләп бәян итәргә йөрәк чыдамас.

Музыка. Кинәт күк күкри, яшен яшьни. 1941 елның 22 июне. Сугыш игълана. «Вставай, страна огромная» дигән җыр яңгырап куя. Тагын ерактан гөрселдәүләр ишетелә башлый. Эфирда татар халык җыры яңгырый.

Әнкәй мине тапкан-баккан,
Ак биләүгә биләгән лә;
Гомере булсын дип теләгән,
Бәхете булсын димәгән.

Биек тауның башларыннан
Герман таяк ташлаган ла;
Без бәхетсез бала үскәч,
Герман сугыш башлаган.

Утырабыз да китәбез
Кап-кара повозкага ла;
Безнең газиз башлар үскән
Германга закускага.

Без утырган машинаның
Артта кала төтене лә;
Без дә болай йөрмәс идек,
Йөртә патша хөкеме.

Мендем туры ат биленә,
Чыктым Герман җиренә лә;
Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

*(«Герман көе».*
*Татар халык җыры)*

Зариф: Лагерьда утыручыларга штрафбатлар составында сугышта катнашырга рөхсәт бирелде. Мин шундук ризалаштым. Һәм фронтка фашистларга каршы сугышка алып китүләрен зарыгып көттем. Менә ул көн килеп тә җитте.

Зариф җилкәсенә капчыгын аскан. Таш ташучы тоткыннар яныннан акрын гына уза.

Ләкин барлык тоткыннарга да рөхсәт булмады сугышка китәргә. Фронтка барырга теләмичә лагерьда калучы тоткыннар да күп булды. Ә кайберәүләрне теләсәләр дә сугышка алмадылар — кылган җинаятенә, Совет иленә ни дәрәҗәдә куркыныч булуына карап...

Зариф тоткыннар яныннан узып барганда кинәт торараш булып ката.

Зариф. Зыятдин! *(Зыятдин башта күрмәмешкә салыша.)* Зыятдин! Синме?

Зыятдин. Мин *(күз кырые белән генә як-якка карап).* Ә бу — синме? *(Зыятдин коры сөяккә генә калган. Көчкә басып тора. Кулындагы таш кисәген төшереп җибәрә.)*

Зариф *(нишләргә белми — көләргәме, еларгамы).* Мин! Күрмисеңмени! Ник җавап бирмисең, эндәшкәч?!

Зыятдин *(чак кына ишетелерлек итеп).* Ник кычкырасың? Минем аркада тагын михнәт күрәсең киләмени?

Зариф *(күзләре яшьләнә).* Син нишләп монда?

Зыятдин *(төссезләнгән күзләре белән Зарифка карап тора).* Әсир төштем.

Зариф *(өзгәләнеп сорый).* Кайчан тагын пленга эләктең соң син?

Зыятдин *(иреннәрен көчкә кыймылдатып сөйли).* Теге вакытта үзебезнең окопларга гына барып җиттем,— сезнекеләр һөҗүмгә күчте. Чолганышта калдык. Әсир иттеләр.

Зариф *(газаплы тавыш белән).* Хәрби әсирләрне дә шушылай интектерәләрмени?! Син бит шыр сөяк кенә.

Зыятдин *(авызын кыйшайтып).* Мин бит гади әсир түгел...

Зариф. Ничек?

Зыятдин. Инде сезнекеләргә бер эләгеп качкан «күке» һәм «диверсант» бит мин.

Зариф. Теге вакытта эләкканеңне белделәрмени?

Зыятдин. Белделәр. Синең хакта озак төпченделәр. Кыйный-кыйный. Минем гади снайпер икәнемә ышанмыйлар һаман. Эрерәк балык дип уйлыйлар.

Зариф *(чарасызлыктан нишләргә белми).* Их Зыятдин, Зыятдин. Мин бит берничек тә ярдәм италмыйм сиңа?

Зыятдин *(Зарифка карап авырлык белән генә елмая).* Үзең дә бик беткәнсең. Кайларда булдың? Син дә утыргансың, ахрысы?

Зариф. Миңа ун ел биргәннәр иде.

Зыятдин. Шул, минем белән җырлап утырганың өченме?

Зариф. Әйе. Бер елдан артыгын утырдым. Сугышка барырга теләүчеләрне фронтка җибәрәләр. Лагерьда череп ятканчы мин фашистларга каршы сугышырга телим. Әйдә, немескә каршы сугышка.

Анда хәйләсен табарсың. Сугышка барырга телим, Гитлерга каршы сугышасым килә, диген. Теләгән кешене фронтка җибәрәләр. Хәер, барысын да түгел. Зыятдин, ишетәсеңме мине? Сорап кара, сине җибәрүләре ихтимал сугышка. *(Йөзендә кинәт өмет нуры балкый.)*

Зыятдин. Мине, беренчедән, фронтка җибәрмәячәкләр. Юк нәрсәләр ягып, сорау алып башыма җитәрләр инде, ахрысы. Икенчедән, синең илең миңа дошман, мин сезнең якта сугыша алмыйм.

Зариф *(ачынып)*. Син һаман үз киреңне сукалыйсың.

Зыятдин *(көлемсерәп)*. Синең кебек кире инде. Татарда кирелек бар бит инде ул.

Зариф *(ялварып)*. Котылу чарасын уйларга кирәк, Зыятдин! Фронтка җибәрүләрен сора... Аннары хет кайсы якка чык. *(Тешләрен кысып үтенә.)* Хәйләләп кара инде, Зыятдин!

Зыятдин *(башын чайкап тыныч кына җавап бирә)*. Юк, Зариф! Юри генә булса да йолдызлы пилотканы беркайчан кимим мин!

Зариф. Бәхәсебезнең кирәк түгеллеге, мәгънәсезлеге, урынсызлыгы аңлашыла. Ярый...

Зыятдин. Сугышта саграк бул инде. Исән-сау әйләнеп кайт. Ләкин лагерьга әйләнеп кайтма. Атаң-анаң, Кәшифәң янына әйләнеп кайт.

Зариф *(күз яшьләрен тыя алмый)*. Тагын бер кат рәхмәт сиңа! Мин инде сине котылып өеңдә ятасыңдыр дип уйлаган идем. Мин ышанам, җибәрерләр сине. Әсирләрне үз илләренә бирергә тиешләр. Түз инде, чыда. Бирешмә.

Зыятдин. Син дә сугыштан исән-сау кайтып җит.

Зариф. Минем аркада интегәсең шикелле.

Зыятдин. Ә миңа син минем аркада җәфа чигәсең кебек. Штрафбатта булачаксыңмы?

Зариф. Әйе. Рәхмәт, Зыятдин, исән калуым өчен.

Зыятдин. Сине татар җыры коткарды. Татар җырын ишетмәгән булсам, аткан булыр идем. Татар җырына, татар теленә рәхмәт укы!

Конвой *(акыра)*. Эй, ну-ка отойди от заключенного.

Зыятдин. Бар, Зариф. Минем белән сөйләшкәнең өчен тагын берәр матавык килеп чыкмагае.

Зариф *(читкәрәк китеп)*. Сиңа күпме бирделәр соң?

Зыятдин. Белмим. Хуш!

Зариф. Хуш!

Зариф китә. Зыятдин таш кисәген күтәреп калкулыкка таба атлый. Авыр һәм көчле музыка.

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Кәшифә өйдә нәрсәдер бәйләп утыра. Җырлый.

Һаваларда очкан кошкайларның
Кунганнарын күрдем киртәгә;
Мәхәббәтем көчле, янган утлар төсле,
Сүнмәс, бәгърем, иртә дә, кичтә дә.

Һаваларда очкан кошкайларның
Күңелле икән шаулап үтүе;
Авыр икән, дуслар, сөйгән ярны озату,
Тагы да авыр сагынып көтүе.

Һаваларда очкан кошкайларым,
Әйтегезче сагынып көтүем,
Аны уйлый-уйлый, күзем йокы алмый,
Йокысыз төннәрем үтүен.

*(«Кошларга». Татар халык җыры)*

Җыр фонында Зариф сөйли.

Зариф: Штрафной батальоннар турында күп ишеткәнегез бардыр. Ләкин сөйләгәнне тыңлап кына ул мәхшәрне тулысынча күз алдына китерү мөмкин түгел. Сугышның иң канлы, иң коточкыч төбәкләренә ташладылар безне. Кайвакыт бер фашист дзотын алганда бер ротадан өч-дүрт кеше генә исән кала иде. Бөтенләй кеше йөрмәслек сазлыклардан штрафбатны үткәрәләр һәм батальонның дүрттән бер өлеше генә исән калып атакага күтәрелә иде. Мин алты немец танкын шартлаттым. Дүрт немецны кулга алып частька алып кайттым. Аның берсе полковник иде. Офицер иттеләр. Капитанга кадәр күтәрелдем. Батальон белән командалык иттем. Минем батальон тулы бер эсэс полкын юк итте. Белоруссиядә булды бу. Шунда мин каты яраландым. Полный кавалер орденов Славы идем инде

батальонны кабул иткәндә. Берлинга кадәр үк барып җитеп булмады. Шулай итеп, капитан званиесендә, мин, полный кавалер орденов Славы, туган ягыма кайтып киттем.

Кәшифә белән өйләнештек. Бәрәкәт урманында бәрәкәтле тормыш корырбыз дип хыялланып яши башладык.

Фронтта да, өйгә кайткач та миңа көн саен диярлек Зыятдинның язмышы тынгылык бирмәде. Кабат-кабат уйлыйм да, гел минем аркада харап булгандыр шикелле тоела.

### СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Зариф белән Кәшифә үз өйләрендә. Кәшифә йөкле. Өстәл тирәсендә кайнаша. Зариф тастымал белән битен, муенын сөрткәләп өстәл янына килә. Йөргәндә бераз аксый.

Кәшифә. Ашыйсың киләме?

Зариф. Кичкә бәрәңге пешерерсең.

Кәшифә *(иренең күңелен ничек булса да күтәрергә тели).* Ашаганнан соң аякларыңа теге суны сыларбыз.

Зариф *(кашларын җыерып)*. Сиңа кем әйтте соң ярдәме тия дип?

Кәшифә. Бөтен әбиләр шулай ди. Мин нәкъ алар әйткәнчә җыйдым үләннәрне дә, пешерүен дә нәкъ аларча эшләдем.

Зариф. Снаряд кыйпылчыклары кергән җирләр, бәлки, төзәлер дә...

Кәшифә. Хәзер менә сызламыйдыр бит?

Зариф. Юк. Төнлә кинәт сызлап куя. Аннары, һава торышы бозылгач.

Кәшифә *(елмаеп иренә карап тора)*. Бетерәбез ул сызлауларны, бетерәбез.

Зариф. Тән җәрәхәтләре, бәлки, төзәлер дә, менә җан газабын нинди үләннәр белән дәвалап була икән? *(Уйга чума.)*

Кәшифә *(авыр сулап)*. Син сугышта күргәннәрең белән бимазаланасың һаман... Тиз генә онытылмас инде ул. Менә балабыз тугач, уйларың башка юнәлеш алыр, караңгы хатирәләрең дә, бәлки, югалыр.

Зариф. Мин сиңа фин татары Зыятдин турында сөйләгән идем бит...

Кәшифә. Әйе.

Зариф. Мине аның язмышы нык борчый. Исән микән? Лагерьда үлде микән... Нишләттеләр икән?

Кәшифә. Син анысын белешә алмыйсың инде.

Зариф *(газапланып)*. Мин бит үзләренекеләр ягына чыгып киткәч, инде котылды дигән идем... Үземне барыбер атарлар дип синең рәсемең белән кульяулыгыңны да аңа биреп җибәргән идем. Менә мин исән, ә ул...

Кәшифә *(өметле тавыш белән)*. Ул да исәндер. Күпме кеше төрмәләрдән кире әйләнеп кайтты. Ә фин татарын гына нишләп үтерерләр икән.

Зариф. Ә күпме кеше кайтмады! Күпмесе юкка чыкты.

Кәшифә *(иренең каршысына килеп утыра)*. Зариф, тынычлан инде, зинһар. Син генә бернишләтә алмыйсың бит инде хәзер.

Зариф. Аңа бит гади әсир итеп карамадылар. Монда минем дә гаебем бар булып чыга...

Кәшифә *(өзгәләнеп).* Нинди гаебең булсын инде аның алдында. Син гел шулай үзеңнән-үзең гаеп эзләп, үзеңне-үзең ашыйсың.

Зариф *(кинәт җанланып)*. Ничек уйлыйсың, шул лагерьга хат язып белешсәм?..

Кәшифә *(пошаманга кала)*. Җүләрләндең мәллә?! Үзеңне дә шуның янына утыртып куячаклар. Тагын да ныграк шикләнә башлаячаклар.

Зариф. Акыллы хатын син. Аңлыйсың. Ләкин миңа бик авыр ул кешенең лагерьда калуын искә төшерү.

Кәшифә. Анысы шулайдыр да.

Зариф *(ныклы тавыш белән)*. Хат язып белешсәм була инде. Мин бит кавалер орденов Славы. Офицер. Батальон командиры. Мин бит Туган ил өчен, Сталин өчен кан койган кеше. Гаебем булган сурәттә дә, кан белән юдым бит мин гаебемне. Мин үземә атмаган, исән калдырган кешенең язмышы белән кызыксына алмыйммыни?!

Кәшифә *(еламсырап)*. Сиңа бит шул кеше аркасында инде ун ел биргәннәр иде. Штрафбатларда да шуның аркасында чередең.

Зариф. Кәшифә, алай димә. Аның аркасында, димә. Ул миңа гомер бүләк итте 1940 елның гыйнварында.

Кәшифә. Алладан курыккандыр. Шуңа атмагандыр.

Зариф. Әйе, бәлки шулайдыр. *(Бераз кызып.)* Ә менә үзебезнекеләр Алладан куркып тормадылар. Судсыз-нисез аттылар. Лагерьларда исә хайван урынына күрделәр.

Кәшифә. Ул сине татар булганың өчен үтермәгән. Татар икәнеңне белә торып та аткан булса, нәрсә була инде ул...

Зариф. Ничек аңлатырга икән сиңа... Һәрбер татар шулай икенче бер татарны коткарырга әзерме соң?

Кәшифә. Татарча җырлап утыручы кешегә үзең атар идеңме?

Зариф *(ачусыз гына)*. Кәшифә, бәгърем, акыллы дигәч, син бигрәк артыгын ук сөйли башладың.

Кәшифә. Ярар, ярар, артыгын сөйләмим. *(Чак кына ишетелерлек итеп.)* Мин сине озак көттем, Зариф. Инде сине тагын югалтудан куркам.

Зариф. Әгәр дә ул хәзер дә лагерьда икән, мин аны коткарырга тырышырга тиеш.

Кәшифә *(өзгәләнеп)*. Тагын шпионлыкта гаепләячәкләр бит үзеңне. *(Пышылдап.)* Минем йөкле икәнемне онытма. Без инде хәзер өчәү, Зариф.

Зариф *(күңеленә шундук шатлык керә)*. Авырлы хатынга җырларга ярый микән?

Кәшифә *(көлә)*. Нишләп ярамасын?!

Зариф *(ягымлы тавыш белән)*. Җырла әле, зинһар, Кәшифә, җырла, җанкисәгем!

Кәшифә. Хәзер. *(Зариф каршысына утырып әкрен генә җырлый.)*

Күбрәк сана, кәккүк, күбрәк сана,
Санга сугып санар саннарны,
Гомер дисбесенең төймәләрен —
Икәү бергә узар елларны.

Күп санама, кәккүк, күп санама
Башка төшәр хәсрәт саннарын;
Өметләрем әгәр бер өзелсә,
Сине бүтән тыңлый алмамын.

Саный кәккүк үзе белгән көйгә
Айлы төнне, алсу таңнарны;
Ә йөрәкләр үз көенә тибә,
Санламыйча сансыз саннарны.

*(«Саннар»)*

Зариф *(хатынын кочаклап алдына утырта).* Рәхмәт! Әй Кәшифә, ярый син бар әле.

Кәшифә *(сикереп тора).* Аякларың болай да авыртып тора. Ә син алдыңа утыртасың һаман.

Зариф *(кулын селти)*. Аннан гына авыртырлык булса, аяк буламыни ул.

Кәшифә *(иренең кәефе күтәрелгәнгә чиксез шатланып)*. Ул Зыятдин инде күптән Хельсинкида яшәп ятадыр.

Зариф *(кинәт җитдиләнә)*. Мин аны табарга тиеш.

Кәшифә *(котсыз калып)*. Үз акылыңдамы соң син?! Тагын үзеңә бәйләнә башлаячаклар!

Зариф *(усал тавыш белән)*. Хәзер миңа бәйләнсәләр дә, бәйләнмәсәләр дә инде мин үземнең кем икәнемне исбатладым. Минем кем икәнемне бергә сугышкан иптәшләрем белә, батальоным белә, югары командование белә, хәтта Мәскәүдә дә беләләр!

Музыка. Сәхнә караңгылана. Сәхнә яктыра. Зариф атылып килеп керә. Бераз аксый.

Зариф *(бусагадан ук кычкыра)*. Кәшифә! Сугыш беткән!

Кәшифә *(аралыктан килеп чыга).* Уф, котымны алдың!

Зариф *(шатлыктан ярылырдай булып кычкыра).* Сугыш бетте!

Кәшифә. И Ходаем. Чын микән?!

Зариф. Радиодан үзем ишеттем. Җиңдек, җиңдек, җиңдек! *(Кочаклашалар.)*

Кәшифә *(нишләргә белми).* Матуррак күлмәк киим микән әллә?! *(Ары-бире сугыла.)*

Зариф. Ки. Ни кисәң дә, гүзәл син. Сылу кешегә солы капчыгы да килешә, ди. *(Көләләр.)*

Кәшифә нишләргә белми. Кабалана-кабалана йөри. Икенче бүлмәгә чыгып китә. Зариф үзенең хәрби киемен кия. Орден-медальләре ялтырый. Көзге каршына килә. Кәшифә икенче бүлмәдән матур күлмәк киеп йөгереп чыга.

Кәшифә *(иренә мәхәббәтле күз карашы белән карап)*. О-о-о! Менә бу егет, ичмаса!

Зариф *(тел шартлатып)*. Шулай булырмын мин. *(Кәшифәгә сокланып карап тора.)* Синме бу?! Мондый чибәр кыз минем хатыным була ала микәнни?!

Кәшифә *(оялган булып)*. Әй, кыланма әле! *(Ире каршына килеп баса. Кыланып честь биргән була.)* Иптәш капитан Күке Зариф! Әйдә, Субайга барып кайтабыз!

Зариф *(хатынын кочып ала һәм җитди тавыш белән әйтә)*. Бәгърем, мин ерак сәфәргә чыгарга булдым.

Кәшифә *(иренең кочагыннан шуып чыга)*. Нинди сәфәргә, ник һаман кыланасың инде! *(Пауза.)* Әйдә, берәр җиргә барып кайтыйк әле. Карале, көн ничек матур бүген?!

Зариф *(катгый карарга килеп)*. Кәшифә, җаным! Мин теге лагерьга барып кайтырга тиешмен.

Кәшифә *(сискәнеп)*. Нинди лагерьга?

Зариф. Зыятдин утырган лагерьга.

Кәшифә *(ачыргаланып)*. Үз акылыңдамы син?!

Зариф *(хатынын юатырга тырышып ягымлы тавыш белән)*. Мин тиз арада әйләнеп кайтачакмын. Минем бурычым ул анда бару, аның язмышы белән кызыксыну. Югыйсә мин мәңге җан тынычлыгына ирешмәячәкмен.

Кәшифә *(елый)*. Күңелем сизә, бәлагә тарыячаксың. Нинди тынгысыз кеше булдың соң син?!

Зариф. Елама, Кәшифә!

Кәшифә *(ыңгырашып)*. Харап буласың бит.

Зариф *(көр тавыш белән)*. Мин — офицер! Зыятдинның язмышы белән кызыксынмасам, мин офицер гына түгел, кеше дә булалмыйм!

Кәшифә елый. Музыка.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәхнәдә караңгылык. Сәхнә яктыртганда подполковник званиесендәге бер кеше тәрәзәдән тышка карап тора. Хәрби киемнән Зариф килеп керә.

Зариф. Разрешите. *(Подполковник борылмый.)* Вы начальник лагеря?

Подполковник *(теләр-теләмәс кенә борылып баса)*. Да.

Зариф. Здравия... желаю... *(Зариф шакката — аның каршында Зимин басып тора.)* Вы...

Зимин *(коры гына)*. Я начальник лагеря. А вы кто будете?

Зариф. Я капитан Зайнуллин. Полный кавалер орденов Славы.

Зимин *(бер дә гаҗәпсенмичә)*. Вижу, вижу.

Зариф. Вы должны меня помнить.

Зимин *(авыз кырые белән генә елмая)*. Как же не помнить-то. *(Шундук татарчага күчә.)* Хәтерлим мин сине. Тик син ул вакытта герой түгел идең, ә киресенчә... Утыр. *(Өстәле янына барып утыра.)*

Зариф *(аның каршына килеп утыра)*. Сез лагерь начальнигы икән...

Зимин. Партия кая куша — шунда барабыз инде хезмәткә. *(Зарифны җентекләп күзәтә.)* Кайда тәмамладың сугышны?

Зариф. Белоруссиядә. Берлинга ук барып җитеп булмады. Каты яраландым.

Зимин. Берлинга барып җитмәсәң дә, көчеңнән килгәнне эшләгәнсең — герой булып кайткансың. Молодец, молодец. Штрафниклардан сирәк кешене болай зурлап данлыйлар. Офицер булгансың. Монда килгәч, мин синең хакта кызыксындым. Фронтта, диделәр.

Зариф *(үз күзләренә һаман ышанып җитми)*. Мин сине монда очратырмын дип уйламаган идем.

Зимин. Мин дә сине кабат бу лагерьда күрермен дип уйламаган идем. *(Серле һәм шомлы итеп елмая.)* Сагындырдымы әллә?

Зариф *(кыяфәтенә салкынлык йөгерә)*. Синең юморны кабул италмыйм мин.

Зимин *(папирос кабызып тарта)*. Әйе, мондый сугышлардан соң нинди юмор хисе калсын кешедә.

Зариф *(саклык белән генә сорап куя)*. Фин снайперын хәтерлисеңме?

Зимин *(кашларын җыерып)*. Нинди снайперны?

Зариф. Финляндия татары...

Зимин *(бераз уйланып утырганнан соң)*. Ә-ә-ә, нишләп хәтерләмәскә. «Күке»! *(Көлемсерәп.)* Карале, синең дә кушаматың Күке иде түгелме? *(Зарифның түшендәге орденнарга карап.)* Мондый геройга хәзер инде алай дәшмәсләр.

Зариф *(гасабиланып)*. Мин төкерәм ничек дәшүләренә! Ул кешене мин фронтка китәр алдыннан шушы лагерьда күрдем.

Зимин. Ничек монда булсын ул?! Кырыгынчы елны үзләренең ягына качкан «күке» син кырык беренчедә сугышка киткәндә ничек монда булырга мөмкин?!

Зариф *(кызып)*. Мин бит аны күреп сөйләштем. Алар таш ташуда иде.

Зимин *(папиросын сүндереп көл савытына ташлый)*. Белмим, белмим. Ничек монда килеп эләккәндер ул. Хәер, монда күпмедер хәрби әсирләр булган. Ну, аларны илләренә озатканнар. Тә-ә-әк, син аны монда кырык беренче елны күргәнсең... *(Уйга кала.)*

Зариф. Кырык беренче елны. Үз күзләрем белән күрдем.

Зимин. Мин бит кырык икенче елның көзендә генә килдем монда эшкә. Папкаларны күтәрербез. Эзләве авыр булыр, чөнки монда күпме кеше утырган бит, малай, һәм дә ки хәзер күпме утыра — коточкыч. Арада хәтта теркәлмәгәннәре дә бар.

Зариф. Зыятдинны теркәми калмаганнардыр.

Зимин. Кемне дисең?

Зариф. Зыятдинны.

Зимин. Ә-ә-ә, бу теге «күке»нең исеме, шулай бит?

Зариф. «Телсез күке». Атмады ул.

Зимин *(уйланып)*. Әйе, сиңа атмаган ул.

Зариф *(таләпчән тавыш белән)*. Мин Зыятдинның язмышы белән кызыксынып килдем!

Зимин *(Зарифка ачуы килгәнне күрсәтмәскә тырышып)*. Аларны партияләп-партияләп туган илләренә озаттылар. *(Елмаеп.)* Ул да инде үзенең Финляндиясендә безне сүгеп, кыҗрап ятадыр.

Зариф. Ул бик ябык, хәлсез иде. Үлмәде микән?

Зимин *(сабыр гына)*. Белешермен, белешермен. *(Кинәт күзләрендә явызлык очкынлап ала.)* Ә аның язмышы белән кызыксынырга курыкмыйсыңмы?

Зариф *(Зиминга текәлеп карый)*. Аңламадым?

Зимин. Син хәзер фашистны җиңеп кайткан боевой офицер, полный кавалер орденов Славы.

Зариф. Әйе, шулай...

Зимин. Гаиләң бармы?

Зариф. Бар.

Зимин. Гаиләң белән тыныч кына, уңга-сулга карамыйча, тегендә-монда тыгылмыйча яшәп ят. Нишләп үзеңә маҗаралар эзләп йөрисең?

Зариф. Мин, Зыятдинның язмышын ачыкламыйча, тыныч яшәп ята алмыйм.

Зимин. Син үзгәрмәгәнсең икән.

Зариф. Әйе, мин шул ук! Кешеләр барысы да син теләгәнчә бертөрле булмаячак беркайчан да!

Зимин *(кисәтүле тавыш белән)*. Син тагын баткаклыкка таба кереп барасың түгелме?

Зариф *(каты ачу белән)*. Нинди баткаклыкка?! Мин аңлыйм нәрсә әйтергә теләгәнеңне!

Зимин *(күзләрен кыса төшеп)*. Аңласаң, бик яхшы.

Зариф *(тавышына ялвару төсе кертеп)*. Мин үтенәм, әйт миңа, исәнме ул? Исән булса, ул кайда хәзер?

Зимин *(салкын тавыш белән)*. Мин белешермен. Тик син үзеңнең язмышыңны катлауландырырга маташасың, ахрысы.

Зариф *(ачыргаланып)*. Тагын ничек катлауландыру мөмкин соң безнең язмышларны, иптәш подполковник! Мин катлаулы язмышларны үзем белән янәшә сугышкан штрафниклардан ишетеп чак кына акылдан язмадым! Төрмәләрдән чыгып утка кергән егетләрнең яртысыннан күбесе бер гаепсез кешеләр иде!

Зимин. Ә син каян беләсең, гаеплеме-юкмы?! Үзләре сөйләгәннән генәме?

Зариф *(кызып-кызып сөйли)*. Анда кем ялган, кем дөресен сөйли — шундук күренә. Үлем белән көн саен күзгә күз карашучы унсигез яшьлек егет, беләсеңме, ни өчен төрмәгә утырган булган? Аның атасын донос буенча атканнар. Имеш, Сталинны ачуланып нәрсәдер әйткән. Ә шул егетнең үзен, шикаять язучының битенә төкергәне өчен, биш елга утырталар. Сугыш башлангач бу егет фронтка җибәрүләрен үтенеп сорый. Минем батальонда сугышты. Авианалеттан соң мин бу егетне носилкада күрдем. Чәрдәкләнеп беткән һәм канга баткан иде. Актык сулышын алганда мин аның янында тордым. Күз яшьләремне тыя алмадым — шунда, солдатларым янында елап җибәрдем. «Берәр үтенечең, теләгең юкмы миңа?» — дип сорадым мин аңардан. Беләсеңме, ничек дип җавап бирде?

Зимин. Ничек дип?

Зариф. «Иптәш капитан, минем атам да, үзем дә халык дошманы түгел»,— дип ыңгыраšты.

Зимин *(үгет-нәсихәтле тавыш белән)*. Минем сиңа бер киңәшем бар: артык ихласланма. Күңелеңдәген ачып, әйтергә кирәкмәгәнне әйтеп ташлый торган гадәттән арынырга вакыт инде сиңа.

Зариф. Әйе, син минем гадәтләрне беләсең... Юкса кырыгынчы елны ун елга хөкем итмәсләр иде...

Зимин *(кинәт кырысланып)*. Мин хөкем итмәдем сине. Трибунал хөкем итте.

Зариф. Материалны әзерләүче син булдың бит.

Зимин. Әйе, мин. Ә нәрсә? Син мине шуның өчен битәрләргә дип килдеңме?

Зариф. Юк.

Зимин *(җикереп)*. Рәхмәт әйт партиягә, иптәш Сталинга — ун ел урынына сиңа ышанып кулыңа корал тоттырганы өчен һәм үзеңнең Ватан алдындагы гаебеңне кан белән юарга мөмкинлек биргәннәре өчен!

Зариф *(теш арасыннан ысылдап)*. Син усалланма! Кемгә нинди рәхмәт әйтү — минем шәхси эшем!

Зимин. Ә син шулай да үз урыныңны бел.

Зариф. Мин аны бик яхшы беләм.

Зимин *(һаман тынычлана алмый)*. Синең кебек геройлар бик күп кайтты фронттан! Барысы да синең кебек амбицияләр белән йөри башласа, тәртип булмаячак.

Зариф *(мыскыллап)*. Тәртип урнаштырыр өчен сез бар бит.

Зимин. Чәнчеп сөйләшмә! Әйе, без бар. Һәм пока без бар, тәртип булачак. Беребезнең дә язмышы җиңел түгел. Беребез дә үз ихтыяры белән яшәми. Без һәммәбез хезмәтчеләр, безнең һәрберебезнең үз урыны, үз вазифасы, үз миссиясе бар. *(Тагын папирос кабызып тарта.)*

Зариф *(тыныч булырга тырыша)*. Шулай. Мин үтенеч белән килдем. Зинһар, ярдәм ит Зыятдин турында белешергә.

Зимин. Ник кирәк ул сиңа?

Зариф. Мин бурычлы ул кеше алдында.

Зимин. Нинди бурычың калды?

Зариф. Ул миңа атмады. Мин хәзер исән булмас идем, әгәр ул аткан булса.

Зимин. Шуннан?

Зариф. Соң, әйтәм бит: үземне аның алдында бурычлы итеп тоям.

Зимин *(авызын кыйшайтып елмая)*. Син тагын ачыктан-ачык сөйлисең. Бик яхшы. Сөйлә. Фин әсирен эзләп йөрүче кеше турында ни уйларга тиеш мин? Ә?! Контрразведка нәрсә уйларга тиеш? *(Зарифка таба сузылып пышылдый.)* Мин сиңа киңәш итәм: бар, кайтып кит, йөрмә монда.

Зариф *(кырт кисеп)*. Юк! Син беләсең ул кеше турында!

Зимин. «Күке» турындамы?

Зариф. «Телсез күке».

Зимин. Әйе, беләм. *(Тавышын күтәрә.)* Беләм! *(Чак кына ишетелерлек итеп.)* Белгән сурәттә дә мин бит сер итеп сакларга тиеш теге яки бу әсир турындагы мәгълүматларны.

Зариф *(тавышын әкренәйтеп)*. Исәнме ул?

Зимин. Исән.

Зариф. Кайда ул?

Зимин *(папиросын тирән итеп суыра)*. 1944 елны Финляндиягә унсигез әсирне кайтарып җибәрделәр. Шулар арасында ул да бар иде. Нишлисең бит, дүрт ел утырды инде утыруын лагерьда... Әгәр дә ул теге вакытта безнең серле снарядлар яшерелгән база тирәсенә килеп чыкмаган булса, аны утыртмыйлар иде. Аны бит шул тикшерү өчен дүрт ел тоттылар.

Зариф *(Зиминга озак карап тора)*. Минем турында да бик озак иснәнеп йөргәннәр туган ягымда. Хәтта лесхозга эшкә килгән булып, безнең нәсел турында төпченеп ятканнар. Сезнең чекистлар эше бит инде бу.

Зимин. Кем әйтте?

Зариф. Якташларым лесхозга читтән килеп яшәүчеләр турында сөйләделәр. Кайдан һәм кемнәр икәнен үзем сизендем, аңладым.

Зимин *(елмаеп)*. Сизгер үзең тагы...

Зариф. Хәтта фронтта да минем сөйләшүләрне гел особистка җиткереп торалар иде.

Зимин *(үтә дә эшлекле кыяфәт белән)*. Сугыш вакытында башкача булалмый инде ул. *(Папиросын сүндереп урыныннан кузгала.)* Аның каравы син исән! Шаталовны хәтерлисеңме?

Зариф. Әйе.

Зимин. Одессаны фашистлардан саклаганда һәлак була. Севрюгин Воронеждан иде бит. Ул немец оккупациясендә кала. Германиягә куалар. Шуннан хәбәре юк. Пропал без вести.

Зариф. Ә Рассуханов?

Зимин *(әйтергәме-юкмы дип уйлап тора)*. Чеченнарның эшләре катлаулырак килеп чыкты шул...

Зариф *(борчулы тавыш белән)*. Ул да высылкага эләкте микәнни?

Зимин. Кырык дүртенче елда аларның барысын да сөрделәр... Күпмесендер Казахстанга, күпмесендер ераграк.

Зариф *(уйга чума)*. Ай-яй.

Зимин *(килеп Зарифның иңенә кулын куя)*. Ихлас күңелдән әйтәм: сине исән-сау булуга мин шат. Күрүемә дә шат.

Зариф *(утырган урыныннан тора)*. Димәк, Зыятдинны кырык дүртенче елны кайтарып җибәрделәр.

Зимин. Әйе.

Зариф. Ярый... *(Кәефе күтәрелә.)* Нинди яхшы хәбәр!

Зимин. Күңелең булдымы? *(Елмаеп.)* Ярый, дустым, исән-сау бул. Бөтен дөнья өчен уйланып, кайгырып утыру дөрес түгел.

Зариф. Димәк, Зыятдинны Финляндиягә озаттылар?

Зимин *(көлә)*. Әйе, тынычлан. Бар, кайт. Йөрмә үзеңне-үзең бимазалап.

Зариф. Ярый, киттем. *(Ишеккә таба юнәлә.)*

Зимин. Сау бул!

Зариф. Киттем. *(Чыгып китә.)*

Шомлы музыка. Сәхнә караңгылана. Зимин телефоннан шылтырата.

Зимин. Приведите! *(Бүлмә буйлап ары-бире йөри.)*

Зыятдинны алып керәләр. Ул бөтенләй хәлсез, ябык һәм бөтен кыяфәтеннән битарафлык аңкый.

Зимин. Утырыгыз! *(Зыятдин килеп утыра. Күзләре төссез — Зиминга карый, ләкин аны күрми шикелле, әйтерсең лә аның аша каядыр бушлыкка карый.)* Сез кем?

Зыятдин *(каядыр төпсез бушлыкка караган сыман)*. Галиәкбәр улы Зыятдин.

Зимин *(җан биздергеч тонык тавыш белән бер-бер артлы сорау бирә)*. Тагын?

Зыятдин. Әсир.

Зимин. Тагын?

Зыятдин. Мин — Финляндия татары.

Зимин. Тагын?

Зыятдин. Мин совет-фин сугышында әсир төштем.

Зимин. Анысын әйттең. Тагын?

Зыятдин. Шуның белән тәмам.

Зимин *(барып урынына утыра)*. Юк, тәмам түгел. Әйт дөресен, 1940 елда теге безнең база турында кем әйтте сиңа?

Зыятдин. Беркем дә әйтмәде.

Зимин. Ә каян белдең?

Зыятдин. Белмәдем.

Зимин. Нәрсә иде ул базада?

Зыятдин. Белмим. *(Тәмам хәлсезләнә. Зиминга карап тора. Һәрбер сүзен бик авырлык белән генә әйтә.)* Сез акылга зәгыйфь түгелдер бит? Ул базада нәрсә барлыгын миннән сорыйсыз. Каян белим мин? Сезнең база бит ул.

Зимин *(тешләрен шыгырдатып)*. Тәмам туйдым мин синнән.

Зыятдин *(әкрен генә)*. Атып үтерегез мине.

Зимин *(ямьсез итеп елмая)*. Юк, суд сине атарга хөкем итмәде. Мин синнән барыбер барысын да сөйләтәчәкмен.

Зыятдин *(ишетелер-ишетелмәс кенә)*. Нәрсә сөйләтмәкче буласың?

Зимин. Зариф белән беренче тапкыр кайчан таныштыгыз?

Зыятдин. Мин сезгә инде мең тапкыр әйттем. 1940 елның гыйнварында. Урманда. Сезнең базагыздан ерак түгел.

Зимин *(урыныннан торып Зыятдин янына килә)*. Аның белән элемтәгә кайсы разведоешма аркылы кердегез?

Зыятдин. Нинди разведка?! Ул да, мин дә бернинди разведка кешеләре түгел.

Зимин *(кабинет буйлап йөри)*. Безнең агентлар Зариф торган якларны нык айкадылар. «Күке» кушаматын аңа тагулары бик сәер — ул сөйләгәнчә үк килеп чыкмый.

Зыятдин. Кушаматның ни катнашы бар монда?

Зимин. Ул сине «күке» диде. Ләкин «Телсез күке» диде. Бу нәрсәне аңлата? *(Зыятдин янына килеп текәлеп карап тора.)*

Зыятдин. Атмаганым өчен әйткәндер.

Зимин *(үчекләп)*. «...Дер»!.. *(Күзләрен чекерәйтеп.)* Ничек уйлыйсың, хәзер кайда ул?

Зыятдин *(күзләрен йома)*. Кем?

Зимин. Зариф.

Зыятдин *(көч-хәл белән сөйләшә)*. Ул сугышка киткән иде.

Зимин. Мәгълүм ки, сугыш бетте... *(Барып графиннан су эчә.)*

Зыятдин. Исән булса, кайткандыр инде.

Зимин *(авызын кыйшайтып елмая)*. Исән ул.

Зыятдин *(бераз хәл кергәндәй була)*. Исәнме?

Зимин. Исән. Тик менә нишләп синең язмыш белән кызыксынмый икән ул?

Зыятдин *(иреннәрен көчкә кыймылдатып)*. Ул бит нинди илдә яшәгәнен белә. Артыннан гел күзәтеп торуларын да сизенә... Аннары, нишләп әле ул минем язмыш турында кайгыртып йөрергә тиеш?! Фронт узган кеше... Ял итсен өендә.

Зимин *(мыскыллы елмаеп)*. Срогың беткәч иреккә чыгармын дип уйлыйсың инде син... Миңа дөресен сөйләмичә беркая да чыкмыйсың!

Зыятдин *(битараф тавыш белән)*. Сөйлисен сөйләдем инде мин. *(Зарифның исән икәнлеген ишеткәч үзендә әле күпмедер көч барлыгын тоя.)*

Зимин. Ярый. Син миңа шунысын гына әйт: Абверның катнашы юкмы монда?

Зыятдин *(чыраен сытып)*. Нинди Абвер инде тагын?! Нишләп сез буш урында казынасыз?!

Зимин *(яман усал тавыш белән)*. Ник атмадың Зарифка?

Зыятдин. Татар җырын ишеттем.

Зимин. Шуның өчен генә атмый калдыңмы?

Зыятдин. Нишләп син татарча җырлавын ишеткәнгә атмадым дигәч ышанмыйсың?!

Зимин *(кыҗрап)*. Чөнки шуның өчен генә дошманны үтерми калу мөмкин түгел!

Зыятдин. Нишләп ул миңа дошман булсын!

Зимин *(кабинеты буйлап арлы-бирле йөри)*. Тәк. Без тагын круг буйлап киттек. *(Килеп Зыятдинның күзенә карый.)* Нишләп ул сиңа дошман түгел?

Зыятдин *(Зиминга туп-туры карап)*. Татарча җырлаганга.

Зимин. Мин бердәнбер сәбәп шулдыр дип ышанмыйм һәм ышанмаячакмын. Хәзер менә атып үтерер идеңме Зарифны?

Зыятдин. Юк.

Зимин. Мине атып үтерер идеңме?

Зыятдин. Әйе.

Зимин. Әлбәттә инде...

Зыятдин *(ыңгырашып)*. Минем хәлем бик начар.

Зимин. Әсир төшкән дошманның хәле яхшы булмый инде аның. Әйт әле миңа: ни өчен бер таныш түгел кеше кинәт якын була башларга мөмкин? Минем аңлыйсым килә! Әйт дөресен, сугышка кадәр таныш идегезме?

Зыятдин. Юк.

Зимин. Безнекеләр арасында әллә тагын берәр сезнең кеше бар идеме? Шуның аша таныштыгызмы?

Зыятдин *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Юк.

Зимин *(сорауларны якын килеп бирә башлый)*. Ул сиңа базада нәрсә барлыгын әйткән бит.

Зыятдин. Юк, әйтмәде.

Зимин. Ә ул миңа әйтте: Зыятдинга сөйләдем, диде.

Зыятдин. Ул алай алдашмас.

Зимин. Ә нишләп син аңа шулкадәре нык ышанасың? Һәрвакыт: ул андый түгел, дисең, ул алдашмас, дисең...

Зыятдин. Чөнки ул — чын ир-егет! Иманлы кешене имансызландыру мөмкин түгел. Иман ул йә бар, йә юк. Ул — иманлы инсан.

Зимин. Алай икән.

Зыятдин *(ишетелер-ишетелмәс тавыш белән)*. Бер соравым бар.

Зимин. Тыңлыйм.

Зыятдин. Әгәр дә мин аны атып үтергән булсам һәм сез мине кулга алган булсагыз, минем хәлем җиңелрәк булыр идеме?

Зимин. Әлбәттә. Син хәрби әсир генә булып саналыр идең.

Зыятдин. Ә аны үтереп сезгә эләкми калган булсам?

Зимин *(көлә)*. Иң бәхетле кеше булыр идең.

Зыятдин. Ялгышасың. Менә бу вариантларны тирәнтен уйлап карагач, миңа үземнең хаклы икәнем аңлашыла.

Зимин *(җирәнеп карый)*. Лагерьда черү — хаклык билгесеме?

Зыятдин *(шулай ук җирәнеп карый)*. Минем лагерьда черүем — сезнең кабахәтлек билгесе!

Зимин *(өстәле янына барып утыра)*. Сиңа хәзер ике дөнья — бер морҗа дип әймәкче буласың мәллә бу дорфалыгың белән? Ышанмыйм. Әле синдә азатлык хыялы яши. Син әле Финляндиягә кайтып хатыныңны, улыңны кочакларммын дигән өмет белән җан асрыйсың.

Зыятдин сулкылдап еларга тотына. Озак елый. Зимин тыныч кына карап утыра. Кинәт сикереп тора да, Зыятдинга урындык китереп бирә.

Утыр.

Зыятдин утыра. Сулкылдаудан бөтен гәүдәсе дер селкенә. Зимин графиннан стаканга су салып Зыятдинга бирә.

Эч.

Зыятдин тончыга-тончыга суны эчеп бетерә. Зимин стаканны алып китә. Зыятдин елаудан туктагач, Зимин үз урынына барып утыра.

Ә Зарифның исән булуына син шатмы?

Зыятдин. Шат.

Зимин. Ярар, мин сиңа бер сер ачам. *(Зыятдин нинди сер икән дип көтеп карап утыра.)* Зариф бик зур хата җибәрде.

Зыятдин *(сагаеп)*. Нинди хата?

Зимин. Ул монда килде.

Зыятдин *(аптырап)*. Ник?

Зимин *(көлемсери)*. Синең язмыш белән кызыксынып. Орденнарын чылтыратып, погоннарын ялтыратып...

Зыятдин. Нишләп йөри инде ул?!

Зимин. Менә шул шул! *(Күзләрен чекерәйтеп сынаулы караш белән карап тора.)* Нык кызыксынды ул синең язмыш белән.

Зыятдин *(башын читкә борып)*. Җүләр икән!

Зимин *(бармагы белән Зыятдин ягына төртә-төртә)*. Вот-вот! Җүләр! *(Тавышын әкренәйтеп.)* Ә ник җүләр дисең аны? Әйе, әйе, синең тел очыңда гына тора... *(Нәфрәт катыш сөенечле елмаю белән.)* 1940 елның гыйнварында Карел урманнарында безнең базадан ерак түгел дошман разведчигы белән очрашуы турындагы делоны күтәрергә туры киләчәк.

Зыятдин *(котсыз кала)*. Сез үз акылыгыздамы, юкмы? Юк нәрсәгә вакыт әрәм итәсез.

Зимин *(кискен хәрәкәтләр белән өстәл тартмаларын ачып-ачып карый)*. Юк, юк, тикшерүләрне яңадан башлыйбыз.

Зыятдин *(күзләрен йома)*. Зариф кайда соң хәзер?

Зимин *(битараф тавыш белән)*. Кайтып киткәндер.

Зыятдин *(хәлсез тавыш белән)*. Минем турыда нәрсә дидең соң син?

Зимин. 1944 елны унсигез әсирне Финляндиягә кайтарып җибәрдек, дидем. Шулар арасында Зыятдин да бар иде, дидем.

Зыятдин *(көч-хәл белән ялвара)*. Аптыратмагыз Зарифны. Бер гаепсез кеше бит ул.

Зимин. Әле яшиселәр бар, алда гомер шактый — ачыкларбыз кемнең күпме дәрәҗәдә гаепле икәнлеген. *(Зыятдин аңын югалтып идәнгә егыла. Зимин өстәлендәге звонокка баса. Конвоирлар керә.)* Аңын җуйды. Алып китегез! *(Зыятдинны кул-аякларыннан күтәреп алып чыгып китәләр.)*

Зимин графиннан су салып эчә. Үзенә урын табалмый йөренә. Көтмәгәндә Зариф атылып керә.

Зариф *(көчкә сулыш алып)*. Ышанмыйм мин сиңа! Кайда ул?

Зимин *(кыҗрап Зарифка таба килә)*. Мин синнән туя башладым!

Зариф *(кычкырып)*. Ул әле һаман шушы лагерьда.

Зимин (*кычкыра*). Кем?

Зариф. Зыятдин!

Зимин *(мыскыл итеп елмая)*. Бәлки. Монда кем генә юк. *(Зарифка якын килеп карап тора.)*

Зариф *(Зиминга җирәнеп карый)*. Мин Мәскәүгә барам!

Зимин (*көлә*). Бар! Анда көтәләр сине! *(Йөзе кинәт караңгылана, күзләре коточкычлана.)* 1940 елгы эшнең кузгатылуын телисең инде син.

Зариф *(кычкырып)*. Кузгалсын! Әллә нәрсәләр кузгалсын! Мин соңгы тапкыр таләп итәм, күрсәт миңа ул кешене!

Зимин *(Зарифның гасабилануын инкарь итеп елмая)*. Ә синең таләпләр куярга хакың юк.

Зариф *(тешләрен кысып)*. Табыйк ул кешене!

Зимин *(мыскыллы елмаеп)*. Лагерь бик зур. Аны эзләтергә кешеләрем юк, үзем эзләп йөри алмыйм. *(Кабинеты буйлап атлый.)*

Зариф. Аңламадым?

Зимин *(төкерекләрен чәчеп акыра)*. Мин ул «күке»не эзләп йөрергә синең атаң Хәбибрахман түгел бит!

Зариф *(ярсып)*. Син — кабахәт! Син тылда үз кешеләребезнең канын эчүче җанвар! Сез фронтта да каныбызны күп эчтегез! Немецтан да күбрәк харап иттегез сез безнең иң асыл кешеләребезне!

Зимин *(бөтен эчке зәһәрлеген, вәхшилеген чагылдырып әйтә)*. Ну, хана тебе, герой! *(Кыҗрап килә дә тешләрен шыгырдатып кабатлый.)* Хана тебе! Хана! Понял?! Хана!

Зариф *(барлык булган нәфрәтен чыгарып)*. Бук!!! *(Зиминның битенә төкерә.)*

Зимин *(беркавым һушсызланып торганнан соң кобурасыннан пистолетын чыгара.)* Атам, сука!

Зариф. Минем дә пистолетым бар! Минеке именной! Командующий үзе бүләк иткән пистолет. *(Пистолетын чыгара.)*

Зиминның ярдәмчеләре атылып килеп керә. Алар, Зарифның өстенә ташланып, аның кулларын артка каералар һәм пистолетын тартып алалар.

Зимин *(килеп Зарифка карап тора)*. Совет власте дошманнарын, халык дошманнарын мин гомерем буе таптадым һәм таптаячакмын! *(Зарифның погоннарын йолкып ташлый. Шуннан соң барып өстәле янына утыра. Телефоннан шылтырата.)* Задержан агент западной разведки. У меня в кабинете. Хорошо. *(Зарифны җибәрәләр. Ул хәлсезләнеп көчкә аягында басып тора.)*

Зариф. Менә ничек... *(Үзенең түшендәге орденнарын йолкып идәнгә ташлый.)* Мин шушындый хәшәрәтләр өчен, лагерь күселәре өчен сугышып йөргәнмен икән! *(Зарифны алып китәләр.)*

Музыка. Зариф сөйли.

Зариф:

— Көнбатыш разведкасының агенты дип исбатлый алмасалар, да миңа биш ел бирделәр. Миннән барыбер шикләнделәр. Магаданга этап белән китеп бардым.

Бер тапкыр лагерьларны тикшерергә дип Мәскәүдән югары дәрәҗәдәге инспекция килде. Инспекция составында безнең армиянең политотдел начальнигы да бар иде. Фронтта ул мине яхшы белә һәм ихтирам итә иде. Мине күреп шаккатты. За что герой сидит дип бик борчылды. Мәскәүгә кайткач, минем өчен ходатайство язган. Мине, рәхмәт яусын аңа, ике елга алданрак, ягъни өч ел утыргач чыгардылар. Мин ут йотып яшәп ятучы Кәшифәм янына кайтып киттем. Мин кайтканда улыма ике яшь ярым иде инде.

**УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Бәрәкәт урманы. Зариф йорты. Зариф, Назимә, Хәбиб өстәл янында утыралар. Чәйләре суынып беткән.

Зариф. Кәшифә мин кайткач бер утырып елады да: «Бүтән беркая җибәрмим үзеңне!» — дип кычкырды. Бу аның гомер буена бердәнбер кычкыруы булды.

Назимә. Син үзең әбиемә бер дә тавыш күтәрмәгәнсең.

Зариф. Каян беләсең?

Назимә. Әти әйтте.

Зариф. Минем өчен бөтенләй бер могҗиза — улым булды. Яшәргә дәрт һәм дәрманны Кәшифә, ата-анам бирсә, вәхши дөнья өстеннән очып яшәргә исә минем улым Мансур ярдәм итте.

Хәбиб. Назимәнең әтисе була инде ул?

Назимә. Әйе, минем әтием.

Зариф. Улым белән бөтенләй башкача ачылып китте дөньялары. Кызганыч, якын кешеләрем иртә вафат булдылар. Әти җитмеш ике яшендә, әнкәй җитмеш дүрттә. Кәшифә җаным алтмышын да тутырмыйча дөнья куйды. Йөрәк белән интекте. *(Тынлык.)* Мин гаепле! Мин, мин! Минем өчен саргайды ул, бичара. Назимәгә өч яшь иде әбисе үлгәндә.

Хәбиб. Көн саен каберенә барасыз икән.

Зариф. Көн саен барам.

Назимә. Бабай, мин Санкт-Петербургка... Ленинградка барып кайттым.

Зариф *(гаҗәпләнеп)*. Кай арада җитештең?

Назимә. Җитештем инде. Хәтта андагы татарларның сабантуен да күреп кайттым. Ә менә синең фин сугышындагы рота командирыңны күрә алмадым. Оныгы Ирина белән генә бер очраштык. Лебедев Анатолий Евсеевич бик карт икән инде. Хастаханәдә ята. Инде сөйләшми дә икән. Миңа аның янына Ирина барып йөрмәскә кушты.

Зариф *(уйга калып)*. Бездән шактый өлкәнрәк иде шул ул...

Назимә. Мин Иринага әйттем: Зәйнуллин Зариф турында әйт, дидем. Синең Анатолий Евсеевич алдында гаебеңне сизүеңне дә, гафу үтенүеңне дә әйттем.

Зариф. Рәхмәт, кызым.

Назимә *(әле бабасына, әле Хәбибкә карап куя)*. Дөнья барыбер могҗизаларсыз булмый инде ул. Хәбибнең кем икәнен белмисең бит әле син, бабай? *(Елмая.)*

Зариф *(хәтерендә казынып Хәбибкә шактый вакыт карап тора)*. Йөзе бик таныш.

Хәбиб *(елмая)*. Йөзем танышмы?

Зариф. Таныш. Тик Субай егете түгел, ахрысы.

Хәбиб. Субайныкы дисәң дә була, Зариф бабай. Мин Финляндиядә яшим. Ерак бабаларым Субайдан.

Зариф. Алай икән... *(Сагаеп кала. Егетне игътибар белән күзәтә.)*

Назимә *(түземлеген җуя)*. Бабай, игътибар белән кара әле.

Зариф *(бите агара, куллары дерелди, тавышы калтырый)*. Син... әллә...

Хәбиб *(торып баса)*. Әйе, мин Зыятдин бабайның оныгы.

Зариф абына-сөртенә тора да Хәбибне кочаклап елый башлый. Музыка. Егетне кочаклаган килеш озак елый. Музыка көчле яңгырый. Музыка тавышы әкренәя.

Зариф *(күз яшьләрен җиңе белән сыпыра)*. Исәнме ул?

Хәбиб. Юк. Узган елны вафат булды. Сине гел искә алды. Бигрәк тә гомеренең соңгы көннәрендә. Синең язмышыңны бик беләсе килде.

Назимә. Утыр әле, бабай, утыр. Син дә, Хәбиб, утыр. Басып тормагыз. *(Утырышалар.)*

Зариф. Кайчан, ничек котылган соң ул?

Хәбиб. 1948 елны азат итеп Финляндиягә кайтарып җибәргәннәр аны.

Зариф *(үзен чиксез бәхетле итеп тоя)*. Алай икән... Исән калган! Кайтып китә алган! Молодец, молодец! Миңа бит гомер буе аның язмышы тынгы бирмәде. Димәк, барыбер котылган!

Хәбиб. Аның инде «үзгәртеп кору» башлангач: «Зарифка хат язарга мөмкиндер хәзер», дип әйткәне булды. Ләкин теге вакытта НКВДдан курку шулкадәр нык сеңеп калган ки, юк, йә тагын сиңа бәйләнә

башларлар дип элемтәгә керергә җөрьәт итмәде. Һәм безгә дә рөхсәт бирмәде. *(Портфеленнән кулъяулыкка төрелгән фоторәсем чыгара.)* Үләр алдыннан ул миңа монда барырга кушты. Субайда бабаларыбыз нигезендә дога кылырсың, диде. Бәрәкәт урманында Зариф исән булса, аны күреп миннән сәламемне тапшыр, диде. Рәхмәт әйт Зарифка, диде.. Миндә нindiдер гаеп булса, кичерүен үтен, диде.

Зариф *(фоторәсемгә карап тора)*. Кәшифәнең яшь чагы. Кулъяулыкны да Кәшифә бүләк иткән иде. Зыятдин боларны ничек саклап кала алды икән лагерьда? *(Кулъяулыкны күкрәгенә кыса.)*

Хәбиб. Лагерьдагы лазаретта ятканда бер шәфкать туташына биргән ул аны. «Сакла. Үлеп китсәм, Татарстанның Субай авылына җибәр, ә инде исән калып моннан чыгарга насыйп булса, кире миңа бирерсең»,— дигән. Шәфкать туташы алып саклаган. Иреккә чыкканда бабай аңа мең рәхмәтләр укып фоторәсем белән кулъяулыкны алып киткән.

Зариф *(кабаланып чалбар кесәсеннән пәке чыгара)*. Менә бу пәкене дә Кәшифә бүләк иткән иде. Гел кесәмдә йөри. Шушы пәкене онытып калдырып кире барган идем мин теге аланга. Шунда Зыятдин килеп чыкты.

Хәбиб. Пәке белән зажигалканы теге чечен егетенә бирдем, дидең бит.

Зариф. Әйе. Зажигалка Зыятдинныкы иде. Алтмышынчы еллар башында Казахстаннан посылка килеп төште. Мин аптырадым: кемнән бу, нәрсә аның эчендә? Посылканы ачтым. Берничә төрле кәнфит, берничә төрле чикләвек, менә шушы пәке һәм бабаңның паспорты белән зажигалкасы. Шунда хат та бар иде. Ачып укыдым — Рассуханов Асланнан икән бу. Шаккаттым. Яраланганнан соң аның аягын кискәннәр икән. Чеченнарны кырык дүртенче елда, вагоннарга төяп, Көнчыгышка таба сөрделәр бит — сатылган халык дип. Шул бер аяклы килеш ул да эләккән переселениегә. *(Күзләрен йомып башын чайкый.)* Ай-яй! Хаты тетрәндергеч! Ничек курыкмаган миңа посылка җибәрергә, өстәвенә хат та язарга! Мин — көнбатыш разведкасына ярдәм итүче дигән шик астында утырып чыккан кеше, ә ул — сөрелгән чечен кешесе. Белсәләр, икебезгә дә эләгә бит инде... Җавап хаты язып торма, дигән, чөнки үзең беләсең, күзәтеп кенә торалар, дигән... Шулай итеп, Кәшифә бүләк иткән пәке белән бабаңның паспорты һәм зажигалкасы миңа кайтып төште.

Хәбиб. Бабамның паспортын рота командирына бирдем дидең шикелле...

Зариф. Хәзер аңлатып бирәм. 1940 елны мине кулга алгач, Лебедевны да допроска йөртә башлыйлар. Рота командиры булганга гына түгел. Мине бик каты яклаган иде ул. Үзен дә хөкемгә тартасылары билгеле булгач, Лебедев, госпитальгә барып, Зыятдинның паспортын Рассухановка бирә. Пәке белән зажигалканы мин Рассухановка биргәнне күрде бугай ул, шуңа күрә паспортны да аңа тапшырырга карар кылгандыр.

Назимә. Лебедевны да утырталармы әллә?

Зариф. Әйе. Ленинградта следственный изоляторда бер елдан артык яткан ул. Сугыш башлангач та төрмәдә булган әле. Аннары инде блокада... Ленинградны сакларга чыгарганнар. Миңа Лебедев турында инде немецка каршы сугышканда фронтта берәү сөйләде. Фин кампаниясендә безнең рота пулеметчысы иде — ул да Ленинград егете, Лебедев белән бер мәктәптә укыган булганнар.

Хәбиб. Хәзер бабамның паспорты, зажигалкасы, димәк, синдә?

Зариф *(уфтанып)*. Караклар алып чыгып киткән бит. Мин бит шул Зыятдинның паспортын урлаганнарына бик нык кайгырдым. Зажигалка зажигалка гына инде ул... Хәер, анысы да кызганыч. Ә менә паспорты миндә булганда, ничектер, әле ниндидер өмет бар иде — белмим нинди өметтер ул.

Хәбиб *(якты елмаеп)*. Зариф бабай, бик кайгырма ул нәрсәләр өчен. Минем бабам гел сине искә алып, сагынып, синең өчен кайгырып яшәде. *(Зариф тагын елап ала.)*

Зиновьев килеп керә.

Зиновьев *(гадәттәгечә елмаеп һәм «куелган» тавыш белән)*. Добрый день!

Назимә *(чит кешенең кем икәнлеген аңларга тырышып игътибар белән карый)*. Здравствуйте!

Зариф *(бернинди эмоциясез)*. Опять приехал?

Зиновьев. Да, должен побеспокоить вас... И обрадовать. *(Елмая.)*

Назимә. Бабай, бу кеше синең яныңа килдеме?

Зариф. Әйе.

Хәбиб. Алайса, без Назимә белән урманда йөреп керик әле.

Зариф. Барыгыз, бар, балалар.

Назимә. И-и-и, Хәбиб, мин сиңа хәзер шундый матур урыннарны күрсәтәм. *(Чыгып китәләр.)*

Зиновьев *(ясалма ягымлылык белән)*. Исәнмесез!

Зариф *(Зиновьевның килүенә шат түгеллеген күрсәтеп)*. Исәнме. Нәрсә кирәк?

Зиновьев *(тантаналы тавыш белән)*. Мы нашли грабителей.

Зариф. Каких?

Зиновьев *(гаҗәпләнеп)*. Как «каких»! Тех, кто дом ваш ограбил. Представляете, это оказались бомжи.

Зариф. Бомжи?

Зиновьев *(көлә)*. Да. Ну, это люди без места жительства, без работы и так далее... Если хотите, мы их привлечем к уголовной отвестственности.

Зариф. Ни к чему это. *(Ике кеше Зарифның телевизорын күтәреп керәләр.)*

Зиновьев. Зариф абы, покажите, куда ставить?

Зариф *(түрдәге тумбочкага ишарәләп)*. Вот его место.

Грузчиклар телевизорны тумбочкага куеп чыгып китәләр.

Зиновьев *(зур канәгатьлек белән*). Думаю, и остальные вещи ваши скомпенсируются.

Зариф. Если это бомжи, то не надо их наказывать. И не требуйте с них моих вещей, я прошу вас. Оставьте их в покое. *(Зиновьевка карап тора һәм паузадан соң өстәп куя.)* И меня оставьте в покое.

Зиновьев *(кәефе кырыла)*. Хорошо. Как себя чувствуете?

Зариф *(кырысланып)*. Когда ты приходишь, не важно!

Зиновьев *(үпкәле тавыш белән)*. Я только с благими намерениями приезжаю к вам. *(Папкасыннан бер документ һәм зажигалка чыгара.)* И это тоже ваше...

Зариф *(документны һәм зажигалканы ала).* Вот за них спасибо. За паспорт и зажигалку Зыятдина большое спасибо.

Зиновьев. Наконец-то, я смог хоть чем-то вас обрадовать.

Зариф *(Зиновьевка текәлеп карап тора)*. Думаешь, ты меня смог обмануть?!

Зиновьев *(каушый)*. Ты что, старик?!

Зариф. Ты не Зиновьев! Может быть, ты фамилию не дедовскую носишь... Но все равно ты не тот, за кого выдаешь. Ты еще молод, и по молодости тебе опыта не хватает.

Зиновьев *(гасабиланып)*. Какого опыта?

Зариф *(авызын кыйшайтып)*. Опыта работы с людьми.

Зиновьев *(югалыбрак кала)*. Я к вам отношусь с большой симпатией. Я знаком со всей вашей биографией. Да. Я хочу с вами быть искренним. Моя фамилия не Зиновьев. Моя фамилия — Зимин.

Зариф *(бөтенләй якын килеп Зиминның оныгын күзәтә)*. Похож, очень похож.

Зимин *(тавышы калтырый)*. Дед о вас часто спрашивает... Мы в Челнах живем... Я его перевез к себе...

Зариф. А почему столицу на Челны поменяли?

Зимин. Отец КамАЗ строил... Меня тоже в Челны направили.

Зариф *(горур тавыш белән)*. У меня сын тоже на КамАЗе работает, начальником цеха. А ты кем работаешь — я догадываюсь.

Зимин *(үзен кулга ала һәм тынычлана)*. Я откровенно вам скажу: это меня дед попросил пообщаться с вами.

Зариф. А что, других методов не смогли придумать?!

Зимин. Дед часто вспоминает о вас...

Зариф. Ну что он никак не угомонится!

Зимин. Нет, нет, вы не то подумали, Зариф абы. Он просто... по-человечески интересуется — как ты живешь, как у тебя здоровье...

Зариф *(кырыс тавыш белән)*. По-человечески?! Спасибо вам за все. И тебе спасибо. Я прошу — меня больше не тревожьте.

Зимин. Зариф абы, наоборот, я хочу вам помочь, чем могу. Если понадобиться какая помощь, звоните мне. Вот моя визитка.

Зариф. Не надо. *(Боерып.)* Уходи!

Зимин. До свидания! *(Чыгып китә.)*

Зиминның оныгы чыгып китүгә Назимә белән Хәбиб йөгереп керәләр.

Назимә. Бабай, кем иде ул?

Зариф *(битараф тавыш белән)*. Милициядән.

Назимә *(телевизорны күреп сөенә)*. Телевизорны алып килгәннәр.

Зариф. Каракларны тотканнар. Менә Зыятдинның паспорты, зажигалкасы...

Хәбиб *(бабасының паспортын саклык белән генә алып ачып карый).* Менә бит ә... *(Зажигалканы алып карый.)*

Назимә *(борчулы тавыш белән)*. Бабай, ятып тормыйсыңмы?

Зариф. Ник?

Назимә. Арыганга охшагансың.

Зариф. Нинди яту инде бүген, кызым! Ә инде арыганга охшаганмын икән... *(Кызына карап тора.)* Кызым, мин, ахрысы, яшәп арыганмындыр.

Назимә (*битәрләп*). Әй бабай, кайчак әллә ниләр әйтеп куясың!

Зариф (*кинәт йөзе яктырып китә*). И-и-и, кызым, шушы кадәр Кәшифә әбиеңә охшасаң да охшарсың икән! *(Кызының аркасыннан сөя.)*

Хәбиб *(Назимәгә карап)*. Әйе шул. Теге фоторәсемдә әллә Назимә, әллә Кәшифә әби — аңламассың.

Зариф *(күтәренке рух белән)*. Хәбиб, улым, бездә кунасыңдыр бит?

Хәбиб. Ни...

Зариф. Бездә, бездә. Ни дә түгел, берни дә түгел... Миндә Финляндия түгел, кәнишне. Шулай да бәрәңге кыздырып хуш ис чыгарсак, хәйран күңелле булачак. *(Көлешәләр.)*

Хәбиб. Ярар. Алайса, иртәгә Субайга бергәләп барырбыз. Мине зиратка алып барырсыз. Ерак бабамнарның каберләре дә шунда. Кәшифә әбинең дә каберен күреп китәрмен.

Музыка.

**УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Бәрәкәт урманы. Зарифның йорты, каралты-курасы күренеп тора. Назимә белән Хәбиб наратлык янында йөриләр. Зариф җыр шыңшый-шыңшый рәшәткәләр каккалап йөри. Читтәрәк машина килеп туктый. Карт Зимин килә. Ул инде бик картайган — таякка таянып акрын гына атлый. Өс киеме бик пөхтә һәм затлы. Зариф чакырылмаган кунакка карап тора. Алар бер-берсен шундук таныйлар.

Зимин. Исәнме.

Зариф. Исән.

Зариф белән Зимин яшьләр йөргән якка карап койма буенда яткан бүрәнәгә янәшә утыралар.

Зимин. Ничек яшисең?

Зариф. Син минем ничек яшәгәнемне һәм ничек яшәвемне үземә караганда да әйбәтрәк белә торган кеше түгелме?! *(Бер-берсенә ничектер карамаска тырышалар кебек.)*

Зимин. Менә язмыш тагын очраштырды. Дөнья бер дә киң түгел ул, Зариф, килешәсеңме?

Зариф. Синең өчен тар инде ул. Сезнең өчен... Минем өемне басу кәмитләрен ник оештырдың соң син? Оныгыңның стажировкасын миндә уздырырга булдыңмыни?

Зимин. Мин сине очратуыма бик шат...

Ерактан Назимәнең «Кошларга» дигән җыр җырлаганы ишетелә.

Зариф. Зыятдинның паспорты белән зажигалка ник кирәк булды соң?

Зимин. Минем тагын бер кат карыйсым килде.

Зариф. Юк. Мин беләм. Оныгыңа мирас итеп калдырмакчы буласың син ул эшне. Оныгыңа ул әйберләрне фотога төшерергә кушкансыңдыр әле.

Зимин. Ул аны үзе дә белә.

Зариф. Димәк, бабасының эшен дәвам итә — тулы мәгънәсендә?

Зимин *(канәгатьсезләнеп)*. Ташла әле, Зариф, безнең синең белән сөйләшер сүз беткәнмени?! Без бит синең белән күп авырлыклар кичергән кешеләр.

Зариф. Без төрлечә кичердек ул авырлыкларны.

Зимин. Өянәкләрең еш буламы?

Зариф. Төрлечә. *(Зимин ягына караш ташлап ала.)* Хәтта өянәкләрем турында да беләсең...

Зимин *(көлемсерәп)*. Телсез Күке дигән кушаматыңны да беләм. Хәтерлисеңме, теге фин татарын, «күке» булса да, ул бит «телсез күке» — чөнки атмады, дигән идең.

Зариф *(кәефенең күтәренкелеген җуймыйча)*. Кичә миңа бик шатлыклы хәбәр алып килделәр, шуңа күрә минем хәлем яхшы бүген.

Зимин. Нинди хәбәр?

Зариф. Сез анысын да беләсез инде.

Зимин *(җыр ишетелгән якка карап)*. Кем җырлый?

Зариф. Минем оныгым Назимә. Нәкъ Кәшифә әбисе кебек искиткеч матур җырлый.

Зимин. Нинди җыр бу?

Зариф. Татар халык җыры. *(Зиминга карап тора.)* Сез безгә бүтән кагылмагыз инде. Актык көннәремне тыныч кына яшим инде, зинһар.

Зимин *(аптыраган кыяфәт белән)*. Сиңа кагылучы юк! Әле бик кагылырлык вакытларда да борчымаска булдык сине.

Зариф. Аңламадым?..

Зимин. Сөргенгә сөрелгән чечен Рассухановтан посылка алгач, сиңа беркем бер сүз әйтмәде.

Зариф *(төсен үзгәртеп)*. Рассухановка аның өчен бер-бер нәрсә булмагандыр бит?

Зимин. Юк. Алтмышынчы еллар уртасында ул гаиләсе белән туган җиренә кайтты.

Зариф *(читкә карап)*. Аяксыз кешене сөргенгә сөрмәсәләр...

Зимин *(авыр сулап)*. Бернишләп булмый...

Зариф *(уфтанып)*. Анда хәзер дә мәхшәр бит әле.

Зимин. Кайда?

Зариф. Чечняда.

Зимин. Шулай шул. Рассуханов соңгы елларда уртанчы улында Грозный шәһәрендә яшәде. Зурысы Мәскәүдә зур бизнесмен иде. Кече улы да Мәскәү белән Грозный арасында нindидер эшләр майтарып йөрде.

Зариф. Ә Аслан үзе ничек икән хәзер?

Зимин *(игълан укыгандагы интонация белән әйтә)*. Рассуханов Аслан — безнең сослуживец, совет-фин сугышы инвалиды — 1995 елны федераль авиация Грозныйны бомбага тотканда һәлак була. Нәкъ йортлары өстенә төшә бомба. Өч улы да хәзер тауларда качып Россиягә каршы сугышалар. Алга таба нәрсәләр булып бетәр анда, белмим.

Зариф *(чиксез нәфрәт белән)*. Мин беләм!

Зимин. Ничек?

Зариф. Гадәттәгечә!

Зимин. Ничек, гадәттәгечә?

Зариф. Менә шулай! Гадәттәгечә! Ник килдең син монда?!

Зимин *(аптырашта калып)*. Сине күрергә дип.

Зариф. Аңлыйм: бөтен нәрсәне белеп торасыз. Сиңа һаман Зыятдинның миңа атмавы тынгылык бирми. Күпме еллар узды. Үзеңә-үзең куйган сорауга җавап табалмыйча иза чигәсең. Син һаман миңа ышанмыйсың? Үзем белән гүргә нindидер бер зур серне алып китәм дип кайгырасың!

Зимин *(көлемсерәп)*. Башлы кеше син, Зариф. *(Кесәсеннән Зарифның орденнарын алып бирә.)* Мә, Зариф, бу синең орденнарың. Дан орденнарын түшеңнән үзең йолкыган идең. *(Зариф орденнарын ала. Учларына салып орденнарына озак карап утыра.)* Ә офицерлыкта воccстановление булачак сиңа — мөрәҗәгать итүең генә кирәк.

Зариф. Анысы кирәкми инде.

Зимин. Ветеран войны булып исәпләнсәң льготалар була. Киреләнмә!

Зариф *(Зиминга таба борылып)*. Миңа иң зур льгота, беләсеңме, нәрсә булыр иде? Зыятдин турында, минем турында, безнең балаларыбыз, оныкларыбыз турында мәгълүматлар җыеп йөрмәсәгез иде.

Зимин. Син нәрсә инде. Син бигрәк. Артык шикчелләнгәнсең син!

Зариф. Синнән дә шикчелрәк кеше дөньяда юктыр.

Зимин. Һәркемнең үз эше, үз вазифасы, үз бурычы бу тормышта.

Зариф. Мин исән чакта, нәселебез исән чакта, гомумән татар исән чакта син тынгылык тапмаячаксың. Мин аңладым: сиңа сәбәп кенә кирәк.

Зимин. Алай түгел, Зариф. Күпертмә. Җавап табалмый калган сораулар бар, әлбәттә...

Зариф. Әйт дөресен, син бит һаман ышанмыйсың Зыятдинның татар җырын ишеткәнгә атмаганына.

Зимин. Хәзер ышанам инде.

Зариф *(кызып-кызып)*. Юк, син хәзер дә шикләнәсең. Синең мин-минлегеңә тынгылык бирми — бәлки, Зыятдин чынлап та зуррак «күке» булгандыр, бәлки, Зариф дөрестән дә көнбатыш шпионы булгандыр... Мине бер уй сискәндерде әле. *(Тавышын әкренәйтеп.)* Әгәренки син шизофреник икән?! Синең шикчеллегең аркасында күпме кеше харап була ала?!

Зимин *(үпкәли)*. Син мине мыскыл итәргә ашыкма.

Зариф *(Хәбиб белән Назимә йөргән якка карап елмая)*. Ашыгасы юк инде хәзер. Кичә миңа яхшы хәбәр китерделәр! Зыятдинның исән калып кырык сигезенче елда Финляндиягә кайтып китүен мәгълүм кылдым!

Назимә белән Хәбиб киләләр. Исәнләшәләр. Зимин Хәбибкә бик озак карап тора. Хәбиб, Зарифның кулындагы орденнарны күргәч, бу кешенең кем икәненә төшенгән кебек була.

Назимә. Исәнмесез!

Хәбиб. Исәнмесез!

Зимин. Исәнмесез! *(Шаккатып Хәбибкә карап утыра.)* Бу кадәре охшаса охшар икән!

Хәбиб *(салкын тавыш белән)*. Беләсеңме, кешеләр нишләп бер-берсен хәтерләтәләр? Ник кайберәүләр бер-берсенә нык охшаганнар?

Зимин. Ник?

Хәбиб. Хәтер исән булсын өчен, күп нәрсәләр онытылмасын, югалмасын өчен.

Назимә *(нәрсәдәндер шикләнеп һәм бераз шүрләп, Хәбибне көтелмәгән кунак янынннан алып китәргә була)*. Әйдә, комачауламыйк бабайларга.

Хәбиб. Киттек! *(Китәләр.)*

Зимин. Син хәзер инде бернәрсәдән дә куркырга тиеш түгел.

Зариф. Курку юк, ләкин оныклар өчен борчылам. Зыятдинның оныгы өчен дә, үземнеке өчен дә. *(Зиминга карап тора.)* Борчылу һәм шомлану бар. Чөнки синең дә оныкларың бар!

Зимин. Ташла!

Зариф. Менә шундый хәлләр... *(Ерактан Хәбибнең җырлаганы ишетелә.)*

Урманнарда йөргән чакта
Адаштым юлларымны;
Күңелем нечкә —
җылармын дип,
Сузмадым кулларымны.

Йөгердем җитәлмәдем лә,
Сикердем читәннәрен;
Ни булгандыр телләремә —
Сау бул дип әйтәлмәдем.

Зимин *(җыр ишетелгән якка карап).* Кем җырлый моны?

Зариф. Зыятдинның оныгы Хәбиб. Нәкъ бабасы Зыятдин кебек шәп җырлый.

Зимин. Ә монысы нинди җыр?

Зариф. Татар халык җыры.

Зимин. Әйт әле, Зариф, ни сәбәпле сез теге вакытта Зыятдин белән бер-берегезне шулай нык якладыгыз?

Зариф. Әйтәм бит, син актык сулышыңа кадәр шикләнәчәксең дип.

Зимин. «Күке» дигән сүзнең тагын мин белмәгән мәгънәсе бар идеме сезнең арада?

Зариф. Син үзеңнең мантыйкларыңда буталып беткәнгә күрә оныгыңа дәвам итәргә кушкансың инде бу эшне.

Еракта Хәбиб җырлый. Ул «Иске кара урман» дигән җырны башкара.

Син акылсыз кеше түгел, ләкин беркайчан менә бу җырларның моңын, мәгънәсен, асылын аңламаячаксың. «Күке» сүзе ничектер, ә менә бу җырның син беркайчан белмәячәк һәм аңламаячак тирән мәгънәсе бар.

Зимин. Әлбәттә, һәрнәрсәне белеп, аңлап бетерү мөмкин түгел.

Зариф. Син әллә кайларга үтеп керергә тырышып казындың, ә ярылып яткан хакыйкатьне аңлый алмадың.

Зимин *(өзгәләнеп)*. Нишләп соң сез икегез дә «Күке» идегез? Икегез дә аннары «Телсез Күке» булдыгыз?!

Зариф *(утырган урыныннан кузгала, як-ягына, аннары күккә карап куя)*. Өянәкләрем кузгалып тотлыга башлаганда, вакыты-вакыты белән телсез калып торгач, мин курыктым. *(Хәбибнең җырлавы ишетелә. Шул фонда сөйли.)* Ләкин бөтенләй үк котсыз калдым дип әйталмыйм. Бер күке телсез калганнан урман яшәүдән туктамас, дидем мин үземә. Ләкин барыбыз да телсез калсак?.. Мин инде үзем әйтәсемне әйттем, җырлыйсымны җырладым. Ә миннән соң барысы да телсез булса?! «Телсез» сүзенең син аңламый торган мәгънәсеннән курыктым мин. Ә менә Зыятдинның исән калып балалар, оныклар үстергәнен белгәч, оныгының телле икәнен күргәч вә ишеткәч, минем өметемнең ялкыны югары күтәрелде. *(Кычкырыбрак.)* Сугышта винтовканы телсез иткән тел әле яшәячәк ул! Винтовканы телсез калдырган җырны ничек үтереп булсын икән?! *(Җыр көчәя.)*

Зимин. Син бөтенләй башка нәрсә турында сөйлисең.

Зариф. Бәлки, шулайдыр. Бу дөньяда һәркем үзенекен сөйли. Аллага шөкер! Телсез түгел мин. Зыятдин да телсез түгел иде. Оныкларыбыз да телсез түгел! Аллага шөкер!

Зимин. Ә мине тынычландырырдай берәр сүз әйтмәссеңме икән?

Зариф. Мин туйдым синнән! Кайтып кит! Бар, үз юлыңда бул! *(Иркен сулап куя.)* Бүген безнең мунча керәсебез бар. Аннары Кәшифәнең каберенә барып кайтырга кирәк. Бар! Борчымагыз безне!

Зимин. Син мине шулай чиксез күралмыйсыңмыни?!

Зариф. Ялгышасың. Нәфрәт түгел бу. Киресенчә, бүген минем күңелемдә андый кара хискә урын юк. Мин элегрәк әле бераз шөбһәләнеп йөргән идем: яшьләр, балалар нәфрәтле булмасlармы безгә карата дип. Улымны, оныкларымны тыңлагач, мин аларда безгә карата үпкә, нәфрәт тоймыйм. Яшь буыннар безне бернәрсәдә гаепләмиләр. Алар безне яраталар. Аннары шунысы бар: нинди генә коточкыч сынаулар аша үтсәк тә, алар без үткәннәр, без кичергәннәр белән яшәмәячәкләр. Безнең заман безнең белән узып китте. Башкача мөмкин түгел. Безнең җәрәхәтләр безнең белән китә. Безнең җан газаплары — безнеке, фәкать безнеке генә. Газапларның да чиге, азагы бар. Үтә, үтә! Үтеп китә болар барысы да. Безнең баштан узганнарны, ни гаҗәп, югалтасы килми шикелле! Әмма ләкин шулай

кирәк, шулай тиеш! Әлбәттә, синең җан газабының каядыр китеп гаип булуы кызганыч, бик кызганыч! Ләкин башкача ярамый! Башкача мөмкин түгел! Барысы да үтә! Кызганыч, ләкин шулай кирәк!

Ерактан Назимәнең «Саннар» җырын җырлавы ишетелә. Аңа Хәбиб кушылып җырлый.

Зимин. Әгәр дә... мин синнән гафу үтенсәм?.. Кичерүеңне сорасам?..

Зариф. Беренчедән, синең гафу үтенергә җыенуыңа мин ышанмыйм. Икенчедән, мин сине гафу итә алам, тик аңлый алмыйм.

Зимин. Бәлки, аңларга теләмисеңдер?

Зариф. Әйе, әйе, менә болай дөресрәк булыр, мөгаен: гафу итәргә телим, ә менә аңларга хәтта теләмим дә.

Зимин *(китәргә җыена)*. Тагын нәрсә телисең яки нәрсә теләмисең миңа?

Зариф *(тавышы көрәя, куәте арта)*. Мин сиңа саулык-сәламәтлек телим! Озын гомер телим! Озак яшә! Ике йөз ел, ике йөз илле ел яшә тагын! Чөнки аңламый калган нәрсәләрне аңларга вакыт сиңа күп кирәк. Сорауларыңа җавапларны табарга сиңа озын гомер кирәк! Ниһаять, аңлагач, бәлки, тәүбә итәргә дә бераз вакыт кирәк булыр әле. Хуш!

Җыр көчәя. Зимин акрын гына, таягына таянып, көтеп торучы машина ягына таба китеп бара. Зариф орденнарын пинҗәк кесәсенә тыга да, яшьләр йөргән яктан яңгыраган җырга кушылып җырлый-җырлый, рәшәткәләрне кадаклый. Музыка.

Тәмам.

*2002—2003*

# ГАСЫР МОҢЫ

*(Театраль роман)*

КАТНАШАЛАР:

Акмуллин Сәләхетдин Бикморза улы.
Акмуллина Хәбибә Солтангәрәй кызы.
Акмуллин Вилдан — Сәләхетдиннең улы.
Акмуллина Әкълимә — Сәләхетдиннең кызы.
Гарифә.
Басыйр.
Илбәк.
Клара.
Фердинанд.
Мәхмәт Доган.
Умаров.
Тимер.
НКВД хезмәткәрләре.
Абвер хезмәткәрләре һ. б.

Вакыйгалар 1906 елдан алып 2006 елга кадәр патша Россиясендә (аннары СССРда), Төркиядә, Германиядә һәм бүгенге Россиядә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### 1

1906 ел. Көз. Казан. Акмуллиннар йорты. Сәләхетдиннең ерак сәфәрдән кайтуын көтәләр. Өйдә Хәбибә, Вилдан, Әкълимә, Гарифә.

Хәбибә. Гарифә, самавырны яңарт.

Гарифә. Хәзер.

Әкълимә. Әтиебез кайчан кайтасын хәбәр иткән булса, поездны каршы алырга барыр идек.

Хәбибә *(борсаланып)*. Исән-сау гына кайтып җитсен инде берүк, Ярабби.

Гарифә. Әүхәди Хәлимәсе әйтте: күптән түгел Петербург янында бер поезд рельсыдан шуып төшкән, ди.

Вилдан. Син гел шуның ише куркыныч хәбәрләр җыеп йөрисең инде.

Гарифә. Әүхәди абзый үзе гәҗиттән укыган.

Хәбибә. Аллам сакласын! Читадан Казанга кадәр поездда кайту ай-һай!

Әкълимә. Әнкәй, ул аннан нәрсә алып кайта?

Вилдан *(үчекләп)*. Кәнфит белән прәнник.

Хәбибә. Байкал артында сәүдә элемтәләрен ныгытырга йөри ул.

Гарифә. Бигрәк ерак арадыр — моннан анда кадәр.

Вилдан *(төрттерүле тавыш белән)*. Әйе, Арчадан да арырак, ди.

Хәбибә. Улым, нишләп һәммәсе белән төрттереп сөйләшәсең?

Вилдан *(коры гына)*. Юк-бар сораулар белән йөдәтмәсеннәр.

Хәбибә *(ягымлы итеп)*. Син бит, улым, егет кеше, кызлар белән бераз ягымлырак сөйләш.

Гарифә *(тәрәзәдән карап кычкыра)*. Кайта! Кайта! Үзе белән ниндидер малай да иярткән.

Барысы да тәрәзә янына баралар, каршы йөгереп чыгалар. Сәләхетдин ун яшьлек малай ияртеп кайтып керә. Малайның бер күзе зәгыйфь — кысылыбрак тора, начаррак күрә.

Сәләхетдин *(әйберләрен идәнгә куеп)*. Исән-саулармы барыгыз да!

Хәбибә. Аллага шөкер. Үзең әйбәт кенә кайтып җиттеңме?

Сәләхетдин *(чишенә)*. Ходайның рәхмәте белән кайтып җиттем. Юл юл инде ул, нык ардырды. Ил кайный. Полиция поездны станция саен тикшереп тора. Кемнәрнедер эзлиләр, кайберәүләрен кулга алалар. Акырыш-бакырыш, этеш-төртеш. *(Вилданга.)* Нихәл, улым?

Вилдан. Исәнме, эти!

Сәләхетдин *(Әкълимәгә)*. Саумы, кызым!

Әкълимә. Исәнме, әти!

Сәләхетдин. Исәнме, Гарифә! *(Барысының да аркасыннан сөеп чыга.)*

Гарифә. Исәнме!

Сәләхетдин. Күчтәнәчләрне, бүләкләрне аннары өләшермен. *(Малайны алга чыгарып.)* Менә, гаиләбез саны артты. Таныш булыгыз, кабул кылыгыз. Бу Басыйр атлы малай. *(Барысы да зур игътибар белән малайга текәләләр.)*

Хәбибә *(аптырап)*. Кем малае соң бу?

Сәләхетдин. Хәзер инде безнеке. Читадагы бер татар гаиләсендә тәрбияләнгән ятим.

Әкълимә *(малайның зәгыйфь күзенә карап)*. Синең бу күзең нишләгән?

Хәбибә. Кызым, кешегә иң беренче нәүбәттә кимчелекле җире турында сорау бирмиләр! Синең белән бу хакта сөйләшкәнебез бар бит инде.

Әкълимә *(башын иеп)*. Гафу ит, әнкәем.

Хәбибә. Миннән түгел, малайның үзеннән гафу үтен.

Әкълимә *(малайга)*. Гафу ит. Ул күзең авыртмыймы?

Сәләхетдин. Кызым, бар әле читкәрәк. Чәйне тизләтә алмассыз микән?

Гарифә кабаланып табын әзерли. Сәләхетдин бүләкләр өләшә, күчтәнәчләрне өстәлгә куялар.

Вилдан *(малайга)*. Син безгә бөтенләйгә килдеңме?

Малай дәшми.

Сәләхетдин. Әйе, улым, ул бездә яшәячәк. Сораулар белән баланы бимазаламагыз.

Хәбибә *(елмаеп малайның башын сыпыра)*. Сөйләшә беләсеңме соң син?

Басыйр *(кинәт тереләнеп)*. Беләм. Сүгенә дә беләм.

Хәбибә. Юк, юк, менә анысы кирәк түгел.

Басыйр *(Сәләхетдингә)*. Минем печ итәсем килә.

Сәләхетдин. Вилдан, улым, бар алып чыгып кер энекәшеңне.

Хәбибә *(башкалар ишетмәслек итеп)*. Әллә алып кайтасың калмаганмы? Балаларыбызга аның йогынтысы ничек булыр?

Сәләхетдин. Аңа үзебезнең йогынтыбыз яхшы булсын. Асраучылары аны каядыр озатып җибәрергә теләгәннәр. Кызгандым. Татар баласы бит.

Хәбибә. Ата-аналары кемнәр булганнар?

Сәләхетдин. Алар Читаның үзендә яшәгәннәр. Атасы экспедиция әгъзасы булган, тайгада адашып үлгән. Анасы йөрәк авыруы белән бу дөньядан киткән. Бик шук, тере малай. Күрсәң син аның биюен! Шундый оста, кызык иттереп бии.

Басыйр белән Вилдан керәләр.

Вилдан. Әти, начар малай бу. Миңа әшәке сүз әйтте.

Сәләхетдин. Нинди әшәке сүз?

Вилдан. Сүгенде.

Сәләхетдин. Ә син аңа әйбәтләп, абыйларча аңлат — сүгенергә ярамый, әйбәт егетләр сүгенмиләр диген.

Әкълимә *(Басыйрга)*. Минем яңа башмагымны күрәсең киләме?

Басыйр *(башын чайкап)*. Юк.

Гарифә *(Басыйрга)*. Әйдә, кулларыңны, битеңне сабын белән юдырам, аннары ашарга утырырсың.

Басыйр. Кулны гына юам, битемне юмыйм.

Гарифә. Ник битеңне юмыйсың?

Басыйр. Сабын күзне әчеттерә.

Әкълимә *(ияреп бара)*. Син миңа бик ошыйсың. Мин сине гел яклаячакмын, беркемнән дә кыерсыттырмам.

Гарифә. Әкълимә, саграк бул аның белән.

Әкълимә. Гарифә апа, син миннән ике яшькә олырак булсаң да, гел өйрәтеп торма, яме.

Гарифә. Үзеңә кара. *(Басыйрның битен, кулларын юарга алып китә.)*

Сәләхетдин *(өстәл янына утырып)*. Казаныбызда нинди яңалыклар бар?

Хәбибә *(чәй ясый)*. Монда да көнаралаш диярлек забастовкалар. Листовкалар, прокламацияләр белән дөнья тулган.

Вилдан белән Әкълимә дә табынга утыралар.)

Сәләхетдин *(чәй эчә-эчә сөйләшә)*. РСДРП белән эсерлар эшедер инде.

Вилдан. Шулар. Безнең мәдрәсәгә дә килделәр урамга чыгарга өндәп.

Сәләхетдин. Чыктыгызмы соң?

Вилдан. Чыктык, кызык бит.

Сәләхетдин. Син, улым, чамалап йөр, мәдрәсәнең рус классына керә алуыңның кадерен бел. Ничек тә булса гимназиягә, реальное училищега, аннары университетка укырга керергә омтыласың бар. Теләсә кемгә ияреп теләсә кая чыкмаска тырыш.

Хәбибә. Барыбер мәдрәсәне тәмамлау таныклыгын хөкүмәт санга сукмый, танымый. Татар балаларына университетларга үрмәләү насыйп булмас инде.

Сәләхетдин. Алай димә. Менә бу забастовкаларның бераз файдасы да тими калмас, шәт. Эсерлар арасында көчле татарлар да бар. Алар безгә тигез хокуклар даулыйлар. Яшьләребезнең киләчәген дә кайгыртырлар, Алла боерса. Февраль аенда миллион ярым шәкерт забастовка ясады, шулай булгач, татар яшьләренең хәлен кайгыртмый калмаслар.

Хәбибә. Ул татар эсерлары арасында кемнәр соң?

Сәләхетдин. Исхакый, Туктаров, Әбүзәров, Казанлы, Рәмиев, Мамлеев. Һо-о-о, шәп кешеләр бар анда!

Хәбибә. Алар нишли ала соң?

Сәләхетдин. Алай димә. Араларында бик акыллы кешеләр бар. Корал тотып илне яхшылыкка үзгәртү мөмкин түгел. Акыллы шәхесләребез калыкса гына алга китә алабыз — аң белән, акыл белән. *(Битен сыпырып.)* Аллаһе әкбәр. *(Диванга барып утыра.)* Юл шаукымыннан арына алмыйм һаман.

Гарифәнең елаганы ишетелә. Вилдан аның янына йөгереп бара.

Хәбибә. Нәрсә булды?

Вилдан. Теге малай Гарифәгә дә сүгенгән.

Сәләхетдин. Килегез әле монда. Нишләп шул арада талаштыгыз?

Басыйр *(иреннәрен турсайтып)*. Ул миңа, шапшак малай икәнсең, диде.

Сәләхетдин. Бүтән әйтмәс. Ул бер сүзен дә сиңа начарлык теләп әйтмәс. Син — шундый шәп биюче малай, нишләп шушындый тәти апаңа начар сүз әйтәсең? Әйдә әле, татулашыр өчен бер биеп җиффәр!

Басыйр *(иреннәрен турсайтып)*. Биисем килми.

Сәләхетдин. Әйдә әле, әйдә әле, тәмле әйберләр белән чәй эчәр алдыннан биергә дә ярый.

Басыйр *(күзләрен елтыратып)*. Теге кызыл тышлы кәнфитне бирәсеңме?

Сәләхетдин. Әлбәттә. Әйдә, һоп-һоп-һоп!

Кул чабып тора, малай бии. Барысы да көлешәләр, кәефләре күтәрелә.

## 2

1910 ел. Җәй. Казан. Акмуллиннар йорты.

Вилдан *(нәрсәдер яза-яза зарлана)*. Нишләп ул укырга йөрми? Нишләп үзе яраткан эшләрне генә башкара. Бездә инде дүрт ел яши, аңа инде ундүрт яшь! Бер күзе начар күрә дип, ятим үскән дип, аның кыргыйлыгына гел шулай түзеп яшәрбезме? Аны шундый яхшы мәктәпкә урнаштырдылар, ә ул укырга йөрергә теләми.

Сәләхетдин. Үзең дә, уналты гына яшьтә булсаң да, тавыш күтәрәсең бит әле менә.

Хәбибә. Әйе, улым, син дә кайвакыт йөгәнсезләнәсең.

Вилдан *(язудан туктый, торып бер әйләнеп килә)*. Ярар, гафу итегез. Үз улыгыз сүз әйтсә дә ярамый, ә аңа ни кыланса да гафу ителә.

Сәләхетдин. Аның ул хәтле нишләгәне бар соң? Бәллүр савытны ваткан икән, ул бит аны юри ватмаган, савыт-сабаны һәрберебез ялгыш вата аны.

Хәбибә. Сәләхетдин, дөресен әйткәндә, Басыйрга безнең тәрбия керми, моны үзең дә аңлыйсыңдыр.

Сәләхетдин. Керер әле. Аны кире Читага илтеп ташлый алмыйм бит инде мин. Аны аякка бастыру безнең бурычыбыз.

Хәбибә. Игелегебез тәэсир итми — кыргыйлыгыннан һич арынмый.

Сәләхетдин. Аның үзсүзлелеген кыргыйлыкка тиңләмәгез. Әйбер урламый. Киреләнсә дә, әйткәнне барыбер үти. Син Вилданның мырылдавына карама.

Хәбибә. Күпме өндәп тә үзебезгә «эти-әни» дип эндәшергә өйрәтә алмадык. Әнә, Гарифә беренче көннән үк эти-әни дип эндәшә башлаган иде.

Сәләхетдин. Асрауга алганнар бөтенесе дә бертөсле булмыйлар. Син Дәрвишләр бистәсеннән алып кайтылган Гарифә белән Себер артындагы Читадан кайткан Басыйрны чагыштырма инде.

Хәбибә. Тагын да үсә төшкәч нәрсә булыр?

Сәләхетдин. Әйбәт булыр. *(Гәҗит укырга тотына.)*

Басыйр керә. Ишек катында тыпырдап биеп ала.

Басыйр. Хатыңны илтеп тапшырдым.

Сәләхетдин. Нишлиләр иде?

Басыйр. Мин ишегалдында Әүхәди агайның үзен күрдем дә бирдем. Шунда уйга чумып йөри иде.

Сәләхетдин. Нәрсә диде?

Басыйр. Рәхмәт әйтте. Бер-ике көннән җавап бирермен, Читага кире киткәнче әле әллә ничә тапкыр очрашырбыз, диде. Мине җентекләп күзәтте — шул арада шушылай үстеңмени дип шаккатты, без сине Казанга алып кайтканда бәләкәй генә нәрсә идең, диде.

Вилдан *(кырын карап)*. Әйбәт ашаталар дип әйттеңме соң?

Басыйр *(Вилданга көлемсерәп карый)*. Юк, телем әйләнмәде.

Хәбибә. Вилдан улым, син дә бераз үзеңне тыйнаграк тотсаң яхшы булыр иде.

Сәләхетдин. Басыйр, минем сиңа бер үтенечем бар... Син Вилданның зарлануларына бигүк игътибар бирмә инде. Ул идеаль тәртип яклый торганрак холыклы, мәктәптә дә шулай диләр. Синең үзсүзлегеңә бераз ачуы килә аның. Ә син үзең нәрсә дә булса ошамаса, дүрт ел эчендә җыелган үпкәләрең булса, киреләнәсе урынга, миңа кил дә ихластан аңлат — без, ир-егетләр, ничек тә аңлашырбыз, уртак тел табарбыз, иншалла. Яме.

Басыйр. Ярар.

Сәләхетдин. Гарифә дә, асрау кыз булуга карамастан, Әкълимәбез кебек үк якын, үз кызыбызга тиң. Аның белән дә дорфа сөйләшмә.

Басыйр. Мин аның белән дорфа сөйләшәммени?! Итегеңне шулкадәре пычратып кайткансың дип бөтен кеше янында әйтмәсен.

Сәләхетдин. Ярар, кеше янында бүтән әйтмәс.

Хәбибә. Без сине яратабыз, Басыйр, сиңа яхшылык кына телибез. Аңлыйсыңмы?

Басыйр. Аңлыйм. Нишләп яратуыгызны гел тәкрарлап торасыз, шуны гына аңламыйм.

Хәбибә. Үзеңне тотышыңа җавап итеп кенә кабатлыйбыз. Сиңа бездә яшәү авыр түгелдер бит?

Сәләхетдин. Хәбибә, син андый сорау бирмә кешегә. Яшәү ул беркайда да авыр да түгел, җиңел дә түгел. Яшәү ул — яшәү. Чакыр Гарифәне, ашарга әзерләсен.

Басыйр. Үзем чакырам. *(Бер урында тыпырдап биеп ала да Гарифәне чакырырга чыгып китә.)*

Сәләхетдин. Тиз үсте бу малай, җегәрле егет булып җитеп килә бит.

Вилдан. Сез үзегезнең балаларыгыз белән бу кадәре үк мәш килмисез.

Сәләхетдин. Чөнки, улым, Аллага шөкер, син дә, Әкълимә дә тәртипле. Сез әле киләчәктә Басыйр белән дә бик тату булачаксыз, Алла боерса.

Хәбибә. Әй, улым, аның күңеле безне барыбер чит-ят итә икән, монда аны гаепләп булмый инде.

Гарифә аш пешерү бүлмәсе белән зур бүлмә арасында ризык ташып йөри. Басыйр самавыр куярга җыена, самавыр күтәргән килеш тыпырдап биеп ала — бу күренештән барысы да көләләр. Вилдан китап тотып узып китә.

Вилдан *(сыктанып)*. Шаулашмагыз. Болай да баш чатнап тора.

Басыйр *(аш пешерү бүлмәсеннән кычкыра)*. Синең имтихан бирәсең бар дип көлмәскә дәмени инде?

Вилдан. Ник эндәшәм шушыңа!

Хәбибә. Улым, башыңны бераз ял иттерсәң дә ярыйдыр.

Сәләхетдин. Әйе, җитеп торыр, ашаганнан соң дәвам итәрсең.

Басыйр. Һи, гыйлемле булам дип баш авырттырып йөр инде.

Гарифә. Синең үзеңә дә уку комачауламас иде.

Басыйр *(купайланып)*. Аллага шөкер, мин өйдә генә дә укырга-язарга өйрәндем инде. *(Гарифәгә.)* Ә син үзең ике ел Мәфтуха абыстайга укырга йөрдең, бер дә белем алган кешегә охшамагансың. Менә Әкълимәне алыйк — Мөштәриеваның мәктәбендә укуы кыяфәтенә чыккан!

Хәбибә. Басыйр, апа кеше белән шулай кырыс сөйләшмә инде.

Басыйр. Нинди апа булсын миңа Гарифә! Ике яшькә генә олырак, ул да асрамага алынган, мин дә. *(Биеп ала.)*

Гарифә. Нидән күңелең болай күтәренкеләнде?

Басыйр *(Гарифәгә ияреп, аны үчекләп йөри)*. Синең чыраең караңгы булганга сөенеп. Һи-һи-һи.

Гарифә *(читкә китеп)*. Уф, теле.

Сәләхетдин *(тыныч кына)*. Шаяруларның да чамасы булырга тиеш.

Басыйр *(тилберләнеп)*. Әйе, шулай, аңладым! *(Гарифә янына бара.)*

Гарифә *(аш пешерү бүлмәсенә чыга торган ишек янында туктап)*. Минем чыраем караңгымы?

Басыйр. Әйттем бит инде. *(Аларның сөйләшүен башкалар ишетми.)*

Гарифә *(ачулы)*. Агач тел!

Басыйр *(күзләрен челәйтеп)*. Ә менә безнең Әкълимә чибә-ә-ә-р. Ул Казанның иң гүзәл кызыдыр.

Гарифә. Мин ямьсезме? *(Чак кына елап җибәрми.)*

Басыйр *(өстенлек белән)*. Авызыңны чалшайтма. Миңа ямьсез карамаганда син дә хәйран чибәр.

Сәләхетдин *(гәҗитен читкә куеп)*. Әкълимәнең мәктәптән кайтканын көтеп тормабыз, утырып ашыйк.

Табынга утырышалар. Әкълимә атылып килеп керә.

Хәбибә *(куркып)*. Кызым, нәрсә булды? Төсең качкан.

Әкълимә *(кайгырып)*. Хәммәт Галәви вафат булган.

Сәләхетдин *(сикереп тора)*. Кит аннан!

Хәбибә. И Ходаем, каян ишеттең?

Әкълимә. Мәктәптә игълан иттеләр.

Хәбибә. Нәрсә булган? Ник үлгән?

Әкълимә. Белмим.

Сәләхетдин *(шәлперәеп)*. Нык чирләде ул соңгы вакытта.

Басыйр *(сагая)*. Кем ул?

Вилдан. Хәммәт Галәвиме? *(Нәфрәтле тавыш белән.)* Ишеттегезме, Хәммәт Галәвинең кем икәнен белми!

Гарифә. Белә лә ул, кылана гына.

Вилдан *(усал итеп)*. Урман кешесе!

Сәләхетдин *(җикереп)*. Вилдан!

Басыйр *(усалланган кыяфәт белән)*. Ә син...

Сәләхетдин *(кыҗрап)*. Вилдан! Авызыңа сугам хәзер! Бар, чыгып кит! Басыйр, кил монда. *(Үзен тыя.)* Хәммәт Галәви — татарларның зур фикер иясе, шагыйре. Ул алдынгы шәхесебез, алга, яктылыкка өндәүче татарыбыз. Яшь-яшь килеш бик шәп шигырьләр язган кеше. Ул да, синең кебек, ятим булган.

Басыйр. Аны ник үтергәннәр соң?

Сәләхетдин. Ә нишләп аны үтергәннәрдер дип уйлыйсың?

Басыйр. Яшь килеш үлгәч...

Сәләхетдин. Ул бик озак чирләгән. *(Хафалана.)* Ни... менә бит нинди кайгы... Барырга кирәк... Карале... шуны әйтмәк булам... Син Вилдан белән ачуланышма. Тату булыгыз. Ул синең абыең.

Басыйр *(битараф)*. Минем абыем юк! Минем беркемем дә юк! Хәммәт Галәви дә үлеп китте.

Хәбибә *(тавышын күтәреп)*. Бу хәтле әхлаксыз булырга ярамый инде!

Сәләхетдин *(ачуын көчкә тыя)*. Синең атаң-анаң да, абыең да, кыз туганың да бар. *(Кинәт кызып.)* Әле генә син мине чыгырымнан чыгардың! *(Боерулы тавыш белән.)* Бар, кече йортка чыгып тор! Марш!

Басыйр. Гарифә белән Әкълимә кереп бикләнә торган кече өйдә утырырга мин хайван түгел бит. Алар анда гел бикләнеп ниндидер серләрен сөйләшәләр, көләләр, гайбәт саталар, елыйлар.

Гарифә. Әләкче!

Басыйр *(ямьсез елмаеп)*. Аларның күз яшеннән ул кече өй дымланып беткән инде, һавасы тынчу анда.

Әкълимә *(тыртаеп)*. Безнең үз серләребез булырга да мөмкин.

Басыйр *(черәшеп)*. Егетләр турында сөйләшкәнегезне дә ишеттем.

Сәләхетдин *(ярсып)*. Күземнән югалып тор! Бар, ишегалдын себер! *(Басыйр чыгып китә.)*

Гарифә. Әләкче! *(Аш пешерү бүлмәсенә китә. Әкълимә киштәдән китап алып йокы бүлмәсенә юнәлә.)*

Хәбибә. Сәләхетдин, миңа Басыйрның үзен тотышы ошамый. Син аны алып кайту белән үк иркәләргә тотындың, аны үз урынын белерлек итеп тәрбияләү мәслихәт иде. Бәлки, аны берәр хәлле кешегә тапшырып булыр?

Сәләхетдин. Юк инде, аның язмышы өчен мин җаваплы. Башкарак ысуллар белән тәрбияләп карарга кирәктер.

Хәбибә. Үзен тәртипле тотсын өчен кичекмәстән чаралар уйлап тап.

Сәләхетдин. Бернинди чара уйлап табарга кирәкми, Хәбибә. Мин сиңа хәзер бер серне ачам. Басыйр атасына охшаган. Атасы экспедициядә булмаган аның. Аның атасы алты елга каторгага сөрелгән. Екатеринбургта полицмейстерны бомба шартлатып үтерергә маташканы өчен. Полицмейстер үзе исән калган, әмма дүрт кеше үлгән, җиде кеше җәрәхәтләнгән. Әнкәсе, баласын алып, ире артыннан киткән, Читага барып урнашкан, чөнки ире шуннан ерак түгел төрмәдә утырган. Атасы төрмәдән качарга маташканда атып үтерелә. Күп тә үтми, әнкәсе йөрәк авыруы белән вафат була.

Хәбибә. Шуларны белә торып алып кайттыңмы аны монда?

Сәләхетдин. Анасы Чита хастаханәсендә үлгәндә, малай шунда санитарлар бүлмәсендә булган. Табиб, жәлләп, моны өенә алып кайткан, малай шуларда яши башлаган. Аларның соңгы вакытта гаиләләре бик ишле иде — бөтен туган-тумачалары шуларда яшәде.

Хәбибә *(тәмам сүренкеләнеп)*. Син инде кызганучан кеше буларак ятимне монда кадәре алып кайтып китәргә булдың! *(Пауза.)*

Сәләхетдин *(сүзне тизрәк икенчегә борырга теләп)*. Хәммәт Галәви вафат булган диген, ә!

Караңгылык. Сәхнә яктыра. Әкълимә китап укып утырганда, Гарифә йөгереп керә.

Гарифә. Әкълимә! Әкълимә!

Әкълимә *(китабыннан аерылып)*. Нәрсә? Ут капты мәллә?

Гарифә. Ут кабар да. Син Басыйрның кем икәнлеген беләсеңме?

Әкълимә. Беләм.

Гарифә. Белмисең. *(Пышылдап.)* Ул кәтерҗән малае икән бит.

Әкълимә. Әй, Гарифә, синнән чыга инде җыен шундый куркыныч хәбәрләр. *(Янә китабына тотына.)*

Гарифә. Нишләп миннән чыксын! Мин ишеткәннәремне сөйлим.

Әкълимә. Кем әйтте сиңа бу яңалыкны?

Гарифә. Әти белән әнинең сөйләшкәннәрен ишеттем. Берүк бу ахмак кыз качып кына кеше сүзен тыңлый икән дип уйлый күрмә!

Әкълимә. Юк, юк, ничек инде мин синең хакта алай уйлыйм ди. Нәрсә ишеттең? *(Китапны читкә куя.)*

Гарифә. Ишек ябылып бетмәгән булган, сөйләшкәннәре ишетелеп торды. Әтиең әнкәйгә бер серне ачты: Басыйр кәтерҗән малае, диде.

Әкълимә *(пошамanga калып)*. Син моны чит кешеләргә әйтә күрмә.

Гарифә. Мине җүләр дип белдең мәллә! Кайчан минем читкә сүз йөрткәнем бар?!

Караңгылык. Сәхнә яктыра. Гаилә, Басыйрдан кала, залда җыелган. Барысы да тып-тын утыралар. Сәләхетдин ачуын көчкә яшереп арлы-бирле йөри.

Сәләхетдин. Басыйр — безнең гаиләбезнең тулы хокуклы әгъзасы! Атасы кәтерҗән булуда аның гаебе юк!

Вилдан. Дөрес, кәтерҗәннең дә төрлесе була. Караклар бар, нахакка сөрелгәннәре дә очрый, гаделсез хөкем ителгәннәре дә юк түгел. Ләкин бу бит кеше үтерүче малае икән.

Сәләхетдин. Тик кенә утыр! Аның атасы ялгыш идея белән саташып, революция хыялларыннан исереп җинаять юлына килеп эләккән кеше.

Хәбибә. Кешене идея буенча үтерсәң дә кеше үтерү бит инде ул.

Вилдан. Син, әти, үзең илдә тәртип булуын телисең, көн саен, нинди генә эшкә тотынсаң да, ил-көн дип сүз катасың. Ә монда бомба шартлатып империяне җимерергә йөрүчене акламакчы буласың.

Сәләхетдин. Мин җинаятьче революционерны якларга да, акларга да җыенмыйм. Фәкать баланың гаепсезлеген аңлатырга телим. Бәлки, Ходай аны безне сынар өчен биргәндер. Бәлки, атасы юлыннан китмәсен өчен без аны дөрес тәрбияләп, хак юлга бастырырга бурычлыбыздыр.

Хәбибә. Гарифә гел шуның аркасында елый.

Сәләхетдин. Гарифә ул артык нечкә күңелле. Басыйрның һәрбер вак-вак шуклыкларына игътибар итмәсә дә ярыйдыр. Син, Гарифә, мышык-мышык еларга тотынганчы, итагатьле итеп, алай ярамый, Басыйр, дип әйт. Өйдәге тәртипкә һәммәбез буйсынырга тиешлегебезне аңа әйбәтләп өйрәтеп торыгыз. Итеге пычранган дип, тир исе килә дип, кычкырып сөйләшмә дип тукып торуның, димәк, файдасы юк. Димәк, башкача мөгамәлә белән тәэсир итү мәслихәт.

Әкълимә. Әйе, чынлап та, ул бит инде бик күп кыргый гадәтләреннән арынды. Монда кайткан чагын, бәләкәй чагын хәтерлисездер бит?

Вилдан. Син бигрәк игелекле, кызганучан бала булдың инде!

Сәләхетдин. Улым, сеңлеңнең шундый сыйфатларга ия булуына сөенергә генә кирәк. Менә шулай, сөеклеләрем. Мондый сөйләшү кабатланмас дип ышанам. «Атаң кәтержән»,— дип әйтүчегә миһербанлы булмаячакмын. Кабатлыйм: Басыйр — безнең гаилә кешесе! Аның холкы, кылган гамәлләре, әйткән сүзе өчен хәзер инде үзебез дә җаваплы. *(Чыгып китә.)*

Вилдан *(ризасызлык белән)*. Әй, безнең эти гел шулай!

Хәбибә. Балалар, атагызның һәрбер фикере белән килешеп бетмәсәм дә, ул начарга әйтмәс. Әтиегез бик гадел кеше. Ул һәрвакыт гаделлек юлыннан барды. Әгәр дә ул кадимлектән арынып, гаиләне каты кул белән тотуның хәзерге заманда кирәге юк дип санап сезләргә күпмедер ирек биргән икән, моның кадерен белегез. Бу, улым Вилдан, бигрәк тә сиңа кагыла.

Әкълимә. Гарифә җаным, иреннәреңне турсайтма инде.

Гарифә, башын Әкълиманең иңбашына куеп, тавышсыз гына елый.

Әйдә, кече өйгә, икәүләшеп иркенләп елыйбыз.

Чыгып китәләр.

Вилдан. Гел шул кече өйгә бикләнеп елыйлар, серләшәләр, нәрсәдер пыш-пыш киләләр шунда.

Хәбибә. Кызлар шулай качып серләшәләр инде алар. Бигрәкләр дә кырыс инде үзең, улым. *(Елмаеп улының аркасыннан сөя.)*

**3**

1914 ел. Беренче бөтендөнья сугышы башланган. Казан. Акмуллиннар йорты. Вилдан сугышка китәргә җыена. Тып-тын утыралар.

Сәләхетдин. Шунысы өметләндерә: Германга без генә түгел, күп илләр каршы. Безнең союзникларыбыз да көчле.

Хәбибә. Бару белән үк утка кертмәсәләр ярый да.

Вилдан. Белмим, әнкәй, сугыш бит ул.

Хәбибә. Нишләп соң бармаска мөмкинлек була торып, афәт эченә атлыгасың?

Вилдан. Әнкәй, мин бармасам, тагын башка берәү бармаса... ни була инде? Кем империяне саклар? Ярый, Басыйрның күзе зәгыйфь, шуңа алмыйлар, аңлашыла торган хәл... Мин исә сау-сәламәт кеше.

Сәләхетдин. Бар, улым, бар. Безнең нәсел үз көче, үз акылы белән рәтле тормыш корган, мал туплаган. Аякта нык басып торган. Син бит шул мөлкәтебезне, нәселебез абруен да саклар өчен барасың сугышка. Патшага, илгә рәхмәтле булу да безнең бурычыбыз.

Басыйр. Вилдан, ачуыңны китергән чакларым өчен ярлыкагыл мине, яме. Тыштан күрсәтмәсәм дә, мин сине күңелемнән һәрвакыт якын иттем. Мин сине абыем кебек күрәм, моны ачыктан-ачык сиздермәсәм дә.

Вилдан. Рәхмәт җылы сүзең өчен, Басыйр. Син дә мине, үпкәләткән чакларым булса, кичер. *(Кочаклашалар.)*

Сәләхетдин *(торып баса)*. Кузгалыр вакыт. Аллага тапшырдык.

Вилдан биштәрен җилкәсенә аса, өйдән чыгып китә, барысы да аны озата китәләр. Караңгылык. Сәхнә яктыра. Җәй. Акмуллиннар гаиләсендә чәй вакыты. Сәләхетдин, Хәбибә, Әкълимә, Гарифә, Басыйр.

Сәләхетдин *(Басыйрга)*. Без хәзер икебез барып складларны тикшерәбез дә, аннары мин кондитер кибетләребезне карап килермен, ә син кием-салымныкына кагыл. Күпмелек сатылганның хисабын алып кайт.

Басыйр. Ярар.

Сәләхетдин. Иртәгә иртәрәк торып Әүхәдиләргә сугылырбыз, товар артыннан кайчанрак барырга исәп итә икән. Бу юлысы, бәлки, минем урынга сине генә җибәрермен.

Басыйр. Үзем генә каушамаммы соң?

Сәләхетдин. Бер дә каушаусыз булмас инде ул. Аның каравы Тобольскидан — Тушаковларны, Төмәннән Мурсалимовларны күрерсең. Алар бөтен Себергә дан тараткан купецлар. Аннан кайткач, Алла боерса, бәлки, Әстерханга да җибәрермен үзеңне — балык сәүдәгәре Капкаев янына. Сугыш михнәтләренә бирешмичә, бернигә карамыйча, коелып иңмичә, киңрәк колач җәю мәслихәт.

Басыйр. Безгә Мәскәүдәге татар купецларына караганда авыррак шул. Анда Гусмановлар, Бурнашевлар ду китереп яталар.

Сәләхетдин. Бүгенгесе көндә аларга да җиңел түгел. Авырлыкка килгәндә, торговый дом тоту җиңел була алмый — сугыш вакытында да, тынычта да. Ишмуратовлар, Апанаевлар да тырышып-тырмашып, авырлыклар кичеп дан казандылар. Безнең дә элемтәләр Себердән, Урта Азиядән узып,

Бурят иленә кадәр сузылды, Аллага шөкер. Булганны югалтмау турында түгел, арттыру, үстерү турында уйларга кирәк. Әйдә, киттек.

Сәләхетдин белән Басыйр «Аллаһе әкбәр» дип битләрен сыпырып табын яныннан кузгалалар. Чыгып китәләр.

Хәбибә. Элегрәк юкка борчылганмын икән. Аллага шөкер, Басыйрыбыз Сәләхетдингә зур ярдәмче булып үсеп җитте бит.

Әкълимә. Вилдан абыйның сугышка китүе дә аңа зур тәэсир ясады.

Гарифә. Әйе, күзгә күренеп үзгәрде ул.

Хәбибә. Барыбер безнең дөрес тәрбиябезнең нәтиҗәсе инде бу.

Әкълимә. Әтинең ышанычлы ярдәмчесе булып калгач, хәзер инде: «Ярый әле Басыйрыбыз бар»,— диясе генә кала.

Хәбибә. Гарифә, без синең белән Тәхлия апаларга барып кайтырбыз. Улы фронттан хат язды микән. Аның улы Шаһбан белән Вилдан бергә киткәннәр иде бит. Вилданның хатын алырга оныттырма. Аларга да укырбыз. Төрле полкларга эләккәннәренә Тәхлия кайгырыр инде. Кайтканда базарга кагылырбыз. Мөгаен, барганда ук керербез базарга — берәр күчтәнәч тә алып барыйк. Син, Әкълимә, безнең белән бармыйсыңмы?

Әкълимә. Юк, әнкәй, укыйсым күп. Барысына да миннән сәлам әйт.

Хәбибә. Ярар.

Хәбибә белән Гарифә чыгып китәләр. Әкълимә креслога утырып китап укырга тотына.Музыка. Әкълимә, укый торгач, йокыга китә. Басыйр кайтып керә, шыпырт кына кызга сокланып карап тора.

Басыйр *(пышылдап).* Әкълимә!

Әкълимә *(сискәнеп уяна).* Ә?!

Басыйр. Әкълимә!

Әкълимә. Йокыга киткәнмен.

Басыйр. Син йоклаганда тагын да чибәррәк икәнсең.

Әкълимә *(каушый, ни әйтергә белми, аптырагач сорап куя)*. Әти кайда?

Басыйр. Ул соңрак кайтачак. Мин тиз-тиз генә кием кибетебезне тикшердем дә, хисап кенәгәсен алып, базарга чаптым.

Әкълимә. Базарга ник бардың?

Басыйр. Хәзер белерсең. Базарда анаң белән Гарифәне күрдем, алардан качып башка тарафка йөгерергә туры килде.

Әкълимә. Нишләп «анаң» дисең. Нишләп син дә әнкәй димисең әнкәйне?

Басыйр. Әйе, әйе, әнкәй, әнкәй. Әнкәй белән Гарифәне күреп читкә тайпылдым. Базарга мин бүләк алырга дип бардым.

Әкълимә. Нинди бүләк?

Басыйр *(энҗе муенса бирә*). Сиңа бүләк алдым.

Әкълимә *(таң калып)*. Аһ! Энҗе муенса! Миңа... бүләк?

Басыйр. Әйе.

Әкълимә. Акча каян алдың?

Басыйр. Беркемгә дә белгертмичә, Әүхәди абыйлар чатындагы урыска утын ярдым.

Әкълимә. Кайчан?

Басыйр. Теге атнакичтә, сез җыелышып Тәхлия апаларда кунакта чакта.

Әкълимә *(читенсенә)*. Кирәк түгел мондый бүләк... тик торганда.

Басыйр. Мине үпкәләтергәме ниятең?

Әкълимә. Юк, юк, Басыйр, син нәрсә! *(Муенсаны ала.)*

Басыйр *(еш-еш сулый)*. Синең яннан үткәндә, минем сулышым каба.

Әкълимә *(курка)*. Нишләп?

Басыйр. Синнән ниндидер исертә торган хуш ис аңкый. *(Тезләнә, кызның кулын тота.)*

Әкълимә *(ялварып)*. Җибәр!

Басыйр. Синең кулың мамык кебек йомшак. *(Иреннәре белән кагыла.)*

Әкълимә *(куырылып кала)*. Булса ни... Аның каравы синеке тимер кебек каты. *(Кулын тартып ала.)* Миңа мондый бүләк кирәкми. *(Муенсаны кире бирә.)*

Басыйр. Ник син минем бүләгемнән баш тартасың?

Әкълимә. Куркам.

Басыйр. Кемнән, миннәнме?

Әкълимә. Юк, синнән түгел. Бу муенсаны каян алдың, дисәләр, әтигә, әнкәйгә ничек җавап бирермен?

Басыйр *(торып баса)*. Ярар алайса, мин аны сиңа аларның күз алдында бүләк итәрмен! *(Муенсаны алып чыгып китә.)*

Караңгылык. Сәхнә яктыра. Гарифә белән Әкълимә кунакка барырга җыеналар. Гарифә бер почмакта киенеп-ясанып тора, Әкълимә икенче почмакта үзен көзгедән карый.

Гарифә. Без Әүхәди абыйларда озак булабызмы соң?

Әкълимә. Юк, менә бу ике китапны кызларына кертеп чыгабыз да, аннары иркенләп Казан буйлап йөрербез. *(Чыгып китәргә җыенганда Әкълимә Гарифәнең муенындагы энҗе муенсага игътибар итә.)* Бу энҗе муенсаны каян алдың?

Гарифә *(каушап)*. Әй, минем бар иде бит инде ул.

Әкълимә *(муенсага карап)*. Гарифә, ник алдыйсың? Синең мондый муенсаң юк иде.

Гарифә. Син ул кешене белмисең.

Әкълимә *(кызып)*. Кемне белмим?

Гарифә. Муенсаны бүләк иткән кешене... Ул... минем бер таныш егетем...

Әкълимә. И Гарифә, Гарифә, алдый да белмисең бит син!

Гарифә *(оялып, башын читкә бора)*. Басыйр бүләк итте.

Әкълимә *(ярсуын көчкә тыя)*. Шул кешедән бүләк алдыңмы?!

Гарифә. Ник... Ул бит инде безгә чит-ят кеше түгел... Үзең дә гел шулай дисең.

Әкълимә *(көнләшә)*. Әйе, әйе... Ни... Син гафу ит, мин Әүхәди абыйларга бармаска булдым. Син генә илтеп кайт әле менә бу ике китапны, яме. *(Шкаф тартмасыннан ике китап алып өстәлгә куя.)*

Гарифә. Нәрсә булды сиңа, Әкълимә? Үпкәләдеңме миңа?

Әкълимә. Әйе, үпкәләдем.

Гарифә. Ничек үпкәләттем соң мин сине?

Әкълимә. Син мине алдарга теләдең. Күптәнге муенса дип алдамакчы булдың мине. Бер таныш егет бүләк итте дип тә алдарга маташтың. Шуңа ачуым чыкты. Мин синнән моны һич тә көтмәгән идем. *(Елый.)*

Гарифә *(аның тирәсендә бөтерелә)*. Зинһар, гафу итә күр, Әкълимә җаным! Каушадым, шундук әйтергә базмадым. Елама инде, шушы кадәр рәнҗерлек нәрсә түгел бит инде. Кичер мине, Әкълимә. *(Диванга утыралар.)* Күптәнге муенсам дип ялганласам да, барыбер мин сиңа кайчан да булса дөресен әйтми калмас идем, шулай бит. *(Елый.)* Мин бит сине сеңлем кебек яратам, минем сине моңарчы алдаганым булдымыни?

Әкълимә *(үзе елаудан туктап, Гарифәне юата башлый)*. Юк, юк, Гарифә, мин сине аңлыйм. Мин сине бик яратам. Шуны уйлап куйдым әле — Басыйр кыз кешегә бүләк ясый икән, бу аның күңеленең матурлыгы хакында сөйли.

Гарифә. Дөресен әйткәндә, мин аңардан бүләк алырга теләмәдем. Муенсадан баш тартсам, ул миңа карата тагын да дорфаланыр иде. Ә инде бүләген кабул иткәч, бәлки, мине кыерсытмый башлар. Бәлки, телен тыяр. Дөрес эшләгәнменме бүләген алып?

Әкълимә. Дөрес, дөрес, Гарифә. Энҗе муенса бик матур.

Басыйр шыпырт кына керә, тыңлап тора.

Гарифә. Ә мин Басыйрдан никтер барыбер бик куркам. Үзе төскә-биткә, буй-сынга чибәр егет ул...

Әкълимә *(Гарифә Басыйрны мактагач ачуы килә)*. Кәтерҗән малае булганга куркасың син аңардан. Нинди матурлык таптың син аның кыяфәтендә?! Аның үзенең дә кыяфәте кәтерҗәннеке. *(Кыланып күрсәтә-күрсәтә сөйли.)* Сыңар күзе акаеп тора... Ул борыны... Уф! Имәнгеч!

Гарифә *(көлә)*. Әкълимә, син бит аны гел мактый идең, яклый идең, аның белән тату идең.

Әкълимә. Мин аның күңеле кәтерҗәннеке икәнне аңламаганмын!

Гарифә. Әйдә кече йортка, берәрсе килеп кермәсен. Елаганыбыз күренеп тора.

Әкълимә. Хәзер. *(Үзен көзгедән карый, битен кулъяулык белән сөртә.)*

Музыка. Басыйр күзләрен йома, стенага ышкылып бер-ике адым атлый. Тумбочкага төртелә, андагы ваза төшеп тәгәри. Кызлар сискәнеп китәләр, Басыйрны күреп тораташ булып катып калалар. Басыйр, ярсуын көчкә тыеп кызларга карап торганнан соң, ишекне шапылдатып ябып чыгып китә.

Музыка көчәя.

## 4

1917 ел. Яз. Казан. Акмуллиннар йорты. Гарифә нәрсәдер чигеп утыра. Әкълимә сөйләшә-сөйләшә аның эшен күзәтә.

Әкълимә *(уфтанулы, тәүбәле тавыш белән)*. Басыйрның юкка чыкканына өч ел вакыт узды. Аның үпкәләп чыгып китүендә мин гаепле икәнне эти дә, әнкәй дә белмиләр. Шулкадәре зур гаеп хисе тоям үземдә.

Гарифә *(сыктанып)*. Әкълимә, җаным, без бит ярым шаярып, бер-беребезне тынычландырып кәефләребезне күтәрер өчен генә аның турында мыскыллырак сүзләр әйттек. Безнең бит күңелебездән аның турында начар нәрсә уйлаганыбыз булмады. Ул үзе нинди генә дорфа булса да, аның бөтен шуклыкларына, әшәкелекләренә һәрвакыт түздек, сабыр иттек. Син аны кәтерҗән малае, күңеле кәтерҗәннеке дигәнгә үпкәләп чыгып китте микәнни? Егет кеше бит инде югыйсә! Син бит аның үзенә әйтмәдең, миңа гына әйттең.

Әкълимә. Үзенә әйткән булсам, бәлки, күңеле алай ук каты җәрәхәтләнмәс иде. Без бит бигрәк, качып-посып сөйләштек. Җитмәсә әле, кыяфәтеннән, төс-битеннән мыскыл итеп көлдем.

Гарифә. Ә тыңлап тору егетлекме? Нишләп ул, шпион сыман, ике кыз сөйләшкәнне качып тыңлап торган? Тыңламасын иде! Ул синң гына үпкәләгәндер дип уйлыйсың мәллә? Хәтерлисеңме, миңа аның мөгамәләсе нинди иде? Ә Вилданга? Үпкәләсә, барыбызга да үпкәләгәндер.

Әкълимә. Бәлки, безгә үпкәләп чыгып китмәгәндер. Юк, юк, безнең сөйләшкәнне тыңлап торган бит ул. Нык үпкәләттем мин аны. Ләкин шул ук вакытта тынычландыра торган фаразым да бар — бәлки, иреккә сусап, безнең тормыштан туеп чыгып качкандыр. Кайларда икән ул?

Гарифә. Исән микән?

Хәбибә керә. Кулында хат.

Хәбибә *(боек)*. Вилданның соңгы хатын тагын укып чыктым әле.

Әкълимә. Фронтларында соңгы вакытта тыныч дигәч, бик сөенеч инде.

Хәбибә. Әй, сугыш бит ул, бүген тынлык, иртәгә мәхшәр булырга мөмкин.

Әкълимә. Аның подпоручик званиесен алуына эти нык сөенә инде.

Гарифә. Подпоручик зур исемме ул?

Хәбибә *(горур тавыш белән)*. Зур исем, офицер дигән сүз. Миңа аның исәнлеге кирәк. Бетәселәре бар микән бу сугышның?

Гарифә. Шуны уйлап куйдым әле — Басыйр да сугышта түгел микән? *(Хатны шкафка куя.)*

Әкълимә. Карале, чынлап та, бәлки, ул да үзе теләп сугышка киткәндер.

Хәбибә. Андый күз белән, үзе теләсә дә, алырлар микән, белмим.

Гарифә. Доброволецларны гарип булса да алалар дип ишеткәнем бар.

Хәбибә. Кайларга китеп югалды икән ул? Инде өч елдан артып китте бит юкка чыкканына. Нишләп алай кинәт кенә гаип булды соң ул? Бездән туйды микән? Үпкәләткән чакларыбызны кичермәде микән? Алай дисәң, монда аны тиктомалга кагучы булмады. Аннары, ул бит соңгы вакытта Сәләхетдиннең эшенә җиңел генә кереп китеп, зур ярдәмчегә әйләнгән иде. Күзгә күренеп яхшы якка үзгәрде, безнең дә аңа мөгамәләбез яхшырды. Сабый чагында бераз элеккәләде инде үзенә, ләкин алай гына Вилданга да, сезнең һәммәгезгә дә эләгә иде.

Гарифә. Юк инде, чыгып качардай итеп үк үпкәләтүче булмады. Киресенчә, үзе гел үпкәләтә иде әле безне.

Әкълимә яшертен кенә күз яшьләрен сөртә.

Хәбибә. Заманалар бигрәк болганып китте бит. Исән микән, балакай?

Гарифә. Төрмәдә түгел микән?

Хәбибә. Аллам сакласын!

Сәләхетдин кайтып керә.

Сәләхетдин *(кергән уңайга)*. Яңалык ишеттегезме?

Хәбибә *(сискәнеп)*. И Ходаем, тагын нинди яңалык?

Сәләхетдин. Патшаны бәреп төшергәннәр. *(Чишенә.)*

Әкълимә. Бәреп?!

Хәбибә. Ничек инде патшаны?.. Нишләгән патша?

Сәләхетдин. Кулга алганнар дип тә сөйлиләр, үзе тәхеттән баш тарткан дигән хәбәр дә бар.

Хәбибә *(иренә ияреп йөри)*. Хәзер нәрсә була инде?

Сәләхетдин. Белмим. Инде императорга да кул күтәргәч... белмим, нәрсәләр булып бетәр. Ахырзамандыр бу.

Гарифә *(шомлы тавыш белән)*. Кем патша була соң хәзер?

Сәләхетдин. Әле монысының язмышы билгеле түгел. Анда ниндидер Вакытлы хөкүмәт төзеп маташалар, ди.

Әкълимә. Сугыш бетәме хәзер... патшаны төшергәч?

Сәләхетдин *(кул селтәп)*. Белмим, белмим. Йөдәтмәгез!

Хәбибә. Кайларда бик озак йөрдең?

Сәләхетдин. Тагын полициягә кереп кызыксындым, Басыйрны эзләү буенча Читага запрос ясаттырдым. *(Диванга утыра.)*

Хәбибә *(янәшә утырып)*. Читага таба киткәндер дип уйлыйсыңмы?

Сәләхетдин. Ни уйларга да белгән юк инде. Аның бу тирәдә бездән башка беркеме дә юк. Доброволецлар исемлегендә дә табылмады.

Әкълимә. Бәлки, ул башка фамилия белән язылгандыр?

Ишек киерелеп ачыла. Сискәнеп китәләр. Вилдан кайтып керә. Өстендә шинель, башында фуражка, аягында күн итек. Бераз аксый. Аны танымый торалар.

Вилдан *(елмаеп)*. Здравия желаю! Нәрсә, яраланып кайткан кешене монда кабул итмиләрме әллә?

Әкълимә. Вилдан абый бит бу!

Хәбибә. Балакаем!

Сәләхетдин. Вилдан! Улым!

Гарифә. Вилдан! *(Йөгереп барып барысы да Вилданны чиратлашып кочаклыйлар. Күрешәләр.)*

Сәләхетдин. Күктән төштең мәллә син?! Чишен, чишен тизрәк.

Вилдан. Мондый аяк белән титаклап йөргәнче, күктә очып йөрү, бәлки, җиңелрәк булыр иде.

Дүртәүләшеп аның тирәсендә бөтереләләр, шинелен салырга ярдәм итәләр, элеп куялар. Вилдан фуражкасын салып Гарифәгә бирә, Гарифә хәрби фуражканы куркып кына ала, аны кая куярга белми аптырый, аннары тумбочка өстенә саклык белән генә китереп куя. Вилдан подпоручик формасыннан, түшендә ике медаль ялтырый.

Сәләхетдин *(улына сокланып карап тора)*. О-о-о, офицер әфәнде! Каһарман, каһарман, каһарман! Акмуллиннар нәселеннән бит син! Әйдә, әйдә, уз тизрәк. Алланың рәхмәте төшкере!

Хәбибә. Улым! Танымый торабыз. Шулхәтле үзгәргәнсең.

Вилдан. Сугыш аерым кешене генә түгел, дөньяның үзен үзгәртә.

Сәләхетдин. Китегез, китегез, юл бирегез. Утыр тизрәк, утыр.

Хәбибә. Улым, аксыйсың...

Вилдан. Әле ничек аягымны кисеп ташламадылар. *(Диванга утыра.)*

Хәбибә. Әй Ходаем!

Сәләхетдин белән Хәбибә Вилданның як-ягына утыралар, Әкълимә белән Гарифә, урындыклар алып килеп, каршысына урнашалар. Барысы да Вилданнан күзләрен алмыйлар.

Сәләхетдин. Димәк, яраландың, улым?

Вилдан. Снаряд янәшә генә шартлады. Күккә очып киттем дип торам — читкә томырылып төштем. Аңыма килгәндә, санитарлар күтәреп баралар иде инде. Күземне ачканымны күргәч, берсе миңа әйтә: ну, ваше благородие, бәхетегез бар икән, ди. Шул снарядтан алты кеше үлгән, берсен бөтенләй танырлык түгел, ди — гәүдәсе чәрдәкләнеп төрле якка чәчрәгән.

Әкълимә *(йөзен чытып еламсырый)*. Вилдан абый, сөйләмә, ичмаса!

Гарифә. Нишләп соң син кайтасыңны алдан хәбәр итмәдең?

Вилдан. Борчыйсым килмәде.

Хәбибә. Яралануыңны да белмәдек. Госпитальдә яттыңмы?

Вилдан. Әйе.

Сәләхетдин. Нишләп хәбәр итмәдең? Яныңа барган булыр идем.

Вилдан. Әйттем бит инде, алдан ук кайгыруыгызны теләмәдем. Аннары, хәзер бит ил буйлап йөрергә дә куркыныч.

Сәләхетдин. Анысы шулай. Патша турында ишеткәнсеңдер?

Вилдан. Ишеттем.

Сәләхетдин. Ул Временное правительство нишли алыр икән бу мәхшәрдә?

Вилдан. Анысы ярар. Анда әле ач этләр сыман большевиклар йөри. Алары фронтта да коткы таратып, солдатларыбыз арасында яман пропаганда алып баралар. Аларның листовкаларын укысаң син — җаның өшер.

Сәләхетдин. Белә-ә-әм, мин аларның гәҗитләрен дә укыганым бар.

Әкълимә. Әй, төкерегез әле шул җүнсез гәҗитләргә! *(Урындыгын абыйсына якынрак күчереп.)* Вилдан абый!

Вилдан. Карале, нинди гүзәл кыз булып өлгергән минем сеңлем.

Әкълимә *(оялып)*. Ярар, ярар.

Вилдан. Гарифәне карагыз әле сез!

Сәләхетдин. Кая, улым, яраңны күрсәт әле.

Вилдан. Башка вакытта, эти. Тәхлия апа ничек?

Сәләхетдин. Ничек булсын. Улы Шаһбаннан хат-хәбәр юк, ут йотып яталар.

Вилдан. Исән микән? Әсир төшмәде микән? Ә Әүхәди абыйлар?

Сәләхетдин. Безнең кебек, влач үзгәрүдән яхшы нәрсә көтми, каңгырап йөриләр.

Хәбибә. Әйдәгез, күңеллерәк нәрсәләр турында сөйләшик әле. Гарифә, чәй куй тизрәк!

Гарифә капылт кына чәй куярга керешә.

Сәләхетдин. Сәүдәгәрлекләре белән бөтен Россиягә даны таралган нәселебезгә тагын бер төрле дан өстәдең — офицер булып, герой булып кайттың. Афәрин, улым! *(Улының иңеннән кагып куя.)*

Вилдан *(көрсенеп)*. И, әти, илдә давыл күтәрелгәндә, геройлыкның кемгә кирәге бар?!

Сәләхетдин. Алай димә, алай димә! Үзебезгә кирәк! Нәселебезгә кирәк!

Хәбибә. Ил кайгысын син генә кайгыртып бетерә алмассың. Башың исән булуына сөенеп, алга таба яшик әле.

Караңгылык. Сәхнә яктыра. 1917 ел. Көз. Сәләхетдин гәҗит укый. Хәбибә аның янында утыра.

Сәләхетдин. Ахырзаман бу!

Хәбибә. Әй, ярар инде, соңгы вакытта һәрбер вакыйганы ахырзаманга юрыйсың.

Сәләхетдин. Ай-яй, моңлы башланган иде бу гасыр. Ай-яй, хәтәр гасыр булырга охшый бу. Бу гасырның кайгысын кичеп чыгарлык булырмы?!

Вилдан кайтып керә.

Вилдан *(чишенә, шинелен элгечкә элә)*. Ишеттегезме, Петроград большевиклар кулында икән. Смольныйга бәреп кергәннәр. Вакытлы хөкүмәтне бәреп төшергәннәр.

Сәләхетдин. Шуны укып утырам бит әле.

Вилдан. Менә күрерсез, байларның малын талап ярлыларга өләшәчәкләр.

Хәбибә. Ичмаса, син, улым, өйгә коткы кертмә!

Сәләхетдин. Ахырзаман бу!

Вилдан. Әти, әнкәй! Мин юлга кузгалырга тиеш. Фронттагы полкыбызның элекке командиры полковник Сидоренко бер кеше аша миңа хат җибәргән. Үзе янына чакыра, Харьковка. Большевикларга каршы көрәш игълан итәбез.

Хәбибә *(котсыз калып)*. Йөрмә, улым!

Вилдан. Юк, барам! Кызыл зараза бөтен илгә таралганчы, Казан да шул хәерчеләр хакимияте астында калганчы аларны туктатырга, хөкем итәргә кирәк!

Хәбибә *(газап белән)*. Җитешерсең әле. Ашыкма.

Вилдан *(катгый итеп)*. Өйдә ята торган заман түгел, әнкәй!

**5**

1918 ел. Илдә гражданнар сугышы бара. Көз. Казан. Акмуллиннар йорты. Гарифә бәрәңге әрчеп утыра. Басыйр кайтып керә. Күн плащтан, маузер белән, бүрегендә кызыл бант.

Басыйр. Исәнмесез!

Гарифә *(әкрен генә торып баса)*. Исәнме... сез...

Басыйр. Нәрсә, Гарифә, күзләреңне акайттың. ВЧК комиссарыннан бу кадәр үк куркырга кирәкми.

Гарифә *(бер кулында пычак, икенчесендә әрчи башлаган бәрәңге)*. Басыйр, синме бу?

Басыйр. Мин бу, мин, мин.

Гарифә *(бәрәңгесен, пычагын ташлап йөгерә)*. Әнкәй! Әнкәй! Басыйр кайтты.

Күрше бүлмәдән Хәбибә чыга.

Басыйр *(көр тавыш белән, бераз кыланыбрак)*. Исәнмесез, иптәшләр! *(Көлә.)*

Хәбибә. Басыйр, балакай! Синме бу?

Басыйр *(күз кырые белән көзгегә карап ала)*. Болай көзгегә караганда мин үземә охшаган кебек. Сезгә ничектер, белмим.

Хәбибә *(ике кулын сузып килә)*. Кайларда йөрдең, кайларга югалдың? *(Күрешәләр.)*

Басыйр. Замана бик өермәле, үзенә суырып алып китте.

Хәбибә. Нишләп беркемгә берни әйтмичә чыгып югалдың?

Басыйр. Сезгә обуза буласым килмәде.

Хәбибә *(шүрләбрәк артка чигеп шаккатып карап тора)*. Нишләп бер хәбәр дә бирмәдең шул гомердән бирле? Хәзер бит инде унсигезенче ел, син бит ундүртенчедә чыгып киткән кеше.

Басыйр. Әйе, дүрт ел узды.

Гарифә. Карале, бөтенләй үсеп, ир кеше булган. *(Ике куллап күрешәләр.)*

Хәбибә. Шул арада шушы хәтле олыгаймасаң. Самавыр куй, Гарифә!

Гарифә каушый, тыз-быз йөри башлый.

Басыйр. Гарифәне танырлык түгел. *(Бүреген салып тумбочка өстенә куя, плащын салмый, түргә уза.)* Ничек яшәп ятасыз?

Хәбибә. Элеккечә түгел инде. Дөньяның асты өскә килде бит. *(Басыйрның өстендәге киемен, кыяфәтен җентекләп күзәтеп.)* Син дә совет властен урнаштырып йөрисең бугай?

Басыйр. Әйе, мин зур кеше хәзер. ВЧК комиссары. Ни... башкалар кайда соң?

Хәбибә. Сәләхетдин Әкълимәне мәктәптән каршы алырга китте. Озакламый кайтып та җитәрләр.

Басыйр. Әкълимә һаман укымыйдыр бит?

Хәбибә. Ул инде үзе мөгаллимә, кызлар мәктәбендә укыта.

Басыйр. Алай икән. Ә Вилдан?

Хәбибә *(ничек дип әйтергә белми тора)*. Вилдан атасының сәүдә эшләре буенча Оренбургка таба чыгып киткән иде. Утыр инде, утыр. *(Өстәл янына утыралар.)*

Сәләхетдин белән Әкълимә кайтып керәләр.

Гарифә *(шатлык белән)*. Карагыз әле, кем кайтты!

Сәләхетдин *(шаккатып)*. Басыйр?!

Басыйр. Мин. Исәнмесез!

Сәләхетдин. Исәнме! *(Кочаклашып күрешәләр.)*

Басыйр. Исәнме, Әкълимә!

Әкълимә *(беравык өнсез калып тора)*. Исәнме!

Сәләхетдин. Кайларга китеп югалдың син? Без бит сине тәмам җуйдык.

Басыйр *(көлемсерәп)*. Мин югала торган кеше түгел.

Сәләхетдин. Кыяфәтеңнән күренеп тора. Син бит тау җимерердәй ир-егет булгансың. *(Басыйр тирәли әйләнеп чыга.)*

Басыйр *(елмаеп)*. Ничек соң эшләр, купец второй гильдии Акмуллин?

Сәләхетдин. Безнең эшләрнең хәзер ничегрәк баруы синең үзеңә дә мәгълүмдер.

Басыйр. Әкълимә, хәлләр ничек?

Әкълимә. Барыбызның да хәлләре бер чама инде. *(Нишләргә белми аптырап торганнан соң, диванга барып утыра.)*

Сәләхетдин. Сине эзли-эзли җаннарыбыз чыкты.

Басыйр *(кулларын як-якка җәеп)*. Менә бит табылдым.

Хәбибә *(Басыйрны аркасыннан сөя)*. Исән-сау икәнсең бит, исән-сау, балакай!

Гарифә өстәлгә самавыр китереп куя, шуннан соң ризык ташый.

Сәләхетдин *(тумбочкадагы кызыл бантлы бүрекне күреп)*. И-и-и, Басыйр, Басыйр, димәк, син кызыллар яклы?

Басыйр *(мәгърур тавыш белән)*. Күренмимени?

Сәләхетдин. Большевик тамы әллә?

Басыйр. Әлбәттә. Минем должностьта большевик булмый ярамый. Мин бит зур кеше хәзер. Менә Казан тирәсеннән акларны куып җибәрдек, тиздән алар тәмам җиңеләчәк. Яңа тормыш, яңа дөнья төзи башлыйбыз, иптәшләр!

Сәләхетдин *(басынкыланып)*. Иптәшләр... Яңа тормышны кан коеп, талап башлагач, ул яңа тормышлар ниндирәк булыр икән?

Басыйр *(коры гына)*. Кан коюны без башламадык. Талауга килгәндә... без байларны, капиталистларны, буржуйларны, купецларны башта байлыкларын халык белән бүлешергә өндибез. Теләмәгәннәргә генә көч кулланабыз.

Сәләхетдин *(җитди)*. Ә менә мин мал-мөлкәтемә үзем хуҗа булып калырга теләсәм, үзем теләгәнчә яшисем килсә, миннән дә талап алырсыңмы?

Басыйр. Әле синнән әйбер талау турында сүз катмадым бит.

Хәбибә. Инде безгә дә кагылсалар... Син, Басыйр балам, Сәләхетдиннең ничек тырышып-тырмашып сәүдәсен алып барганын үзең күреп үстең. Сәүдә йортын тотуның никадәр авыр икәнен үзең дә беләсең.

Сәләхетдин. Башкаларның да күбесе шулай үз тырышлыклары белән аякка бастылар, татар купецларының без барысын да беләбез.

Басыйр. Кибетләрең, складларың, базларың, товарың ни хәлдә соң?

Сәләхетдин. Әлегә барысы да ябык, барысы да бикле хәлдә. *(Кинәт кызып.)* Кеше малын талап яңа влач уңышка ирешә алмаячак, бу бит инде көн кебек ачык.

Басыйр *(көлемсерәп)*. Мин сезне сагынып кайттым, ә сез минем белән талау турында, влач турында сөйләшәсез.

Хәбибә *(әңгәмәне йомшартырга теләп)*. Юк, юк, Басыйр, син нәрсә! Без илдәге хәлләрне күзәтеп котсыз калдык. Большевикларның җитәкчеләре күрмиләр, аңламыйлар микәнни дип кенә әйтүебез.

Басыйр. Аңлыйла-а-а-ар. *(Елмая.)* Чәй эчәбездер бит?

Сәләхетдин *(җанланып)*. Әйе, әйе, әйдәгез, нәрсә катып калдыгыз? Әллә Басыйрның зур кеше булып кайтканыннан өнсез калдыгызмы? Басыйрыбыз кайткан! Үз кешебез бит ул! Безнеке бит ул!

Хәбибә *(чәй ясый)*. Безне яклар да әле, Алла боерса.

Сәләхетдин. Әлбәттә. *(Басыйрны иңеннән кага.)* Бер дә борчылмагыз. Басыйрыбыз исән-сау! Менә бит, шатлыклы вакыйгалар да юк түгел! *(Чәй эчәләр.)*

Караңгылык. Төн. Вилдан кайтып керә. Аяк очларына гына басып аш пешерү бүлмәсеннән ипи алып чыгып ашый. Икенче бүлмәдән шыпырт кына Басыйр чыга.

Басыйр *(караңгылык эченнән)*. Вилдан, синме?

Вилдан *(сискәнеп китә)*. Ә? Син кем?

Басыйр. Мин Басыйр. Шәмне яндыр. *(Вилдан шырпы сыза, шәмне табып кабыза, өстәлгә куя.)* Исән-сау кайтып җиттеңме?

Вилдан. Син монда нишлисең?

Басыйр. Сине көтәм.

Вилдан. Син, югалган кеше, каян килеп чыктың?

Басыйр. Мин, Вилдан туган, сезнең корпусны тар-мар иткән дивизиядә зур миссиямне үтәп йөрдем. Хәзер монда безнең хакимият урнашты. Каян килеп чыктың дип соравың бик сәер. Монда мине Байкал артыннан синең атаң Сәләхетдин алып кайтты. Онытtыңмыни?

Вилдан. Син бит инде китеп югалган идең.

Басыйр. Син дә бит югалгалап торасың. Ләкин әллә кая ерак югала алмассың, мин синең кайда нишләп йөргәнеңне бик яхшы беләм. Казан янында җиңелгәч, отрядыгыздан уналты кеше генә калып, Оренбург артына — казачий атаман Дутов ягына качтың. Күп тә үтмәде, менә кача-поса гына кире кайтып та җиттең. Дөрес әйтәмме, поручик Акмуллин?!

Вилдан. Син кем соң хәзер?

Басыйр. Минем фамилиям Гайнанов. Чын атамның фамилиясе бу. Мин большевик, ВЧК комиссары Гайнанов.

Вилдан. Мин сине бала чагыңнан ук яратмадым!

Басыйр. Әйе, шулай. Чөнки син Сәүдә йорты тотучы купец малае! Шуңа күрә минем ишеләрне яратмадың син. Ә сезне халык яратмый. Сезне якларга теләүчеләр дә бигүк юк.

Вилдан *(кызып)*. Ә сезне яклаучылар күпме? Җәй көне безнекеләрнең ике меңлек отряды кереп Казанны алды. Аларга бит нибары Вацетис җитәкчелегендәге 5 нче латыш полкының берничә ротасы каршылык күрсәтте. Бу сезнең Казан халкы алдында абруйсыз икәнлегегезне күрсәтте.

Басыйр *(кайнарлана)*. Ярар, сез җәй көне Казанны алдыгыз. Ә озак тота алдыгызмы соң Казанны? Күпме яттыгыз Казанда — бер аймы? Совет властеның абруе булмаса, шул арада зур гаскәр туплый алыр идекме? Тухачевскийларны, Берзиннарны җиңеп карагыз!

Вилдан. Казанны чехословак корпусының отряды саклады. Ә аларга мин беркайчан ышанмадым. Полковник Чечекка аңа Казан да, Россия дә, син дә, мин дә кирәк түгел. Чехословак корпусы бер тапкыр инде үз императорларына хыянәт иткән икән, актык тамчы канга кадәр монда көрәшәме инде?

Басыйр. Менә шул кая барып котылырга белмичә бәргәләнүче чехословак корпусы, Оренбург тирәсендә иснәнеп йөрүче атаман Дутов казаклары һәм шуның ише әтрәк-әләм генә көрәшә дә инде сезнең якта, ваше благородие!

Алар кычкырып сөйләшкәнгә, барысы да уянып берәм-берәм залга чыгалар.

Вилдан *(кычкырудан тыелып)*. Фронтта армияне капитуляциягә өндәвегез, патшага, хөкүмәткә, дәүләткә каршы сугыш игълан итәргә чакыруыгыз, ил мөлкәтен, кеше малын таларга тотынуыгыз җәзасыз калыр дип уйлыйсыңмы?

Басыйр. Поручик! Җәй көне Казанны алуыгыз стратегик яктан сезгә бигүк кирәк тә түгел иде, сезгә мондагы алтын запасы кирәк иде, шулаймы?

Вилдан. Әйе. Моны белүең бик әйбәт. Россиянең Казанда сакланган 651,5 миллион сумлык алтынын һәм 110 миллион кредит билетларын безнекеләр кулга төшереп Уфа тарафларына алып киттеләр.

Басыйр. Шулай булгач, кем ил мөлкәтен талаучы булып чыга?

Вилдан. Сезгә — властьны законсыз рәвештә алган кешеләргә эләксен идемени ул хәзинә?

Басыйр *(әрле-бирле йөреп)*. Фронттагы агитаторларны яманлыйсың. Ул дөнья сугышы кемгә кирәк соң — империядәге халыкларгамы? Миңамы, синең үзеңәме? Кемгә кирәк иде ул мәгънәсез кан коюю?

Вилдан. Алай уйласаң, бер сугышның да кирәге юк. Ләкин нинди генә сугыш булмасын, каршыңда дошман була торып, винтовкаларыңны үз дәүләтеңә таба бору — хыянәтнең иң әшәкеседер.

Басыйр. Димәк, изелгән, җәберләнгән халык бу дәүләтнең асылын аңлаган. Халыкның, армиянең түземлеге беткән.

Вилдан. Синең ишеләр котыртып, гамәлгә ашмас гүзәл тормыш вәгъдә итеп, надан халыкның башын бутый.

Басыйр. Безнең бәхәснең азагы юктыр шикелле.

Вилдан *(бәхәстән туя)*. Юк, без сезнең белән озак бәхәсләшмәячәкбез.

Басыйр. Син урнашып килүче Совет властеның көчен, максатын, җитдилеген әле аңламыйсың!

Вилдан *(тыныч кына)*. Мине сугышка озатканда әйткән җылы сүзләреңә ышанган идем мин. Алга таба, исән булсак, чын туганнар кебек булырбыз дип уйлаган идем. Ялгышканмын икән.

Басыйр. Мин бит әле сиңа бернинди начарлык эшләргә өлгермәдем.

Вилдан *(тагын кызып)*. Сез илне оятка, хурлыкка калдыручылар, сез илне җимерүчеләр, сез, империянең авыр халәтеннән файдаланып, изге төшенчәләрне таптап йөрисез. Фронтта мин бер большевикны солдатлар арасында агитация ясап йөргәне өчен чак кына атып үтермәдем, иптәшләрем ирек бирмәде. Ә бит сезне башта ук атып үтереп барырга кирәк булган.

Басыйр *(яман усал итеп)*. Син артык күп әйтеп ташламадың микән?

Хәбибә *(арага керә)*. Вилдан улым, нәрсә булды, ник ярсыйсың?! *(Ягымлы.)* Басыйр, якын итеп, безгә кайткан. Сөенергә кирәк.

Сәләхетдин *(күңел күтәренкелеге белән)*. Әйе, улым, алга таба бергәләп тату гына яшәү турында уйлыйк.

Вилдан. Без капма-каршы фронт кешеләре, без аның белән дошманнар.

Сәләхетдин *(ачулы)*. Син үзебезнең гаиләбездән дә дошман тапма инде.

Басыйр *(вәкарь тавыш белән)*. Әйе, без дошманнар! Син җиңелгән як вәкиле, ә мин җиңеп килүче власть вәкиле!

Вилдан *(кыҗрап)*. Шулаймы?! Мин хәзерге вакытта әсирме, әллә азатмы?

Басыйр *(авызын кыйшайтып)*. Үз ихтыярыңда.

Вилдан. Алайса, тату гына бергәләп яшәгез, ә мин киттем! *(Чыгып китә.)*

Хәбибә *(улының артыннан кычкыра)*. Вилдан! Улым! *(Өзгәләнеп.)* Сәләхетдин! Нәрсә, без хәзер үз улыбызны дошман итәбезме?

Сәләхетдин *(ярсып)*. Туктагыз әле! Беркем беркемне дошман итми!

Басыйр. Мине монда яшәргә кайтты дип уйлый күрмәгез.

Сәләхетдин. Яшә, яшә, нишләп инде монда яшәмәскә.

Басыйр. Минем төп эшем әлегә барыбер Мәскәүдә. Анда торыр урыным бар. Миңа хәзер кая барсам да торак мәсьәләсен уңай хәл итеп бирәләр. Вилдан мине сезгә бөтенләйгә кайткан дип уйлагандыр.

Хәбибә. Ул синең ЧКдан икәнеңне белгәч курыккандыр.

Басыйр. Курыккан кеше алай җикеренми ул. Ник курыксын! Мин аның хәтта документларын да тикшермәдем.

Сәләхетдин *(тынычланып)*. Ярар, үз хәлебездән килгәнне рәтләрбез. Уртак тел табарбыз, иншалла. Без барыбер бер гаилә.

Хәбибә. Таң атып килә инде.

Йокы бүлмәсенә кереп китә. Аның артыннан Гарифә китә.

Сәләхетдин. Шундый хәлләр диген... Шулай диген, җәмәгать! Бик моңлы башланган иде бу гасыр. Хәтәр гасыр булырга охшый бу. Бу гасырның кайгыларын кемнәр ничек кичеп чыгар икән? *(Икенче бүлмәгә чыгып китә.)*

Басыйр *(Әкълимәгә)*. Туңдыңмыни? Калтыранасың... *(Елмая.)*

Әкълимә *(бер урында тора)*. Басыйр. Мин... синең кайтуыңа бик шат.

Басыйр. Чын әйтәсеңме?!

Әкълимә *(калтыравыклы тавыш белән)*. Син юкка чыкканнан бирле, мин үземне гаепле санап яшәдем. Күңелемдә мең-мең кат Ходайдан һәм синнән гафу үтендем. Син мине ярлыкагыл, Басыйр!

Басыйр *(кызга таба атлый)*. Нинди гаебең бар соң синең минем алдымда?

Әкълимә. Гарифә белән минем бала-чагаларча сөйләшүебезне, шунда синең хакта дорфа сүзләребезне ишеткәч югалдың бит син.

Басыйр. Юк, Әкълимә, синең дә, Гарифәнең дә гаебе юк. Минем үземә тынчу була башлагандыр, чыгып китәр өчен сәбәп кенә кирәк булгандыр.

Әкълимә *(күз яшен сөртеп)*. Димәк, син мине кичерәсең?

Басыйр. Алай гына да түгел. Мин монда сине сагынып кайттым. *(Якын килә.)* Дүрт ел буена сине уйламаган көнем, сәгатем булды микән?! Мин бит сиңа күптәннән гашыйк. Белсәң иде сине ничек яратуымны. Син хәзер бигрәк тә чибәр, син тагын да затлырак, син тагын да гүзәлрәк!

Әкълимә *(артка чигеп)*. Басыйр, туктале...

Басыйр. Синең яраткан кешең бар мәллә?

Әкълимә *(башын иеп)*. Әйе, мин күңелемдә бер егетне йөртәм.

Басыйр. Кем ул?

Әкълимә. Ул да мөгаллим.

Басыйр. Мин сине яратам, Әкълимә! *(Кызның кулын тота.)* Беләсең килсә, мин сиңа ошар өчен михнәтләр кичә-кичә революция юлыннан киттем, кеше булырга, аякка басарга, бу дөньяда чүп-чар булып калмаска. Минем һәрбер максатым, һәрбер кылган гамәлем сине уйлап, синең өчен эшләнде. Мин хәзер абруйлы, зур кеше, миннән күпләрнең коты алынып тора. Бу бит әле чик түгел, әле үсәселәрем алда, әле алда бөек-бөек эшләр көтә. Әйдә язмышларыбызны бер-берсенә урап, киләчәккә кулга-кул тотышып атлыйбыз. *(Кочакламакчы була.)*

Әкълимә *(читкә тайпыла)*. Юк, Басыйр, алай гына булмый бит ул... Ничек аңлатыйм икән?..

Басыйр *(күзләрен чекерәйтеп)*. Син мине бәләкәй чакта ярата идең.

Әкълимә. Мин сине туганым кебек яраттым, асрамага алынган малайны яраткан кебек түгел. Хәзер дә син миңа туганым кебек якын. *(Бермәл Басыйрга карап тора.)* Дөресен әйткәндә, син миңа бала чакта ныграк ошый идең, чөнки син чынлап та кыргый, сәер, башка малайларга бер дә охшамаган идең, сине берәрсе ачуланса, гел яклый идем.

Басыйр *(гасабиланып)*. Миңа синнән башка беркем, бернәрсә кирәкми, миңа синнән башка бу революцияләрнең дә, хәтта дөньясының да кирәге юк! Әллә нәрсәләр әйттерәсең инде.

Әкълимә *(моңсу елмаеп)*. Син үзгәргәнсең, мәһабәт ир-егет булгансың, зур кешегә әйләнгәнсең, тик минә үсмер вакытта син кызыграк идең, үзеңә тартыбрак тора идең.

Басыйр *(кызны иңнәреннән кысып тота)*. Мин сине яратам, Әкълимә! Миңа кияүгә чык!

Әкълимә *(селкенә дә алмый)*. Басыйр! Тилердеңме әллә?

Басыйр. Мин сине сагынып чак кына акылымнан язмадым! Минеке бул! Күтәреп кенә йөртермен!

Әкълимә *(башын читкә борып)*. Юк, Басыйр! Бер-береңне ихтирам итеп, бер-берең белән гел күрешеп туганнарча гына да яшәргә мөмкин.

Басыйр *(исәрләнеп)*. Алай гына түгел! Син минем хатыным булырга тиеш! *(Үпмәкче була.)*

Әкълимә *(ычкынып бүлмәнең түренә бара)*. Тынычлан, Басыйр. Мин синең хатының була алмыйм.

Басыйр *(усаллана)*. Һаман кәтерҗән малае дип карыйсыңмы миңа?

Әкълимә *(Басыйрны үпкәләтүдән куркып)*. Юк, сиңа мин беркайчан да, элегрәк тә, хәзер дә кәтерҗән малае дип карамадым һәм карамыйм. Ир белән хатын булу өчен синең генә яратуың җитми.

Басыйр. Ә-ә-ә-ә... Шулай диген... Әйе, шулай инде, шулай... Ни... Әле сез белмисездер... Атаң Акмуллин Сәләхетдингә ЧКда материаллар тупланган. Совет властена каршы иң нык көрәшүче байлар исемлегендә күрдем мин аны. Чехословак корпусының бу тирәдәге частьларына азык-төлек ташыганы да мәгълүм, Оренбург янындагы атаман Дутов гаскәренә ярдәм итүләрен сорап үзенең дус сәүдәгәрләренә язган хатлары да чекистлар кулында. Казан купецларын, большевикларны инкарь итеп, контрреволюциягә ярдәм күрсәтергә өндәп йөргәнен дә беләләр. Улы Вилданның ак офицер икәнен инде күптән беләләр. Атаңны бүген-иртәгә кулга алулары ихтимал.

Әкълимә *(котсыз кала)*. Кулга алырлык нинди җинаять эшләгән соң ул?

Басыйр *(шомлы тавыш белән)*. Чутлап-уйлап карасаң, совет власте алдында аның җинаятьләре күп җыела. Ә менә мин сине хатынлыкка сорап, ул ризалык бирсә, аның язмышы уңай тарафка борылырга мөмкин.

Әкълимә *(нәфрәтләнеп)*. Юк! Бу — әшәкелек! Бу — этлек! Мине алай куркытырга ничек телең әйләнә? Куркытсаң да сиңа чыкмыйм! Хәтта атам-анам риза булса да. Хәер, алар беркайчан риза булмаячаклар! *(Чыгып китә.)*

## 6

Акмуллиннар йорты. Зал. Сәләхетдин борчулы кыяфәттә утыра. Хәбибә керә. Пауза.

Хәбибә *(шөбһәләнеп)*. Бик җитди сөйләшүгә чакырдың, ахрысы.

Сәләхетдин *(хатынына карамыйча)*. Әйе. Утыр. *(Пауза.)*

Хәбибә. Йә, сузма инде, болай да йөрәк урынында түгел.

Сәләхетдин. Басыйр Әкълимәне хатынлыкка сорый.

Хәбибә *(тетрәнеп)*. Әстәгъфирулла! Синең белән үк сөйләштеме әллә?

Сәләхетдин. Әйе.

Хәбибә. Нәрсә дидең?

Сәләхетдин. Вакыты ул түгел, дидем. Әкълимә инде ярәшелгән кыз, дидем.

Хәбибә. Корырак итеп, кистеребрәк итеп әйтергә идең. Карале, оялмыйча кызыбызның кулын соравын!

Сәләхетдин *(урыныннан кузгала)*. Әкълимәгә өйләнермен дип өмет баглап йөрүче теге мөгаллим дә җебегрәк шул.

Хәбибә. Ник, беткәнмени затлы егетләр. Кызыбызга әллә кемнәр кызыгып йөри.

Сәләхетдин. Әкълимә үзе ни дияр икән?

Хәбибә. Ни дисен! Басыйрның кем икәнен белмимени, аңламыймыни ул?!

Сәләхетдин. Кем икәнен дип... *(Бүлмә буйлап йөри.)* Басыйр бөтенләй үк адәм актыгы түгел инде. Башлы, куәтле, булдыклы булмаса большевиклар аны шундый должностька куймаслар иде. Мал-мөлкәтебез өчен калтыранып, үзебез өчен котсыз калып утырганчы... Басыйр киявебез булса, безгә бернинди куркыныч янамас дип уйлыйм.

Хәбибә *(еламсырап)*. Үзебезнең куркынычсызлыгыбыз өчен син кызыңның язмышы белән түләмәкче буласыңмы?

Сәләхетдин *(җикереп)*. Киреләнеп утырмасана! Коткы күбрәк синнән чыга! Безнең хәлебез чынлап та мөшкел, аңлыйсыңмы шуны?!

Хәбибә. Димәк, әле миңа барысын да сөйләмисең, нидер яшерәсең?

Сәләхетдин. Сөйләрмен. Сөйләп бетерермен. Вакыты җиткәч.

Хәбибә *(кырт кисеп)*. Кызыбыз Әкълимәне Басыйрга хатынлыкка бирүгә мин каршы! Бүтән кабатлап та тормыйм!

Сәләхетдин *(хатыны каршына килеп баса)*. Мин Әкълимәне Басыйрга бирү ягында! Син — каршы, мин — риза. Шулай итеп, Әкълимәнең үзенең сүзе хәлиткеч булачак.

Хәбибә *(ачынып)*. Ярар! Бик яхшы! Әкълимә үзе беркайчан риза булмаячак!

Әкълимә керә. Пауза.

Сәләхетдин *(йөзе яктыра)*. Кил, утыр, кызым.

Хәбибә. Кызым, атаңа әйт әле сүзеңне! Хәзер инде үзеңнән тора.

Сәләхетдин. Кызым, нишлибез?

Әкълимә *(бүлмә уртасында тора)*. Әти, сез риза булсагыз, мин риза.

Хәбибә *(сикереп тора)*. Юк! Кызым, акылыңа кил! Шушындый сылукаебызны... *(Елый.)*

Сәләхетдин *(диванга утыра)*. Аллага тапшырдык.

Хәбибә. Ә Вилдан? Вилданнан сорамадык бит әле!

Сәләхетдин. Вилдан безне аңлар.

Хәбибә. Басыйрны ул барыбер дошман итәчәк!

Сәләхетдин. Сеңлесенең ире булгач дошман итмәс.

Хәбибә *(елый)*. Ходаем!

Әкълимә *(анасына кушылып елый)*. Әнкәй, Басыйр безнең нәселгә җил-яңгыр тидермәс. Син бит күрәсең, безне яклаучы да, саклаучы да юк. Басыйрның яңа хакимияттә абруе зур. *(Әнкәсен кочаклый.)*

Басыйр керә. Хәбибә белән Әкълимә елаудан туктарга тырышалар.

Басыйр. Мөмкинме?

Сәләхетдин. Әйдә, әйдә, Басыйр, уз, утыр.

Хәбибә белән Әкълимә капылт кына икенче бүлмәгә чыгып китәләр.

Басыйр *(креслога утыра)*. Синең «дело» белән безнең кешеләр шөгыльләнә, мин иртәгә үк алар белән сөйләшермен.

Сәләхетдин. Син аларга аңлат, мин бит акларга илдәге анархиядән куркып, тәртип урнашсын өчен ярдәм иттем. Миңа чех корпусы ни, аклар ни, кызыллар ни, Дутов ни, Тухачевский ни! Минем дус-ишләрем, туган-тумачам өчен дә шулай.

Басыйр *(салкын тавыш белән)*. Хәзер инде тегесе ни, бусы ни диярго ярамый. Йә бер яклы, йә икенче яклы буласың.

Сәләхетдин *(Басыйрга текәлеп карап торганнан соң)*. Ә чын власть урнашып, сезне җинаятьчеләр дип хөкем итә башласалар?

Басыйр *(тимер тавыш белән)*. Юк, хаклык безнең якта, шуңа күрә без генә хөкем итәчәкбез. *(Кинәт елмая.)* Ярар, никах турында ничек соң?

Сәләхетдин *(сәерсенгән булып)*. Сине нишләп никах кызыксындыра? Сез, большевиклар, Аллага ышанмыйсыз түгелме?

Басыйр *(көлемсерәп куя)*. Электән килгән нәрсә бит инде. Сезгә дә бераз ярарга тырышасым килә.

Сәләхетдин. Коммунизмда гаиләләр бетереләчәк, ди бит. Ә син гаилә корырга җыенасың...

Басыйр *(урыныннан кузгала)*. Коммунизмны аны әле төзисе бар. Син алай чәнечкеләп сөйләшмә инде.

Сәләхетдин *(торып баса)*. Ярар. Вакытын билгеләрбез. Аллага тапшырдык!

Шунда ук. Төн. Яшертен генә Вилдан кайткан. Сәләхетдин, Хәбибә боегып утыралар, Вилдан әрле-бирле йөри.

Вилдан *(кулларын селтәп ачулана)*. Нишләдегез сез, аңламыйм?!

Хәбибә. Инде мин дә ялвардым, елый-елый күз яшьләрем бетте.

Вилдан. Әти! Әкълимәне шул кешегә бирдеңме?

Сәләхетдин. Кирегә юл юк инде. Әкълимә аңа үзе теләп чыкты. Безгә бу мәхшәрдән исән-сау калуны кайгыртырга кирәк. Мин дә, син дә аларның дошманнары исемлегендә. Басыйр минем эшне туктаттырырга вәгъдә бирде. Сине дә хөкемгә тарттырмас. Ул берсекөнгә Мәскәүдән Казанга минем эш буенча махсус кайтырга тиеш.

Вилдан. Миңа шәхсән аның ярдәме кирәк түгел! Мин барыбер аларга каршы көрәшәчәкмен!

Сәләхетдин. Басыйр әйтте: Вилданның әле һаман иректә булып, монда китә-кайта йөри алганына миңа рәхмәт әйтегез, диде.

Вилдан *(ярсып)*. И-и-и, алама токым! Ни дигән була икән бит! Син, әти, шундый көчле ихтыярлы, аягыңда нык басып торган кеше, кыска гына вакыт арасында күзгә күренеп шәлберәйдең!

Сәләхетдин *(тонык тавыш белән)*. Мин күбрәк синең өчен, сезнең өчен, нәселебез өчен куркам.

Хәбибә. Чыннан да, улым, гел шулай качып ятмассың бит инде. Берәр җирдә үтереп ташласалар үзеңне?

Сәләхетдин. Синең кебекләрнең адым саен документларын тикшерәләр, беләсең бит инде.

Хәбибә *(йөзе чак кына яктырып китә)*. Бәлки, качып йөрмәскәдер? Вилданыбызның нинди начарлыгы тиде соң большевикларга?

Сәләхетдин *(усал)*. Син анысын большевикларның үзеннән барып сора!

Хәбибә *(сыкрап)*. Син күзгә күренеп кырыслана барасың. Соңгы вакытта миңа гел җикерәсең.

Сәләхетдин. Аның аклар армиясенең поручигы икәнен белсәләр, беләсеңме, нишләтәләр? *(Пауза.)* Ярар, тора-бара Басыйр җайлар әле. Вилдан гына түгел, әллә кемнәр сугыша аклар ягында. Туган туганга каршы сугыша бүген.

Вилдан. Мин Колчак армиясенә китәм! Омскида аларның штаблары.

Хәбибә. Ничек була инде бу? Әкълимә Басыйр белән Мәскәүдә — кызыллар ыстанында, син Омскида — аклар ягында буласыңмы?

Сәләхетдин *(көр тавыш белән)*. Улым, үзеңә кара, үзең хәл ит.

Вилдан *(сәгатькә карап)*. Таң атарга күп калмады. Миңа китәргә кирәк. Себер якларына китәр алдыннан әле мин кайтып күренермен. *(Чыгып китә.)*

Караңгылык. Сәхнә яктыра. Акмуллиннар йорты. Өйнең асты өскә килгән. Әйберләр, киемнәр тәртипсез рәвештә аунап ята. Гарифә елап утыра. Вилдан кайтып керә.

Гарифә *(җан ачысы белән)*. Вилдан!

Вилдан *(кычкырып)*. Нәрсә булды? Әти кайда, әнкәй кайда?

Гарифә *(елый-елый)*. Алты кеше килеп өйне тентеделәр, әтине кулга алдылар. Синең хакта бик нык төпчеделәр.

Вилдан. Әтине алып киттеләрме?

Гарифә. Алып киттеләр.

Вилдан. Әнкәй кайда?

Гарифә. Әнкәй: «Сәләхетдин, мин синнән калмыйм»,— дип, үзен дә алып китүләрен үтенде.

Вилдан йөгереп чыгып китә.

## 7

Караңгылык. Сәхнә яктыра. 1919 ел. Көз. Казан. Акмуллиннар йорты. Вилдан, Гарифә, Басыйр, Әкълимә утыралар. Әкълимә яңа туган баласын кочаклаган.

Вилдан *(Басыйрга кычкыра)*. Берегезгә дә җил-яңгыр тигезмәм, дип вәгъдә биргән иден бит син! Казан чекистлары минем сүзне тыңлыйлар, дидең!

Басыйр *(басынкы)*. Мине Мәскәүдән җибәрмәделәр. Анда көнаралаш диярлек фетнәләр калкып торды, хәзер дә шулай. Көньяктан Мәскәүгә таба Деникин гаскәрләре үрмәләгәч, эшләрем анда тагы да тыгызланды. Көзгә таба Деникинны куа башлагач кына, ниһаять, менә кайтырга мөмкинлек туды.

Вилдан. Син әти белән әнкәйнең язмышына бөтенләй битараф булдың!

Басыйр *(тавышын күтәреп)*. Ә син Колчак гаскәрендә рота белән командалык иткән кеше. Инде Казанга якын ук килеп җиткән идегез бит, ник үзең атаң-анаңа ярдәм италмадың соң?

Вилдан. Казанны алган булсак, мин аларны коткарыр идем. *(Әкълимәгә таба борылып.)* Ә син, Әкълимә, ничек анда Мәскәүдә тыныч кына ята алдың?

Гарифә *(көтмәгәндә җикерә)*. Нишләсен ул, шунда ятмыйча! Йөкле килеш нишләргә тиеш ул?! *(Шундук һушына килеп авызын учы белән каплый.)*

Әкълимә *(кайгылы)*. Аларның икесен берьюлы атып үтергәннәрме соң?

Вилдан *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Башта әтине, шундук әнине дә.

Әкълимә *(өзгәләнеп)*. Ышанмыйм, ышанмыйм, ышанмыйм!

Вилдан. Төрмәдә эшләүче Вәгыйз атлы кеше үзе күргән.

Әкълимә *(күзләрен йомып артка кайшала)*. Үлә-ә-ә-әм.

Гарифә *(атылып килә)*. Әкълимә, җаным! *(Баласын ала.)*

Басыйр. Атаң ЧК комиссарының битенә төкергән. Шуңа теге атып җибәргән.

Әкълимә *(иңрәп)*. Җитте! Сөйләмә!

Вилдан *(Басыйрга якын килеп)*. Кая закон? Кая гадел хөкем? Бу нинди вәхшилек?! Минем әти дә, әнкәй дә бер гаепсез кешеләр, кешегә начарлык эшләү түгел авыр сүз дә әйтми торган кешеләр! Нәрсә бу?! Нишлисез сез?!

Басыйр *(юашланып)*. Мин белми калдым. ЧКда да төрле кешеләр бар.

Вилдан *(йодрык төйнәп)*. Кешеләр?! Сезне кешеләр дип атап буламы?

Басыйр *(кинәт усалланып)*. Кешеме мин, юкмы — син хәл итә торган фәлсәфә түгел, поручик!

Гарифә *(торып Вилдан белән Басыйр арасына керә)*. Вилдан, бәйләнмә!

Басыйр *(тыныч, ләкин янаулы тавыш белән)*. Син, Вилдан, яхшы чакта кит тизрәк. Мәгълүм ки, Колчак гаскәрләрен Себер буйлап куып йөриләр, Деникинны көньякка таба кыйный-кыйный этәләр. *(Күзләрен кысып.)* Син нишләп үз тарафдарларың белән Дальний Востокка таба элдермәдең? Монда фетнә әзерләү эшләре белән калдыңмы?

Әкълимә *(Басыйрның нәфрәтләнүен күреп, абыйсы өчен курка)*. Вилдан абый, кит!

Вилдан чыгып китә.

Басыйр *(кузгала)*. Тынычланыгыз. Үлгән кеше артыннан китеп барып булмый. Яшәргә кирәк. Мин барысын да ачыклармын. Гаеплеләрне җәзага тарттырачакмын. Мин бүген соң кайтырмын. *(Чыгып китә.)*

Караңгылык. Сәхнә яктыра. Акмуллиннар йорты. Өйдә Гарифә һәм баласын тотып Әкълимә утыралар. Вилдан кайтып керә, кыяфәте йончыган, еш-еш сулый, кабалана.

Вилдан. Басыйр кайда?

Әкълимә *(торып баса, куркып карап тора)*. Кайтып җитәргә тиеш.

Вилдан. Җыеныгыз! Тизрәк!

Әкълимә. Кая?

Гарифә *(Вилданнан күзен алмый)*. Әй Ходаем!

Вилдан *(нәрсәгә тотынырга белми)*. Әкълимә! Гарифә! Монда беребезгә дә калырга ярамый. Алар беребезне дә кызганмаячак. Әти белән әнинең башына җиткәч, безне генә калдырырлар дип уйлыйсызмы әллә?

Әкълимә. Кая качабыз соң без?

Вилдан *(шкафта актарынып)*. Сембергә акларның һөҗүме булырга тиеш. Без Идел буйлап, су юлы белән Сембер аша Саратовка барып җитәргә тиешбез. Аннан Царицынга ерак түгел. Краснов гаскәренә иярербез.

Әкълимә. Ничек? Бала белән!

Вилдан *(кесәсенә ниндидер кәгазьләр тыга)*. Курыкма. Без үзебез генә түгел. Безнең белән тагын ике офицер гаиләсе булачак әле. Документлар әзер. Гарифә, нишләп катып торасың? Бернәрсә дә алмыйбыз! Киттек!

Гарифә. Әкълимә! Мин калам. Вилдан! Мин йортны ташлый алмыйм. Мин сезгә асрама булып килгән кеше, миңа тимәсләр, җәберләмәсләр. Мин йортны саклыйм, сез бит әле барыбер кайчан да булса бер кайтачаксыз.

Вилдан. Ярар, Гарифә, барысы өчен дә рәхмәт сиңа.

Гарифә Әкълимәне кочып елый.

Әкълимә. Гарифә җаныкаем!

Гарифә. Әкълимә! Басыйрга нәрсә диярмен?

Әкълимә. Басыйр сораса, безнең чыгып киткәнне күрми калдым, диген.

Вилдан. Булды! Кузгалдык!

Вилдан, Әкълимә баласын күтәреп чыгып китәләр. Гарифә, котсыз калып, бүлмә уртасында басып тора. Музыка.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### 1

1938 ел. Төркия. Истанбул. Азан тавышы ишетелә. Төрекчә музыка яңгырый. Аннары төрекчә сөйләшкән тавышлар ишетелә. Әкълимә, аның улы Илбәк үз йортларында фоторәсемнәр карап утыралар.

Әкълимә *(сагышлы)*. Кырымда төшкән фоторәсемнәребез генә бар шул. Нәселебез фотолары Казанда калды. Врангель армиясе белән Кырымга барып җиткәндә, сиңа бит әле бер яшь тә тулмаган иде.

Илбәк *(бер фотога күрсәтеп)*. Менә монсы нинди рәсем?

Әкълимә. Бу Новороссийскидан Кырымга эвакуация алдыннан.

Илбәк. Шунда да фотога төшәргә мөмкинлегегез бар идеме?

Әкълимә. Вилдан абыйның полкташ офицеры командующий аппаратында абруйлы кеше иде. Шул төшертте. *(Фоторәсемнәрне аралап.)* Ярый әле Вилдан абый гел янәшәдә булды. Исән калмас идек.

Илбәк *(фотога ымлап)*. Бу фото кайда төшелгән?

Әкълимә. Монсы Кырымда. Менә монсы инде Төркиядә, Галлиполида. Күрәсеңме сине нәрсәгә төргәнбез — шинель кисәгенә.

Әкълимәнең ире Мәхмәт портфель тотып кайтып керә.

Мәхмәт *(көр тавыш белән)*. Хәерле кич!

Әкълимә *(ягымлы итеп)*. Хәерле кич, Мәхмәт!

Илбәк *(фото карый-карый)*. Хәерле кич!

Мәхмәт. Тагын фотосурәтләрегезне карап утырасызмы?

Әкълимә. Әйе. Шуларны караган саен, ничекләр исән калганыбызга шаккатып сөенеп туя алмыйм.

Мәхмәт. Инде 1938 ел җитте, ә син һаман исән калуыңа шаккатып утырасың. *(Портфелен стена буена куя. Ул да фотолар карарга тотына.)*

Әкълимә. Мин күбрәк улым Илбәкнең исән-сау калуына куанып шаккатам. Үзем дә инде... күкрәк сөте имүче баламны күтәреп, Казаннан качып, Төркиягә кадәр барып җиттем.

Мәхмәт. Абыең Вилдан шундый авантюрист булгач.

Әкълимә. Юк, юк, Вилдан абыйга рәхмәттән башка сүз юк. Әти белән әнкәй харап булгач, барыбер анда кала алмас идек.

Илбәк *(бер фотога төртеп күрсәтә)*. Бу Истанбул түгел бит?

Әкълимә. Истанбул түгел, Бурса каласы. Мәхмәт белән шушы калада таныштык. Сине Истанбулда, танышларымда калдырып торган идем, дүрт яшь иде сиңа ул вакытта.

Илбәк. Хәтерлим, хәтерлим. Кемнәрдә калдырганың да исемдә — синең белән бергә тәрҗемәче булып эшләүче апаларда.

Әкълимә. Бурсадан инде Мәхмәт белән парлашып кайттык. «Нинди ямьсез мыеклы абый!» — дип, яратмыйча йөргәнеңне дә хәтерлисеңдер әле.

Илбәк. Хәтерлим.

Көләләр.

Мәхмәт. Әниеңне Бурсада яшәргә күндерә алмадым, күпме ялындым — улыңны барып алып килик тә шушында яшик дип. Юк, аңа Истанбул гына кирәк булды.

Әкълимә. Истанбул — интернациональ шәһәр. Россиядән күчкән кешеләр күп булганга монда күңелем тартты. Туган җирне сагыну беренче елларны бигрәкләр дә көчле иде бит. Аннары шушы калада мин чын мөгаллимә, тәрҗемәче була алдым.

Мәхмәт *(шаярып)*. Ә мин — Бурсадагы атаклы университетның тарих кафедрасын җитәкләгән атаклы Мәхмәт Доган — әнкәң аркасында Истанбулга килеп гади тарихчы гына булып калдым.

Әкълимә *(шаяруга кушылып)*. Гади тарихчы гына түгел, Россиядән качкан мөгаллимәнең ире булып күтәрелдең.

Көләләр.

Менә, улым, Мәхмәт бәй белән бергә төшкән рәсемегез.

Фотоны җентекләп карыйлар.

Мәхмәт. Илбәккә ничә яшь монда?

Илбәк. Унике.

Әкълимә *(уйга калып)*. Унике микәнни?

Илбәк. Утыз беренче елгы фото бит.

Әкълимә. Әйе шул. *(Илбәкне аркасыннан сөеп.)* Сиңа, улым, унтугыз тула бит инде.

Вилдан керә. Кара кәчтүмнән, ак күлмәкле, галстук таккан. Кыяфәтендә җитди ыспайлык. Бераз аксый.

Вилдан *(мәгърур кыяфәт белән)*. Сәламаләйкум!

Мәхмәт *(сөенеп)*. Вәгаләйкумсәлам!

Әкълимә *(канатланып)*. Вилдан абый!

Илбәк. О-о-о, Вилдан абый, исәнме! *(Атылып килә.)*

Мәхмәт. Хуш килдең, Вилдан бәй! *(Күрешәләр, кочаклашалар.)*

Әкълимә. Әйбәт кенә килеп җиттеңме?

Вилдан. Тоткарланулар булды. Европа киеренкелектә бит хәзер.

Мәхмәт. Киеренкелектә булмый — сезнең Германиягез барысының да котын алып тора.

Әкълимә. Нишләп Вилдан абыйның Германиясе булсын ул?

Вилдан. Дөрес әйтә, дөрес. Минем Германияне яратуымны аңлап әйтә ул.

Мәхмәт. Син ачуланма, Вилдан, шулай да Гитлерыгыз ут белән шаяра.

Әкълимә. Вилдан абыйга «Гитлерыгыз» дип әйтмә инде.

Вилдан. Әйтсен. Минем нинди хезмәттә икәнемне чамалап әйтә ул. Вәләкин, Мәхмәт бәй, синең күп белүең, артык күп аңлавың үзеңә берәр кайчан хилафлык китермәгәе. Син, тарихчы буларак, анализлый беләсең, күп укыйсың, күп кызыксынасың, тик шулай да киңәшемә колак сал — күп сөйләшмә. Кайбер күргән-аңлаган нәрсәләрне сизмәмешкә салышсаң кулайрактыр.

Мәхмәт *(елмая)*. Ярар, ярар, бөтенләй урынсызга кызыбрак киттең әле.

Вилдан *(түргә утыра)*. Илбәк энем, хәл-әхвәлләр ничек?

Илбәк *(абыйсыннан күзләрен алмый)*. Ярыйсы.

Әкълимә. Миңа ярдәм итәм дип, укуын ташлап, тәрҗемә эшенә чумды.

Илбәк *(җитди кыяфәт белән)*. Керемле эш.

Вилдан. Соңгы вакытта нәрсәләр тәрҗемә итәсез соң?

Илбәк. Күп анда. Нәшрияттан гел шылтыратып торалар.

Әкълимә. Фоторәсемнәрне карап, хатирәләргә бирелеп утырдык әле.

Мәхмәт. Хатирәләргә бирелмәгән, күз яше тамызмаган көне юк инде Әкълимәнең.

Әкълимә *(моңсу)*. Ничек хатирәләргә бирелмисең, Вилдан абый! Кырымга качуыбызны, Врангель армиясен, генерал Кутепов корпусын, Галлиполидагы ыгы-зыгыларны син дә гел искә аласыңдыр.

Вилдан. Ул михнәтләр көн саен диярлек төшләремә кереп йөдәтә.

Мәхмәт. Югыйсә үзең күпне күргән кеше, ә үзең нацистларга хезмәткә кергәнсең. Ул Гитлер әле әллә нинди михнәтләр күрсәтмәгәе.

Вилдан. Мин нацистларга хезмәт итмим. Мин большевикларга каршы хезмәт итәм. Минем бүгенге эшчәнлегем — Россияне канга батырган, ата-анамны үтергән канечкечләргә каршы көрәшү. Германия җәберләнгән халыкларны яклаячак. Большевикларга каршы көрәшер өчен кирәк миңа Германия.

Мәхмәт. Гитлер большевиклар белән уртак тел тапты түгелме?

Вилдан. Минемчә, бу вакытлы гына.

Мәхмәт. Нацизм белән большевизмның асыллары бер үк ләбаса.

Вилдан. Юк! Нацистлар үз халкын канга батырмый, төрмәләргә тутыртмый. Ә Россиядә большевиклар үз халыкларының канын койды һәм хәзер дә дәвам итә. Син беләсеңдер, совет илендә нинди режим урнашканын?

Мәхмәт. Беләм. Анда инде төрмәләре тулгандыр.

Вилдан. Минем Илбәк белән бергә-бер калып сөйләшәсем килә. *(Әкълимә белән Мәхмәт икенче бүлмәгә чыгып китәләр.)*

Вилдан *(паузадан соң)*. Карале, ә, нинди егет булып үсеп җиттең бит!

Илбәк *(дәрт белән)*. Кайчан мине Германиягә алып барасың инде?

Вилдан. Алып барырмын. Син шунда яшәячәксең, кешечә яшәячәксең, ә инде вакыты җиткәч, Казанга кайтачакбыз, коммунистлардан азат ителгән илебездә торачакбыз. Үз гомеремдә моны күрүгә ирешермен, иншалла. Моның өчен без һәрберебез, хәленнән килгәнчә, көрәшергә тиеш. Большевиклар башлаган сугыш дәвам итә. Акмуллиннарны, минем ата-анамны, синең әби-бабаларыңны харап иткән кешеләр безнең туган илебездә хуҗа булып, тантана итеп яшәп яталар, ә без исә чит җирләрдә каңгырап йөрергә мәҗбүрбез.

Илбәк. Мәхмәт бәй, СССРны таркату, аны җиңү мөмкин түгел, ди.

Вилдан. Ул акыллы кеше, ләкин ялгыша. Тарихчылар гел ялгышалар.

Илбәк. Бергә-бер калып миңа әйтер сүзең шушымы?

Вилдан. Юк, бу гына түгел. Син анаңның нинди авырлыклар кичергәнен дә, башына нинди кайгы төшкәнен дә беләсең. Әкълимә дә, син дә — Басыйр атлы чекист кочагыннан котылып хәтта чит илгә качарга мәҗбүр булган кешеләр. Ул адәм актыгы һаман да исән. Казанда яши. Бер әһәмиятле, серле заводны күзәтү эшен җитәкли. Кыска гына әйткәндә шул элекке системасында хезмәт итә инде.

Илбәк. Ай-яй нык куралмыйсың син аны.

Вилдан *(Илбәкнең күзенә туры карап)*. Ә син?

Илбәк *(иңнәрен сикертеп)*. Мин... Минем аны бер тапкыр да күргәнем юк. Әнкәй һәм син сөйләгәннәр буенча гына беләм. Әлбәттә, аңа ихтирамым бар дип әйтә алмыйм, гәрчә атам булса да.

Вилдан. Синең миңа ярдәм итәсең киләме?

Илбәк. Вилдан абый, син әнкәмне дә, мине дә коткарган кеше. Сиңа ярдәм итү — минем бурычым. Нинди файда китерә алам мин сиңа?

Вилдан *(бик җитди итеп)*. Бу юлысы мин Германиядән монда махсус синең янга дип килдем.

Илбәк *(гаҗәпсенеп)*. Моңа лаекмы мин?!

Вилдан. Кыланма, энем! Чынлап та синең янга дип килдем бу юлысы. Минем нindirәк хезмәттә икәнемне чамалыйсыңдыр инде?

Илбәк. Чамалыйм. Бик романтикалы, ләкин үтә дә куркыныч эштә син.

Вилдан *(тирән сулап)*. Бу дөньяда нинди эштә эшләсәң дә куркыныч, энекәш. Безнең оешмада СССРдагы хәлләр, аның төрле тәбәкләрендәге тормыш, халыкның бүгенге халәте — барысы турында да мәгълүматлар бар. Казан каласында да безнең резидентура эшли. Казандагы зур вазифадагы кешеләр, завод-фабрикаларның җитәкчеләре хакында да без шактый күп нәрсә беләбез. Синең атаң Басыйр турында да бездә мәгълүмат шактый. Аның чын фамилиясе Гайнанов. Атасының исеме Кәрәм. Гайнанов Кәрәм — террорист, революционер. Синең атаң — Гайнанов Басыйр Кәрәм улы — бик әһәмиятле хәрби продукция чыгаручы заводны саклау, күзәтү белән җитәкчелек итә. Белүебезчә, атаң бик абруйлы, бик күп информациягә ия кеше.

Илбәк. Бер күрергә иде шуны.

Вилдан *(шатлык белән)*. Ә бит синең аны күрергә мөмкинлегең бар.

Илбәк *(көлә)*. Ничек?

Вилдан. Син атаңны эзләп СССРга барасың — Казанның үзенә. Атаңны табасың. Мөмкин булса, аңардан үзе эшли торган серле объект турында мәгълүматлар аласың. Нинди продукция чыгарга тора, нинди планнар, мөмкин булса, аның үзен чит илгә качарга үгетләп карыйсың.

Илбәк. Чын әйтәсеңме син?

Вилдан *(каты итеп)*. Чын! Килүемнең сәбәбен әйтергә баядан бирле укталып торам бит инде! Син барып аны күрергә тиеш!

Илбәк *(сүренкеләнә)*. Ул мине ничек кабул итәр икән соң?

Вилдан *(аяусыз кыяфәт белән)*. Үзенең улын әйбәт кабул итәргә тиеш. Моннан СССРга барырга документларны үзем әзерләрмен.

Илбәк *(елмая)*. Мине шпион итеп җибәрмәкче буласың инде алайса?

Вилдан. Мин сиңа тәкъдим генә ясыйм, үзең хәл ит.

Илбәк. Мин аны Казанда табармын микән соң?

Вилдан *(коры)*. Табарсың. Синең яныңа Казанда, вокзалда ук, безнең кеше килер. Ул сиңа барысын да аңлатыр, инструкцияләрне шуңардан алырсың. Ничек сак булырга икәнне, үзеңне ничек тотарга, нәрсә сөйләргә ярый, нәрсәдән телне тыярга кирәк — мин сиңа монда үзем әле өйрәтермен.

Илбәк *(хыялланып)*. Дөресен әйткәндә, минем Россиягә барасым килә. Бигрәк тә Казанга. Әтине дә күрәсем килә.

Вилдан *(таләпчән итеп)*. Миңа ярдәм итәсең киләме?

Илбәк. Әлбәттә, Вилдан абый! Син бит безнең бердәнбер таянычыбыз!

Караңгылык. Сәхнә яктыра. Әкълимә, Илбәк. Илбәкнең күңеле күтәренке. Әкълимә бик моңсу кыяфәттә улына иңе белән терәлеп утыра.

Әкълимә. Бик ерак сәфәргә җыенасың, улым. Әллә барып йөрмисеңме?

Илбәк. Вилдан абый әйтүенчә СССРга бару авыр булмаячак.

Әкълимә. Нишләп сиңа анда барырга тәкъдим ясады соң ул?

Илбәк. Мин үзем сорадым: Вилдан абый, мәйтәм, мөмкин булса, мин Россиягә барып кайтыр идем. Атамны бер күрәсем килә, дидем. Вилдан абый безнең өчен әллә ниләр эшләргә әзер. Ярдәм итәрмен, диде.

Музыка.

Әкълимә. Атаңны күрәсең киләме?

Илбәк. Әйе, әнкәй, минем аны очратып бер сөйләшәсем килә.

Әкълимә. Куркам бит мин сине анда җибәрергә, улым!

Илбәк *(күңел шатлыгы белән)*. Нәрсәсеннән куркырга! Атамны эзләп барам бит мин! Куркыныч, кыңгыр эш белән түгел!

Әкълимә *(күз яшьләре белән елмая)*. Беләм, улым, аңлыйм. Атаңны күрәсең киләдер... Тик менә бер дә анда сине җибәрәсем килми. Куркам. Атаңны күрергә тырышуыңа каршы түгелмен, ләкин куркам мин, куркам, куркам.

Музыка көчәя.

1938 ел. Көз. Казан. Вокзал. Илбәк плащ, эшләпә кигән, чемодан күтәреп басып тора. Радио тавышы яңгырый. «Казан сөйли. Мәскәү вакыты белән алты сәгать». Татар музыкасы.

Илбәк *(үтеп баручы кызга)*. Гафу итегез, туташ... Бу Казанмы?

Кыз *(аптырап)*. Бу — Казан. Сез күктән төштегезме әллә?

Илбәк. Ник алай дисез?

Кыз. Беренчедән, миңа, таныш түгел кызга, шундук татарча эндәштегез. Икенчедән, кайсы калада икәнне белмәвегез сәер. Өченчедән, сез чынлап та әллә кайлардан килеп төшкән кешегә охшагансыз.

Илбәк *(елмаеп)*. Сезнең исемегез ничек?

Кыз. Клара. *(Егетне кызыксынып күзәтә.)*

Илбәк. Клара! Беренчедән, сезнең төс-битегез буенча татар кызы икәнне чамалау кыен түгел. Икенчедән, гүзәл Казан-кала шушындыйдыр дип уйламаган идем. Өченчедән, мин чынлап та әллә кайлардан килеп төшкән кеше. Сез миңа гаҗәпләнеп карыйсыз. Мин дә шәхсән сезгә гаҗәпләнеп карыйм. Беренчедән, сез искиткеч гүзәл, икенчедән, сезнең исемегез һич кенә дә татарча түгел.

Клара *(башын кыңгыр салып)*. Клара Цеткинны ишеткәнегез бармы?

Илбәк *(кашларын җыерып)*. Кем ул?

Клара. О-о-о, сез әллә кайлардан гына түгел, дөнья артыннан килеп чыккансыздыр, ахрысы. Клара Цеткин дигән коммунист хатын-кызны да ишетмәгәч. Шуңа ихтирам йөзеннән мине Клара дип атаганнар.

Илбәк. Мондый чибәр затны аның исеме белән атарлык булгач, димәк, чынлап та бөек хатын-кыз булгандыр ул.

Клара. Сез үзегез ни атлы соң?

Илбәк. Илбәк.

Клара. Илбәк?! *(Баш чайкап.)* Хәтә-ә-әр! Казанга кунакка килгәнсездер?

Илбәк. Кунакка. Кабул итсәгез.

Клара. Анысы инде каян килгәнегезгә карап.

Илбәк. Үз телеңдә сөйләшүче очрагач бигрәк рәхәт. Алайса, Мәскәү вокзалында адашкан эт шикелле каңгырап йөрдем, чөнки урысча белмим. Мин Төркиядән килдем, башта Мәскәүгә кадәр, аннары менә монда. Югыйсә Мәскәүдә вокзалда гына кундым, ләкин анда да урысча белмәвем белән иза чиктем.

Клара *(таң калып)*. Сез Төркиядән үкмени?

Илбәк. Шуннан ук.

Клара. Татарча әйбәт сөйләшәсез.

Илбәк. Мин бит татар баласы. Сез миңа ярдәм итмәссезме?

Клара. Ничек?

Илбәк. Миңа Кызыл партизаннар урамына барырга кирәк.

Клара. Мин сезне ничек барырга өйрәтеп трамвайга утыртып җибәрермен. Кызганычка каршы, мин ашыгам, вакытым булса, озатып та куйган булыр идем. Адашмассыз дип уйлыйм, дүртенче тукталышта төшкәч сорарсыз, анда инде ерак түгел. Анда сезнең туганнарыгыз бармы?

Илбәк. Әйе, бар. Ә сез үзегез Казанның кай тирәсендәрәк торасыз?

Клара. Мин үзем бер кардәш апамнарда торам, Уң Болакта. Мин Әгерҗедән килдем, монда тегүчелеккә укыйм.

Илбәк. Ә без тагын очрашырбызмы?

Клара. Теләгегез булса, очрашырга мөмкин. *(Сумкасыннан кәгазь белән карандаш алып, адресын яза.)* Менә адресым. Йөгердем. Ашыгам. *(Китә. Илбәк аның артыннан карап кала.)*

Соргылт киемле, эшләпә кигән серле кеше пәйда була. Илбәк янына килә.

Серле кеше *(каядыр еракка карап)*. Казан үзгәрә-ә-ә.

Илбәк *(киеренкелек белән)*. Дөнья үзе тик тормый, гел үзгәрә.

Серле кеше. Хак сүз.

Илбәк. Бу мин уйлап чыгарган фикер түгел.

Серле кеше *(текәлеп карый)*. Минем фамилиям — Умаров. Хуш килдегез!

Илбәк *(кыюланыбрак)*. Мин Илбәк атлы.

Умаров. Әйдәгез әнә теге эскәмиягә утырыйк. *(Эскәмиягә барып утыралар.)* Бу кыз белән әле яңа гына таныштыгызмы?

Илбәк. Яңа гына булмый, мин бит әле генә Мәскәү поездыннан төштем.

Умаров. Ә ул сезне каршы алды түгелме?

Илбәк. Юк, юк!

Умаров. Килеп җитмәс борын әллә кемнәр белән танышмаска киңәш итәр идем. Кайдан, кем икәнлегегезне дә әйтергә ашыкмагыз.

Илбәк. Ярар.

Умаров. Нинди адрес белән барасыгызны онытмадыгызмы?
Илбәк. Юк, онытмадым.
Умаров. Атнага бер тапкыр очрашачакбыз. Беренче очрашуыбыз киләсе атнаның шимбә көнендә булыр. *(Кәгазь бирә.)* Дүртенче аптекага кереп Светлананы сорарсыз. Менә бу рецептны күрсәтерсез. Ул сезгә, рецептның срогы чыккан, дияр, ә сез аңа, әллә соң минем үземнең дә срогым чыкты микән, дип шаярырсыз. Светлана сиңа кая барырга аңлатыр, мин сине шунда каршы алырмын. Киләсе очрашулар хакында шунда сөйләшербез.
Илбәк. Аңлашылды. *(Як-якка каранып.)* Мин Казанны башкачарак күзаллаган идем.
Умаров. Ошамыймы әллә?
Илбәк. Әле вокзалдан ерак китмәдем, шуңа күрә әйтә алмыйм.
Умаров. Ник соң, алайса, вокзалдан ары китмәгән килеш башкача күзаллаган идем дисез?
Илбәк. Поезддан төшү белән атмосфера авырлыгын тойдым.
Умаров. Ә Мәскәү вокзалында?
Илбәк. Анда тагы да авыррак.
Умаров. Истанбулда атмосфера басымы бөтенләй юк мәллә? Ха-ха-ха. Сезне атагыз белән очрашу көтә, һава баса, атмосфера авыр дип каңгыраймагыз!
Илбәк *(тирән сулап)*. Әйе, әтине күрәсем килә.
Умаров. Монда килүегезнең максатын онытмагыз.
Илбәк. Сезне нинди мәгълүматлар кызыксындырачак соң?
Умаров. Ул күзәтә торган берләшмәнең продукциясе, сыйфаты, заводның киләчәге, перспективасы. Тора-бара әтиегез белән ничек сөйләшергә, аны нәрсәләр эшләргә күндереп карарга өйрәтермен. Башта очрашыгыз әле. Алга таба барысын да тәфсилләп аңлатырмын. Конструкторлар, яңа проектлар турында минем киңәшләрем белән генә сораштырачаксыз, саклык белән генә.
Илбәк. Аңладым.

### 3

Акмуллиннар йортының кече өй дип аталган өлеше. Гарифә кер юа. Илбәк керә.

Илбәк. Исәнмесез!
Гарифә *(эшеннән туктап)*. Исәнмесез!
Илбәк. Гайнановлар монда яшиме?
Гарифә. Әйе.
Илбәк. Миңа Гайнанов Басыйр атлы кеше кирәк. Сез аның...
Гарифә. Мин аның хатыны Гарифә. *(Чүпрәген тоткан килеш.)*
Илбәк. Ул өйдә түгелме?
Гарифә. Ул эштән бик соң кайта. Сез кем буласыз соң?
Илбәк. Мин ерактан, Төркиядән килдем. Атамны эзләп йөрим.
Гарифә *(каушый)*. Кем соң сез?
Илбәк. Илбәк атлы мин.
Гарифә. Ә Басыйр сезгә ник кирәк? *(Бер-ике адым атлый.)*
Илбәк. Мин аны эзләп килдем.
Гарифә. Аңлатыгыз әле, ни йомыш белән монда кердегез?
Илбәк *(тавышын күтәребрәк)*. Мин Гайнанов Басыйрның улы.
Гарифә *(куркып)*. Басыйрның улы?!
Илбәк. Әйе.
Гарифә. Анагыз кем соң сезнең?
Илбәк *(көр тавыш белән)*. Акмуллина Әкълимә Сәләхетдин кызы.
Гарифә *(һушсызланып)*. Әкълимә?! Чын әйтәсезме?
Илбәк. Чын әйтәм.
Гарифә. Ул әллә исәнме?
Илбәк. Нишләп исән булмаска тиеш ди ул! Исән.
Гарифә *(кулындагы юеш чүпрәкне кая куярга белми, аптырагач таз торган якка томыра.)* И Ходаем! Чишенегез.

Илбәк чемоданын идәнгә куя, чишенә.

Узыгыз әле, узыгыз, түр бүлмәгә узыгыз, зинһар.

Илбәк урындыкка утыра.

Алдамыйсызмы соң сез?

Илбәк. Алдамыйм. *(Гарифәнең куркуыннан бераз читенсенә.)*

Гарифә *(урындык алып килеп, Илбәкнең каршысына утыра)*. Шушындый зур булып үсеп життеңмени син? Син бит менә мондый гына идең. *(Куллары белән күрсәтә.)* Хәер, унтугыз елдан артык вакыт үтте бит инде. Кайда яшисез соң сез?

Илбәк. Төркиядә.

Гарифә *(шөбһәле тавыш белән)*. Төркиядән монда килеп буламыни? Ничек монда кайтасы... киләсе иттең?

Илбәк *(елмая)*. Әтине эзләп килдем.

Гарифә *(шаккатып)*. Бигрәк Әкълимәгә охшагансың бит син. Сиңа Илбәк дип исем кушканнар иде шул.

Илбәк. Сез бабайларга асрама кыз булып килгән Гарифә ападыр инде?

Гарифә. Әйе, балам, әйе. Әкълимә белән бергә үстек без. *(Елый.)*

Илбәк. Ул сезнең турыда гел сөйли.

Гарифә. Белсәң иде аны ничекләр искә алганымны, ничекләр аны сагынып яшәвемне! Тик менә минем бүгенге тормышымны белсә, минем нинди әшәкелеккә барганым мәгълүм булса, ул рәнҗер, мөгаен.

Илбәк. Бүгенге тормышыгыз нинди соң сезнең?

Гарифә. Вилдан Әкълимә белән сине алып Казаннан чыгып качкач, шул ук 1919 елның азагында Басыйр мине үзенең хатыны итте. Бергә яши башладык. Яклаучым булмады, Басыйр теләгәнчә килеп чыкты инде. Власть үзгәрер, элекке тормыш кире кайтыр дип өметләнгән идем, Акмуллиннар йортына күз-колак булып, аны саклап торуны үземнең бурычым дип санадым. Ә Басыйрның хатыны булудан баш тарта алмадым, гәрчә аны яратмасам да. Тик менә власть элеккегә кире кайтмады, Әкълимә дә, Вилдан да күренмәделәр, гомер уза торды, йортны да саклап кала алмадым. Хәтта Басыйрның да Акмуллиннарның йортын тулысынча саклап калу хәленнән килмәде. Йортның төп өлешендә егермегә якын гаилә яши. Безгә менә кече йортны тулысынча бирделәр, анысын да Басыйр зур кеше булганга гына тулысынча бирделәр әле.

Илбәк *(өй эченә күз сала)*. Әнкәй белән сез шушы кече йортны бик ярата торган булгансыз, шулаймы?

Гарифә *(яшь аралаш елмаеп)*. Әйе, каян беләсең?

Илбәк. Әнкәй еш сөйли.

Гарифә. Әкълимә белән бөтен серләребезне шушында сөйләштек. Еларга да, көләргә дә шушында керә идек. Ярый әле ичмаса шушы кече йортны бирделәр безгә.

Илбәк. Ә зур йорттагы кешеләр кемнәр?

Гарифә. Ул хәтле гаиләләрдә кемнең кем икәнен шайтан белсенме. Беләсем дә килми. Ярлыларга бүлеп өләшәләр, имеш. Андагы тәртипсезлек, андагы әшәкелек. Ул йортка әллә кемнәр тула башлагач, йөрәгемнең ничек әрнегәнен сөйләп бетергесез. Ярый әле алардан аерым яшибез. Әрәм булды йорт. Акмуллиннар йорты бит! Кемнәр уйлаган шушылай килеп чыгар дип.

Фердинанд керә. Пәлтә, фуражка кигән.

Фердинанд *(кунакны күреп)*. Исәнмесез!

Илбәк *(торып баса)*. Исәнмесез!

Фердинанд. Әнкәй, нәрсә булды? *(Чишенә.)*

Гарифә. Әйбер-кара юк, улым. Бездә кунак бар. Бу безнең улыбыз Фердинанд, егерменче елгы, синнән яшь ярымга гына кече.

Илбәк *(кулын сузып)*. Илбәк.

Фердинанд *(кул биреп)*. Фердинанд.

Гарифә *(кыюсыз гына)*. Улым, бу синең туганың.

Фердинанд *(гаҗәпләнә)*. Туганым?! Нинди туганым?

Гарифә. Әкълимәнең улы бу.

Фердинанд. Әтинең беренче хатынынныкымы?

Гарифә. Әйе.

Фердинанд *(Илбәкне җентекләп күзәтә)*. Каян килеп чыкты соң ул?

Илбәк. Мин Төркиядән килдем. *(Кара-каршы утыралар.)*

Фердинанд *(көлемсерәп)*. О-о-о! Сез Төркиядә ятасыз, ә минем әнкәм монда сезне гел елап искә ала, кайларда харап булдылар икән, каберләре кайда икән, ди. Ничек СССРга эләктең соң син?

Илбәк. Эләкмәдем, атамны эзләп килдем.

Фердинанд. Әти кирәк булдымыни? Төркия безгә дошман түгелме соң?

Илбәк. Нишләп Төркия дошман булсын?

Фердинанд *(өнәмәүле караш белән)*. Ник, ул бит гел Россиягә каршы сугышты, гражданнар сугышында да совет Россиясенә каршы булды.

Гарифә *(борчылып)*. И улым, анда синең ни эшең бар. Туганың табылганга куанасы урынга әллә нинди сугыш вакыйгаларын сөйләп утырасың. Күп укуның да кайвакыт зыяны бар шул.

Илбәк. Кайда укыйсың?

Фердинанд. Техникумда.

Гарифә. Укуын укырлар, ил генә тыныч булсын инде берүк. Әле Акмуллиннар йортының бүгенге хәле турында әйтеп утыра идем. Кайлардан килгән шундый әшәкелек?!

Фердинанд. Аптырадың инде шул Акмуллиннар йорты дип. Бер генә гаилә яши алмый бит инде андый зур йортта. Син, әнкәй, һаман шул патша заманын сагынып яшисең. Әти дә сине гел шуның өчен ачулана.

Илбәк. Талап алынган йортның ничек инде кадерен белсеннәр!

Фердинанд *(кырысланып)*. Акмуллин кебекләр халык тире белән, гади халык җилкәсендә баеганнар. Шуңа күрә сарай кебек зур йортларда яшәгәннәр. Кешеләргә бүлеп бирү дөрес.

Гарифә. И-и-и, сөйләшүе! Илбәкнең бабасы Акмуллин Сәләхетдин үзе өчен кешегә тир түктермәде. Ул үз көче белән, үз тирен түгеп көн күрде. Аның кебек ил өчен янып, газапланып яшәүче сирәктер ул.

Фердинанд *(авызын чалышайтып)*. Ил өчен... Үз мәнфәгатьләре, үз корсаклары өчен кирәк булган аларга ил дә, халык та!

Гарифә *(китеп бара)*. Син мине рәнҗетәсең, улым.

Басыйр кайтып керә.

Басыйр *(өс киемен салып)*. Бездә кунак бар мәллә?

Гарифә. Әйе, кунак бар. *(Басыйр янына килә, аңа куркып карап тора.)*

Басыйр. Нишләп йөзең агарган?

Гарифә. Каушаудан ул.

Илбәк *(тора)*. Исәнмесез!

Басыйр *(сагаеп)*. Исәнмесез!

Фердинанд. Әти, Западтан улың кайтты!

Басыйр *(Фердинандка)*. Нинди шаяру бу? *(Илбәккә.)* Сез кем буласыз?

Илбәк *(каушый төшеп)*. Илбәк.

Басыйр. Нинди Илбәк?

Гарифә *(әкрен генә)*. Синең улың, Әкълимәнең улы.

Басыйр. Илбәк?! *(Якынрак килә.)*

Фердинанд. Кем шаярадыр әле монда — минме, башка кешеме?

Басыйр *(Фердинандка капылт кына борылып)*. Молчать! Гарифә, Фердинанд, барыгыз чыгып торыгыз.

Гарифә белән Фердинанд чыгып китәләр.

Илбәк *(югалып калмаска тырышып)*. Исәнме!

Басыйр *(тавышында кырыслык, таләпчәнлек саклап)*. Исәнме! Син кем?

Илбәк. Синең улың Илбәк. Әнкәм — Әкълимә.

Басыйр *(ни әйтергә белми тора)*. Син каян?

Илбәк. Төркиядән.

Басыйр. Анаң кайда?

Илбәк. Шунда калды.

Басыйр *(һаман ышанып бетми)*. Ничек монда килә алдың?

Илбәк. Атамны эзлим дигәч, Төркиядән чыгардылар, СССРга керттеләр.

Басыйр *(аптырап)*. Мине ничек таптың?

Илбәк. Табасым килде, сине күрәсем килде, шуңа күрә таптым.

Басыйр. Сиңа ничә яшь соң?

Илбәк. Унтугыз.

Басыйр. Әйе, әйе... *(Кинәт боерып.)* Тәк... Документы!

Илбәк *(катып кала)*. Нәрсә?

Басыйр. Документыңны күрсәт!

Илбәк *(документын күрсәтә)*. Документларым тәртиптә.

Басыйр аның документларын караганда, Илбәк атасын җентекләп күзәтә.

Басыйр *(сөенә, ләкин шул ук вакытта нык курка)*. Акмуллин... Илбәк... Басыйр улы... Шушылай үсеп җиттеңмени инде? Гаҗәп, гаҗәп... Карале син... көтмәгәндә... Фамилияң Акмуллин... Һе...

Илбәк *(елмая)*. Исәнме, эти!

Басыйр. Исәнме... улым! *(Кочаклашалар.)* Синмени бу?..

Илбәк *(көлә.)* Бигрәк кызык сорау. Мин булмый кем булсын инде бу!

Басыйр. Анаң Төркиядә...

Илбәк. Төркиядә. Син ышанмыйсың бугай?

Басыйр *(ык-мык килеп ала)*. Утыр әле син, утыр. Менә бит! *(Тагын Илбәкнең документларын актара.)* Ни... көтмәгәндә... Ышанып булыр ул... Акмуллин Илбәк Басыйр улы... Һе...

Әрле-бирле йөри башлый. Илбәк аңа карап утыра.

**4**

Казан. Ресторан. Утызынчы еллар музыкасы яңгырый. Илбәк ресторанга керә, уйланып торганнан соң, телефоннан атасына шылтыратырга була.

Илбәк *(телефон трубкасына)*. Алло! Әти, мин әле бу — Илбәк. Гафу ит, эшеңне бүлдем, ахрысы. Шуны әйтергә дип шылтыратам, мин, бәлки, бүген өйгә кунарга кайтмам. Без Клара белән Идел буенда учак ягып төн чыкмакчы булабыз. Мин рестораннан шылтыратам. Әлегә Кларaны көтәм, без аның белән ресторанда утырырга сүз куештык. Минем Идел буенда бер дә кунганым юк. Әй, синең вакытың кайчан була әле. Ярар, ярар, борчылма.

Телефон трубкасын элеп куя, тәрәзә ягындагы өстәл янына барып утыра. Официант меню тотып килеп җитә.

Официант. Рәхим итегез — меню.

Илбәк. Рәхмәт!

Официант читкә китә, Илбәк менюны актарып карый. Ресторанга Умаров керә. Килеп Илбәкнең каршысына утыра.

Умаров *(кырыс)*. Сәлам!

Илбәк *(аптырашта кала)*. Сәлам!

Умаров. Син соңгы тапкыр биргән мәгълүматлар расланмады. Йә атаң сиңа дөресен әйтмәгән, йә син үзең дөрес информация бирмәгәнсең.

Илбәк. Мин нәрсә ишеттем, шуны әйттем. Әти фанатик коммунист, чекист, ул серле информацияне беркемгә, хәтта миңа да әйтмәс, мөгаен.

Умаров. Әниең турында еш сораштырамы?

Илбәк. Сораштыра. Әбием белән бабамны коткара алмавына үкенә, уфтана. Бераз салгач елап та алгалый.

Умаров. Бәлки, менә шундый халәтендә мәгълүматларны суырып алырга мөмкиндер?

Илбәк. Булмый. Барып чыкмаячак.

Умаров. Төркиягә качу турында сүз катканы юкмы?

Илбәк. Ул бит җүләр түгел, ник моннан качсын! Теләге булса да әле, ничек кача алсын?! Гади кеше булса бер хәл...

Умаров. Әйе, әйе. Нишләп бик озак элемтәгә керми тордың?

Илбәк *(Умаровка текәлеп карап тора)*. Мин бу уеннан чыгам!

Умаров *(сискәнеп)*. Ничек инде?!

Илбәк. Мин монда атамны күрергә дип килдем. Мин разведкага хезмәт итәм дип ант бирмәдем. Мин үз атама каршы, анамның туган иленә каршы көрәшә алмыйм. Кирәген, мәгънәсен күрмим.

Умаров. Әби-бабаңнарың монда атып үтерелде, анаң сине — имчәк баланы — күкрәгенә кысып чит илләргә чыгып качарга мәҗбүр булды. Ниһаять, сине Вилдан абыең монда барырга өндәде. Боларны онытма.

Илбәк. Мин башта атама каршы көрәшә алырмын дип уйлаган идем. Әтине очраткач аның шундый бәхетсез икәнен күрдем, аңладым. Ярый, Вилдан абыйны аңлап була, аның әтиемне дошман итүе табигый. Ләкин бу эш минем хәлемнән килми. Соңгы вакытта мин баш ватам: атамда гаеп шулкадәре зур микәнни? Ул да бит корбан. Аның язмышы да фаҗигале ләбаса. Ул нинди рәхәт күргән бу дөньяда?

Умаров. Бу уйларың белән син упкынга таба якынаясың түгелме?

Илбәк. Атама каршы бару дөрес булырмы соң? Мин, син кушканча, читләтеп-читләтеп ул күзәтә торган завод турында, продукцияләре хакында, андагы белгечләр турында кызыксынып сораштырып карадым. Әти шундук сәерсенеп куйды, шөбһәгә калды. Бүтән андый сораулар бирмәскә кушты. *(Сөйләшүдән җиксенеп.)* Булмый миннән, булмый, булмый!

Умаров. Төркиядән монда килер алдыннан ни уйладың соң син?

Илбәк. Атамны күрәсем килде, анам туып-үскән, әби-бабайлар яшәгән җиргә аяк басасым килде. Аннары, Казанга килеп төшү белән, мин шундый гүзәл татар кызын очраттым.

Умаров *(як-ягына каранып)*. Акылыңа кил!

Илбәк. Зинһар, гафу ит. Мине катнаштырма! Мин куркам. Алай-болай син яки мин, яисә барыбыз да тотыла калсак? Барыбыз да харап булачакбыз бит. Без генә түгел, әти дә, Гарифә апа да, Фердинанд та. Син профессионал буларак, бәлки, котыла да алырсың, ә без бит харап булачакбыз.

Умаров. Ә үтерелгән әбиең белән бабаңны оныттыңмы? Нишләп әнкәң чит җирләрдә туган илен сагынып саргаеп ята? Ә Вилдан абыең?

Илбәк. Инде булган фаҗигаләрне, аларның ачы язмышларын үзгәртү мөмкин түгел. Үч алудан ни мәгънә? Әби белән бабай да терелмәячәкләр, әнкәйгә дә җиңеллек килмәячәк. Ә менә яңа фаҗигаләрнең тууы ихтимал.

Умаров *(сынаулы караш белән)*. Син исеңдә тот, Германиядә Вилдан абыең гына түгел, синең анаң да шунда.

Илбәк. Әнкәй Төркиядә.

Умаров. Күптән түгел Вилдан абыең аларны Германиягә алып киткән.

Илбәк *(шомланып)*. Минем анама бер-бер нәрсә булуы ихтимал дип куркытмакчы буласыңмы?

Умаров. Эшләр алайга кадәр үк барып җитмәс дип ышанасым килә.

Илбәк. Вилдан абый әнкәмне җәберләтмәс.

Умаров. Вилдан абыеңның үзен дә җәберләмәгәйләре анда.

Илбәк *(паузадан соң)*. Кабатлагыз әле, әтидән тагын нинди мәгълүматлар алырга тиеш мин?

Умаров. Киләсе елда чыгасы продукциянең күләмен, маркаларын, техник сыйфатларын белергә иде. Кайсы галимнәрнең тәкъдимнәрен файдаланачаклар икән? Киләчәккә перспективалар, хәрби юнәлештәге яңарышлар ничегрәк?

Илбәк *(беравык карап торганнан соң)*. Ничек шулай тиз табасың син мине? Хәтта ресторанга да артымнан ук килеп кердең?

Умаров *(тәмам кәефсезләнеп)*. Табуын табармын, ләкин барыбер озакка югалма, яме. Бүтән кабатлап тормыйм. Элемтәне югалтма. Киләсе очрашу ял паркында булыр. Тынычлан, ял ит, бүгенге халәтең узар дип ышанам, башыңнан икеле-микеле уйларыңны алып ташла.

Илбәк. Ярар.

Умаров рестораннан чыгып китә. Илбәк боегып утыра. Клара керә. Илбәкнең каршысына утыра.

Клара *(еш-еш сулый)*. Уф, хәлдән тайдым! Озак көттердемме?

Илбәк *(булган әңгәмә тәэсире астында)*. Юк. Бу кадәре чапмасаң.

Клара *(назлы)*. Чапсам ни... Бәлки, сине нык сагынганмындыр.

Илбәк *(елмаерга тырыша)*. Алайса ярар, чапсаң да ярый.

Клара. Нишләп йөзең моңсу? Әнкәеңне сагынасыңдыр?

Илбәк *(тирән сулап куя)*. Әнкәемне бик сагындым. *(Кызга мәхәббәтле күзләре белән карый.)* Их, Клара, ярый сине очраттым әле монда. Шунысы кызык — син бит минем Казанда иң беренче танышкан кешем. Ходай үзе җибәрде сине каршыма.

Клара *(пышылдап)*. Синең үзеңне Ходай монда миңа җибәргәндер.

Илбәк *(менюны кызга бирә)*. Әйдә, кара, нәрсә китертәбез.

Клара менюны ала, Илбәк елмаеп Кларантны күзәтеп утыра. Музыка. Официантны чакырып заказ бирәләр. Көлешә-көлешә, бөтен дөньяны онытып утыралар. Официант шәраб һәм ризык алып килә. Утызынчы еллардагы музыка көчәя. Басыйр керә, як-ягына карана. Илбәк белән Кларантны күреп ала, алар утырган өстәл янына килә.

Басыйр *(җитди)*. Исәнмесез!

Клара *(шүрләп)*. Исәнмесез!

Илбәк *(югалыбрак кала)*. Әти?!

Басыйр. Мин. *(Өстәл янындагы буш урындыкка утыра.)*

Илбәк. Клара, зинһар, гафу ит, бер минутка чыгып тормассыңмы... Һава сулап кер.

Клара. Ярар. *(Җәһәт кенә чыгып китә.)*

Басыйр *(басынкы)*. Менә нәрсә... Әллә нигә бер ресторанда утырсаң ярый... *(Пауза.)* Синең белән җитди сөйләшәсем бар. Минем нинди оешмадан, нинди эштә икәнемне, нәрсә белән шөгыльләнүемне чамалыйсың бит инде?

Илбәк. Ачыктан-ачык әйтмәсәң дә, нинди вазифалар башкаруыңны аңлыйм.

Басыйр *(пошаманлы кыяфәттә)*. Синең табылуыңа, мине эзләп СССРга килүеңә шатмын. Әкълимәнең исән булуына бик куанам. Аның алдында гаебем зур. Әлбәттә, аның качып китүенә минем ачуым әле дә суынмады, ләкин шул ук вакытта мин аңлыйм — Вилдан абыйсы алып китмәсә ул монда калган булыр иде, син дә шушында минем белән үскән булыр идең. Кабатлап әйтәм, мин синең белән кавышуыма чиксез шат... Ләкин...

Илбәк *(кинәт җанланып)*. Әйт, әйт, әти, мин тыңлыйм.

Басыйр *(башын иеп)*. Миннән шикләнә башлаулары ихтимал.

Илбәк *(эреләнебрәк)*. Шикләнүләре нигезле булып чыкса?

Басыйр. Ни дигән сүз инде бу?! Нишләп исердең әле?

Илбәк (*купайланып)*. Аз гына шәраб эчтем. Ник куркасың син, әти, шулкадәр?

Басыйр *(көчкә тыелып)*. Син әле аңлап бетермисең. Бу Төркия түгел!

Илбәк *(тыныч)*. Ә бит мин сине төшләремдә еш күрдем. Нәкъ шушындый итеп. Менә бу зәгыйфь күзеңне дә нәкъ шушылай итеп күрә идем. Кызык бит, бер тапкыр да күрмәгән атамны төп-төгәл, дөрес итеп күрә идем. *(Елмая.)*

Басыйр. Фоторәсемдә күргәнең булгандыр.

Илбәк. Юк, әнкәйдә синең бер генә дә фотосурәтең юк. Шәраб эчәсеңме?

Басыйр *(катгый итеп)*. Юк! Нинди шәраб?! *(Як-ягына каранып куя.)*

Илбәк *(битараф булып кылана)*. Кайгырма. Мин Төркиягә кайтып китәм.

Басыйр *(кызып, ләкин читкә ишетелмәслек итеп)*. Сине Төркиягә беркем кире чыгармаячак. Төркиягә кайтып китә алсаң да, миңа инде шик төште. Син Төркиягә кайтып китсәң, киресенчә, минем хәлем мөшкелрәк булачак. Бер вариант та уңай түгел. Хәзер инде сак, уяу булырга кирәк. Синең мине эзләп килүең икебезнең дә киләчәкне билгеләде бугай инде. Миңа бүтән эшкә шылтыратма. Яшәү урынын мин сиңа табармын.

Илбәк *(атасының борсалануын аермачык күрә)*. Миңа торак эзләп маташма, мин әнкәй янына Төркиягә кайтып китәм.

Басыйр. Кем чыгара сине моннан?! Бала-чага! Нинди илдә икәнеңне һаман аңламыйсың әле син. Мин сиңа эш табармын. Күрәсең, язмыш дигән нәрсә бардыр ул. Синең мине эзләп табуың миңа җәза урынынадыр, мөгаен.

Илбәк *(атасының гасабилануын күреп берникадәр ләззәтләнә)*. Улы атасын тапкан өчен нинди җәза бирсеннәр?

Басыйр *(ачынып)*. Синең фамилияң Акмуллин, аңлыйсыңмы?! Совет властена каршы көрәшкән контра буларак атып үтерелгән Акмуллинның фамилиясе синдә! Әйдә чыгыйк. Берничә күз монда нык текәлгән.

Илбәк *(көлә)*. Тегеләй дә куркыныч, болай да куркыныч, дисең бит үзең. Чыктык ни дә, чыкмадык ни.

Басыйр. Яшьлегең белән аңлап бетермисең... Халыкара обстановка, үзең беләсең... Киеренкелек арта... Илдә тәртип кирәк... Көн саен диярлек контраларны фаш итәләр, шпионнар тотыла...

Илбәк *(пышылдап)*. Мин синең серле объектың турында сорашканым булдымы?

Басыйр *(текәлеп карый)*. Юк.

Илбәк. Берәр тапкыр синнән мәгълүмат алырга тырыштыммы?

Басыйр. Юк. Мин сиңа әйтмәс идем дә.

Илбәк. Синең эшең буенча берәр сорау биргәнем бармы?

Басыйр. Юк. *(Як-ягына карап куя.)*

Илбәк. Юкмы? Юк! *(Алга таба иелеп.)* Ә бит мин монда махсус җибәрелгән кеше — шпион буларак дисәм дә була. Ризалык биргән булдым, чөнки сине күрәсем килде.

Басыйр *(беравык шаңкаеп утыра)*. Монда кем белән элемтәдә торасың?

Илбәк *(тыныч кына)*. Беркем белән дә элемтәдә тормыйм.

Басыйр *(кайнарланып)*. Алдыйсың! Кем җибәрде монда сине?

Илбәк. Вилдан абый.

Басыйр *(тиз-тиз сорый)*. Акмуллинмы?

Илбәк. Нәкъ шул.

Басыйр. Ул кемгә хезмәт итә?

Илбәк. Белмим.

Басыйр. Нинди максат белән килдең монда?

Илбәк *(ихластан)*. Сине эзләп. Сине күрәсем килде. Ә синең мине күрәсең килгән идеме?

Басыйр *(сораудан югалыбрак кала)*. Шпион итеп күрәсем килмәгән иде.

Илбәк. Ә минем сине, кем булуыңа карамастан, бик күрәсем килде... эти! *(Кинәт усаллана.)* Әти, бит тирәнрәк уйлап баксаң, сине яратырлык та, ихтирам итәрлек тә түгел!

Басыйр *(шактый вакыт улына карап утырганнан соң, тыныч кына)*. Яратсаң да, яратмасаң да, синең, улым, ярты каның Екатеринбургта полицмейстерга бомба ыргыткан Гайнанов бабаңныкы, яртысы гына купец Акмуллинныкы. *(Урыныннан кузгала, ишеккә таба юнәлә.)*

Илбәк. Әйе шул.

Музыка. Атасын үпкәләткәнгә үкенә, башын куллары белән кысып ыңгырашып куя. Басыйр рестораннан чыгып китә. Музыка көчәя.

1941 ел. Икенче бөтендөнья сугышы башланган. Казан. Басыйрлар өе. Басыйр, Гарифә, Илбәк чәй өстәле янында утыралар.

Гарифә. Фердинандның киткәненә бер ай узды. Хаты килер вакыт бит инде.

Басыйр. Хат язарга җае юктыр әле. Ул хәтле солдатларның хатларын ничек ташып җитешсеннәр.

Илбәк. Әллә инде фронтка ук керде микән?

Басыйр. Әле әзерлексез шундук сугышка кертмәсләр.

Гарифә. Нимес инде Мәскәү янында бит.

Басыйр *(ачусыз гына)*. Күп сөйләшмә. Илбәк, синең эштә тәртипме?

Илбәк. Тәртип. Слесарьларның бригадиры итеп куярга уйлыйлар.

Басыйр *(канәгать)*. Маладис, маладис.

Илбәк. Фронтка җибәрүләрен сорап тагын ике тапкыр бардым, алмыйлар.

Басыйр. Сине алмаслар инде анда... Алсыннар иде дә бит.

Гарифә. Алмасыннар. Үзең теләп сугышка бару ник кирәк?

Басыйр *(кырыс)*. Күп сөйләшмә!

Илбәк. Кларaның тутасы миңа бер кечкенә бүлмәсен бирде.

Басыйр. Ярар, ярар, бик әйбәт.

Илбәк. Син гафу ит... Монда килүем өчен... Мин бер зур йомыш белән кердем. Рөхсәт итсәң, без Клара белән никах укытыр идек.

Басыйр *(уйга калып)*. Никах...

Гарифә. Ник куркасың, никахны укытырга ярый ла, тыймыйлар бит.

Басыйр *(ачусыз)*. Күп сөйләшмә! Аны шыпырт кына укытырга кирәк.

Гарифә. Доброволец булып барам дигәч, нинди җавап бирделәр соң?

Илбәк. Ничегрәк җавап биргәннәрен чамалыйсың бит инде.

Басыйр. Әйе, әйе.

Илбәк. Соңыннан өстәп куйдылар: мех фабрикасында эшләвеңне дәвам ит, диделәр. Хәзер анда слесарь-ремонтниклар җитми.

Басыйр. Ярый. Әйбәт кенә, тыныч кына эшләп ят. Гражданлык белән проблемалар бүтән калыкмас дип уйлыйм.

Илбәк *(боегып)*. Әнкәйне сагындым.

Басыйр. Бернишләп булмый. Сине беркая да җибәрмәячәкләр. Күрәсең бит, хәтта сугышка да алмыйлар үзеңне.

Илбәк. Аны бүтән беркайчан да күрмәсәм нишләрмен?

Басыйр. Барыбер яшәргә кирәк. Гарифә, безне икебезне калдырып чыгып тор әле. *(Гарифә чыгып китә.)* Миннән яшермә... Монда кем белән элемтәдә торасың?

Илбәк *(аптыраган булып)*. Беркем белән дә элемтәдә түгел.

Басыйр *(яман тавыш белән)*. Кем белән очрашырга тиеш идең соң?

Илбәк. Үзләре мине каршы алырга тиешләр иде.

Басыйр. Каршы алдылармы?

Илбәк. Юк. *(Атасының күзенә карамаска тырыша.)*

Басыйр. Алдыйсың. Кем белән очрашасың яки очраштың?

Илбәк. Беркем белән дә очрашмадым, очрашмыйм да.

Басыйр. Элемтәгә кереп очрашуга чакырсалар — баш тарт, белмәмешкә салышу ягын кара, кыскасы, башыңны җүләргә сал. Чөнки, иманым камил, сине монда килгән беренче көнеңнән үк күзәтәләр. Кларaңа артыгын сөйләп ташлый күрмә.

Илбәк. Ярар.

Басыйр *(көлә)*. Шпион! Сине монда җибәргән кешене әйтер идем. Нинди разведчик инде син! Кем янына җибәргәннәр бит әле үзеңне! Каешланып беткән, тәҗрибәле чекист Гайнанов Басыйр янына! Адәм көлкесе!

Илбәк *(ихластан)*. Мин үзем теләп килдем Казанга! Сине күрәсем килде!

Басыйр озак итеп улына карап тора. Караңгылык. Сәхнә яктыра. Кларaның тутасындагы бүлмә. Илбәк белән Клара, салмак кына сөйләшеп, янәшә утыралар.

Клара *(йомшак кына)*. Менә никах укыттык.

Илбәк *(елмая)*. Кызык килеп чыкты — Казанга килгәч иң беренче танышкан кызга өйләнергә насыйп икән. Барыбер бәхетле кеше мин.

Клара. Эшеңдә әйтмәдеңме никах укытканыбызны?

Илбәк. Юк, никах турында әйтмәдем. Өйләнешкәнебезне беләләр.

Клара. Безнең комсорг каян ишеткәндер — килеп миңа шелтә белдерде. Комсомолка башың белән никах укыткансыз, диде. Тегү фабрикасы өчен хурлык, ди әле ул.

Илбәк. Аның өчен сиңа берни дә булмас бит?

Клара. Юктыр инде, нәрсә булсын. Никах укытучылар бер без генә түгел бит. Безнең цехта гына да никахлылар шактый.

Илбәк. Игътибар итмә! *(Илһамланып.)* Без хәзер ир белән хатын! Бу бит зур вакыйга!

Клара *(сөенә, ләкин тавышы моңсу)*. Ләкин бигрәк авыр заманда никахлаштык без, Илбәк.

Илбәк. Заманның мондыйлыгында безнең гаеп юк. Мин дә язмышым әллә ничекләр чуалып китәр дип уйламаган идем. Менә шул болганчыкта ярый әле син очрадың.

Клара. Күңел тыныч түгел.

Илбәк. Без хәзер гел бергә булачакбыз.

Клара. Сугышка китәм дип бүтән талпынма. Безнең балабыз туачак.

Илбәк. Талпынмыйм. Алмадылар бит инде.

Ишек шакыйлар. Клара сискәнеп китә. Биш кеше килеп керә. Икесе ишек катында калалар. Икесе өйне тентергә тотыналар. Берсе Илбәккә сораулар бирә.

— Акмуллин Илбәк Басыйр улы сезме?

— Мин.

— Төркия гражданинымы?

— Әйе.

— Сез шпионажда, Советлар Союзына көрәштә гаепләнәсез. Сез кулга алындыгыз!

Илбәкне алып чыгып китәләр. Клара баскан урынында катып кала. Ике шәүлә өйне тентүне дәвам итә. Караңгылык. Сәхнә яктыра. Басыйрлар йорты. Гарифә почмакта утыра. Басыйр үзен кая куярга белмичә арлыбирле йөри.

Басыйр *(шыңшый)*. Мин дөньяда иң бәхетсез кеше! Нинди язмыш бу! Нишләп болай килеп чыга соң бу?! Нишләп гел болганып тора бу тормыш?!

Гарифә *(кычкырып диярлек)*. Дөньяда бәхетле кеше бармы соң ул?

Басыйр *(теш арасыннан)*. Тик кенә утыр! Каһәр суккандыр мине!

Гарифә *(кинәт ярсып)*. Әйе, каһәр суккандыр, мөгаен! Үзеңнең кылган эшләреңнән соң әллә син рәхәт яшәрмен дип уйлаган идеңме? *(Кулларын селтәп иренә таба килә.)* Иң бәхетсез, имеш! Синдә генәмени кайгы! Мин? Әкълимә? Илбәк? Аның хатыны Клара? Барыбызда да кайгы җитәрлек! Әйе, каһәр суккандыр — сине генә түгел, мине дә, барыбызны да! Үзең гаепле! Күпме кешене бәхетсез иткән, күпме кешенең язмышын бутаган кеше син!

Басыйр *(хатынының сүзләреннән беравык телсез калып тора, кинәт шәлперәя)*. Мин беркайчан беркемне бәхетсез итәргә тырышмадым. Ник болай килеп чыга соң ул? Должностем, исемем, абруем бар, нинди дәрәҗәгә ирештем, ләкин шуның рәхәтен татый алмыйм. Чөнки үзем гел куркып яшим. *(Елый.)* Фронтка җибәрмиләр. Инде әллә ничә тапкыр үтендем, ялвардым. Монда кирәк син, диләр. Минем сугышка китәсем килә, тизрәк, тизрәк, тизрәк. Фронтка ник җибәрмәгәннәрен аңлыйм — тиздән мине дә кулга алачаклар. Бердәнбер котылу чарасы — сугышка китү.

Караңгылык. Сәхнә яктыра. 1942 ел. Кыш. Басыйрлар йорты. Гарифә гөлләргә су сибеп йөри. Баласын күтәреп Клара керә.

Клара *(ишек катыннан)*. Гарифә апа!

Гарифә *(куанып)*. И Клара, уз әйдә! Бир тизрәк баланы. *(Кларадан баласын ала.)* Чишен.

Клара *(чишенә)*. Гарифә апа, үземә генә куркыныч. Сиңа килергә булдым. Тутам зарлана, ачулана: шушындый вакытта бала таптың, дип битәрли. Аның белән мөнәсәбәтләр начарланып китте.

Гарифә. Ярый килдең әле, үземә дә бик ямансу, куркыныч иде. *(Баланы караватка яткыра.)* Итегеңне салма, идәнебез салкын.

Клара *(кулларын өреп җылыта)*. Байтак вакыт күрешкән юк бит инде.

Гарифә. Әйе шул. Басыйрны сугышка алдылар. Ялынып-ялварып, ниһаять, фронтка китә алды. Исән-сау гына булсыннар инде, Ярабби. Фердинандтан инде ике хат килде. Берсе фронтка барганда язылган, икенчесен инде окоптан язган. *(Утыралар.)*

Клара *(авыр сулап куя)*. Ә Илбәктән бер хәбәр дә юк.

Гарифә *(барып баланы карап килә)*. Булыр, балам, булыр, көтәргә кирәк, түзәргә кирәк. Безнең бурычыбыз хәзер — сабырлык белән көтү.

Клара. Шулайдыр инде. Якты көн бер килми калмас. Кеше бит җәза белән газап өчен генә килмидер бу дөньяга. Көтәргә кирәк, түзәргә кирәк.

Гарифә. Син миндә кал яшәргә. Икебезгә алай ук ямансу булмас. Баланы бергәләп карарбыз. Җиңелрәк булыр.

Клара *(күз яшьләрен сыпырып)*. Рәхмәт, Гарифә апа. Мин, дөресен әйткәндә, синең шушы тәкъдимеңә өметләнеп килгән идем дә.

Гарифә. Улыгызның исемен дә белмим бит әле мин.

Клара *(елмаеп)*. Җәмил дип куштык.

Музыка.

**6**

1943 ел. Германия. Берлин. Вилданның аерым йорты. Әкълимә, Вилдан.

Әкълимә *(тәрәзәдән тышка карап)*. Илбәкнең киткәненә биш ел узды. Күңелем каршы иде аның СССРга баруына. Аның атлыгып барасы килүен күргәч катгый итеп каршы килмәдем шул.

Вилдан *(өстәлдәге кәгазьләр өемен актара)*. Каты давыл купты бит.

Әкълимә *(газаплы)*. Берүк исән генә була күрсен инде, балакаем.

Вилдан. Аны анда сугышка җибәрмәделәр микән?

Әкълимә. Бик ихтимал. Хөкем итеп төрмәгә утыртмадылар микән? Мәхмәт әйтә, СССРда бер гаепсезгә дә «халык дошманы» дип гаепләп төрмәгә утырта алалар, ди.

Вилдан *(чыраен сытып)*. Аны ул әйтмәсә дә беләм мин.

Әкълимә. Үлем җәзасына хөкем итсәләр? Аллам сакласын, Аллам сакласын!

Вилдан. Юк ла. Атасын эзләп килгәне өчен үлем җәзасы бирмәсләр.

Әкълимә. Мәхмәт әйтә, Вилдан аны тикмәгә җибәрмәгәндер, ди. Синең абверда эшләвеңне белеп әйтә инде ул.

Вилдан. Күп сөйләшмәсен! Синең Мәхмәтең артык акыллы булып чыкты.

Әкълимә. Алай димә, бик миһербанлы кеше ул, аның ярдәме белән күпме авырлыкларны җиңдек бит.

Мәхмәт керә.

Мәхмәт. Көнчыгыш фронттагы хәлләрне ишеткәнсездер инде?

Вилдан. Ишеттек, ишеттек.

Мәхмәт. Чигенә вермахт гаскәрләре.

Вилдан *(кәгазьләре белән мәш килеп)*. Сөенәсеңме?

Мәхмәт. Сөенсәм дә, сөенмәсәм дә, фаразларым дөрес булып чыкты.

Вилдан. Сез тарихчыларның бер фаразы дөрес булса, унысы ялган була. Фаразларыңны, фикерләреңне бүтән беркайда беркемгә әйтмә, яме. Киеренкелек артканнан арта бара, гестапо подвалына төшмәгәең.

Мәхмәт *(Әкълимә янына килеп)*. Мин Төркиягә китәм.

Вилдан *(эшеннән туктый)*. Бар!

Мәхмәт *(борын астыннан мыгырдап)*. Нишләп синең белән Германиягә күчәргә ризалаштык без — үкенеп туялмыйм.

Вилдан *(кайнарланып)*. Әкълимә сеңлем минем белән китәргә теләде, ә син тагылып килдең.

Әкълимә *(үпкәләп)*. Вилдан абый! Мәхмәт минем ирем, ник аның белән дорфа сөйләшәсең?! Синең яшь хатының булганга, балагыз туганга күрә, сезгә ярдәмебез тияр дип килдек без монда.

Вилдан *(тынычланып)*. Рәхмәт! Гафу итегез, нервылар бөтенләй какшаган. Шул эмигрант кызына өйләнгәнем өчен дә допроска чакырып йөртteләр бит.

Әкълимә *(килеп кулын абыйсының иңенә куя)*. Хәзер йөдәтмиләр бугай бит инде.

Вилдан *(сыкранып)*. Нинди хәлдә калдым мин! Үзем илсез-ватансыз качак. Хатыным эмигрант кызы. Кем безне ихтирам итсен, кем безне кешегә санасын. Ничек миннән шикләнмәсеннәр!

Әкълимә *(ягымлы)*. Татар эмигрантының кызына, татар кызына өйләнүең яхшы булды. Язмышка рәхмәт укырга кирәк. Улың Тимер шулхәтле үзеңә охшаган.

Мәхмәт *(кулына китап алып, креслога утыра)*. Бәлки хәзер гаиләң турында күбрәк уйларга кирәктер, совет властена каршы көрәшү турында түгел.

Вилдан *(җикереп)*. Күп сөйләшмә! Минем коммунистлар белән мәңге бетмәслек конфликтым бар. *(Торып йөри башлый.)*

Мәхмәт *(китапка караган килеш)*. Ярты дөньяны канга батырган Гитлерга хезмәт итеп синең мәңгелек конфликтың хәл ителер микән?

Вилдан *(кыҗрап)*. Тыныңны чыгарма!

Мәхмәт *(китабын читкә куя)*. Син дә фашистларча әшәкеләндең, Вилдан.

Вилдан *(кычкырып)*. Мин фашист түгел. СССР — минем дошманым. Атам-анам үлеме өчен булдыра алганча мин аларга каршы көрәшәчәкмен! Басыйр яшәгән ил — минем өчен дошман!

Мәхмәт *(тыныч)*. Синең атаң-анаңны Басыйр үзе үтермәгән бит.

Вилдан. Басыйрга ышанып, аңа өметләнеп качырмадым мин әти белән әнкәйне. Бөтен бәлабез шул Басыйрдан башланды. Аны Себер якларыннан әти алып кайткач ук, мин, бала гына булсам да, йортыбызга кайгы кайтканны тойдым. *(Ямьсез итеп елмая.)* Мин Илбәкне СССРга Басыйрны кулга алсыннар өчен җибәрдем. Аны компрометацияләр өчен.

Әкълимә *(сискәнеп китә, әкрен генә абыйсына таба атлый)*. Иң беренче чиратта Илбәкне кулга алулары ихтимал дип уйламадыңмы?

Вилдан *(усал итеп)*. Минем тегеләй-болай уйлап торасым килми! Әйе, Илбәкне махсус җибәрдем! Чөнки минем үч аласым бар!

Әкълимә *(ыңгырашып)*. Ул бит минем улым!

Вилдан *(ярсып)*. Әйе, синең дә улың, шуңа күрә Басыйрларга каршы көрәшкә өлеш кертсен!

Әкълимә *(ачынып кычкыра)*. Син! Син! Син мине алып киттең Казаннан! Син мине алып чыгып китмәгән булсаң, мин үз илемдә яшәр идем. Улымны үзеңнең максатыңа ирешер өчен куркыныч астына куйдың.

Вилдан. Максатыма?! Алай икән... Димәк, барысына да мин гаепле?

Әкълимә. Илбәкне анда харап итсәләр, үзеңне гаепле санамассыңмы?

Вилдан *(башын куллары белән кысып)*. Атасын эзләп килгән кешегә нәрсә булсын! *(Диванга барып утыра, күзләрен йома.)*

Мәхмәт. Синең аңың томаланган. Большевикларның Басыйрдан да куркынычраклары бар, ә син һаман шул Басыйр исеме белән саташасың.

Вилдан. Минем иң беренче дошманым — шул.

Мәхмәт. Син Илбәкне коточкыч репрессияләр барган илгә җибәрдең. Сыйнфый көрәш дип шулкадәре үк фанатларча кыланырга ярамый.

Вилдан *(Мәхмәткә нәфрәт белән карый)*. Синең атаң белән анаңны подвалда атып үтермәгәннәр. Бик оста сөйләшәсең.

Әкълимә. Җитте! *(Үксеп елый.)*

Мәхмәт *(Вилданга якын килеп)*. Бәлки, син Илбәкне Басыйрның улы булганга күрә махсус рәвештә корбан итәргә карар кылгансыңдыр? Синең сеңлеңнең дә улы икәнен инкарь итеп? Сиңа, бәлки, Илбәк тә яртылаш дошмандыр?

Вилдан. Белмим. *(Башын күтәреп Мәхмәткә карап тора, теш арасыннан ысылдый.)* Ә менә син дошман!

Әкълимә *(үксеп аларның арасына керә)*. Вилдан абый, акылыңа кил!

Мәхмәт *(абаланып)*. Китәм Төркиягә! Миңа Германиягез дә, синең кебек каһарманнар да кирәкми!

Вилдан *(акрын гына торып баса, ямьсез итеп авызын кыйшайта)*. Беркая да китмисең! Сине бүген үк гестапо подвалына ябачаклар. Куралмыйм синең ише тарихчыларны, бук чәйнәүчеләрне!

Әкълимә. Вилдан абый! Акылыңа кил!

Вилдан *(диванга ава, сулкылдап еларга тотына)*. Әкълимә!

Әкълимә аны юата. Мәхмәт беравык карап тора да чыгып китә.

Әкълимә *(абыйсының башын кочып)*. Тынычлан, абый!

Вилдан *(сеңлесен кочаклап елый)*. Гафу ит мине, сеңлем! Мин үзем өчен генә түгел, синең өчен, балаң өчен курыктым. Шуңа сезне алып качтым Казаннан, Россиядән. Чит илләрдә үз теләгем белән йөриммени мин?!

Әкълимә *(ягымлы)*. Мин аптыраганнан гына әйттем, абый, чамадан артыграк кызып. Синең барыбыз өчен дә кайгырганыңны беләм. Сиңа рәхмәттән башка сүз юк. Ачуланма мине, яме. Мине шунысы нык куркыта... Син хәзер тәмам нәфрәт колына әвереләдең.

Вилдан. Әйе шул. Коммунистлар колы булырга гына язмасын.

Әкълимә. Арыдың син, абый. Синең холкың нык үзгәрде, син инде элекке Вилдан түгел. Бераз тынычланырга кирәк, гаиләң янында, улың янында ешрак булырга тырыш. Нәфрәт бит ул кешене нык ардыра.

Вилдан *(елаудан туктый)*. Сеңлем, син мине ярлыкамассың инде?

Әкълимә *(тынычлана)*. Ни өчен?

Вилдан. Илбәкне СССРга җибәргәнем өчен.

Әкълимә. Ярар инде... Ул бит үзе дә теләде атасын күрергә. Ниһаять, төп карарны ул үзе кабул итте бит.

Вилдан. Мәхмәт кайда?

Әкълимә. Юлга җыенадыр. Төркиядә аның эшләре бар. Барып кайтсын.

Вилдан. Миңа ачуы килгәндер.

Әкълимә. Юктыр. Ул олы йөрәкле, мәрхәмәтле кеше. Хәтерлисеңдер, Төркиядә шуның ярдәме белән аякка бастык бит.

Вилдан *(башын тотып)*. Сиңа өйләнүе дә кызганудан дип уйлыйсыңмы әллә?

Әкълимә. Кешене жәлләгәнгә күрә өйләнмиләр инде, яратып өйләнде ул миңа. *(Тагын тәрәзә янына бара.)*

Вилдан *(барып графиннан су салып эчә)*. Карале, Әкълимә, минем соңгы командировкам да абвер эшләре буенча булды. Польшага, Седльце шәһәренә бардым. Анда әсирләрдән легионнар төзиләр — Германия ягында сугышыр өчен. Идел-Урал легионын да төзеп яталар, анда татарлар, башкортлар, башка милләтләр дә бар. Мине махсус чакырдылар — киңәш өчен. Исемлекләрне тиз-тиз генә карап чыктым. Анда Гайнанов Фердинанд Басыйр улы дигән кеше бар — исемлектә күрдем. 1920 елгы. Фотосын карагач шаккаттым — тач Басыйр инде менә. Басыйрның үз фамилиясе дә Гайнанов иде бит. Мин кичекмәстән тагын Едлинга барам, аның кем икәнен ачыклыйм. Әгәр дә ул Басыйрның улы икән, мин аны үземнең шәхси әсирем итәчәкмен.

Әкълимә. Йөрмә!

Вилдан. Туктале син! Аны үземдә тотсам, Илбәккә алыштырып булмасмы.

Караңгылык. Сәхнә яктыра. Берничә ай вакыт узган. Әкълимә радио тыңлап утыра. Анда фронттан немец, инглиз, рус телләрендә сводкалар тапшыралар. Фердинанд шыксыз кыяфәттә Әкълимә каршында пәйда була, бер сүз дәшмичә басып тора. Фердинанд артыннан Вилдан керә.

Әкълимә *(Фердинандка текәлеп карап торганнан соң)*. Исәнмесез!

Фердинанд *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Исәнмесез!

Вилдан. Таныш бул, Әкълимә, бу — Басыйр белән Гарифәбезнең улы Фердинанд. *(Мыскыллы елмаю белән.)* Кайчан да булса Германиягә килеп эләгер диптер инде, Фердинанд дип исем кушканнар бит аңа.

Әкълимә *(чын күңелдән сөенеп)*. Утырыгыз, утырыгыз... менә монда. *(Фердинанд креслога утыра.)* Сезне инде бөтенләй азат иткәннәрдер?

Фердинанд *(төссез караш белән)*. Каян белим мин?

Вилдан *(читкә басып карап тора)*. Аны хезмәтче итеп үзебезгә алырга рөхсәт бирделәр. Кем уйлаган Басыйрның улын очратырбыз дип.

Әкълимә *(ягымлы тавыш белән)*. Ул Гарифәнең улы. *(Фердинандның каршысына утыра.)*

Вилдан. Мин аны Басыйрның улы булганга лагерьдан монда алып кайттым. Карале, Басыйрга ничек охшаган.

Әкълимә *(кызганып)*. Син аның ябыклыгын кара.

Вилдан. Анда совет солдатлары барысы да шыр сөяк кенә. Фердинанд сугышка киткәндә, безнең Илбәк аларда калган, ди. Безнең йортта матур гына яшәп яталар икән, кече йортта. Зур йортыбызга җыен хәерче пролетариатны тутырганнар, ди.

Әкълимә *(чиксез куанып)*. Чынлап та, Илбәк сездә, Басыйр белән Гарифә янында калдымыни?

Фердинанд. Әйе.

Әкълимә. Без бит аны югалттык.

Вилдан *(Фердинандка)*. Син безнең йорт янындагы солдатларны күргәнсеңдер инде?

Фердинанд *(шомраеп)*. Күрдем.

Вилдан. Алар безнең сакчыларыбыз, бер үк тыпырчынма, качу ягын уйлый күрмә, ерак китә алмассың.

Әкълимә. Ник качсын! Ул бездә яшәячәк, безнең гаиләбез кешесе булып.

Вилдан *(көлемсерәп)*. Ул хәзер безнең хезмәтчебез. Ләкин атасы Басыйр кебек гаиләбез вәкиле булмаячак.

Әкълимә *(ачуланып)*. Вилдан абый!

Вилдан. Син, сеңлем, гомергә шундый кызганучан йөрәкле булдың инде. Мин тиздән әйләнеп кайтырмын. *(Чыгып китә.)*

Әкълимә *(аналарга хас назлылык белән)*. Мин Әкълимә апаң булам. Әнкәң Гарифә белән бергә үстек.

Фердинанд *(карап торганнан соң)*. Сезнең турыда гел сөйли иде ул.

Әкълимә. Кайчан әсир төштең, балам?

Фердинанд. 1942 елны.

Әкълимә. И, Гарифә ут йотып ятадыр. Хатлар яза идеңме соң фронттан?

Фердинанд. Барлыгы унбер хат яздым.

Әкълимә. Әсир төшкәнеңне анаң белмидер?

Фердинанд. Ничек белсен инде ул!

Әкълимә. Чынлап та, минем улым Илбәк Казанда, сездә яшиме?

Фердинанд. Әйе.

Әкълимә *(тавышы калтырый)*. Атаң ничегрәк кабул итте соң аны?

Фердинанд. Бик әйбәт кабул итте.

Әкълимә. Син сугышка киткәндә Илбәк ничек иде соң?

Фердинанд. Ничек булсын, исән-сау иде. Ул үзе теләп фронтка китмәкче иде, алмадылар. Бәлки, соңрак алганнардыр да, белмим. *(Тәрәзәгә ымлап.)* Йортыгыз тирәсендәге кешеләр чынлап та сакчылармы?

Әкълимә. Әйе, безнең йортны саклыйлар. Курыкма, алар безнең тынычлыгыбызны, иминлегебезне сакларга дип махсус куелган солдатлар.

Фердинанд *(куркулы тавыш белән)*. Мине нишләтерләр икән?

Әкълимә *(якты елмаеп)*. Сиңа бездә беркем дә тимәс, улым. Син Гарифәнең улы булгач, үземнең улым кебек үк якын. Гарифә белән бит без чын туганнар кебек үстек — ике сеңел кебек.

Фердинанд. Мин дошман ягындагы кешеләрдә яшиммени инде хәзер?

Әкълимә *(гаҗәпләнеп)*. Кем дошман? Нинди дошман ягында?

Фердинанд *(кырын карап)*. Сез нацистларга хезмәт итәсез түгелме соң?

Әкълимә *(аптырашта кала)*. Кем, минме?

Фердинанд *(аска карап).* Белмим... Ә абыең...

Әкълимә *(усаллана)*. Ә син үзең легионга кереп Кызыл Армиягә каршы сугышырга җыенмадыңмы?!

Фердинанд. Минем тизрәк концлагерьдан котыласым килде. Ә Вилдан абыеңның тарафдары булырга теләмим! *(Дер-дер калтырарга тотына.)*

Әкълимә *(кинәт тынычлана)*. Сиңа аның тарафдары булырга беркем дә кушмый. Уйлап кара, сиңа бит язмыш елмайды — абый сине концлагерьдан һәм легион белән сугышка китүдән коткарды. Тыныч кына яшәп ят. Алга таба күз күрер.

Фердинанд *(сыктанып)*. Күз күрер... Үз илемә кайткач ни әйтермен? Әллә сез мине инде мәңге туган илемә кайтмам дип уйлыйсызмы?

Әкълимә *(пышылдап)*. Туган илебезгә кайту турында син генә түгел, хәтта без дә хыялланабыз.

Фердинанд *(пышылдап)*. Мин куркам. Безнең армия якынайганнан-якыная бара. Гитлерның да, барыгызның да... барыбызның да җавап тотасы булачак. Монда алып кайтып абыең миңа булачак хөкем карарын икеләтә катылатты.

Әкълимә *(торып китә)*. Ярый, әгәр дә син монда яшәргә җирәнәсең икән, үзең сайла, кая телисең — кире концлагерьгамы, легионнар белән фронткамы?

Фердинанд *(концлагерь сүзеннән куркып)*. Юк! Мин болай гына әйттем! Сезгә рәхмәттән башка сүзем юк! Мине беркая да җибәрмәгез! *(Калтырана.)*

Әкълимә *(килеп аны иңеннән коча)*. Тынычлан, тынычлан. Җикергәнем өчен гафу ит. Тынычлан, балакаем!

Караңгылык. Сәхнә яктыра. Атна-ун көн вакыт үткән. Бомбалар шартлаган тавыш ишетелә. Гөрселдәүләр якында гына яңгырый. Фердинанд тәрәзәдән тәрәзәгә йөгереп тышка карый. Әкълимә атылып килеп керә.

Әкълимә *(ишек яңагына сөялеп хәл алып тора)*. Көн саен ешрак бомбага тоталар.

Фердинанд *(йөгереп килә)*. Кайда булдың?

Әкълимә. Абый турында белешергә бардым. Беркем бернәрсә белми.

Фердинанд. Безнең сакчыларыбыз кая китте?

Әкълимә. Безне хәзер сакламыйлар. Вилдан абыйны кулга алганнардыр дип уйлыйм. Сакчыларның булмавын шуның белән бәйле дип саныйм.

Фердинанд *(ялварып)*. Абыең турында сорашып йөрмә инде, үзеңне дә кулга алулары ихтимал.

Әкълимә *(Фердинандка карап тора)*. Син куркасыңмы?

Фердинанд. Куркам!

Әкълимә *(түргә уза)*. Мин инде хәзер беркемнән дә, бернәрсәдән дә курыкмыйм. Өстебезгә бомба төшсә, бер мизгелдә барысы да тәмамланыр иде.

Фердинанд *(өзгәләнеп)*. Юк, юк, андый сүз әйтмә! Качарга кирәк!

Әкълимә *(тонык кына)*. Кая?

Фердинанд. Кая дип! Кешеләр качалар бит! Соңга калмагаек, качарга кирәк, качарга!

Әкълимә *(битараф)*. Кемнән, нәрсәдән? Үз язмышыңнан барыбер качу мөмкин түгел.

Мәхмәт атылып килеп керә.

Мәхмәт. Әкълимә!

Әкълимә *(кинәт җанланып)*. Мәхмәт!

Мәхмәт *(килеп Әкълимәнең кулын күкрәгенә кыса)*. Исәнме!

Әкълимә *(моңсу елмаеп)*. Күрәсең бит, әлегә исән.

Мәхмәт. Вилдан кайда? *(Каударланып бүлмә буйлап йөри.)*

Әкълимә. Вилдан абый юкка чыкты. Беркөнне хәзер кайтам дип чыгып китте дә шуннан югалды. Мин сине инде бүтән күрмәм дип уйлаган идем.

Мәхмәт. Ничек инде мин сине ташлыйм?!

Әкълимә *(почмакта ың-шыңсыз басып торучы Фердинандка ишарәләп)*. Таныш бул, бу — Фердинанд. Гарифә турында сиңа күп сөйләгәнем бар. Фердинанд шуның улы. Хәзер инде минем дә улым. Безнең улыбыз.

Мәхмәт *(бер мәлгә туктап)*. Каян килеп чыкты соң ул?

Әкълимә. Аннары аңлатырмын.

Мәхмәт. Тизрәк, мөмкинлек барда качарга кирәк! Җыеныгыз!

Әкълимә *(нәрсәгә тотынырга белми)*. Хәзер үкме?

Мәхмәт. Кайчан тагын? Өстеңә бомба төшкәнне көтеп утырырсыңмыни?! Тизрәк! Нәрсәләреңне аласың? Тиздән бу тирәдән көл генә калачак.

Әкълимә. Әйе, Мәхмәт, әйе. Моннан китәргә кирәк. Кая барабыз соң?

Мәхмәт. Төркиягә таба.

Әкълимә *(әйберләрен җыярга тотына).* Ә Вилдан абый?

Мәхмәт *(Әкълимәгә булышып)*. Исән булса ул безне эзләп тапмый калмас. Хәзер аны монда көтеп утырудан мәгънә юк. Киттек!

Якында гына бомба шартлый. Әкълимә, Фердинанд, Мәхмәт чыгып китәләр.

**7**

1946 ел. Кыш. Казан. Кларaның тутасы яши торган өй. Клара гөлләргә су сибеп йөри. Бусагада бер ир кеше пәйда була.

— Исәнмесез!

Клара *(сискәнеп китә)*. Исәнмесез!

Илбәк. Ялгыш кермәдемме?

Клара *(сулы савытын тәрәзә төбенә куеп, килә)*. Сезгә кем кирәк соң?

Илбәк. Җаныкаем, миңа барыгыз да бик кирәк. Син дә, улым Җәмил дә.

Клара. Илбәк!

Илбәк. Клара! *(Кочаклашалар.)*

Клара. Мин бит сине танымый торам.

Илбәк. Нык үзгәрдем мин. Нык үзгәрттеләр мине, Клара.

Клара. Соңгы вакытта төшләремдә еш күрдем сине, шул кайтасыңа булган икән.

Илбәк. Менә кайттым. Ничек яшәп ятасыз соң?

Клара. Яшибез инде, безнең гомерне без яшәмичә кем яшәсен.

Илбәк. Әйбәт әйттең, кеше үз гомерен яшәми кая барсын, аның өчен кем яшәсен аның гомерен.

Бик озак, тып-тын гына, бер-берсенә карап утыралар. Кларaның күз яшьләре ага да ага. Илбәкнең дә күзләре дымлы. Хатыныннан күзләрен алмый.

Клара. Туп-туры монда керәсе иттеңмени?

Илбәк. Юл уңае булгач, башта монда кереп тутаңның хәлен белим, дидем. Аннары... күңелем дә бик сизенде — синең монда икәнеңне. Улыбыз кайда соң?

Клара. Гарифә апада. Без бит һаман шунда яшибез. Тутам авырып хастаханәдә ята, бүген янына бардым, кереп гөлләргә су сибүемне үтенде.

Илбәк. Үзегез ничек соң?

Клара. Түзәрлек, Җәмилгә инде биш яшь, әти кайчан кайта, дип теңкәгә тия. Аның сине күргәне дә юк бит. *(Илбәкнең кочагына керә.)* Гарифә апаның гына аяк-куллары сызлап авырып тора.

Илбәк. Авырулар була инде ул, терелербез. Савыгырбыз, Алла боерса.

Клара. Мин дә гел шулай дим инде.

Илбәк *(пышылдый)*. Клара, җаным! *(Үбә.)*

Клара. Илбәгем! *(Иренең чәчләрен сыпыра.)* Чәчең ап-ак булган бит.

Илбәк. Себердә кар-буран күп. Анда агармый мөмкин түгел.

Клара *(бармагын иренең битенә тидерә)*. Битең җыерчыкланып беткән.

Илбәк. Күңелемне ачып карасаң иде син, андагы сызык-сызык канлы җәрәхәтләрне белсәң иде.

Клара. Атаңның похоронкасы килгәнне язган идек инде сиңа.

Илбәк. Әйе. Әти дә бу дөньядан китеп барды. Ә Фердинанд?

Клара. Син әле ансын белмисең — ул «без вести пропал» дип санала. Исәндерме-юктырмы, белмибез. Гарифә апа исәндер дип ышана. Көтәбез инде. Әле бит сугыш беткәнгә бер ел гына. Әле бит һаман кайталар да кайталар. Бөтенләй хәбәрсез югалганнар да кайтып керәләр.

Илбәк. Әйе, ышанырга, көтәргә кирәк. *(Уйга кала.)* Әнкәй анда Германиядә исән калды микән?

Клара *(ышанычлы итеп)*. Исәндер, нишләп исән булмасын. Ул да сине көтәдер, исәнлегеңә ышанадыр.

Илбәк. Әнкәйне күрмәгәнгә сигез ел вакыт узды. Мин инде аны бүтән күрә алмамын.

Клара *(елмаеп)*. Алай димә. Өметне җуймаска кирәк!
Илбәк *(шатлык белән)*. Клара!
Клара *(иренең муенына сарылып)*. Илбәк! *(Кочаклашалар.)*

Музыка.

**8**

Төркия. Истанбул. Әкълимә язып утыра. Фердинанд керә.

Фердинанд *(борчулы кыяфәт белән)*. Исәнме!

Әкълимә *(күзлеген сала)*. Исәнме, улым! Нишләп бик озак күренмәдең?

Фердинанд *(Әкълимәнең каршысына килеп утыра)*. Вакыт булмады.

Әкълимә *(кәгазьләрен читкәрәк куеп)*. Беркайда эшләмәүче кешенең вакыты шулай аз була инде аның. Мәхмәтне җирләгәннән соң бер тапкыр акча сорап килдең дә, шуннан бирле күренгәнең юк.

Фердинанд *(чыраен караңгылатып)*. Хәлем начар минем.

Әкълимә. Үз хәлеңне үзең кайгыртмасаң, беркем дә килеп синең өчен аны эшләмәс. Әнә Мәхмәт нинди абруйлы тарихчы, галим иде, беркемнең читтән килеп, йөрәгең авырта, үзеңне сакла, әйдә, сәламәтлегеңне кайгыртыйк, дигәне булмады. Үзе дә минем әйткәннәрне тыңламады, йөрәге турында онытып эшләде дә эшләде. Кеше үзен-үзе нык карарга тиеш, үзенең киләчәген, үзенең сәламәтлеген кайгыртырга тиеш.

Фердинанд. Чит-ят илләрдә үзеңнең киләчәгеңне кайгырту авыр шул.

Әкълимә. Гел язмыштан зарланып, гаепне башкалардан күреп яшәү дөрес түгел ул. Мәхмәт сине укырга кертте, укыйсың килмәгәч, эш табып бирдек үзеңә, авыр эш дип, эшне дә ташладың.

Фердинанд. Ярдәм итәргә тырышса да, ул миңа барыбер әрәмтамак дип карады.

Әкълимә *(кырысланып)*. Без сиңа үзебездә яшәргә шартлар тудырдык, ә син аның белән гел конфликтта булдың. Аның бер-бер артлы инфарктларында синең дә өлешең бар.

Фердинанд *(торып баса)*. Әйе, әйдә, аның үлүен миңа сылта инде тагын.

Әкълимә. Сылтамыйм, ләкин шундый яхшы кешегә синең бер генә тапкыр да җылы сүз әйткәнең булмады.

Фердинанд *(киштәдәге китапларны карап)*. Төрекләрне яратмыйм мин. Мин аңа нинди начарлык эшләгән — гел нотык укырга тотына иде, тегеләй ярамый, болай ярамый, гел оялтырга тырышып, гел битәрләп...

Әкълимә. Миннән акча даулавыңны яратмады ул. Мин синнән беркайчан да акча кызганмадым. Тагын бирермен акча. Ләкин үзеңә дә эшләп ашарга өйрәнер вакыт. Минем белән берәр нәрсә була калса, нишләрсең?

Фердинанд *(зар белән)*. Үзегез мине концлагерьдан йолкып чыгардыгыз, үзегез мине монда Төркиягә алып киттегез.

Әкълимә. Һаман бер үк сүзне кабатлыйсың син. Синең җавабың һәрвакыт әзер. *(Торып өстәлнең эскәтерен төзәткәли.)*

Фердинанд *(үпкәле)*. Сез булмасагыз, минем язмышым башка юнәлештә китәр иде. Бәлки инде хәзер Казанда ата-анам янында яшәп ятар идем.

Әкълимә *(кайгылы)*. Казан, Казан... Илбәк, җаным-бәгърем, исән микән?

Фердинанд. Нәрсә булсын аңа, аны бит сугышка да алмадылар.

Әкълимә. Әй балам, балам, әллә монда кире киләсе килми микән?

Фердинанд. Аны Төркиягә кем чыгарсын аннан?!

Әкълимә *(уйга чума)*. Мин монда Илбәкне сагынып картаеп ятам, ә тегендә Гарифә сине көтеп саргаядыр. Вилдан абыйның кабере кайда икәнне дә белмим. Бар микән аның кабере?

Фердинанд. Аны үтергәннәрмени соң?

Әкълимә. Әйе, хәзер инде шик калмады. Мәхмәт Германиягә барып белешеп кайткан иде. Офицерлар төркеме Гитлерга покушение ясаганнан соң, эмигрантлар арасында да «чистарту» ясаганнар — кулга алып, күбесен үлем җәзасына хөкем иткәннәр — гаеплесен дә, гаепсезен дә. Абыйга да шик төшкәндер, күрәсең. Ярый әле, ичмаса, гаиләсен Аргентинага озатып кала алды.

Фердинанд. Адашкан кеше иде ул.

Әкълимә *(кинәт усалланып)*. Ул сине коткарган кеше! Бүтән беркайчан да минем Вилдан абыем исеменә тел-теш тигезәсе булма!

Фердинанд. Ярар.

Әкълимә *(тынычланып)*. Син һаман шул фахишә белән яшәп ятасыңмы?

Фердинанд. Фахишә түгел инде ул.

Әкълимә. Фәхешханәдә эшләгән нәмәрсә кем була инде?

Фердинанд. Ул анда башка эштә булган.

Әкълимә. Алар бөтенесе бер иш. *(Пауза.)* Тагын акча кирәкме?

Фердинанд *(читенсенгәндәй)*. Без тиздән Америкага китәбез. Безне анда эш урыны әзерләп көтәчәкләр. Миңа бераз акча кирәк... хәзергә.

Әкълимә *(Фердинанд янына килә)*. Бирермен, бирермен, улым. *(Күңеле йомшарып китә, Фердинандны аркасыннан сөя.)* Их, Фердинанд, Фердинанд. Син бит Гарифәнең улы. Сагынасыңмы соң анаңны?

Фердинанд *(җебеп)*. Әлбәттә. Мине бөтенләй үк җансыз кешегә санама инде! Болай да күңел гел җирсеп тора. *(Еламсырый.)* Бәхетсез мин, бәхетсез! Минем ни гаебем бар соң?!

Әкълимә. Бәхетсезлегеңнең сәбәпләрен башкалардан күрсәң, башкаларны гаепләсәң, тагын да бәхетсезрәк булачаксың, улым, шуны исеңдә тот. *(Акча алып килеп бирә.)* Менә шуның хәтле генә, артыгын бирә алмыйм. Тәрҗемә өчен хәзер аз түлиләр, тормышымның матди ягы куанычлы түгел.

Фердинанд *(акчаны куен кесәсенә тыга)*. Рәхмәт! *(Әкълимәнең кулын ике куллап кыса.)* Ярый син бар әле. Син үзеңне сакла инде, бик күп эшлисең.

Әкълимә *(эш өстәле янына килә)*. Минем куанычым, юанычым шул эшемдә генә инде. Ярый әле тәрҗемә эшен дә, укытучылыкны да яраттым, хәлемнән килгәнчә эшләсәм яшәргә була, Алла боерса.

Фердинанд *(күтәренке кәеф белән)*. Ярый, киттем мин!

Әкълимә. Хуш!

Фердинанд чыгып китә. Әкълимә эшен дәвам итә.

**9**

1956 ел. Көз. Казан. Илбәк радио төзәтеп утыра. Гарифә авыр хәлдә урын өстендә ята.

Гарифә *(әкрен генә)*. Илбәк, улым, синең яңа эшең нинди соң?

Илбәк. Мин шул ук заводта, элек мастер идем, хәзер участок начальнигы итеп куйдылар.

Гарифә *(горурланып)*. Менә бит ничек күтәрделәр сине.

Илбәк. Үзем дә аптырадым инде. Минем биографиям белән...

Гарифә. Яхшы кешене аны әллә каян күрәләр. Син анаңа охшагансың. Әкълимә дә олы җанлы, йомшак күңелле, миһербанлы кеше иде. Шуңа күтәрәләр сине.

Илбәк. Ай-һай, белмим. Кайвакыт кешенең яхшылыгы үзенә хилафлык китерә. Алга таба ничек булыр...

Гарифә. Җәмил кайчан кайта?

Илбәк. Бүген соңрак кайтырмын, диде. Класcташ малай белән ниндидер эшләре бар. Үсмерләр бит, кызлар белән дә йөри башладылар бугай инде.

Гарифә *(түшәмгә карап)*. И гомерләрнең узуы диген.

Клара кайтып керә. Сумкасында ашамлыклар, дарулар.

Клара. Уф, хәлдән тайдым. *(Алып кайткан әйберләрен урнаштырып.)* Нишлисең?

Илбәк *(радионың эчен җентекләп карый)*. Теге иске радионы рәтлим.

Клара *(Гарифәгә)*. Барлык кирәк дарулар бар хәзер. Ныклап дәваланабыз. *(Даруларны Гарифәнең караваты янындагы тумбочкага куя.)* Мин хәзер ашарга пешерәм.

Гарифә. Рәхмәтләр яусын сезгә, балакайларым! Сез булмасагыз, нишләр идем.

Клара. Син булмасаң, без нишләгән булыр идек!

Гарифә. Балакайларым, зинһар, якынрак килегез әле. *(Илбәк белән Клара, шомланып, Гарифә янына килеп утыралар.)* Мин инде озак булмам.

Илбәк *(елмаеп)*. И, Гарифә апа, андый сүз әйтмә инде. Даруларың бар, без һәрвакыт яныңда, савыгырсың, Алла боерса, аякка басарсың.

Гарифә *(газаплы)*. Миңа инде дару-мазар ярдәм итмәс. Улымны күрү өметем инде өзелде, хәзер бу дөньядан китәргә дә вакыттыр.

Клара *(катгый)*. Бирешергә маташма әле! Без бар бит.

Гарифә *(ыңгырашып)*. Мин дә улымны югалттым, Әкълимә дә. Ярый ла Илбәк исән. *(Пауза.)* Әкълимәне дә бүтән күрергә язмаган икән.

Илбәк. Туктале, Гарифә апа, әйдә әле, даруларыңны эчеп куй башта.

Гарифә. Мине ярлыкагыз, балакайлар. Әкълимәнең үзеннән ярлыкау сорарга мөмкинлек юк, сез ярлыкагыз. Мин гомерем буе күңелемдә авыр гөнаһ йөге асрап яшәдем. Мин үземдә бик зур гаеп, зур гөнаһ тоям, мин бүгенге көнгә кадәр үземне гаепле дип саныйм. 1919 елны мин Әкълимәләргә ияреп чыгып китәргә тиеш идем. Ә мин калдым. Минем калуымнан бер файда булмады — Акмуллиннар йортын да саклап кала алмадым. Миннән сораучы да булмады, бүлгәләделәр йортны. Шуның өстенә Басыйрның хатыны булдым. Хәер, моның өчен Әкълимә мине каргамас иде, ләкин... Без бит Әкълимә белән шулкадәр якын идек, ике сеңел кебек. Аның белән ияреп киткән булсам, минем язмышым болай ук ачы булмас иде, мөгаен.

Музыка. Караңгылык. Гарифә вафат була.

**10**

1985 ел. СССРда үзгәртеп кору процессы башланган. Михаил Горбачевның чыгышы ишетелә. Кабинет. Түрдә караңгылык. Алтмыш алты яшьлек Илбәк керә.

Илбәк *(караңгылык эченә эндәшә)*. Мөмкинме?

Тавыш. Акмуллин Илбәк Басыйр улымы?

Илбәк. Әйе.

Тавыш. Унтугызынчы елны туганмы?

Илбәк. Әйе. Нәкъ шулай. Мин гариза язган идем.

Тавыш. Укыдым. Сезнең үтенечне канәгатьләндерү мөмкин түгел. Сез дөрес аңлагыз...

Илбәк. Бу бит минем бердәнбер үтенечем. Мин хәтта реабилитация дә сорап йөрмәдем һәм сорарга җыенмыйм да. Менә шушы гозеремне генә үтәгез.

Тавыш. Сезне бер кешенең күрәсе килгән иде.

Илбәк. Кем ул?

Кабинетта ап-ак чәчле, картайган Умаров пәйда була.

Тавыш *(караңгылык эченнән)*. Иптәш генерал-майор!

Умаров. Әйе, әйе... Исәнмесез!

Илбәк. Исәнмесез!

Умаров *(караңгылыкка)*. Безнең икебезне генә калдырчы!

Тавыш. Аңладым.

Умаров *(елмаеп)*. Утыр, Акмуллин Илбәк Басыйр улы. *(Түргә утыра.)*

Илбәк. Миңа сезнең йөзегез таныш. *(Өстәл янындагы урындыкка утыра.)*

Умаров. Миңа да таныш синең йөзең.

Илбәк. Сез...

Умаров. Умаров мин, Умаров, ялгышмыйсың, дөрес таныдың. Пенсиядәге картлач мин хәзер. Синең гаризаң турында миңа өемә шылтыратып хәбәр иттеләр. Менә килергә булдым. Үзеңне дә күрәсем килде.

Илбәк *(тетрәнеп)*. Ничек болай?.. Сез...

Умаров. Үз күзләреңә үзең ышанмыйсыңдыр, шулаймы?

Илбәк. Әйе, ышанып булмый.

Умаров. Аптырама. Вилдан абыең сине монда җибәргәндә, аларның Казандагы резидентурасы кулга алынган иде инде. Резидентура кешесен «уйнап» сине каршы алырга мине билгеләгәннәр иде.

Илбәк. Димәк, Казанга килү белән үк мин совет чекисты белән очрашканмын.

Умаров. Шулай килеп чыкты инде.

Илбәк. Сез минем шпионлык эшенә алынырга теләмәгәнемне белдегез. Фәкать атамны күрәсем килгәнне аңладыгыз.

Умаров. Германия белән сугыш башланмаса, бәлки, сине кулга алмаслар иде.

Илбәк. Сез шәхсән бит минем разведкага хезмәт итүдән баш тартуымны аңладыгыз, нишләп төрмәдән коткармадыгыз?

Умаров. Ул очракта үземә шик төшәр иде.

Илбәк. Ай-яй кайгылы гасыр бу. Башыма сыйдырып бетерә алмыйм.

Умаров. Әтиең Гайнанов Басыйр Кәрәм улы сугышка китеп котылды.

Илбәк. Котылды дисезме? Ул бит анда һәлак булды.

Умаров. Сугышта геройларча һәлак булу лагерьларда өшеп үлүгә караганда яхшырак түгелме? Ул чыннан да геройларча һәлак булган.

Илбәк. Мин әнкәмнең исәнме-юкмы икәнен белмим. Исән булса, эзләп табарга, исән булмаса, ичмаса, каберенә барып баш ияргә рөхсәт бирсеннәр өчен гариза язган идем.

Умаров. Әйе, менә минем алдымда ул гариза. Синең әнкәң исән.

Илбәк. Чын әйтәсезме?!

Умаров. Чын әйтәм. Кызганыч ки, сиңа чит илгә чыгу рөхсәт ителми.

Илбәк. Сез минем язмышны энәсеннән җебенә кадәр беләсез. Германиягә анам янына барырга рөхсәт алырга ярдәм итегез!

Умаров. Синең анаң Төркиядә.

Илбәк. Төркиядә?

Умаров. Әйе. Күптән инде.

Илбәк. Ә Вилдан абый?

Умаров. Вилдан абыеңны хөкем итеп атып үтергәннәр.

Илбәк. Нәрсә өчен?

Умаров. Төгәл әйталмыйм.

Илбәк *(уйга кала)*. Нинди гасыр бу?! Бу гасырның кайгысын кичеп чыгу мөмкин булырмы? *(Умаровка башын күтәреп карый.)* Бабам шулай дигән.

Умаров. Купец Акмуллинмы?

Илбәк. Бабай дигәннән... Минем икенче бабам революционерларның беренчеләре рәтендә булган. Без бик зур бәя түләдек! Анамны күрергә рөхсәт итегез!

Умаров. Менә нәрсә... Сине 1938 елдан белгәнгә күрә, үз җаваплылыгым астында, Төркиягә барырга рөхсәт юллап карармын. Барып чыгармы, юкмы — белмим.

Музыка.

**11**

Төркия. Әкълимә киң бүлмә уртасында утыра, ап-ак яулык бәйләгән. Ул инде бик карт. Илбәк керә. Илбәк тә инде олы яшьтә, бераз бөкрәйгән. Анасына карап тора. Әкълимә аны абайлап тыныч кына карап утыра. Илбәкнең теле «исәнме!» дип әйтергә әйләнми, чөнки әнкәсе гомер буе аның күңелендә йөрде, ул аның белән күңелендә беркайчан да аерылмады.

Илбәк *(карлыккан тавыш белән)*. Әнкәй! *(Якынрак килә.)* Әнкәй! *(Анасының каршында тезләнә.)* Кичер мине! Ярлыкагыл!

Әкълимә. Илбәк улым, синме?

Илбәк. Мин, әнкәй, мин.

Әкълимә. Ник болай озак югалып тордың, улым?

Илбәк. Озакка югалдым шул, әнкәй. Тиз генә синең яныңа әйләнеп кайтырмын дип уйлаган идем. Ялгышканмын.

Әкълимә. Мин бит сине бик сагындым, улым.

Илбәк. Мин яшьлегем белән җиңелрәк уйлаганмын. Нинди читлеккә эләгәсемне белми чыгып киткәнмен. Белгән булсам, сине ташлап китеп барыр идеммени?!

Әкълимә. Син Казаннанмы?

Илбәк. Әйе, әнкәй. Мин сине туган иленә алып кайтам, әнкәй, Казанга.

Әкълимә. Мине Казанга алып кайтасыңмы, улым?

Илбәк. Әйе, әнкәй.

Әкълимә. Нишләп болай картайдың, улым? Чәчләрең ап-ак.

Илбәк. Мин бит инде алтмыштан уздым, әнкәй.

Әкълимә. Мин сине күрмичә бу дөньядан китәрмен дип курыккан идем.

Илбәк. Алай булырга мөмкин түгел иде, әнкәй. Бер-беребезне тапмыйча бу дөньядан китү зур хата, гаделсезлек булыр иде.

Әкълимә. Мин бит синең бу дөньяда барлыгыңны, исән икәнлегеңне тоеп яшәдем, улым.

Илбәк. Мин дә, әнкәй, көн саен сине уйлап йөрмәсәм, төрмәләрдән исән калып чыкмаган булыр идем.

Әкълимә. Төрмәләрдә дә утырдыңмыни, улым?

Илбәк. Күптән булган хәл инде ул. Күп вакыт узды. Минем инде оныкларым бар бит, әнкәй. Бер оныкам сиңа шулкадәре охшаган.

Әкълимә. Синең оныкларың ук бармыни?

Илбәк. Минем улыма — кырык җиде, кызыма кырык ике яшь. Инде сиңа охшаган оныкам кияүгә чыгарга йөри. Әнисе генә каршы, укып бетермичә чыкмыйсың, ди.

Әкълимә. Синең хатының кем соң?

Илбәк. Клара исемле.

Әкълимә. Татармы соң ул?

Илбәк. Татар.

Әкълимә. Сине яратамы соң ул?

Илбәк. Ярата, әнкәй, яратмаса, минем белән бөтен авырлыкларны ерып яшәмәс иде. Мин сине Казанга алып кайтам, анда сине барысы да зарыгып көтәләр.

Әкълимә. Мин анда кайта аламмы соң?

Илбәк. Әлбәттә. Мин сине күтәреп булса да Туган иленә алып кайтам, әнкәй. Анда нинди үзгәрешләр булганын ишеткәнсеңдер инде.

Әкълимә. Әйе, әйе.

Илбәк. Әнкәй!

Әкълимә. Улым! Илбәк, җаным-бәгърем! Хәзер инде тынычлап үлсәм дә була.

Илбәк. Үләргә ашыкма әле, әнкәй. Безнең бит болай да бергә яшәгән бәхетле елларыбыз бик аз булды.

Әкълимә. Әйе, бигрәкләр дә моңлы, кайгылы гасырда яшәргә туры килде шул. Күкрәк сөте имүче баламны күтәреп фронтлар аша Казаннан Төркиягә качу кирәк иде микән?!

Илбәк. Андый сорау бирмә хәзер, әнкәй. Без шушы вәхши гасырның коллары гына бит. Хәлеңнән килсә, кичер мине!

Әкълимә. Улым, җаным-бәгърем, син үзең мине ярлыкагыл!

Музыка.

**12**

2006 ел. Телевидениенең ОРТ каналыннан «Жди меня» тапшыруы бара.

Алып баручы. Итак, это передача «Жди меня». Нам позвонили из Аргентины. Позвонил нам Акмуллин Тимер Вильданович 1944 года рождения. У него в России должен быть дядя, живет он в Казани, зовут его Акмуллин Ильбек Басырович. Он очень хочет увидеть его, если же его нет в живых, то желает встретиться с его детьми и внуками...

Алып баручының тавышы әкренәя, аннары бөтенләй юкка чыга. Сәхнәдәге зур экранда егерменче гасыр вакыйгалары бер-бер артлы уза. Шул фонда Илбәк чыга. Аңа инде сиксән җиде яшь. Икенче яктан алтмыш өч яшьлек ак сакаллы кеше күренә. Бу — Вилданның улы Тимер. Илбәк белән Тимер бер-берсенә таба атлыйлар. Кул биреп күрешәләр, кочаклашалар.

Тимер. Исәнме, Илбәк абый!

Илбәк. Исәнме, энем!

Тимер. Мин Аргентинадан килдем. Мин — Акмуллин Тимер Вилдан улы.

Илбәк. Акмуллиннар нәселенең дәвамы бар, Аллага шөкер! Хуш килдең, энем! *(Кочаклашалар.)* Акмуллиннар нәселе исән әле!

Тимер. Мин гомерем буе сезне бер тапкыр да күрмәгән килеш сагынып, юксынып, күрәсем килеп яшәдем. Минем инде балаларым, оныкларым бар. Хәтта алар да, минем кебек, бер дә аягыбызны басмаган шушы җирне сагыналар. Аңлатып булмаслык җирсү тынгы бирми.

Илбәк. Бабаларының туган туфрагы тарта, Тимер энем.

Тимер. Тормыш-көнкүрешебез яхшы булуга карамастан, җанда ниндидер газап бар.

Илбәк. Ул гасыр газабы. Гасыр моңы сыкрата күңелләребезне. Без шушы гасыр балалары. Безнең газап — ул безнеке. Бәлки, без гаепле дә түгелдер гасыр чуалышларында, ләкин бу сынауларны үтәргә безгә язган. Гасыр моңын без азагына кадәр кичерергә тиешбез. Үзебезнең гасырыбыз бу. Без яшәдек бу гасырда. Үзебезнең язмышыбыз бу. Без үзебез бу!

Музыка. Сәхнә караңгылана. Сәхнә яктыртганда, Акмуллиннарның гасыр башындагы йорты. Анда Акмуллиннар гаиләсе утыра. 1906 елгы күренеш. Акмуллин Сәләхетдин Бикморза улы, Акмуллина Хәбибә Солтангәрәй кызы, Акмуллин Вилдан, Акмуллина Әкълимә, Гарифә — асрамага алынган хезмәтче кыз, Басыйр — асрамага алынган малай. Алар, фотосурәттәге кебек, тып-тын, хәрәкәтсез утыралар. Сәхнә алдында сиксән җиде яшьлек Илбәк карт басып тора.

Илбәк. Ай-яй моңлы гасыр бу. Ай-яй хәтәр гасыр булды бу. Бу гасырның газабын кичеп чыктыкмы? Аны кичеп чыгу мөмкинме?

Музыка.

Тәмам.

*2006*

# ЧАПТЫ АТЫМ КАЗАНГА

*(Ике пәрдәле пьеса)*

КАТНАШАЛАР:

Салих — авыл завклубы, 40 яшьтә.
Җәмилә — Салихның хатыны, 40 яшьтә.
Мулланур — авыл җитәкчесе, 45—50 яшьләрдә.
Мирза — чит райондагы мал врачы, 40—45 яшьләрдә.
Рим — Мирзаның улы, 18 яшьтә.
Локман — Салихның классташы, Казанда яши, журналист, 40 яшьтә.
Гөлнур — Салихның классташы, Локманның хатыны, 40 яшьтә.
Чулпан — Локманның кызы, 18 яшьтә.
Минәзәл — пост милиционеры, 25—30 яшьләрдә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Салихлар йорты. Җәмилә камыр баса. Салих үз уйлары белән бүлмә буйлап атлый.

Салих *(горур һәм тантаналы кыяфәт белән)*. Ишеттеңме, Казан каласына мең ел тула икән?

Җәмилә *(камыр баса-баса)*. Мең?.. *(Ясалма кызыксыну белән.)* Кайчан?

Салих *(көзге каршына килеп туктый)*. Шушы арада. *(Уйга калып.)* Чынлап та, башкалабыз шулай ук олы яшьтә микән?! Мең яшь тула микәнни Казанга да?!

Җәмилә *(камыр изә-изә)*. Инде сиңа кырык тулганны, Казанга гына мең бардыр.

Салих *(барып диванга чалкан ята)*. Казанга барам!

Җәмилә. Кая, кая?!

Салих. Казанга!

Җәмилә. Ник?

Салих. Баян апкайтам. Мең еллык тарихлы башкалабыз була торып, нишләп әле мин моңга, музыкага сусап яшәргә тиеш?!

Җәмилә. Казанга киеп барырга синең рәтле күлмәгең дә юк бит, бөтенесенең якасы кырылган

Салих *(бу юлы үзенең фәкыйрьлегеннән ниндидер горурлык хисен барлап һәм чынбарлыктан сәер өстенлек абайлап)*. Спонсор эзләп йөрүче кешенең өс-башы сәләмә булырга тиеш аның.

Җәмилә. Автобуска акча бирмим.

Салих. Ничек инде бирмисең?!

Җәмилә. Булмагач, каян алып бирим мин аны.

Салих. Ә бәрәңге саткан акча кая?

Җәмилә. Оныттыңмыни жимпер алганны. Күпмелек саттың соң син бәрәңгене?! *(Еламсырап.)* Кешедән оят — ничә ел инде бер пәлтә киеп йөрим.

Салих. Шыңшыма, хатын. Ярый әле шул начар гына пәлтәне киеп куярга менә дигән фигураң, чибәрлегең бар.

Җәмилә. Шул телең генә коткара инде сине.

Салих. Кешене нәрсә булса да торымнан торымга коткарып торырга тиеш, хатын. Сорамыйм мин синнән акча. Кая яшереп куйганыңны да, ничә сум икәнен дә беләм, әмма вә ләкин таләп итмим. *(Торып утыра.)* Хәлем кинәт начарланып китте әле. *(Тагын чалкан ята.)*

Җәмилә. Тагын депрессиядер.

Салих. Шулайдыр. Тик менә бу юлысы тирәнрәк төште бугай бу депрессия. *(Күкрәгенə уа, ыңгыраша.)*

Җәмилә. Чын әйтәсеңме син? *(Кулларын камырдан чистарта башлый.)*

Салих. Нишләп мин шаярып ятыйм!

Җәмилә *(якынрак килә)*. Фельдшерны чакырыйкмы?

Салих *(чыраен сытып)*. Кирәкми. Аның «зеленка»дан башка бүтән даруы юк. Миләш кайнатып эчәргә куша бит ул ничек авырсаң да. Син Мулланурны чакыр. Салих үлә, диген. Үләр алдыннан әйтәсе сүзләре бар, диген. Бар. *(Җәмилә куркып елый.)* Елама. Син бит мине жәлләп еламыйсың. Син теге яшереп куйган акчаңны минем үлемтеккә тотарга туры киләчәк дип борчылып елыйсың.

Җәмилә. Ни сөйлисең инде син, җүләр. Фельдшер «скорый» чакыртсынмы каладан?

Салих. Кирәкми «скорый» чакыртырга! Барыбер кеше үлгәч кенә килеп җитә ул. Мулланурны чакыр.

Җәмилә. Авыл җитәкчесен чакыру яхшы түгел.

Салих. Ә аңа әйтәсе сүзләремне әйтми бу дөньядан китеп баруым яхшы булырмы?

Җәмилә. И Ходаем!

Чыгып йөгерә. Кыяфәте йончыганрак булсын өчен, Салих чәчләрен тузгыта, күлмәк төймәләрен чишә һәм куркыныч позада диванга кәкрәеп ята. Җәмилә белән Мулланур атылып килеп керәләр.

Мулланур. Нишләдең, Салих?

Салих *(сыкраулы тавыш белән)*. Миңа инде күп калмагандыр. Мин инде озак булмам. Алай-болай кинәт ычкына калсам, сиңа исән чакта әйтәселәремне әйтеп калдырыйм инде.

Мулланур. Әй, кыланма инде. Депрессияме, гадәттәгечә?

Салих. Монысы актык депрессия инде.

Мулланур. Сиңа берәр нәрсә кирәктер инде тагын.

Салих. Ник алай дисең?

Мулланур. Син бит кирәк нәрсәне гел шулай кыланып сорыйсың.

Салих *(ыңгырашып куя)*. Алай түгел, иптәш Мулланур. Синең завклуб булып эшләгәнең юк, шуңа күрә көләсең.

Мулланур. Көлмим. Кай җирең авырта?

Салих. Җан сызлый.

Мулланур. Алайса, сиңа авыл җитәкчесе түгел, берәр мөфти кирәктер.

Салих. Юк, син дә кирәк! Син кайгыртырга тиеш авыл мәдәниятен!

Мулланур *(Салихның чыраена карамаска тырышып).* Нәрсә кирәк инде тагын?

Салих *(ыңгырашып)*. Баян.

Мулланур. Мин сиңа ничә мәртәбә әйттем: баянга түгел, авыз гармунына да акча юк! Нәрсә син, баян да баян дисең һаман! Тегесен урлатмаска идең. Рәхмәт әйт үзеңнән түләттермәгәнем өчен.

Салих. Рәхмәт.

Мулланур. Нигә син шул гомердән бирле баян дип саташасың! Баян бит ул — нимес инструменты! Хватит, нимес көенә биергә!

Салих. Үзебезнең инструмент юк бит.

Мулланур. Булмаса ни... Нормально яшибез бит әле. Клубта кино күрсәтми башлагач та алай зур үзгәреш сизмәдем, китапханәгә яңа китаплар кайтмаганнан да беркем үлмәде. Гомергә уен коралыбыз булмады өебездә, ә аңа карап кеше арасында ким-хур булмадым. Гомеремдә бер китап укымадым — ә менә гел җитәкче должностьларда эшлим. Менә, ачуым килмәгәе, клубың җимерелеп төшсен, әйеме, аңа карап дөнья җимерелмәячәк, валлаһи газим.

Салих. Алай фикерли башласаң... Әйе, мәсәлән, синең алгы дүрт тешеңне сугып төшергәннән авылга бернинди зыян килмәячәк, шулай бит инде...

Мулланур *(кинәт усалланып)*. Аңламадым?

Салих. Мин фәкать сезнеңчә фикерли генә башладым.

Мулланур. Әле болай фикерләрлек булгач, димәк, хәлең бер дә мөшкел түгел. Син минем белән алай сөйләшмә, яме. Депрессия дип тормам... Үләргә ятучы кеше мондый амбициозный булмый ул. Дөресен әйткәндә, завклуб әфәнде, сине күргәч минем үземнең яшисем килми башлый. Мало того, бу дөньядан мин синең аркада туйдым, вот так!

Җәмилә. Мулланур абый, сез аңа ачуланмагыз инде. Ул кайвакыт ни әйткәнен аңламый да кала. Яз-көз аның неврозы көчәя.

Мулланур. Яз-көз, яз-көз... Син, әйдә, клубтагы булган нәрсәне барлап, җыйнап, саклап калу турында кайгыр.

Салих. Баянсыз клуб буламыни?

Мулланур. Акча юк.

Салих. Алайса, машина биреп тор.

Мулланур. Кая барасың?

Салих. Казанга барам, спонсорлар табам.

Мулланур. Беренчедән, Казанга барып җитәрдәй техника бездә юк. Икенчедән, синең кебек хәерчеләр башкалада чат саен басып та, утырып та, хәтта ятып та торалар. Карале, Салих, синең белән сөйләшкәннән соң саруымның кайнавын сода да басмый. Ник йөдәтәсең соң син мине?!

Салих. Мин Казанга барырга тиеш.

Мулланур. Беләсеңме, Казанга барып җитәргә күпме бензин кирәк?! Бензинның бер литры сигез сум. Киттем мин. Баш миемне көзән җыера башлады.

Салих. Син татар мәдәниятенә битараф кеше. Син моңсыз, культурасыз бәндә.

Мулланур. Ташла! Татар мәдәнияте баянга килеп терәлгәнмени? Базга су кергән, хатынның бөере авыртып тора, үземнең инде икенче көн урт тешем сызлый, язгы чәчү башланырга тора, ә син юк нәрсә белән теңкәгә тиясең.

Салих. Барыбер Казанга барам.

Җәмилә *(Мулланур янына килеп пышылдый).* Куркам, төнлә саташып чыгып китмәгәе.

Салих. Барыбер Казанга барам!

Мулланур. Хәерле юл. *(Завклубка текәлеп карап тора.)* Карале, мин сиңа ат бирә алам.

Салих *(торып утыра)*. Бир! Командировочный да бир!

Мулланур. Менә анысы юк инде, туган. Мин кушмыйм бит сиңа анда барырга.

Салих. Ат бир!

Мулланур. Бар, ат караучы Вахит абый янына, мин рөхсәт бирде, диген. Ат белән барып кайт. Ичмаса, хет бер-ике атна күрми торырмын үзеңне. Түлке мин ышанмыйм синең анда спонсор табасыңа. Казанда бихисап күп җырчылар, артистлар. Алар үзләре төрле районнарга чыгып акча соранып йөриләр. Кем бирсен сиңа Казанда акча?! *(Чыгып китә.)*

Җәмилә. Казанга атка атланып барып керерсең микәнни?

Салих. Барып җитәргә кирәк әле башта. Атны шәһәр читендәге берәр хуҗалыкта калдырып торып була бит. Киттем мин ат утарына. *(Чыгып китә.)*

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Трасса. Машиналар тавышы. Милиция сержанты Минәзәл юл кырыенда үтә җитди кыяфәт белән йөри. Муенына автомат аскан. Милиция сыбызгысын сызгырта. Аннары кычкыра: «Тукта!» Салихның: «Тр-р-р-р, малкай!» — дигәне яңгырый.

Минэзэл. Пачиму по трасси на лошади едешь?
Салих *(үзе күренми, тавышы гына ишетелә)*. Я же по краю трассы еду.
Милиционер. Ну и што. Чичас здис эскурт пройдет.
Салих. Нинди эскерт?
Минәзәл. Эскерт түгел, Мәскәү делегациясенең колоннасы Чаллыдан Казанга барачак.
Салих. Алар миңа комачауламый бит.
Минәзәл. Вәт дурак! Правительственный эскурт узачак, аңлыйсыңмы! Дакументы!
Салих. Менә паспортым.
Минәзәл. Атка документ бармы?
Салих. Юк.
Минәзәл. Кем аты бу?
Салих. Минеке.
Минәзәл. Синеке икәнне раслый торган документ бармы?
Салих. Юк.
Минәзәл. Бияме, алашамы?
Салих. Айгыр.
Минәзәл. Кайда учетта тора?
Салих. Конюшняда. Вахит абыйда.
Минәзәл. Ограждениегә бәйләп куй да кил монда. *(Салих милиция будкасы янына килә.)* Соңгы вакытта йорт хайваннары, кош-корт урлау очраклары бик ешайды. Шуңа күрә мин тикшерергә обизиян.
Салих. Сез бит монда машиналарны гына тикшереп торырга тиеш. *(Минәзәлгә паспортын бирә.)*
Минәзәл *(Салихның паспортын тикшереп)*. Ат ул, между прочим, транспорт та. Атка без неравнодушны. Президентыбызның атларны ничек яратканын ишетеп беләсеңдер...
Салих. Ишетеп кенә түгел, күреп тә беләм. Бөтен конторапарда ат рәсеме төшерелгән плакатлар ябыштыралар. Президент ат яратканга бит инде ул.
Минәзәл. Но-но, сүзне алайга кертмә. Син миңа бу ат синеке икәнне исбатла.
Салих. Ничек исбатлыйм?.. Карале, синең башка эшең юкмыни... Авыл аты бу. Күмәк хуҗалык җитәкчесе Мулланур миңа биреп торды бу атны Казанга барып кайтырга. Спонсор эзләп чыгып киттем мин. Авыл клубына баян кирәк. Мине җибәр инде син. Ат бик арыды, инде көне буе киләм бит. Мамадыш тукталышындагы кунакханәдә кунармын дигәнием, атны урнаштырыр урын булса.
Минәзәл. Анда атны ябар урыннары юктыр аларның.
Салих. Берәр җае килеп чыгар әле.
Минәзәл. Әйдә, будкага.
Салих. Ник?
Минәзәл. Компьютердан тикшерәм сине. Анда безнең бөтен данныйлар бар. Алай-болай синең фамилияң яисә ат турында берәр мәгълүмат юк микән.
Салих. Ничек мин компьютерда булыйм, авылдан чыкканым юк. Ат бигрәк тә. Аның конюшнядан чыкканы юк.

Будкага кереп китәләр. Машина тавышлары көчәя. Шомлы музыка. Бераз вакыт үткәч, будкадан чыгалар.

Минәзәл. Правительственный делегация килеп җиткәнче кунакханәгә менеп җитәсеңме соң син?
Салих. Ыграк куалармын.
Минәзәл. Дамба астыннан бар. Не дай бог тагын юлдан барсаң. Учти, алда анда безнең постлар бар әле. Аңладыңмы?
Салих. Аңладым. *(Атын калдырган тарафка атлый.)*
Минәзәл. Әллә кемнәр бар дөньяда.
Салих *(акырып йөгереп килә)*. Ат юк! Ат әллә кая киткән! Атны урлаганнар!
Минәзәл. Нәрсә булды?
Салих. Ат юк! Синең аркада! Атым кайда?
Минәзәл. Ник соң син аны бәйләп куймадың?
Салих. Бәйләдем мин аны. *(Йөзенә газап төсе чыга.)*
Минәзәл. Әллә кая китмәс. Шушы тирәдәдер. Эзлә.
Салих. Юк бит. Кая китәр ул, ә? *(Арлы-бирле сугыла.)*

Тирә-яктан атны эзлиләр. Ат күренми.

Минәзәл. Кире авылыңа чапмагандыр бит? Алай дисәң, ул арада күздән югалмас иде.
Салих. Ник бәйләндең, ник тоткарладың соң син мине?! Хәзер нишлим инде?
Минәзәл. Атның үзе кире килә торган гадәте бар, бәлки, кире килер.

Салих. Ул ашаган җиренә кире кайта. Милиция постына кире ник килсен ул! *(Як-якны күзәтеп.)* Юк инде, юк, качкан!

Минәзәл. Чынлап та юк. Кая китәр икән шул арада. Озак та тормадык югыйсә будкада.

Салих. Авыл җитәкчесе үтерә мине! *(Елый.)*

Минәзәл. Елама. Әнә, күрәсеңме, «БМВ» тора, теге кафе янында. Ул Мирза дигән кешенеке. Әнә үзе дә чыгып килә. *(Кычкыра.)* Мирза! Кил әле монда!

Мирза *(шактый исерек, җырлый-җырлый килә).*

Ал чәчәк аткач балан,
Гөлгә күмелә алан,
Ал чәчәк аткач балан,
Гөлгә күмелә алан...

Минәзәл. Гадәттәгечә, салган.

Мирза *(килеп күрешә).* Сәлам бирдек, Минәзәл дус! Алла хакы өчен автомат көпшәңне минем якка борма. Ату йөрәк болай да яралы, кем әйтмешли. Нихәлләр бар соң?

Минәзәл. Минем служба бара. Миңа нәрсә. «БМВ»ыңны читкәрәк алып куйсаң, минем монда полный тәртип була. Алайса, тиздән зур делегация узачак.

Мирза. Хәзер, алып куям, брат. Син кушсаң, таудан Вяткага этеп төшерергә дә могу машинамны.

Минәзәл. Кирәкми. Әнә кафе артынарак кына куй.

Мирза. Бик зур кеше киләмени?

Минәзәл. Мәскәүдән кемдер килгән Чаллыга.

Мирза. Путин үзе түгелдер бит?

Минәзәл. Юк, ул түгел.

Мирза. Минем Путинны күрәсем бар. Без бит әшнәләр аның белән. Узган ел сабантуена килгәч танышкан идек. Мин Казанда сабантуй өчен ответственный идем. Путинга мин әйттем бит: башыңны катыкка тыксаң, Татарстан сине мәңге онытмас, дидем. Бу безнең иң зур милли уен, мәйтәм, давай, катыктан акча эзләгән булып кылан. Кеше күрмәгәндә генә авызына акча каптырдым да, теге катыкка башын тыгып, имеш, акча тапты.

Минәзәл. Аның авызында акча бар идемени инде?

Мирза. Булмаска. Әйтәм бит, кеше күрмәгәндә капты да авызына. Минтимер Шәриповичка тәкъдим итмәдем инде катыктан акча эзләргә. Аның башы сыярдай посуда юк иде якын тирәдә. Аның башы Путинныкы кадәре ике бар бит.

Минәзәл. Син берәр ат күрмәдеңме бу тирәдә?

Мирза. Юк, күрмәдем. Нинди ат?

Минәзәл. Ат югалттык.

Мирза. Башың исән булсын, башыңны югалтма.

Салих. Минем атым юкка чыкты, күрмәдегезме?

Мирза. Күрмәдем дидем бит инде. Нинди ат соң ул?

Салих. Минем ат.

Мирза. Юк белән башны катырмагыз әле. *(Кулын йөрәк турысына куя.)* Татар йөрәге скрипка түгел, уйнамагыз. *(Җырлап җибәрә.)*

Ачуланма, туган,
закускага суган,
Кесәнең такыр чагы.
Алып кил миңа тагын
Күрше карчыкның казын,
Алып кил миңа тагын
Күрше карчыкның казын...

Минәзәл. Туктале. Син бик абруйлы кеше бу тирәдә.

Мирза. А как же. Мин бит Мирза! Знаменитый мал врачы. Тикмәгә докторскийны защищать иттеммени мин?! Миңа бит профессор дигән исем дә бирделәр күптән түгел. Шуны юып йөреш әле.

Минәзәл. Бер үтенеч бар.

Мирза. Синең гозерме, әллә бу карачкыныкымы?

Салих. Мин карачкы түгел.

Мирза. Ә син докажи, ха-ха-ха.

Минәзәл. Ярар, үпкәләмә инде, аның сөйләшүе шундый.

Мирза. Маладис, аңлыйсың, дуңгыз. Тизрәк әйт инде, Минәзәл, үтенечеңне. Яратмыйм озакка сузганнарын. *(Кулын күкрәгенә куя.)* Татар йөрәге скрипка түгел, уйнама, әйт тизрәк.

Минәзәл. Мирза туган, менә бу кешенең будкада документларын тикшергәндә, аты каядыр юкка чыккан.

Мирза. Шуннан?

Салих. Ат авылныкы.

Мирза. Мин ветеринарный врач буларак ул ат турында бернәрсә әйтә алмыйм, чөнки минем әлеге дә баягы атны күргәнем юк. Ә менә доктор наук буларак чамалый алам: ул ат йә качкан, йә урлаганнар. *(Күккә карап.)* Һәм дә профессор буларак әйтәм: күккә очып китә алмый ул хайван, чөнки Аллаһы Тәгалә миңа — мал врачына әйтми-нитми җир йөзеннән йорт хайваннарын, бигрәк тә авылныкын юкка чыгармый.

Салих *(ыңгырашып)*. Хәзер ничек авылга кайтыйм?!

Мирза. Җәяүләп инде. Атың югалгач ничек кайтасың — җәяү.

Минәзәл. Син аңа ат үлде дип справка эшли алмыйсыңмы соң?

Мирза. Син кушсаң, ул ат ике тапкыр үлеп, ике тапкыр терелеп, өченче тапкыр җан тәслим кылды дигән документ та эшләп бирә алам. Син бит мине әллә ничә тапкыр выручать иткән кеше. Яхшылыкны онытмыйм мин. *(Җырлап җибәрә.)*

Ачуланма, туган,
Закускага суган,
Кесәнең такыр чагы.
Кил, кил, кил, кил, иркәм, кил инде,
Кил, иркәм, кил инде, елмаеп көл инде,
Сагындым, бәгърем, сине.

Минәзәл. Эшләп бир, зинһар, күрмисеңмени бу бичараның кыяфәтен.

Мирза. Да-да, кыяфәт бигүк чибәр түгел. Синең кыяфәтең обманутый вкладчикныкы сыман. Ярар. Атың үлде дип справка бирәм мин сиңа, йә үзең шушында үлеп китәрсең дә, бәддогасы безгә булыр. Ха-ха-ха. Кем соң син?

Салих. Салих.

Мирза. Кайда эшлисең?

Салих. Авылда, завклуб булып.

Мирза. Андый эш бармыни әле ул?! *(Кесәсеннән справка бланкысы чыгара, Минәзәлнең җилкәсенә куеп яза.)* Гафу ит, Минәзәл туган, эчтек без шактый күп.

Минәзәл. Ярый, ярый.

Мирза. Фамилияң ничек?

Салих. Нәҗмиев Салих.

Мирза. Отчествоң?

Салих. Габтелбәревич.

Мирза. Кайсы авылдан син?

Салих. Катлаулыдан.

Мирза. Муллануrга сәлам әйт.

Салих. Сез беләсезмени аны?

Мирза. Мин бөтен Татарстан кешесен беләм.

Салих. Сезнең исемегез ничек?

Мирза. Мирза. Меня зовут Мирза, работать мне нельзя, ха-ха-ха.

Салих. Алайса, бу справкага ышанырга тиеш ул.

Мирза. Минем справкаларга ышанмаган кеше очратканым юк әле, ха-ха-ха. *(Кесәсеннән пичәт алып шапылдатып кәгазьгә баса.)* Мә, кайгырма. Ат югалды дип бу кадәре бетеренмиләр инде. Баш исән булсын. Ха-ха-ха. Хәлләр ничек, сержант?

Минәзәл. Әйбәт тә, тик менә правительственный колонна узачак хәзер. Мәскәү делегациясе белән. Син машинаңны юлдан ал инде.

Мирза. Кем килгән?

Минәзәл. Әллә тагы.

Мирза. Безгә юньле кеше килмәс. Йә Шахрай, йә Чубайстыр инде. Ха-ха-ха. *(Җырлый-җырлый китә.)* Ачуланма, туган, закускага суган, кесәнең такыр чагы-ы-ы...

Минәзәл *(артыннан карап кала)*. Суган гына түгел синең закускага. Гел ит кенә ашыйсың син.

Салих. Бу справка чынмы соң?

Минәзәл. Чын булмый инде. Пичәте-ние бар.

Салих *(справканы куен кесәсенә тыгып куя)*. Кире авылга юл тотам инде хәзер.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Авыл. Салихлар өе. Җәмилә гөлләргә су сибеп йөри. Салих кайтып керә дә диванга ава. Җәмилә аптырап карап тора.

Җәмилә *(ишетелер-ишетелмәс кенә)*. Барып кайттың да мәллә?

Салих *(түшәмнең бер ноктасына текәлеп)*. Күрмисеңмени!

Җәмилә. Акча таптыңмы?

Салих *(тонык кына тавыш белән)*. Без синең белән шактый вакыт гомер кичердек бергә... Бәхил бул, яме.

Җәмилә. Нәрсә булды? Нишләп җәяү?

Салих. Очып кайтыйммыни, җәяү булмый!

Җәмилә. Атың кайда?

Салих. Ат юк.

Җәмилә. Ничек юк? Саттыңмы әллә?

Салих. Ат әллә качкан, әллә урлаганнар.

Җәмилә. Ни сөйлисең син?!

Салих. Милиция туктатты, документларымны тикшергән арада аттан җилләр искән.

Җәмилә. Ник ычкындырдың соң син атыңны?

Салих. Милиция будкасына ат белән кереп булмый бит.

Җәмилә. Бәйләп куймадыңмыни?

Салих. Бәйләдем!

Җәмилә. И Ходаем, хәзер ат бәясен дә түләтәчәкләр. Төрмәгә утыртып та куярлар әле үзеңне.

Салих. Миңа хәзер барыбер.

Җәмилә. Аңа барыбер! Ә мин? Ә кызың? Без нишләргә тиеш? Мулланурны ничек юмалыйбыз хәзер?

Салих. Бар, чакыр Мулланурны. Анда бер мал врачын очраттым мин. Профессор. Исерек булса да сүзне тыңлады. Ат үлде дип справка бирде. Чакыр Мулланурны.

Җәмилә. Бар икән күрәселәр! *(Чыгып китә.)*

Салих *(арлы-бирле йөренә)*. Ник болай интегәм соң мин?! Нинди гөнаһларым өчен соң бу иза чигүләр?! *(Тастымал алып муенына чорный һәм үзен-үзе буып карый. Тастымалны муеныннан алып читкә ыргыта. Йөткерә.)* Үләксә бит мин! Тулы кеше түгел бит мин! Бу мескенлекнең чиге бар микән, юкмы?! *(Күкрәген угалап диванга барып ята.)*

Җәмилә белән Мулланур керәләр.

Мулланур *(мыскыллы тавыш белән)*. С приездом!

Салих *(түшәмгә караган килеш кенә)*. Благодарю.

Мулланур. Йә, күрсәт, кайда баян, спонсорский акча, атланып чыгып киткән атың?

Җәмилә *(ялварып)*. Бик каты бәрелмә инде, хәле авыр бит.

Мулланур. Кем гаепле соң аның хәле авыр булуда?! Тагын нинди убытоклар китерерсең икән син авылга, ә?! Кемнәр уйлап чыгарган шушы клубларны, кемнәр уйлап тапкан аның завклубларын, кемнәр уйлап чыгарган ул баянны — бөтенесен җыеп язгы ташуларда Камага тондырыр идем. Һәрберсенең муенына баян бәйләп. Яр кырыенарак чыкканнарын үзем лично багор белән эчкәрәк этеп торыр идем. Кая куйдың атны, мөртәт?!

Салих. Үлде ат.

Мулланур. Шулай нык кудыңмыни?

Салих. Юк, каты чабарга куркам ла мин, баруын әкрен генә бардым.

Мулланур. Ат болай гына үлми ул.

Салих. Менә, анда танылган мал врачы... профессор званиесе дә бар икән аның... Мирза исемле. Кафедан ашап-эчеп чыгып килә иде... Справка бирде... *(Куен кесәсеннән калтырана-калтырана справканы ала, Мулланурга суза.)* Атны шунда, Мамадыштан ерак түгел, үләт базында җирләдек. Сине белә ул профессор.

Мулланур *(справканы йолкып ала)*. Минем таныш профессорларым юк. *(Укый.)* Бу бит син үлгәнгә язып биргән. Менә укыйм: синең фамилияң, синең исемең...

Салих. Ничек инде?

Җәмилә *(Мулланурдан алып укый)*. Чынлап та, шулай килеп чыга. Ат турында сүз юк. Свидетельство о смерти... Синең исем-фамилияң...

Салих. Ну, минем исем-фамилиям булмый, атның фамилиясе юк бит.

Мулланур. Нинди справка алып кайттың син, жулик?

Җәмилә. Нишләп жулик булсын ул!

Мулланур. Менә: Нәҗмиев Салих Габтелбәревич. Бу синең иреңме?

Җәмилә. Әйе.

Мулланур. Үлде диелгән. Чичлосы бар, подписе, пичәте. Ат турында сүз юк.

Салих *(справканы алып карый)*. Ул профессор исерек иде, дөрес язмаган инде, күрәсең.

Мулланур. Ник соң син ул справканы язгач ук укып карамадың?

Салих. Мин анда тәмам хәлсезләндем, справка укырлык та чутым юк иде. Ат үлде, мин түгел.

Мулланур. Син исбатла атның үлгәнен! Ник үлгән соң әле ул? Әллә сатып җибәрдеңме?

Салих. Юк.

Җәмилә. Ат сатарга түгел, бәрәңге сатарга да ояла бит. Әйбер сата торган кеше түгел ул. Бәрәңгене дә үзем сатам бит мин.

Мулланур. Ничек инде сау-сәламәт ат үлеп китәргә тиеш?!

Салих. Милиционер бик шөкәтсез кеше иде, ат шуңардан нык курыкты да, йөрәге ярылды бугай. Андый ямьсез кеше күргән хайванмыни ул.

Мулланур. Синең үзеңне бәреп үтереп, күкрәгеңә шушы справканы куеп калдырасы бар.

Җәмилә. Туктале, Мулланур абый, Салих тегенди-мондый кеше түгел, сез аны әллә нинди җинаятьләрдә гаепләргә ашыкмагыз. Теге мал врачын барып тапсын. Ул профессор бераз салмыш булган, ди, справканы дөрес язмаган.

Мулланур. Ну да, профессорның аек көне юк инде аның. Хәзер ничек барсын да ничек тапсын ул аны? Тагын ат биримме?

Салих. Кирәк түгел!

Мулланур. Мин әле бу арада сөенеп йөргән идем... Ат караучы Вахит абый төш күргән: имеш, ат утарында бер атка артык икән. Имештер, бөтенебез җыелып аны ачуланабыз икән, нишләп лишний ат хасил булды конюшняда, дип. Ә ул, имеш, акланырга тырыша, тик ничек акланырга белми. Аптырагач кычкыра: артык ат булганга сөенергә генә кирәк бит, аңгыралар, ди. Мин инде аның төшен яхшыга юрап йөри идем. Тфү! Бар икән әле күрәселәр!

Җәмилә. Салихның хәлен дә аңла инде.

Мулланур. Бар, ат үлгәнгә чын справка ясатып, атның диагнозын яздырып, минем өстәлемә алып кайтып куй.

Җәмилә. Ярар, ярар. Ярар диген, Салих. Ник бер сүз дә әйтмисең. Намусың чиста булгач, ник куркырга?!

Салих. Ярар.

Мулланур. Баян, Казан, спонсор! Тфү! Культураны алга җибәрүче, сволочь! Бәреп үтереп, кабереңә таш урынына нимес баяны куясы бар синең, деятель культуры, хайван! *(Чыгып китә.)*

Җәмилә. Бар, ятма.

Салих. Кая барыйм?

Җәмилә. Теге мал врачын тап.

Салих. Җәяү ничек барып җитим мин анда!

Җәмилә. Мин сиңа акча бирәм. Теге бәрәңге саткан акчаны. Автобуслык кына бирәм түлке.

Салих. Автобуска акча бирәсеңме?

Җәмилә. Бирәм инде.

Салих *(җанланып)*. Рәхмәт, хатын. Изге кеше син.

Җәмилә. Ярар, ярар. Хәлем начарланып китте әле үземнең дә. *(Ята.)*

Салих *(сикереп тора)*. Кай төшең авырта, хатын?

Җәмилә. Депрессия.

Салих. Тагын ниләр күрергә язган икән?!

Җәмилә. Чыннан да, чукындың бит шул баян дип!

Салих *(уфтанулы һәм газаплы тавыш белән)*. Хатын! Кичер!

Музыка. Сәхнә караңгылана. Музыка тына. Сәхнә яктырганда, Җәмилә елап утыра. Мулланур керә.

Мулланур. Киткәненә ничә көн булды?

Җәмилә. Унике көн.

Мулланур. Почтада сиңа хат килгәнне әйттеләр.

Җәмилә. Килде.

Мулланур. Берәр бәла-казага юлыккан мәллә тагын?

Җәмилә *(газаплы тавыш белән)*. Теге мал врачы үзе дә үлгән бит.

Мулланур. Справка язып биргән профессормы?

Җәмилә. Әйе. Мә, укы.

Мулланур *(кычкырып укый)*. «...Исәнме, Җәмилә! М-м-м-м... Эзләдем-эзләдем... М-м-м-м... Ул мал врачы шушы арада үзе үлгән. Кинәт үлеп киткән. Берәр чире булгандыр инде. Хәзер нишләргә дә белмим. Казанда Идел буе районының базарында шабашка эшләп бераз ипи-чәйлек акча эшләдем. Хәзер мал врачы үлгәнлеккә дә справка кирәк бит инде. Алайса, Мулланур ышанмаячак. Классташларыбыз Локман белән Гөлнурларда кундым ике кич. Базарда очраштык. Күп итеп сәлам әйттеләр сиңа. Локман теге врачның үлгәнлегенә справка алырга ярдәм итәр дип ышанам. Мин хәзер авылга кайтырга да куркам инде. Мулланурны ул врач беләм дигән иде. Исеме Мирза аның. Син, Җәмилә, Мулланурдан сора әле, аның кайда туганын белми микән. Миңа язып җибәр, Гөлнурлар

адресы белән. Мин Локманнарда әле пока. Сау булып тор, җанкисәгем. Мин бик сагындым сине. Кайчан кайтырмын — белмим. Сау бул! Синең Салихың».

Мулланур. Локманнары кем тагын?

Җәмилә. Безнең классташлар. Без бергә укыдык. Гөлнур, мин, Салих, Локман. Локман Гөлнурга өйләнде, Салих — миңа.

Мулланур. Локманга чыгасың калган.

Җәмилә. Ник?

Мулланур. Тормышың тынычрак булыр иде, бәлки.

Җәмилә. Теге мал врачының исеме Мирза, ди. Сине белә икән ул? Сез танышлармы әллә?

Мулланур. Белмим мин бернинди Мирзаны да.

Җәмилә. Аның кайда яшәгәнен белергә кирәк бит.

Мулланур. Хәзер исән кешенең кайда яшәгәнен дә билгеләве авыр, не то что үлгән кешенекен! *(Чыгып китмәкче була.)*

Җәмилә. Хатны калдыр!

Мулланур. Әй! *(Кулындагы хатны Җәмиләгә бирә дә чыгып китә.)*

Җәмилә *(хатка карап)*. Их, Салих, Салих!

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Локманнар фатиры. Локман, Гөлнур, Салих утыралар. Чулпан бизәнә.

Локман. Казан ошыймы соң?

Салих. Минем бит Казанның ниндилегендә хәбәрем юк. Баш каткан минем. Бик тынгысыз, шау-шулы кала. Ничек яшисездер монда.

Локман. Кеше теләсә кайсы мохиткә ияләшә, күнегә. Кеше үзенең хәлətенə дә күнегә һәм күнә башлый бит. Синең хәлләр бигүк яхшыдан түгел, әлбәттә.

Салих. Мин нишләргә дә белмим инде хәзер.

Гөлнур. Кызым, чәй куй әле.

Чулпан. Хәзер. *(Чәй әзерләргә керешә.)*

Салих. Бөтен ышаныч синдә.

Локман. Мин тырышып карармын. Ләкин аңламыйм: ул врач үлгән икән, аның үлүе турында справка нигә кирәк?! Бит ул справканы язганнан ат табылмаячак.

Салих. Ичмаса, Мулланурның нәфрәте бераз кимер иде.

Локман. Минемчә, турыдан-туры спонсорлар эзләргә кирәк — атка да, баянга да акча җитәрлек булсын. Ну, теге врачның яшәгән җирен, кайда үлгәнлеген эзләрбез, әлбәттә. Раз кеше үлгән, аның бу дөньяда юклыгын гына ничек тә исбатлый алырбыз.

Гөлнур. И, Җәмилә ут йотып ятадыр инде анда.

Салих. Әле кызым белми.

Чулпан *(табын әзерли-әзерли)*. Часто кайтамы Миләүшә?

Салих. Каникул саен.

Гөлнур. Салих, ник соң сез кызыгызны да культпросветучилищега керттегез, аңламыйм?

Салих. Үзе теләп керде.

Локман. Нинди сорау инде бу: ник керттегез? Анда синең ни эшең бар. Нәрсә, мәдәният хезмәткәре булса начармыни?!

Гөлнур. Болай гына әйтүем. Менә бит, Салих та культпросветучилище тәмамлаган кеше... Ничек бимазалана.

Локман. Монда культпросветучилищеның бернинди катнашы юк, Гөлнур. Син укытучы башың белән әллә ничек фикерли башладың соңгы вакытта. Менә мин журналист булып йөргән булам, гәҗиттә эшлим, имеш, нәрсә, бимазаланмыйбыз мәллә?

Чулпан. Ну ладно, пап, че ты опять кричишь?

Локман. Татарча сөйләш! Әнә, педагог булсаң, кызыңны сөйләшергә өйрәт.

Гөлнур. Синең дә кызың бит ул.

Локман. Финансово-экономическийга керттең, теләге булмаган килеш, менә күрербез — кайда эшләр дә кем булыр. Бимазаланмасмы?!

Салих. Мин китим.

Локман. Утыр, кая китәсең! Син без әйткәләшкәнгә карама, Салих. Без гел шулай.

Гөлнур. Шулкадәре кырыс булмыйлар инде.

Локман. Яши-яши шундыйландым мин.

Чулпан. Потому что беркайчан беркая ял итәргә барганыбыз юк. Поэтому нервныйлар барыгыз да. *(Чәй ясый.)*

Локман. Арыдыңмыни ял итәргә! Нинди сүз таптылар. Отдыхать, ял итәргә. Шулкадәре эшләп арыганнармыни. Нәрсә эшләделәр дә ни кырдылар әле ял итәрлек. Шул булганын җимереп арысалар гына инде. Кая карама, кемне генә очратма, фәлән җиргә фәлән көнгә ялга бардык дигәннәрен ишетәсең. Дәүләт таркалып барганда, туда-сюда ял итәргә йөриләр. Арыганнар!

Гөлнур. Авылга кайтып килик, ичмаса.

Локман. Авылга кайту ярый. Саф һава сулаудан тыш менә шул ялга йөрүчеләрдән ерактарак булып тору яхшы.

Салих. Авыл да бик тәртипсез шул хәзер. Яшьләр бик әшәке. Һавасы да тирә-яктагы заводлар аркасында тынчуланды. Авылда да кеше әшәкеләнде, төнлә чыгарга куркыныч.

Гөлнур. Күтәрегез культураны, сез бит культура работниклары.

Локман. Сез укытучылар тәрбияләгән шакалларның культурасын ничек күтәрсеннәр алар.

Чулпан. Ой, ну нәрсә сез спорите? Сез бер-берегезне ачуланып утырасыз, ә жизнь по-своему идет. Как-будто сез зарланганнан берәр нәрсә яхшы якка үзгәрә. Вас послушаешь, прямо не знаешь, то ли плакать, то ли смеяться.

Локман. Кызым, безелдәмә әле. Тавышың анаңныкына охшаган, тешкә сылана торган тавыш.

Гөлнур. Үзеңнеке матур инде.

Салих. Хезмәт хакың гәҗиттә болай начар түгелме?

Локман. Мин канәгать үзем, начар түгел. Ләкин мин үзем эшләгән эштән канәгать түгел. Әйтәсе фикеремне кычкырып әйтә алмагач, нәрсәгә кирәк ул минем профессиям. Мин журналист дип саный алмыйм үземне. Гомумән, бездә журналистика юк. Журналистика булсын өчен хөрлек кирәк, күңел хөрлеге. Әле мин матбугатта көчле, таң калырлык фикерле бер генә мәкалә дә укыганым юк. Менә бүген бөтен гәҗит-журналларны яп — аңа карап бернәрсә үзгәрмәячәк, тормыш, Чулпан әйтмешли, үз ходы белән барачак та барачак. Кил әле, кызым, кайвакыт акыллы фикерләр әйтеп куясың. *(Кызын кочаклый.)* Маладис, ул ягың белән анаңа охшамагансың.

Салих *(тәрәзәдән карап)*. Ничек яшисез бу Казанда?! Бигрәк тынгысыз бит монда.

Локман. Яшәү беркайда да рәхәт түгел, Салих.

Салих. Анысы шулай.

Локман. Беләсеңме нәрсәсе авыр тормышның безнең өчен. Безгә яшәү шартларын тагалар. Менә синең белән миңа мичкә тәгәрәткән бәрәңге белән ипи дә җитәр иде, бер чалбар, бер күлмәк җитәр иде, шулаймы. Ләкин халыкның күбесе синең өс киемеңә, кыяфәтеңә, кесәң калынлыгына игътибар итә. Барысына төкереп ыштансыз яшәргә дә булыр иде, ләкин гаилә бар, балалар бар, телисеңме-юкмы, кешеләрнең фикереннән, аларның мөгамәләсеннән беркая да китеп булмый.

Салих. Шулай.

Локман. Кая гына килеп кермә, хәерче икәнлегеңне сизәләр дә сине кешегә санамыйлар. Һәм син менә шул килеш берәр эш майтарып кара. Сине ихтирам итмәсәләр, бернинди эш кыра алмыйсың. Кеше фикереннән азат булу мөмкин түгел, Салих. Үзең үлгән сурәттә дә үзеңнән соң синең хакта фикер кала! Гомумән, кеше дөньяга туу белән үк башкалар уйлап чыгарган кануннар дөньясына, аңа кадәр туганнар уйлап чыгарган яшәү шартларына күнегергә, шул мохиттә яшәргә мәҗбүр. Шуңа күрә җаваплылык һәрбер кешедә булырга тиеш. Теге яки бу кешене битәрләгәнче иң элек шуны онытмаска кирәк — ул кеше башка кешеләр дөньясында яшәргә мәҗбүр.

Чулпан. Юк, индивидуальность өчен көрәшергә кирәк.

Локман. Менә, яшьләрдән еш ишетәм шул сүзне. Нинди индивидуальность? Сезнең бит бер үк сүзләр, бер үк кызыксынулар. Нәрсәң индивидуально соң синең, мәсәлән? Борынны яннан тишеп алка тагып башкалардан аерылып буламы? Кашны йолкып була, ертык чалбар киеп була, ләкин бу индивидуальность түгел, кызым. Сез барыгыз да бер көтүдә йөрисез, ә үзегез индивидуальность, ирек дигән буласыз. Бер буын да әле өлкәннәргә көрәш игълан итеп әллә кая ерак киталмады. Чөнки һәр буын үзе картая бара һәм тора-бара хәтта тиздән бу дөньядан китәсен чамалый башлый. Күк астында йөргән бер бөҗәк икәнен яшь кеше аңламый бит ул. Җәмгыятьтән беркая китә алмыйсың. Нининдер сыйфатларың, яшәү рәвешең үзгә булуы ихтимал, әмма ләкин барыбер бер үк кануннар буенча яши кешеләр — бер үк ризык, бер үк һава, бер үк ихтыяҗлар. Бүгенге бардакта теләсә кем үзен индивидуальность дип игълан итсен, ләкин аңа карап бу балаганнан котыла алмый ул.

Салих. Элегрәк барыбер яшьләрдә әхлак кануннары азмы-күпме бар иде әле.

Гөлнур. Менә бу перестройкадан башланды бөтен әшәкелек.

Локман. Юк. Нишләп, алайса, коммунистлар вакытында алай нык тәрбияләгәч, берничә ел эчендә вәхшилек белән фәхешлеккә кереп баттык? Ай-яй әйбәт тәрбияләнгән икән, алайса, халык социализм чорында. Сәбәбе дә, нәтиҗәсе дә үзебездә. Запад та гаепле түгел Менә үзебездән эзлик бөтенесен дә. Җинаятьче дә үзебездә, аны хөкем итүче дә, төзүчесе дә янәшә, җимерүчесе дә. Бөтенесе үзебездә яши.

Салих. Культура түбән дәрәҗәдә инде бездә, сүз дә юк.

Локман *(Салихка карап көлә)*. Мин сине шул беркатлылыгың өчен хөрмәт итәм, Салих. Нәрсә соң ул культура? Ул бит яшәү укладының бер чагылышы. Башта йортың төзек, тамагың тук булырга тиеш,

аннары гына кеше җырлый-бии башлый. Иң борынгы кешеләр иң элек корал әзерләгәннәр, ауга барганнар, мамонтны тунап, ит пешереп, учак янында тамак туйдырганнар. Шуннан соң гына сәнгать башланган — таш куышның стеналарына рәсемнәр ясый башлаганнар. Бит беренче рәсемнәрдә мамонтларга һөҗүм итүләрен ясаганнар. Бернинди Министерство культуры, отдел культурылар булмаган бит ул вакытта.

Чулпан. Вот күрдеңме, димәк, бүгенге заманда кеше акча күбрәк эшләргә омтылырга тиеш — тамагы туйсын өчен. Димәк, культура турында аннары уйларга кирәк?

Локман. Акчаны аны эшләп табарга кирәк. Бүгенге ысуллар белән түгел. Ничек табасыз акчаны, менә культурагыз да шулай. Милли культура бар! Менә Салих — аның вәкиле! Милли культураны сакларга кирәк. Аны саклар өчен татарның яшәү укладын сакларга кирәк. Барыбер сәясәткә килеп терәлә, зараза! Ничек кенә каезлама, кыска гына итеп әйткәндә: кеше булырга кирәк иң элек. Нәрсә без гәп куертып утырган булабыз. Чәй эч, Салих. Минем хатын белән кызым болай надан кешеләр түгел инде дә, тик шулай да хатын-кыз сүзе хатын-кыз сүзе инде ул — игътибар итмик.

Салих. Иртәгә көнне эш белешүгә багышлыйм, Алла боерса.

Локман. Нинди эш табарсың икән инде син? Казанда эш күп, ләкин синең специальность буенча урыннар буш түгелдер шул.

Салих. Барыбер эзләргә кирәк. Син теге врачның кайда үлгәнен белеш инде, яме. Ул бик танылган кеше булган. Путин белән дә таныш булганнар алар. Былтыргы сабантуйда катыктан акча эзләргә тәкъдим иткән ул Путинга.

Локман. Алайса, акыллы кеше булмаган ул. Ул катык белән бөтен татарны мыскыл иттеләр. Путин башын катыкка тыгып үзен мыскыл иткән икән — бу аның шәхси эше. Ә менә катык чөмереп акча эзләү — татарның милли уены дип үзәк телевидениедән әйтүләре мине бик кимсетте. Татарның милли уены булалмый ул. Ходай кешегә башны акыллы фикерләр, бөек эшләр өчен биргән. Аны катыкка тыгарга ярамый!

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Казан. Үзәк урамнарның берсе. Урам чатында Салих иске гармунда уйнап утыра. Кара күзлек кигән, кыяфәте йончыган. Локман үтеп бара. Туктый. Баскан урынында катып кала һәм аптырап Салихка карап тора.

Локман *(Салих янына килә)*. Сыздырасыңмы?

Салих *(башын күтәрә)*. Булдыра алганча. Каян белдең минем монда икәнне?

Локман *(як-ягына каранып)*. Кызым күргән. Кайтып әйтте. Кая югалдың?

Салих. Югалмадым, менә бит монда утырам.

Локман. Кайчаннан бирле күренмисең, без Гөлнур белән әллә ниләр уйлап бетердек инде. Тор, кеше көлдермә.

Салих. Мин болай да адәм көлкесенә калдым инде. Мин бит тагын бер фаҗигагә юлыктым.

Локман. Нәрсә булды тагын?

Салих. Мин берәүгә коттедж төзешергә наниматься иткәнием. Әйбәт түләрмен дигән иде.

Локман. Шуннан?

Салих. Хуҗасы бик бай инде. Авызы тутырук алтын, бармак саен алтын. Гел ун меңлек коньяк кына эчә. Аның ашый торган ризыкларының исемен дә, ни икәнен дә белмим мин.

Локман. Шуннан?

Салих. Гаражы өстендәге материалларын аралаганда ялгыш машинасы өстенә тимер уголоклар ишеп төшердем.

Локман. Машинасы нинди?

Салих. «Мерседес».

Локман. Тфү!

Салих. Шулхәтле бай булгач, машина түбәсе яньчелүгә бик борчылмас дип уйлаган идем.

Локман Борчылдымы?

Салих. Шунда, гаражында ук сугып аударды. Күпме ятканмындыр — чамаламыйм. Аңыма килгәч аның чыраен күрдем дә «үтерәм» дигәнен генә ишеттем. Алай җиңел генә үлеп китеп булмый шул. Биш мең доллар сорый. *(Битарафлык белән.)* Мин инде асылынмакчы идем, рух җитми, Локман. Мин инде әллә ничә тапкыр асылынып карадым, булдыра алмыйм.

Локман. Асылыну җиңел булса, үзен бераз ихтирам иткән һәрбер кеше асылыныр иде.

Салих. Мин Казанга килгәч үземнең кирәк түгеллегемне генә түгел, кеше түгеллегемне аңладым. Казанга мең ел булса ни дә, ун мең ел тулса ни минем өчен. Берәр дару табалмыйсыңмы тиз генә ычкындыра торган бу дөньядан?

Локман. Ярар. Теләңә салынма. Андый дару синең баяныңнан да кыйммәтрәк. Карале, ә бу гармунны каян алдың соң син?

Салих. Икенче Горкида берәүгә кирпеч ташышкан идем. Кайгы-хәсрәтләремне сөйләп биргәч, иске гармунын бирде. Бака телләренең яртысы уйнамый. Шуңа бик сыздырып булмый. Бәлки, шуңа аз түлиләрдер.

Локман. Бәлки. Күп җыелдымы?

Салих. Ничек җыелсын инде? Бер ун-унбиш сум чамасы гына.

Локман *(кашларын җыерып, күзләрен кысыбрак чутлый башлый).* Биш мең долларны утызга тапкырласаң... безнең акча белән йөз илле мең чыга. Гармун уйнап көненә унбиш сум җыйсаң... Тәк... ун мең көн уйнарга кирәк... Ничә ел була инде ул?.. Тәк... ун меңне өч йөз алтмыш бишкә бүләбез... Син дә уйла, тик утырма...

Салих. Баш эшләми минем.

Локман. Тәк... биш... м-м-м... Вобшем, егерме җиде-утыз ел чамасы ышкыйсың була гармунны. Сиңа хәзер кырык. Җитмеш яшеңдә расчитаешься теге ун меңлек коньяк эчә торган кеше белән. Аннан соң үлеп китсәң дә була.

Салих. Көлмә инде.

Локман *(кинәт кырысланып)*. Мин җитди сөйләшәм, нишләп көлим. Бу арада кайда кундың соң син?

Салих *(башын читкә бора)*. Кайда туры килә.

Локман. Ник безгә кайтмыйсың?

Салих. Яхшы түгел.

Локман *(ачуланып)*. Менә болай утыру, теләсә кайда кунып йөрү яхшымы? Әйдә, киттек безгә!

Салих. Юк, мин үз профессиям белән акча эшләп утырам. Рәхмәт сиңа барысы өчен дә.

Локман. Хәзер үз профессияң белән акча эшлим дисәң ачтан үләсең. *(Салихны җиңеннән тартып торгызмакчы була.)* Тор!

Салих *(җиңен ычкындырып)*. Үлү яхшырактыр, бәлки.

Локман. Телеңә салынып утырма, якташ, кордаш, класташ!

Тарткалашалар.

Салих. Беркая да бармыйм!

Әүмәкләшәләр.

Локман. Тарткалашма, зараза! Мине монда күп кеше таный. *(Як-ягына карап куя да тагын тартып торгызмакчы була.)* Оятка калдырасың.

Салих *(каршы тора, аяк тери).* Гармунны ватасың. *(Үпкәле тавыш белән.)* Син журналист башың белән, гәҗиттә эшләгән килеш теге мал врачының туган авылын табарга да ярдәм италмадың.

Локман *(Салихны йолкып торгызмакчы була)*. Табабыз, табабыз, Салих, тынычлан гына. Каршы торма, зараза!

Салих. Җибәр! Күлмәкне ертасың, хайван! *(Локманны этә.)*

Милиция сыбызгысы сызгыра. Минәзәл килеп җитә.

Минәзәл. Что здесь происходит?

Локман. Барысы да тәртиптә, сержант.

Минәзәл. Ник сугышасыз?

Локман. Сугышмыйбыз. Бу минем якташым.

Минәзәл. Казанның үзәк урамында потасовка оештырасыз.

Салих *(күзлеген сала)*. Йөзең таныш. *(Күзләрен акайтып сержантның җиңенә ябыша.)* Син бит Мамадыш постында торганыең. Вятканы чыккач, күпер башында.

Минәзәл. Но-но! Без рук! Ал кулыңны!

Салих. Мине хәтерләмисеңме? Атым югалды минем анда... *(Аннан-моннан йолкып сөйли.)* Правительственный делегация узмакчы иде... Мал врачы... справка... Компьютердан тикшердең мине дә, атны да, конюх Вахит абыйны да карадың компьютерыңнан...

Минәзәл *(бераз йомшарып).* Ә-ә-ә, булды андый хәл. Төсмерлим мин сине. Синең атың югалды шул, әйе, әйе. Табылмадымы?

Салих. Юк, табылмады. Аттан соң минем нинди михнәтләр күргәнне белсәң иде. Син нишләп монда соң?

Минәзәл. Мин хәзер Казанда. Күрәм, син дә Казанда хәзер.

Салих *(үпкәләп)*. Әйе, менә мин дә башкалада. Син теге вакытта бәйләнмәгән булсаң, аттан колак какмый идем мин.

Минәзәл. Службам шундый булгач.

Салих *(йөзендә шатлык чагыла)*. Сине очратуым әйбәт булды әле. Ишеткәнсеңдер инде, теге мал врачы үлгән бит.

Минәзәл *(гаҗәпләнеп)*. Мирзамы?!

Салих. Әйе.

Минәзәл. Шулаймыни?! Кем әйтте?

Салих. Мамадыш районында үткән-сүткән кешеләрдән сораштырган идем. Аны яхшы белүче кеше әйтте.

Минәзәл. И-и-и, жалко. Бик кызык кеше иде. Каты эчте шул. Талантлы кешеләр шул эчеп харап булалар инде алар.

Салих. Ул миңа теге вакытта справканы дөрес бирмәгән. Аның язуы буенча ат түгел, мин үзем үлгән булып чыгам икән.

Минәзәл. Хәзер нишләргә соң?

Салих. Хәзер инде ул мал врачының үзе үлгәнгә таныклык кирәк. Кайсы авылдан иде ул?

Минәзәл. Мин аның кайсы авылныкы икәнен белмим бит. Син центральный загска бар, анда үлгән кешеләр турында мәгълүматлар булырга тиеш.

Локман. Мин инде әллә кайлардан тикшерттем — беркайда бернинди информация юк.

Минәзәл. Бәлки, ул без вести пропалдыр... Хәзер кеше күп югала бит. *(Үрелеп еракка карый.)* Син монда буласыңмы әле?

Салих. Кая барыйм инде мин.

Минәзәл. Мин үз постыма барыйм әле, аннары сөйләшербез. *(Китә.)*

Салих. Сине ничек күреп була?

Минәзәл *(кычкырып җавап бирә)*. Мин гел шушында дежурить итәм.

Локман. Әйдә, безгә кайтабыз.

Салих *(һаман Минәзәл киткән якка карап тора)*. Мин кич белән үзем барырмын сезгә. Мин бу сержант белән сөйләшим әле. Аның аркасында башланды бәла-казаларым, бәлки, ярдәм итәр.

Локман. Ярар. Кич белән көтәбез сине бездә. *(Китә.)*

Салих *(гармунда уйнап җырлый)*.

Әйткән идең:
«Әгәр сөя калсаң,
миннән башка берәр бүтәнне,
Сөй бары тик миннән яхшыракны,
Сөймә ләкин миннән түбәнне...»

Рим килә. Кара күзлек кигән. Сагыз чәйни. Заманча матур киенгән, муенында алтын чылбыр, бармагында алтын йөзек.

Рим *(туктап тыңлап тора)*. Сәлам, абзый!

Салих *(башын күтәреп)*. Сәлам!

Рим. Матур сайрыйсың!

Салих. Рәхмәт. Ошаса, берәр сум булса да ташла.

Рим. Пажалысты. *(Кесәсеннән бер сум акча алып Салих алдына ташлый.)* Инструментың слабыйрак синең.

Салих. Башкасы булмагач, нишлим.

Рим. Минем бик шәп баяным бар, кирәк түгелме?

Салих *(җанланып)*. Кирәк булмый! Шул баян кирәк булганга монда утырам да инде мин. *(Сагаеп.)* Ләкин бик кыйммәттер бит.

Рим. Сиңа ярты бәясенә бирәм. Чөнки миңа срочно акча кирәк.

Салих. Күпмегә бирәсең?

Рим. Сөйләшербез.

Салих. Әйе шул, аны башта карарга кирәк.

Рим. Карарсың. Ошарга тиеш ул сиңа. Шәп инструмент.

Салих. Синең үзеңнекеме соң ул?

Рим. Әйе. Мин консерваториядә укыйм, дүртенче курста. Студент кешенең инде аның, үзең беләсең — акча кирәк тә акча кирәк.

Салих. Әйе, әйе... Яшь кешегә акча кирәк... Хәер, карт кешегә дә кирәк инде ул. Мин үзем менә акчасыз кеше. Хәерчелекнең нинди яман нәрсә икәнен бик яхшы беләм. Әгәр бәясе мине канәгатьләндерерлек булса, бәлки, классташымнан әҗәткә алып торырмын. Кайчан карыйбыз соң баянны?

Рим. Син иртәгә монда буласыңмы?

Салих. Булам.

Рим. Иртәгә обедтан соң шушында алып килермен.

Салих. Ярый, сөйләштек. Исемең ничек?

Рим. Рим.

Салих. Мин Салих абыең булам. Бик кыйммәт сорамассың инде... Мин ерактан килгән кеше...

Рим. Сиңа бөтенләй арзанга бирермен.

Салих *(өметләнеп)*. Рәхмәт.

Рим. Сау булып тор!

Салих. Хуш!

Рим китә. Салих алдында яткан акчаны барлап саный башлый. Минәзәл килә.

Минәзәл *(Рим киткән якка ымлап)*. Теге шакал нишләп йөри синең янда?

Салих *(акчаны кесәсенә тыгып)*. Шакал түгел ул. Баян тәкъдим итте. Арзан бәягә бирермен, диде.

Минәзәл. Син Казан шпанасына ышанма. Алдарга может. Акчаңны да алырлар, баян да бирмәсләр. Сак бул.

Салих. Алайса, ул баян алып килгәч, минем янга сугылырсың әле, бергәләп карарбыз баянны, яме.

Минәзәл. Монда алып киләм дидемени?

Салих. Әйе.

Минәзәл. Ярар.

Салих. Мин бик авыр хәлдә. Бурычка баттым. Ат өчен дә түлисе бар. Берәр ничек спонсор табарга ярдәм италмыйсыңмы?

Минәзәл. Минем эше кешегә спонсор табу мөмкин түгелдер инде ул. Мин ни артист түгел, ни язучы түгел. *(Көлемсерәп.)* Берәрсеннән конфисковать иттерү ягын карасак кына инде.

Салих. Алай кирәк түгел. Мин бер мафиозникка йорт төзешкәндә гаражы өстеннән «Мерседес»ына уголоклар төшердем.

Минәзәл. Яньчелдеме?

Салих. Бик каты.

Минәзәл. Нәрсә ди?

Салих. Башта кыйнады. Хәзер биш мең доллар түләргә тиеш мин аңа.

Минәзәл *(үтә җитди кыяфәт белән)*. Түләмичә булмый. Түләмәсәң, үтерәләр. Казан бу. Бурычы бар кеше йә бурычын түли, түләмәсә...

Салих. Аңлыйм.

Минәзәл. Син шулай да ул «Мерседес» хуҗасының исем-фамилиясен, кайда яшәвен әйт әле.

Салих. Салмачы артында аның коттеджы. Каенлыктан болайрак. Фамилиясен белмим, Гоша дип йөриләр аны. Машинасының номеры — өч берле.

Минәзәл *(язып ала)*. Өч берле... Блатной номер. Сине ничек табып була? Координатларыңны калдыр әле миңа. Вдруг, если что... Аның машинасының ремонтына түләргә тиеш буласың инде, сүз дә юк. Ә шулай да кызыксыныйм әле — нindирәк кеше икән ул, бик куркыныч микән... Бәлки, әйбәтләп сөйләшеп килешү мөмкиндер.

Салих. Аның белән кешеләрчә сөйләшү мөмкин түгел, ахрысы.

Минәзәл. Кайда торасың, адресыңны әйт.

Салих. Әле яңа гына яныма берәү килеп китте бит — ул минем классташым. Әлегә шуларда булырмын, ахрысы. Проспект Ямашева, алтмыш беренче йорт, йөз җитмеш беренче фатир.

Минәзәл *(язып ала)*. Яздым.

Салих. Ярый сине очраттым әле, бераз өметем кабынды. Хәлләр мөшкел бит минем.

Минәзәл. Бирешмә, бирешмә. Заманы әллә нинди бит аның. Ярый, постыма киттем мин. Пока! *(Китә.)*

Салих *(гармун уйнап җырлый)*.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул шул.
Караңгы төн, томанлы көн —
Без аерылган көн бит ул...

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Локманнар фатиры. Гөлнур белән Локман чәй эчеп утыралар. Чулпан киемнәрен үткли.

Гөлнур. Бүген дә килмәс ул.

Локман. Килергә тиеш.

Гөлнур. Нинди җебек кеше булгандыр инде.

Локман *(коры сөйләшә)*. Алай димә! Бу заман җебеккә, катыга карамый. Әллә кемнәр югалып калды, әллә кемнәр сәнәктән көрәк булды. Салих ул сәнгатькә, моңга гашыйк кеше булды гомергә. Хәтерләмисеңмени аның ничек баянда уйнаганын, уенлыкта аның гел түрдә утырганын.

Гөлнур. Соң инде, заман Салихка яраклашмас бит, нәрсәдер эшләргә кирәк. Гаиләсе бар, ул бит ир кеше.

Локман. Сөйләшкәндә җиңел ул. Син әйткәннәр белән мин килешәм, ләкин бер яктан гына карарга ярамый.

Чулпан *(кер үтүкли)*. Ул просто адаптироваться итә алмый бу дөньяга.

Локман. Ул чиста кеше, намуслы кеше, шуңа тормышын кайнатып җибәрә алмый ул. Бүген кеше сайларга тиеш — намуслы кеше булыргамы, әллә тулы канлы, мул тормышта яшәргәме.

Чулпан *(тавышын күтәреп)*. Ой, пап, әле ярый син менә шулай уйлыйсың. Тагын күпмедер вакыт узар. Алай уйлаучылар калмаячак. Все равно по общим законам жить придется.

Локман. Ерткычлар законы буенча яшәрсез. *(Шопырдатып чәй эчә.)*

Чулпан. Менә минем булачак ирем булдыксыз, хәлсез, акчасыз булса, сезгә ошармы?

Гөлнур *(катгый итеп баш чайкый)*. Ю-у-у-к, хәлсез, булдыксыз, акчасыз кешегә чыкмыйсың! Сәнгать кешесе дә кирәк түгел, атаң шикелле журналист та кирәкми.

Локман *(Чулпанга)*. Синең бу йөри торган егетең миңа бер дә ошамый.

Чулпан. Нормальный парень.

Гөлнур. Бик әйбәт, заманча егеткә охшаган. Килеп керү белән затлы одеколон исе аңкый үзеннән. Күрдеңме, Чулпанга нинди туфли бүләк итте. Минем гомергә андыйны кигәнем юк.

Локман. Кайда эшли ул? Кем ул? Ул маңка малай каян андый акча ала? Беркөнне өч меңлек виски белән кергән.

Чулпан. Сөенергә кирәк. Ул студент, но аның ата-анасы байлар, димәк.

Локман. Белмим, белмим.

Гөлнур. Ярар, Аллага тапшырдык инде. Чатта гармун уйнап утырышлы булмасын берүк.

Локман. Хайваннар арасында хайванча яшәгәнче, бәлки, чатта гармун белән утыру аруractыр.

Чулпан *(авызын кыйшайтып)*. О, начинается.

Локман. Тик кенә тор! Минем шакмаклы күлмәкне үтүкләдеңме?

Чулпан *(иреннәрен турсайтып)*. Үтүкләдем, үтүкләдем.

Гөлнур. Ярар, тиктомалга тавыш чыгарма әле, Локман. Чулпан, егетең киләме бүген безгә?

Чулпан. Килә.

Гөлнур. Атасы, кырыс сөйләшмә инде ул егет белән, зинһар. Бик җитди ниятләр белән йөри шикелле.

Локман. Кем әле аның белән кырыс сөйләшкән?!

Култык астына гармунын кыстырып Салих керә.

Салих *(басынкы тавыш белән)*. Хәерле кич!

Локман *(сөенеп)*. Кайттыңмы? Маладис!

Гөлнур. Әйдә, ашарга утыр.

Салих *(гармунны ишек катында калдырып килә)*. Рәхмәт. *(Кыяр-кыймас кына килеп табын янына утыра.)*

Гөлнур *(Салих алдына тәлинкә белән аш куя)*. Ничек, акча эшләп буламы урамда?

Салих *(ашый)*. Юк инде, алай гына булмый ул. Әле рэкетирлар килеп йөдәтә. Ярый әле теге Минәзәл дежурить итә анда. Ул башка смена милиционерларына да әйтеп куйды, миңа тимәсеннәр дип.

Гөлнур. Җәмиләдән дә хат юк. Ул да жалко. Сагынасыңмы соң?

Салих *(ашаудан туктый)*. Сагынмый, ничек сагынмыйсың инде!

Гөлнур. Аша, аша.

Локман. Мин әлегә теге врачның эзенә төшә алмадым. Минемчә, үлгән кешенең эзен эзләп, аның исән түгеллегенә справка табарга маташып йөрүнең кирәге юк.

Салих. Нишлик соң?

Локман. Мин бизнесменнарга мөрәҗәгать иткәләдем инде — ярдәм сорап. Сиңа бит хәзер шактый акча кирәк. Биш мең доллар теге «Мерседес» өчен, ат өчен. Баян да кыйммәт бит әле.

Гөлнур. Андый акчаны ничек, каян тапмак кирәк?!

Салих. Эзләп маташмыйк, Локман, андый акчаны кем бирсен синең белән миңа.

Локман. Мин инде филармониягә дә бардым, Культура министрлыгында да булдым, театрларга да кереп чыктым, чөнки театрларда төрле концертлар еш була. Юк, һич кенә дә арзан бәягә инструмент юнәтеп булмый.

Рим керә. Затлы киемнән, кулында чәчәк бәйләме, зур коробка кәнфит, коньяк.

Рим *(елмаеп)*. Исәнмесез! *(Салихны күреп аптырабрак кала.)*

Гөлнур. Исәнме!

Чулпан *(йөгереп килә)*. Привет, Рим! *(Аның кулындагы кучтәнәчләрне алып өстәлгә куя.)* Әни, чәчәкләрне вазага куй.

Гөлнур *(чәчәкләрне иснәп)*. Рәхмәт яусын. *(Чәчәкләрне вазага утырта.)*

Рим. Приятного аппетита. *(Ирләр белән кул биреп күрешә.)*

Салих. Рәхмәт.

Чулпан. Рим, ашыйсың киләме?

Рим. Юк.

Чулпан. Алайса, чәй эчәрсең.

Рим. Чәй эчеп тормыйк инде. Киттек, әйдә.

Чулпан. Хәзер, тиз генә киенәм дә. *(Күрше бүлмәгә йөгереп кереп китә.)*

Салих *(текәлеп карап тора)*. Син... теге Рим бит?

Гөлнур. Сез әллә танышмы?

Рим *(кырт кисеп)*. Юк.

Салих. Баян алып килергә вәгъдә итүче син түгел идеңмени?

Рим *(түземсезлек белән Чулпанны көтеп)*. Юк, ялгышасыз.

Салих *(таләпчән тавыш белән)*. Син бит вәгъдә иттең.

Рим. Ә, әйе, иртәгә... Искә төште. Аннары сөйләшербез, яме.

Салих. Ярар, ярар, иртәгә мин шунда булачакмын.

Чулпан *(күрше бүлмәдән чыга)*. Хәзер, китәбез.

Локман. Баяның бармыни?

Рим *(сөйләшү андый темага кереп киткәнгә бик читенсенә)*. Әйе... бар...

Локман. Зинһар, сат Салих абыеңа арзанрак бәягә. *(Серле тавыш белән.)* Бүләк итсәң дә була. Чулпан, сөйләш әле шуның белән.

Чулпан. В самом деле баян есть что ли у тебя?

Рим. Есть.

Чулпан. Рим, продай его ему за дешево, пожалуйста. У этого дяди дела совсем плохи.

Рим. Ярар, ярар.

Локман. Алып кил безгә баяныңны, яме.

Рим. Ярар.

Салих *(шатланып)*. Алайса, урамга түгел, монда алып килерсең.

Рим. Сөйләштек.

Чулпан. Ну, киттекме?

Рим. Киттек.

Чулпан. Без киттек, мам!

Гөлнур. Озакка югалма!

Чулпан. Ярар! *(Рим белән Чулпан чыгып китәләр.)*

Гөлнур. Чынлап та баян тәкъдим итеп килдемени?

Салих. Әйе.

Локман *(елмаеп)*. Ул инде каушады. Читенсенде безнең алда сату-алу турында сөйләшергә. Егетне аңлап була.

Гөлнур. Безнең янда кузгатасың калмаган, Салих.

Салих. Әйе шул, түземлегемне җуйдым бит.

Локман. Ярар, ярар, әйбер-кара юк, кузгатса ни булган.

Салих. Күпмегә сатар икән?

Локман. Баянын карыйк әле башта. Бәлки, бүләк итәр.

Гөлнур. Бүләк итмәс инде ул.

Локман. Менә күрербез инде кызыңның йөргән егете яхшымы, начармы.

Гөлнур. Яхшы булам дип, ул сиңа үз әйберсен бушка бирмәс инде.

Салих. Бушлай бирмәс. Бәясен бик зур күтәрмәсен инде.

Локман. Анысы шулай. Карале, Салих туган, нинди мескенлек, ә! Ни генә ала башласак та — арзан кирәк! Акчабыз җитәр микән, кыйммәт сорамаслар микән дип яшә әле син гомер буе! Без шушы көнгә калырдай кешеләр микәнни соң?! Нефтьле Татарстанмы без, әллә бетле Татарияме?

Гөлнур. Ил мөлкәтен дөрес бүлмәделәр, кемдер баеды, кемдер хәерчеләнде.

Локман *(кызып китә)*. Ташла, Гөлнур, алай примитив карама! Мәсьәлә катлаулырак монда. Үзебездән тора барысы да. Үзебезне күпмегә бәялибез, шулкадәре түлиләр. Үзебезне үзебез талыйбыз. Үзебезне үзебез бетерәбез. Үзебезнең арабыздан эзләргә кирәк кабахәтен дә, яхшысын да. Бөтенесе үзебездә — нәтиҗәсе дә, сәбәбе дә!

Салих. Монда алып килүе әйбәт булыр, бергәләп карарбыз. Аннары, таныш кешедән әйбер алу җиңелрәк инде ул.

Локман. Шулай, бергәләп әйбәтләп карарбыз.

Салих. Рәхмәт, тамак туйды. Ярый сез бар әле. Нишләр идем?!
Локман *(Салихны иңеннән кага)*. Их, кордаш, кордаш!
Гөлнур. Салих, әйдә, яшь чактагы берәр көйне уйна әле.
Локман. Әйе, туган, күңелне тетрәндереп ал, зинһар.

Салих гармунда уйнап җырлый:

Яшьлегемне эзләп чыктым
Җәйнең болыннарына,
Әйтте җил: «Синең яшьлегең
Февраль бураннарында».

Кушымта:
Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Дөрес чамаламаганмын
Гомеремнең чикләрен,
Авыз итә алмый калдым
Июньнең җиләкләрен.

Кушымта.

Ник болай тиз үтә көннәр?
Һаман да аңламадым.
Бакчамда җиргә коела
Сентябрь алмалары.

Кушымта.

Алмагачым әйтте миңа:
«Югаласы югалган,
Озак йөргәнсең февральдә,
Шуңа чәчең агарган».

Кушымта.

Йөгердем кыш уртасына —
Яшьлекне табыйм инде.
Адаштым, хәлем җитмәде,
Ярый әле яз килде.

Кушымта.

Җирдә бәйрәм. Ничәнче кат
Чәчәк ата сиреньнәр.
Иң кирәк сүзне әйтерләр
Инде башка иреннәр.

Кушымта:
Язда булдым, җәйне гиздем,
Яратып һәм табынып.
Йөрим алма бакчасында
Бураннарны сагынып.

*(Сентябрь алмалары)*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Салих кара күзлектән урам чатында гармунда уйнап утыра. Кешеләр үтеп китә. Кемдер туктап тыңлап тора, кемдер акча ташлый, кемдер битараф килеш узып китә. Бервакытны Мирза килеп чыга. Ул туктап Салихның уйнаганын тыңлап тора. Салих башын күтәрә дә уйнаудан туктый.

Салих *(гармунны кырыйга куеп әкрен генә күтәрелә)*. Мирза әфәнде! Өнемме бу, төшемме?
Мирза. Ә син үзең ничек уйлыйсың соң? *(Китмәкче була.)*
Салих *(күзлеген сала да аның җиңенә ябыша)*. Сине бит үлде дигәннәрие.
Мирза *(үзен тыныч тота, ычкынырга маташмый).* Алай дигән кеше үзе инде хәзерге вакытта гүр ияседер. Мирза ул бөтен кеше үлеп беткәч тә бер атна-ун көн йөриячәк әле. Чөнки күп эшем эшләнмәгән әле бу дөньяда. Син кем буласың соң? Мин бит сине белмим?!

Салих *(бер-ике адым артка чигеп)*. Мин — Салих! Минем атым үлгәнгә справка биргән идегез.

Мирза. Мин гомеремдә ничәмә мең справка биргән кеше. Барыгызны да хәтерли алмыйм, бигайбә.

Салих *(кабаланып сөйли)*. Күптән түгел булды ул. Вятка күпере янында. Минем атым югалды. Шунда постта торучы сержант белән синнән үтенеп сорадык ат үлгәнгә справка языгыз дип. Сез справка яздыгыз. Андый справка кирәк түгелие.

Мирза. Атың терелгәнме әллә?

Салих *(газаплы кыяфәт белән)*. Юк шул, атым югалды бит минем. Ә сез справка биргәниегез мине җәлләп.

Мирза. Нәрсә, җәллисе калмаган мәллә?

Салих. Алай түгел. Сез, гафу итегез, ул вакытта бераз салмыш идегез...

Мирза. Мин хәзер дә салмыш.

Салих *(ялагайлык белән)*. Бик әйбәт. Димәк, сез сәламәт кеше.

Мирза. Сиңа нәрсә кирәк, похмеляться итәргәме?

Салих. Юк. Сез миңа теге вакытта ат үлде дип язасы урынга ялгыш мин үлде дип язып биргәнсез.

Мирза *(шаккаткан булып)*. Не может быть!

Салих *(елмаеп)*. Шулай язгансыз шул.

Мирза. Ну, син исәндер бит?

Салих *(йөзеннән шатлык чәчеп)*. Күрүегезчә, әлегә исән-сау.

Мирза. Соң, алайса ерт та ат ул справканы. Ялгышулар була инде ул. Ерт та ат. Исән килеш үлдем дигән справка белән йөрү нескромно, мне кажется. Пиво эчәсеңме?

Салих *(Мирзадан күзләрен алмый, югалтудан курка)*. Эчәм.

Мирза *(сумкасыннан бер шешә сыра алып бирә)*. Мә, тешең белән ач.

Салих *(Мирза китеп бармасын дип куркып карап тора)*. Тешләр начар минем.

Мирза *(теше белән ачып бирә).* Ул справка белән берәр кәнитил килеп чыкты мәллә?

Салих *(сыраны ала, бер йотып куя)*. Авыл җитәкчесе Мулланур ат таптыра миннән.

Мирза. Син аңа әйт: татар йөрәге скрипка түгел, пажалысты, уйнама, диген.

Салих. Мин сезнең аны белүегез турында әйткәнием, ул сезне белмим, диде.

Мирза. Мин белгән җиткән. Мин нишләргә тиеш хәзер?

Салих *(ихлас күңелдән)*. Мин шулхәтле шат сезнең исән булуыгызга! Сезне күрүемә бик шат. Мин бит Мамадыш районында сезнең хакта сораштырдым. *(Йөзе кинәт караңгылана.)* Гафу итегез, сезне үлде диделәр.

Мирза *(бер дә исе китмичә генә)*. Безнең якта шундый дурацкий шаяру бар: берәр кеше турында сорасалар, үлде дип җавап бирәләр. Просто безнең районда кеше артык күп, шуңа күрә кеше үлгәнгә сөенәләр бездә. Безработица, тегесе-монысы...

Салих *(үзен гаепле сизеп)*. Мин инде сезнең үлүегез турында таныклык артыннан йөри идем. Мулланурга кайтарып бирергә.

Мирза *(җитди тавыш белән)*. Мин үземнең үлүем турында да сиңа справка язып бирә алам, тик анысы бушка булмаячак, кыйммәткә төшәчәк.

Салих *(ялварып)*. Юк, юк, раз инде сез исән, атым үлгәнлеккә генә таныклык ясап бирегезче.

Мирза *(бик эшлекле кыяфәт белән)*. Минем үзем белән бланклар бар, тик пичәт кесәмдә түгел. Бер хатында калдырганмын. Иртәгә очрашыйк. Мин сиңа эшләп бирермен.

Салих *(Мирзаны очратканга чиксез куанып)*. Сез Казанда нишләп йөрисез?

Мирза *(тантаналы тавыш белән)*. Иң зур эшләр Казанда кайный, туган. Мин бит бик кирәкле кеше Татарстанга. Менә сайлаулар узды, мин мәш килдем, чтобы тыныч узсын. Менә Казанның мең еллыгын уздыруда да мине катнаштырырга маташалар. Төрле артистларга ярдәм итүче дә мин, концертларын оештырам, Вәзи Мәзиев дигән яшь җырчыга аппаратура алып бирдем. Эш күп.

Салих *(сокланып)*. Сез мал врачы була торып шулай киң диапазонда эшлисез икән...

Мирза *(аны-моны уйламыйча)*. Кешеләре хайван булгач, минем кебек мал врачлары кирәк монда, брат.

Салих *(кыюсыз гына)*. Бәлки, сез миңа да спонсорлык ярдәме күрсәтә алырсыз?

Мирза. Синең нинди талантың бар соң?

Салих *(җитдиләнеп)*. Авылга баян кирәк.

Мирза. Үзең нишли аласың соң син — җырлыйсыңмы, биисеңме?

Салих. Минем үзем язган бер җырым бар. Хатын миннән китәргә йөргәндә ялагайланып аңа багышлап язган идем. *(Гармунына тотына.)*

Мирза. Алайса, көчле җырдыр ул. Йә, җырлап күрсәт.

Салих җырлый.

Көзгә кереп барабызмы,

Нигә болай караңгы?
Әллә томан арабызда,
Әллә авыр карадың...

Кушымта:
Китте миннән, синдә йөри
Күңелемнең яртысы,
Сине югалткан көнне үк
Мин үләрмен, ахрысы.

Сәгать саен күз алдымда,
Белмим, нигә юксынам,
Сине кочып елар өчен
Хәсрәтем дә юк сыман.

Кушымта.

Мизгел саен яңа дулкын,
Мизгел саен сагынам,
Ни булгандыр зиһенемә —
Бары сиңа табынам.

Кушымта.

Көзгә кереп барабызмы,
Нигә болай караңгы?
Әллә томан арабызда,
Әллә авыр карадың...

Кушымта.

Мирза *(сокланып)*. Гениально! Син бит талант!

Салих. И, кая инде.

Мирза. Менә, татар мәңге шулай ул. Тыйнак, мескен булырга тырыша һәрвакыт! Кая инде димә! Кыюрак булырга кирәк. Әйдә концертларыңны заделывать итәбез. Бер конферансье, бер биюче кыз кирәк. Болай гына акча беркем дә бирми. Концертлар шаукымында тегеннән-моннан акча күчерттереп була. Эшлибезме?

Салих. Мин бит авыл клубында гына җырлыйм. Район үзәгендә елга бер тапкыр.

Мирза. Син бит ишетәсең, район үзәгендә җырлау түгел, район үзәгенә барганы булмаган кеше дә хәзер Казанда концертлар куя. Булышам мин сиңа! Репертуар әзерли тор! Күп итеп акча эшлибез.

Салих *(читенсенеп)*. Куркам, каушыйм. Ә акча кирәк. Минем бит ат өчен түлисе бар хәзер, баянга акча кирәк. Әле бит син белмисең: шабашка эшләгәндә берәүнең иномаркасын яньчедем уголоклар белән — аңа биш мең доллар түлисе бар.

Мирза. О-о-о, син көннән көн тирәнрәк батып барасың.

Салих. Шулай шул.

Мирза *(куллары белән кискен хәрәкәтләр ясап сөйли)*. Мин әйткәнне тыңла. Татар йөрәге скрипка түгел, уйнама. Әйткәнне тыңла. Бөтен нәрсәң булачак. Мин дә хәерче идем. Хәзер Казанда гына ике квартирам бар. Казан безнеке ул. Итне татар да, урыс та, яһүд тә бик ярата. Мин яшь тана ите белән... Ну, вобшем... Ышанасыңмы миңа?

Салих. Ышанмый. На ходу справка язып бирә торган кешегә ничек ышанмыйсың.

Мирза. Иртәгә көндезге сәгать икедә сине кайда табып була?

Салих. Мин менә шушында гармунда уйныйм. Шушында очрашыйк.

Мирза. Синмени ул бу арада җиффәрәсең гармунда?

Салих. Әйе. Синең дустың, теге сержант Минәзәл дә моннан ерак түгел дежурить итә. Әнә тегендә.

Мирза. Беләм. Мин булыштым бит аңа монда күчеп урнашырга. Бүген аның сменасы бугай. Аны барып күрим әле мин. Ярый, иртәгә сәгать икедә.

Салих. Ярар, иртәгә очрашабыз. Син бүтән югалма инде.

Мирза. Мин югала торган кеше түгел!

Мирза китә. Салих, елмаеп, ул киткән якка карап тора.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Салих Локманнарда кабалана-кабалана шулпа ашап утыра.
Тончыга-тончыга сөйли.

Салих *(ашый-ашый сөйли)*. Шаккаттым! Тетрәндем!

Локман. Менә бит, ә син аны үлеләр арасыннан эзләттең мине. Әле җитмәсә, битәрләдең табалмыйсың дип.

Салих *(Локманга гаепле караш белән карап тора)*. Ачуланма инде.

Локман. Концертларын белмим, малай, концерт белән күп кеше мавыга хәзер. Элек эшлисе килмәгән кеше милициягә эшкә керә иде, хәзер ялкау кеше арзан бәяле синтезатор кнопкаларын өйрәнеп сәхнәгә чыгу ягын карый. Син башта справка белән эшеңне тәмамла. Син ул Мирзаның координатларын алып калмадыңмы соң, телефон номерын?

Салих. Юк.

Локман *(ачуланып)*. Ну, нинди кеше син, ә! Тагын югалса?!

Салих. Иртәгә киләм диде сәгать икедә.

Локман. Берәр сәбәп белән йә сәбәпсез алай-болай килми калса? Монда нинди эш белән йөри соң ул мал врачы?

Салих. Ул бөтен өлкәдә дә киң колач белән йөзә, ахрысы. Ул бик блатной кешегә охшаган.

Локман. Бозауларны списывать итеп, ит белән акча эшләүчедер инде.

Салих *(үпкәләп)*. Ярдәм итәргә торучы кеше турында алай димә инде.

Баян күтәреп Рим килеп керә.

Рим. Исәнмесез!

Локман. Исәнме!

Салих. Исәнме!

Гөлнур күрше бүлмәдән чыга.

Гөлнур. Исәнме, Рим!

Рим. Исәнмесез! Менә баянны алып килдем. *(Урындыкка куя.)*

Локман *(килеп карый)*. Салих, кара әле инструментны, ничегрәк икән?

Гөлнур *(якынрак килеп)*. Шәп инструменттыр бу.

Салих *(баянны алып әйләндергәләп карый, уйнап ала)*. О-о-о, бу бит әле яңа диярлек, шәп баян!

Күрше бүлмәдән Чулпан килеп чыга.

Чулпан. Привет! Алып килдең, да? Молодец!

Локман. Чулпан, Рим белән сөйләш инде, бәясен чамалап сорасын.

Чулпан. Күпмегә бирергә уйлыйсың инде?

Рим. Ну, синең хакка инде... Ике меңгә бирәм.

Локман. Мондый ислемай сибенгән егет бер меңгә бирсә дә ярый инде.

Гөлнур. Локман, алай түгел. Ул бит аңа да кадерле, үзе дә акчага сатып алган бит ул аны.

Чулпан. Отдай за полторы, ты же все равно играть не умеешь.

Гөлнур. Бәлки, өйрәнер әле.

Локман. Өйрәнәсе кеше инструментны сатарга йөрми ул.

Салих. Анда, консерваториягездә, арзанракка табып булмыймы соң?

Чулпан. Ул каян белсен.

Салих. Консерваториядә укый бит, шуңа соравым.

Локман. Безгә юридическийда диде.

Чулпан. Ул консерваториядән юридическийга күчте.

Салих *(уйнап карый)*. Шәп баян бу! *(Иснәп карый.)* Бу инструмент ничектер бик таныш, якын тоела әле миңа. *(Баянны әйләндергәләп карый.)* Син моны каян алганыең?

Рим. Базарда сатып алдым.

Салих. Кайсы базарда?

Рим. Вьетнамскийда.

Салих *(баянны җентекләп тикшерә)*. Җәмәгать, бу бит минем баян! *(Корт чаккандай сикереп тора да баян тирәли йөри.)* Бу минем родной баяным! Аның өстендәге инвентарный номерын кырып сөрткәннәр инде, әлбәттә. Әмма вә ләкин мин, на всякий случай, тагын яшерен урында вак цифрылар белән язган идем ул номерны. Менә күрәсезме?

Баян каешының аскы яктан эләктергән урында, эчтә язылган саннарны бармагы белән төртеп күрсәтә. Барысы да килеп карыйлар.

Бу — минем инструмент, документлары клубта, исбатлый алам.

Рим *(каушый)*. Мин аны сатып алдым. *(Торып баса.)*

Локман. Сидеть!

Рим кире урынына утыра.

Рим. Сез нәрсә... *(Торып китмәкче була.)*

Локман. Кая талпынасың?! *(Римның кулын каера.)* Салих, әнә теге элгечтәге каешны алып кил тизрәк.

Салих. Нигә ул? *(Каешны алып килә.)*

Чулпан *(куркып)*. Мам, че они делают?!

Гөлнур. Нишлисез сез, садистлар!

Локман *(Римның ике кулын да каерып).* Салих, бәйлә кулларын!

Салих. Ник? *(Үзе тегенең кулларын бәйли.)*

Локман. Тыгызрак бәйлә, аннары аңлатырмын.

Рим каршы торып карый, көче җитми.

Без аны разбираться итәр өчен генә бәйлибез. Гаебе булмаса җибәрербез.

Римны, кулларын бәйләп, урындыкка утыртып куялар.

Гөлнур *(кычкырып)*. Кияү белән алай ярамый обращаться!

Локман *(кычкырып җавап бирә)*. Нинди кияү?!

Чулпан *(чәрелдәп)*. Җибәрегез Римны! Рим, тебе больно?

Локман. Молчать! Китегез читкәрәк! *(Барысы да читкә тайпыла.)* Каян алдың бу баянны?

Рим *(теләр-теләмәс кенә җавап бирә)*. Базарда сатып алдым.

Салих. Кайчан?

Рим. Күптән инде.

Локман. Сатучының төс-битен хәтерлисеңме?

Рим. Әллә тагы.

Минәзәл килеп керә.

Минәзәл. Исәнмесез! *(Карап тора.)* Минем килеп керүем вакытсыз булды бугай.

Локман. Киресенчә, нәкъ вакытында килеп кердегез. Безгә хәзер именно милиционер кирәк тә.

Салих. Әллә җибәрикме? Баянны алып калабыз да.

Рим. Мин аны сатып алдым.

Чулпан. Базарда сатып алдым ди бит!

Гөлнур. Карале, егетне интектерәләр!

Минәзәл. Аңлатыгыз әле, нәрсә бара монда?

Салих *(гасабиланып һәм шул ук вакытта баяны табылудан сәер илһамлану кичереп).* Бу егет баян алып килде миңа сатарга. Ә бу баян — безнең клубныкы. *(Кискен хәрәкәтләр белән, калтырана-калтырана баянны боргалап күрсәтә.)* Менә монда, яшерен урынга мин язган инвентарь номеры. Менә монысы кызымның жвачкасы ябышып бераз краскасы купкан иде. Менә монысы — өстә, күриктә томатный соус табы бар. Бер туйда шабашкада тамызган идем. Минем баян бу. Минеке! Исбатлый алам.

Локман *(усал һәм таләпчән тавыш белән)*. Казанда берәр туганың бармы?

Рим. Әтием монда булырга тиеш.

Локман. Кайда ул?

Минәзәл *(ишеккә таба юнәлә)*. Мин киттем. Миннән башка гына разбираться итегез инде.

Локман *(җикереп)*. Юк, юк, китмисез! *(Бермәл карап тора.)* Ә сез ник килгәниегез соң монда?

Салих. Бу теге, Мамадыш күперендәге сержант. Хәзер Казанда хезмәт итә ул. Минем янга килгәндер.

Минәзәл. Әйе, әйтәсе сүзем бар иде сиңа. Аннары... Син чатка гармун уйнарга чыгарсың әле, шунда әйтермен, яме. *(Чыгып китмәкче була.)*

Локман *(сержантның юлына аркылы төшә)*. Юк! Мин журналист, күп тиражлы гәҗиттә эшлим. Сүземне тыңлагыз, китмәгез! *(Римга мөрәҗәгать итә.)* Атаңны кайдан табып була?

Рим. Телефоннан шылтыратып.

Локман. Номерын әйт.

Рим. 907947.

Локман. Нинди номер бу?

Рим. Мобильныеныкы.

Локман. Чыгып шылтыратып керергә кирәк.

Чулпан *(елап бите юешләнеп беткән)*. Римның мобильные бар бит.

Локман. Бигрәк әйбәт. Бир.

Чулпан Римның кесәләрен капшап телефонын алып бирә.

Минәзәл *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Мин китим инде. Бу минем эш түгел.

Локман. Юк, милиция эше бу! *(Телефонны әйләндергәләп карый.)*

Рим. Чулпан, номерны җыеп бир.

Чулпан *(әтисеннән телефонны ала)*. Номерны әйт.

Рим. 907947.

Чулпан *(номерны җыя)*. 907947. *(Тыңлап тора.)* Сөйләш. *(Телефонны Римның колагына куеп тотып тора.)*

Рим. Әти, бу мин, Рим. Әти, мине заложник итеп алдылар... Син монда килергә тиеш... Монда килгәч күрерсең... Мин баян алган идем бит базардан... Шуны миннән урлагансың дип талап алмакчы булалар... Кирәкми... Монда милиционер бар инде... Син монда кил... Минем куллар бәйләнгән... телефонны да башка кеше тотып тора ... Күп... Кил, сиңа тимиләр алар... Юк, юк, кирәк түгел... Монда башка ситуация... Ярар... *(Өйдәгеләргә.)* Әтием хәзер килә.

Чулпан *(телефонны Римның күкрәк кесәсенә тыгып куя).* Рим, син ул баянны урламагансыңдыр бит? *(Елый.)*

Рим. Мин аны сатып алдым.

Гөлнур *(өзгәләнеп)*. Егетне мыскыл итеп кеше көлкесенә калабыз бит.

Чулпан *(таләпчән тавыш белән)*. Әти, җибәрегез Римны!

Локман *(тыныч, ләкин яман усал итеп)*. Тик кенә тор! Алайса, хәзер сине дә бәйләп ташлыйм!

Гөлнур. Менә милиционердан сорагыз әле, гаебе исбатланмаган килеш кешене бәйләргә ярыймы?

Локман. Син башта сора, клубтан баян урларга ярыймы дип.

Чулпан. А ты докажи, что это Рим украл.

Локман. Исбатлый алмасам, гафу үтенермен.

Минәзәл. Мин китим инде. Атасы килгәч үзегез карагыз шунда.

Гөлнур *(ялварып)*. Юк, юк, сез китмәгез инде.

Мирза керә. Тынлык урнаша.

Мирза. Исәнмесез!

Салих. Исәнмесез!

Локман. Сез кем?

Салих *(сөенеп)*. Бу Мирза әфәнде. *(Кул биреп күрешә.)*

Локман. Теге үлгән профессормы?

Гөлнур *(нәфрәтләнеп)*. Бөтен кеше белән дә дорфа сөйләшмә инде.

Чулпан *(әтисенә ямьсез карап)*. Әйе, тем более милиционер янында.

Локман *(җикереп)*. Молчать!

Салих *(Мирзага елмаеп карап тора)*. Сез мине эзләп килдегезме?

Мирза *(коры гына)*. Мин улымны эзләп килдем.

Салих *(аптырашта кала)*. Нинди улыңны?

Минәзәл. Аның малае бит бу!

Локман *(мыскыллы елмаеп)*. Шулаймыни?! Бик шатмын!

Гөлнур *(елый)*. Оят, хурлык!

Салих *(гаҗәпләнеп)*. Ничек?! Бу синең улыңмыни?

Рим *(чарасызлыктан кысылган тавыш белән)*. Әти, мин гаепле түгел!

Мирза *(Римга таба атлый)*. Нәрсә булды тагын синең белән, мөртәт?!

Салих. Синең улың Рим миңа баян тәкъдим итте... Мин сатып алмакчы идем... Сез гафу итегез, Мирза әфәнде, ләкин бу баян минеке. Исбатлый алам. Минем клубтан югалган инструмент бу.

Гөлнур *(Мирзаны танып ала)*. Болар бит безнең авылга кайтып йөрүчеләр. Мулланурның туганнары. Кайда күргәнем бар бу егетне дим... Сез бит Мирза абый — Мулланур абыйның двоюродные. *(Мирзага таба килә.)*

Локман. Димәк, авылга кайткач урлаган. *(Римга.)* Соңгы тапкыр авылга кайчан кайттың?

Мирза. Хайван! *(Римның яңагына чабып җибәрә.)*

Рим *(кычкыра)*. Сукма!

Мирза. Җәмәгать! Әйдәгез, тавыш-тынсыз гына килешик.

Локман *(усаллык белән)*. Синең чыраеңа карагач һич кенә дә килешәсе килми.

Мирза *(серле караш белән карап тора)*. Сердце татарина не скрипка, не надо играть. Миңа бик каты бәрелергә тырышма инде син, начальник.

Локман. Сиңа бәреләсе юк. Үзең бер бәрелерсең әле. *(Бүлмә буйлап йөри.)* Тәк, баян табылды. Шул баян аркасында Салих атсыз калган. Будь добр, ат бәясен түлә!

Мирза. Атың миндә синең.

Салих *(таң кала)*. Ничек?!

Мирза. Мурзиха авылының ветеринарында ул. Шунда урнаштырдым. Хәзер шылтыратам мин аңа. *(Мобильный телефонын алып номерны җыя. Барысы да тып-тын торалар.)* Алло! Сәгыйть! Ат синдәме? Теге, башындагы ак таплы яшь айгыр. Әнә, Вятка буеннан илтеп бирделәр бит сиңа... Ну... Качты?! Ничек? Утарны сикереп чыккан? Чын әйтәсеңме? Ярар, мин сиңа кич белән шылтыратырмын әле. *(Телефонны кесәсенә тыгып куя.)* Җәмәгать! Ат качкан. Түләрмен. Менә хәзер үк бераз наличными бирәм. *(Кесәсеннән бер уч акча алып Салихка бирә. Салих шундук акчаны чалбар кесәсенә тыгып куя.)* Кайткач авылда безнең турыда сөйләмә. Мулланур минем двоюродный бит. Анда кайтырга ару булмаячак.

Локман. Ат өчен түләмәсәң, гәҗиттә язып чыгам. Катлаулы авылы җитәкчесенең туганы һәм аның малае дип...

Мирза. Татар йөрәге скрипка түгел, уйнамагыз инде, зинһар. Түлим дигәч түлим инде, сез нәрсә. Минәзәл, әйт әле минем әйткән сүземдә торучы кеше икәнне.

Минәзәл. Түли, түли.

Салих. Мин аңламыйм... Ничек сез, профессор башыгыз белән...

Локман. Нинди профессор булсын ул!

Минәзәл көлә.

Салих. Мин аңламыйм, ник урладыгыз соң сез минем атны?

Локман. Ну, ат йөри юл кырыенда. Егетләргә әйттем: барыгыз, машина бәреп киткәнче бу атны Мурзихага илтеп куегыз, дидем. Мин бит белмәдем синең Мулланур абыйның авылыннан икәнне.

Салих. Ник, ә Мулланур абыеңның авылыннан булмаганны урларга кирәкме?

Локман. Нәрсә син аның белән сөйләшеп торасың, Салих? Сез бит берегез бер планетаныкы, икенчегез башка планетаныкы!

Салих. Гаеп сездә бит, килешәсезме?

Мирза. Гаепсез кеше юк бу дөньяда.

Минәзәл. Әйдәгез, килешегез инде. Баян табылды. Акча бирде бераз. Ат бәясен түләргә вәгъдә итте. Үзем проконтролирую. Минем сиңа, Салих, куанычлы хәбәр бар. Шул хәбәр хакына җибәр син боларны. Түлисе бәяне түләрләр, түләрләр. Куанычлы хәбәрне әйтим инде тизрәк.

Локман. Чишегез бавын.

Мирза *(улының кулларын баудан азат итә)*. Ай-яй тыгыз бәйләгәннәр сине. Шакал! *(Римның башына сугып җибәрә.)*

Чулпан *(Римга карап тора)*. Урод! *(Күрше бүлмәгә чыгып китә.)*

Гөлнур. Ник кирәк бу спектакль миңа?! *(Тәрәзә янына барып баса да тышка карап тора.)*

Локман *(Мирза белән Римга)*. Чыгып китегез! Гөлнур форточкаларны ач, җилләсен фатир.

Мирза *(Локманга)*. Артыгын кыланасың, хозяин. *(Римга сугып җибәрә.)* Әйдә, дуңгыз малай, бәреп үтерәсе бар сине!

Мирза белән Рим чыгып китәләр. Гөлнур форточкаларны ача.

Минәзәл. Теге мафиозник Гошаны Васильево поселогында атып үтергәннәр. Бик каты разборкалары булган. Так что, Салих туган, биш мең түлисең юк.

Локман *(Салихның иңенә шапылдатып суга)*. Менә бит, Алла бар ул.

Салих *(кашларын җыерып)*. Кеше үлгәнгә сөенмә инде.

Локман. Нинди кеше соң син! Үзеңне үтерер иде бит ул.

Салих *(кәефе күтәрелә башлый)*. Чыннан да, Алла кушмаган эш юк. Баян табылды. Биш мең бурычым юк. Сөенергә кирәк, сөенергә. Мирза ат өчен түләр микән?

Минәзәл *(үтә дә җитди кыяфәт белән)*. Моны мин үз өстемә алам. Мин ул кеше өчен бик күп нәрсә эшләдем һәм дә аның турында мин бик күп беләм.

Салих. Карале, профессор түгелдер ул?..

Минәзәл. Ярар, киттем мин.

Локман. Син кайчан дөньяга күзләреңне ачыбрак карый башларсың икән, Салих?!

Салих. Шулай да, Аллага шөкер, эшләр уңай якка борылып бара түгелме?!

Гөлнур. Сөенергә бик ашыкмагыз әле. Җәмиләңнән хат килде. Сиңа түгел, минем исемгә. Сиңа язып тормаган инде... Киткән ул синнән. Син кайткач, үзе разводка бирәчәк.

Минәзәл. Минем кирәгем калмагандыр инде монда. Киттем мин. Син кайгырма, хатын-кызның кире кайта торган гадәте бар аның. Минем үземнең хатын инде дүрт тапкыр китеп кире килде. Тагын китәргә йөри... Сау булыгыз! *(Чыгып китә.)*

Салих *(коелып иңә)*. Күңелем сизгәние аны... Мин бүген начар төш күргәнием. Имеш, мин йорт каршында басып торам. Ә Җәмилә мин югалткан атка атланып Казан тарафларына китеп бара. Мин

нидер кычкырмакчы булам, телем әйләнми. Артыннан йөгермәкче булам, аяклар тыңламый. Куркып уянып киттем. *(Хәлсезләнеп урындыкка утыра.)*

Локман. Начар төш түгел бу. Син югалткан атка атланып чыгып киткәч, ул бик ерак китә алмый, шулаймы? Син дә ул ат белән Вятка күперен чыккач дальше киталмадың.

Гөлнур. И, кызганам шул Җәмиләне.

Локман. Гел Җәмиләне генә кызганасың син.

Гөлнур. Бер класста укыдык, дуслар идек. Салих бит ни дисәң дә ир кеше. Хатын-кызга авыррак.

Салих *(кичеп чыккысыз газап белән)*. Болай да тормышның рәте юк иде, хәзер инде тәмам җимерелде.

Локман *(кырыс тавыш белән)*. Әйдә, ярар, хатын-кыз бетмәгән дөньяда.

Гөлнур. Ни сөйлисең син! Әле кызыгыз белмидер...

Салих *(күз яшен сыпырып куя)*. Белер инде, тиздән каникулга кайта бит ул.

Локман *(якташын тынычландырырга тырышып)*. Татулашырсыз әле. Ат шикелле эзсез югалмас хатының. Менә уннан артык фирмага мөрәҗәгать иттем акча сорап. Катлаулы авылының мәдәниятенә ярдәм итәргә кирәк дип, кайберсенә синең проблемаңны, синең вакыйгаңны, синең халәтеңне сөйләдем. Ярдәм итәрбез, диделәр, шуларның берничәсе булышса да шәп булачак бит. Борчылма, барысы да рәткә керер дип ышаныйк.

Гөлнур. Ышанып кына...

Локман *(кычкырып)*. Тик кенә тор! *(Гөлнур да, Салих та сискәнеп китәләр.)* Ышануны да югалтсаң яшәүнең мәгънәсе каламы соң?! *(Кинәт ясалма ягымлылыкка күчә, тавышында үчекләү сизелә.)* Ну, ничек, хатын, Чулпанның хәлле егете ошыймы сиңа? *(Кычкырып эндәшә.)* Чулпан, чык әле монда!

Чулпан *(күрше бүлмәдән чыга, елап шешенеп беткән)*. Нәрсә?

Локман. Акчалы, булдыклы егетең шушымы синең, кызым? *(Кызын кочаклый.)* Елама, кызым, тынычлан.

Чулпан. Ну ладно, пап, че ты издеваешься?! *(Янә күрше бүлмәгә кереп китә.)*

Локман *(көлә)*. Хәерче кирәк түгел, ха-ха-ха! Булдыксыз кирәк түгел, акчасыз кирәк түгел! Ә мондый кирәкме? *(Җирәнеп.)* Рим! Исеме исем түгел!

Гөлнур. Ярар инде, үз кызыңнан үзең көлмә.

Локман. Мин кызымнан гына түгел, иң элек синнән көләм күбрәк!

Гөлнур. Алдан ук кем белгән кемнең кем икәнлеген.

Локман. Кешенең чыраена язылган кем икәнлеге — укый белергә генә кирәк! Кешене кешедән аера белер вакыт җитте сиңа да, хатын! Иллегә таба китеп барасың бит инде кәкре-бөкре аякларың белән титак-титак атлап.

Гөлнур. Оятсыз! *(Күрше бүлмәгә кереп китә.)*

Локман. Кайгырма, Салих! Гел кара полоса гына булмый тормышта. Синең бит бер кешегә дә начарлык эшләгәнең юк. Мәктәптә укыганда да класста иң тыйнагы, иң тәртиплесе син идең бит, шулаймы. Әле беркөнне Гөлнур да шулай дип утырды. Шуңа күрә синең тормыш барыбер бер яктырып китәчәк. Син лаеклы бит якты тормышка. Ә бит тирәнрәк уйлап баксаң, иң мөһиме шул — яхшы тормышка лаеклы булу!

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Авыл. Салих өенә кайтып керә. Баян һәм зур сумка күтәргән. Җәмилә юк.

Салих *(ишек катында кымшанмыйча басып тора)*. Тынлык. *(Әйберләрен куеп өй буйлап атлый.)* Җәмилә юк. Чынлап та киткән. Анасындадыр инде. *(Баянны алып урындыкка утыра. Уйнап җибәрә. Җырлый.)*

Җәмилә кайтып керә.

Салих *(таң кала, баянны әкрен генә идәнгә куя, торып баса)*. Җәмилә?!

Җәмилә *(ишек катыннан)*. Мин. Ә син Салихмы?

Салих. Әйе, танымыйсыңмыни? *(Бер-берсенә ни әйтергә белмиләр.)*

Җәмилә. Кая югалдың син? *(Бер-берсеннән күзләрен алмыйлар.)*

Салих. Казанда идем.

Җәмилә. Чынлап та, Казанга мең яшьме?

Салих. Бардыр. Бик шау-шулы, ыгы-зыгылы шәһәр ул. Анда бер өчпочмак егерме дүрт сум тора. Шул олы яшьтәге шәһәр булганга шулай кыйммәт бит анда пәрәмәч!

Җәмилә. Ошадымы соң Казан?

Салих. Юк. Анда син булмагач, бер яме юк аның.

Җәмилә. Ошагандыр. Ошамаса, болай озак кайтмый тормас идең.

Салих. Син ничек соң монда?

Җәмилә. Элеккечә, бернинди үзгәрешем юк. Син менә үзгәргәнсең.

Салих. Кайсы төшем?

Җәмилә. Әллә тагы... Бераз городскойланып киткәнсең димме...

Салих. Юкны сөйләмә инде.

Җәмилә *(хисләре ташып чыга)*. Салих!

Салих. Җәмилә! *(Кинәт йөгереп килеп кочаклашалар.)*

Җәмилә *(елый)*. Кая югалдың син? Инде үзем сине эзләп чыгып китмәкче идем. Гөлнурларга гел хат язу да яхшы түгел, кешедән читен.

Салих. Син мине ташлап киттеңмени? *(Кочаклашкан килеш сөйләшәләр.)*

Җәмилә. Кая китим мин, инде бу яшьтә?! Юри яздым син тизрәк кайтмассыңмы дип. Инде әллә ниләр уйлап бетердем, анда берәр марҗага йортка кергәнсеңдер дип тә уйладым.

Салих. Кемгә кирәк мин, инде бу яшьтә...

Җәмилә. Алай димә. Баянда уйнаганыңны ишетсәләр, теләсә кем кертер.

Салих. Мин сине шундый сагындым!

Җәмилә. Мин дә сине сагындым! *(Салихның җилкәсен капшап.)* Бигрәк нык ябыккансың.

Салих. Әле ничек исән калдым.

Җәмилә. Тиздән Миләүшә кайта.

Салих. Син аңа хатта язмагансыңдыр минем маҗараларны?

Җәмилә. Юк, юк. Киләсе атнада сабантуй. *(Баянга ымлап.)* Баян алгансың икән.

Салих *(йөзеннән шатлык чәчеп)*. Үз баянымны таптым бит мин.

Җәмилә *(аптырап)*. Кит аннан!

Салих. Әйе. Клубтан урланган баянымны Казанда таптым.

Җәмилә. Ничек инде?

Салих. Аннары тәфсилләп сөйләрмен.

Җәмилә. Мулланур да сине юксынды. Инде мин аның белән әйбәтләп сөйләштем: ат өчен аз-азлап зарплатадан тотып калачаклар. Алай бик каты ачуланмый инде хәзер.

Салих. Түләп бетерербез әле ничек тә.

Җәмилә. Ашыйсың киләме?

Салих. Нинди ашау, Җәмилә! Шулкадәр сагындым сине. *(Кысып-кысып кочаклый.)* Бергә чакта гына аңламыйсың шул бер-береңә кирәклекне.

Җәмилә. Казан ничек анда?

Салих. Ул бөтенләй башка дөнья, Җәмилә. Казанга мең ел түгел, йөз мең ел булса да риза мин.

Җәмилә *(читкәрәк китеп, ирен башыннан аягына кадәр күзәтә)*. Яңа кәчтүм алган... Син анда Казан хатыннары белән чуалмый калмагансыңдыр.

Салих. Таптың сөйләшер сүз! Син нәрсә инде!

Җәмилә. Ярар, ярар.

Салих. Сиңа да бүләкләр алып кайттым бит мин, кызыбызга да.

Җәмилә. Акча каян алдың?

Салих. Мирза бераз бирде ат өчен. Калганын соңрак түләрмен, диде. Уйлап тордым да, әй, төкерим сәнә, дип, ул биргән акчага сезгә бүләкләр алдым. *(Сумкадан кофталар, яулыклар, хушбуйлар алып хатынына тоттыра. Башына чәшке бүрек киертеп куя.)*

Җәмилә. Сөбханалла! *(Әле кофтаны түшенә куеп карый, әле яулыкны әйләндергәли, әле хушбуйны ачып исни. Барып көзгедән карап тора.)* Бу бүрек миңамы?

Салих. Сиңа. *(Сокланып карап тора.)* Мондый затлы бүрек бик килешә икән үзеңә.

Җәмилә. Салих, мондый бүрекне куркынычтыр бит киеп йөрергә. Аны караклар салдырып алмасмы соң?

Салих. Караңгы төшкәч кимәссең, көндез генә киярсең.

Җәмилә. Ярар. *(Йөгереп килеп кочаклый.)* Ярый син бар әле дөньяда! Минем гомергә мондый матур кием кигәнем юк бит. Болай ук расхудланасың калмаган.

Салих. Ничек инде мин Казан хәтле Казанга барып бүләксез кайтыйм ди. Хатын, сабантуйга Локманнар кайтуы ихтимал авылга. Бездә кунак булырлар инде, яме.

Җәмилә. Бездә булмый, кемдә булсыннар инде.

Мулланур керә.

Мулланур. Исәнме! *(Бик җитди итеп карап тора.)*

Салих. Исән. Үзең исән-саумы?

Кул биреп күрешәләр.

Мулланур. Кайттыңмы?

Салих. Кайттым. Җәмилә, бар син чыгып тор әле.

Җәмилә чыгып китә.

Мин сиңа хәзер барысын да сөйлим. Кинодагы сыман маҗаралар килеп чыкты бит.

Мулланур *(басынкы кәеф белән)*. Сөйләп торма. Барысын да беләм.

Салих *(сагаеп)*. Нәрсә беләсең?

Мулланур. Бөтенесен дә беләм. Миңа Мирза шылтыратты. *(Гасабиланып.)* Син Мирза турында да, аның улы Рим турында да авылда беркемгә дә сөйләмә инде, хәтта хатыныңа да. Мирза минем двоюродный братым бит. Ул гомере буе зимагурлыкта йөрде. Үзе бик башлы да кеше ул, но менә һич пүтле тормыш алып бармады. Әллә нинди шуллер булды инде, бернишләтә алмыйсың. Алар монда кайткалап йөриләр. Хәтерләмисең генәдер. Малаеның да кайтканы бар.

Салих. Баянны шул урлаганмы?

Мулланур *(ык-мык килеп)*. Бәлки, шулдыр. Белмим. Син оныт инде бу турыда. Мирза да бик үтенә.

Салих. Ат өчен түләтмисеңме соң миннән?

Мулланур. Юк инде. Син гаепле түгел бит. Списать итәрбез. Безнең үзебезнең дә мал врачыбыз бар лабаса. Безнеке профессор түгел, әлбәттә, но бер атны списать итәрлек кенә башы бар. Конюх Вахит начар төш күргән әле түлке.

Салих. Нинди төш?

Мулланур. Имеш, конюшнядан ат югалган. Ат әрәм булугадыр инде.

Салих. Шул, теге атыбыз югалу кергәндер инде төшенә. Нишлисең бит. Шулай килеп чыккач. Төштә күргәннең өндә киресе була, дип тә әйтәләр...

Мулланур *(эшлекле кыяфәт белән)*. Ярар инде. Ял ит. Тиздән сабантуй. Сиңа эш күп булачак. Борчылма, тынычлан, ял ит.

Салих. Ярар, рәхмәт.

Мулланур. Үзеңә рәхмәт! *(Чыгып китә.)*

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Салихлар өе. Бәйрәм табыны әзерлиләр. Ерактан төрле татар көйләре яңгырап тора. Бәйрәм алды атмосферасы. Локманнар кайтып төшә. Локман баян күтәргән.

Локман. Мөмкинме?

Салих. Мөмкин!

Локман. Исәнмесез!

Гөлнур. Исән-саулармысез!

Чулпан. Исәнмесез!

Җәмилә. Бәрәч, Гөлнурлар килгән! Исәнмесез! Узыгыз тизрәк!

Гөлнур белән кочаклашалар. Җәмилә Чулпанны кочаклый.

Кияүгә бирерлек булган!

Чулпан. Миләүшә кайчан кайта?

Гөлнур. Иртәгә, Алла боерса.

Салих. Хуш килдегез! Үтегез түргәрәк!

Барысы да кул биреп һәм кочаклашып күрешәләр. Казаннан алып кайткан күчтәнәчләрне мәш килеп урнаштыралар.

Локман *(тантаналы тавыш белән)*. Салих туган, ун фирманың дүртесе сиңа ярдәм кулын сузды. Менә сиңа дүрт конверт, дүртесендә дә акча. Теләсә ничек тот. Бер Сәүдә йорты сиңа яңа баян бүләк итә. Ал! *(Баянны каршына куя.)*

Салих *(канатланып)*. Болай булса атка үзебез дә сразы түли алачакбыз. Ул фирмалардан акча алу дөресме соң, уңайсыз бит?

Локман. Спонсорлык шул бит инде ул. Мин гәҗит битендә мөрәҗәгать иттем, алар ярдәм иттеләр. Тәртип!

Салих *(уңайсызланып)*. Баяным бар бит инде...

Локман. Нинди кеше соң син! Рәхмәт әйт тә ал инде!

Җәмилә. Гомергә шулай кирәгеннән артык намуслы булды инде ул. Әйдәгез, табынга. Сабантуй табынына.

Гөлнур. Сабантуй иртәгәме?

Җәмилә. Иртәгә.

Локман *(кордашын иңеннән кагып)*. Иртәгә яңа баянда сыздырасың инде, Салих!

Салих. Алла боерса!

Өстәл янына утырышалар.

Җәмилә. Әйдәгез, булганын капкалый торыгыз. Минем ашым хәзер пешеп җитә. Чәй эчә тормыйсызмы?

Локман. Чәйне соңыннан эчәрбез. Ашны көтик.

Җәмилә ашны җиткерү белән мәшгуль, Гөлнур аңа булыша, Чулпан стенадагы фоторәсемнәрне карап йөри. Баян күтәреп Минәзәл керә.

Минәзәл *(тирләп беткән, еш-еш сулый)*. Нәҗмиевләр йортымы?

Салих. Әйдә, әйдә, кер, Минәзәл, безнең йорт бу.

Минәзәл. Исәнмесез!

Салих. Исәнме! Уз әйдә.

Минәзәл *(көчкә сулыш алып)*. Менә, баян алып килдем.

Салих. Нинди баян соң бу?

Минәзәл. Конфискованный. Мин Зәйнескидән бит үзем. Сабантуйга кайтып барышым. Мине машина көтеп тора. Ашыгам. Хәлләрегез ничек соң?

Салих. Рәхмәт. Әйдә инде, чәй булса да эч.

Минәзәл. Вакыт юк. Машина көтеп тора.

Салих. Кирәк түгел бу баян. Минем хәзер икәү инде.

Локман *(кырт кисеп)*. Юк, кирәк! Алып кал баянны! Рәхмәт, Минәзәл!

Минәзәл *(елмаеп)*. Әнә укыган кеше дөрес әйтә. Ярый, киттем. Сабантуй бәйрәмнәре котлы булсын!

Салих. Рәхмәт!

Минәзәл. Сау булыгыз! *(Чыгып йөгерә.)*

Җәмилә *(аш бүлә-бүлә)*. Кем бу?

Салих. Аннары сөйләрмен.

Җәмилә. Әйдәгез, ашагыз.

Гөлнур. Миләүшә кайтмаган икән.

Җәмилә. Хатында иртәгә кайтам дигән. Сабантуйның иң кызык өлешен күрми калыр инде.

Локман *(ашый-ашый)*. Яшьләр өчен иң кызыгы төнлә, кичке уенлыкта була инде аның.

Мирза керә. Бер култык астында — баян, икенчесендә — зур төргәк.

Мирза. Исәнмесез!

Салих. Исәнме!

Җәмилә. Исәнмесез!

Салих. Җәмилә, таныш бул, бу теге профессор, доктор наук, мал врачы.

Мирза. Менә, миннән сиңа баян. *(Кесәсеннән бер пачка акча бирә.)* Монысы ат өчен. Сабантуй белән тәбрикләп китердем.

Салих *(башын чайкап)*. Кирәк түгел бернәрсәң дә.

Локман *(боерулы тавыш белән)*. Кирәк! Баян да кирәк, акча да кирәк! Ал! *(Мирза кулыннан акчаны алып Салихка бирә.)* Кирәк! *(Баянны башка баяннар янына куя.)* Ә монысы нинди төргәк?

Мирза. Тозлы балык. Тәтештәге дусларым биреп җибәргәннәрие.

Локман. Анысы да Салихкамы?

Мирза. Әйе.

Локман *(төргәкне алып Салихка тоттыра)*. Мә, Салих, Тәтештә балыкны шәп тозлыйлар анда. Рәхмәт.

Салих *(югалып кала)*. Кирәк түгелие...

Локман *(әмер биргән сыман)*. Кирәк!

Мирза. Салих, мин синең Мулланур авылыннан икәнеңне белгән булсам... ни... белмәдем бит.

Локман. Ярар, ярар. Татар йөрәге скрипка түгел, Мирза, уйнама. Сабантуйлар мөбарәк булсын!

Мирза *(Локманга)*. Син теге... ни... артыгын кыланма инде... Дөнья бу. Барыбыз да Җирдә йөрибез. Бер очрашырбыз әле. Сау булыгыз! *(Чыгып китә.)*

Локман. Хуш!

Салих. Болай ярамас бит.

Гөлнур. Биргән нәрсәдән баш тарта торган заман түгел.

Җәмилә. Гөлнур белән Локман белми әйтмәсләр, алар кушканча эшлә инде син. Ашагыз, кадерле кунаклар!

Локман *(ашый-ашый)*. Синең баяннарың хәзер урлап бетерерлек түгел.

Салих. Әйтмә дә генә! Кайсысында уйнарга белгән юк!

Көлешәләр. Мулланур атылып килеп керә.

Мулланур. Җәмәгать! *(Бер мизгелгә туктап тора.)* Кунаклар бар икән... Ни... гафу итегез! Исәнмесез! Җәмәгать! Ат кайтты! Ат үзе кайтты! Бичаракаем, туган җир туган җир шул. Кайткан! Салих, ишетәсеңме, ат кайткан! Син югалткан ат кайтып ат абзары тирәсендә йөри. Утар ишеген ачкач, үзе кереп китте.

Салих *(һушсыз калып)*. Чын әйтәсеңме?!

Мулланур. Валлаһи газим!

Локман *(сөенеченнән рәхәтләнеп көлә)*. Маладис, сабантуйга кайтып җитешкән.

Гөлнур *(шаккатып)*. Әй бичара малкай, ничек юлны тапкан диген син!

Чулпан *(гаҗәпсенеп)*. Ничек адашмаган!

Салих. Ат кайткан! Ат кайткан! Алланың рәхмәте төшкере! Җаныкаем, ат кайткан! И малкай! Һәй, акыллы ат икән үзе. Ат кайткан!*(Үзен кая куярга белми, шатлыгы хәттин аша. Кунакларны, хатынын — барысын да кочаклап чыга. Күз яшьләрен сыпырып, Мулланур янына килә, аны да кочаклап ала.)* Мулланур әфәнде, уз, утыр түргә.

Мулланур. Мин утырып тормыйм инде. Эш күп. *(Салихка карап тора.)* Син миңа ачуланасыңдыр.

Салих *(ихлас күңелдән елмаеп)*. Ачуланмыйм. Син ат биреп тормаган булсаң, мондый бәйрәм булыр идемени бүген?!

Мулланур *(күзләрен акайтып)*. Ат кайтты! Үзе кайткан! *(Чыгып китә.)*

Җәмилә. Нәрсәсенә гаҗәпләнәсез?! Минем Салихым кайтканны ат кына кайтыр инде ул!

Барысы да көлешәләр.

Локман. Уйнап җибәр әле, Салих!

Гөлнур. Әйе, Салих, иртәгә сабантуй бит!

Җәмилә. Уйна, Салих, яшь чакларыбызны искә төшерик әле!

Салих баянны ала һәм уйнап җибәрә.

Нигә күңел болай талпына?!
Бу җирсүгә, ахры, юк дәва.
Әйдәп еракларга —
якты офыкларга —
Болын буйлап ялгыз ат чаба.

Бу җәйләр дә үтеп китәчәк,
Көз төсләре керер бакчага,
Әллә киләчәккә, әллә балачакка
Мине дәшеп ялгыз ат чаба.

Төштәгедәй чаба ялгыз ат,
Үтеп бара яшел үзәнне,
Җәйге болын буйлап,
язмыш белән уйнап
Әллә минем гомер узамы?!

Нигә күңел болай талпына?!
Бу җирсүгә, ахры, юк дәва.
Әйдәп еракларга —
якты офыкларга —
Болын буйлап ялгыз ат чаба.

*(Ялгыз ат)*

Тәмам.

*2001*

# БИТ

*(Ике актлы пьеса)*

КАТНАШАЛАР:

Дарья.
Артемий.
Вадим.
Роберт.
Нэлли.

Вакыйга Россиянең бер провинциаль шәһәрендә бара.

## БЕРЕНЧЕ АКТ

### I

Август ае. Шәһәр кырыендагы агач йортлар һәм бакчалар күренә. Музыка. Яшьләрнең шатлыклы авазлары, дәртле музыкадан соң кычкырып көлгән тавышлары яңгырый. Вадим, Роберт, Дарья, Нэлли, Артем киләләр. Алар Дарьяның апасы яши торган йортка якынаялар. Болдыр, алма бакчасы һәм чормага менә торган баскыч күренә. Яшьләр капка янында туктыйлар.

Роберт. Клава түти йоклыймы?

Дарья. Йоклый. Ул иртә ята.

Артем *(алма бакчасына карап)*. Сизәсезме, тирә-якка алма исе таралган?! Искиткеч! Нәкъ бала чактагы кебек!

Роберт *(көлемсерәп)*. Сизелә ки, безнең Артем олыгайды, хәтта инде балачагы кайдадыр артта калды дип хис итә.

Дарья. Әйе! Чынлап та, без балачагыбыз белән мәңгегә хушлаштык инде, ахрысы.

Нэлли. Җәмәгать, мәктәпне тәмамлаганнан соң бер ел узганга һич кенә дә ышанасы килми! Вакытның шулхәтле тиз үтүен карагыз әле!

Вадим. Әйдәгез, бүген таралышырга ашыкмыйк. Елга буена төшик. Зур иттереп учак ягыйк. Таң атканчы утырыйк. Шулаймы, Роберт?

Роберт. Бик яхшы тәкъдим! Күп итеп шампан шәрабы алырбыз. Ни дисәң дә, без бит бүген мәктәпне тәмамлавыбызның бер еллыгын билгелибез. Нэля, ничек уйлыйсың?

Нэлли. Коллектив ничек уйласа, мин дә шулай уйлармын. Даша, шампан шәрабы эчәсең киләме?

Дарья. Юк, юк, бүгенгә җитәр. Әйдәгез, башка вакытта.

Вадим. Син һәрвакыт менә шулай аркылы төшәсең инде. Артем, нишләп үзеңнең йөргән кызыңны дөрес тәрбияләмисең?

Артем. Сәгать ничә соң?

Роберт *(сәгатенә карап)*. Бу вакытта әле балаларны да йокларга яткырмыйлар.

Нэлли. Даша, йә, нишлибез?..

Дарья. Артемга иртәгә эшкә.

Вадим *(күзләрен чекерәйтеп)*. Ох, Артемы турында ничек кайгырта! Әйтерсең лә ире!

Нэлли. Безнең Артем хәзер бик кирәкле кеше. Яшь булуына карамастан, инде дефицитлы егеткә әйләнде. Сез барыгыз да институт турында, алга таба белем алу турында уйлыйсыз, ә Артем умырып акча эшли.

Артем. Телеңә салынып торма. Ватык сәгатьләрне төзәтеп кенә акча каерып булмый ул.

Роберт. Әлбәттә. Хәзер ярлы кеше генә ватык сәгатен рәтләргә бирә. Бераз акчасы булган кеше яңа сәгать сатып ала.

Нэлли. Ну нәрсә, Даша, елгага барабызмы?

Дарья. Әйдәгез, башка вакытта барыйк.

Роберт. Ярар, икенче бер вакытта, алдан сөйләшеп, әзерләнеп барырбыз.

Нэлли *(Робертка сыенып)*. Таралышабызмыни?

Вадим. Эх, сез! Тагын кайчан мондый кичләр, мондый мөмкинлекләр булыр!

Роберт *(Нэллины кочаклап)*. Ярый, дуслар, сау булып торыгыз! *(Китәләр.)*

Артем *(кичке салкыннан бераз калтыранган Дарьяны коча һәм китеп баручы парга эндәшә)*. Тыныч йокы!

Вадим. Тагын мин япа-ялгызым калдым! *(Ерагаеп баручы парга карап тора.)*

Артем *(көлә)*. Аның каравы мәшәкатең кимрәк — беркемне дә озатып йөрисең юк.

Дарья. Вадим, бар, кайт. Күзләрең үлгән судакныкы шикелле. Йокың килә бит.

Барысы да рәхәтләнеп көләләр.

Вадим. Үлгән судакныкы кебекме? *(Үпкәләүсез.)* Мыскыл ит, мыскыл ит әйдә.

Дарья. Үпкәли күрмә.

Вадим. Бернишләп булмый. Кайтып ятасы гына кала. Ярый, хуш иттек! *(Артемның кулын кыса, Дарьяга чак кына башын ия.)*

Дарья. Тыныч йокы, Вадим!

Ниндидер җыр шыңшый-шыңшый, Вадим караңгылык эчендә югала. Ерактан Роберт белән Нэллиның кычкырып көлгәннәре ишетелә. Артем белән Дарья икесе генә калалар.

Дарья *(җиңел сулап)*. Ниһаять, без икәү генә калдык! Компаниядә күңелле, ләкин һәрнәрсәнең чамасы булырга тиеш. Шулкадәр арыдым.

Артем *(кызга текәлеп карап тора, елмая)*. Даша, син искиткеч чибәр!

Дарья *(көлә)*. Әйе инде... Ходай биргән. Алай ук җентекләп карамасана!

Артем. Карап туялмыйм.

Дарья. Алайса кара инде.

Артем *(гаҗәеп ягымлылык белән)*. Дашенька!

Дарья. Ой! *(Күзләрен йома.)* Эреп китәм хәзер. Миңа беркемнең дә болай матур иттереп исемем белән эндәшкәне юк.

Артем. Чын әйтәсеңме?

Дарья *(пышылдап)*. Тавышың да бик матур синең — моңлы, тирән нииндидер...

Артем *(пышылдауга күчә)*. Мине тиздән армиягә алачаклар.

Дарья. Сине алмаслар.

Артем. Ник алай дисең?

Дарья. Син әниеңнең бердәнбер улы. Сине солдат хезмәтеннән азат итәргә тиешләр.

Артем. Миңа повестка килде инде. Хәзер бөтенесе армиягә бармау җаен эзлиләр. Хезмәт итәргә кеше җитми. Шуңа күрә әниемнең бердәнбере икәнем беркемне дә кызыксындырмаячак.

Дарья *(җитдиләнеп)*. Сиңа Роберт белән сөйләшергә кирәк. Аның әтисе ягыннан нииндидер туган тиешле бер абыйсы военкоматта майор булып эшли.

Артем *(көлә)*. Их, томана. Майор бит ул — звание.

Дарья. Мин каян аңлыйм инде ул нәрсәләрне...

Артем. Чормага менәбезме?

Дарья. Сиңа кайтып ял итәргә кирәк. Сиңа иртәгә эшкә.

Артем. Барыбер йокыга киталмый ятачакмын. Бераз утырыйк инде чарлакта.

Дарья *(җанланып)*. Скрипкада уйныйсыңмы соң?

Артем. Уйнармын. Тик мин әлегә һаман шул өч көйне генә уйный алам. Яңа көйләр өйрәнергә вакыт юк. *(Елмая)*. Скрипкаң кайда дип, әни теңкәгә тиде инде

Дарья. Ә син ни дип җавап бирәсең?

Артем. Дашада калдырдым, дим. *(Көлә.)* Ә ул ышанмый — йә югалтканмын, йә сатканмын дип уйлый.

Чормага менәләр.

Артем. Түтиең ишетми микән?

Дарья. Юк.

Артем. Ул барыбер безне ишетәдер шикелле тоела.

Дарья. Клава түти тумыштан чукрак-телсез. Ул минем иң яраткан түтием. Күрәсеңме, аның алма бакчасы нинди гүзәл! Саф күңелле кешенең генә мондый гөлбакчасы булуы мөмкин. Мин бит шушында үстем — аның канаты астында. Әле эти белән әни хәтта битәрлиләр иде — гел Клава түтиеңдә ятасың дип. Ә бит ул синең белән минем монда озак-озак утыруыбызны белә.

Артем *(гаҗәпләнеп)*. Чынлапмы? Ачуланмыймы соң?

Дарья. Юк. Клава түти мине үз кызыдай ярата. *(Чарлакның ишеген каерып ачалар да, аякларын асылындырып, төнге бакчага карап утыралар.)*

Артем. Рәхәт соң монда! *(Тирә-якка күз сала.)* Безнең шәһәребездә бу — иң шәп бакча. *(Дарьяга карап тора.)* Син янәшә чакта миңа бөтен дөнья бер әкияти алма бакчасы булып күренә!

Дарья. Алдамыйсыңмы? *(Шаян тон белән.)* Ихлас әйттеңме, классташ?

Артем *(җитди тавыш белән)*. Классташ димә миңа.

Дарья. Ник?

Артем. Роберт та сиңа классташ, Нэля да... һәм Вадим да сиңа классташ. Минем синең классташың гына булып каласым килми. Тагын шуны да әйтәсем килә... Вадим гел синең тирәдә бөтерелә.

Дарья. Алай бер дә сизгәнем, игътибар иткәнем юк.

Артем. Сизәсең, сизәсең, бөтен нәрсәне сизәсең. Игътибар да итәсең. Ул сиңа гашыйк. Һәм дә синең мәхәббәтеңне яуларга өметләнә.

Дарья. Булса ни... Мин бит сине яратам!

Артем. Ә мин сине югалтырмын дип куркам.

Дарья. И-и-и, тинтәк. Кайларга югалыйм ди мин! Син инде әллә ничәнче мәртәбә миңа Вадимның гыйшкы төшкән дисең. Ә менә Нэля тып-тын гына сине яратып йөри. Күрмиләр, аңламыйлар дип уйлый бугай. Иптәш кызым булса да, ул миннән бик каты көнләшә. Синең белән минем якын мөнәсәбәтләрне күргәч, ул бит үзен кая куярга белми. Кыскасы, ул астыртын гына сиңа гашыйк булып йөри.

Артем. Ташла. Аның Роберты бар. Ул Нэляны өзелеп ярата. Ә мин сине үлеп яратам һәм беркемгә дә алыштырмыйм.

Дарья. Бик әйбәт. Ә бүтән нәрсә турында, җыен юк-бар хакында уйланып башыңны катырма.

Артем. Син мине армиядән көтәчәксеңме?

Дарья. Сине армиягә алмаска тиешләр. Син ятим.

Артем. Мин ятим түгел!

Дарья. Ну... яртылаш ятим инде. Сөйләш Роберт белән. Военкоматтагы абыйсы син әниеңнең бердәнбер баласы икәнне билгеләп, ассызыклап куйсын. Закон буенча сине алырга тиеш түгелләр.

Артем. Шулаен шулай да... Икенче яктан караганда... Кемдер хезмәт итәргә тиеш бит. Барчасы да армиядән баш тарта башласалар, нәрсә була инде ул.

Дарья. Закон буенча булырга тиеш. Әниеңне кызганам мин. Әй, алмыйлар ла сине армиягә! *(Теманы үзгәртү нияте белән.)* Ой, карале син: бүген күктә күпме йолдыз! Карале, карале! *(Торып баса.)*

Артем. Егыла күрмә.

Дарья. Хәзер, скрипкаңны алып киләм. Мин аны сандыкка яшердем. *(Скрипканы алып килә.)* Уйна, җаныем, оялма. *(Көлә.)*

Артем *(скрипканы ала)*. Башта аны көйләргә кирәк. *(Скрипканың кылларын тарттыра.)*

Дарья. Әниең алып биргән скрипкамы бу?

Артем. Әйе. Ялынгач-ялваргач, туган көнемә алып бирде. *(Көлемсерәп.)* Мин моның настройкасы нинди булырга тиеш икәнне дә белмим бит. Һаман самоучитель алырга җай чыкмый. *(Кылларны тарттырып, смычок белән уйнап, дикъкать белән тыңлый.)*

Дарья. Настройкасын белмим дисең... Ә бит син аны барыбер ничектер көйлисең.

Артем. Мин бит аны мандолина шикелле настраивать итәм. Әнием мандолинада яхшы уйный. Бәләкәй чагымда ук мине дә өйрәткән иде. Аның мәктәптә үзенең укучыларына уйнаган бөтен көйләрне уйный беләм мин мандолинада. Менә бу скрипкада да настройканы мандолинадагы кебек көйлим. Һәм кылларга да мандолинадагы шикелле үк басам. Көлкеме?

Дарья. Юк, нишләп көлке булсын. Киресенчә, шәп! Син — акыллы һәм сәләтле кеше. Аннары, яшь булуыңа карамастан, син — гениальный сәгать төзәтүче!

Артем *(уңайсызланып)*. Җитте сиңа.

Дарья. Өстәвенә син матур җырлыйсың!

Артем. Җитте дим! Хәзер чарлактан аска сикерәм бит.

Дарья *(назлы тавыш белән)*. Тавышың да таң калырлык матур синең. Бигрәк тә миңа исемем белән эндәшкәндә.

Артем *(мәхәббәт белән)*. Даша!

Дарья. Тагын эндәш әле! *(Күзләрен йома.)* Үләм хәзер!

Артем *(кыздан күзләрен ала алмый)*. Дашенька! *(Үбешәләр.)*

Дарья *(егетне җиңел генә этә)*. Скрипканы сытасың бит. *(Каушый.)* Әйдә уйна. *(Артемның күз карашыннан үзен уңайсыз хис итә.)* Карале, ай нинди бүген!

Артем. Бүген бөтен нәрсә искиткеч. Бүген бөтен дөнья — зур бер могҗиза!

Дарья. Артем! Миңа тагын исемем белән эндәш әле!

Артем. Даша! Дашенька! *(Аның исеме бик озак кайтаваз булып кат-кат яңгырап тора.)*

Артем скрипкада уйный. Чормадан көй агыла һәм Артемның тавышы яңгырый: «Даша! Дашенька!»
Тирә-якның караңгылыгына чормадан яктылык сирпелә.

## II

Сигез ел вакыт узган. Көз. Алма бакчасы. Йорт күренә. Вадим белән Дарья, ашыга-ашыга, бакча уртасындагы өстәлдә табын әзерлиләр.

Вадим *(ачуланып)*. Нишләп килмиләр инде! Бу Роберт белән Нэля мәңге шулай — беркайчан чакырган вакытка килеп җиткәннәре юк.

Дарья. Кичә рестораннан сәгать ничәдә таралыштык соң — исеңә төшер әле.

Вадим. Булса ни. Хәзер кич бит инде. Күптән рәтләнергә вакыт. Роберт ул кичә бик аз эчте.

Дарья *(арыганлык белән)*. Моннан соң беркайчан туган көнемне ресторанда үткәрмәячәкмен.

Вадим. Ошамадымыни?

Дарья. Шау-шу, ыгы-зыгы күп.

Вадим. Әйе, анда шау-шу җитәрлек шул.

Дарья. Бәлки, барып алырсың аларны?

Вадим. Җилтерәтеп алып килми булмас. *(Дарьяга якын килеп.)* Сөеклем, сине тагын бер кат үткән туган көнең белән котлыйм. *(Дарьяны үбеп ала.)* Барып ашыктырыйм мин тегеләрне. *(Чыгып китә.)*

Дарья өстәл тирәсендә мәш килә. Болдырга таба барганда, кинәт чормадан тавыш ишетелә: «Даша!» Бу аваз кат-кат кабатлана да каядыр еракта югала. Дарья сискәнеп китә. Ул, салмак кына атлап, бакча уртасына кире килә. Аны кинәт чиксез ямансулык әсир итә. Аның колагына чорма ягыннан тагын тавыш ишетелә: «Дашенька!» Дарья курка. Авыр халәттә басып тора. Әкрен генә барып өстәл янындагы урындыкка утыра. Шул вакытта капка ачыла һәм Вадим, Нэлли, Роберт керәләр.

Роберт. Тагын бер кат туган көнең белән сине, безнең кадерле Дарья! *(Өстәлгә бер шешә коньяк һәм бер кап кәнфит куя.)*

Нэлли. Котлыйм, бәгърем! *(Дарьяны битеннән үбә.)*

Дарья. Туган көнем кичә булды бит, оныттыгыз дамыни?!

Роберт. Һәй, ресторан ресторан инде ул! Анда ничектер туган көн бәйрәме икенче планга күчә ул.

Нэлли. Бүген синең яңа яшеңнең беренче көне. Чын бәйрәме аның бүген булырга тиеш.

Вадим *(канатланып)*. Менә шуның өчен эчеп тә куйыйк! Утырыгыз, нәрсә басып торасыз! *(Рюмкаларга коньяк сала.)*

Табынга утыралар.

Роберт. Узган атнада безнең дә бер вакыйга булды — Нэля белән өйләнешкәнебезгә биш ел тулды. Бу мин сиңа әйтим, аз срок түгел. Ялгышмасам, бер айдан сезнең туй гөрләгәнгә дә ике ел тула.

Вадим. Нәкъ шулай. Ике ел да шактый вакыт. Картаябыз. *(Көлешәләр.)*

Роберт. Даша, кадерлем, тагын бер тапкыр туган көнең белән сине!

Нэлли. Иң якты теләкләребезне кабул ит!

Дарья. Рәхмәт! *(Чәкештереп эчәләр.)*

Нэлли *(бакчаны күзәтеп)*. Монда шундый рәхәт!

Вадим. Дөресен әйткәндә, үзем дә шушы бакчада гына чын-чынлап ял итә алам һәм кеше булам.

Роберт. Оҗмах инде оҗмах.

Дарья. Мин бәлеш алып киләм. *(Өйгә таба юнәлә.)*

Аңа тагын ишетелә: «Даша!» Ул шау-гөр килеп утырган компаниягә кисәк борылып карый. Ләкин тегеләр бернигә игътибар итмичә кычкырып сөйләшәләр, көлешәләр. Тагын каяндыр ишетелеп куя: «Даша!» Дарья үзалдына: «Йа Ходаем!» — дип куя. Аякларын көчкә сөйрәп өйгә кереп китә.

Вадим. Әйдәгез, бәлеш килеп җиткәнче дуслыгыбыз өчен эчеп куйыйк.

Нэлли. Юк, юк, Дашаны көтәбез.

Роберт. Әлбәттә, көтәргә кирәк.

Вадим. Ярый, мин риза. Тик менә, уйлавымча, ул анда озак маташыр.

Нэлли. Күпме маташса да түзик.

Роберт. Әйдә, берәрне тартып алыйк. *(Кесәсеннән бер пачка сигарет чыгара. Вадимга суза. Сигарет кабызалар.)*

Өйдән, бәлеш күтәреп, Дарья чыга.

Нэлли *(шатлык белән)*. Менә, безнең чибәркәебез дә чыкты!

Роберт. Алда әле бакча өчен, табигать өчен күтәрәсе тостлар бар. Әйдәгез, әлегә тагын бер мәртәбә Дарья өчен, аның чибәрлеге һәм алтын куллары өчен күтәрик!

Нэлли. Шәп!

Вадим. Әйдәгез. *(Эчәләр.)*

Дарья. Җитәр минем өчен эчәргә! Сезнең купшы сүзләрегездән башым әйләнеп китүе ихтимал. *(Бәлешне кискәли.)* Әйдәгез, ашагыз әле, ашагыз! Инде тәмәке дә кабызганнар! Башта капкалап алсагыз ни булган!

Нэлли. Аларга әйттең ни, әйтмәдең ни.

Дарья *(кашларын җыерып өстәлне күзәтә)*. Тәк... чәйгә печенье, кәнфит алып чыгасы бар икән. Тагын кайбер нәрсәләрне онытканмын әле мин.

Вадим. Үзем алып чыгыйммы?

Дарья. Тарт инде тәмәкеңне. Үзем алып чыгам. Син бүтән тартмыйм дигән идең түгелме?..

Вадим. Бүген ярый инде. Аннары ташлармын.

Дарья. Миңа Нэля булышса әйбәт була инде...

Нэлли. Әйдә, әйдә, рәхәтләнеп булышам.

Өйгә таба китәләр.

Вадим. Роберт туган, болай гына тагын берәрне каплап куйыйк әле. *(Рюмкаларга аракы сала.)*

Роберт *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Менә нәрсә... Әйдә, за упокой души тотып куйыйк... хатыннарыбыз юк чакта... Артемның рухы өчен. Урыны җәннәттә булсын.

Вадим *(канәгатьсезлек белән)*. Ә нишләп «хатыннар юк чакта»?!

Роберт. Ярар, сүзгә бәйләнмә инде. Без Артемны искә алырга тиешбез.

Вадим *(кызып)*. Кызык әйттең әле син: «хатыннар юк чакта». Минем хатыным белән аның арасында кайчандыр мәхәббәт булганына кинаяләп әйттеңме алай дип? Шуңа күрә мин Даша янында аның упокое өчен эчәргә куркырга тиешме?!

Роберт *(тавышын күтәреп)*. Кайнарланмасана! Нинди кеше соң син! Бөтенләй урынсыз кыза башлыйсың. Алайга китсә, минем хатыным да аңа гашыйк булып йөргәние. Хәзер нәрсә инде... Инде әллә кайчан булган нәрсәләр...

Вадим *(ачуланып)*. Ю-у-ук, син хатыннарыбыз монда чагында тәкъдим ит аның өчен эчәргә!

Роберт *(усал тавыш белән)*. Тилеләнмә! Ир кеше бул! Без бүгенге заман кешеләре. Артем турында сүз чыккач, без синең белән хатыннар турында уйларга тиеш түгел.

Вадим *(күзләрен чекерәйтеп)*. Ә нәрсә турында уйларга тиеш без?

Роберт *(басынкылык белән)*. Үзебезнең начар эш кылганыбыз турында уйларга тиеш без.

Вадим *(үзен кулга алып)*. Тәкъдиренә шулай язылган инде... Кемнеңдер тормыш юлы уңган була, кемнеңдер юк... Кемгәдер җай чыга. Кемгәдер юк...

Роберт. Сугышта бу төшенчәләр мондагыдан нык аерыладыр.

Вадим. Каян беләсең?

Роберт. Белмим. Шулайдыр дип уйлыйм.

Вадим. Офтанасыңмы?

Роберт. Ә син гаебеңне танымыйсыңмыни?

Вадим. Нинди гаебемне? Армиядә хезмәт итүдән котылып калгангамы?

Роберт. Синең белән минем армиядән баш тарту ул кадәр үк коточкыч гөнаһ түгелдер дә бит... Ә менә Артемны...

Вадим. Язмышыңа рәхмәт укы. Бу дөньяда кем ничек булдыра — шулай бөтерелә, кайнаша.

Роберт. Шулай шул, кызганычка каршы.

Вадим *(рюмканы күтәреп)*. Роберт, бу авыр әңгәмәне туктатыйк. Әйдә, Артемның җаны тынычлыкка ирешсен, урыны оҗмахта булсын өчен эчик тә...

Роберт *(төшенкелек белән)*. Әйдә. *(Эчәләр.)*

Өйдән Дарья һәм Нэлли чыгалар. Татлы ризыклар алып киләләр.

Вадим *(ясалма күтәренкелек белән)*. Хатыннарыбыз килә! *(Пышылдап.)* Бу теманы бүтән кузгатмыйк.

Роберт *(кырыс кына)*. Ярар. *(Хатыннарга.)* Бигрәк озак! Сездән башка шундый күңелсез!

Нэлли. Ә без анда, сездән качып, шыпырт кына тәмәке тарттык. *(Көләләр.)*

Роберт *(шаярып)*. Менә тартырмын мин сезгә! Вадим, карале син боларны, ә!

Вадим. Тәмам юлдан яздылар! *(Барысы да көләләр.)*

Роберт. Нишлисең бит — шушы заман хатыннары!

Күңел ачу дәвам итә.

## III

Роберт һәм Нэлли фатиры. Нэлли тузан суырткыч белән ковролинны чистарта. Эшеннән туктый, ишек ягына колак салып тыңлап тора. Ишек кыңгыравы зеңгелди. Нэлли тузан суырткычны сүндерә дә барып ишекне ача. Бусагада йончыган кыяфәттә Дарья пәйда була.

Дарья *(үпкәле тавыш белән)*. Звонокка басам, дөбердәтәм! Бер биш минут чамасы торганмындыр.

Нэлли *(күзләрен акайтып)*. Чынмы?! Гафу ит, зинһар! Тузан суырткычыбыз трактор сыман акырып эшли. Һич кенә дә Робертны яңа суырткыч алырга мәҗбүр италмыйм. Уз әйдә, утыр.

Дарья *(диванга утыра)*. Комачауладым, ахрысы...

Нэлли. Юк, юк, комачауламадың. Мин эшемне тәмамладым инде. *(Суырткычны почмакка алып куя. Дарьяга текәлеп карап тора.)* Син нигәдер нык каушагансың шикелле.

Дарья *(газаплы тавыш белән)*. Хәлем коточкыч минем, Нэля.

Нэлли. Вадим белән ызгыштыгыз мәллә?

Дарья. Әй, без аның белән көнаралаш талашабыз. Хикмәт аңарда түгел. Күңелем газап чигә.

Нэлли. Сәбәбе нәрсәдә икән соң? Синең битең дә ап-ак. *(Янәшә утыра.)*

Дарья *(ыңгырашып)*. Әллә нишләдем мин...

Нэлли. Бәлки, бераз коньяк йотарсың?

Дарья *(читкә карап)*. Юк, юк, күрәсем дә килми.

Нэлли *(сынаулы караш белән)*. Ә бәлки, син балага узгансыңдыр?..

Дарья. Юк ла. Тикшерендем инде. Балага узсам, бәхетле булыр идем мин.

Нэлли. Кай җирең авырта?

Дарья. Кайчан ничек... Йә йөрәк кысып ала, йә һава җитми башлый. Төрлечә... Караңгы уйлар бимазалый.

Нэлли. Нәрсәдән соң бу?!

Дарья *(пышылдап)*. Курку биләп алды мине.

Нэлли. Нәрсәдән шулкадәре котсыз калдың соң син?

Дарья. Белмим. Су бир әле.

Нэлли *(графиннан стаканга су сала, Дарьяга бирә)*. Сезнең бөтен нәрсә тәртиптә. Әйбәт кенә яшәп ятасыз. Тиздән коттеджыгыз әзер булачак. Обстановка үзгәрәчәк...

Дарья. Әйе, тизрәк күченергә инде. *(Стакандагы суны эчеп бетерә, стаканны Нэллига бирә.)*

Нэлли. Ул агач йорттан китәсең дә килми иде бугай инде синең...

Дарья *(калтыравыклы тавыш белән)*. Куркам мин. Бу йортны калдырырга да кызганыч. Әлбәттә, ул йорт барыбер безнеке булып калачак. Әти белән әни аны сатарга җыенмыйлар. Менә дигән дача! Минем балачагым шунда узды бит. Клава түти дә гүя бөтенләй вафат булмады. Чукрак-телсез булгач, исән чагында да тып-тын яшәде... Үлгәненә инде өч ел, ә менә барыбер исәндер шикелле. Шунда кайдадыр рухы яши — тыныч, игелекле һәм мәңгелек рух. Вадим белән безгә ул йорт бик уңай булды инде. Аның ата-анасы белән бергә яшәүне күз алдына китергәч эсселе-суыклы булып китәм. Кайнатам белән кайнанам минем начар кешеләр түгел, тик шулай да...

Нэлли. Әлбәттә, аерым яшәүгә җитми инде! Аерым яшәү рәхәт! Менә, түтиеңнең йорты да сезгә калу — икеләтә рәхәт һәм бәрәкәт. Коттеджыгыз да була, шундый бай бакчалы йортыгыз да — бу бит һәркемнең хыялы. Әллә шул йорт аркасында берәр күңелсез ыгы-зыгы килеп чыкты мәллә дип уйлап куйган идем... Алайса, нәрсә сине бу кадәре тетрәндерде соң?

Дарья. Нишләргә дә белмим. *(Җан газабы белән.)* Куркам!

Нэлли *(сагаеп)*. Ачыграк сөйләшә алмыйсыңмы? Син бит нидер әйтергә телисең, тик үз-үзеңне тыясың. Нәрсәнедер әйтеп бетермисең. *(Таләпчән итеп.)* Ихлас күңелдән әйт әле: нәрсә булды?

Дарья *(шактый вакыт Нэллига карап тора)*. Зинһар, беркемгә әйтмә, яме. Син бит кайвакыт телеңне тыя алмыйсың. Артык күп сөйләшеп ташлыйсың.

Нэлли *(гаҗәпләнеп)*. Даша, син мине үпкәләтмә инде!

Дарья. Үпкәләмә, Нэля. Син бит начар ният белән сөйләмисең... Бераз онытылып кына китәсең.

Нэлли *(үтә җитди кыяфәт белән)*. Ну... пүчтәк мәсьәләләр буенча, бәлки, телем озынаеп та куядыр... Ә мөһим нәрсә булса, мин сер саклый беләм.

Пауза.

Дарья *(пышылдап)*. Мин тавыш ишетәм.

Нэлли *(як-ягына каранып)*. Аңламадым.

Дарья. Миңа кемдер исемем белән эндәшә. *(Куркудан куырыла.)* Миңа тавыш ишетелгән кебек тоела.

Нэлли. Нинди тавыш?

Дарья. Аның тавышы.

Нэлли. Кемнеке?

Дарья. Алла хакы өчен, беркемгә дә сөйләмә. Робертка да әйтә күрмә. Вадимга барып җитсә, бетте баш — нык көнләшәчәк.

Нэлли *(сенсация ишетәсе килүдән җанлана)*. Беркемгә дә сөйләмим. Нәрсә инде син, бала-чага сыман!

Дарья *(кинәт тавышын көчәйтә)*. Миңа Артемның тавышы ишетелә.

Нэлли. Ничек инде?

Дарья. Менә шулай. Миңа эндәшкән кебек тоела: «Даша! Дашенька!» Җүләрләнәм бугай инде.

Нэлли. Ничек ишетәсең аның тавышын? Бәлки, төшеңдә генә ишетәсеңдер?

Дарья. Өнемдә. Чарлактан миңа эндәшә шикелле. Чакырган төсле.

Нэлли. Алай икә-ә-ән. Күптәнме?

Дарья. Нәрсә күптәнме?

Нэлли. Аның тавышын ишетәсең?

Дарья. Беренче тапкыр безнең бакчада туган көнемне бәйрәм иткән көнне ишетелде.

Нэлли. Аны еш искә төшерәсеңдер, күп уйлыйсыңдыр аның хакында.

Дарья *(бераз тынычланып)*. Алай ук димәс идем. Сигез ел вакыт узды бит инде. Әлбәттә, үткәннәрне хәтердән сөртеп ташлау мөмкин түгел. Бигрәк тә якты, рәхәт мизгелләрне.

Нэлли *(уйга калып)*. Менә бит, ә, юкка чыкты кеше. Бар иде, хәзер — юк. Кызганыч, бик кызганыч. Ичмаса белсәк иде: күмелгән микән, кабере бар микән, әллә сөякләре берәр тарафта аунап ята микән.

Дарья. Яңа ел кичәсендә, туксан дүртенче елдан туксан бишенчегә күчкәндә, Грозный шәһәрендә мәхшәр булган... Миңа соңгы хатын язганда әле ул, күрәсең, анда эләгәсен белмәгәндер.

Нэлли. Бәлки, анда һәлак булмагандыр. Бәлки, әсир төшкәндер дә шунда пленда үтергәннәрдер.

Дарья. Кайда үтерсәләр дә, барыбер түгелмени! Аерма юк. Кайда үтерсәләр дә, барыбер аның ятим җаны кайдадыр үзенә урын табалмыйча адашып йөридер. Шуңа күрә тавышы ишетеләдер дә миңа.

Нэлли. Син үзеңдә гаеп тоясың мәллә?

Дарья. Мин аны нык яраттым.

Нэлли. Әйе шул... Ул да сине бик ярата иде. Сигез ел гомер узып китте. Бәлки, кияүгә чыкканыңа битәрлисеңдер үзеңне?

Дарья. Шайтан белсен...

Нэлли. Минемчә, кирәкми. Беренчедән, син башта аны алты ел көттең. Икенчедән, син бит әллә нинди чит-ят кешегә түгел, ә үзебезнең классташыбызга, үзебезнең уртак дустыбызга чыктың.

Дарья. Шулаен шулай да... Барыбер дөрес түгел, гадел түгел...

Нэлли. Чәй эчәсең киләме?

Дарья. Юк, рәхмәт. Кайтыйм мин. *(Урыныннан кузгала.)* Үтенәм, беркемгә дә әйтмә. Вадим белсә — бетте баш. *(Нэллига текәлеп карап тора.)* Шулай да ачасым калмады сиңа серемне.

Нэлли *(ачуланып)*. Шикләнүең белән син бит мине кыерсытасың! Нишләп ышанмыйсың син миңа?! Иптәш кызыңа ышанырга кирәк.

Дарья *(ишек янына җиткәч туктый)*. Ә сиңа Артемның тавышы ишетелмиме?

Нэлли *(аптырап)*. Ә нишләп мин аның тавышын ишетергә тиеш?!

Дарья *(күзләрендә усаллык чагылып ала)*. Син дә бит аңа бик каты гашыйк идең.

Нэлли *(авызын кыйшайтып)*. Кайчан?!

Дарья *(тыныч кына)*. Ә мин шундый нык көнләшә идем!

Нэлли. Бу бит инде әллә кайчан булган хәлләр! Безгә ничәшәр яшь иде соң ул вакытта, тинтәк!

Дарья *(йомшак тавыш белән)*. Үпкәләмә миңа, Нэля. Хәлем бик начар. *(Ялварып.)* Зинһар, мине гафу ит!

Нэлли *(кызганулы тон белән)*. Син нәрсә инде, җанкай! Үз-үзеңне кулга ал, тынычлан. *(Дарья янына йөгереп килә.)* Бу бит үтеп китә торган халәт. Барысы да яхшы булачак: хәлең дә, бөтен нәрсәң дә. Барысы да тәртипкә керәчәк. *(Кочаклашалар.)*

Дарья. Рәхмәт, Нэлли!

Дарья чыгып китә. Музыка. Нэллиның кәефе кырыла, үзен кая куярга белми. Роберт кайтып керә. Култык астына папка кыстырган.

Нэлли *(Дарья белән сөйләшкән тәэсирдән арына алмый)*. Бүген иртә кайттың...

Роберт. Иртәмени?

Нэлли. Ашыйсыңмы?

Роберт. Нәрсә пешердең?

Нэлли. Борчаклы аш.

Роберт. Ашыйм.

Нэлли *(тиз генә табын әзерли)*. Даша килгәние.

Роберт *(папкасын ачып төрле документлар актара)*. Мин аның бездән чыкканын күреп калдым. Ник килгәние? *(Өстәл янына утыра.)*

Нэлли *(тәлинкәгә аш сала)*. Болай гына... Ләчтит сатарга. Хатын-кызның төп эше шул гәп куерту инде. Аларның тиздән өй туе булыр инде. *(Ире каршына утыра.)*

Роберт *(ашый-ашый)*. Да-а-а, алагаем коттедж төзеп куйды Вадим. Кирәк бит шулхәтле урларга...

Нэлли. Дустың хакында алай димә инде.

Роберт. Дус! Дуслар тигез булган сурәттә генә чып-чын дуслар була алалар.

Нэлли. Минемчә, син үзең аның белән дустанә мөнәсәбәтләрне тагы да якынайтырга, ныгытырга омтылырга тиешсең. Бәлки, акча да биргәләр.

Роберт. Әйе, бирер. Соңгы вакытта мин аңа шулкадәр күп яхшылыклар эшләдем. Ә ул һәрвакыт бер шешә коньяк белән майлый да шуның белән төгәлләп куя.

Нэлли. Бизнесменнар алар барысы да саран. Ул үзе синнән нәрсәдер өмет итеп, эстәп йөри. Син яшелчә базасы директоры булгач, ул бит сине бик хәлледер, бөтен нәрсәгә көче җитәдер дип уйлый.

Роберт. Игътибар итәсеңме соң, соңгы вакытта ничек үзгәрде ул?!

Нэлли. Бөтенебез дә үзгәрәбез. *(Уйга калып.)* Нинди күңелле компания идек бит без, хәтерлисеңме, нинди дуслар идек!

Роберт. Хәтерлим.

Нэлли. Өй туйларына нәрсә бүләк итәбез?

Роберт. Карарбыз, уйлашырбыз. *(Башын чайкый.)* Да-а-а, шундый сарай салып куйды, ә! Патша сараемыни! Ә үзе гел теләнеп йөри: йә теге кирәк аңа, йә моны бир аңа.

Нэлли. Ну, шундый кеше инде, нишләтәсең! Шуңа күрә коттеджын да төзеп куя алды. Андый кеше булмаса, бәлки, төзи алмас иде. *(Чак кына ишетелерлек итеп.)* Ә без төзиячәкбезме, юкмы?

Роберт *(кырыс караш ташлап)*. Сиңа шушы йорт җитмәгәнмени?! Кирпеч йорт, иркен... Тагын ни кирәк! Кемнәрдер артыннан чабу нигә кирәк!

Нэлли *(читкә карап)*. Кеше артыннан чабарга дип түгел инде... Бөтен кеше төзи бит... Без алардан ким-хурмыни?!

Роберт *(коры гына)*. Көнләшергә кирәкми. Вакыты җиткәч, бәлки, без дә шундый нәрсә салып куярбыз.

Нэлли *(гасабиланып)*. И Ходаем, мин беркемнән дә көнләшмим. Бигрәк тә Вадим белән Дарьядан бөтенләй көнләшерлек түгел. Алар барыбер бәхетле була алмаячаклар — коттеджларында да, әллә нинди патша сарае төзеп куйсалар да...

Роберт. Нишләп әле син кеше бәхете турында кайгырасың. Анда синең ни эшең бар. Әлбәттә, Вадим ул... Ничек йомшаграк итеп әйтергә... Кыскасы, аңарда шакшы җитәрлек... Күңелендә каралык байтак аның... Тик менә аның хатыны бик әйбәт: тыныч, сабыр, уңган. Андый хатын белән Вадимның тормышы тәртиптә булачак.

Нэлли. Син боларны миңа төрттереп сөйләп утырасыңмы?

Роберт. Нинди төрттерү?! Дашаны беләсең бит инде...

Нэлли *(кызып)*. Ә мин начар хатынмы?!

Роберт *(тыныч кына)*. Мин сине начар дидеммени?! Нәрсә син гел әйткән сүзгә ябышасың?!

Нэлли. Хәтерем калды. Бу сүзләрең белән рәнҗеттең мине.

Роберт *(күтәренке тавыш белән)*. Син искиткеч әйбәт хатын. Үзең бит коттеджлар турында сүз башладың, без кешедән ким түгел дип сайрарга тотындың. Тормыш ул, ничек яшәсәң дә — эт тормышы. Тормыш дигән булып тездән тиң шакшыга батып яшибез. Миңа калса, кешелек дөньясы — күнче һәм бирән күселәр белән тулган бер зур сасы яшелчә базасы. Менә безнең компаниядә Артем бар иде... урыны оҗмахта булсын... Аның беркемгә беркайчан начарлык эшләгәне, хәтта начарлык теләгәне дә булмады. Ә ул хәзер — юк. Бар иде кеше, тотты да юкка чыкты! Көнләшергә кирәкми. Булганына шөкер итә белергә кирәк. Бүген бар син, иртәгә — юк!

Нэлли *(ачуланып)*. Нәрсә син һаман бер үк балык башын чәйнисең: көнләшергә кирәкми, көнләшергә кирәкми! Кем көнләшә соң әле?! *(Ярсып.)* Ник мине тагын нервыландырасың?! Даша белән Вадимга көнләшерлекме соң?! Раз инде мондый сөйләшү башланды, мин сиңа дөресен әйтәм: Даша болай гына, сәбәпсез генә килмәде безгә. Ләчтит сатарга гына килгән дип алдадым мин.

Роберт *(ашаудан туктап)*. Тәк, тәк... Йә, ачып сал әле — ник килде ул безгә?

Нэлли *(паузадан соң)*. Аңарда галлюцинацияләр башланган.

Роберт *(кашларын җыерып)*. Галлюцинация?

Нэлли *(серле тавыш белән)*. Аңа Артемның тавышы ишетелә. Тик син Вадимга әйтә күрмә, яме.

Роберт. Кызы-ы-ык...

Нэлли *(пышылдап)*. Чарлактан Артемның рухы эндәшкән кебек тоела, ди.

Роберт. Сагына микәнни?

Нэлли. Шулайдыр. Мәхәббәтләре көчле иде бит.

Роберт *(кырысланып)*. Аларның мәхәббәтен күреп тә көнләшә идең син.

Нэлли *(усал тавыш белән)*. Җитте!

Роберт *(чәнчүле тавыш белән)*. Ай-яй, ошый иде сиңа Артем!

Нэлли *(иренә нәфрәт белән карап тора)*. Соңгы вакытта әллә нишләдең син. Ник минем белән болай сөйләшәсең? Ник җәберлисең мине?

Роберт *(өстәл клеенкасының бер бизәгенә текәлеп)*. Соңгы вакытта мин Артемны төштә еш күрәм. Әнисе үлгәннән соң керә башлады ул төшемә. Элек керми иде. *(Авыр сулап.)* Әнисен күмгәнгә ай ярым булды бугай инде, әйеме?

Нэлли *(кыяфәте кинәт үзгәрә, нәфрәте юкка чыга)*. Әйе. Авыр туфрагы җиңел булсын. Чыдамады ана йөрәге. Бердәнбер улы юкка чыкты бит. Без вести пропал... Сигез ел көтте... Менә... түзмәде!

Музыка. Робертның аппетиты югала. Торып, арлы-бирле йөри. Шкафтан сигарет алып кабыза.

## IV

Көз. Алма бакчасы. Агач йортның болдыры, чарлакка менә торган баскыч, читтәрәк капка күренә. Вадим кайта. Өйгә кереп чыга. Дарья өйдә юк.

Вадим *(як-ягына каранып)*. Даша! *(Бакча ягына.)* Даша! *(Аптырап тора. Аннары бакчага керә, алмагачлар арасында йөри.)*

Капка ачыла. Дарья керә — йөзендә моңсулык.

Дарья. Син дәштеңме?
Вадим. Кем булсын тагы?!
Дарья. Тыкрыкның теге башында ук ишетелде.
Вадим *(борчулы тон белән)*. Мин сине югалттым.
Дарья. Ничек инде югалттың?
Вадим *(коры гына)*. Кайда идең?
Дарья. Әниләргә бардым.
Вадим. Ничек алар анда?
Дарья. Аллага шөкер, нормально. Залда кечкенә ремонт ясарга маташалар. Булышырбыз әле, яме.
Вадим. Ярар, ярар. *(Тынгысызланганын яшерә алмый.)* Яңгыр явар, ахрысы.
Дарья *(үтенеп)*. Барыбер, әйдә, беркавым монда утырыйк әле.
Вадим *(хатынының халәтен аңлый алмый җәфалана)*. Нишләдең син? Бүген бөтенләй төссезләндең!
Дарья *(битарафлык белән)*. Арыдым.
Вадим. Туган көн алҗытты сине.
Дарья. Шулайдыр. Игътибар итмә миңа. Бераз хәл алам да ашарга берәр нәрсә әзерләрмен. *(Авырлык белән елмая.)*
Вадим *(тынычланып)*. Алайса, тавык пешер әле, яме, матурым. Мин шул арада Робертларга барып кайтам. Робертка бер эшем бар... Җилләнермен дә бер уңайдан.

Вадим чыгып китә. Дарьяны якты моңсулык биләп ала. Аңлаешсыз һәм татлы күңел сыкравы аны чынбарлыктан бераз өскәрәк күтәрә. Кинәт аңа рәхәт булып китә — ник икәнен ул һич аңламый. Куллары белән алмагач ботакларына кагыла. Моңлы елмаю аның йөзен балкыта. Үзалдына ниндидер җыр көйли. Кулларын як-якка җәя, чак кына башын артка каерып бөтерелеп ала.
Дарья. Йә Ходам! Нинди хозурлык бу бакчада! Нинди сихри һава!

Кинәт йортның чормасы ягыннан тавыш ишетелә: «Даша! Дашенька!» Дарья алмагач артына кача.

Дарья *(калтыранып)*. Ник мине җәфалыйсың, Артем! Нәрсә соң бу?! Минем бит инде онытасым килә! Минем инде онытыласым да килә! Бәлки, синең җаның, рухың мине кичерә алмыйдыр?! Гаепләме соң мин?! Йә Ходам! Нәрсә соң бу?!

Аның халәте кискен үзгәрә. Аны курку әсир итә. Бәхетле яшәешнең ярдәмсезлеге, гаҗизлеге, тиз ватылучанлыгы аны мизгел эчендә котсыз калдыра. Билгесезлек каршында аның аңы бөтенләй көтелмәгән көчләргә буйсына. Ул болдыр ягына йөгерә, бер мәлгә туктый да өйгә кереп китә. Алма бакчасына караңгылык төшә. Ялгыз скрипка тавышы яңгырый. Капка ачыла. Вадим керә — бераз исерек. Вак кына яңгыр сибәли. Яңгырга исе китмәгән Вадим бакчага уза. Бакчаның бер өлешен яктыртып торган лампаны кабыза һәм өстәл янына утыра. Тәмәке тарта.Өйдән Дарья чыга — кулына зонтик тоткан. Зонтикны ача, салмак кына атлап Вадим янына килә.

Дарья. Күптән утырасыңмы?
Вадим *(хатынына карамыйча)*. Күптән.
Дарья. Чыланасың бит.
Вадим. Кибәрмен әле.
Дарья *(иренең каршысына утыра)*. Тартмаска вәгъдә биргән идең.
Вадим. Мондый һава торышында тартмыйча булмый.
Дарья. Нәрсә хөрмәтенә эчтең?
Вадим. Болай гына.
Дарья. Роберт беләнме?
Вадим. Әйе.
Дарья. Тавык әзер. Шулпасы искиткеч тәмле килеп чыкты. Сигаретыңны тартып бетер дә, кереп ашыйбыз.
Вадим *(хатынына сынаулы караш белән карап тора)*. Кәефең ничек соң?
Дарья *(авыз чите белән генә елмаеп)*. Ярыйсы.
Вадим *(таләпчән тавыш белән)*. Бәлки, ата-анаң берәр канәгатьсезлек белдергәндер? Бәлки, алар минем хакта берәр нәрсә әйткәннәрдер?
Дарья *(тынычландырырга тырышып)*. Юкны сөйләмә инде! Сине яратканнарын, хөрмәт иткәннәрен беләсең бит.
Вадим *(мыгырдап)*. Ну да.
Дарья. Күпме эчтегез?

Вадим сорауга җавап бирми, һәм авыр тынлык урнаша.

Вадим *(каты тавыш белән)*. Мин беләм — син Артемны оныта алмыйсың.
Дарья *(сискәнеп)*. Син нәрсә?!
Вадим. Шулай түгелмени?
Дарья. Ник алай дисең әле син?
Вадим. Мин бит сизә-ә-ә-әм.
Дарья. Вадим, без синең белән ир һәм хатын. Мине яратсаң, бүтән мондый әңгәмә кузгатма, аңладыңмы?!
Вадим *(гаепләү тоны белән)*. Ничек инде кузгатмаска! Син үзеңнең халәтеңне, күңелеңдәге хисләрне чит кешеләргә ачасың, ә иреңнән яшерәсең.
Дарья. Кемгә нәрсә ачкан әле мин?
Вадим. Әллә нинди тавышлар ишетүеңне, әллә нәрсәләр тоюыңны. *(Дарьяга текәлеп карап тора.)*
Дарья *(читкә карап)*. Әйе, миңа тавышлар ишетелгән кебек тоела. Мин куркам.
Вадим *(таләпчән итеп)*. Ә конкретно әйтмәссеңме: кемнең тавышы яңгырый синең колагыңда?
Дарья *(күз яшьләре белән)*. Зинһар, гафу ит мине, Вадим! Сине көнләштерәсем килмәгән иде. *(Читкә карап.)* Нэля телен тыя алмый инде!
Вадим. Миңа Роберт әйтте.
Дарья *(үзен көчкә кулга алып)*. Ну Нэля! Тел бистәсе! Робертын да... әйтер идем!
Вадим *(авыр әңгәмәне бигүк тирәнгә кертәсе килми)*. Тизрәк коттеджга күчәргә кирәк — безнең өчен иң яхшысы шул булыр.
Дарья. Анда бит әле яшәрлек түгел.
Вадим. Шушы арада инде анда яшәргә мөмкин булачак.
Дарья. Ай-һай. Анда әле буяу исе тиз генә бетмәячәк.
Вадим. Буяу исеннән куркырга... Балага узмагансыңдыр ла... Балага узу дигәннән... Кайчан дәвалана башлыйбыз инде?
Дарья *(паузадан соң)*. Дәваланырга теләгем юк.
Вадим. Озакка сузарга ярамый. Хәзер үк тотынырга кирәк. Аннары соң булуы ихтимал.
Дарья. Кысырлыктан дәвалану мөмкинмени?
Вадим. Нинди томана кеше соң син?! Әлбәттә, мөмкин! *(Тынычлана.)*
Дарья. Алайса, нишләп Нэля белән Роберт дәваланмыйлар?
Вадим. Анда безнең эшебез юк. Кем белгән, бәлки, шыпырт кына дәваланалардыр. *(Тавышын әкренәйтеп.)* Син әле белмисеңдер... Аларның балалары юклыкта Роберт гаепле.
Дарья *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Каян беләсең?
Вадим. Сизәм. Ирләрнең дә кайберләре бесплодный була бит.
Дарья. Анысын беләм. Үзе гаепле икәнне үзе әйтте мәллә? *(Көлемсерәп)*. Бөтен нәрсәне күрәсең, бөтенесен аңлыйсың...
Вадим. Дөресен әйт әле, әтиең белән әниең кәефеңне кырдылармы?
Дарья. Юк, алай түгел. Ярар, дөресен әйтәм. Мин чиркәүдә булдым. Ә әти-әни янына юл уңаеннан гына кереп чыктым.
Вадим *(гаҗәпләнеп)*. Чиркәүгә?!
Дарья. Әйе. *(Башын читкә борып.)* Ходайдан бала бирүен сорадым. Җан тынычлыгын да үтендем.
Вадим. Җанны тынгысызландырырга бернинди сәбәп юк. Ә бала табар өчен дәвалану зарур. *(Ялынып.)* Үтенәм синнән, зинһар, миннән бер нәрсә дә яшермә. Мин бит синең ирең! Мин сине үлеп яратам! Безнең мөнәсәбәтләр ихлас булырга тиеш. Башкача ярамый. Минем таныш психотерапевтым бар — бик яхшы доктор. Аңа барып кайтырбыз. Аннары инде гинекология... буенча тотынырбыз...
Дарья *(уйчанланып)*. Мин чиркәүгә йөриячәкмен.
Вадим. Зинһар, киреләнмә инде, яме! Чиркәү беркая да югалмас.
Дарья *(өстәлне әйләнеп чыга, Вадимга килеп елыша)*. Минем бу халәтем үтеп китәчәк. Ачуланма мине, Вадим. Син бит мине яратасың. Шуңа күрә ачуланма.
Вадим. Ярар, ачуланмам. *(Дарьяны битеннән үбә.)* Әйдә, ашыйсы килә.
Дарья. Әйдә.

Өйгә кереп китәләр. Бакчада төн урнаша.

## V

Шул ук бакча. Өйдән Дарья чыга. Болдыр янындагы чиләкне алып бакчага таба бара. Тавыш ишетә: «Даша!» Дарья туктый. «Дашенька!» Кинәт өстә чорма ишеге каерылып ачыла. Дарья сискәнеп шул якка карый. Беркем юк. Ләкин чорма ишеге ачык. Шул тарафтан тагын ишетелә: «Дашенька!»

Дарья. Кем бар анда? Беркем дә юк бит инде югыйсә. Нинди тавыш соң бу?

Чормадан тавыш ишетелә. Бу мин, Дашенька!

Дарья *(кулыннан чиләген төшереп җибәрә, аркасы белән коймага сеңә)*. Кем?

Чормадагы тавыш. Тавышымны танымадыңмы?

Дарья. Тавышыңны танымадым.

Чормадагы тавыш. Курыкма. Мин — Артем.

Дарья. Артем булгач, ник качасың?

Чормадагы тавыш. Минем битем шөкәтсез. Синең котсыз калуың ихтимал.

Дарья. Күренмәгәч син миңа куркынычрак.

Чормадагы тавыш. Ярар, алайса мин төшәм.

Дарья. Йә Ходам!

Чорма ишегендә коточкыч гарип йөзле кеше күренә. Бу кешедә элеккеге Артемны һич кенә дә тану мөмкин түгел. Ул әкрен генә баскыч буйлап төшә. Төшкәч, Дарьяга таба атларга базмый тора.

Артем. Исәнме, Даша!

Дарья *(тораташ булып ката)*. Исәнме! Син Артеммыни?

Артем. Әйе. Мине хәзер йөземнән танып булмый шул.

Дарья *(калтыранып)*. Нәрсә булды соң сиңа?

Артем. Бронетранспортерда яндык. Менә... мин ничектер... исән калдым.

Дарья. Синме соң бу?

Артем. Мин, Дашенька, мин!

Дарья. Тавыш синеке. Тик... Бәлки, син аның рухы гынадыр? Бәлки, син өрәктер?!

Артем. Юк, Дашенька, мин өрәк түгел. Чормада минем пакетым бар. Анда минем кайбер документлар... Хәзер... Мин сиңа күрсәтәм... *(Җәһәт кенә баскычтан кире чормага менеп китә.)*

Дарья ерактан якынлашып килүче Вадим машинасын абайлап ала. Артем, кулына пакет тотып, чормадан төшмәкче була.

Дарья *(әле һаман һушына килә алмый)*. Зинһар, берүк төшә күрмә! Вадим кайтып килә.

Артем. Ник, кайтса ни!

Дарья *(шашынып)*. Төшмә! Шунда кал! Ул бит әллә ниләр уйлаячак!

Артем. Ярар алайса. *(Чорма эченә кереп югала.)*

Дарья шок халәтендә. Үзен кая куярга белми. Аунап яткан чиләкне ала, тик кая барырга белми. Вадим килеп керә.

Дарья *(тәмам югалып кала)*. Син... кайттыңмыни?..

Вадим. Кайтканымны күреп торасың бит! *(Гасабиланып.)* Нәрсә инде тагын агарып каттың! Тагын тавышлар ишетелә мәллә? Соң, юк бит беркем дә! Бернинди тавышлар да юк! Синең колагыңа гына ишетелә! Ышан миңа! Сиңа теләсә кайсы психиатр нәкъ шулай дип әйтәчәк. Беләсеңме нәрсә... Давай, мин бүген чормага менеп йоклыйм. Бүген чормада кунам һәм шуннан соң сиңа бернинди тавыш ишетелми башлаячак.

Дарья *(кычкырып)*. Кирәкми! Моның кирәге юк!

Вадим. Мин хәзер үк чормага менәм һәм син аннан серле тавышлар ишетми башлагач кына төшәм.

Дарья *(ялварып)*. Юк! Менмә чормага!

Вадим. Ник куркасың соң син?! Нәрсәдән, кемнән куркасың?! *(Баскычка таба бара.)*

Капкадан Роберт керә һәм күзәтеп тора.

Дарья *(ярсып)*. Алла хакы өчен, менмә анда!

Вадим *(тонык тавыш белән)*. Мин анда төн чыкмакчы булам, синең галлюцинацияләреңә чик куяр өчен. Мин анда кунам бүген, синең саташып йөрүең сәбәпсез икәнне исбатлар өчен. Мин бүген чормага менеп йоклыйм — анда беркемнең дә юклыгына, бернинди тавышларның яңгырамавына сине ышандырыр өчен. Тынычландырасым килә сине!

Дарья *(көчкә үзен кулга алып)*. Минем хәлем рәтләнде. Бүген инде мин тынычландым. Бүген инде мин бернинди тавышлар ишетмим.

Роберт *(кычкырып)* Хәерле көн!

Вадим *(Робертны күреп ала)*. Сәлам, Роберт! Нишләп капка төбендә торасың?

Роберт. Мин сезгә комачауладым, ахрысы? *(Килә.)*

Вадим. Юк, юк, кер әйдә. Чормага менмәкче идем. Тиздән күченәбез бит инде. Анда, өстә безнең вак-төяк, чүпрәк-чапрак күп. Араларга кирәк: кайсын ташларга, кирәген каккалап, чистартып куярга. Даша әйтә: җитешербез әле, ди, бүген пычранып маташмыйк, ди. *(Чорма баскычы яныннан Робертка таба атлый.)*

Роберт *(көлемсерәп)*. Аңлашылды. Кәефең ничегрәк, Даша?

Дарья *(эчке киеренкелек белән автомат кебек җавап бирә)*. Кәефем яхшы. *(Үзе дә сизмәстән.)* Нэля нишли?

Роберт. Әниләренә китте. Әтисе чирли.

Дарья *(әңгәмәнең мәгънәсенә бөтенләй төшенмичә генә сөйләшә)*. Әтисенә нәрсә булган?

Роберт. Ул бөерләре белән интегә бит инде. Ташларын алдырасы бар, диләр. Ә ул операциядән баш тарта. Ә үзе әнә интегеп ята. *(Вадимга.)* Карале, минем сиңа эшем бар иде.

Вадим. Тыңлыйм.

Роберт. Иртәгә беркая да китмисеңме?

Вадим. Ә нәрсә?

Роберт. Иртәгә минем янга бер фирмадан килергә тиешләр. Бик кызыклы тәкъдимнәре бар. Килешү төзегәндә, син янымда булсаң иде. Ул эшнең төрле нечкәлекләре байтак, шуңа күрә синнән башка ерып чыгалмам дип куркам.

Вадим. Иртәгә без Даша белән соң гына кайтачакбыз. Берсекөнгә күчереп булмыймы соң ул очрашуны?

Роберт. Берсекөнгә син монда буласыңмы соң?

Вадим. Монда булам — һичшиксез.

Роберт. Алайса, мин аларга берсекөнгә килергә кушып шылтыратам.

Вадим. Шулай ит. Сөйләштек.

Ирләр сөйләшкәндә, Дарья китми, шул ук вакытта үзен кая куярга һәм ничек тотарга белми. Вадим чормага менмәгәе дип котсыз калып тора. Роберт Дарьяның сәерлеген абайлап ала һәм сагая.

Роберт *(авыз чите белән генә елмаеп)*. Нэляга синнән сәлам әйтимме?

Дарья *(сискәнеп)*. Ни дисең?

Роберт. Нэляга синнән сәлам тапшырыйммы дим?

Дарья *(җанланып)*. Әйе, әлбәттә, сәлам әйт аңа... миннән.

Роберт *(Дарьяның йөзенә текәлеп карый)*. Ну, ярый, сау булып торыгыз! Киттем мин.

Дарья *(елмаерга тырышып)* Сау бул!

Роберт чорма ягына күз сала һәм сагаюлы уйчанлык белән чыгып китә.

Вадим *(хатынының кәефен күтәрергә ниятләп елмая)*. Әйдә, каты иттереп чәй эчик әле.

Дарья *(чак кына елмая)*. Өйдәме, бакчадамы?

Вадим. Өйдә.

Өйгә кереп китәләр. Музыка. Караңгылык иңә.

## VI

Шул ук күренеш. Роберт пәйда була. Өйалдына таба килә. Ишек бикле — зур йозак эленеп тора. Чорма баскычына таба атлый. Як-ягына карана. Куеныннан ау пычагы чыгара. Баскычтан әкрен генә чормага күтәрелә. Саклык белән генә чорма ишеген ача. Чорма эчендә юк була. Шул вакытны бакчадан кемдер атылып чыга, һәм чорма баскычын ала да читкә илтеп ташлый. Баскычны ташлагач, ул алмагачлар арасына кереп кача. Чорма ишеге авызында Роберт күренә. Баскычның юклыгын күргәч, ул нык каушый. Хәзер инде чормадан ул берничек тә төшә алмый.

Роберт. Һәй, кем бар анда? *(Пауза.)* Баскычны урынына куегыз! Мин дошман түгел, мин бернинди начарлык теләмәгән идем...

Агачлар арасыннан коточкыч ямьсез чырайлы кеше чыга.

Гарип кеше. Исәнме, Роберт!

Роберт *(куркып)*. Син... кем?

Гарип кеше *(якынрак килә)*. Мин — Артем. Тик минем чыраем сиңа таныш тоелмас дип уйлыйм.

Роберт *(чирканып, ышанмыйча котсыз калып)*. Артем?!

Артем. Нәкъ үзе!

Роберт. Ничек болай!.. Мөмкин түгел...

Артем. Бу дөньяда теләсә нәрсәнең булуы мөмкин.

Роберт. Ә мин Роберт. Синең классташың... дустың... Хәтерлисеңме?

Артем. Хәтерлим. Мин сине танымый тордым. Симергәнсең.

Роберт. Бераз тазару бар инде... Син үзең генәме?

Артем. Әйе. Мин чынлап та берүзем генә. Бөтен дөньяда берүзем, япа-ялгызым.

Роберт *(Артемның гарипләнеп, бозылып беткән йөзендә бер генә булса да таныш сызык табарга тырышып карый)*. Синме соң бу?!

Артем. Бу сорауны мин үз-үземә кат-кат биргәнем бар: минме соң бу? Чынлап та — мин икән. Мин бу, мин, һич кенә дә башка кеше түгел. Һәм дә бу чынбарлыктан берничек котылу, китү мөмкин түгел. Бу — «мин» булганга түгел китә алмау, ә менә шул «мин» булганга күрә китмим.

Роберт *(шок халәтеннән чыга алмый)*. Ничек болай килеп чыкты соң?..

Артем *(тавышында сәер шатлык яңгырый)*. Әйдә, күрешик инде. Күрешмәгәнгә шактый вакыт узды бит. Сикер!

Роберт. Син нәрсә, моннан сикереп булмый. Аягымны сындырам бит.

Артем. Биекме?

Роберт. Баскычны куй.

Артем *(баскычны барып ала)*. Баскычны алмаган булыр идем дә... Кулыңда пычак күрдем...

Роберт. Мин бит син икәнне белмәдем. Әллә кем бит монда...

Артем *(баскычны урынына куя, Роберт курка-курка гына төшә башлый)*. Ай-яй симергәнсең! Карале, баскыч ничек бөгелә!

Роберт төшкәч, алар биш-алты адым арадан бер-берсенә карап торалар. Роберт әле һаман бу шөкәтсез битле кешенең Артем икәнлегенә ышанмый.

Роберт *(гарип чырайга карарга теләмәсә дә, карарга мәҗбүр булып)*. Син кем?

Артем *(ихлас күңелдән, ягымлы тавыш белән)*. Тагын бер тапкыр исәнме, классташ! Мин — Артем.

Роберт *(урыныннан кузгалырга куркып)*. Но... син... Синең йөзең... Ничектер, ышанып булмый...

Артем. Кемгә ышанмыйсың? Нәрсәгә ышанмыйсың? Минем Артем икәнемә ышанмыйсыңмы? Мин исбатлый алам. Мин безнең балачагыбыз, мәктәп елларыбыз турында, безнең бергә йөргән чакларыбыз турында бәйнә-бәйнә, тәфсилләп сөйли алам. *(Пауза.)* Син миннән куркасың.

Роберт *(газаплы елмаю белән)*. Юк инде, син нәрсә. *(Үзен кулга алып, якынрак килә.)*

Артем. Менә монда минем документларым... төрле справкалар... *(Курткасының эчке кесәсеннән документлар алып Робертка суза.)*

Роберт документларны алып игътибарсыз гына карый, чөнки Артемны гел күзәтеп тора. Документларны Артемга кире бирә.

Роберт. Артем! Ышанасы килми... Син аңларга тиеш... Без инде уйлаган идек... Син исәнмени?

Артем. Исән.

Роберт. Моңарчы кайда булдың соң син?

Артем. Пленда.

Роберт. Карале, ә... Менә нәрсә... Монда әллә ничек... Кеше бакчасында... Монда басып торам... Ә син кайчан кайттың соң?

Артем. Күптән түгел.

Роберт. Алай икән.

Артем. Әйдә инде, ниһаять, кул биреп күрешик. Мин бит сагындым барыгызны да.

Роберт. Исәнме, Артем! *(Артемның кулын кыса. Куркуын яшерә алмый — бөтен кыяфәтендә чагыла.)*

Артем. Исәнме, Роберт! Сине күрүемә шат.

Роберт. Мин дә шулай ук. *(Артемның битенә карап аның эчке халәтен аңларга тырыша. Ләкин Артемның чырае шулхәтле бозык һәм гарип ки, аңа карап бернәрсә аңлау мөмкин түгел.)*

Артем. Минем битем коточкыч. Тик шулай да никтер төрле маскалар, күзлекләр киясем килми...

Роберт *(ялагайланып)*. Иң мөһиме — син исән!

Артем. Исән булу иң мөһиме дип саныйсыңмы?

Роберт. Әлбәттә. Әниең генә...

Артем. Әйе шул. Йортыбызны да сүткәннәр икән. Безнең йорт урынында ниндидер затлы сарай төзеп куйганнар.

Роберт. Анда главаның урынбасары яши. Менә нәрсә... Төнлә безгә кил.

Артем. Ә нишләп төнлә?

Роберт *(иңнәрен сикертеп)*. Ну... Ну әйдә, хәзер үк киттек.

Артем. Юк, мин беркая да бармыйм. Мин монда калам. Син минем турыда беркемгә дә әйтмә, яме.

Роберт *(пышылдап диярлек)*. Беркемгә дә әйтмәм.

Роберт китә. Музыка. Артем чорма баскычына таба атлый. Караңгылык иңә.

**VII**

Шул ук күренеш. Вадим белән Дарья кайтып керәләр.

Дарья *(өйалды янына җиткәч ирен җиңеннән тотып туктата)*. Туктале, Вадим. Сөйләшәсе бар. Тыныч кына тыңла мине... Тик барысын да дөрес аңла һәм үзеңне кулда тот. Монда могҗиза булды.

Вадим. Нинди?
Дарья *(тонык тавыш белән)*. Артем исән.
Вадим. Ничек инде?!
Дарья *(тавышын күтәреп)*. Исән ул!
Вадим *(кырыс кыяфәт белән)*. Каян беләсең?
Дарья *(калтыранып)*. Мин аны күрдем... Син, зинһар, тыныч бул... Курыкма...
Вадим *(көчле тавыш белән)*. Кемнән яки нәрсәдән куркырга тиеш мин?!
Дарья. Син Артем исән булганга шат түгелмени?
Вадим. Кайда соң ул?
Дарья *(йөзенә газап саркый)*. Ул... анда... өстә. Ул күренергә базмый. Ул шундый фаҗигагә тарыган!
Вадим. Кайда ул?
Дарья. Чормада.
Вадим *(ачуланып)*. Тагын саташасың!
Дарья *(кычкырып.)* Артем! Күрен әле, зинһар!
Вадим. Тәмам җүләрләндең мәллә?
Дарья. Бар, чормага күтәрел, үзең күрерсең.
Вадим. Менә сиңа, мә! *(Чорма баскычы янына килә.)*
Дарья. Котсыз калма, әзер бул. Аның бите янган.
Вадим. Кемнең?
Дарья. Артемның.
Вадим. Нишләп анда соң ул?
Дарья. Кунарга урыны юктыр.
Вадим. Нинди хәл бу, ә! *(Баскыч буйлап чормага менә.)*
Дарья *(киеренкелек белән)*. Син аны танымаячаксың. Ләкин ул барыбер — Артем! *(Кычкыра.)* Артем!
Вадим *(баскычтан)*. Кем булсын анда! Ышанмыйм мин сиңа.

Вадим чорма эчендә юк була. Дарья котсыз калып көтеп тора. Вадим шактый вакыт күренми тора. Ниһаять, чорма ишегендә пәйда була.

Вадим *(баскычтан төшә)*. Син чын-чынлап тилергәнсең, ахрысы. Анда беркем дә юк. Аннан бернинди тавышлар да ишетелми. Врач билгеләгән даруларның барысын да эчәсең — минем күз алдында. Йоклар алдыннан йоклаткыч дару кабул итәрсең.
Дарья *(апатия белән)*. Мин бит аны күрдем.
Вадим. Синең бу халәтең мине туйдыра башлады.
Дарья *(күзләрен йома)*. Нәрсә соң бу?!

Музыка. Пәрдә ябыла.

## ИКЕНЧЕ АКТ

### I

Роберт белән Нэлли фатиры.

Нэлли *(сагышлы тавыш белән)*. Ә бәлки, ул түгелдер, башка кешедер?
Роберт *(пошаманлы кыяфәт белән)*. Чырае шөкәтсез... ужаслар фильмындагы кебек. Бите аныкы түгел... ә документлары — аныкы.
Нэлли *(уйланып тора)*. Артемның документларын башка кеше дә табып алырга мөмкин.
Роберт. Ә ни мәгънә?
Нэлли. Кем белгән!..

Ишек кыңгыравы зеңгелди. Икесе дә сискәнеп китәләр.

Роберт. Ник куркабыз соң без? *(Ишеккә таба бара.)*
Нэлли *(куркып)*. Ул микәнни?
Роберт *(ишекне ачарга батырчылык итми тора)*. Ул түгелдер. Монда килмәс ул. Мин аны чакырган идем, килмим, диде.
Нэлли. Кем икән соң бу?
Роберт. Вадимдыр. Мин аңа шылтыратып сөйләгән идем.

Роберт ишекне ача һәм артка чигенә. Бусагада Артем пәйда була. Аның гариплэнеп, ямьсезләнеп беткән кыяфәте Нэллины котсыз калдыра.

Артем. Хәерле кич!

Нэлли *(күзләрен акайтып)*. Ой, әнекәем!

Артем. Көтмәгән идегезме?

Роберт *(ярарга тырышкан елмаю белән)*. Көттек, көттек. Мин бит сине үзем чакырдым. Әйдә, түргә уз.

Артем әкрен генә бүлмә уртасына уза.

Артем. Исәнме, Нэля!

Нэлли. Исәнмесез! *(Артемның йөзен якыннан күреп, агарып ката, калтырана.)*

Артем *(Нэллига карап тора)*. Бик нык үзгәргәнсең. *(Көлемсери.)* Үзгәргәнсең дигән булам тагы... Ә үзем... Мин бит үзем башкаларга караганда иң нык үзгәргән кеше. Ә менә прическаң синең шәп, Нэля! Таң калырлык!

Роберт *(каушавын көчкә җиңеп)*. Ул бит үзе парикмахер булып эшли... Син утыр... кая утырасың килә... Менә диванга утырсаң җайлырак булыр.

Артем *(диванга утыра.)* Өегез матур.

Роберт. Кая матур булсын инде... Күптән ремонт ясаган юк...

Артем. Менә, Нэлли, кайттым мин. Шушындый кыяфәттә.

Нэлли *(хәсрәтле тавыш белән)*. Исән булуың әйбәт. Ничек кенә булмасын...

Артем. Шулай дип уйлыйсыңмы?

Нэлли. Әлбәттә.

Артем *(кырыс тон белән)*. Нэля, чәй куеп җибәр.

Нэлли. Хәзер.

Роберт *(Артемга)*. Ашыйсың киләме?

Артем. Юк. Ә менә чәйне эчәм. Чәй яратам мин.

Нэлли ашыга-ашыга чәй әзерли.

Роберт *(бүлмә почмагындагы креслога барып утыра)*. Ничек болай килеп чыкты соң? Нәрсә булды?

Артем. Бронетранспортерда яндык. 1995 елның 1 январенда. Бөтенесе янып бетте. Мин генә исән калдым. Аңыма килдем — чеченнарда пленда икәнмен. Грозныйдан таулар арасына алып киттеләр.

Роберт. Без инде ни уйларга да белмәдек. Һәрберебезгә синең соңгы хатларың бер тирәдә килеп җитте дисәң дә була — ноябрь азагында. Аннары инде... «без вести пропал» дигән хәбәр килде.

Артем *(паузадан соң)*. Йә, ничек яшәп ятасыз? *(Нэллиның табын әзерләвен күзәтә.)*

Роберт *(бераз уңайсызланып)*. Яшибез инде шунда.

Нэлли. Чәй әзер. Өстәл янына утырыгыз.

Артем өстәл янына утыра. Роберт та, Нэлли да аның каршысына утырырга җөрьәт итмиләр. Роберт өстәлнең бер башына, ә Нэлли икенче башына утыралар. Чәй эчәләр.

Роберт *(исенә төшереп)*. Әйдәгез, очрашу хөрмәтенә затлы аракы эчик!

Артем. Мин эчмим.

Роберт. Алайса, мин дә эчмим.

Чәй эчәләр. Пауза.

Артем. Балаларыгыз бармы?

Роберт *(кырт кисеп җавап бирә)*. Әлегә юк.

Нэлли. Даша белән Вадимның да балалары юк. *(Үзен гаепле сизгәндәй.)* Бигрәк сәер — аларның да юк балалары, безнең дә юк.

Роберт *(шелтәле караш белән)*. Нэля, Артемга тагын чәй яса.

Артем. Шәһәребез бик нык үзгәргән.

Роберт. Вакыт уза. Бөтен нәрсә үзгәрә. Тормыш үзгәрә.

Артем. Үзгәрсә дә матур безнең шәһәр. Бигрәк тә хәзер — алтын көздә әйтеп бетергесез гүзәл безнең шәһәребез. Тирә-якта көз хөкем сөрә. Бөтен тыкрыкларга, почмакларга хуш исле көз кереп тулган. Елның иң изге вакыты — көз. Гөнаһлы язлардан өстен һәм бөегрәк фасыл — алтын көз! Мин көзләргә мәңгегә гашыйк! Хәтерлисезме елга буйларында төннәр уздырганыбызны? Соңгы тапкыр без нәкъ менә шушы вакытта — алтын көздә — елгага барган идек.

Нэлли *(уйга калып)*. Әйе, мин хәтерлим.

Артем. Син, Роберт, анда Вадим белән чак кына сугышмый калдың.

Роберт *(елмаеп)*. Исерек булганбыздыр инде.

Артем. Соң, аек түгел идек инде. Сезне аера-аера хәлләрем бетте... Күлмәгем ертылды.

Роберт *(ностальгия белән)*. Әйе, бар иде якты, бәхетле көннәр. *(Паузадан соң.)* Киләчәккә нинди планнарың бар?

Артем. Нинди планнар булсын әле монда. Барсы да миннән читкә тайпылалар.

Нэлли. Ничек котылдың?

Артем. Нәрсәдән?

Нэлли. Әсирлектән ничек ычкына алдың?

Артем. Әхмәт, хуҗам, мине җибәрде. Әхмәткә мин ничек килеп эләктем... *(Тирән сулап куя.)* Без, әсирләр, унбиш кеше идек. Таулар арасындагы ерак бер авылга алып килделәр. Хәллерәкләрне сайлап алып, төрле хуҗаларга өләштеләр. Мине атып үтермәкчеләр иде. Бер чечен кешесе килеп миннән, нинди һөнәрләрең бар, дип сорады. Мин әйттем: сәгатьләр, телевизорлар, башка нәрсәләр төзәтә алам, дидем. Ул барып полевой командирдан мине аңа бирүләрен сорады. Командир ризалашты. Шулай итеп, Әхмәт исемле хуҗам барлыкка килде. Әхмәтнең бер улы Грозный янында һәлак булган. Инде соңыннан, шактый вакыт үткәч, мин аннан сорадым: нигә мине, мондый янган битле, шөкәтсез кешене, үзеңә алдың, дидем. Ул миңа: мондый бозык, акайган күзле чырай белән беркая качу мөмкин түгел, диде.

Роберт. Ничек җибәрәсе итте соң ул сине? Улын да үтергәннәр икән...

Артем. Улы өчен мине ул бер тапкыр да кыерсытмады. Кече улы Әкрәм генә үтеп барышлый гел таяк белән суга иде — бу аның үзенчә абыйсы өчен үч алуы иде. Мине үтерергә хыяллана иде. Аңа алты яшь иде ул вакытта. Хәзер үсте инде. Ундүрт яшь аңа. Әкрәмнән ике яшькә олырак Әминә исемле кызлары башта мине нык дошман итте. Аңа инде уналты хәзер. Вакыт үткән саен, аларның миңа карата мөгамәләсе үзгәрде, тора-бара гаиләләренең бер әгъзасына әвереләдем. Бөтен авылга сәгатьләр, телевизорлар, башка техниканы ремонтлау белән шөгыльләндем.

Нэлли. Ничек җибәрәсе иттеләр соң?

Артем. Мин төш күрдем. Әнием яланаяк, ап-ак киемнән, яңа гына ерылган кап-кара буразнадан атлый. Артына да борылып карамыйча, әнием шул буразна буйлап офыкка таба китте. Һәм юкка чыкты. Мин аңладым: әнием вафат булган. Төшемне Әхмәткә сөйләдем. Ул да әйтте: «Мондый төш — үлем-китемгә,— диде.— Анаң өчен мин сине җибәрәм. Исән булса хәлен бел, әгәр дә чынлап та үлгән икән, каберенә барырсың. Тик син монда кире килергә сүз бир»,— диде. Туган якта булганнан соң кире аларның авылына килергә вәгъдә бирдем. Ул миңа әле болай дип тә әйтте: «Үзегездә син мондый гарип йөзең белән беркемгә кирәк булмаячаксың, син үзегездә барыбер яши алмаячаксың. Ә монда, безнең авылда, син инде үз кеше, сине монда яраталар, хөрмәт итәләр», — диде. *(Авыр сулап куя.)* Менә туган якка кайтып җиттем. Әнием дә вафат булган, йортыбыз да юкка чыккан.

Роберт. Ләкин син бит кире Кавказга китмәячәксең?

Артем *(иңнәрен сикертеп)*. Юктыр инде.

Нэлли. Әлбәттә, кире китми инде ул анда! Таулардагы чечен авылына китәргә җүләрмени ул! *(Иренә шелтәле караш ташлап.)* Син дә инде сорап торасың...

Роберт. Үзебезнең шәһәрдә калырга ниятлисеңме?

Артем. Кая барыйм инде, кая?!

Нэлли *(кызганып)*. Битең авыртамы?

Артем. Хәзер инде авыртмый.

Нэлли. Яхшы пластик операция ясатырга кирәк. Ә аңарчы махсус күзлек киеп йөрергә дә мөмкин — битнең күпмедер өлешен капларлык итеп.

Роберт *(нәфрәтле тавыш белән)*. Нэля...

Артем. Рәхмәт, чәй бик тәмле булды! *(Кузгала.)*

Роберт. Син хәзер нишләргә уйлыйсың?.. Берәр җиргә барасың юктыр бит?

Артем. Зиратка барам. Мин анда инде бик күп көннәр-төннәр үткәрдем. Зиратта тыныч, рәхәт, тик шул ук вакытта коточкыч авыр да. *(Ишеккә таба юнәлә.)*

Роберт. Без һәрвакыт өйдә... Рәхим ит... теләсә кайсы вакытта.

Артем. Рәхмәт. Исән-сау торыгыз!

Артем чыгып китә. Пауза.

Роберт *(ачыргаланып)*. Нәрсә син кытаклыйсың!

Нэлли *(гаҗәпләнеп)*. Нәрсә ошамады?

Роберт. Нигә аның йөзе хакында сүз катасың?! Ник аның битен кат-кат исенә төшерәсең, ярасына тоз сибәсең?! Тинтәк!

Нэлли *(үпкәләп)*. Нишлисең син! Ник мине мыскыл итәсең?!

Роберт *(җирәнеп)*. Өйрәтеп утырган була: операция ясарга... күзлек табып кияргә... Синнән башка белмәсләр иде инде!

Нэлли. Ник бу хәтле кызасың? Нәрсә булды сиңа?
Роберт *(үчекләп)*. «Исән булуың әйбәт... Ничек кенә булмасын...» Аңа болай да авыр, ә син шундый сүзләр әйтәсең!
Нэлли. Әйтсәм ни?! Ул безгә чит-ят кеше түгел лә!
Роберт. Чит-ят булмаса, бигрәк тә ярамый кешенең авырткан урыннарына кагылырга. Балабыз юклыгында да игътибарны акцентлап утырасың, аңгыра!
Нэлли *(ярсып)*. Ник мине рәнҗетәсең?! Нигә дип мыскыл итәсең?! Син үзең тиле-миле!
Роберт *(хатыны янына атылып килә, ачуын йөгәнли алмый)*. Нәрсә?! Минме тиле-миле?!
Нэлли *(төкерекләрен чәчеп).* Син!
Роберт *(чыгырыннан чыгып)*. Син! *(Кизәнеп хатынының яңагына суга.)*

Нэлли диванга капланып елый. Әмма аның елавы озакка сузылмый. Ул сикереп тора, бернинди куркусыз иренең каршысына килеп баса.

Нэлли *(иренең күзенә туп-туры карап).* Ни хакың бар миңа сугарга! Адәм актыгы! Хәсис!
Роберт. Нәрсә-ә-ә-ә?!
Нэлли *(ысылдап)*. Әйдә, тагын бер генә тапкыр сугып кара! Аның фаҗигасендә син гаепле икәнне бүген үк бөтен кеше беләчәк!
Роберт *(кинәт каушый)*. Аңламадым?!
Нэлли *(һаман иренең күзенә карап, кыю һәм ныклы тавыш белән)*. Аңламадыңмы?! Артемның гарипләнүендә син гаепле. Вадим да гаепле. Аңлашылмаслык берни дә юк монда. Монда бөтен нәрсәне гап-гади генә аңлатып була. Гомумән, һәрбер кешенең теләсә нинди ямьсезлеге гап-гади аңлатыла!

Роберт тораташ булып ката. Шул вакытта Вадим керә.

Вадим. Комачауламадыммы?
Нэлли *(җиңүчеләргә хас кыяфәт белән)*. Юк, комачауламадың! *(Кычкырып диярлек.)* Даша өйдәме?
Вадим *(сәерсенеп)*. Өйдә.

Нэлли тиз-тиз атлап чыгып китә. Роберт аны туктатырга да җитешми кала.

Вадим *(шапылдап ябылган ишеккә карап тора)*. Нәрсә булды аңа?
Роберт *(басынкы тавыш белән)*. Истерика.
Вадим *(Робертны беркавым җентекләп күзәтеп тора)*. Син аны күрдеңме?
Роберт *(арыган тавыш белән)*. Күрдем. Ә син?
Вадим. Мин әле юк.
Роберт. Ул әле яңа гына бездән чыгып китте.
Вадим. Кая китте?
Роберт. Зиратка. Әнисенең кабере янына.
Вадим. Ну... ничегрәк соң ул?
Роберт. Сүз белән генә әйтү кыен. Үзең күрерсең әле.
Вадим. Ниләр сөйли?
Роберт. Болай... тегесен-монысын... Озак сөйләшмәдек. Бронетранспортерда янганнар, пленда булган...
Вадим *(читкә карап)*. Аңламыйм... Димәк, Даша чынлап та чормадан аның тавышын ишеткән булып чыгамыни?..
Роберт *(гасаби киеренкелек белән)*. Моны син миннән сорарга тиеш түгел! Каян белим мин!
Вадим *(кыбырсып)*. Ник тыпырчынасың син?! Тыныч кына сөйләшә алмыйсыңмыни?!
Роберт *(кызып)*. Синең Дашаңның тавыш ишетү-ишетмәвенең ни әһәмияте бар! *(Бүлмә буйлап йөри.)* Артем кайткан. Чырае янган — чиркангыч, иләмсез — үзенә бөтенләй охшамаган. Коточкыч!
Вадим *(уйга калып)*. Димәк, барыбер ул безнең чормабызда яткан... Күптән анда менеп урнашты микән ул?
Роберт *(салкын гына)*. Барыбер түгелмени?!
Вадим *(аптырап)*. Миңа сиңа мә! Кызык кеше син! Без берни белмичә яшәп ятабыз, ә ул безнең өстебездә ята...
Роберт *(тыныч булырга тырышып)*. Синдә көнчелек хисе уянды, шул гына.
Вадим. Ә синдә көнчелек уянмас идеме, әгәренки минем урында булсаң?!
Роберт *(ачу белән)*. Көнләшәсе юк. Ул урод. Аның йөзенә карарга куркыныч. Андый кешедән көнләү көлке. Монда хәзер җитдирәк момент бар. *(Вадимга карап тора.)* Нэля нәрсәдер белә.
Вадим. Нәрсә белә?
Роберт. Артемның фаҗигасендә синең белән минем гаепле икәнне битемә бәреп әйтте.
Вадим *(кинәт сагаеп)*. Нәкъ менә шулай дидеме?!

Роберт *(гасабиланып)*. Әйе, әйе, әйе!

Вадим *(аптырашта кала)*. Кара син аны... Ә ул нәрсә... каян белә?..

Роберт. Әйталмыйм.

Вадим. Бәлки, чамалый гынадыр? Фаразлый гынадыр?

Роберт. Бәлки.

Вадим. Ә син үзең алай-болай берәр кайчан берәр кемгә әйтеп ташламадыңмы? Ялгыш кына...

Роберт. Юк ла. Мин аңа суктым. Гомердә беренче тапкыр. Түземлегемне җуйдым. Нервы... Суккач — тотты да әйтте: аның фаҗигасендә син һәм Вадим гаепле, диде.

Вадим *(уйланып торганнан соң)*. Болай ук нервыланырга ярамый. Артем бит үзе бернәрсә дә белмидер. Аңламыйм, нәрсәдән шушы кадәр куркасың?

Роберт. Мин курыкмыйм. Син ул куркасың. *(Авызын кыйшайтып.)* Сиңа бит бары тик бер уй тынгы бирми: Даша белән Артем кайчандыр бер-берсен яратканнары синең җаныңны ашый.

Вадим *(явызланып)*. Нидән чыгып әйтәсең моны?

Роберт. Бөтенесе күзеңнән күренеп тора.

Вадим. Син минем күзләремнән берни күрә алмыйсың. *(Ямьсез итеп көлә.)* Синең үзеңнең эчең кайный — Нэля аңа гашыйк иде, шул ярсыта сине. Аннары, өстәп шуны әйтәм: бүтән мондый тонда сөйләшмә минем белән, ишетәсеңме, син...

Роберт *(үзен кулга алып)*. Ярый. Чыннан да, тынычлану мәслихәт. Алайса, сугышып китүебез дә ихтимал... *(Пауза.)* Аңа ярдәм итәргә кирәк.

Вадим *(көлемсерәп)*. Кемгә?

Роберт *(тыныч кына)*. Артемга.

Вадим *(мыскыллы елмаеп)*. Ничек, нәрсәдә ярдәм итәргә аңа?

Роберт *(алҗып)*. Торырга урын табарга... Акча бирергә... Эшкә урнаштырырга... Тагын ничек булышалар кешегә? Аңа ярдәм итү — безнең бурычыбыз.

Вадим *(күзләрен кысып)*. Ну әйдә ярдәм ит, алай теләгең зур булгач. Синең абыең олактырды бит аны армиягә.

Роберт *(кинәт кабынып)*. Аны армиягә олактырырга син үтенеп сорадың түгелме?!

Вадим *(тыныч кына)*. Моның өчен син миннән күп акча алдың.

Роберт *(борын тишекләрен киңәйтеп)*. Ул акчаны мин сиңа кире бирермен. Без зур кабахәтлек эшләдек: үзебез армиядән котылдык, ә аны, закон буенча хезмәт итәргә тиеш булмаган килеш, армиягә олактырдык. Минем военкоматтагы абыем гаепле, сүз дә юк. Тик менә иң зур гаеп синең белән миндә.

Вадим. Туктале...

Роберт *(кырт кисеп)*. Син аның хәзер ниндилеген күрсәң!..

Вадим *(битарафлык белән)*. Димәк, тәкъдиренә шулай язылган булган. Сугышка эләгергә язган... Синең белән мин дә анда барып янсак яки үлсәк, моннан кемгә файда булыр иде?!

Роберт *(сыкрап)*. Бик җайлы җавап бирмәкче буласың син! Акланырга һәрвакыт мөмкинлек бар ул. Ярый әле ул үзе белми... аны армиягә без җибәргәнне.

Вадим *(кызып)*. Даша белән безнең өйләнешүебез дә дөрес түгелме?! Анысында да гаебем бармы минем?

Роберт *(тыныч кына)*. Юк ла, ул хәтле вакыт узгач Дарьяның сиңа чыгуы гаеп эш түгел. Анысын аңлар дип ышанам.

Вадим. Миңа калса, аңа барыбер монда калмау яхшырактыр.

Роберт. Ник? Ул бит монда туып үскән кеше. Ул — безнең классташыбыз. Без дуслар идек. Ничек алай дип әйтә аласың?! Кая барсын ул?

Вадим. Ул монда чагында без барыбер тыныч кына яши алмаячакбыз.

Роберт. Ә моңарчы без тыныч яшәдек мәллә? Моннан соң да тыныч кына яшәмәкче буласың мәллә? Бәлки, син барысына да төкерәсеңдер. Ә менә мин инде күптән җан тынычлыгын җуйдым.

Вадим *(Робертка акаеп карап тора)*. Бигрәк үзгәрдең син!

Роберт *(аның күз карашыннан качарга теләп)*. Олыгайганмындыр.

Вадим *(тыныч, ләкин усаллык белән)*. Ул бөтен нәрсәне җимерәчәк. Тормышыбызның асты өскә киләчәк.

Роберт *(кычкырып диярлек)*. Бер генә кеше җимерерлек булгач, синең тормышың бер тиенгә дә тормый. Андый тормыш кайчан да булса бер ишелеп төшәр иде.

Вадим. Син бөтенләй китапча җырлый башладың. *(Пауза.)* Ул безне җәзасыз калдырмаячак.

Роберт. Ул андый егет түгел.

Вадим *(көлеп)*. Андый егет түгелме?! *(Кинәт нәфрәтләнеп.)* Ул элеккеге Артем дип уйлыйсыңмы син?! Ул бездән шулкадәрле үч алачак... Синең күңелең сизмимени?! Ул безне җәзасыз калдырмаячак.

Роберт *(шәлберәеп)*. Без инде үз җәзабызны алдык. Үзенең кайтуы белән үк яртылаш җәзалады ул безне. Кайтмаган суратта дә... син ничектер, ә мин үземне җәзалы хис иттем. Хәер, син моны аңлый алмассың...

Вадим *(ямьсез елмаеп)*. Шулай инде, мин бит ахмак, каян аңлыйм мондый нәрсәләрне!

Тынлык урнаша. Роберт сигарет кабыза. Вадим бүлмә буйлап йөренә. Шомлы музыка.

## II

Дарья тәрәзә янында утыра. Тәрәзәдән алма бакчасы, чорма баскычы күренә. Нэлли керә.

Нэлли. Сәлам.
Дарья. Сәлам, Нэля. Ярый килдең әле. *(Тәрәзә яныннан китә.)*
Нэлли *(ашкынып)*. Әйдә, берәр нәрсә эчик әле!
Дарья *(Нэллиның халәтен аңлау өчен дикъкать белән карап тора).* Коньякмы?
Нэлли. Әйе.
Дарья. Син бик нык каушагансың. *(Бардан коньяк һәм ике рюмка ала.)* Мин дә эчәм.

Өстәл янына утыралар. Дарья рюмкаларга коньяк сала. Нэлли шундук эчеп куя.

Нэлли *(икеле-микеле булып торганнан соң)*. Даша, сиңа ничегрәк сөйләргә икән... акылдан язмаслык итеп...
Дарья *(бераз коньяк эчә)*. Нәрсә сөйләмәкче буласың миңа?
Нэлли *(тавышына кыюлык тоны керә)*. Син курыкма гына... тыныч бул... Нык бул.
Дарья *(түземсезләнеп)*. Әйт тизрәк.
Нэлли *(серле тавыш белән)*. Артем исән бит.
Дарья *(моңаеп)*. Беләм.
Нэлли *(гаҗәпләнеп)*. Каян беләсең?
Дарья *(башын читкә борып)*. Мин аны күрдем.
Нэлли. Күрдең?! Кайчан?!
Дарья. Кайчан булса да барыбер түгелмени?!
Нэлли. Йә Ходам! Бите... Коточкыч!
Дарья *(тирән сагыш белән)*. Чынлап та коточкыч. Тик аның бите түгел, безнең шул кыска арада үзгәрүебез коточкыч.
Нэлли *(ачынып)*. Аны күргәч, минем җаным куырылды... Ул безгә килеп керде... *(Чыраен сытып.)* Коточкыч! Аның йөзе...
Дарья *(боегып)*. Хәзер ул сездәме?
Нэлли. Ул зиратка китте...

Нэлли коньякны үзе салып эчә. Бераз исерә.

Дарья *(авыр сулап)*. Вадим да сездәме?
Нэлли. Бездә.
Дарья. Роберт нәрсә ди соң?
Нэлли. Ни әйтсен инде ул. *(Елый.)* Яңагыма сукты. Моңарчы беркайчан кул күтәргәне юк иде. Кизәнеп, бар көченә сукты, кабахәт!
Дарья. Ни өчен сукты?
Нэлли. Бер сәбәпсез дисәм дөрес булмас... Нервылана башлады. *(Сулкылдап.)* Хайван! Адәм актыгы! Артемнан курка бит ул!
Дарья *(киеренкелек белән)*. Артемны күргәч, минем куркуымны белсәң иде син!
Нэлли *(авызын кыйшайтып)*. Роберт аның йөзеннән курыкмады бит.
Дарья. Нәрсәдән курыкты соң ул?
Нэлли *(паузадан соң)*. Белмим, хәзерге вакытта Вадимың нинди хисләр кичерәдер, ә минеке бик нык каушады, тәмам югалып калды. Гәрчә беркем бернәрсә белми, беркем шикләнми дип уйласа да.
Дарья. Аңлатыбрак сөйләш.
Нэлли. Артемны кем армиягә олактырганы сиңа мәгълүмдер бит?
Дарья. Унсигез яшь тулгач берничә тапкыр военкоматка чакырдылар да, аннары алып киттеләр.
Нэлли *(җилкенеп)*. Димәк, син бернәрсә дә белмисең икән. Аны армиягә алырга тиеш түгелләр иде — әнисенең бердәнбер улы булганга күрә. Вадимың аны ничек тә булса армиягә җибәрү юлын эзләде — шул ике ел эчендә сине үзенеке итү нияте белән.
Дарья *(шаккатып)*. Шуннан?
Нэлли *(кызып-кызып)*. Робертның абыйсы военкоматта эшли иде. Хәзер ул Волгоградта яши. Вадим Роберт белән сөйләште: Артемны военкоматтагы абыйсы армиягә олактырсын дип. Әлбәттә, акчага —

шактый зур суммага. Робертка да хәйран акча эләкте бугай. Роберт бит мине Артемга гашыйк дип уйлап йөрде, шул сәбәпле ул да аны ике елга озатырга теләк белдерде.

Дарья *(ышанмыйча)*. Ни сөйлисең син, Нэля!

Нэлли *(кычкырып)*. Сүзне бүлмә, яме! Син бит беләсең: Артем белән әнисенең бер таяныр кешеләре дә юк иде. Аларның барып ярдәм сорар туганнары, әшнәләре юк иде. Судларга йөри торган кешеләр дә түгел алар. Армиядән котылыр өчен военкоматта взятка бирерлек акчалары да булмагандыр. Үзең беләсең, хәзер дә блаты булмаган, акчасыз кешеләрнең малайларын алалар армиягә. *(Пауза.)* Артем миңа ошый иде, яшермим — кызык, акыллы, башкаларга охшамаган егет буларак. Менә шулай. Алар үзләре армиядән котылдылар, ә Артемны олактырдылар.

Дарья *(ачу белән)*. Уйдырма! Ялган! Ирең сукканга күрә нахак сүз сөйләп утырасың. Үзең уйлап чыгарганны сөйлидең син!

Нэлли *(кайнарланып)*. Мин сиңа әллә ниләр белән ант итә алам. Син белмисеңдер, без дә бит Артем белән хат алыштык... Дуслар, классташлар буларак инде... Бер тапкыр Роберт белән каты гына талаштык та мин, кызып китеп, Артемга барысын да яздым.

Дарья. Нәрсәне яздың?

Нэлли. Сине «дусларың», классташларың армиягә олактырды, дип.

Дарья *(авыз чите белән)*. Бигрәк әшәке син, Нэля... Сөйләгәнең хак булса инде...

Нэлли *(кинәт боегып)*. Миннән дә әшәкерәк кешеләр бар әле.

Дарья. Син каян белдең соң аны армиягә Вадим белән Роберт алдыртканны?

Нэлли. Военкоматта минем бер таныш кызым эшләде. Ул гел безнең парикмахерскийга йөрде, мин ясый идем прическаларын. Менә шул кыз Робертның абыйсының сөяркәсе иде. Ул аны ташлаган. Ачудан бу кыз тотты да сөйләде миңа.

Даша. Син һәрвакыт тузга язмаган, юк сүз сөйлисең! Тик менә хәзер никтер сиңа ышанасым килә башлады. Син һәрвакыт, көнләшепме, башка сәбәп беләнме, бәлки, бөтенләй начарлык теләмичә, гел минем күңелемне ярсытасың, гел йөрәгемне әрнетерлек нәрсәләр сөйлисең... Минем газаплануым сиңа ләззәт бирә, ахрысы. *(Пауза.)* Син сөйләгәннәр хакмы?

Нэлли. Ант итәм!

Дарья. Димәк, Вадим белән Роберт олактырдылар аны армиягә? Һәм дә бу турыда Артем синең хаттан белгән?..

Нэлли. Әйе.

Дарья *(басынкы тавыш белән)*. «Без капчыкта ятмый»... Бөтен нәрсә кайчандыр мәгълүм була. Бернәрсәне яшерү мөмкин түгел.

Нэлли *(шыңшып)*. Белсәң иде хәлемнең авырлыгын!

Дарья *(тирән уйга чумып)*. Ә мин, киресенчә, тынычлана башладым әле. Кеше юкка чыгу чынлап та коточкыч. Чөнки бернәрсәне үзгәртү мөмкин түгел, гафу үтенеп тә булмый, алдында тезләнә дә алмыйсың. Ә менә кеше исән булса, нинди генә фаҗигага кичермәсен, ничек кенә гариплэнмәсен, барыбер нәрсәнедер үзгәртү, төзәтү мөмкин. Мин хәзер ышанам: минем тормышымда да зур борылыш булачак — яхшы якка. Башкача мөмкин түгел!

Нэлли *(уйлап торганнан соң)*. Минем тормышымның да кискен үзгәрүе мөмкин. Тик менә яхшы якка микән? Мин куркам!

Дарья *(кинәт үзендә ышаныч тоеп)*. Ә миндә курку юкка чыкты. Син, юньсез, ник моңарчы миңа моны сөйләмәдең?

Нэлли. Сөйләгән булсам... шуннан? Файдага булыр иде микән? Мин бит беркемгә дә зыян, начарлык килмәсен дип бу хакта бер сүз дәшми йөрдем.

Дарья *(ачусыз гына)*. Син бөтенләй минем иптәш кызым булмагансың икән. Гомумән, барыбыз да үзара дуслар булмаганбыз. Нindидер бер үсмерләр көтүе булганбыз.

Нэлли *(Дарьяга үпкәләми)*. Артем безнең үсмер елларыбызны сагына... Елга буена барып кунганнарыбызны искә төшереп утырды.

Дарья. Барыбыз да сагынабыздыр да. Әмма дә ләкин бу фәкать үзеңнең бала чагыңны сагыну гына.

Нэлли *(Дарьяга карамаска тырышып)*. Каты күңелле син хәзер, Дарья. Рәхимсезләндең.

Дарья *(тавышын күтәреп)*. Нэлли! Мин рәхимсез түгел, ә менә дөреслек рәхимсез!

Роберт белән Вадим керәләр. Сәер, сынаулы караш белән хатыннарына карап торалар.

Вадим. Нишлисез?

Дарья *(тыныч кына)*. Сөйләшеп утырабыз.

Роберт *(елмаерга тырышып)*. Ике хатын, очрашкач, гадәттә, нишлиләр инде.

Вадим *(гасабиланып)*. Әйдәгез киңәшләшик... Безнең яшьлек дустыбыз афәттән котылып кайткан... Без менә Роберт белән аңа ничек ярдәм итү турында уйланабыз... Сез дә үз фикерләрегезне әйтсәгез әйбәт булыр.

Нэлли *(җанланып)*. Әйдәгез уйлашыйк.

Вадим *(үтә җитди кыяфәт белән)*. Даша, бу йортны әлегә Артемга калдырып торырга тәкъдим итәм, ә үзебез кичекмәстән коттеджга күченик.

Дарья *(тыныч, ләкин бәхәскә урын калдырмаслык тавыш белән)*. Мин беркая да кичекмәстән күченмәячәкмен.

Вадим *(кырысланып)*. Бәлки, син инде гомумән каядыр күченүгә каршыдыр?

Дарья. Белмим.

Вадим. Сине һич аңламассың. Йә коттеджга күчәсең килә синең, йә монда калырга телисең. Йә тегеләй, йә болай! Күпме түзәргә мөмкин инде!

Роберт *(Нэляга)*. Минемчә, монда гаилә мәсьәләләре буенча әңгәмә башлана. *(Вадимга.)* Без Нэля белән соңрак керик мәллә?

Вадим. Юк, соңрак түгел! Беркая да китмәгез. Сез монда чакта соравыма җавап аласым килә: нишләп ул безнең чормада качып яткан?!

Роберт *(читенсенеп)*. Шулай да гаилә проблемасына керде сөйләшү. Нэля, әйдә чыгабыз.

Роберт белән Нэлли чыгып китәргә җыеналар.

Нэлли *(ясалма ягымлылык белән)*. Чынлап та, әйдәгез, башка көнне сөйләшербез. Мәсәлән, иртәгә.

Дарья. Туктагыз. Сез хәзер кая барасыз?

Роберт. Өйгәдер инде.

Дарья. Мин дә сезнең белән барам.

Вадим. Ә мин?

Дарья. Ә син тынычлан, башыңны тәртипкә китер.

Роберт *(иңнәрен сикертеп)*. Вадим туган, бер сүз дә әйтә алмыйм.

Вадим *(нәфрәтләнеп)*. Барыгыз, барыгыз! *(Кесәсеннән сигарет пачкасы чыгара, калтырана-калтырана сигарет кабыза.)* Барыгыз!

Роберт, Нэлли һәм Дарья чыгып китәләр. Вадим берүзе кала. Урындыкта утырып тәмәке тарта. Шомлы музыка. Тавыш-тынсыз, төштәгедәй, өйгә Артем килеп керә. Аны күреп, Вадим сикереп тора.

Вадим *(өнсез калып)*. Син кем?

Артем *(тыныч тавыш белән)*. Мин — Артем. Исәнме, Вадим!

Вадим *(өй почмагына таба чигенә)*. Син өрәктер?

Артем. Мине теләсә кемгә һәм теләсә нәрсәгә охшат, теләсә ничек ата, әмма дә ләкин мин — Артем.

Вадим *(каушавын көчкә җиңеп)*. Артем... Дустым... Братан... Артем туган! Син... Исән... Мин чиксез шат. Исәнме. *(Артемның кулын кысып күрешә.)* Бигрәк озак көтәргә туры килде сине. Кай тарафларда йөрдең ничәмә еллар буе?

Артем. Сөйләсәң, бик озынга китә. Хәер, син үзең дә беләсеңдер инде.

Вадим. Болай... өстән-өстән генә. Утыр әйдә, сөйләшик.

Артем иске диванга утыра, Вадим кая урнашырга белми. Ниһаять, ул табуретканы эләктереп ала да диваннан читкәрәк куеп утыра. Авыр тынлык урнаша.

Артем *(гаҗәп тыныч тон белән)*. Тормышлар ничек бара?

Вадим *(авызын кыйшайтып көлемсери)*. Ничек дип... Эт тормышы инде. Тормыш ул бөтен җирдә авыр. Чабабыз, бөтереләбез, кайнашабыз... Бизнес, конкуренция...

Артем. Аңлашылды.

Вадим *(паузадан соң)*. Без инде сине исән түгелдер дип уйлаган идек.

Артем. Мин үзем дә исән икәнемә ышанмыйм.

Вадим *(моңсу тавыш белән)*. Әйе, туган, синең башыңа төшкәнне беркемгә дә теләмәссең. Ай-яй, синең өлешеңә тиде... *(Авыр сулап.)* Күптән кайттыңмы?

Артем. Ничә көн узганны хәтерләмим. Кыскасы, әнинең кырыгын зиратта үткәрдем инде.

Вадим. Ә бу көннәрдә кайда яшәдең соң син?

Артем. Зиратта. Каравылчылар белән сөйләштем дә, шунда яшәргә рөхсәт бирделәр.

Вадим *(өскә ымлап)*. Ә чормада кайчаннан бирле яшисең?

Артем. Минем анда бер тапкыр да кунганым юк. Яшермим, мин анда мендем. Дөресен әйтәм, бер төнне шунда уздырырга да ниятем бар иде.

Вадим. Ник?

Артем. Зиратта салкын. Бүтән барыр урыным юк. Аннары, зират каравылчыларының минем зиратта озак яшәвемә эчләре поша башлады.

Вадим. Нишләп башта ук безгә күренмәдең?

Артем. Сезне борчыйсым килмәде.

Вадим *(коры гына)*. Борчыйсың килмәгән, ә чормага менгәнсең.

Артем. Бер генә төн кунмакчы идем мин.

Вадим *(тавышын күтәреп).* Нәкъ Дашаның туган көнен бакчада билгеләп утырган көннеме?.. Ник алай?

Артем. Туры килгән.

Вадим. Син бит Дашага эндәшкәнсең?

Артем. Юк. Аңа тоелган гына. *(Пауза.)* Ихластан әйтәм, бер мәртәбә эндәштем.

Вадим. Ник?

Артем. Дөресен әйтимме?

Вадим. Дөресен әйт.

Артем. Ычкынды. Үзеннән-үзе эндәшелде. Үземне тыя алмадым. *(Вадимга карап тора).* Син нишләп миннән сорау аласың? Допроска охшап китте. Син миннән шикләнәсең. Син шикләнәсең.

Вадим *(Артемның күз карашыннан курка).* Юк ла, син нәрсә! Даша һәм мин — ир белән хатын... Шуңа күрә, чормада кемдер булгач, табигый ки, бер дә рәхәт түгел. Әллә ниләр уйларсың...

Артем. Гаебемне таныйм.

Пауза.

Вадим *(кинәт).* Мин сиңа акча белән ярдәм итә алам.

Артем. Миңа акча кирәкми.

Вадим *(чыраен сытып).* Даша авырый. Халәтен аңлап булмый, әллә нәрсә шунда... Мин аның хәле начарланып китүне синең кайтуың белән бәйле дип саныйм. Язмышларыбыз менә шулайрак килеп чыкты шул... Һәркемнең үз язмышы... Син мине аңлыйсыңдыр. Мин сиңа теләсә кайчан булышырмын. *(Шкафтан бер пачка доллар ала, Артемга суза.)* Әлегә менә бу акчаны ал.

Артем. Кирәк түгел. Яшереп куй долларларыңны. Теләгеңне әйт.

Вадим *(акчасын янә кире шкафка тыгып куя).* Син кит моннан. Шәһәребездән ераккарак кит. Мин Дашаны нык яратам.

Артем. Мин комачауламыймдыр лабаса? Мин — шушындый бозык чырайлы кеше — кемгә дә булса комачаулый аламмы соң?!

Вадим. Сине күргән саен аның күңеле ярсыр. Ул бик кызганучан. Китсәң, аңа да, сиңа да яхшырак булачак. Барыбызга да.

Артем. Мин беркая да китәргә җыенмыйм. Минем китәр җирем дә юк. Кайда кем көтеп тора мине?! Син бер дә борчылма, мин беркемгә дә комачауламам. Аңладыңмы, мәктәп дустым, кадерле классташым?!

Вадим. Әйт, ничек, нәрсә белән ярдәм итәргә сиңа?

Артем. Вадим, мин синең ярдәмеңә мохтаҗ түгел. Юкка болай кыбырсыйсың.

Вадим *(көлемсерәп).* Мин кыбырсыйммы?! Гафу ит, ләкин Россия буенча террактлар гөрселдәгәннән соң синнән шикләнергә дә хакыбыз бар. *(Кинәт усаллана.)* Нишләптер кинәт, көтмәгәндә, качып кына һәм сәер рәвештә килеп чыктың син.

Артем *(тавышында мыскыллау тоны яңгырый).* Аңламыйм, әгәренки ике ел хезмәт итеп исән-сау әйләнеп кайткан булсам, син миңа үзем туып-үскән шәһәрдән китәргә кушмас идеңме?

Вадим. Син мине аңламадың, Артем... *(Читкә карап.)* Гафу ит... Синең мондый битеңне күрү барыбызга да авыр, барыбызның да җаны телгәләнә.

Артем. Әгәр дә һәлак булсам, комачауламас идемме? *(Вадимны иңеннән кага.)* Вадим туган, синең көнләшүең бөтенләй нигезсез.

Вадим *(бераз тынычлана).* Гафу ит мине, зинһар. *(Килеп, Артемны кочаклый. Чиркануын яшерергә тырыша.)* Их Артем, Артем. Нинди көнләшү! Сиңа карарга куркыныч. Мин әле һаман һушыма килә алмыйм. *(Бүлмә буйлап йөри.)* Менә нәрсә... Син миннән акча алмадың. Белмим, нәрсә тәкъдим итәргә сиңа? Менә нәрсә... Әгәр дә телисең икән, чормада куна аласың.

Артем. Рәхмәт. Минем бик нык йокым килә. Мөмкин булса, хәзер үк менәм чормага.

Вадим. Бар, бар, мен. Ял ит. Йокла.

Артем өйдән чыгып китә. Вадим ашыгып сигарет кабыза. Дарья керә.

Дарья *(паузадан соң).* Бөтен өйне тутырган төтен белән. Суларлык түгел.

Вадим *(ярарга тырышып).* Ишекне ачам. *(Ишекне кысып кына ача.)* Дарья, син миңа үпкәләмә. Бу бит безнең өскә көтмәгәндә килеп төште.

Дарья *(битараф тавыш белән).* Үпкәләүдән ни мәгънә?!

Вадим *(назлы булырга тырышып).* Даша, җаным, мин сине шундый яратам!

Дарья *(текәлеп карап тора).* Тынычландыңмы?

Вадим. Бераз. Мин аның белән сөйләштем.

Дарья. Кем белән?

Вадим. Артем белән. *(Паузадан соң.)* Ул анда... өстә.

Дарья. Кайда?

Вадим. Чормада.

Дарья. Мин риза. Ул шушы йортта калсын, ә без коттеджда яшәп торырбыз.

Вадим *(сәерсенеп)*. Нишләп «яшәп торырбыз» дисең? Без бөтенләйгә күченмибезмени анда?

Дарья *(сабырлык белән)*. Сүзгә бәйләнмә. Аңа әйтергә кирәк: чормадан төшсен. Өйдә яшәсен.

Вадим *(күтәренкелек кичерә)*. Ярар, мин аңа әйтермен. Без аңа һәрвакыт ярдәм итәрбез. Без аны ташламабыз. Ул бит шәп егет! Бәхетсезлеккә, фаҗигагә юлыккан кеше... Нишлисең бит... Барысы да тәртиптә булачак. Барыбыз да әйбәт яшәрбез!..

Кайдадыр өстә ялгыз скрипка уйный.

## III

Алма бакчасы. Йорт. Капка, болдыр, чорма күренә. Тастымал белән капланган җамаяк күтәреп Нэлли керә. Як-ягына каранып, сак кына атлап болдырга таба килә. Ишек бикле — йозак эленгән. Бакчага керә. Чормага менә торган баскыч янында туктый. Нишләргә белми, аптырап тора. Шул вакытны чорма ишеге ачыла һәм Артем пәйда була.

Артем *(аска карап)*. Нэля, синме?

Нэлли *(сискәнеп)*. Мин. *(Башын күтәреп карарга курка.)*

Артем. Курыкма, бу мин — Артем.

Нэлли. Исәнме!

Артем. Исәнме! Кемне эзлисең?

Нэлли *(югалып кала)*. Мин синең яныңа дип килдем.

Артем. Шулаймыни?

Нэлли. Мин сиңа пәрәмәчләр алып килдем. Дөге һәм ит белән. Дөге һәм итле пәрәмәч яратканың исемә төште дә... менә махсус синең өчен пешердем.

Артем *(шатлыклы тавыш белән)*. Рәхмәт яусын! Хәзер төшәм.

Артем баскыч буйлап төшә. Нэлли тын алырга да куркып тора. Шулай да ниндидер сихри бер көч Нэллины Артемга тарта.

Нэлли. Монда ашыйсыңмы?

Артем. Әйе, әнә теге өстәлдә.

Бакча эчендәге өстәл янына баралар. Артем, кыяфәте белән куркытмас өчен, Нэллига карамаска тырыша. Нэлли җамаякны аның алдына куя да читкәрәк утыра.

Нэлли. Пәрәмәчләр әле кайнар...

Артем *(пәрәмәч алып ашый)*. М-м-м, тәмлелеге! Үзең пешердеңме?

Нэлли. Үзем.

Артем. Парикмахершалар мондый тәмле ризык пешерәләрдер дип уйламаган идем.

Нэлли *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Мин бит инде күптән ирдә.

Артем. Роберт кем булып эшли?

Нэлли. Яшелчә базасы директоры.

Артем. Начар түгел. *(Җамаяктан тагын пәрәмәч ала.)*

Нэлли. Ул үзе политехнический институт тәмамлаган иде... Тик бөтен нәрсәнең асты өскә килде, дөньялары буталып-чуалып бетте. Хәзер инде үз һөнәре буенча эшләүче сирәктер. Вадим да бит строительный институт тәмамлады, ә үзе бөтенләй башка төрле бизнес белән шөгыльләнә.

Артем. Аның каравы үзенә яхшы, затлы иттереп төзи. Димәк, строительныйны тәмамлавы тикмәгә түгел. Тагын берне ашыйммы?

Нэлли. Әлбәттә. Ашап бетер.

Артем. Рәхмәт.

Пауза.

Нэлли *(тирән уйга чумып)*. Сиңа барысын да язасым калмаган икән теге вакытта...

Артем *(паузадан соң)*. Робертның абыйсы һаман да военкоматта хезмәт итәме?

Нэлли *(сөмсере коела)*. Юк. Ул башка шәһәргә күчеп китте. Кемдер ул хәзер, белмим. Мин, тиле, әле ул вакытта Робертка кияүгә чыгармын дип уйламый идем. Ә Даша Вадимга чыгасын белми иде. Син аша, аша. Син әйт: тагын нәрсә ашыйсың килә. Пешереп алып килермен. Бүген минем ял көнем.

Артем *(күтәренке кәеф белән)*. Монысы өчен рәхмәт. Тамак туйды. Зур рәхмәт сиңа. Шундый тәмле пешергәнсең.

Нэлли *(күз яшьләрен көчкә тыеп)*. Исән булуыңа мин чиксез шат. Анаң гына... исән икәнеңне белми-күрми китеп барды.

Артем. Дөресен әйткәндә, мин үзем исән калуыма шат та, шул ук вакытта шат та түгел. Мондый йөз белән... Әнием үлгәнгә дә... кайгырам, шул ук вакытта кайгырмыйм да. Минем мондый иләмсез чыраемны күреп, ул интегеп яшәр иде, тормышы җәзага әверелер иде. *(Башын Нэлли ягына борып карап тора.)* Миңа карарга коточкыч чиркангычтыр, әйеме?

Нэлли *(читкә карап)*. Алай түгел. Мин синең элеккеге чын йөзеңне хәтерлим.

Артем. Нәрсә, бу йөзем, димәк, чын түгел?

Нэлли *(үзен гаепле сизеп)*. Ой, мин дөрес әйталмадым... Башкачарак әйтмәкче идем. Агач тел бит мин.

Артем. Әйдә, өйгә керәбез. Анда чәй кайнатырбыз. Эчәсе килә башлады.

Нэлли *(эчке киеренкелек белән)*. Артем, гафу ит. Мин куркам.

Артем. Аңлыйм.

Нэлли *(кинәт үзендә көч табып)*. Курку үтәчәк. Бары тик ияләшергә генә кирәк. Әйдә керәбез. Чәй кайнатып эчәрбез.

Өйгә кереп китәләр. Музыка. Күп тә үтми, капкадан Роберт килеп керә. Ул өйгә керергә җөрьәт итми. Артем белән Нэлли чыгалар. Нэлли кулына җамаяк тоткан.

Артем *(шатлыклы аваз белән)*. Сәлам, Роберт!

Роберт *(коры гына)*. Сәлам! Нэля, син нишләп монда?

Нэлли. Үзең бит, Артемга берәр нәрсә пешер, дидең.

Роберт *(мыгырдап)*. Әйе... үзем... пешерергә куштым...

Нэлли капкадан чыгып китә.

Артем *(ихлас күңелдән)*. Пәрәмәчләр өчен зур рәхмәт!

Пауза.

Роберт *(тавышындагы каушавын яшерә алмый)*. Артем! Син озак югалып тордың. Күп вакыт үтте. Синнән монда хәзер шикләнүләре ихтимал.

Артем. Ник шикләнергә тиешләр миннән?

Роберт. Әсирлектән соң берәр тикшерү үттеңме син?

Артем. Бик күп комиссияләр аша үттем.

Роберт. Ярый, синең син икәнне, бәлки, исбатлагансыңдыр.

Артем. Минем мин икәнлегемдә икеләнгән идең мәллә?

Роберт *(тавышын көчәйтеп)*. Хикмәт анда түгел. Нишләп соң син пленга эләктең? Белүемчә, әсир төшкән кеше бездә сатлыкҗан булып санала...

Артем *(искиткеч тыныч тавыш белән)*. Сатлыкҗаннарны билгеләү синең эш түгел.

Роберт *(кызып)*. Ә нишләп әле сине тоткынлыктан азат иттеләр? Нишләп кемнәрнедер атып үтергәннәр, ә сине атмаганнар?!

Артем *(көлемсерәп)*. Зинһар, гафу ит атмаганнары өчен. Гафу ит исән калуым өчен. Бу гөнаһымны кичерә аласыңдыр бит син?

Роберт *(усалланып)*. Бәлки, син дезертирдыр, бәлки, үзең теләп дошманга бирелгәнсеңдер?

Артем *(кычкырып көлә)*. Сиңа барыбер түгелмени?! Синең бит барыбер Ватаның юк!

Роберт. Ничек инде минем Ватаным юк?!

Артем. Менә шулай. Армиясендә дә хезмәт итәргә теләмәгәч, димәк, синең Ватаның түгел бу.

Роберт. Син мондый купшы сүзләрне ташла!

Артем. Мин фәкать синең тональностька гына күчтем.

Роберт. Сине бик җентекләп тикшерүләре мөмкин, тирәнрәк «казулары» ихтимал.

Артем. Бездә барысы да мөмкин.

Роберт *(усаллыгын яшерми)*. Син оста сәгатьче, теләсә нинди техниканы ремонтлый аласың... Сорау туа: чеченнар сине монда кем буларак җибәрделәр икән? Нинди задание белән сине җибәргәннәр алар? Террорист итеп түгелме? Син алай-болай камикадзе түгелме?

Артем *(ирония белән)*. Синең яшелчә базаңны шартлатыргамы? Әллә Вадимның коттедж ишегалдындагы бәдрәфне юк итәргәме?

Роберт *(кычкырып)*. Юкка көләсең!

Артем *(гаҗәеп сабырлык белән)*. Син мине үзеңнән көләргә мәҗбүр итәсең. Рәхмәт. Пәрәмәчләр бөтенләй булмады шикелле.

Артем бакча эченә юнәлә. Роберт, ишегалдында беркавым басып торганнан соң, капкадан чыгып китә.

## IV

Шул ук күренеш. Артем бакчада йөри. Алмагач төбендәге җирдән бөрешеп беткән алма ала, аны чалбарына ышкып чистарта һәм аппетит белән ашый. Дарья керә. Матур күлмәк кигән, кулында пакет.

Дарья *(кыюсызланып)*. Исәнме!

Артем *(чиксез шатланып)*. Исәнме, Дашенька! Син искиткеч гүзәл!

Дарья *(оялып)*. Мин сиңа ашарга алып килдем.

Артем. Нәрсә алып килдең?

Дарья. Пәрәмәчләр.

Артем. Нәрсә пәрәмәче, эчендә ни?

Дарья. Дөге һәм ит белән.

Артем *(көлә)*. Шәп!

Дарья. Миннән көләсеңме?

Артем. Юк. Рәхәт булганга көләм. Мин яшәеш бәхетен кинәт тойдым. Шуңа рәхәтләнеп көләм. Шәһәребездә бөтен кеше дөгеле-итле пәрәмәчләр пешергәнгә бик шат мин.

Дарья. Синең кәефең яхшы.

Артем. Менә хәзерге вакытта ничек инде минем кәефем яхшы булмасын!

Дарья. Кайда ашыйсың?

Артем. Менә шушында. Хәтта басып торган урынымнан да кузгаласым килми. *(Назлы тавыш белән.)* Дашенька!

Дарья *(күзләрен йома)*. Тагын бер әйт.

Артем. Дашенька!

Дарья. Кабатла.

Артем. Дашенька!

Дарья *(кинәт һушына килә, үзен кулга ала)*. Әйдә, суынганчы аша.

Артем, аякларын бөкләп, алмагач төбенә утыра. Дарья янәшә урнаша. Артем пакеттан пәрәмәч алып ашый.

Дарья. Ничек?

Артем. М-м-м... Телне йотарлык! Син генә шушындый тәмле пәрәмәч пешерә аласың. *(Тәмләп ашый.)*

Дарья *(паузадан соң)*. Әле һаман ышанып җитеп булмый — синме соң бу?

Артем *(ашый-ашый)*. Бәлки, чыннан да мин түгелдер бу?! Ә?! Әгәр дә бу мин түгел икән... Ә?!

Дарья. Әй, юкны сөйләмә инде. Синең тавышыңны башка кешенеке белән бутыйммы инде мин?! Син генә миңа таң калырлык итеп исемем белән эндәшә аласың. Бу — син, син, син, Артем!

Артем. Ярар, бәхәсләшмим. *(Тагын пәрәмәч алып ашый.)* Ә син нигә эшләмисең? Күңелеңә хуш килгән эш юкмы?

Дарья. Эшен табар идем дә мин. Вадимның мине эшләтәсе килмәде.

Артем. Эшләтәсе килмәде... Ник үткән заманда әйтәсең — «эшләтәсе килмәде...»

Дарья. Эшләтәсе килми. Мин культура институтын тәмамладым. Культуроведение факультетын. Дипломым буенча юньле эш юк инде, тик мин үзем башка төрле эшкә дә ризалашыр идем. Ә синең планнарың нинди?

Артем *(иңнәрен сикертеп)*. Планнар юк әле.

Дарья *(уйланып торганнан соң)*. Карале, сиңа укырга керергә кирәк. Югары белем алырсың. Диплом белән барыбер җиңелрәк булыр.

Артем. Укырга вакыт юк, Дарья.

Дарья. Ничек инде вакыт юк?

Артем. Минем тегендә кайтасым бар.

Дарья *(котсыз калып)*. Кая?

Артем. Төньяк Кавказга. Таулар арасындагы авылга.

Дарья *(ышанмый)*. Шаярасыңмы?

Артем. Юк, шаярмыйм. Мин Әхмәткә кире киләм дип вәгъдә бирдем. Ул мине анам янына дип кенә җибәрде.

Дарья *(газаплы кыяфәт белән)*. Син моны хәзер үзең уйлап чыгардың. Алдыйсың син. Безнең барыбызның да борчылуыбызны сиздең дә кире китәргә булдың. Безгә комачауламас өчен күзебездән югалмакчы буласың бит син. Туып үскән шәһәремдә калам, дигән идең бит.

Артем. Ихлас күңелдән әйтмәдем мин аны.

Дарья. Акылдан яздың мәллә! Ничек инде үз теләгең белән кире әсирлеккә китәргә мөмкин?!
Артем. Бу хакта бүтән сөйләшмик.
Дарья *(хәсрәтле тавыш белән)*. Йә Ходам!

Музыка. Дарья кулының арты белән Артемның битенә кагылырга батырчылык итә. Артем аның кулын учларына алып күкрәгенә кыса.

Артем *(ягымлы итеп)*. Даша! Дашенька!

Дарья *(күз яшьләре аша)*. Дөресен әйткәндә, синең йөзеңне күрү куркыныч. Ләкин тавышың ишетелү белән синең битең шундый матурлана.

Артем. Ә син дөньяда иң гүзәл кеше.

Дарья. Мин андый сүзләргә лаеклы түгел.

Артем. Лаеклы. Тик артык боек, моңсу син. Сагышлануның да чамасы булырга тиеш. Чамасы булган сурәттә генә сагыш төсе якты була.

Дарья. Син олы йөрәкле кеше. Чынлап та беркемгә дә ачу тотмыйсыңмы? Беркемгә дә нәфрәтең юкмыни?

Артем. Ә нигә?! Шулай да, ачыктан-ачык әйткәндә, мин кешеләрне яратмыйм. Әмма дә ләкин кешеләрдән башка бер кеше дә яши алмый. Башкалардан тыш аерым кешенең тормышын күз алдына китерү кыен. Мин бик сагындым: сине, сезне — дусларымны. Бөтен кешеләрне ярату мөмкин түгелдер. Гомумән кешеләрне яратырлык түгел. Кешелек дөньясы мәхәббәткә лаек түгел. Аерым алган кешене генә яратырга буладыр. Анаңны... яки берәр хатын-кызны... шул ук вакытта, тирәнрәк уйлап баксаң, башка кешеләрне яратмыйча гына аерым кешене ничек яратырга мөмкин ди. Алайса бит ул чын мәхәббәт булалмый. Менә шундый парадокс. Бәлки сөю эйфориясендә бөтен кешеләрне, хәтта кабахәтләрне дә ярата башласын өчен кешегә мәхәббәт биреләдер.

Дарья. Мин әле, шулай да, кире әсирлеккә китмәссең дип ышанам.

Музыка.

## V

Алма бакчасы. Дарья өстәл янында утыра. Вадим, сигарет тарта-тарта, арлы-бирле йөренә. Роберт алмагач янында басып тора. Нэлли коймага сөялгән. Тынлык.

Роберт *(өстәл янына килә)*. Ни дисәң дә, моннан китсә, аңа яхшырак булачак. Безнең компаниядән ул гына шундый зур бәлагә тарыды. Аңа гына шундый өлеш тиде. Аңа безнең янда яшәве авыр, кыен булачак. Психологик яктан читен булачак аңа безнең арада яшәү.

Вадим. Кем әйтте, ул безнең арада яшәячәк дип? Бер шәһәрдә яшәп тә бер-береңне күрмәскә мөмкин. Монда калса да ярый.

Нэлли. Аны монда калдырырга кирәк. Үзе әйтте бит: үзем туып үскән шәһәрдә яшисем килә, диде.

Дарья *(нервыланып)*. Ул үзе белер нишләргә кирәклеген. Ник әле барыгыз да аның өчен хәл итәргә тотындыгыз?! Болай да инде аның язмышы белән башкалар җитәрлек уйнаган.

Роберт *(ирония белән)*. Синнән, Дарья, кайвакыт шундый көчле фразалар килеп чыга.

Дарья. Ник, шулай түгелмени?

Пауза.

Нэлли *(уйланып)*. Төш түгелме соң бу? Безме соң бу?

Вадим *(аска карап)*. Чыннан да, без бит мондый түгел идек бугай!

Дарья *(җан ачысы белән)*. Ләкин без мондый булырга әзер идек. Исегездәме, ничек тота идек үзебезне? Ихласлык күп идеме бездә? Бездә уен күбрәк иде. Без рольләребезне шундый оста уйный идек, хәтта бүгенгедән дә остарак!

Вадим *(борын астыннан)*. Чечня булмаса... Сугыш булмаса, димәкче идем...

Дарья *(кырт кисеп)*. Сугышны да кешеләр башлый.

Нэлли. Барыбер бу хәлгә ышанасым килми әле.

Дарья. Без һәрвакыт кайгыларның өндә булмавын телибез.

Капка ачыла. Артем пәйда була. Тынлык урнаша. Артем бакчага керә. Барысы да сагаялар.

Артем. Хәерле көн!

Вадим. Хәерле көн! *(Артем белән кул биреп күрешә.)*

Роберт. Сәлам, туган! *(Артемның кулын кыса.)*

Нэлли. Исәнме, Артем!

Дарья. Исәнме!

Вадим *(киеренкелектән арынып өчен, барысының да кәефен күтәрергә ниятләп).* Карагыз әле, дуслар, без бит әле иптәшебез Артемның кайтуын кешеләрчә бәйрәм дә итмәдек.

Артем *(тыныч кына).* Кирәкми. Сез мине болай да бик җылы каршы алдыгыз. Мин шат. Мин бәхетле. Иң мөһиме — без очраштык. Бер-беребезнең күзләренә карарга мөмкинлегебез бар. Сөйләшә алабыз, үткәннәрне искә алып көлешә алабыз. Теләгән кешегә уңышлары белән мактанырга мөмкин, гаебен тойган кешегә кызарырга мөмкин... Тик минем үземнең йөзем хәзер инде кызармый. Сизәм, минем кайтуым кайберәүләргә бик авыр тәэсир ясады. Мин сезне озак борчымам. Сезгә карата иң якты, иң яхшы хисләремне белгертәсем килә. Минем иң якты, бәхетле көннәрем, ничек кенә булмасын, барыбер сез классташларым белән бәйле. Гафу итегез мине...

Дарья *(кычкырып).* Артем, нишләвең бу?!

Артем *(шул ук тыныч тонда дәвам итә).* Мин сезнең барыгызны да яратам. Очрашуыбызга мин бик шат. Кешеләр арасындагы мохиттә күктән иңдерелгән ниндидер бер изге яктылык бар, шул кешеләрнең нинди булуларына карамастан. Ниндидер илаһи бернәрсә була кешеләр төркемендә. Яктылык, аура. Ничек атасагыз да ярый. Әнә шул атмосферага чумган сурәттә генә кеше чын-чынлап яши. Затлы кешеләрме анда, вак җанлылармы — моның әһәмияте юк. Шунысы кызык һәм сәер: аларның мохитендә илаһилык үзләренә бәйсез рәвештә, аерым яши. Шул илаһилык гел алар арасында йөри, алардан калмый, ул аларны ташламый. Иң мөһиме — шуны тою һәм шуңа куану.

Тынлык урнаша.

Нэлли. Нәрсә авызыгызга су каптыгыз?! Сөйләшегез акыллы кеше белән. Миннән кала барыгыз да югары белемле бит.

Дарья. Тик кенә утыр! Телеңне тый!

Пауза.

Артем *(алмагач тирәли бер әйләнеп чыккач).* Киттем мин.

Беркем бер сүз әйтми. Артем чыгып китә.

Нэлли *(ыңгырашып).* Йә Ходам, нишләп бу кадәр читен соң?!

Вадим *(гаҗәпләнеп).* Аңламыйм, нигә без траурда утырырга тиеш? Яшәмәскәмени инде хәзер?!

Роберт *(чак кына ишетелерлек, ләкин каты тәэсир итәрлек тавыш белән).* Яшә, сиңа комачаулаучы юк.

Дарья *(ачыргаланып).* Йә Аллам! Без кыска гына вакыт эчендә битләребездә шулкадәр күп маска алмаштырдык. Ә ул хәтта хәзер дә маска кими. Аның йөзенең кызармавы да янып җөйләр белән чуарланганнан түгел. Аның бернәрсә өчен дә, беркем алдында да кызарасы юк. Әгәр дә ул безне гаепләсә, үземне җиңелрәк хис итәр идем. Ләкин ул беркемне гаепле санамый, хәтта бернинди үпкә әсәре дә юк аңарда, киресенчә, ул бездә үзенең дусларын, классташларын күрә. Шуңа минем җаным нык әрни.

Нэлли *(кинәт ярсып).* Синең генә җаның әрни дип уйлыйсыңмы әллә?! Башкаларга нотык укырга да хакың юк! Син бездән чистарак мәллә? Без бер компания, без барыбыз да бериш!

Дарья. Менә моны белүем җан әрнүемне йөз мәртәбә көчәйтә!

Нэлли чыгып китә.

Роберт. Синең фаразларың чынга ашты, Вадим, бөтен нәрсәнең асты өскә килде. *(Бакча эченәрәк керә.)*

Вадим *(абына-сөртенә аның янына йөгереп килә һәм пышылдый).* Бәлки, аны юк итәргәдер, үтерергәдер? Ысуллар күп бит. Беркем беркемнән шикләнмәячәк.

Роберт *(тешләрен шыгырдатып).* Юк! Аның ертылып беткән йөз белән кайтуы гына да инде минем бөтен гомеремә җитәрлек җәза. Тагын зуррак гөнаһка әйдәмә!

Вадим *(күзләрен яман ялтыратып).* Андый кыяфәт белән яшәү ник кирәк?! Ул гомере буе интегәчәк. Без дә котылабыз, ул үзе дә!

Роберт. Син бу уй-ниятеңне башыңнан чыгарып ташла! Котылабыз... Без инде моннан беркайчан һәм берничек котыла алмабыз. Аның үлемендә дә гаепле буласым килми. Болай да муеннан булды бу.

Вадим. Әйдә, алайса, милициягә яки ФСБга шылтыратабыз: шундый-шундый кеше кайтты Чечнядан... террористик ниятләр белән, дип...

Роберт. Бернәрсә дә исбатлый алмасалар? Без хәбәр иткәне дә мәгълүм булса аннары? Тыпырчынма, үзеңне кулга ал, тынычлан!

Вадим *(Робертның битенә якын килеп ысылдый)*. Син дә бит тыпырчынасың. Мин бит күрәм — үзеңә урын таба алмыйсың.

Роберт *(чыраен сытып)*. Минем башым чатный.

Роберт чыгып китә.

Вадим *(Дарья янына килә)*. Мин яратам сине! Мин синең өчен үләргә дә әзер! Мин бит аңа мондый фаҗига теләмәдем. Без бит андый сугыш килеп чыгасын, аның шул сугышка барып эләгәсен белмәдек. *(Калтырана.)* Роберт гаепле... Ул үзенең военкоматтагы абыйсы аша эшләде... Хәзер инде үткән-беткән... Кире кайтарып булмый... Үзгәртү дә соң. Мин синнән башка яши алмыйм. Элек тә яши алмый идем. Ул армиядә хезмәт иткән арада минем хисләремне дөрес бәяләрсең дә мине ярата башларсың дип өметләндем. Зинһар, гафу ит мине! Кем уйлаган болай килеп чыгасын. Без бит синең белән начар яшәмибез. Без синең белән бик якын кешеләр, инде ике ел без — ир белән хатын. Дәваланырсың... балабыз туар. Тормышыбыз үзгәрер. Яңа, башка төрле тормыш башланыр. Артем бу йортта яшәсен. Рәхәтләнеп яшәсен шушында. Без аңа акча белән булышырбыз. Әйдә, иртәгә үк коттеджда тора башлыйбыз. Бөтенләй башка тормыш башлыйбыз, өр-яңа планнар белән!

Дарья *(тыныч һәм үз-үзенә нык ышанып)*. Юк! Мин шушы чормалы, бакчалы йортта калам. Яңа коттеджда яңа хыяллар белән яңа тормыш башларга теләгем юк. Минем теге, элекке якты тормышымны дәвам итәсем килә. Анда чормадан офык күренә, һәм шул тарафта өмет уты балкый. Алма бакчасы гөрләп чәчәк аткан тормышны, алма исле тормышны дәвам итәсем килә минем. Ул дөньяда искиткеч матур итеп миңа исемем белән эндәшәләр. Мин шул тормышны дәвам итәсем килә. Ниһаять, минем синең белән өйләнешкәнчегә кадәр булган тормышымны дәвам итәсем килә.

Вадим өнсез кала. Нишләргә белми. Капкадан атылып чыгып китә. Музыка. Дарья әкрен генә бакча буйлап йөри.

## VI

Чорма. Артем белән Дарья, сигез ел элек утырган шикелле, чорма ишегеннән аякларын асылындырып утыралар. Тирә-якта алтын көз хөкем сөрә.

Артем *(илһамланып)*. Нинди шәп һава! Нәкъ бала чактагы кебек! Алтын көздән дә ямьлерәк чор юктыр.

Дарья *(елмая)*. Синең көзне яратуың мине гаҗәпкә калдыра. Синең кебек кеше язны яратырга тиеш түгел микән?

Артем *(шатлыклы тавыш белән)*. Беренчедән, мин көзгә таба туганмын. Гашыйк икәнемне дә сиңа көз аенда, тугызынчы класста әйттем. Сине беренче тапкыр үбүем дә көз көне булды. Шулай булгач, ничек инде мин көзне яратмаска тиеш?!

Дарья *(якты сагыш белән)*. Синнән мондый якты хатирәләрне ишетергә лаеклымы соң мин, Артем?

Артем. Дашенька! Син үзеңне ни өчендер битәрлисеңме әллә?

Дарья. Битәрләү генәме соң. Миңа хәзер рәхәт кебек булса да, күңелдә газап сыкрый. *(Тамак төбенә төер тыгылгандай итеп.)* Артем... мин сине көттем. Вадимны мин бик озак үземә якын китермәдем. Син югалганнан соң биш ел узгач кына мин аңа артымнан йөрергә, илтифат күрсәтергә рөхсәт бирдем. Бер ел йөрдек. Матур, купшы, зәвыклы ухаживать итте. Ул вакытта да гел сине уйладым мин... Аннары өйләнештек. Менә шулай. Гаебем юк та шикелле. Барыбер пычраклык, гаделсезлек, түбәнлек килеп чыкты. Бәлки, чынлап та, кире китүең дөресрәк тә булыр.

Артем *(гаҗәеп тынычлык белән)*. Син бу кадәр борчылырга тиеш түгел. Бу дөньяда беркем бернәрсәдә гаепле түгел. Шул ук вакытта барысы да гаепле — һәрбер кеше нәрсәдә булса да гаепле.

Дарья *(еламсырап)*. Ачулан инде безне, сүк, хөкем ит, карга! Бәлки, кинәт җиңелрәк булып китәр иде — безгә дә, үзеңә дә.

Артем. Юк, кирәкми. Мин инде хәзер анык беләм: кайчан да булса һәрберебезгә җиңел һәм рәхәт булачак.

Дарья. Монда сиңа бөтен кеше дә чит-ят түгел. Син үз-үзеңне чит итеп тоясың. *(Пауза.)* Хәер, сине бөтенесе саттылар.

Артем. Алай димә. Кешеләрне гаепләргә ярамый. Һәрбер кеше туганда ук гаделсезлек дөньясына килә. Башта ук бөек гаделсезлек салынган. Яңа туган бала аңа кадәр яшәгән кешеләр дөньясына килеп эләгә һәм шунда үсәргә мәҗбүр. Дөньяга килгән бала инде аңарчы төзелгән мохиттә, аңарчы кабул ителгән кануннар, гореф-гадәтләр буенча яшәргә тиеш була. Шул законнар калыплашканда, шул яшәү рәвеше барлыкка килгәндә әле туасы бала дөньяда булмаган. Һәм ул, тугач, шул дөньяда яшәргә дучар ителә, гәрчә ул дөнья аңа ошамаса да. Аның асылы аңарчы кемнәрдер төзегән мохиткә каршы булган сурәттә дә әле ул барыбер җайлашырга һәм үзе килгән дөньяның кануннарын кабул итәргә мәҗбүр. Шуңа күрә кешенең кылган эшләре өчен, ясаган адымнары өчен, хәтта җинаятьләре өчен дә ул үзе генә

җавап тотарга тиеш түгел! Барысы да, барысы да, бөтенебез, бөтен кешелек дөньясы җаваплы! *(Ярсып.)* Барысы да гаепле, барыбыз да гаепле! Яңа туган балага яшәү шартлары әзерләп куючылар да гаепле! Аны тәрбияләүчеләр дә гаепле! Аны төрле вакыйгаларга этәрүчеләр дә гаепле! *(Кинәт тынычланып.)* Аерым бер кеше гаепле була алмый. Шул ук вакытта бөтенесе берьюлы гаепле. Шуңа күрә беркемне дә гаепләргә, хөкем итәргә ярамый.

Пауза.

Дарья *(тыныч кына)*. Син анда кире китәсеңме?

Артем *(шундый ук тынычлык белән)*. Әлбәттә.

Дарья. Әхмәт барыбер сине үтерәчәк.

Артем. Әхмәт мине коткарды — үлемнән алып калды. Шуңа күрә аның мине теләсә кайчан үтерергә хакы бар. Анда сугыш бара — анда үз законнары. Ә монда исә үтерергә хакы булмаган, үтерергә лаексыз кешеләр дә мине үтерә ала.

Дарья. Вадим белән Робертны күздә тотып әйтәсеңме?

Артем. Юк. Аларның хәленнән килә торган эш түгел ул. Мин Әхмәткә кире килермен дип вәгъдә бирдем. Без аңа трактор җыя башлаган идек. Миннән башка ул аны төгәлли алмаячак.

Дарья. Монда сиңа бөтенесе хыянәт иткәнгә китәргә карар кылдыңмы?

Артем. Кешеләр һәрвакыт бер-берсен саталар, хыянәт итәләр. Шуңа бит алар бәхетсез. Ә бәлки, бәхетсез булганга бер-берсен саталардыр.

Дарья. Әйе, син үзеңнең йөзеңне югалтмагансың, Артем. Ә менә кешеләргә ышанычыңны тәмам җуйгансың. Кешеләргә ышанмавың тоткынлыкка кире китүеңнән тыйсын иде, мин хәзер бары тик шуны телим.

Артем. Әгәр дә мин кире чечен авылына бармасам, мин үземне коткарган кеше алдында үз йөземне югалтачакмын. Әлбәттә, үлүем яхшырак булыр иде, бәлки, ләкин аның мине үтертмәве факт буларак зур кыйммәткә ия.

Дарья. Димәк, гомереңне саклап калган кешегә син ышанасың? Син аңа ышанасың... Ә ул сине барыбер үтерә ала...

Артем *(көлеп)*. Ә синдә кешеләргә ышанмау ни сәбәпле шушы кадәр көчле? Каян килде мондый ышанмаучылык?

Дарья *(читкә карап)*. Шуннан ук.

Артем *(ягымлы тавыш белән)*. Даша! Дашенька!

Дарья *(дерелдәп ала)*. Кеше тавышы — аның җан авазы. Синең тавышың шул ук. Димәк, син явызланмагансың, әшәкеләнмәгәнсең. Син элеккеге кебек матур кеше. Син миңа хәзер тагын да якынрак, кадерлерәк. Син миңа хәзер бөтенләй башка төрле якын. Китмә!

Артем. Мин китәргә бурычлы. Ә монда минем бернинди бурычым юк.

Дарья. Монда сине чын күңелдән яратучы кеше бар.

Артем. Ә ирең алдында бурычларың юкмы?

Дарья. Инде хәзер башка кеше алдында нинди бурычларым булсын минем? Юк. Ирем дә юк минем. Мине хәзер бер генә нәрсә куркыта: синең тавышыңны бүтән ишетмәм микәнни? Минем исемемне беркем дә синең кебек әйтә алмаячак.

Артем. Скрипкамны әйбәтләп төреп бир әле.

Дарья. Артем, үтенәм, калдыр скрипкаңны, алып китмә! Әле кайтырсың дип өметләнәсем килә.

Артем. Миңа скрипкам кирәк. Минем кайтуым да бит... анамның каберенә баш ияргә һәм скрипкамны алып китәргә дип...

Дарья *(боегып)*. Ә мине күрәсең килмәгән идеме?

Артем. Башта минем сиңа күренәсем килмәде. Синең каршыңа гарип чырай белән килергә курыктым. Чормадан скрипканы гына алмакчы идем. Сез бакчада туган көнеңне уздырып яткан көнне мендем мин чормага. Чормадан төшәргә җитешмәдем — сез табын әзерли башладыгыз, аннары кунаклар килде. Шунда качып утырырга, сезнең бәйрәм иткәнне күзәтергә мәҗбүр булдым. Түзмәдем, берничә тапкыр сиңа эндәштем. Бик сагындым сине. Сине күргәч, чак кына чормадан сикереп төшмәдем, көчкә тыйдым үземне. Ә скрипканы мин ул көнне чормада тапмадым.

Дарья. Мин аны яшереп куйдым. Карале, син бит миңа чормадан берничә көн рәттән эндәштең, шулаймы?

Артем *(күзләрен йома)*. Хәзер, искә төшерәм. Сез бакчада бәйрәм иткән көнне... Аннары, шул синең янга чыккан көнне. Мин бит скрипкамны эзләргә тагын килдем. Исәнме соң минем скрипкам?

Дарья. Исән. Ә башка көннәрне синең тавышың ишетелгән кебек тоелган гына микәнни?

Артем. Шулайдыр. Минем кайдадыр якын-тирәдә икәнемне сиземләгәнсеңдер.

Дарья. Зиратта яшәдеңме?

Артем. Әйе.

Дарья. Ник баштук күренмәдең?! *(Елый.)*

Артем. Даша! Дашенька! *(Аның тавышы шактый вакыт кайтаваз булып яңгырап тора.)* Алып кил скрипкамны.

Дарья *(канатланып)*. Уйныйсыңмы?!

Артем. Уйныйм.

Дарья чорманың түр почмагыннан скрипканы алып килә. Артем скрипканы алып көйли башлый.

Дарья *(күз яшьләрен сыпырып).* Мандолинаны көйләгән кебек көйлисеңме?

Артем. Әйе. Скрипка настройкасын тәки өйрәнә алмадым.

Дарья *(елмая)*. Булса ни! Барыбер матур яңгырый бит.

Артем моннан сигез ел элек чыгарган көен уйный. Дарья таң калып тыңлый.

## VII

Алма бакчасы. Дарья белән Нэлли янәшә утыралар. Сөйләшмиләр. Сулып барган алтын көзнең сихри тавышлары гына ишетелгәләп куя.

Дарья. Коньяк-мазар эчәсең килмиме?

Нэлли *(сискәнеп).* Ой, юк, миңа ярамыйдыр!

Дарья *(аның ягына карамыйча гына).* Ник алай?

Нэлли *(паузадан соң)*. Мин балага уздым. Син үзең эч.

Дарья. Миңа да ярамыйдыр. Мин дә бит йөкле.

Ялгыз скрипка көе яңгырый. Алар, шактый вакыт бер сүз дәшми, каядыр еракка карап утыралар.

Нэлли. Бәхетле иттеме ул безне, әллә җәза бирдеме?

Дарья. Икесе дә бар.

Нэлли. Бигрәк сәер: чынлап та, бәхет белән хәсрәт гел янәшә йөриләр.

Дарья. Чиксез бәхеттән кеше үлеп китмәсен өчен шулай ул. Кайгысыз ничек бәхетле була алсын ди кеше!

Нэлли. Мин Роберт белән, бәлки, алга таба да яшәр идем... Мин бит инде аны күптән беләм... Тик менә Артемны күргәч... Ничек инде бергә яши алыйк хәзер?..

Дарья. Нишләмәкче буласың?

Нэлли. Әти-әни янына кайтам яшәргә.

Дарья. Ник элегрәк сөйләмәдең аларның кабахәтлеге турында? Кирәкмәгәндә син телеңне тыймыйсың, кирәк чакта бер сүз тартып алып булмый синнән.

Нэлли. Сөйләргә базмадым. Хәлемнән килмәде.

Дарья. Хәер, хәзер казынудан ни мәгънә... Ләкин син барыбер стерва! Һәм без барыбыз да — адәм актыклары!

Нэлли. Мин синең белән килешәм.

Скрипка уйный.

Дарья *(хыялланып)*. Минем малай туачак. *(Пауза.)* Улын күреп ул чиксез куаначак.

Нэлли. Ә ул кайтырмы соң?

Дарья. Һичшиксез кайтачак.

Нэлли. Ник алай ышанычлы итеп әйтәсең?

Дарья. Чөнки ул скрипканы үзе белән алмады. Калдырды. Димәк, кайтачак. Ә улым әтисе кебек үк скрипкада уйнаячак. Скрипканы мандолина кебек көйләячәкбез.

Нэлли. Нигә мандолина кебек?

Дарья. Чөнки алай моңлырак яңгырый.

Нэлли. Алай икән.

Дарья. Кайткач, ул миңа исемем белән эндәшәчәк. Шул чагында бәхеттән йөрәгем ярылмаса ярар иде. Улы үзенә охшаганны күргәч таң калачак. Тач ул булачак инде менә! Коеп куйган әтисе! Улым нәкъ әтисе кебек ягымлы, тирән тавышлы, нәкъ әтисе шикелле якты, матур йөзле булачак!

Музыка.

Тәмам.

*2003*

# КИЛӘ ЯВА, КИЛӘ ЯВА...

*(Ике пәрдәле комедия)*

КАТНАШАЛАР:

Сәҗидә — 35—40 яшьләрдәге хатын.
Фәндәс — Сәҗидәнең ире, 40—45 яшьләрдә.
Шәйхи — сантехник, 40—45 яшьләрдә.
Рәшит — 40—45 яшьләрдәге бизнесмен.
Зәйнәп — Фәндәснең сөяркәсе, 25—30 яшьләрдә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәҗидәләр фатиры. Сәҗидә өй җыештыра. Телефон шылтырый.

Сәҗидә *(трубканы алып).* Алло... Әйе, мин. Юк, танымадым. Рәшит?.. Ә-ә-ә, теге, кафеда танышкан идек... Хәтерлим, исемә төште. *(Көлә.)* Инде ул гомердән бирле. Ярты ел узды түгелме соң... Әй, сез ирләр гел шулай инде. Ә үзегез мине искә алдыгызмы соң? Шулаймы... Сез, Рәшит, кызык кеше икәнсез... Чынлапмы? *(Көлә.)* Ышанмыйм. Юк, юк, мөмкин түгел. Нишләп дип... Иң беренче сәбәп — минем ирем бар. Туктале, нишләп ярты елдан соң шылтыратырга булдыгыз? Ә-ә-ә-ә, шулаймыни, чит илләргә командировкага йөрисезмени... Юк, юк, мөмкин түгел. Очрашып сөйләшергә?.. Юк, юк. Ә мин сезнең телефон номерыгыз язылган кәгазьне югалттым. Мин бит ирдәге хатын. Ярый, телефон номерыгызны язып алам, бик янансу вакытта, бәлки, шылтыратырмын... сөйләшергә кеше булмаганда. Әйе, ялгыз чагымда. Утыз ике, ундүрт, сиксән биш. Бу өй телефоныгызмы? Ярый. Болай начар түгел шикелле. Чит илләргә йөрүченеке кебек булмаса да, түзәрлек инде. Зарланыр урын юк. *(Ишек кыңгыравы зеңгелди.)* Гафу итегез, безгә кемдер килде. Ярый, сау булыгыз. Вәгъдә итмим, күз күрер. Сау булыгыз!

Зур чемодан күтәреп, Фәндәс кайтып керә.

Фәндәс. Өйдәме син, юкмы? *(Чемоданын идәнгә ташлый.)* Уф, көч-хәл белән менеп җиттем. Лифт эшләми. Исәнме, карчык. *(Кочакларын җәеп елмая һәм хатынына таба атлый.)*

Сәҗидә *(салкын гына).* Исәнме!

Фәндәс. Әллә шат түгел инде син минем кайтуыма... *(Хатынын кочаклап үбә.)*

Сәҗидә *(иренең кочагыннан шуып чыга һәм сынаулы караш ташлый).* Мин синең кайтуыңа, бәлки, шатмындыр да, ләкин үзең уйлап кара: кайсы хатын ире ял йортына киткәч, үзе генә шатланып утырыр икән?!

Фәндәс. Шулай килеп чыкты бит. Мин бит сиңа әйттем, отпуск ал, дип.

Сәҗидә. Отпускымның җәй ахырында гына буласын бик яхшы белә идең ләбаса.

Фәндәс. Мөмкинлекне ычкындырмаска булдым инде, үзең дә шулай дидең бит.

Сәҗидә. Сез ирләр гел шулай, мөмкинлекләрне бер дә ычкындырмыйсыз. Бәлки, сине сынап карар өчен генә ризалык белдергәнмендер?!

Фәндәс *(ачуы кабара башлый).* Туктале, кайтып керүемә ташланма миңа! Мин бит сине сагынып кайттым.

Сәҗидә *(киреләнеп).* Анда сагынырга бигүк ирек бирмәгәннәрдер.

Фәндәс. Ни сөйлисең соң син! Менә сиңа бүләк алып кайттым. *(Төргәк алып бирә.)*

Сәҗидә *(бик исе китмәгән кыяфәт белән бүләкне ала).* Рәхмәт.

Фәндәс. Икенчесендә бергә барырбыз, яме.

Сәҗидә *(йөзе тагын да ныграк караңгылана).* Бармыйм мин синең белән беркая да!

Фәндәс *(тавышын күтәреп).* Ярар инде, нәрсә бала-чага сыман киреләнәсең!

Сәҗидә *(ярсып кычкыра).* Бала-чага сыман? Үзең мине бала-чага урынына күргәч! Җәй уртасында хатынын ташлап китсен дә...

Фәндәс. Шулай килеп чыкты бит инде...

Сәҗидә. Кешеләрдән дә оят.

Фәндәс *(үзен кулга ала һәм хатынын да тынычландырырга ниятли).* Карале, карчык, исән-сау кайтып җитүемә, синең исән-имин торуыңа куанырга кирәк.

Сәҗидә. Ай теле. Төчеләнергә оста да инде шушы ирләр!

Фәндәс *(кочакламакчы була).* Тукта инде, карчык! Бик сагындым үзеңне.

Сәҗидә *(ирен этә).* Кит әле, кит.

Фәндәс *(кинәт кырыслана).* Ярар. Бик матур каршы алдың. Рәхмәт. Киттем мин.

Сажидә *(күзләрен чекерәйтеп).* Кая киттең?

Фәндәс *(чыгып китәргә җыена).* Әнидә кунам бүген. Тынычлан башта. Аннары кайтырмын. Бераз сүрел.

Сажидә *(кыжрап).* Бөтенләй кайтмасаң да була! Оятсыз!

Фәндәс *(тыныч кына).* Чемоданда күчтәнәчләр... сиңа.

Сажидә. Кирәк түгел! *(Чемоданга китереп тибә.)*

Фәндәс чыгып китә, Сажидә диванга капланып елап кала. Торып әрле-бирле йөри башлый. Иренең чемоданын актара. Аннан матур кофта ала, затлы коньяк, берничә кап кәнфит чыгара. Аптырап утырганнан соң телефоннан шылтырата.

Сажидә. Алло, Рәшит, сезме? Бу мин, Сажидә. Бик аптыраушта калдыгызмы? Юкмы... Мин бүген үк шылтыратырга булдым әле сезгә. Мин бит ялгызым чакта шылтыратырмын дигән идем. Менә бүген мин коточкыч ялгыз. Сөйләшеп утырыр кешем дә юк. Ирем?.. Ул әнисенә китте. Ял йортыннан кайтты да әнисенә кунарга китте. Юк, сез үзегез миңа килегез. Дуслык урамы, утыз икенче йорт, егерме беренче фатир. Көтәм. *(Трубканы куя. Аптырашта калып ары-бире йөрергә тотына.)* Җүләр мин, җүләр! Нишлим мин? Минме соң бу? *(Барып көзгедән каранып тора.)* Кадалып китсен лә!

Сажидә кинәт катгый карарга килә һәм Рәшит килүенә әзерләнә башлый — киенә, бизәнә, ясана. Шул ук вакытта үзе капма-каршылыклы уйлар белән бимазалана. Бервакыт ишек кыңгыравы зеңгелди. Сажидә сискәнеп китә, Рәшит килде дип бик нык каушый. Ләкин, аны тагын да ныграк котсыз калдырып, бусагада ире Фәндәс пәйда була.

Фәндәс *(читенсенеп).* Мин... ни... ачкычымны онытып калдырганмын.

Сажидә *(үзен кая куярга белми).* Соң, ачкычыңны ал да инде, бар, чыгып кит.

Фәндәс *(бик каты борчылып).* Туктале, ачкычтамыни хикмәт! Без бит инде синең белән шактый гомер иткән кешеләр. Шырт-пырт итеп бер-беребезне бимазаларга безгә бит уналтышар яшь түгел!

Сажидә *(иренең кире кайтуыннан бик нык каушый, Рәшит менә-менә килер дип куркып, ни әйтергә дә белми таптанып тора).* Үзең гаепле.

Фәндәс. Зинһар, үзеңне кулга ал. Гаепле, гаепле... Атта да, тәртәдә дә бардыр инде, кем әйтмешли. Әгәренки гаеп миндә күбрәк дип санасаң, гафу ит.

Сажидә *(бер чарасыз кала һәм ирен гафу итәргә теләсә дә аны тизрәк чыгарып җибәрергә тырыша).* Бар, әниеңдә кун бүген. Иртәгә тынычлап сөйләшербез.

Фәндәс. Ирем берүзе ял йортында булды дип гаилә таркатмыйлар инде. Улыбыздан оят. *(Уйга калып.)* Янына барып кайтырга кирәк булыр.

Сажидә. Менә бит, кайтып җитү белән Казанга барырга сәбәп тә таптың.

Фәндәс. Ярар инде, ә! Гел таларга гына торма инде! Улымны сагындым.

Сажидә. Аны Казанга олактыруда да син гаепле.

Фәндәс. Укысын, укысын. Казан Казан инде ул. Бөтен зур кешеләр иң элек Казанда белем алдылар. *(Ишек кыңгыравы зеңгелди, Сажидә бөтенләй коелып төшә.)*

Фәндәс. Кем икән бу?

Сажидә *(бик нык каушый).* Бу кем... ни... Мин хәзер аңлатам.

Сүзен әйталмый кала, иңенә ачкычлар, шланглар һәм тимер-томыр тутырган иске сумка асып сантехник Шәйхи килеп керә.

Шәйхи. Исәннәрмесез!

Фәндәс. Исәнмесез!

Шәйхи *(горур кыяфәт белән һәм кылануын яшермичә).* Мин сантехник Шәйхетдин булам. На правительственном уровне сөйләшкәндә Шәйхулла, ә хатын-кыз өчен просто Шәйхи. Сезнең сантехникагызны карыйсы бар икән, имеш.

Фәндәс. Вакытсызрак килдегез, ә шулай да килүегез әйбәт. Безнең рәтлисе нәрсәләр байтак монда.

Шәйхи *(фатир эченә уза һәм бармагын зур мәгънә белән өскә күтәрә).* Сантехникның килүе беркайчан да вакытсыз булалмый. Бигрәк тә үзегез чакырткач.

Фәндәс. Без бит инде ярты ел элек ЖЭКка шылтыраткан идек, сантехник җибәрегез, дип.

Шәйхи. Менә бит килдем. *(Фәлсәфи кыяфәт белән.)* Сантехникның аның кайчан килүе түгел, ә бәлки, гомумән килүе хәерле. Озак көткән нәрсә кадерлерәк була ул. Озак көткән, нык теләгән нәрсә барыбер кайчан да бер килми калмый. Сантехник та барыбер килә ул. Дөньяда сантехник килми калган фатир бар микән? Мөгаен, юктыр. Димәк, сантехникның килеп керүе — ул ниндидер котылгысызлык. Мәхәббәт килүе сыман. Язларның һичшиксез җитүе, сыерчыклар кайтуы шикелле. Туу һәм үлем кебек, ниһаять. Мин килдем! *(Шулай сөйләнә-сөйләнә коралларын әзерли һәм эшкә керешә.)*

Сажидә *(үзен кая куярга белми).* Син, Фәндәс, әниеңә бармыйсың булып чыгамыни?

Фәндәс. Сантехник килгәч, беркая да барып булмый инде.

Шәйхи. Хуҗа, кил, синсез булмый монда. *(Шәйхи ванна бүлмәсендә һәм туалетта казына башлый, Фәндәс аның янына китә.)*

Сажидә *(нишләргә белми үзалдына мыгырдана)*. Нинди җүләрлек эшләдем бит, ә! Хәзер килеп керсә, бетте баш. Урамга чыгып каршы алырга кирәк. *(Чыгарга җыена.)*

Кулына чәчәк бәйләме тотып һәм шампан шәрабы күтәреп бусагада Рәшит пәйда була. Өстендә кура җиләге төсендәге пинжәк, муенына шактый калын алтын чылбыр таккан, бармагына алагаем зур итеп эшләнгән алтын йөзек кигән.

Рәшит *(авызы ерык, күзләре мут)*. Исәнме, Сажидә! *(Шундук түргә уза.)*
Сажидә *(өзгәләнеп)*. Ирем кайтты, чыгып китегез тизрәк!
Рәшит *(ишеккә таба юнәлеп)*. Үзең чакырдың бит.
Фәндәс *(туалеттан чыга һәм кунакны күреп ала)*. Сез кем?
Рәшит *(ни әйтергә белми)*. Рәшит!
Сажидә *(нык каушый)*. Ул теге сантехникның иптәше. *(Рәшиткә.)* Безгә сантехник килде... Сез бит шуның янына дип кергәнсездер?
Рәшит *(югалып калмый)*. Әйе, мин аларның участок начальнигы. Мондамы ул?
Сажидә. Монда, монда, әйдәгез, узыгыз бәдрәфкә.
Рәшит. Рәхмәт. Килү белән бәдрәфкә узарга кушкач әллә ничек, әлбәттә. *(Сантехник янына бара.)*
Фәндәс *(Сажидәгә)*. Нишләп соң ул чәчәкләр тотып йөри?
Рәшит *(ишетеп ала)*. Сантехниклар начальнигы торба күтәреп йөрергә тиешмени?! Бер йортны су баскан иде. Шуларны коткардык. Чәчәкләрне шунда бирделәр. Тә-ә-ә-к, ничек эшләр, барамы?
Шәйхи *(бәдрәфтән чыга)*. Бара.
Рәшит *(үтә җитди кыяфәт белән)*. Әйдә, озакка сузма, әле тагын берничә фатирга барасы бар бүген.
Шәйхи *(аптырап)*. Минем бүген бүтән беркая да барасым юк. Син нәрсә минем белән командовать итәсең?
Рәшит *(тыныч кына)*. Чөнки мин синең участок начальнигың.
Шәйхи. Безнең участок начальнигы Тәлгать Бариевич...
Фәндәс *(пошаманга калып)*. Тәлгать Бариевич, ди...
Рәшит. Мин — начальник участка. Кем ул Тәлгать Бариевич? Кайда ул?
Шәйхи. Аны узган атнада бүлнискә салдылар. Үпкәсенә салкын тигән.
Рәшит. Үлде ул.
Шәйхи *(күзләрен акайтып)*. Үлде?! *(Хәлсезләнеп китә.)* Ул миңа фатир вәгъдә иткән иде.
Рәшит. Үләр вакыты җиткән кеше синең фатир аласың бар дип үлемен кичектерә алмый инде ул. Ә бәлки, сиңа фатир бирмәс өчен ычкынгандыр. Хәзер мин синең участок начальнигың.
Шәйхи *(бу хәбәрдән һушына килә алмый утыра)*. Их, Тәлгать Бариевич, Тәлгать Бариевич... Минем аңа утыз мең бурычым да бар иде әле.
Рәшит. Теге дөньяда бирерсең. Ярар, син монда озак тоткарланма. Мин сине ЖКУда көтәм. *(Чыгып китмәкче була.)*
Фәндәс. Сез сантехниклар начальнигы булгач, әйдәгез, утырып чәй эчик. Без сезгә хәзер еш мөрәҗәгать итәрбез, ахрысы, чөнки саноборудование бик иске бит инде безнең. Мин бүген генә ял йортыннан кайтып төштем.
Рәшит *(авызын кыйшайтып, үзалдына)*. Мин моңа бик шатмын.
Фәндәс. Бик шәп коньяк алып кайттым. Әйдәгез, авыз итәрсез.
Рәшит *(Шәйхигә)*. Эшең күпме әле?
Шәйхи. Байтак.
Рәшит. Эшлә. Ашыкма. *(Өстәл янына утыра.)* Коньяк начар нәрсә түгел инде ул.
Фәндәс. Сажидә, нәрсә катып калдың, капкаларга берәр нәрсә әтмәллә.
Сажидә *(кабаланып өстәлгә ризык ташый)*. Хәзер, хәзер.

Өстәл янына утырыша башлаганда гына ишек кыңгыравы зеңгелди. Зәйнәп керә.

Зәйнәп *(мөлаем елмаеп)*. Исәнмесез!
Сажидә. Исәнмесез! *(Зәйнәпне башыннан аягына кадәр җентекләп күзәтә.)* Сез дә сантехникларның берәр бухгалтеры түгелдер бит?
Зәйнәп *(аптырап кашларын күтәрә)*. Ник алай дисез? Исәнме, Фәндәс!
Фәндәс *(шаккатып)*. Исәнме!
Зәйнәп *(түргә уза, сумкасын диванга ташлый)*. Син нишләп миңа әйтмичә кайтып киттең?! Мин бит сине югалттым.
Фәндәс *(торып кыбырсый башлый)*. Сажидә, кызарга ашыкма. Бу — Зәйнәп.
Сажидә *(яман усал итеп)*. Шуннан?
Фәндәс *(Сажидә тирәсендә бөтерелеп)*. Курортта бергә ял иттек.
Сажидә. Рәхмәт.
Зәйнәп *(Сажидәгә)*. Исәнмесез!

Сажидә *(нәфрәт белән карап).* Сәлам!

Зәйнәп *(берни булмагандай елмаеп).* Сез миңа алай кырыс карамагыз. Без Фәндәс белән бер-беребезне яратабыз.

Фәндәс *(кемгә эндәшергә белми).* Зәйнәп! Сажидә!

Рәшит *(аягын аякка атландырып киерелеп утыра).* Кызык икән сезнең монда. Күптән мондый компанияләрдә булганым юк иде.

Сажидә. Йә, йә, чибәркәй, тыңлыйбыз.

Фәндәс. Сажидә, туктале. Зәйнәп, син ник килдең?

Зәйнәп. Беренчедән, миңа әйтмичә кайтып китүең пошаманга калдырды. Икенчедән, шул арада сине сагынырга да өлгердем. Өченчедән... нәрсә санап торам соң мин... Гомумән, синнән башка яши алмыйм.

Сажидә *(тәмам аптырашта калып).* Син тилеме әллә?

Зәйнәп. Сез нишләп минем белән дорфа сөйләшәсез? Фәндәс, нишләп мине якламыйсың?

Сажидә *(кычкырып).* Кем бу?

Фәндәс *(башын аска иеп).* Ял йортында танышкан идек.

Сажидә. Танышсагыз... Танышкан кешенең йортына ияреп кайту мәҗбүримени хәзер?

Зәйнәп. Без бер-беребезне яратабыз, шулай бит, Фәндәс.

Фәндәс *(кырт кисеп).* Юк!

Зәйнәп *(күзләрен акайтып).* Ничек инде «юк»?! Яратам дип антлар иткәнеңне, нинди вәгъдәләр биргәнеңне онытттыңмыни? Син нәрсә, мине алдадың гына мәллә? Юк, юк, синең башың гына бераз буталгандыр. Безгә бит чиксез рәхәт булды, без бит бер-беребезне күрмичә бер сәгать тә тора алмый идек.

Фәндәс *(кычкырып).* Юк! Юк! Юк! Ник килдең син монда?!

Зәйнәп. Ничек инде «ник килдең»?.. Син бит әле әйткән идең, мәңге бергә булачакбыз, дип. Ә хәзер инде ник килдең дисең!

Сажидә. Үләм, оят, хурлык! *(Чыгып йөгерә.)*

Фәндәс. Сажидә, туктале! *(Хатыны артыннан чыгып китә.)*

Зәйнәп *(өстәл янына утыра, авыр сулап куя).* Болай килеп чыгар дип уйламаган идем.

Рәшит *(шампан шәрабын ачып сала).* Син, чибәркәй, чынлап та ял йортыннанмы, әллә җүләрләр йортыннан гынамы?

Зәйнәп *(Рәшитнең бокалын ала һәм эчеп куя).* Моны мыскыл итү дип аңларгамы, әллә комплимент дип кабул итәргәме?

Рәшит. Син моны мактау сыманрак кабул ит инде.

Зәйнәп *(ачу белән).* Рәхмәт.

Рәшит. Киявең булсын Нуриәхмәт.

Зәйнәп. Нишләп сез минем белән ирониялe сөйләшәсез?

Рәшит *(бераз алга таба сузылып).* Чөнки ошыйсың син миңа.

Зәйнәп *(башын күтәрә төшеп).* Мин бик күпләргә ошыйм.

Рәшит *(үзенә дип шәраб сала, Зәйнәп аны тагын алып эчеп бетерә.)* Син Фәндәснең сөяркәсеме чынлап та?

Зәйнәп *(горур кыяфәт белән).* Әйе.

Шәйхи. Ачкычларым калып торсын. Краннарны япмый торыгыз. Мин тиз генә ЖКУга барып киләм.

Рәшит. Бар, бар, әбрәкәй сандугачы. Болай да һава начар монда. *(Шәйхи чыгып китә.)*

Зәйнәп. Ә сез кем буласыз?

Рәшит. Кем дип әйтим икән... Әлегә беркем дә түгел.

Зәйнәп. Фәндәснең туганы түгелме?

Рәшит. Җитешеп булмады әле. Чак кына баҗасы булмый калдым.

Зәйнәп. Ничек инде?

Рәшит. Карале, син берәр аквариумда яшәдеңме әллә моңарчы?

Зәйнәп. Юк, ник алай дисез?

Рәшит. Болай гына. Балык исе килеп киткәндәй булды.

Хәлдән таеп Фәндәс кайтып керә.

Фәндәс. Их Зәйнәп, Зәйнәп. Тормышның астын өскә китердең бит.

Зәйнәп. Бу синең хатының иде мәллә?

Фәндәс *(кыжрап).* Юк, сантехникның хатыны иде.

Зәйнәп. Ул нинди хатын иде соң?

Фәндәс *(кычкырып).* Минем хатыным иде! Ник килдең син монда?

Зәйнәп *(шаккатып).* Ничек инде ник килдем... Синең яныңа. Үзең бит миннән башка яши алмыйм дигән идең.

Фәндәс. Син бит минем гаиләм барлыгын бик яхшы беләсең!

Зәйнәп. Миңа әйтми-нитми кайтып киткәнеңне белгәч, бик борчылдым. Миңа үпкәләгәнсеңдер дип уйладым. Гомумән, аннары әллә ниләр уйлап бетердем. Мин сине бик сагындым. *(Барып кочаклый.)*

Фәндәс *(муенынннан аның кулларын алып ташлый).* Туктале, Зәйнәп. Уф, әйдә бераз коньяк эчик әле. *(Рәшиткә.)* Гафу итегез, сезнең исемегез ничек?

Рәшит. Рәшит.

Фәндәс. Мин Фәндәс булам. (*Рюмкаларга коньяк сала.*) Ә теге сантехник кайда?

Рәшит *(рюмканы ала).* Мин аны ЖКУга җибәрдем. Хәзер килер. Әйдә, туган, борчылма, мондый гына матавыклар килеп чыккалый инде ул. *(Зәйнәпкә ымлап.)* Мондый тавык-чебешләр бар чагында буталчыкларның бетәсе юк.

Зәйнәп *(канәгатьсезләнеп).* Сез әллә ничек сәер сөйләшәсез минем белән.

Рәшит *(коры гына).* Әле синең белән сөйләшүче дә юк. *(Эчеп куя.)*

Зәйнәп. Фәндәс, нишләп ул минем белән дорфа сөйләшә?

Фәндәс. Сөйләшсен. Чөнки ул сантехниклар начальнигы.

Рәшит *(рюмканы күтәреп).* Очрашуыбызга бик шат. *(Эчәләр.)* Нишлисез инде хәзер?

Фәндәс. Зәйнәп, син кичекмәстән китәргә тиеш.

Зәйнәп. Юк, мин синнән башка беркая да китмим.

Фәндәс. Мин үзем синең яныңа барырмын.

Читкә алып китеп нәрсәдер аңлата, күрше бүлмәгә кереп китәләр.

Рәшит *(көлә).* Кызык бу дөнья.

Сантехник килеп керә.

Шәйхи *(Рәшит янына килеп баса, карап тора).* Син нишләп алдадың?

Рәшит. Кемне?

Шәйхи. Тәлгать Бариевич исән. Ул — безнең начальник. Син түгел.

Рәшит *(утырган җиреннән генә Шәйхине түшеннән йомарлап тота һәм тешләрен шыгырдата).* Син, әбрәкәй сандугачы, күп сөйләшмә. Сиңа барыбер түгелмени — кем нәчәлник. Унитазга башың белән тыгып куюым бар, шуңа күрә мине үзеңнең нәчәлнигең диген. *(Янына тартып утырта.)* Ярар, ярар, курыкма. Мә сиңа. *(Шәйхинең түшендәге кесәгә акча тыгып куя.)* Саласыңмы бераз?

Шәйхи. Салам, әлбәттә. *(Рәшит коньяк сала, Шәйхи шундук эчеп куя.)*

Рәшит. Бар, эшлә!

Шәйхи. Ярый, рәхмәт. *(Туалетка китә.)*

Фәндәс белән Зәйнәп икенче бүлмәдән чыгалар.

Фәндәс *(Зәйнәпне иңеннән кочып).* Мин сине хәзер вокзалга кадәр озатып куям, билет алып бирәм, утыртып җибәрәм.

Зәйнәп *(еламсырап).* Фәндә-ә-ә-с!..

Фәндәс *(өзгәләнеп).* Матурым, мин атна азагында үзем киләм синең яныңа. *(Шәйхигә эндәшә.)* Сезнең эшегез күпме әле?

Шәйхи *(ванна бүлмәсеннән кычкырып җавап бирә).* Ике-өч сәгатьлек.

Фәндәс. Алайса, сез эшли торыгыз. Мин хәзер әйләнеп кайтам. *(Рәшиткә.)* Сез дә китми торыгыз. Зәйнәпне озатып киләм. Китми торыгыз.

Рәшит. Китмим. Сантехник эшен тәмамламыйча беркая да китмим.

Фәндәс белән Зәйнәп чыгып китәләр.

Рәшит. Әй, җан көеге! Кил, берәр рюмка тотып куй.

Шәйхи *(килеп утыра).* Син нишлисең соң монда? *(Эчәләр).*

Рәшит. Бернишләмим. Юлым уңмады әле бүген. Күрәсеңме, нинди матавыккилеп чыкты.

Шәйхи. Һи-и-и, матавык мондый булмый ул. Пүчтәк бу. Мин күп фатирларда булган кеше, әллә нинди кәнитилләр күргәнем бар. Мин синең ни сәбәп белән монда йөрүеңне аңладым.

Рәшит. Бүгенге заманда бик күп аңлау ярамый.

Шәйхи. Мин үземә тиешлесен генә аңлыйм.

Рәшит. Син озаграк маташ, яме. *(Сантехникның түш кесәсенә тагын акча тыгып куя.)* Миңа монда озаграк торырга сәбәп кирәк.

Шәйхи *(бераз исерә).* Мин ул хатынны бәреп үтерер идем.

Рәшит. Мин аның Фәндәсен дә бәреп үтерер идем әле...

Еш-еш сулап Саҗидә кайтып керә. Шәйхи туалетка кереп китә.

Саҗидә. Кайда теге кабахәтләр?

Рәшит *(авызын кыйшайтып).* Минемчә, алар кире ял йортына китеп бардылар, ахрысы.

Саҗидә *(диванга салынып төшә).* Күңелем сизгән иде аны...

Рәшит. Төкер. Андый хыянәтче ир сиңа лаек түгел. Әйдә минем белән.

Саҗидә. Кая?

Рәшит. Минем бу шәһәрдә дүрт фатирым бар. Кайсына телисең, шунда барабыз. Берсе Химиклар урамында, икенчесе Мурадьяна урамында, өченчесе Бызов урамында, дүртенчесе... м-м-м-м... карале, фамилиясен онытканмын... Анысы да беркем белми торган фамилия инде... Татар кешесе... Ярар, кадалып китсен. Әйдә минем белән. Стрессларыңны бетерермен.

Саҗидә. Мин беркая да бармыйм. Мондый хурлыкны күтәреп йөри алмыйм мин.

Рәшит. Нинди хурлык! Була торган хәл. Үтереш-суеш юк. Үлүче-мазар күренми.

Саҗидә. Бу хурлыкны күтәргәнче үлүең яхшырак түгел микән?!

Рәшит. Төкер. Әйдә минем белән. *(Кочакламакчы була.)*

Саҗидә. Кит әле, кит.

Рәшит. Үзең чакырдың бит.

Саҗидә. Чакырасым килеп чакырмадым мин сине.

Рәшит. Алай булмый инде. Менә тотармын да ireңә әйтеп бирермен кем икәнемне, ничек монда килеп эләккәнемне.

Саҗидә. Сез ирләрдән әллә ниләр көтәргә була.

Рәшит. Кайгырма. Ял йортында сау-сәламәт ир тик ятмас инде ул. Аңа ачу итеп икебез гөжләтеп алыйк.

Саҗидә. Ярар. Рәшит, тыңла, мин бераз хәл алыйм, башымны рәткә кертим. Аннары сиңа үзем шылтыратырмын.

Рәшит. Ярый алайса, син кайчан шылтыратасың соң?

Саҗидә. Бүген.

Рәшит. Ярар, көтәм. *(Саҗидәнең кулын үбә һәм чыгып китә.)*

Саҗидә *(нишләргә белми, фатир буйлап йөри).* Нәрсә соң бу? Төшме бу, өнме?!

Фәндәс кайтып керә.

Фәндәс *(гаепле кыяфәт белән).* Саҗидә!

Саҗидә *(җирәнеп башын читкә бора).* Менә, үзеннән-үзе исбатланды.

Фәндәс. Гафу ит мине. Кичер. Ихтыярың, теләсәң нишләт.

Саҗидә. Һе, нишләтә алам мин сине? Аерылабыз да, вәссәлам. Шунысы бар — улыбыздан оят.

Фәндәс. Саҗидә, ашыкма. Тормышта әллә ниләр була. Кичер мине. Мин синнән башка яши алмыйм.

Саҗидә. Сайра, сайра. Менә күрсәттең бит инде.

Шәйхи *(эшен ташлап карап тора).* Бәлки, миңа башка вакытта килергәдер... Монда эш байтак әле.

Саҗидә. Үзеңә кара. Ник бездән сорыйсың?

Шәйхи. Юк, мин гаилә матавыкларына комачауламыйм дип кенә әйтүем.

Саҗидә. Син безгә комачауламыйсың. Ашыйсың киләме?

Шәйхи. Минем гел ашыйсым килеп тора.

Саҗидә. Әйдә утыр.

Шәйхи *(өстәл янына килеп утыра, шундук ашарга тотына).* Рәхмәт, бигрәк тәмле. *(Тончыгып ала.)*

Саҗидә. Әнә коньяк, салып эч. *(Шәйхи үзе салып эчә. Тагын ашый. Бераз исерә.)*

Шәйхи *(ашый-ашый).* Маегызга чыдый алмыйсыз. Минем шкурада яшәп карасагыз иде сез. Мин бит инженер. Дипломымны ярты миллионга саткан кеше мин. Кайчандыр КХТИ тәмамлаган идем, механический факультетны. Сокращениегә эләктем.

Фәндәс. Дипломыңны ник саттың соң?

Шәйхи. Акча кирәк булды да. Хатын үтерә язды бер турны, акча эшлә, дип. Каян алыйм мин акча — заводтан чыгардылар, урлый белмим, таларга йөрәк җитми. Мин ярый әле хет ярты миллионга саттым. Минем белән бергә укыган Хәмит дипломын дүрт ваучерга алыштырган булган. Тинтәк! Чубайска инде кырыкка якын хат язып җибәргән. Ни җавап килми, ди, ни акча җибәрмиләр икән. Хәмитнең ерунда. Технологический факультетта укыган бер танышым бөтенләй дөнья куйды. Дипломын базарда алты банка тушенкага алыштырган булган. Шул тушенка белән агуланып үлде. Кырык сигезенче елгы тушенка булган. Мәрхүм үзе дә кырык сигезенче елгы иде. Менә хәзер сантехник булып эшлим. Шунысы әйбәт — кеше арасында. Кеше арасында ачка үлмисең инде ул. Хатын гына көнләшә. Төс-битең матурланып китте, ди, рәхәт эшкә күчтең, хатын-кыз белән фатир саен

шаярасыңдыр, шуңа тамагың туктыр синең, ди. Ач булсаң да яратмый, тук булсаң да битәрли. Сезгә ни җитми соң?

Фәндәс. Миңа бик уңайсыз шушындый хәл килеп чыгуына. Җитмәсә, чит кешеләр алдында.

Саҗидә *(елый).* Минем борчылуларым, нервылануларым тикмәгә булмаган икән бит.

Фәндәс *(ярсып).* Туктале син! Синдә генәмени нервы! Инде теңкәмә тидең бит соңгы вакытта! Ник талыйсың син мине?!

Саҗидә. Кычкырма миңа! Тикмәгә шикләнеп йөрмәгәнмен икән бит, кайгыруларым урынсыз булмаган!

Фәндәс *(кыҗрап).* Тик кенә утыр! Туйдым! *(Әрле-бирле йөри.)*

Саҗидә *(кычкырып).* Мин дә туйдым! *(Сикереп тора.)*

Алар тузынганда Шәйхи тыныч кына тәмләп ашап утыра. Көтмәгәндә тагын Зәйнәп килеп керә.

Шәйхи *(мыскыллы тавыш белән).* Тагын килдеңмени, балакаем? Ыслушай, мин синнән туя башладым. Әле беркемнән дә болай тиз җаным бизгәне юк иде.

Фәндәс *(шаккатып карап тора).* Зәйнәп, мин бит сиңа билет алып бирдем. Ник китмәдең?!

Зәйнәп. Әллә ничек... китәсем килмәде.

Фәндәс. Ярар. Алайса, үзем чыгып китәм. У-у-у-у-ф, киттем мин! *(Йөгереп чыгып китә.)*

Ике хатын бер-берсенә нәфрәт белән карап каталар.

Шәйхи *(ашый-ашый).* Сез Фәндәсне үпкәләтмәгез. Әле ачыклыйсы бар — кем гаепле. Кая китте икән ул?

Саҗидә. Каян белим мин!

Шәйхи. Куып җитим әле мин аны. *(Тиз генә Фәндәс артыннан чыгып китә.)*

Саҗидә. Ну... нишлибез?

Зәйнәп *(биленә таянып).* Мин дә шул ук сорауны бирмәкче идем, нишлибез?

Саҗидә. Син махсус рәвештә безнең гаиләбезне таркатырга килгәнсеңдер шикелле.

Зәйнәп. Ә миңа, киресенчә, Фәндәс белән миңа комачауларга килгәнсездер шикелле сез бу дөньяга.

Саҗидә. Сөйрәлчек! Шлюха! Себерке! Оятсыз!

Зәйнәп *(мыскыл итеп).* Су эчеп алыгыз, дәвам итәргә җиңелрәк булыр.

Саҗидә. Үләксә!

Зәйнәп *(тыныч кына).* Сезгә дәваланырга кирәк.

Саҗидә *(истерикага күчә).* Оят, хурлык! Шушы көнгә кал инде, ә! Кем син? Кайдан син?

Зәйнәп *(һаман тыныч).* Мин — Зәйнәп.

Саҗидә. Зәйнәп икәнеңне мин инде хәзер мәңге онытмаячакмын.

Зәйнәп. Мәңге яшәргә җыенмыйсыздыр бит?

Саҗидә. Ә син үзең, пумала, озак яшәргә хыялланасыңмы?

Зәйнәп. Һәрхәлдә, сездән соң да яшәячәкмен, чөнки мин сезгә караганда яшьрәк. *(Чәчләрен төзәткәләп куя.)*

Саҗидә *(аптырагач капланып елый башлый).* Кем каргышы төште соң миңа?!

Зәйнәп. Уф, арыдым үзем дә. *(Диванга барып ята, баш астына мендәр куя.)* Мин бер-ике сәгать йоклап алам әле, яме.

Саҗидә *(торып утыра һәм аңа шаккатып карап тора).* Әстәгъфирулла! Нәрсә бу? Оят, читенсенү дигән нәрсә юк микәнни бу кешедә? *(Телефон шылтырый. Саҗидә сискәнеп китә. Барып трубканы ала.)* Алло. Әйе. Юк, юк, сез нәрсә. Минем өйдә шундый мәхшәр, ә сез... Нинди очрашу?! Рәшит, сез бит бала-чага түгел, бу халәттә миңа хәтта сөйләшергә дә авыр. Белмим. Аптыратмагыз! *(Трубканы ташлый.)*

Саҗидә кайгыга батып утыра. Торып йөри, нишләргә белми. Телефон кат-кат шылтырый, Саҗидә трубканы алмый.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Шул ук фатир. Зәйнәп көзге каршында буянып-ясанып утыра. Шәйхи керә.

Шәйхи *(коры гына).* Хәерле көн!

Зәйнәп *(тиз генә карап ала).* Исәнмесез!

Шәйхи. Халык кайда?

Зәйнәп. Нинди халык?

Шәйхи. Хуҗалар кайда?

Зәйнәп *(бизәнүен дәвам итеп).* Фәндәс бөтенләй монда кунмады. Саҗидә каенанасы янына китте.

Шәйхи. Ә син нишләп утырасың монда?

Зәйнәп. Бизәнеп.

Шәйхи. Тфү, сине монда ничек калдырды ул?
Зәйнәп. Кем?
Шәйхи. Саҗидә.
Зәйнәп. Куып чыгарып карады да ул мине, булдыра алмады.
Шәйхи *(якын килеп карап тора).* Кит син!
Зәйнәп *(гаҗәпләнеп).* Кая китим ди мин?
Шәйхи. Каян килдең, шунда кит!
Зәйнәп *(күзләрен акайтып карап тора).* Ә сез кем әле шулчаклы минем белән алай сөйләшергә!
Шәйхи. Мин нейтральный кеше — сантехник. Утыз икеле ачкыч белән маңгаеңа бер генә бирермен! Кеше тормышын бозып йөрисең!
Зәйнәп. Биреп карагыз!

Фәндәс кайтып керә. Исерек.

Фәндәс *(алпан-тилпән килә).* Исәнмесез! Бу — мин. Нишләп ят кешеләр бар монда? *(Шәйхигә.)* Син кем?
Шәйхи. Сантехник.
Фәндәс. Очень приятно. Ә бу — мин.
Шәйхи. Аңлыйм.
Фәндәс *(диванга таба атлый).* Нәрсә аңлыйсың соң син, бичара?
Шәйхи. Кем бичарадыр бит әле монда...
Зәйнәп *(йөгереп килә).* Ой, Фәндәс, нәрсә булды сиңа?
Фәндәс. Әйтер идем инде... сантехник янында яхшы түгел.
Шәйхи. Әйт, әйт.
Фәндәс *(Зәйнәпне этеп).* Саҗидә кайда?
Зәйнәп. Китте.
Фәндәс. Кая?
Зәйнәп. Белмим.
Фәндәс *(диванга ята).* Син дә кит. Берегез дә кирәк түгел. Барыгыз да күземнән югалыгыз.
Шәйхи *(аптырап).* Мин дәме?
Фәндәс *(башын калкытып карап тора).* Ә син кем соң әле?
Шәйхи. Шәйхи.
Фәндәс. Нинди Шәйхи?..
Шәйхи. Сантехник.
Фәндәс. Әле генә мин кергәндә бер сантехник бар иде бит инде. Что-то күбәеп киттегез әле сез.
Шәйхи. Шул мин идем бит инде ул.
Зәйнәп. Өстеңә юрган ябыйммы?
Фәндәс *(йокымсырый).* Әнә сантехникның өстенә яп.
Зәйнәп. Бу мин бит, Зәйнәп.
Фәндәс *(йокы аралаш).* Килеп керде Зәйнәп, кәҗә ... чәйнәп.
Зәйнәп *(кочаклый, үбә башлый).* Фәндәс! Матурым, бу мин бит!
Фәндәс *(күзләрен ача).* Ә сантехник кайда?
Зәйнәп. Ул туалетта.
Фәндәс. Уф, йөрәгем жу итте, өстемә сантехник менә дип.
Зәйнәп *(җилтерәтеп).* Фәндәс, бу мин, Зәйнәп.
Фәндәс. Ә бу мин, Фәндәс. *(Йокыга китә.)*

Рәшит килеп керә. Кочагында чәчәкләр, шампан шәрабы, бер кап кәнфит.

Рәшит. Шылтыратам, шылтыратам... Нишләп трубканы беркем дә алмый? Үзең генәмени?
Зәйнәп. Сантехник монда.
Рәшит *(кулындагы әйберләрне өстәлгә урнаштыра).* Ул монда прапискага керергә маташамы әллә? Саҗидә кайда?
Зәйнәп *(ачуланып).* Нишләп бөтенегез дә миннән сорыйсыз?
Рәшит. Урамдагы кешедән сорыймммыни инде! *(Диванга ымлап.)* Бу теге Фәндәс мәллә?
Зәйнәп. Әйе. Сез, сантехниклар начальнигы, монда еш киләсез әле никтер...
Рәшит. Менә син ул әллә каян килеп кердең монда. Ә син миңа ошыйсың, зараза. *(Зәйнәпнең иягенә бармагы белән кагыла.)*
Зәйнәп *(аның кулын читкә этеп).* Ну, ну, саграк кыланыгыз.
Рәшит *(Зәйнәптән күзләрен алмый).* Мин бит ЖКУдан түгел. Мин сәяркә-налетчик. Сине күргәч әллә нишләдем.
Зәйнәп. Ә мин хәзер Фәндәсне уятып әйтәм синең кем икәнеңне.

Рәшит *(Зәйнәпнең сарафаны эченә, күкрәкләре турысына ун доллар кыстырып куя.)* Тик кенә утыр. Мин ошыйммы сиңа?

Зәйнәп *(читкә карап).* Ошасаң ни...

Рәшит. Әйдә киттек минем белән.

Зәйнәп. Мин Фәндәс янына килдем.

Рәшит. Син аңа кирәк түгел, ахрысы.

Шәйхи *(алар янына килә).* Сөйлим барысын да Фәндәскә. Хәзер уятам да әйтәм кем икәнеңне.

Рәшит. Яшисең килмимени?

Шәйхи. Юк, туйдым дөньясыннан.

Рәшит *(сантехникка бер мескенгә караган сыман карап тора).* Ә синең кем икәнеңне хәзер үк үзеңә әйтимме? *(Уйлап тора.)* Әйтмим. Йә ванна бүлмәсендә хурлыгыңнан асылынып үләрсең. Аннары бәддогасы миңа булыр. Мин сиңа хәер генә бирим әле. Мә. *(Акча бирә. Шәйхи акчаны алып чалбар кесәсенә тыгып куя.)*

Шәйхи *(Зәйнәпкә).* Әйтәм Фәндәскә.

Зәйнәп. Нәрсә әйтәсең?

Шәйхи. Бу кеше белән гыйшык-мыйшык киләсең дип.

Зәйнәп *(күзләрен акайтып).* Кайда? Кайчан?

Рәшит. Нервыланма юк өчен. Ун доллар бир дә котыл.

Зәйнәп. Нахал!

Сумкасыннан акча ала һәм сантехникка бирә. Шәйхи акчаны ала да үз эшен дәвам итәргә китә.

Рәшит *(Зәйнәп каршына җайлабрак утыра).* Сөйлә әйдә.

Зәйнәп. Нәрсә сөйлим?

Рәшит. Ничекләр итеп шушы көнгә калдың? Аннары, шунысы сәер, ничек сине берәр җирдә бәреп үтермиләр икән?

Зәйнәп. Хам! Менә сезне ничек үтермиләр икән?!

Рәшит. Мине инде әллә ничә тапкыр үтереп караганнары бар, ләкин ничектер барып чыкмый.

Зәйнәп. Кешесенә туры килмисездер. Үзегезне белегез, оялмыйча утырасыз бит әле шушында.

Рәшит. Нишләп әле оялырга тиеш мин? Мине, җанкисәгем, чакырып китерделәр. Ә менә сине монда көтүче генә түгел, күрергә теләүче дә юк бугай.

Зәйнәп *(үзен кая куярга белми).* Мин туйдым сездән.

Рәшит. Нишлисең бит, мин, мәсәлән, синнән генә түгел, бөтен дөньясыннан инде күптән туйдым. Син кем?

Зәйнәп. Ничек инде «кем»?!

Рәшит. Атаң-анаң, Ватаның бармы синең?

Зәйнәп. Минем бөтен нәрсәм бар.

Рәшит. Синдә оят кына юк.

Зәйнәп. Җиттеме сезгә, юкмы! Фәндәс!

Рәшит. Кычкырма, йокласын. Сиңа ничә яшь соң, тавык баш?

Зәйнәп *(башын читкә борып).* Хатын-кызга андый сорау бирмиләр.

Рәшит. Мондый ситуациядә ярый. Ничәнче елгы син?

Зәйнәп. Ә ничә яшь бирер идең?

Рәшит. Бирмәс идем. Әле булганын да кире алыр идем.

Зәйнәп. О-о-о, острить иткән була!

Рәшит. Син бер илледә бардыр инде.

Зәйнәп. Нахал! Күзегезгә берәр нәрсә үсте мәллә! Сезнең шаяруларыгыз үзегезгә, әлбәттә, килешә, ләкин бер дә кызык түгел!

Рәшит. Минем белән барасыңмы?

Зәйнәп. Кая?

Рәшит. Абзар артына! Кая булсын инде... Минем бу шәһәрдә алты фатирым бар. Теләсә кайсына барабыз.

Зәйнәп *(күзләрен чекерәйтеп).* Миңа илле яшь бит, нишләп әле мине чакырасың?

Рәшит. Сиңа карап утыргач, мәрхүмә әбием искә төште. Бала чакта әбием белән йоклый идем. Бик җылы була торган иде.

Зәйнәп. Фәндәс! Мине монда мыскыл итәләр!

Фәндәс *(йокы аралаш).* Нишләтәләр?

Рәшит. Кычкырма! Тавышың тавыш түгел, общежитие вахтерыныкы шикелле — җан биздергеч.

Зәйнәп. Җитте! *(Рәшитнең яңагына сугып җибәрә.)*

Рәшит *(аның кулын тотып ала һәм шатырдатып кыса).* Яхшы чакта гафу үтен. Әле соң түгел.

Зәйнәп *(ялварып).* Җибәрегез, чыгырымнан чыгардыгыз мине.

Рәшит *(кулын шытырдатып кыскан килеш кайнар итеп иреннәреннән үбә, Зәйнәп каршы тормый).* Себерке! Кайнар нәрсә син үзең.

Зәйнәп *(йомшак кына).* Нахал.

Рәшит. Синдә миңа бер сыйфатың ошады.

Зәйнәп. Кайсысы?

Рәшит. Ул синең иң матур сыйфатың — синдә оят юк. Синең кебекләргә яшәве рәхәтрәк. Ләкин тормышта оятның кайчан да булса бер кирәк булып чыгуы бар. Шалт, мәсәлән, кичекмәстән оят кирәк! Ә ул юк! Менә шунда синең бетүең ихтимал.

Зәйнәп *(тәкәбберләнеп).* Бүтән кайгың булмаса, аптырама бер дә.

Рәшит. Бүтән кайгым юк, шул синең кебек тавык-чебеш өчен кайгырып кына йөрим инде мин көнетөне.

Фәндәс *(уяна).* Үләм!

Рәшит. Үлмисең. Вәгъдә итәсең генә. Әйдә баш төзәтәбез.

Зәйнәп *(янына йөгереп бара).* Фәндәс, бик читенме?

Фәндәс *(аптырап карап тора).* Син китмәдеңмени әле?

Зәйнәп. Мин мәңгегә килдем.

Фәндәс *(торып утыра).* Күңел болгана.

Рәшит. Синеке генә түгел, минем дә саруым кайный башлады инде монда.

Фәндәс *(өстәлгә ымлап).* Анда эчәргә берәр нәрсә бармы?

Рәшит. Бетеп килә.

Фәндәс. Зәйнәп, матурым, менә сиңа акча... Бар, кибеттән берәр эчемлек алып кайт. *(Чалбар кесәсеннән бөгәрләнеп беткән кәгазь акча алып бирә.)*

Зәйнәп. Мин сезнең кибетләрегезне белмим.

Фәндәс. Автобус тукталышында киоск бар, шуннан ал. Берәр әйбәт коньяк... Лимон булмасмы.

Зәйнәп теләр-теләмәс кенә, сукранып чыгып китә.

Рәшит. Кил әйдә, калганын салып бетерик әле. Нинди төшләр күрдең?

Фәндәс. Әллә тагы... Саташ-боташ инде шунда.

Рәшит. Өндә дә шул саташ-боташ инде ул. Әйдә утыр. *(Рюмкаларга коньяк сала.)*

Фәндәс *(чыраен сытып).* Уф, мин эчмәм инде.

Рәшит. Эч, эч, җиңеләеп китәчәксең. *(Эчәләр.)*

Фәндәс. Менә шундый хәлләр, туган. Син анда ЖКУда безнең гаилә хәлләрен сөйләмә инде, зинһар.

Рәшит. Юк, юк, син нәрсә. Сантехнигыма да катгый итеп әйтеп куярмын, күп сөйләшмәсен. Син үзең кем булып эшлисең соң?

Фәндәс. Бер кечкенә фирма директоры мин.

Рәшит *(як-ягына каранып).* Үзең фирма директоры, ә фатирың бик әллә ни түгел.

Фәндәс. Тиздән яңа фатир сатып алырга җыена идек. Акча бар. Бөтен нәрсә бар.

Рәшит. Күрәм, болай бернәрсәгә дә кытлык кичермисез бугай анысы.

Фәндәс. Шулай да бит... Саҗидәгә генә нидер җитми һаман. Гел кыбырсый, теңкәгә тия. Түземсез. Мин аңа һәрвакыт әйтәм: сабырлык кирәк. Вакыты җиткәч Ходай үзе бирә ул, мәйтәм. Ял йортына берүзем китүнең сәбәбе дә шул — бераз хатыннан ял итим дигән идем. Менә бит нинди көтелмәгән матавык килеп чыкты. Теге тилесенең монда килеп җитүен кара әле син!

Рәшит. Зәйнәпне әйтәсеңме?

Фәндәс. Соң инде!

Рәшит. Димәк, яраткан. Яратырлык иткәнсең.

Фәндәс *(уйланып тора).* Ышанасыңмы, юкмы, мин бит ул Зәйнәп белән хәтта бер тапкыр да йокламадым.

Рәшит *(аптырап).* Ничек инде?!

Фәндәс. Ресторанда килеп мине үзе биергә чакырды. Ошыйсың, диде. Мин сине әллә каян күреп алдым, башкалардан аерылып торасың, оригинальный ир, диде. Биедек, исердек, урамда йөрдек. Тагын коньяк эчтек, минем бүлмәгә кайтып аудык. Ләкин мин аның белән йокламадым.

Рәшит. Ачу килерлек шул. Ну монда хәзер син барыбер хатыныңа исбатлый алмаячаксың инде. Ул Зәйнәпне берәр ничек җүләр дип исбатларга иде.

Фәндәс. Тиле түгел кешене ничек тиле дип исбатлап булсын инде?!

Рәшит. Аның акыллы түгел икәнлеген исбатлап торасы юк, әлбәттә.

Фәндәс. Саҗидә белән мөнәсәбәтләр гел киеренке булганга бик эч поша иде, хәзер инде тәмам ерып чыккысыз булды.

Рәшит. Төкерсәнә! Әйдә тотып куйыйк. *(Эчәләр.)*

Фәндәс. Авырмы сантехниклар белән эшләве?

Рәшит. Авыр, бик авыр. Ну алар миннән куркалар.

Шәйхи *(атылып килеп чыга).* Юк, болай булмый, синең кем икәнеңне әйтми калалмыйм!

Рәшит *(аны изүеннән эләктереп ала, түш кесәсенә акча тыгып куя.)* Бар, эшлә. *(Шәйхи берсүзсез китеп бара.)*

Фәндәс. Ник кыза ул?

Рәшит. Нервысы какшаган. Үзең уйлап кара, көннәр буе бәдрәфтә казына... Аннары... Фатир чираты җитте аның, шуңа нәчәлствога бераз үпкәләбрәк йөри. Ну Шәйхигә мин шушы арада бирәм инде фатир, чөнки әйбәт эшләүче, тырыш сантехникка охшаган.

Фәндәс. Син Шәйхине кыерсытма инде, яме.

Рәшит. Ник әле алай дидең?

Фәндәс. Кызганам мин аны.

Рәшит. Ник әле син аны жәлләп утырасың? Гарип түгел, ни түгел...

Фәндәс. Ул бит югары белемле кеше, дипломлы инженер, сантехник булып эшләргә мәҗбүр.

Рәшит. Жәлләмә! Ул инженер, ә менә мин — актер! Мине кем жәлләр икән?!

Фәндәс. Син карап торуга бер дә мескенгә охшамагансың. Кем әле син?

Рәшит. Рәшит.

Фәндәс. Отчествоң?

Рәшит. Просто Рәшит. Татарда нинди отчество ди инде ул!

Фәндәс. Менә син акыллы кешегә охшагансың.

Рәшит. Рәхмәт.

Фәндәс. Бер киңәш бир, нишлим?

Рәшит. Ничек инде, нишлим?!

Фәндәс. Күрәсең бит нинди кәнитил килеп чыкты. Шунысы бик рәнҗетә — мин бит Саҗидәгә хыянәт иткән кеше түгел. Гомумән, аңардан башка миңа беркем дә кирәкми. Мин аны гомергә яраттым, хәзер дә яратам. Болай да беҗегрәк кеше иде ул, хәзер инде бөтенләй дөнья кубар. Ничек ышандырыйм, ничек исбатлыйм?! Ул бит минем хатыным, мин аңардан башка яшәвемне күз алдыма да китерә алмыйм!

Рәшит. Да-а-а, монда хәлләр мин уйлаганча гына түгел, җитдирәк һәм тирәнрәк икән. Менә мин сиңа карап-карап торам да, кем әйтмешли, тагын бер карап куям. Әйбәт кеше син. Синең кебекләрдән бераз көнләшәм хәтта. Мин беркайчан да югалып кала торган егет булмадым, әмма ләкин синең кебекләрдә очрый торган сыйфатларга мин һәрвакыт кытлык кичердем.

Фәндәс. Мәсәлән, нindиләренә?

Рәшит. Аны болай гына әйтеп аңлатып булмый бит.

Фәндәс. Үзем гомергә җебек булдым. Бик күп кирәк очракларда гайрәтем җитми.

Рәшит. Мин яшьрәк вакытта кешелек дөньясын яратырга, җирдәге барлык кешеләргә мәхәббәт белән яшәргә омтыла идем. Әле кайвакыт була иде шундый мизгелләр — мин бит кешеләрне яратмыйм, дип үземне битәрли идем. Гадәттә мондый хисләр берәр пычрак эш кылгач яки берәрсенә авыр сүз әйткәч, яисә берәрсен кыйнагач туа торган иде. Яши-яши аңладым: кешелек дөньясын яратырлык түгел икән, гомумән, бөтен кешеләрне ярату мөмкин түгел. Аерым кешене ярату мөмкин, анысы да вакытлыча гына. Кешеләрне яратам, дип кычкыручы кешегә игътибар белән кара әле, гадәттә андый кеше пычрак була, аның күңеле кара һәм ул аны хәтта яшерә алмый — кешеләрне яратам дигән ахмак сүзләр булып сасы авызыннан тышка бәреп чыга. Ләкин кешеләрне кыйнарга да ярамый, ахрысы. Сыерны кыйнаганнан сөте дә артмый, акыл да керми бит.

Фәндәс. Гаиләң бармы?

Рәшит. Бар иде кайчандыр. Хатын белән аерылгач, яңа гаилә корып булмады.

Фәндәс. Өйләнерсең әле.

Рәшит. Хатын-кыз белән күп чуалангач, алардан ныграк шикләнә башлыйсың шул. Нindидер изге төшенчәләр юкка чыга төрле хатыннарны татыгач. Нәрсәдер югала, гашыйклыклар, яратулар да бөтенләй башкача була башлый. Беркемгә дә ышанмыйм, чөнки үземне бик яхшы беләм, чөнки үземә ышанырлык түгел.

Фәндәс. Алай төшенкелеккә бирелмә әле. Башка кайгың булмаса, төкер! Менә минем хатын белән нәрсә килеп чыкты көтмәгәндә. Ничек хәл итәргә бу матавыкны.

Рәшит. Ә син үз агымына җибәр бу халәтне. Ташла. Уйлама. Үзеннән-үзе ничек килеп чыга, шулай барсын. Син бит белмисең бу очракта нинди адым ясавың файдалырак икәнне? Нишләргә кирәклеген шайтан белсен.

Фәндәс. Алай түгел инде. Ничек тә булса аңлашырга кирәк. Хәзер Зәйнәпне, Саҗидәне янәшә утыртып аңлатып карарга кирәк.

Рәшит. Туктале. Ә син ничек уйлыйсың, хатыныңның сөяркәсе бармы?

Фәндәс. Син нәрсә инде! *(Үзе пошаманга кала.)*

Рәшит. Хатының чибәр, әле яшь, аның да бит сөяркәсе булуы ихтимал.

Фәндәс *(шикләнеп).* Ни сөйлисең!

Рәшит. Син ял йортында чакта монда сөяркәсе белән очрашып яткан булса ни хәл итәрсең?

Фәндәс. Юк, юк, минем Саҗидәм андый хатын түгел! Миңа хыянәт итми ул.

Рәшит. Ә син хыянәт итәсеңме соң?

Фәндәс. Юк.

Рәшит. Ә Зәйнәп килгән бит сине эзләп.

Фәндәс. Зәйнәп бит ул. Саҗидә андый түгел.

Рәшит. Хатын-кызның һәрберсе ике фужер шампанский эчкәч дөньясын оныта. Яше дә, карты да.

Фәндәс *(курка).* Син нишләп, Саҗидәнең сөяркәсе булуы ихтимал, дидең?

Рәшит. Чөнки дөнья бит бу. Кешеләр дөньясы.

Фәндәс. Минем бу турыда хәтта бер генә тапкыр да уйлаганым юк.

Рәшит. Кайвакыт уйларга да кирәк...

Фәндәс. Син сантехниклар начальнигы булгач... ЖКУ кешесе буларак, бәлки, берәр нәрсә ишеткәнең бардыр минем хатыным турында?

Рәшит. Юк ла, болай гына әйтәм инде. Бераз уйларыңны икенче юнәлешкәрәк җибәрер өчен.

Фәндәс. Кая югалды теге?

Рәшит. Зәйнәпме?

Фәндәс. Әйе.

Рәшит. Ул югала торган нәмәрсә түгел, бер дә борчылма.

Фәндәс. Кайтты бугай.

Зәйнәп кайтты дип уйлыйлар, ләкин Саҗидә кайтып керә.

Фәндәс. Әнигә сөйләдеңме?

Саҗидә. Сөйләдем.

Фәндәс. Кирәк түгел иде!

Саҗидә. Кирәк иде! Кабахәт! Әнә шул шлюхаң белән яшә!

Фәндәс. Туктале, кычкырма. Рәшит әфәндедән яхшы түгел.

Саҗидә. Кычкырам! Синең белән рәхәт күрмичә яшәү җитмәгән, өстәвенә сөяркә ияртеп кайткансың!

Рәшит *(үзен тыя алмый).* Җитте сиңа! Тынычлан! Тыңла иң элек ир кешенең сүзен!

Саҗидә *(күзләрен акайтып).* Ә сез ник кычкырасыз миңа?!

Рәшит. Чөнки монда минем специалистым бик нечкә эш башкара бәдрәфтә, комачауламагыз, аңа тынычлык кирәк.

Шәйхи *(бик сәер кыяфәттә килеп чыга).* Син...

Рәшит *(кесәләрен капшый, долларлары беткән булып чыга).* Фәндәс, акча биреп тор әле, зинһар. *(Фәндәс акча суза.)* Шәйхигә бир әле шуны. *(Фәндәс Шәйхигә акчаны бирә, Шәйхи берсүзсез кире туалетка китә.)*

Фәндәс *(борын тишекләрен киңәйтеп).* Рәшит, сез минем хатынга кычкырмагыз бүтән.

Рәшит. Гафу ит. Саҗидә, син дә гафу ит, зинһар. Болай ярамый бит инде.

Фәндәс. Сигаретың бармы?

Рәшит. Бар.

Фәндәс. Әйдә, саф һавада бер тартып керик әле.

Рәшит. Әйдә. Кайда тартабыз?

Фәндәс. Балконда. *(Чыгып китәләр.)*

Шәйхи *(Саҗидә янына килеп).* Ну син нәрсә инде?! Син әле башта аныклап ачыкла: теге ял йорты себеркесе чынлап та иреңнең сөяркәсеме, юкмы.

Саҗидә. Аның нәрсәсен ачыклыйсың инде, көн кебек ачык лабаса!

Шәйхи. Ә менә бу Рәшит ЖКУның сантехниклар начальнигы түгел бит.

Саҗидә. Нәрсә әйтмәкче буласың?

Шәйхи *(усалланып).* Кем соң ул?

Саҗидә. Каян белим!

Шәйхи. Ул бит минем начальнигым түгел.

Саҗидә. Минеке дә түгел.

Шәйхи. Менә бу моментта синеке бит ул...

Саҗидә. Ул минем сөяркәм түгел!

Шәйхи. Ә син Фәндәскә исбатлый аласыңмы Рәшитнең сөяркә түгеллеген?!

Саҗидә. Син әйтмисең! Син яхшы кеше. Син бер сүз дә әйтмисең Фәндәскә. *(Сумкасыннан акча алып бирә.)*

Шәйхи *(акчага карап тора).* Акча бирсәләр, алмый калалмыйм инде мин. Алам инде. Сантехник бит мин. *(Акчаны алып кесәсенә тыгып куя.)*

Коньяк күтәреп Зәйнәп килеп керә.

Зәйнәп *(алып кайткан әйберләрне өстәлгә урнаштыра).* Уф, хәтта киоскка да чират сезнең монда. Провинция провинция инде ул...

Шәйхи. Карале, йонлы баш, мин сиңа беркем дә түгел, ләкин ЖКУ вәкиле буларак маңгаеңа утыз икеле ачкыч белән тартуны үземнең бурычым дип саныйм.

Зәйнәп. Төрмәдәге унитазларны чистартасыгыз килә мәллә?

Шәйхи. Син... *(Ыргыла.)*

Саҗидә *(аны тыя).* Кызма, Шәйхи, кызма, кирәкми. Карагыз әле, чибәркәй, инде оят, намус дигән төшенчәләр сезгә берни түгел икән, бәлки, башкача сөйләшергәдер сезнең белән.

Зәйнәп. Ничек ул башкача?

Саҗидә. Бәлки, Шәйхи түгел, сез утырырга тиештер төрмәдә?

Зәйнәп. Ни өчен?

Саҗидә. Оятсыз рәвештә бәреп кереп гаиләне таркатырга маташуың өчен.

Зәйнәп. Нинди кешеләр сез! Нинди шулхәтле дөрес кешеләр соң сез? Минем йөрәгем, җаным юкмыни! Ул мине алдап, әллә ниләр вәгъдә итеп рәхәтләнеп ятты да... Мин бит уенчык түгел, миндә дә горурлык бар! Мин дә үземне таптарга, мыскыл итәргә ирек бирә торганнардан түгел. Мәңгегә бергә булабыз дип, айлы төндә минем алдымда тезләнеп ант итте, менә, пожалуйста, мәңге минем белән булсын! Мин эт баласы түгел лә, әле сөеп, әле тибеп җибәрергә. Мин бит ышандым!

Саҗидә. Юк, моңа бернәрсә дә аңлатып булмый.

Шәйхи. Моңа аңлатып торасы юк, артына тибеп чыгарып җибәрәсе генә бар.

Зәйнәп. Сезнең намусыгыз җитәме соң әле тибәргә! Чүпрәк!

Саҗидә. Тукта! Ник аны мыскыл итәсең!

Зәйнәп. Ә сез, чистоплюйка, артыгызны кысып тик кенә утырыгыз, яме. Мин яраткан кешемне эзәрлекләп фатирына килеп керергә оялмадым. Ә сез үзен сантехниклар начальнигы дип атаган сөяркәгезнең кем икәнлеген дә әйтергә куркып утырасыз. Ник соң куркасыз, алай бик чиста, әхлаклы кеше булгач? Ирегезгә әйтеп бирә аласызмы Рәшитнең кем икәнлеген, ә? Сантехниклар начальнигымы ул, әллә сөяркәгезме?!

Шәйхи *(аңа таба килә).* Син...

Зәйнәп *(кычкырып җибәрә).* Якын килмәгез!

Саҗидә. Шәйхи, тынычлан. *(Зәйнәпкә)* Син дә тыныч бул!

Зәйнәп. Мин бик тә тыныч. Хәзер ирләр керәчәкләр һәм әйтеп бирәчәкмен Рәшитнең кем икәнлеген. Фәндәс белеп торсын әле хатыны монда нишләп ятканны.

Саҗидә *(күзләрен акайтып).* Аһ, елан!

Шәйхи. Тукта, Зәйнәп, ашыкма, алай ярамый. Менә сиңа... Мә, бу акчаларны ал, әйтми тор.

Бөтен булган акчасын бирә, Зәйнәп акчаны ала. Шуннан соң Шәйхи яңадан үз эшенә тотына. Фәндәс белән Рәшит керәләр.

Фәндәс. Тормыш катлаулы нәрсә инде ул.

Рәшит. Аны без үзебез катлауландырабыз ла.

Зәйнәп *(йөгереп килә).* Фәндәс, менә коньяк алдым, кәнфит, лимон алдым.

Саҗидә. Уф, оят, хурлык!

Фәндәс. Әйдәгез әле, утырып сөйләшик, тынычланыйк, бер-беребезне аңларга тырышыйк, ниһаять. *(Утырышалар.)*

Саҗидә. Йә, сөйлә инде.

Фәндәс. Җәмәгать, минемчә, монда бернинди фаҗига юк. Коелып иңәрлек һәм гаиләне куркыныч астына куярдай берни күрмим.

Рәшит. Мин дә шулай уйлыйм. Барысы да тәртиптә.

Зәйнәп *(сикереп тора).* Тәртиптә?!

Шәйхи *(кулына шланг тотып туалеттан атылып чыга).* Син, ыштыр бит, тик кенә утыр ирләр сөйләшкәндә! Шланг белән бер генә бирермен оятсыз чыраеңа!

Зәйнәп. Фәндәс!

Рәшит. Шәйхи, тынычлан, син бит эштә! Син дә, Зәйнәп, нервыланма, әнә сок йотып куй. Үзең ял йортында буталасың, ә үзеңнең нервыларың бөтенләй беткән — общежитие кастеляншасыныкыннан да болайрак.

Фәндәс. Тынычланыгыз, зинһар. Зәйнәп... Саҗидә... Монда аек акыл белән фикер йөртү мәслихәт.

Саҗидә. Тынычланып сөйләшү, аңлашу менә бу себерке күздән югалгач кына мөмкин булачак.

Зәйнәп. Синең ни хакың бар мине мыскыл итәргә?! Мескен! Мин Фәндәскә сезнең хакта да берничә сүз әйтергә мәҗбүрмен.

Шәйхи *(туалеттан зур торба кисәге күтәреп килеп чыга).* Үтерәм, ана дуңгыз!

Зәйнәп. Фәндәс, коткар!

Рәшит *(сикереп торып Шәйхине этеп җибәрә).* Син эшлә, тыгылма!

Фәндәс. Болай сөйләшеп булмый инде. Зәйнәп, син хәзер үк кит!

Зәйнәп. Китмим! Нишләп әле Рәшит монда утыра, ә мин китәргә тиеш?

Фәндәс. Аңламадым?..

Зәйнәп. Бәлки, сөекле хатының Саҗидә аңлатып бирер...

Рәшит. Тик кенә утыр, пумала! Фәндәс туган, эш шунда ки, мин сантехниклар начальнигы түгел.

Фәндәс. Ә кем соң сантехниклар начальнигы?

Рәшит. Белмим.

Фәндәс. Ә кем соң син?

Рәшит. Мин, туган, Рәшит атлы. Хатының янына дип килгән идем.

Фәндәс. Шаярасың!

Рәшит. Шаярмыйм! Шәйхи, кил әле монда.

Шәйхи *(килә).* Нәрсә?

Рәшит. Мин бит синең начальнигың түгел, шулаймы?

Шәйхи. Ни сөйлисең?! Син безнең участок начальнигы!

Рәшит. Әйт дөресен! Тәлгать Бариевич сезнең начальник!

Шәйхи *(аның колагына).* Харап итмә инде гаиләне. *(Кычкырып.)* Шаяра ул, шаяра. Безнең начальник бу.

Рәшит *(Шәйхине этеп җибәрә).* Комедия оештырмагыз инде, зинһар! Мин Саҗидә янына кунакка килгән идем.

Фәндәс. Саҗидә, ни сөйли бу кеше?!

Саҗидә. Әйе, минем яныма килгән иде. Син генә гуляйть итәргә димени!

Зәйнәп *(шатланып).* Ну ничек хәзер ситуация?!

Рәшит. Тик кенә утыр, карачкы!

Фәндәс. Димәк, бу синең сөяркәң?

Саҗидә. Әйе.

Шәйхи *(йөгереп килеп җитә).* Саҗидә ханым, катлауландырмагыз инде!

Саҗидә. Кит!

Фәндәс. Ә син соң ничек оялмыйча, ни йөзең белән мине битәрләп утырасың, оятсыз!

Зәйнәп. Әйтмә дә!

Фәндәс *(ярсып).* Күземнән югал! Син минем хатыным түгел! Аерылам!

Зәйнәп. Яхшыатлы булып кыланып утыруын карале син аның!

Фәндәс *(кыжрап).* Әйберләреңне җый да күземнән югал!

Саҗидә *(котсыз кала).* Фәндәс! Туктап тор!

Шәйхи белән Саҗидә Фәндәсне тынычландырырга маташалар.

Фәндәс. Шлюха!

Барысы да тып-тын калалар.

Рәшит *(усал итеп башын чайкый).* Фәндәс, хатыныңа бүтән андый сүз әйтмә!

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Саҗидәләр фатиры. Саҗидә өйдә ялгызы. Үзен кая куярга белми.

Саҗидә *(кайгылы).* Нишләргә инде?! *(Бер катгый карарга килеп телефоннан шылтырата.)* Алло. Рәшит, исәнмесез. Бу мин, Саҗидә. Хәтерлисез микән... Әйе, әйе. Нихәлләрегез бар? Минеке бик начар... Менә шылтыратырга булдым әле... *(Елый.)* Фәндәс югалды шул... Әйе. Без бит ярты елдан артык инде бергә яшәмибез. Нәрсәсе аңлашылмый инде. Чыгып китте дә югалды. Шул теге матавыктан соң без бит бер атна да бергә тормадык. Каян белим? Мин бит үзем шуңа күрә сезгә шылтыратам. Рәшит, зинһар, ярдәм итегез, эзләп табыгыз шуны. Сезнең бит бу шәһәрдә абруегыз бар. Киләсезме? Рәхмәт! Алайса, хәзер үк килегез, зинһар. Көтәм, көтәм, әлбәттә! Көтеп утырачакмын!

Өйдә тәртипсезлек хөкем сөрә. Саҗидә кабалана-кабалана җыештыргалый башлый. Бераз вакыт узганнан соң бусагада Рәшит белән Зәйнәп пәйда булалар. Зәйнәп авырлы — корсагы зур булып кабарып тора, бер кулы белән Рәшитне култыклаган, икенче кулы белән шатыр-шотыр ямь-яшел

каты алма ашый. Саҗидә аларның икесен бергә күреп таң кала.

Рәшит *(киң елмаеп)*. Исәнмесез!
Саҗидә *(гаҗәпләнүен яшерми)*. Исәнмесез! Сез...
Зәйнәп *(кашларын сикертеп)*. Исәнмесез! Әйе, без бу.
Саҗидә *(каушый)*. Узыгыз әйдә.
Рәшит. Хатыным белән таныштырып торуның кирәге юктыр, сез инде танышлар, ахрысы.

Зәйнәп алманы ашап бетереп, сумкасыннан шалкан алып шатырдатып ашый башлый.

Саҗидә. Утырыгыз.
Зәйнәп. Мин ятып торыйм әле. *(Эчен тотып әкрен генә диванга барып ята.)*
Саҗидә *(аңа карап тора)*. Әйе, әйе, ятып тор. Мендәр кирәкме?
Зәйнәп. Кирәк.

Саҗидә мендәр алып аның баш астына куя.

Рәшит. Аерылдыгызмы?
Саҗидә *(башын куллары белән кысып)*. Югалды ул. Рәшит, синдә дә гаеп юк түгел. Ярдәм ит, табыйк аны!
Рәшит *(борчулы кыяфәт белән)*. Кайчан югалды диден әле?
Саҗидә. Ярты елдан артык инде. Беркем белми кайда икәнен.
Рәшит. Аның фирмасы бар иде бит.
Саҗидә. Банкротлыкка чыкты аның фирмасы, тар-мар килде. Ул фирмадан җилләр исте инде.
Рәшит *(аптырап)*. Каян табарга соң инде аны? Уйлап карарга кирәк.
Саҗидә *(тагын Зәйнәпкә карап тора)*. Сез Зәйнәп белән бергә яшисезмени?
Рәшит. Ир белән хатын булгач бергә яшибез инде. Бәби көтәбез менә.
Саҗидә *(елый)*. Кайда икән ул?
Рәшит. Төрмәгә утыртмадылар микән соң аны?
Саҗидә. Юк, юк, мин инде милициянең теңкәсенә тиеп беттем, утырткан булсалар, хәбәр итми калмаслар иде.
Рәшит. Берәр җирдә үтереп ташламадылар микән?
Саҗидә *(котсыз калып)*. Әй Ходаем! Юктыр, мин гел көнаралаш диярлек моргка шылтыратып торам.
Рәшит *(тыныч кына)*. Нәрсә, мәет әбизәтелне моргта ятарга тиешмени?!
Саҗидә *(коточкыч караш белән карап тора)*. Әллә ниләр сөйләмә инде.
Рәшит. Берәрсенә зур бурычлары, бирәсе акчалары юк идеме?
Саҗидә *(беркавым уйлап тора)*. Юк бугай. Мине гафу итми чыгып китте инде ул.
Рәшит. Шул минем аркадамы?
Саҗидә. Шулай инде. Минем бит беркем белән дә чуалганым юк.
Рәшит. Ай тинтәк, аңлата алмадым микәнни шуңа!
Саҗидә. Мин ял йортында чакта, Рәшит белән монда яткангыгыз, дип атна буе җелегемне корытты да юкка чыкты.
Рәшит. Зәйнәп!
Зәйнәп *(диванда алма ашап ята)*. Нәрсә?
Рәшит. Син алай-болай Фәндәснең бу шәһәрдәге яшерен координатларын белмисеңме?
Зәйнәп *(башын читкә борып)*. Белмим дә, беләсем дә килми.
Рәшит. Белсәң әйт, аны табарга кирәк.
Зәйнәп. Ул кеше минем өчен үлде инде.
Саҗидә *(күз яшьләрен сыпырып)*. Зәйнәп, белмисеңме кайда булуы ихтимал?
Зәйнәп. Белмим. Нәрсә, югалттыңмы иреңне?
Саҗидә. Сезнең аркада! *(Зәйнәпкә.)* Син дә гаепле. *(Рәшиткә.)* Син дә гаепле, Рәшит. *(Нәфрәтләнеп.)* Кеше бәхетсезлегеннән икегезгә уртак бәхет төзеп яшәп ятасыз. Бәби көтәсез.
Рәшит. Кызма, Саҗидә. Мин Фәндәсне эзләп табуны үземнең бурычым дип саныйм. Барыбер табачакмын аны, әгәр исән булса.
Саҗидә *(сикереп тора)*. Исән, исән!
Рәшит. Телефон номерлары язылган кенәгәләрегезне бир әле.
Саҗидә *(аптырап)*. Бөтенесен үзе белән алып киткән.
Рәшит. Нинди адреслар буенча эзләп була икән аны... Әгәр инде бу шәһәрдән китмәгән булса... Сине ташлап китәр алдыннан телефоннан кемнәр белән һәм дә ниләр турында сөйләшкәненә колак салмадыңмы соң?

Саҗидә. Әллә тагы. Шул матавыктан соң, сез киткәч, эчә башлады ул. Теге сантехник Шәйхи бар бит әле.

Рәшит. Әйе.

Саҗидә. Аның эше монда байтак иде, ул бер атнага якын бездә булды. Фәндәс белән эчтеләр дә эчтеләр.

Рәшит. Стоп! Бәлки, ул Шәйхигә салган баштан ычкындыргандыр кай тарафларга олагасын?!

Саҗидә. Бәлки.

Рәшит. Исерек баштан әллә нинди серләр ычкына бит кайчакта. Шул сантехникны кичекмәстән табарга кирәк. Дөресрәге, иң яхшысы, аны чакыртырга кирәк.

Зәйнәп. Теге вакытта минем маңгайга ачкыч белән сугарга теләгән сантехникнымы?

Рәшит. Әйе.

Зәйнәп *(чыраен сытып).* Андый кешене чакыртмагыз инде монда, миңа бит дулкынланырга ярамый.

Рәшит. Ә син дулкынланма, барысы да тәртиптә.

Зәйнәп *(иркәләнеп).* Минем шалканым бетте. Миңа тагын кирәк.

Рәшит. Саҗидә, шалканың юкмы?

Саҗидә. Юк. Чөгендер бар.

Рәшит. Чөгендер ярамыймы?

Зәйнәп. Юк. Ә алмагыз бармы?

Саҗидә. Бар.

Зәйнәп. Яшелме?

Саҗидә. Яшеле дә бар.

Зәйнәп. Бирегез, зинһар.

Саҗидә *(теләр-теләмәс кенә кузгала).* Хәзер. *(Алма алып килеп бирә, Зәйнәп ашый.)*

Рәшит *(телефоннан шылтырата).* Алло, ЖКУмы? Исәнмесез! Сезне Дуслык урамыннан борчыйлар. Утыз икенче йорт, егерме беренче фатир. Сантехник җибәрсәгез иде. Нәрсә булды дип... Килгәч күрер, сантехник җибәрегез монда. Сез Шәйхине җибәрегез, чөнки ул күптән түгел ремонт ясады монда. Әллә нинди үзе генә аңлый торган узеллар урнаштырган иде. Шәйхине җибәрегез монда, зинһар. Түләү наличными булачак, аңа да, сезгә дә шәхсән үзем түлим. Көтәбез. Дуслык урамы, утыз икенче йорт, егерме беренче фатир. Көтәбез. Шәйхи киләме соң? Ярый, рәхмәт. *(Трубканы куя.)*

Саҗидә. Шәйхи киләме әллә?

Рәшит. Әйе, аны җибәрергә вәгъдә бирделәр.

Зәйнәп *(борылып ята).* Нәрсә, ялгызың яшәдеңме моңарчы?

Саҗидә *(нәфрәтләнеп карап тора).* Әйе. Мин бит син түгел.

Рәшит. Тс-с-с-с, Зәйнәпкә дулкынланырга ярамый.

Саҗидә. Ярамаса, тик кенә ятсын.

Рәшит. Саҗидә, телеңне тый.

Зәйнәп. Син түгел дип... Нәрсә мин?!

Саҗидә. Синең кебекләргә никтер бәхет гел елмая ул!

Зәйнәп. Дөньяга үзең елмаеп карасаң, дөнья да сиңа елмая, шундый закончалык бар.

Рәшит. Сиңа фәлсәфи темаларга сөйләшергә ярамый, Зәйнәп. Авырлы икәнеңне онытма.

Шәйхи килеп керә.

Шәйхи *(атылып килеп керә, затлы киемнән, муенында галстук, кочагында чәчәкләр, шампан шәрабы, төргәк белән ашамлыклар).* Нәрсә булды монда тагын?

Рәшит. Сәлам, Шәйхи!

Шәйхи. О-о-о-о, таныш кешеләр. Сәлам. Нәрсә булды? *(Кулындагы әйберләрне өстәлгә урнаштыра.)*

Рәшит *(җентекләп күзәтә).* Син, Шәйхи, үзгәргәнсең.

Шәйхи *(башын күтәребрәк).* Мин хәзер Шәйхулла Галимуллович булам инде. *(Кул биреп күрешәләр.)*

Рәшит. Ә-ә-ә-ә, нишләп алай?

Шәйхи. Мин, туган, хәзер начальник участка. *(Рәшитне иңеннән кагып.)* Ну, молодец, күңелең сизгер икән... Безнең Тәлгать Бариевич чынлап та үлеп китте бит.

Саҗидә. Кем иде соң ул?

Шәйхи. Безнең начальник иде ул, үпкәсенә салкын тиеп бик озак бүлнисләрдә ятканые... Хәзер мин аның урынында. Фатир алдым. Теге, дипломымны сатканыма кайгырып йөргән идем бит, хәтерлисезме? Күптән түгел яңа диплом сатып алдым миллион ярымга. Эшләр әйбәт бара, Аллага шөкер. Хатынга норковый тун алырга җыенабыз. Алтын коронкалар куйдырдым. *(Авызын ерып күрсәтә.)* Син Рәшит бит әле?

Рәшит. Әйе. Карале, хәтерең яхшы икән, ярты елдан артык вакыт узды, ә син мине хәтерлисең.
Шәйхи. Син нишләп тагын монда килеп эләктең? *(Коньяк шешәсен ача.)*
Рәшит. Эшләр хөрти монда, туган.
Шәйхи *(Зәйнәпне күреп ала).* Әстәгъфирулла, син һаман мондамыни әле?
Зәйнәп *(ачусыз гына, ишетелер-ишетелмәс итеп).* Пошел вон!
Рәшит. Авыр сүз әйтмә, Шәйхулла...
Шәйхи. Галимуллович.
Рәшит. Шәйхулла Галимуллович, авыр сүз әйтмә. Ул минем хатыным, аңа нервыланырга ярамый.
Шәйхи *(әле берсенә, әле икенчесенә карап).* Монда яңа матавык туарга тормыйдыр бит?
Саҗидә *(усал итеп).* Бу әлеге дә баягы матавыкның дәвамы.
Рәшит. Шәйхулла...
Шәйхи. Галимуллович.
Рәшит. Шәйхулла Галимуллович, теге вакытта сиңа Фәндәс исерек баштан әйтеп ташламаган идеме, мәсәлән, берәр җиргә китәргә җыенуы яисә берәр кая барырга хыяллануы турында?
Шәйхи. Карале, чыннан да Фәндәс нихәлләрдә, аны күптән күргән юк?
Саҗидә *(еламсырап).* Югалды ул. Шуңа күрә сине чакырдык бит монда. Белмисеңме аның кайда икәнлеген?
Шәйхи *(аптырашта кала).* Каян белим инде мин. Күптән югалдымы?
Саҗидә. Ярты елдан артык вакыт үтте.
Рәшит. Исеңә төшер әле, әйтмәдеме кайларга китәчәге турында?
Шәйхи *(уйлап тора).* Юк, хәтерләмим. Саҗидәне барыбер гафу итмим, Рәшит белән яшәсен дип ярсып кычкырганын гына хәтерлим. Мин ремонтны тәмамлап чыгып киткәндә монда иде бит әле ул.
Саҗидә. Шул синнән соң бер атна чамасы гына торды да югалды.
Рәшит. Кайда булыр икән ул?
Шәйхи. Чыгып качкач аны эзләүдә мәгънә бар микән соң?
Зәйнәп. Ниһаять, бер рәтле сүз чыкты. Ташлап чыгып киткән кеше өчен кайгырып утырмагыз инде.
Саҗидә *(ярсып).* Ничек алай әйтә аласыз!
Рәшит. Зәйнәп, син хаклы түгел. Тыныч кына ят. Сиңа сөйләшергә ярамый.
Шәйхи. Син, Саҗидә, аның тетмәсен теттең дә үзең, хәзер сагынып, кара кайгыга батып утырасың.
Рәшит. Син, Шәйхулла...
Шәйхи. Галимуллович.
Рәшит. Син, Шәйхулла Галимуллович, монда нотык укырга килмәгәнсеңдер бит! Алла хакы өчен, вәгазь укыма. Син хәзрәт түгел, син — сантехник.
Шәйхи. Мин — участок начальнигы.
Рәшит. Барыбер мулла түгел.
Шәйхи. Бәлки, миңа бөтенләй китеп барыргадыр?!
Рәшит *(боерулы тавыш белән).* Китмисең! Табарга кирәк Фәндәсне!
Шәйхи *(тавышын күтәреп).* Син миңа кычкырма! Синең аркада һәм Зәйнәбең аркасында килеп чыкты түгелме бу бәхетсезлек?! Кеше бәхетсезлеге аркасында бәхетле булдыгыз да...
Рәшит *(кыжрап).* Син чүбек чәйнәп торма, Галимулла Шәйхуллович!
Шәйхи. Шәйхулла Галимуллович.
Рәшит *(ярсып).* Аерма юк! Син минем өчен барыбер Шәйхи! Участок начальнигың үлгәнгә күрә сиңа төс керде бит бераз, кеше фаҗигасеннән файдаланып тернәкләнеп киләсең түгелме? Үлүенә сөенеп, аның урынына эшкә урнашып, үзеңнән, дөньядан канәгать булып йөрисең түгелме?
Шәйхи *(курыкмый, үзен нык тота).* Миндә синең эшең булмасын! Жулик! Ничек кенә булмасын, мин эшләп ашыйм!
Зәйнәп *(чыраен сытып борылып ята).* Кычкырмагыз, зинһар! Йөкле хатын янында тынычрак сөйләшегез инде!
Саҗидә. Әйдә, мин сине икенче бүлмәгә урнаштырам. *(Саҗидә Зәйнәпне алып чыгып китә.)*
Рәшит *(тыныч кына).* Син кызма.
Шәйхи *(шулай ук кинәт тынычлана).* Син дә кызма. Һәркем булдыра алганча яши бу тормышта, һәркем үзенчә тырыша-тырмаша.
Рәшит. Кайда икән Фәндәс?
Шәйхи. Мин беләм аның кайда икәнен.
Рәшит *(сискәнеп).* Кайда ул?
Шәйхи. Әйтмим.
Рәшит. Чынлап та беләсеңме?
Шәйхи. Беләм.
Рәшит. Әйт тизрәк!
Шәйхи. Әйтмим.

Рәшит. Ник әйтмисең?
Шәйхи. Чөнки ачуымны китердең.
Рәшит. Гафу ит, Галимулла...
Шәйхи. Шәйхулла.
Рәшит. Шәйхулла...
Шәйхи. Галимуллович.
Рәшит. Шәйхулла Галимуллович, алдыңда тезләнергә дә ризамын, әйт, зинһар. Бу гаиләнең таркалуында минем гаебем дә зур. Әйт, мин сине моның өчен буш калдырмам. Минем әле сиңа кирәгем чыгып куяр. Әйт инде.
Шәйхи *(пышылдап).* Саҗидәгә дә, хатыныңа да әйтергә ашыкмый тор, яме.
Рәшит. Ярар, ярар. Кайда ул?
Шәйхи *(пышылдап).* Ерак түгел. Шушы тирәдә генә.
Рәшит. Әйт инде тизрәк, кайда?
Шәйхи *(пышылдап).* Миндә эшли ул, сантехник булып.
Рәшит *(шаккатып).* Кит аннан!
Шәйхи. Әйе, мин аның начальнигы. Мин бит шуңа күрә үзем монда килдем. Әллә син Шәйхи үзе килсен монда дигәнең өчен килдем дип уйлыйсыңмы? Юк, Фәндәснең монда килмәсен белеп үзем килдем.
Рәшит. Аны монда алып килергә кирәк.
Шәйхи. Килмәячәк ул монда.
Рәшит *(таләпчән тавыш белән).* Тыңла мине. Фәндәсне монда китертергә кирәк!
Шәйхи. Булмый.
Рәшит *(ачуланып кычкыра).* Син бит участок начальнигы в конце концов! Синең сантехнигың бит ул!
Шәйхи *(уйга калып).* Берәр нәрсә оештырырга кирәк алайса — унитазны җимерергәме, кранны ватаргамы.
Рәшит *(шатланып).* Менә, менә! Монда аны китертер өчен Саҗидә өйдә юк дип әйтергә кирәк булачак. Син Фәндәсне үзең монда каршы алырсың, аннары чыгып китәрсең.
Шәйхи. Шуннан?
Рәшит. Шуннан соң берәр ничек Саҗидәне өйгә кертергә кирәк.
Шәйхи. Аңарчы Саҗидә кайда булачак соң?
Рәшит. Каян белим мин. Оештырырга, очраштырырга кирәк аларны, аңлыйсыңмы? Күрмисеңмени, Саҗидә ничек кибеп беткән?
Шәйхи. Аның каравы синең Зәйнәбең күпергән.
Рәшит. Күп сөйләшмә! Кем өчендер син участок начальнигы — Шәйхулла...
Шәйхи. Галимуллович.
Рәшит. Кем өчендер син Шәйхулла Галимуллович, ә минем өчен ничек Шәйхи булгансың, тәки шулай ук Шәйхи булып калдың. Минем белән чамалап сөйләш. Мин сиңа түләрмен, Фәндәсне чакырт монда. Фатирыгызда булдым, сантехникагызны ремонтларга кирәк, диген. Алдан берничә кранны ватарбыз да... Бар, ремонтла, Саҗидә өйдә юк, диген.
Шәйхи. Нишләп йөрисең безнең фатирда, дип сораса?
Рәшит. Саҗидә сантехник чакырды, диярсең. Синең бармасыңны белгәч үзем бардым, Саҗидә ачкычын биреп үзе каядыр китте, диярсең. Давай, хәзер үк.
Шәйхи. Ярар, мин әйтермен... Килер микән?
Рәшит. Бар, башта краннарны ват.
Шәйхи. Мин ватам, миңа нәрсә... *(Ванна бүлмәсенә китә.)*
Рәшит. Саҗидә, чык монда!
Саҗидә *(чыга).* Нәрсә?
Рәшит. Аптырама, табабыз Фәндәсеңне.
Саҗидә *(тәмам хәлсезләнеп).* Кайда икән соң ул?
Рәшит. Әлегә билгеле түгел. Дөнья шактый киң бит ул. Син каушама гына.
Шәйхи *(кулына краннар тотып чыга).* Саҗидә, боларны алыштырырга кирәк.
Саҗидә. Әле әйбәт иде бит.
Шәйхи. Юк, юк, мин сиңа импортныйларны куйдыртам. Хәзер үк сантехнигымны җибәрәм. Синең берәр җиргә барасың юкмы?
Саҗидә. Юк.
Шәйхи *(Рәшиткә).* Юк, ди.
Рәшит. Сантехникка аракың бармы соң?
Саҗидә. Бар.

Рәшит. Болай итәбез. Минем синең белән сөйләшәсе бар, Саҗидә. Әйдә, саф һавага чыгыйк әле. Син фатирны биклә дә ачкычны Шәйхигә бир, сантехник үзе ачып керер. Ул эшен тәмамлаганчы мин синең белән Фәндәсне эзләп табу турында сөйләшәчәкмен. Бар әле, Зәйнәпне алып чык. *(Саҗидә күрше бүлмәгә кереп китә.)* Син Фәндәсне монда җибәрәсең. Ул үзе ачып керә. Бу вакытта мин Саҗидә белән йорттан читтәрәк сөйләшеп торачакбыз. Ни турында сөйләшергә табармын. Фәндәс монда кереп эшли башлагач, мин Саҗидәне җибәрәм, өенә керә, шунда Фәндәс белән очрашалар.

Шәйхи. Очрашуларыннан мәгънә булырмы?

Рәшит. Иң элек аларны очраштырып карарга кирәк, аннары күз күрер.

Шәйхи. Тс-с-с, чыгалар. Киттем мин.

Рәшит. Хәзер үк җибәр Фәндәсне.

Шәйхи. Ярар. *(Чыгып китә.)*

Саҗидә *(күрше бүлмәдән чыга).* Әйдәгез, чәй эчеп алыйк.

Рәшит. Чәйләр эчеп тормыйк инде.

Зәйнәп *(күрше бүлмәдән чыга).* Кайтабызмы?

Рәшит. Кайтабыз. Башта Саҗидә белән сөйләшәсем бар. Әйдә урамга.

Саҗидә. Өйдә генә сөйләшмибезмени?

Рәшит *(ялганлый башлый).* Безне алырга машина килергә тиеш, йорт номерын әйттем, ә фатир номерын әйтмәгән идем. Тышка чыгып торсак әйбәтрәк булыр, йә күтеп тормыйча китеп барыр.

Саҗидә *(хәсрәтле кыяфәт белән).* Фәндәсне эзлибезме соң?

Рәшит. Эзлибез, эзлибез, борчылма. Һәм табачакбыз.

Саҗидә. Бөтен ышаныч синдә.

Чыгып китәләр.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук фатир. Музыка. Фатирда Фәндәс пәйда була. Кыяфәте алама, сакал-мыек баскан, иске бушлат кигән, башында иске бүрек, аягында күн итек. Кыршылып һәм катып беткән брезент капчык тоткан — анда ачкычлар, инструментлар, иңенә берничә шланг аскан.

Фәндәс *(үзалдына).* Исәнмесез. Сантехник чакырган идегезме? Менә мин килдем. *(Фатир буйлап йөри, әйберләргә кагылып карый. Бөтен нәрсә таныш, сагындырган.)*

Саҗидә керә. Аның керүен ишетеп, Фәндәс кара күзлек кия һәм тиз генә ванна бүлмәсенә барып эшкә керешә.

Саҗидә *(аны танымый).* Исәнмесез!

Фәндәс *(тавышын үзгәртебрәк).* Исәнмесез!

Саҗидә. Буламы?

Фәндәс. Булдырсаң була ул.

Саҗидә. Шәйхи, яхшы краннар куйдырам, диде дә...

Фәндәс. Әйе, менә бит шуларны куеп ятам.

Саҗидә. Исемегез ничек?

Фәндәс *(томлыгып).* Ф-ф-ф-ф... Фәрит.

Саҗидә. Ашыйсыгыз киләме?

Фәндәс. Минем гел ашыйсым килеп тора.

Саҗидә *(табын өстеннән тастымалны алып куя).* Әйдәгез капкалап алыгыз.

Фәндәс *(кулларын чүпрәккә сөрткәләп).* Хәзер, ясап бетерим инде, күп калмады. *(Тагын эшкә керешә).* Менә хәзер тәртип.

Саҗидә. Болары озакка чыдарлар инде импортный булгач, шулаймы?

Фәндәс *(өстәл янына килеп утыра).* Мәңгелек бернәрсә дә юк. Без бөтен нәрсәне мәңге хезмәт итсен дип телибез, ә бит һәрнәрсәнең азагы, чиге була. Мәхәббәт тә, нәфрәт тә, гомер үзе дә барыбер бер тәмамлана.

Саҗидә *(ашарга әзерли).* Бигрәк моңсу сантехник булып чыктыгыз әле сез. Әллә сез дә кайчандыр институт тәмамлаган, югары белемле кешеме?

Фәндәс *(ашый-ашый).* Әйе, каян белдегез?

Саҗидә. Заманы шундый бит. Дипломыгызны да саткансыздыр әле, акча кирәк булгач...

Фәндәс. Саттым шул.

Саҗидә. Күпмегә?

Фәндәс. Бер миллионга.

Саҗидә. Ашагыз, ашагыз.

Фәндәс. Рәхмәт, бик тәмле булган.

Саҗидә. Гаиләгез бармы?
Фәндәс. Бар иде. Ә сез ялгыз, ахрысы?
Саҗидә. Ашагыз, ашагыз. Тагын салыйммы?
Фәндәс. Салыгыз.
Саҗидә. Карагыз әле, Фәрит, сез бит ЖКУда эшлисез... Анда берәр ничек белеп булмый микән... Бәлки ЖКУга мәгълүмдер... Мин анда барып үзем сорарга оялам... куркам. Мин иремне югалттым.
Фәндәс. Ничек?
Саҗидә. Сәбәп тә юк шикелле. Ә менә югалттым. ЖКУда белмиләр микән кайда икәнлеген, паспортный столда, мәсәлән. *(Елый.)*
Фәндәс. Хатыны белмәгәнне ЖКУ кайлардан белсен икән. *(Кузгала.)* Бик тәмле булды, рәхмәт. Ярый, киттем мин. Сау булыгыз!
Саҗидә. Сау булыгыз.

Фәндәс чыгып китә. Рәшит белән Зәйнәп атылып килеп керәләр.

Рәшит. Ничек, сөйләштегезме?
Саҗидә. Сантехник беләнме?
Рәшит. Әйе.
Саҗидә. Аның белән сөйләшүдән ни мәгънә инде. Ул ничек ярдәм итсен!
Рәшит. Аңламадым?..
Саҗидә. Нәрсә аңламадың?
Зәйнәп. Нәрсә диде соң ул?
Саҗидә. ЖКУда кызыксынырмын, бәлки, паспортисткалар беләләрдер ireңнең кайда икәнлеген, диде.
Зәйнәп. Ә үзе кем соң ул?
Саҗидә. Кем?
Зәйнәп. Ну бу, әле генә чыгып киткән сантехник.
Саҗидә. Бик әйбәт кеше. Фәрит исемле. Гомумән, сантехниклар әйбәт кешеләр барысы да. Чөнки алар һәрвакыт ярдәм итәргә киләләр. Начар кеше ярдәмгә килми. *(Уйга кала.)*
Рәшит. Син аның белән әйбәтләп сөйләштеңме соң?
Саҗидә. Әйе инде, ник аптыратасың.
Зәйнәп. Син аны танымадыңмы соң?
Саҗидә. Юк, кем соң ул?
Рәшит *(Зәйнәпне чеметеп ала).* Бәлки, шулай кирәктер. *(Саҗидәгә.)* Син ул сантехникны моңарчы күргәнең юк идемени?
Саҗидә. Юк, беренче мәртәбә күрүем. Ник алай сорыйсыз?
Рәшит. Мин аны бу тирәдә күргәнем бар шикелле, таныш кебек, шуңа гына кызыксынуым.
Саҗидә. Кайлардан эзләргә соң инде аны?

Шәйхи атылып керә.

Шәйхи. Ну, нәрсә?..
Рәшит. Шаулама! Зәйнәп, Саҗидә, сез теге бүлмәгә чыгып торыгыз әле, монда хәзер штаб утырышы булачак.

Зәйнәп белән Саҗидә күрше бүлмәгә чыгып китәләр.

Шәйхи. Аны Саҗидә танымаган бит.
Рәшит. Аңладым инде. Үзе нәрсә ди соң?
Шәйхи. Бераз күңеле җеби башлады инде аның.
Рәшит. Тагын китертеп булырмы аны монда?
Шәйхи. Хәзер бер чирканчык алгач, китертү җайлырак булыр инде ул, ләкин мөнәсәбәтләре нишләр.
Рәшит. Аны көтелмәгән вакытта, кинәт чакыртырга кирәк. Аварийная ситуация, дип. Һушына да килалмый калсын, суларга да ирек бирмичә Саҗидә белән йөзгә-йөз очраштырыйк.
Шәйхи. Ә Саҗидәгә болай гына әйтсәк, аннары Фәндәс белән әйбәтләп сөйләшеп, юмалап, кавыштырып...
Рәшит. Юк, алай гына булмый. Кеше психологиясен аны бераз алдап, бутап адаштырмасаң, яхшы нәтиҗәгә ирешү мөмкин түгел. Турыдан-туры кешене күндерү бик авыр, аңа көтелмәгән ысуллар белән, күп уйланырга ирек бирмичә юнәлеш бирү җайлырак. Аннары тагын шунысы бар, берәр экстренный сәбәп табып, аны монда китертеп кавыштырсак, табигыйрәк килеп чыгачак. Безнең кушуыбыз буенча очрашу матур булмас бит.

Шәйхи. Ярар, очраштылар ди. Таныдылар ди бер-берсен... Татулашырлармы соң?

Рәшит. Анысы инде безнең эш түгел, иң элек аларны очраштыру мәслихәт. Аннары күз күрер, ситуациясенә карап эш итәрбез.

Шәйхи. Нинди кичектермәс эш табарга соң инде аңа?

Рәшит. Пожар бик куркыныч... Су басу оештырырга кирәк. Фатирны су бассын.

Шәйхи. Ничек итеп?

Рәшит. Үзең сантехниклар кабиләсенең башлыгы, ә үзең миннән сорап утырасың ничек су басарга тиеш дип. Подвалда вентильләр күп бит, берәрсен ачып су тутыртып булмыймыни соң?

Шәйхи. Юк, алай булмый, фәкать өске каттан гына су агызу мөмкин.

Рәшит. Димәк, өске каттагы фатирдан су бастырырга?

Шәйхи. Әйе, краннарыннан озак итеп су агызсаң баса инде ул. Өстәгеләр ризалашырлармы соң?

Рәшит. Ә өстә кем яши соң?

Шәйхи. Укытучы. Элеккеге укытучы. Хәзер эшләми инде.

Рәшит. Дипломын күпмегә сатты икән?

Шәйхи. Бик арзанга бугай.

Рәшит. Нинди фәнне укыта иде?

Шәйхи. Тарих.

Рәшит. О-о-о-о, андый диплом хәзер бушка да кирәк түгел. Тәк, аның укытучы булуы бик әйбәт, димәк, акчасы юк. Түлим мин аңа! Су басарга тиеш бу йортны. Танымаганнар, имеш, бер-берсен. Ничего, су баскач таныйрлар.

Шәйхи *(пошаманга калып).* Карале, өстә дә матавык башланачак бит.

Рәшит. Син, сантехниклар фельдмаршалы, үзең дә аңларга тиеш — тормыш бит бу — су басса кемдер котыла, кемдер бата, кемгәдер фаҗига кайгы китерсә, кемгәдер бәхет китерә. Бар, өскә менеп тарих укытучысын морально әзерли тор, мин хәзер үзем менеп җитәм.

Шәйхи *(икеләнеп).* Ризалашыр микән?

Рәшит. Тарих укытучысы булгач, ул әллә нинди авантюраларга барачак. Беләсең килсә, акча өчен ул бөтен дөньяны суга батырып, үзе генә берәр утрауда калырга да риза. Кеше бит ул, кеше. Дөнья бит ул, Шәйхулла...

Шәйхи. Галимуллович.

Рәшит. Шәйхулла Галимуллович, дөнья бит ул синең исем-отчествоң кебек үк катлаулы түгел. Тормыш ул гап-гади нәрсә, аны без үзебез катлауландырабыз, чөнки шунсыз ямансу. Бар өске фатирга, бу операцияне уңышлы гына ерып чыгалсак, туган көнеңә базардан тагын шәп бер диплом сатып алып бүләк итәчәкмен, батып үлмәсәң. Бар өскә!

Шәйхи. Ярар, киттем мин. *(Менеп китә.)*

Рәшит. Бар! *(Беркавым карап тора һәм телефонның чыбыгын пычак белән кисә.)* Зәйнәп, Саҗидә! *(Хатыннар күрше бүлмәдән чыгалар.)* Саҗидә, мин сине хәзер бикләп чыгып китәм.

Саҗидә. Ник?

Рәшит. Шулай кирәк. Фәндәсең белән очрашасың киләме?

Саҗидә. Килә.

Рәшит. Шулай булгач, тып-тын гына өеңдә утыр. Ни генә булмасын, беркая да чыгып качарга маташма, тыпырчынма.

Саҗидә *(котсыз калып).* Ник куркытасың?!

Рәшит *(тавышын күтәреп).* Фәндәс кирәкме сиңа?

Саҗидә *(газаплы кыяфәт белән).* Ник сорап торасың инде аны!

Рәшит. Шулай булгач, хәтта су басса да өеңдә бул. Кычкырырга рөхсәт ителә, ләкин фатирыңнан чыкма!

Саҗидә. Ни сөйлисең син?!

Рәшит. Тыңла мин әйткәнне! Беркая да китмә, шулай кирәк! Фәндәсеңнән колак кагасың килмәсә. Зәйнәп, киттек.

Зәйнәп *(иркәләнеп).* Минем хөрмә ашыйсым килә.

Рәшит. Түз, түз бераз. Киттек. Саҗидә, беркая да китмә!

Саҗидә. Ярар.

Су баса башлый. Саҗидә бәргәләнә. Телефоннан шылтыратып карый, телефон эшләми. Идәндәге әйберләрне диванга, өстәлгә, креслога ашыга-ашыга күтәреп куя. Нишләргә белми, кычкыра: «Ярдәм итегез, коткарыгыз!» Фәндәс атылып килеп керә. Кара күзлек кигән.

Фәндәс. Нәрсә булды?!

Саҗидә. Коткар!

Фәндәс. Хәзер! *(Өскә йөгереп менеп китә.)*

Шәйхи *(йөгереп керә)*. Ну, ничек?

Сажидә *(кычкырып)*. Ничек, ничек! Батабыз!

Шәйхи. Батмыйбыз! *(Чыгып йөгерә.)*

Рәшит *(Зәйнәпне җитәкләп атылып килеп керә)*. Ну, ничек?! Таныдыңмы?

Сажидә. Нәрсәне, кемне? Ярдәм итегез!

Рәшит. Хәзер! *(Зәйнәбен җитәкләп чыгып йөгерә.)*

Фәндәс *(йөгереп керә, кара күзлеген каядыр югалткан)*. Сажидә, җаным, борчылма! *(Түшәмгә карап тора.)*

Сажидә. Фәндәс?!

Фәндәс. Мин!

Сажидә. Мин сине кайчаннан бирле көтәм!

Фәндәс. Хәзер! Өскә менеп төшәргә кирәк! *(Чыгып йөгерә.)*

Сажидә. Фәндәс!

Шәйхи *(атылып керә)*. Ну, ничек? Сөйләшмәдегезме?

Сажидә. Фәндәс бит ул! *(Артыннан чыгып йөгермәкче була.)*

Шәйхи. Шушында гына бул! Хәзер! *(Чыгып йөгерә.)*

Рәшит *(килеп керә)*. Таныдыңмы?

Сажидә. Таныдым! Өстә ул!

Рәшит. Беркая китмә! *(Чыгып йөгерә.)*

Зәйнәп *(атылып килеп керә)*. Рәшит кайда?

Сажидә. Өстә.

Зәйнәп. Фәндәсне күрдеңме соң?

Сажидә. Күрдем.

Зәйнәп. Рәшит керсә, әйт, мин өстә! *(Зәйнәп чыгып йөгерә.)*

Бик озак шулай чабышып йөриләр. Фәндәс тә берничә тапкыр кереп, чыгып йөгерә. Ниһаять, ул хатыны каршында көчкә сулыш алып басып тора.

Сажидә. Фәндәс, мин сине шундый сагындым!

Фәндәс. Мин дә сине сагындым, Сажидә!

Сажидә. Тукта инде, сөйләшик.

Фәндәс. Ашыкма, су баса бит.

Сажидә. Бассын.

Фәндәс. Мин общий вентильне ябып кына керим инде.

Сажидә. Мин сине танымый тордым бит. Шулкадәре үзгәргәнсең.

Фәндәс. Мин бөтенләй беттем, Сажидә. Фирмам банкротка чыкты, бик каты эчеп алдым. Менә хәзер сантехник булып эшлим. Тормышның асты өскә килде.

Сажидә. Юк, юк, алай түгел. Барысы да тәртиптә... булачак... Кайт тизрәк, миңа синнән башка яшәү юк.

Фәндәс. Минем хәзер бернәрсәм юк, бурычка баттым. Сиңа нигә андый ир?!

Сажидә. Булсын. Баш бәласе түгел. Миңа син кирәк! Миңа синең акчаң да, байлыгың да, машинаң да, фирмаң да — берсе дә кирәк түгел. Миңа син кирәк, Фәндәс, аңлыйсыңмы!

Фәндәс. Сажидә, җаным! *(Хатынын кочаклый.)*

Сажидә. Гафу ит мине!

Фәндәс. Син дә мине гафу ит!

Алар кочаклашып торганда, Шәйхи, Рәшит, Зәйнәп килеп керәләр.

Сажидә. Фәндәс, мине ташлап чыгып китмә, яме.

Фәндәс. Ярар. Хәзер мин вентильне генә ябып керим инде.

Рәшит. Борчылма, борчылма, без Шәйхи белән яптык инде аны.

Шәйхи. Җәмәгать, кочаклашырга җитешерсез, алда гомерләр озын әле. Менә идәндәге бу суны кичекмәстән җыеп түгәргә кирәк. Чөнки мин, участок начальнигы буларак, монда җаваплы кеше. Өстә инде матавык башланды, аста да башлансын дисезмени?

Рәшит. Әйдәгез, бергәләп корытыйк! Зәйнәп, сиңа ярамый, син диванга менеп утыр.

Зәйнәп диванга менеп кунаклый. Рәшит белән Шәйхи чалбар балакларын, җиңнәрен сызганып куялар, тас һәм чиләк күтәреп әрле-бирле чабалар. Сажидә белән Фәндәс бер-берсеннән аерыла алмый һаман кочаклашып торалар.

Шәйхи *(аларга карап тора)*. Карагыз әле, Сажидә, Фәндәс! Аннары кочаклашырсыз. Суны түгик башта.

Рәшит *(җиңеннән тарта).* Комачаулама. Син бигрәк инде, нәчәлник булдым дигәч тә... *(Тыз-быз йөгерешәләр.)*

Шәйхи. Ярый әле пожарниклар катнашмады бу матавыкта.

Рәшит. Аллам сакласын!

Көтмәгәндә Зәйнәп, диванда яткан килеш, шар ярып кычкырырга тотына. Барысы да аның тирәсендә бөтереләләр.

Саҗидә. Тизрәк «скорый» чакырыйк! Тулгак тота башлады.

Шәйхи. Тудыра башлады бугай! «Скорый»га шылтыратыгыз тизрәк!

Рәшит. Телефон эшләми!

Фәндәс. Бар, автоматтан шылтырат!

Рәшит чыгып йөгерә.

Шәйхи. Әстәгъфирулла, тыныч кына яшәргә язмаган икән!

Саҗидә. Хәзер, хәзер, матурым... Барысы да әйбәт булачак!

Зәйнәп тирәсендә ыгы-зыгы дәвам итә.

Тәмам.

*1997*

# ЯВА КАРЛАР, ЯВА КАРЛАР...

*(Ике пәрдәле комедия)*

КАТНАШАЛАР:

Фәндәс.
Саҗидә — Фәндәснең хатыны.
Рәшит.
Зәйнәп — Рәшитнең хатыны.
Шәйхи.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Фәндәсләр фатиры.

Фәндәс *(тәрәзәдән тышка карап тора).* Икенче көн инде кар ява. *(Нәрсәнедер исенә төшергән сыман, кызу-кызу атлап, өстәл янына килә. Илһамланып җыр яза башлый. Терсәкләре белән өстәлгә таянып уйланып утыра. Шуннан соң ашыга-ашыга уйларын кәгазьгә төшерә. Мыр-мыр итеп кенә укып куя. Сикереп торып баянын ала да диванга утырып көен уйнап карый. Тагын өстәл янына килеп җырның текстын тикшерә. Янә баянын алып уйнап ала. Кәгазьгә карап сүзсез генә шыңшып җырлап карый. Шуннан соң баянын читкә куеп тәрәзә янына килә.)* Кар ява да, кар ява. Үзе ямьле, үзе бигрәк ямансу. Күпме карлар яуган бу пычрак дөньяга. Күпме ак төс әрәм киткән ошбу шакшылыкны капларга дип. Күпме генә яумасын ак карлар, кешелек дөньясы кешелек дөньясы булып калыр инде ул. Рәшит белән Зәйнәп нишләп яталар икән... *(Телефоннан шылтырата.)* Алло! Зәйнәп, синме? Исәнме, Зәйнәп! Нихәлләрегез бар? Рәшит нишли?.. Ял йортында?.. Үзе генә киттемени?.. Ярар инде, елама... Төрле чак була. Ышанасыңмы-юкмы, минем Саҗидәм дә ял йортында... Соң, минем үземнең генә барып кайтканым бар иде бит, шуңа күрә ризалык бирдем инде... Эшләрем тыгыз, бармадым, үзен генә җибәрдем... Әйе... Бик сагындым Саҗидәмне. Әллә нинди төшләр күрәм. Инде аңа багышлап җыр да яздым. Ишеп кар ява башлады да, шундук җыр язарга утырдым... Әйе, икенче көн инде кар ява. Шулаймыни... Кайсы тешең? Урт тешеңмени? Менә һава торышы үзгәргәнгә сызлый да инде ул... Кил алайса карыйм. Мин бит хәзер өйдә дә кабул итәм... Дәвалыйм да, кирәк булса, алып та ташлыйм... Авырттырмыйм инде, авырттырмыйм... Такси тот та ун минуттан монда буласың... Ярый, көтәм. *(Телефон трубкасын куя. Телевизорны кабыза. Анда Шәйхи чыгыш ясый.)*

Шәйхи *(телевизордан).* Без, халык депутатлары, халыкның көнкүреш шартлары яхшырсын өчен бар көчебезне куярга тиеш. Милләтебез мәсьәләсенә килгәндә, раковиналар, унитазлар зур роль уйный. Бәдрәфсез һәм ваннасыз халык чын милләт булалмый. Мин депутат буларак кына түгел, ЖЭУ начальнигы буларак та әйтәсем килә: латин графикасына күчү кемгә ничектер, ә минем сантехникларыма бернинди хилафлык китермәячәк. Чөнки минем сантехника инде күптән латинчага күчте. Үзебезнең татар телендә укый алмаучы сантехнигым Дибилмәтев тә унитазлардагы язуларны су урынына эчә. Татарстан мәнфәгатьләрен яклаганда ЖЭУ хезмәткәрләре дә үз сүзләрен әйтергә тиеш.

Конституцияне яңадан кисеп яңадан теккәндә, ичмаса, кран резьбаларын үзгәртмичә «правая резьба» калдырырга иде. Тиздән халык санын алу уздырылачак. Миндә, мәсәлән, бер генә урыс эшли — дворник Кожевников. Калганнары татарлар. Менә мин уйлап-уйлап тордым да, татарларны төрле төркемнәргә бүлгәнче, бердәнбер урыс Кожевниковны үзебезнең шул зур татар төркеменә кушарга булдым. Хезмәт хакына ун процент надбавка ясыйм дигәч, фамилиясен Кожевниковтан Кожиахметовка үзгәртергә вәгъдә бирде.

Шул вакытны Шәйхи үзе килеп керә. Шундук бара да теш дәвалау креслосына утыра. Авызын киң итеп ача. Аның чыгышы телевизордан дәвам итә.

Фәндәс *(әле телевизорга, әле Шәйхигә карап тора).* Запись бирәләрмени?

Шәйхи. Әйе, сүндер. *(Тагын авызын зур итеп ача.)*

Фәндәс *(телевизорны сүндереп Шәйхи янына килә).* Нәрсә борчый?

Шәйхи. Син куйган пломба купты бугай.

Фәндәс *(карый).* Юк, купмаган.

Шәйхи. Тел белән кагылгач кытыршы булып тора бит.

Фәндәс. Тешегезне күптән чистартмаганга ул.

Шәйхи. Әй туган, кәк депутат итеп сайладылар — теш чистартырга түгел, артны кашырга да ара юк.

Зәйнәп керә. Затлы тун кигән.

Зәйнәп. Исәнмесез!

Фәндәс. Исәнме, Зәйнәп, уз әйдә түргә. *(Йөгереп барып Зәйнәпкә тунын салырга булыша.)* Әйдә, әйдә, түргә уз!

Шәйхи. О-о-о, Зәйнәп, нихәл?

Зәйнәп. Ярыйсы.

Шәйхи *(сәгатенә карап).* Ач әле, ач телевизорны.

Фәндәс *(телевизорны ача).* Һаман сез әле монда.

Шәйхи *(телевизордан сөйли).* Чыгышым ахырына якынлашты. Берничә көннән Яңа ел җитә. Барыгызны да якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм. Сезгә саулык-сәламәтлек, эшегездә зур уңышлар телим. Чыгышымны бер җыр башкарып тәмамлыйсым килә. Бу җырны мәрхүм Тәлгать Бариевич бик ярата иде. *(Баянга кушылып җырлый.)*

Сандугачлар су дип эчә
Яфрактагы чыкларны.
Уйлама, җаныем, юкларны,
Уйла бергә йоклауны.

Биек тауның башларында
Эзли бөркет оясын.
Синең белән бер йокласам,
Ник кадалмый дөньясы.

Карурманны чыгам дисәң,
Юктыр аның чикләре.
Синең белән йоклар өчен
Бер генә төн җитмәде.

Сандугачлар су дип эчә
Яфрактагы чыкларны.
Уйлама, җаныем, юкларны,
Уйла бергә йоклауны.

*(Шәйхи җыры.)*

Телевизорда — реклама!

Шәйхи. Ярый, киттем мин.

Фәндәс. Минем сезгә йомыш бар иде фатир буенча...

Шәйхи. Аннары... Яңа ел каршылаганнан соң. *(Чыгып китә.)*

Зәйнәп *(ишек ягына ымлап).* Кеше булган!

Фәндәс. Начар кеше түгел ул... Тик менә һич тотып булмый үзен. Миңа еш килә ул тешләрен дәвалатырга. Килеп керә дә утыра. Авызын карлыгач оясы кадәр иттереп ача. Тешен рәтләгәч чыга да китә. Фатир мәсьәләсен хәл итмәсме дип кайчаннан бирле өметләнеп йөрим. Депутатның вакыты юк инде аның кеше белән аралашырга...

Зәйнәп *(мөлаем кыяфәт белән)*. Ничек хәлләр?
Фәндәс. Ярыйсы болай. Кая, күрсәт тешеңне.
Зәйнәп. Сине күргәч сызламый башлады ул.
Фәндәс. Шәйхине күргәч куркудан басылгандыр ул. Кызыгыз кайда, әбисендәме?
Зәйнәп. Әйе. Саратовта.
Фәндәс. Рәшит кайсы ял йортына китте?
Зәйнәп. Кызылъярга. *(Яңагын тотып.)* Уф, тагын сызлый башлады тешем.
Фәндәс *(гаҗәпләнеп)*. Минем Саҗидәм дә Кызылъярда бит.
Зәйнәп *(җитди кыяфәт белән)*. Димәк, минем ирем дә, синең хатының да бер үк ял йортында яталар... Уф, үләм, тешем...
Фәндәс. Утыр креслога, хәзер дәвалыйм тешеңне.
Зәйнәп. Авырттырма, яме. *(Теш дәвалау креслосына утыра.)*
Фәндәс *(коралларын әзерли)*. Ярар. Аларның бер ял йортында булулары минем дә эчне пошыра... Ә икенче яктан... булсалар ни... Анда кеше күп... Кем кем белән бер ял йортында очрашмас...
Зәйнәп *(кәефе күтәрелә)*. Әйе шул. Карале, тешем сызламый башлады.
Фәндәс *(теш турында бөтенләй онытып)*. Ә мин аңа багышлап җыр яздым.
Зәйнәп. Кемгә?
Фәндәс. Саҗидәмә. Тыңлыйсың киләме?
Зәйнәп. Килә.
Фәндәс *(илһамланып)*. Өр-яңа җыр. Берүзе ял йортына китсә дә, мин аны нык сагындым.
Зәйнәп *(коры гына)*. Шул берүзе киткәнгә нык сагынгансыңдыр син аны.
Фәндәс *(баянын барып ала, урындыкка утыра)*. Берүзе китте шул. Җитмәсә, синең Рәшитең дә шунда икән. *(Йөзенә канәгатьсезлек төсе чыга.)*
Зәйнәп. Җырның исеме ничек?
Фәндәс. «Кар ява...» дип атала. *(Кинәт җитдиләнеп.)* Берүзе ял йортына киткән юньсез хатыным Саҗидәгә багышлана. *(Җырлый.)*

Нигә болай шомлы икән көннәр,
Нидер көткән сыман — тын һава.
Киткәнеңә бары ике атна,
Ә урамда инде кар ява.

Хәзер инде мин — Вакытның колы,
Менә тагын төнгә көн ава.
Бергә йөргән җәйге сукмакларга
Көне-төне ишеп кар ява.

Адашмасаң иде кышкы юлда,
Бу сагышка, ахры, юк дәва.
Тәрәзәләр өмет белән карый,
Ә дөньяга инде кар ява.

*(Фәндәс җыры.)*

Зәйнәп *(чын күңелдән)*. Искиткеч җыр.
Фәндәс *(баянны почмакка илтеп куя)*. Чәй эчәсеңме?
Зәйнәп. Юк, тагын тешкә ябышачак — кайнар ярамый.
Фәндәс. Өй салкын бит, җылыныр өчен дә чәй эчү ярый.
Зәйнәп. Безнең дә өй салкын. Телевизордан берәр кызык нәрсә юк микән?
Фәндәс. Хәзер кабызам. *(Телевизорны кабыза. Анда тагын Шәйхи чыгыш ясый.)*
Шәйхи *(телевизордан сөйли)*. Быел җылылыкны иртәрәк бирергә уйлыйбыз. Туңган халык ул чын милләт булалмый. Җылылык татарларга гына түгел, башка милләтләргә дә кирәк. Әйтик, без татар фатирларына җылы биреп, урыс яки чуаш яши торган фатирга бирми калалмыйбыз. Бу — сәяси генә түгел, шулай ук әхлакый мәсьәлә. Мин депутат буларак та шуны әйтә алам: халыклар дуслыгын ныгытуда ҖЭУлар зур роль уйный алыр иде.

Шәйхи үзе килеп керә. Телевизорга карап тора.

Зәйнәп. Сезне телевизордан карап утыра идек.
Шәйхи. Ә-ә-ә, узган атнадагы запись. *(Зәйнәпкә карап тора.)* Син һаман монда икән... Мин телефонны калдырганмын. *(Кресло янындагы урындыктан телефонын алып кесәсенә тыга.)* Сау булыгыз! *(Чыгып китә.)*
Фәндәс. Сау булыгыз!

Шәйхи *(телевизордан чыгышын дәвам итә).* Мин җитәкли торган ЖЭУда милли проблема юк. Минем сантехникларым һәрбер фатирны намус белән обслуживать итәләр — урысныкымы ул, татарныкымы, чуашныкымы. Әле күптән түгел хәтта бер немецка да раковина куйдылар. Чыгышымның ахырында мин сезгә мәрхүм Тәлгать Бариевичның яраткан җырларының берсен башкарасым килә. *(Баян уйнап җибәрә, баянга кушылып җырлый.)*

Сандугачлар су дип эчә
Яфрактагы чыкларны,
Уйлама, җаныем, юкларны,
Уйла бергә йоклауны.

Зәйнәп. Сүндер, зинһар! *(Фәндәс барып телевизорны сүндерә.)* Эчем поша... Рәшит белән синең хатының бер ял йортында. Бу очраклы дип уйлыйсыңмы?

Фәндәс *(уйга кала)*. Саҗидә булмаса, башка хатын-кыз күп анда, Рәшит булмаса да, ир-ат җитәрлек... Безнең дә синең белән танышу ял йортында булган иде бит.

Зәйнәп *(чыраен сытып)*. Уф, тешем сызлый башлады.

Фәндәс. Утыр креслога. *(Зәйнәпне теш дәвалый торган креслога утырта.)* Ач авызыңны.

Зәйнәп. Зур итепме?

Фәндәс *(шприц белән килә).* Синең авыз ничек ачсаң да зур. Ач, курыкма, мин сиңа авырттырмый торган импортный укол кадыйм.

Зәйнәп ыңгырашып авызын ача. Фәндәс укол кадый. Зәйнәп кычкырып куя.

Фәндәс. Булды. Бер биш минут утыр, шуннан соң тешеңне дәвалый башлыйм.

Зәйнәп *(ыңгыраша)*. Минем башым әйләнә. Нашатырька!

Фәндәс. Әйдә, диванга ят. *(Зәйнәпне култыклап алып барып диванга яткыра.)*

Фәндәс Зәйнәпне диванга яткырып маташканда, Саҗидә кайтып керә.

Саҗидә *(сумкаларын идәнгә ташлап).* Комачауламадыммы?

Фәндәс *(котсыз калып)*. Юк... син нәрсә... Саҗидәм, бәгърем, кайтып җиттеңмени?

Саҗидә. Рәхәттер сиңа: бер бәгырең кайтып җитте, икенче бер бәгырең диванда сузылып ята.

Фәндәс *(ничек акланырга белми)*. Мин сиңа хәзер аңлатып бирәм... Син тегенди-мондый нәрсә уйлый күрмә... *(Ни әйтергә белми.)* Аның авызы хәзер наркозлы...

Саҗидә *(усал тавыш белән)*. Хәзер авызны башта наркозлыйлармыни?

Фәндәс *(хатынына чишенергә ярдәм итә)*. Син, зинһар, тегенди-мондый нәрсә уйлый күрмә!

Саҗидә *(ирония белән)*. Юк инде, кайтуыма диванымда чит хатын яткач, нишләп мин тегенди-мондый нәрсә уйлыйм. Монда гомумән уйланып торасы юк.

Фәндәс *(тавышын күтәреп)*. Саҗидә, син, гадәттәгечә, кайнарланып, аңыңны үзең томалап гасабиланасың. Тагын матавык чыгарырга маташасың.

Саҗидә *(җикереп)*. Кайтуыма диванда Зәйнәп яткач мин нишләргә тиеш! Зәйнәп булмады бу... Теге вакытта курорттан ул синең артыңнан ияреп кайткач, хәтерлисеңме, тормышның ничек асты өскә килгәнне?!

Фәндәс. Ну, бетте бит инде, ул вакытны ачыкланды барысы да. Зәйнәп Рәшиткә кияүгә чыкты. Рәшит синең янга кунакка килгән иде ул вакытта, онытмадыңмы?!

Саҗидә. Мин аны сиңа ачу итеп кенә чакырган идем. *(Бүлмә буйлап ары-бире атлый.)* Менә сиңа мә! Яңа ел алды булгач, бер-ике көнгә алдан кайтып Яңа ел каршыларга әзерләнә башлармын дигән идем... Ә монда... кайтмасам да әзерләнәсе булганнар икән.

Фәндәс *(өзгәләнеп)*. Юк, алай түгел! Ник ышанмыйсың миңа?!

Саҗидә *(Зәйнәпкә таба бара)*. Син инде берничә ел элек Фәндәс артыннан монда кайтып кергән идең... Һаман да шундый ук сөйрәлчек булып калгансың икән!

Зәйнәп *(авызын ача алмый, көчкә җавап бирә)*. Минем наркоз! Синең ни хакың бар мине мыскыл итәргә?!

Саҗидә *(мыскыл итеп).* Наркоз аның... Сине күргәч минем бөтен башым наркозлана, миемне көзән җыера башлый.

Зәйнәп *(авызын ача алмыйча борын төбеннән мыгырдый)*. Фәндәс, мин шылтыратып алыйм әле.

Фәндәс. Шылтырат.

Зәйнәп *(телефоннан көчкә сөйләшә).* Алло!.. Зәйнәп... Әйе, мин... Нәрсә булсын минем авызымда?! Наркоз! Укол кададылар! Син кайтып җиттең дәмени? Иртәрәк кайтырга булдыңмы? Ә-ә-ә, Яңа ел каршыларга алданрак әзерләнергә дип... Минме?.. Иптәш хатында кунакта... Хәзер кайтып җитәм. *(Трубканы куя.)*

Фәндәс *(сагаеп)*. Рәшит кайтканмы әллә?

Зәйнәп *(яңагын тотып Сажидәгә карап тора)*. Әйе. Мин өемә шылтыраттым. Кайткан.

Фәндәс *(күзләрен акайтып)*. Рәшит тә Кызылъярда ял итте. *(Сажидәгә.)* Син дә шунда идең бит...

Зәйнәп *(борын төбенә мыгырдый)*. Син дә, Рәшит тә бер үк ял йортында булдыгыз...

Сажидә. Шуннан?

Зәйнәп *(яңагын тотып чыраен сыта)*. Бер үк көнне кайтып төштегез... Син Яңа ел алды дип иртәрәк кайткансың... Ә ничек әле ул Рәшит тә нәкъ шулай уйлаган?

Сажидә. Анысын син үзеңнең Рәшитеңнән сорарсың, яме. *(Тагын кызып китә.)* Теше сызлаган оятсызның! Икәүләшеп утыралар, кайтуыма, мин сиңа әйтим... Бирермен мин сиңа наркоз!

Зәйнәп *(ыңгырашып)*. Мин теш дәвалатырга дип килдем. Ә сез Рәшит белән бер ял йортыннан бер үк вакытта кайттыгыз. Мин бит өйдән күптән түгел килдем.

Фәндәс *(аптырап)*. Мин дә пошаманга калдым әле, Сажидә...

Сажидә *(кычкырып)*. Нәрсә, шикләнәсезме?.. Мин Рәшитнең шул ял йортында икәнен белмәдем дә, мин аны анда күрмәдем дә. Бер үк көнне кайтуыбыз да очраклы хәл. Ә менә бу пумала башның монда булуы мине чынлап та шөбһәгә сала.

Фәндәс *(тыныч булырга тырышып)*. Син, Сажидә, Зәйнәпкә каты бәрелмә әле. Чынлап та теше сызлый аның. Теше сызлагач кеше килә инде ул... Шәйхи, мәсәлән, инде әллә ничә тапкыр килеп китте.

Шәйхи атылып килеп керә.

Шәйхи. Исәнмесез тагын бер тапкыр! Фәндәс, выручай, пломба купты бугай. Кайнар чәй эчкәндә авыртты. *(Креслога барып утыра.)* Ничек ял иттең, Сажидә?

Сажидә. Ярыйсы.

Шәйхи. Рәшит монда түгелмени?

Фәндәс *(гаҗәпләнеп)*. Рәшит монда булырга тиешмени? *(Шәйхинең авызын карый.)*

Шәйхи. Ник, Сажидәнең сумкаларын күтәрешеп кайтканын күргәч, сез монда бергәләп чәй эчәсездер дип уйлаган идем.

Фәндәс *(инструментын шалтыратып савытка ташлый)*. Сезнең тешләрегез әйбәт. Мин куйган пломбалар да урыннарында.

Шәйхи. Алайса, погодадан сызлыйдыр. *(Зәйнәпкә.)* Нәрсә, яңагыңа берне тарттылар да мәллә инде?

Фәндәс. Укол кададым мин аңа.

Зәйнәп *(еламсырак тавыш белән)*. Рәшит сумкаларын күтәрешеп кайттымыни?

Шәйхи. Соң, инде якын танышыңның, бигрәк тә хатын-кызның әйберләрен күтәрешеп кайту бар инде ул. Ярый, рәхмәт, мин Госсоветка киттем. *(Чыгып китә.)*

Фәндәс *(Сажидәгә таба бара)*. Әле ул сине озата ук килдемени?

Сажидә *(каушавын күрсәтмәскә тырышып)*. Әйе, ял йортында очрашып, күрешеп йөрдек. Күптәнге танышлар буларак сөйләшеп тә торган чаклар булгалады. Бергә кайтырбыз дидек. Бер шәһәргә кайтабыз бит инде... Танышлар... Әйберләремне күтәрешеп кайтты. Бергә кайту ничек тә җиңелрәк, тынычрак. Нәрсәсе бар инде аның?!

Зәйнәп *(борыны белән)*. Ял йортында болай гына очрашмыйлар.

Сажидә *(ачу белән)*. Бөтен кеше дә син түгел бит! Бәлки, син анда себерелеп йөргәнсеңдер. Ә менә мин андый түгел. *(Кычкырып.)* Нишләп минем фатирда син? Минем ирем белән, ә?!

Фәндәс *(җикерә)*. Җитте! Зәйнәп, беркая да китмисең! *(Телефоннан шылтырата.)* Алло! Рәшит, сәлам! С приездом! Бу Фәндәс иде әле... Таныдыңмы... Ничек ял иттең соң?.. Әйбәтме... Минем Сажидәне очратмадыңмы син анда алай-болай?.. Юкмыни?! Ул да шул ял йортына киткәние... Күрмәдең алайса?.. *(Трубканы ташлый.)*

Зәйнәп *(авызын кыйшайтып)*. Менә бит, көн кебек ачык. Берсе, очраштык, ди. Икенчесе, юк, ди.

Телефон шылтырый.

Фәндәс *(телефон трубкасын алып).* Алло!.. Ә-ә-ә, Рәшит... Ташлыйсы килде... Мә, Зәйнәбеңә бирәм, сөйләш... Әйе, монда ул.

Зәйнәп *(трубканы ала, наркозлы икәнен дә онытып кинәт кычкыра башлый).* Сволочь! Паразит! Изменщик! Мразь! Кабахәт! Подлец! Подонок! Тварь! Кобель! Дерьмо! Черт! Хайван! Чмо! *(Трубканы ташлый.)*

Фәндәс *(күзләрен әйләндереп)*. Акылдан язарга була. *(Нишләргә белми арлы-бирле йөри. Аптырагач барып радионы кабыза. Радиодан Шәйхи чыгыш ясый.)*

Шәйхи *(радиодан сөйли).* Без, халык депутатлары, Яңа ел алдыннан сайлаучыларыбызга нәрсә әйтә алабыз соң — шуны да уйлыйк. Ватандашларыбызга нинди бүләкләр әзерләдек бу юлы?! Бер-беребезгә нинди сюрпризлар күрсәтергә җыенабыз? Яңа елга берничә көн калды. Әйдәгез уйлыйк.

Фәндәс. Уф, монысы да тәмам туйдырды. *(Радионы сүндерә.)*

Сажидә *(Зәйнәпкә карап тора)*. Мин аңламыйм, нишләп син монда?

Зәйнәп *(тавышын көчлерәк чыгарырга тырышып)*. Син сорамас микән дип! Кая барыйм мин хәзер? Минем бит синеке шикелле бу шәһәрдә әнием яшәми.

Сәҗидә. Иренә теләсә нәрсә әйтте дә, хәзер өенә кайтырга да курка. Саратов себеркесе!

Зәйнәп. Пошла вон! *(Диванга барып ята.)*

Фәндәс *(нәфрәтләнеп)*. Теше сызлап килде ул. Син җавап бир: нишләп Рәшит белән бер үк вакытта, бер үк ял йортына барып, аннан бер үк көнне бергә кайтып төштегез?

Ишек кыңгыравы зеңгелди.

Зәйнәп *(диваннан сикереп тора)*. Рәшит килде!

Ишекне ачалар. Шәйхи керә.

Шәйхи. Гафу итегез... Мобильныемны онытып калдырганмын. *(Эзли. Теш дәвалый торган креслодан табып ала.)* Менә бит ул. Гел онытып калдырам мин аны. Сез нәрсә кайгыга баттыгыз? Бер-бер фаҗига килеп чыкмагандыр бит?

Фәндәс. Юк, юк.

Ишек кыңгыравы зеңгелди. Рәшит керә.

Рәшит. Исәннәрмесез! *(Коры гына.)* Зәйнәп! Син нишләп монда?

Зәйнәп *(куркып)*. Теш сызлады.

Рәшит *(Зәйнәпнең яңагына җиңелчә генә суга)*. Суккач, бәлки, туктар сызлавы.

Шәйхи. Туктале, Рәшит, депутат алдында хатын-кызга сукмыйлар инде. Ул да бит минем избиратель.

Фәндәс. Менә карагыз әле, Шәйхулла...

Шәйхи. Галимуллович.

Фәндәс. Шәйхулла Галимуллович! Рәшит белән Сәҗидә бер ял йортында булганнар... Бергә кайтканнар...

Рәшит *(катгый итеп)*. Юк! Мин синең хатыныңны анда вабше күрмәдем. Күрәсем дә килми. Мин аның белән анда очрашмадым.

Фәндәс *(сынаулы караш белән)*. Бит Шәйхулла Галимуллович Сәҗидәнең сумкаларын күтәрешеп озатып куйганыңны күргән.

Шәйхи *(кашларын җыерып уйланып торган була)*. Бәлки, башка кеше булгандыр... Мин алай төп-төгәл әйтә алмыйм... Чөнки сез барыгыз да минем избирательләрем...

Фәндәс. Юк инде, төгәл әйтергә тиешсең. Сәҗидә бит үзе әйтеп бирде инде. *(Тынлык урнаша.)*

Рәшит. Ну, ярый, озатып куйдым ди... Шуннан ни булган?

Шәйхи. Да!

Рәшит. Ә менә минем кайтуыма хатыным өйдә юк. Ул синдә икән. *(Нәфрәтләнеп.)* Минем иртәрәк кайтуымны көтмәгән идегезме?..

Фәндәс. Теш дәвалатырга килде ул!

Рәшит *(ачу белән)*. Имынны мин югындамы?..

Фәндәс *(ясалма ягымлылык белән)*. Кешенең теше син кайда булуга карамастан сызлый. Хәтта син үлгәч тә кешеләрнең тешләре авыртачак.

Шәйхи. Да! *(Җитди кыяфәт белән.)* Мәрхүм Тәлгать Бариевич әйтмешли, үлгән кешенең генә теше сызламый.

Сәҗидә *(чарасызлыктан нишләргә белми)*. Ирләре ирләр төсле түгел. Шәйхулла әфәнде, кайвакыт кайбер нәрсәләрне күрмәү яхшырактыр, минемчә.

Шәйхи *(бармагын өскә күтәреп)*. Мин — депутат! Бөтен нәрсәне күрергә тиеш.

Фәндәс *(Сәҗидәгә чәрелдәп кычкыра)*. Вон! Анаң янына!

Сәҗидә тиз генә киенеп чыгып китә.

Рәшит *(тешләрен кысып)*. Ә син чәчбикамал, нәрсә шпрот сыман торчать итеп торасың?! Марш өйгә! *(Зәйнәп тунын эләктерә дә кимичә генә чыгып китә.)*

Шәйхи *(кыяфәтенә чиксез канәгатьсезлек чыгарып)*. Һич тыныч яши алмыйсыз сез, әйеме. Сезнең арада гел матавык чыгып тора.

Рәшит *(кырыс кына)*. Менә сезнең ишеләр телен тыймаганга шулай ул.

Фәндәс *(кулын болгап)*. Ә нишләп телен тыярга тиеш ул?! Мин — аның избирателе! Ул — минем даими пациентым!

Шәйхи. Да! Народный избранник белән чамалап сөйләшүегезне үтенәм! Мин, между прочим, тиздән Гаагадагы международный трибуналда эшләячәкмен. Инде күптән чакырып йөриләр. Саграк кыланыгыз. *(Чыгып китә. Шундук яңадан борылып керә.)* Мобильный калган. *(Өстәлдән телефонын алып чыгып китә. Тынлык урнаша.)*

Рәшит *(Фәндәскә карап тора).* Ну, нишлибез?

Фәндәс *(Рәшиткә карап тора).* Белмим.

Рәшит *(тыныч кына).* Ял йортыннан кайтып килүче хатыныңны өенә кадәр озатып куюым, минемчә, сиңа көнләшергә һич кенә дә сәбәп булалмый. Таныш хатынга ярдәм итү, сумкаларын күтәреп илтеп кую — фәкать джентльменлык билгесе. *(Кыза башлый.)* Ә менә кайтуыма хатынымның синдә булуы — Яңа елга миңа бик зур бүләк!

Фәндәс *(ялварулы тавыш белән).* Рәшит, тыңла мине. Хәлегезне белим дип, ни эшләр бетереп ятасыз икән дип сезгә шылтыраттым. Зәйнәп өйдә иде. Сине, ял йортына китте, диде. Тешем сызлый, диде. Кил, дидем, дәвалыйм, дидем. Таныш хатынга, үзең әйтмешли, ярдәм итү — джентльменлык ул. Сиңа көнләшерлек бернинди сәбәп юк. *(Кинәт тавышын күтәреп.)* Ә минем шикләнүләрем исә урынлы дип саныйм, чөнки мин теге вакытта ял йортыннан кайткач, син үзең Сәҗидә янына шампанскийлар күтәреп килгәниең.

Рәшит. Ну, ул вакытта синең Сәҗидәң белән минем арада бернәрсә юклыгын аңлаштык бит инде.

Фәндәс *(уйга калып).* Ә хәзер мин чынлап та шикләнә башладым — теге вакыт өчен дә, хәзер дә...

Рәшит *(иреннәрен нечкәртеп).* Син онытма, ул вакытта ял йортыннан синең арттан Зәйнәп кайтып җиткәние.

Фәндәс *(кыю булырга тырышып).* Син бит аңладың Зәйнәп белән минем арада берни булмаганны.

Рәшит *(нәфрәт белән).* Хәзер инде чын-чынлап шикләнәм — теге вакыт өчен дә, хәзергесе өчен дә...

Фәндәс *(җикереп).* Теге вакытта Зәйнәп миңа ияреп кайткач, ник аңа өйләндең соң син?!

Рәшит *(кычкырып).* Анда синең эшең юк! Ә син үзең шикләнгәч, ник Сәҗидәң белән яшисең?

Фәндәс *(кинәт тынычланып).* Мин яратам аны. *(Тәрәзә янына китә.)* Мин аны шулкадәр нык яратам. Синең гомереңдә дә алай яратканың юктыр.

Рәшит *(шулай ук кинәт тынычлана).* Ник алай уйлыйсың?

Фәндәс *(тышка карап).* Мәхәббәт иясенә охшамагансың син.

Рәшит *(үзен кулга алып).* Ярар, ярар, син психотерапевт түгел, син — теш врачы. Кеше сыйфатлары хакында сүз йөртмә. *(Җитди кыяфәт белән.)* Фәндәс туган, мин инде элеккеге Рәшит түгел... Тормыш басты... Ул Зәйнәп белән дә бик авыр яшәве... Ну, эш анда түгел... Минем әйтәсем килә... чын күңелдән... ант итәм... Синең Сәҗидәң белән минем арада берни юк. Булганы да юк. Сумкалары авыр иде, шуңа күрә озатып куйдым. Син рәхмәт кенә әйтергә тиешсең моның өчен. Көнләшмә. Синең хатының хыянәт итә торган кеше түгел, беләбез бит инде... Үзең дә беләсең.

Фәндәс *(коры гына).* Рәхмәт. Мин дә элеккеге Фәндәс түгел... *(Кыза башлый.)* Мине дә тормыш басты... *(Нәфрәт белән.)* Әшәкеләндем... Мин элек мондый түгел идем... Тормыш кырысландырды, явызлык өстәде...

Рәшит *(сагаеп).* Болай дип нәрсә әйтмәкче буласың?

Фәндәс *(яман усал итеп).* Мин сиңа хәзер дөресен әйтәм! Әзер тор! *(Сәҗидәнең юл сумкасын тибеп аудара. Рәшит янына килеп баса.)* Син ял йортында чакта Зәйнәбең гел миндә булды! Син киткән көнне үк очраша башладык. *(Мыскыллап елмая.)* Китмәссең ял йортына хатыныңнан башка үзең генә!

Рәшит *(Фәндәсне буып ала).* Юк! Ышанмыйм!

Фәндәс *(гырылдый).* Ы-ы-ы! *(Рәшит Фәндәсне җибәрә.)* Үтерәләр! *(Рәшит аны тагын буа, теге гырылдый башлагач җибәрә. Фәндәс еш-еш сулап хәл җыеп тора.)* Бусаң да, бумасаң да, Зәйнәбең миндә булды.

Рәшит *(нишләргә белми, арлы-бирле йөри).* Мин дә дөресен әйтергә мәҗбүр. *(Фәндәс каршына килеп баса, битенә төкерекләрен чәчеп сөйли.)* Беләсең килсә, синең сөекле хатының Сәҗидә белән без алдан сүз куешып Кызылъяр ял йортына киттек. Анда без гел бергә булдык! Менә бергә кайтып төштек. *(Авызын кыйшайтып елмая.)* Җибәрмәссең хатыныңны үзен генә ял йортына! *(Фәндәс өнсез калып торганда, Рәшит ишекне атып чыгып китә.)*

Фәндәс *(җан өзгеч тавыш белән кычкыра).* А-а-а-а!

Ут сүнә. Музыка. Ишеп кар ява. Буран башлана. Фатирга кар тула, һәм ап-ак көртләр хасил була.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Рәшитләр фатиры. Зәйнәп үзен кая куярга белми. Елый. Әйберләрен сумкаларга, чемоданнарга тутыра башлый, кинәт бу эшеннән туктый. Шкафтан дару алып эчә. Шундук тынычлана. Телевизорны кабыза. Телевизордан Шәйхи чыгыш ясый.

Шәйхи. Халыкны сыйфатлы дарулар белән тәэмин итү дә безнең зур бурычыбыз булып тора. Бигрәк тә йөрәк-кан тамырлары дарулары турында кайгыртырга тиешбез. Нервылары бетте халыкның. Тынычландыру даруларын үзебезнең бакча артында үсә торган үләннәрдән дә әзерләп була...

Зәйнәп *(сискәнеп телевизорны сүндерә).* Йа Ходаем, әллә берәү генә түгел инде бу! *(Торып бүлмә буйлап йөри. Барып үзен көзгедән карап тора. Куллары белән билен кысып боргаланып карый. Юбкасын күтәреп ботларын күзәтә. Ыржаеп алгы тешләрен карый.)*

Саҗидә керә. Кыяфәте яман.

Саҗидә *(күзгә каршында басып торучы Зәйнәпкә мыскыллы караш белән карап).* Чибәр, чибәр.
Зәйнәп. Сама знаю. Сиңа ни кирәк?
Саҗидә *(авызын кыйшайтып)*. Сагындым сине.
Зәйнәп *(ясалма битарафлык белән)*. Күптән күрешкән юк шул. Минемчә, безнең икебезнең берсе үләргә тиеш.
Саҗидә. Мин беләм кем үләргә тиеш икәнне.
Зәйнәп. Мин дә чамалыйм.
Саҗидә. Ничек җир йотмый синең кебек оятсызны?!
Зәйнәп. Сине йотмаганны, ничек мине йотсын әле ул?!
Саҗидә *(үзен кулга алырга тырышып)*. Әйдә, ихлас күңелдән сөйләшик әле.
Зәйнәп. Сөйләшеп карыйк, тик барып чыгар микән.

Кара-каршы утыралар.

Саҗидә *(таләпчән тавыш белән)*. Син кайчан минем гаиләмне җимерүдән туктаячаксың?
Зәйнәп *(тыныч кына)*. Мин синең гаиләңә бер ягым белән дә кагылганым юк. Ә менә син үзең кайчан минем күземә чалынудан туктаячаксың?
Саҗидә. Синең аркада гына очрашабыз түгелме без?! Мин сине мәңге күрмәсәм, үземне дөньяда иң бәхетле кеше дип санар идем.
Зәйнәп. Бәхетең минем белән генә бәйлемени синең? Син нәрсә, миңа ачу итеп Рәшит белән ял йортына киттеңме әллә?
Саҗидә *(башын читкә борып)*. Мин үзем генә бардым ял йортына.
Зәйнәп *(күзләрен чекерәйтеп)*. Ну, син минем Рәшитем белән булгансың бит анда.
Саҗидә *(кырт кисеп)*. Юк!
Зәйнәп. Менә син ул оятсыз!
Саҗидә Минме оятсыз?! Син нишләп яттың минем фатирда?
Зәйнәп. Соңгы тапкыр әйтәм, бүтән кабатламыйм: тешем сызлады, теш дәваларга бардым.
Саҗидә *(авызын җәеп елап җибәрә).* Уф, гарьлегемнән үлә-ә-ә-м. *(Кинәт елаудан туктый.)* Ярый. Минем дә йөрәгем бар. Минем дә түземлегемнең ахыры-чиге бар түгелме! Әзер бул — мин сиңа хәзер дөресен әйтәм!
Зәйнәп *(мыскыллы караш белән)*. Йә, йә...
Саҗидә *(усал итеп)*. Әйе, без, Рәшит белән алдан сөйләшеп, бер ял йортына киттек. Анда бергә яшәдек. Менә бер үк көнне кайттык. Без бер-беребезне яратабыз. Аңладыңмы?!
Зәйнәп *(үзен көчкә кулга ала, дару йота).* Мин беләм, барысын да беләм. Ә хәзер инде син сумкаңдагы даруларыңны барлап куй. Бер-ике таблетка алдан капсаң да ярый. Чөнки мин дә хәзер сиңа дөресен әйтәчәкмен.
Саҗидә *(тиз генә сумкасыннан бер-ике төймә дару алып каба)*. Тыңлыйм.
Зәйнәп *(ишетелер-ишетелмәс кенә)*. Сез ял йортында вакытта мин сезнең фатирда синең Фәндәсең белән яшәдем.
Саҗидә *(куллары салынып төшә, кинәт хәлсезләнә).* Кабахәтләр!

Икесе дә чарасыз тып-тын утыралар, хәтта талашырга да хәлләре юк. Тышта буран улый. Ике хатын шулай хәлсезләнеп бер-берсенә тонык күзләре белән карашып утырганда, Рәшит кайтып керә. Буран кинәт көчәя.

Рәшит *(хатыннарның әле берсенә, әле икенчесенә карап тора).* Нишләдегез сез? Бер-бер нәрсә ашадыгызмы әллә?
Зәйнәп *(ыңгырашып).* Подлец!
Рәшит *(кизәнә, ләкин сукмый).* Пошла ты! *(Барып телевизорны кабыза. Телевизордан Шәйхи чыгыш ясый.)*
Шәйхи *(телевизордан).* Гаилә ул — җәмгыятьнең иң мөһим ячейкасы. Ир белән хатын мәсьәләсен без уйлап чыгармаган, ә табигать үзе. Ләкин шуңа да карамастан депутатлар да, ЖЭУ хезмәткәрләре дә бу мәсьәләне читтән генә күзәтергә тиеш түгел.
Рәшит. Понятно. *(Телевизорны сүндерә.)* Буран, буран... Бар дөньяны томалаган.

Буран көчәя. Музыка. Рәшит җырлый.

Бар дөньяны, буран, камап алдың,
Җитми һава, киләчәкне томалама.
Ярсуыңнан шашып давыллама,
Яңа елга юлны син каплама!

Кушымта:

Буран, буран, буран,
Һәр тарафка инде кереп тулган.
Сулышыңнан һәммәсе дә туңган,
Тукта, буран, тукта, һәй, буран!

Бар дөньяны буран камап алган,
Үзәгемне калын көртләр сарган.
Шул көртләрне туздырмакчы булып
Бәргәләнә күңелем буран сыман.

Кушымта:

Буран, буран, буран,
Һәр тарафка инде кереп тулган.
Сулышыңнан һәммәсе дә туңган,
Тукта, буран, тукта, һәй, буран!

*(Рәшит җыры.)*

Караңгылык урнаша. Сәхнә яктырганда Рәшит үзе генә каңгырып утыра. Шәйхи керә.

Шәйхи. Сәлам!

Рәшит. Сәлам!

Шәйхи. Ызгыш минем аркада килеп чыкты мәллә?

Рәшит. Әллә тагы... Но Саҗидәнең әйберләрен күтәрешеп кайтканымны әйтмәсәң дә була иде.

Шәйхи. Ну күтәрешсәң ни булган! Нәрсәсе бар инде аның!

Рәшит. Әнә аңлатып кара.

Шәйхи. Зәйнәп кайда соң?

Рәшит. Белмим. Мин сезнең белән дорфа сөйләшкәнем өчен гафу үтенәм. Мин сезне сантехник чагыгыздан бирле хөрмәт итәм.

Шәйхи. Мин дә сине бандит чагыңнан ук беләм. Шаярам, шаярам. Әйе, мин гап-гади сантехник идем. Мин вак-төяккә игътибар итмәдем. Шуңа күтәрелдем мин. Ә син шәлберәеп барасың. Фәндәс тә шулай. Ну аның хет эше блатной.

Рәшит. Әйе, сез күтәрелеп барасыз, гел югарыга таба юнәләсез. Мин бик шат.

Шәйхи. Да. Әле син белмисеңдер, мине бит ООНга эшкә чакыралар.

Рәшит. Сантехник итепме... Ой... Сантехниклар белән җитәкчелек итәргәме дип сорамакчы идем.

Шәйхи. Син нәрсә инде, ыслушай...

Рәшит. ЖЭУлар буенчамы?

Шәйхи. Юк, юридический мәсьәләләрне карый торган бүлеккә. Анда бит тоже сөрсегәннәр, малай, свежий башлар анда да кирәк бит. Вәт, инде чакыру бар миңа. Гаагадагы трибуналга да чакырып йөриләр.

Рәшит *(каушый)*. Алайса, зинһар, миңа ярдәм итегез.

Шәйхи. Нинди ярдәм кирәк сиңа?

Рәшит. Мин Зәйнәпне кыйнадым.

Шәйхи. Ну и што! Депутат буларак мин төкерәм хатыныңны кыйнавыңа. Ә менә ЖЭУ начальнигы буларак «алай ярамый» дип әйтәсем килә. Ә ир кеше буларак «дөрес эшләгәнсең» дип әйтергә дә могу.

Рәшит *(кинәт җанланып)*. Сез хәзер зур кеше. Ярдәм итегез. Нишлим, ичмаса, киңәш бирегез. Мин Зәйнәпне кыйнадым.

Шәйхи. Ныкмы?

Рәшит. Тәпәләдем инде.

Шәйхи. Милициягә гариза яздымы әллә?

Рәшит. Юк.

Шәйхи. Шулай булгач, аптырама бер дә.

Рәшит. Аннары... Мин бит Фәндәсне алдадым. Аның хатыны белән ял йортында бергә булдык дип. Булмадык. Анда мин Саҗидәне күрдем, анысын яшермим. Хәл-әхвәлләрне сораштык та бетте шуның белән.

Шәйхи. Ә ник алай дидең соң Фәндәскә?! Шулай ярыймы соң инде?!

Рәшит. Ачу килде. Фәндәс тә бит миңа «Зәйнәп белән булдык» диде.

Шәйхи. Менә сиңа мә. Берничә ел элек көчкә котылган идегез бер матавыктан. Нишләп соң сез тыныч кына яши алмыйсыз?! Ярый, уйлармын. Берәр җай чыкмасмы... Хыянәт булмадымы?

Рәшит. Юк!

Шәйхи. Ярар, ярдәм итеп карармын. Борчылма. *(Киң елмаеп.)* Уйлама, җаныем, юкларны, уйла бергә йоклауны.

Рәшит. Беркая да китми торыгыз, зинһар. Мин хәзер, биш минуттан әйләнеп керәм.

Рәшит чыгып китә. Күп тә үтми, Фәндәс килеп керә. Нервылана. Бүлмә буйлап йөри. Истерикага бирелә. Шәйхи аны көчкә тынычландыра.

Фәндәс. Рәшит кайда?

Шәйхи. Хәзер кайта ул.

Фәндәс. Җүләр мин! Рәшиткә коточкыч ялган әйттем. Аның хатыны миндә ятты дидем.

Шәйхи. Ник алай дидең соң?

Фәндәс *(калтыранып)*. Ачуым килде. Бер үк көнне ял йортыннан кайтканнарына ачу килде. Алдадым.

Шәйхи. Рәзве шулай ярый! Ник тыныч кына яшәмисез соң сез?! Ә?! Болай да проблемалар муеннан. Суверенитет куркыныч астында. Башкортстанда татарларны кысалар. Латин графикасына күчә алмыйбыз. Себер татарлары бездән аерылмакчы булалар. Ә сез ял йорты, хыянәт, тегесе-монысы... Болай да баш каткан!

Фәндәс. Гафу итегез, сез бит үзегез беркөнне чыгыш ясадыгыз: гаилә тотрыклылыгы милләт өчен бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе дип.

Шәйхи. Ну гаиләгезнең тотрыклылыгын депутат хәл итәргә тиеш дигән сүз түгел бит әле бу.

Фәндәс *(еламсырап)*. Рәшит бит «Саҗидә белән бергә булдык» диде.

Шәйхи. Юри әйтә. Син ачудан әйткәнсең. Ул да үч итеп әйткән. Зәйнәпнең синдә кунганы булмадымы?

Фәндәс *(катгый итеп)*. Юк! Ул пумала баш нигә кирәк миңа?!

Шәйхи. Ярар, бар кайт. Кайгырма. *(Фәндәсне иңеннән кага.)* Уйлама, җаныем, юкларны, уйла бергә йоклауны.

Фәндәс. Кайтыйммыни?

Шәйхи. Әлегә Рәшит белән очрашмый торсаң яхшырак булыр. Өеңә кайт. Борчылма. Җайлармын.

Фәндәс. Рәхмәт! Сау булып торыгыз!

Шәйхи. Хуш! *(Фәндәс чыгып китә. Шәйхи сәгатенә карый.)* Кая олакты бу? *(Тәрәзәдән карый.)* Бураны бик каты дулый, әллә адашты микән? Хәер, болар барысы да адашты бугай!

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Фәндәсләр фатиры. Фәндәс үзе генә өйдә. Телефон шылтырый.

Фәндәс *(телефон трубкасын алып)*. Алло!.. *(Чиксез шатлык белән.)* Шәйхулла Галимуллович! Исәнмесез! Мин бик шат сезнең тавышыгызны ишетүемә. Хәзер үк киләсезме? Пломбагыз купты мәллә тагын? Ә-ә-ә, безнең гаилә мәсьәләсе буенча... Рәхмәт... Әйе... Ярый... Көтәм. *(Арлы-бирле йөренә.)* Шәйхулла Галимуллович килә... Рәхмәт яугыры... *(Ишек кыңгыравы зеңгелди.)* Әллә килеп тә җиттеме... *(Ишекне ача.)*

Рәшит керә. Кулында пакет.

Рәшит *(елмаерга тырышып)*. Сәлам!

Фәндәс *(аптырашта кала)*. Сәлам! Ни йомыш?

Рәшит. Менә килдем әле...

Фәндәс *(каушый)*. Хәзер монда бик абруйлы кеше киләчәк. Минем вакытым юк сезне кабул итәргә.

Рәшит. Кем килергә тиеш?

Фәндәс. Шәйхулла Галимуллович.

Рәшит. Беләм. Ул миңа монда булырга кушты. Шушында очрашабыз, диде. *(Түргә уза, төргәген диванга куя. Чишенә, тунын, бүреген элгечкә элеп куя.)*

Фәндәс. Ярар алайса. *(Гасабиланып үзен кая куярга белми. Барып телевизорны кабыза. Телевизордан Шәйхи чыгыш ясый.)*

Шәйхи *(телевизордан сөйли)*. Планетаның кинәт җылына башлавында, Җир шарының температурасы бер градуска күтәрелүендә ЖЭУларның гаебе юк. Ләкин, җәмәгать, җаваплылыкны үз өстебездән алып ташларга ашыкмыйк. Төньяк Боз океанының бозлары эремәсен өчен без нинди көч сарыф итә алабыз: депутат буларак та, планетаның гражданнары буларак та? Шундый глобаль мәсьәләләр алдыбызда торганда фатирлардагы җылылык, әлбәттә, икенче планга да күчәргә мөмкин...

Шәйхи килеп керә. Кулында портфель. Бүрегендәге карны каккалый, аны элеп куя. Тунын салып диван башына ташлый. Портфелен өстәл астына куя. Телевизорга карап тора.

Шәйхи. Сүндерегез! *(Фәндәс телевизорны сүндерә.)* Сәлам бирдек! *(Гадәттәгечә, теш дәвалау креслосына барып утыра, авызын киң итеп ача. Кинәт ник килгәнен исенә төшерә.)* Гафу итегез, онытылып киткәнмен. *(Креслодан торып ишек янына бара. Тышка кычкыра.)* Алып керегез!

Шәйхинең ике ярдәмчесе фатирга алагаем зур чыршы алып кереп утырталар. Шундук чыгып та китәләр.

Рәшит *(пакетыннан коньяк, берничә алма чыгара, аларны өстәлгә куя).* Менә минем кучтәнәчләрем.

Шәйхи *(өстәл астындагы портфелен тартып ала да бер шешә виски, төрле закускалар чыгарып өстәлгә куя).* Хватит бала-чагаланып йөрергә. Аңлашырга вакыт. Татулашыгыз, в конце концов! *(Шешәгә ымлап.)* Әйдә, Фәндәс, кайнаштыр.

Фәндәс *(рюмкаларга эчемлек сала).* Әйдәгез, берәрне тотып куйыйк.

Шәйхи. Алай түгел. Рәшиткә әйтәсе килгән сүзеңне әйт, тост урынына шул булыр. Аннары Рәшит сиңа әйтәсе сүзен әйтер. Яңа ел алдыннан гына араларыгызны бозмагыз инде.

Фәндәс *(кулына рюмка алып).* Рәшит... Мин бит ачуымнан алдадым. Зәйнәп белән минем арада бернәрсә юк. Теш дәвалатырга килгәние... Гафу ит мине.

Рәшит. Әйе, миңа Шәйхулла...

Шәйхи. Галимуллович.

Рәшит. Шәйхулла Галимуллович әйтте синең тәүбә иткәнеңне.

Фәндәс. Әйдәгез, андый ахмаклыкларым бүтән кабатланмасын өчен тотып куйыйк әле.

Шәйхи. Менә монысы бераз тостка охшаган. *(Эчеп куялар.)*

Рәшит. Хәзер мин әйтим инде. *(Фәндәс тиз генә рюмкаларга коньяк сала.)* Мин дә фәкать нәфрәт колына әверелеп кенә алдаштым. Ял йортында без Саҗидә белән бергә булмадык.

Фәндәс *(шатланып).* Миңа Шәйхулла Галимуллович әйтте инде...

Рәшит. Сумкалары авыр булгач, вокзалдан йортыгызга кадәр озатып куйдым, бары тик яхшылык эшлим дип. Сине ихтирам иткәнгә һәм Саҗидәне хөрмәт иткәнгә күрә генә. Фәндәс, син мине гафу ит. Мондый нәрсә бүтән кабатланмас.

Шәйхи *(шатланып).* Менә бит ничек нормальләште. Кычытмаган җирегезне ничу кашырга. Әйбәт кенә яшәгез. Икегезнең дә хатыннарыгыз менә дигән, үзегез прекрасный кешеләр.

Рәшит *(канатланып).* Әйдәгез шуның өчен тотып куйыйк! *(Эчәләр.)*

Фәндәс *(җылы караш белән карап тора).* Рәшит, гафу ит!

Рәшит. Син дә мине гафу ит. *(Кочаклашалар.)*

Фәндәс. Ярый әле безнең Шәйхулла Галимулловичыбыз бар. Ул бит безне гел коткара. Аңардан башка нишләр идек.

Шәйхи *(ашый-ашый).* Миннән башка бетәсез сез.

Фәндәс *(исерә башлый).* Әйдәгез, Шәйхулла әфәнде хөрмәтенә тотып куйыйк әле берәрне.

Рәшит *(рюмкаларны тиз генә тутыра).* Чынлап та, Шәйхулла...

Шәйхи. Галимуллович.

Рәшит. Шәйхулла Галимуллович ярдәмендә матавыклардан чыгабыз. Рәхмәт сезгә.

Фәндәс. Кул-аягыгыз сызлаусыз булсын. *(Эчәләр.)* Музыка җитми. *(Сикереп торып радионы кабыза. Радиодан Шәйхи сөйли.)*

Шәйхи *(радиодан сөйли).* Шуны да әйтергә кирәк: эчкечелеккә каршы көрәшүдән мәгънә юк. Аны фәкать контрольдә тоту турында гына гәп куертырга була. Тирәнрәк уйлап баксаң, эчкечелекне контрольдә тоту җиңел түгел. Хәтта исерек кешене дә контрольдә тоту бик авыр бит. Бигрәк тә җегәрле кеше булса. Суга да ега. Шуңа күрә эчкечелек мәсьәләсенә бик сак кына адымнар белән якынлашу мәслихәт.

Рәшит *(сөенеп).* Бу бит сез сөйлисез.

Шәйхи. Әйе, кабатлап бирәләр. Сүндер, Фәндәс, сөйләшеп утырыйк. *(Фәндәс радионы сүндерә.)*

Фәндәс *(ихлас күңелдән).* Ярый сез бар әле. Бу матавык фаҗига белән дә тәмамланырга мөмкин иде бит.

Шәйхи. Башка вакытта чамалабрак алдашырсыз.

Фәндәс. Аллам сакласын. Башка кабатланмасын инде мондый нәрсәләр.

Шәйхи. Үзегездән тора.

Фәндәс. Минем бер тост әйтәсем килә. Әйдә, Рәшит, сөекле хатыннарыбыз өчен берәрне тотып куйыйк әле. Алар исән-сау булсыннар. Мин бит миңа Саҗидәмнең хыянәт итмәгәнен беләм.

Рәшит. Әйдә. *(Эчәләр.)* Шәйхулла...

Фәндәс. Галимуллович.

Рәшит *(бераз исерә).* Шәйхулла Галимуллович, үзегезнең гаилә хәлләре ничек, әйбәтме?

Шәйхи *(ашаудан туктый, кинәт җитдиләнә, авыр сулап куя).* Мин хатыным белән аерылдым бит.

Фәндәс *(йөзенә газап төсе чыга).* Шулаймыни? И-и-и, нишләп?

Шәйхи. Аерылышырга булдык.

Фәндәс. Без Рәшит белән барып сөйләшмикме соң хатыныгыз белән? Бәлки, татулаштыра алырбыз.

Шәйхи. Юк, юк, кирәкми.

Фәндәс. Сез бит безгә ярдәм иттегез. Бәлки, безнең дә ярдәм тияр.

Шәйхи. Кирәкми.

Рәшит. Тагын өйләнергә уйламыйсызмы соң?

Шәйхи. Менә уйлап йөрим дә...

Рәшит. Кандидатура бармы соң? Булмаса, менә дигән хатын табып бирәм сезгә.

Шәйхи. Кандидатура бар барын... Бик яшь шул...

Фәндәс. Татар кызымы?

Шәйхи. Татар. Татарча сөйләшә генә белми. Тәлгать Бариевичның кызы ул. Үзе чибәр, үзе яшь...

Рәшит *(җитди кыяфәт белән)*. Яшь кызлар белән рәхәт тә ул, тик менә акча да күп китә шул аларга...

Шәйхи. Юк, ул әле бала-чага бит, «Чупа-чупс» кына ашый. Ну, тора-бара расход китәчәк инде.

Рәшит. Ә ник соң андый яшькә өйләнмәкче буласыз?

Шәйхи *(бераз исерә)*. Мәрхүм Тәлгать Бариевичның кызы булганга. Ятим булмасын дип. Никахны язга таба укытырбыз инде. Әле башта Тәлгать Бариевичның һәйкәлен куйдыртасы бар. Зур һәйкәл ясатасым килә — Ленинннан да биегрәк итеп.

Фәндәс. Материал күп китәчәк. Кыйммәткә төшәр бит...

Шәйхи. Юк, агачтан ясатам.

Рәшит. Һәйкәлне яхшы металлдан ясатыгыз инде. Кызына өйләнергә дә йөргәч...

Шәйхи. Мин аның бюстын ясаткан идем инде бронзадан. Җомга көнне ЖЭУ каршына куйдык, шимбә көнне кубарып алып киткәннәр.

Фәндәс. Табылмадымы?

Шәйхи. Таптык. Цветной металл җыя торган складта ята — йөзтүбән. Мәрхүмнең башына кошлар да кунарга өлгермәде.

Рәшит. Ул бюст кайда соң хәзер?

Шәйхи. Өемдә, сервант өстендә тора. Һәйкәлне затлы металлдан эшләтсәң, аның янына каравылчы куярга кирәк булачак. *(Нәфрәтләнеп тавышын күтәрә.)* Ә кем гарантия бирә, что каравылчы оештырмас һәйкәлне кубаруны?! Агачтан кирәк, агачтан.

Фәндәс. Нинди агачтан? Усак тиз чери, юкә бүртә...

Рәшит. Имәннән ничек?

Шәйхи. Имәнне урлыйлар. Имән дә кыйммәт материал санала.

Фәндәс. Алайса, бернигә яраксыз агачтан ясатырга кирәк.

Шәйхи. Мин дә шулай уйлыйм.

Рәшит. Ә агачтан ясалган һәйкәл тамыр җәеп үсеп китсә? Агач агач бит инде ул.

Фәндәс. Аллам сакласын! Ботаклары чыгып яфраклар ярып утырса, Тәлгать Бариевичның рухы моңа нык рәнҗер.

Рәшит. Әйе. Анда каргалар да оя кора башласа нишләрсең?!

Шәйхи. Әй, әллә нинди куркыныч нәрсәләр сөйләмәгез әле. Һәйкәл турында әле ныклап уйлыйсы бар.

Рәшит. Бәлки, музеен гына ачаргадыр. Кигән киемнәрен элеп куясың шунда...

Шәйхи. Карале, чынлап та, моны уйларга кирәк әле. Без бит бүген монда башка проблеманы хәл итеп утырабыз. Мин хатынымны аерган кеше буларак әйтәм сезгә: гаиләләрегезне саклагыз.

Фәндәс. Әйе. Рәшит, синең хатының шулхәтле шәп... *(Кулы белән авызын каплый.)* Әй, нәрсә сөйлим мин... Әйбәт кеше хатының... Сакла хатыныңны...

Рәшит. Синең дә Саҗидәң менә дигән хатын... Югалта күрмә...

Фәндәс *(шикләнеп)*. Ә ник әле алай дисең?

Рәшит. Үзең шулай дисең бит...

Шәйхи *(борчылып)*. Тагын әләгешеп китә күрмәгез.

Фәндәс. Ну син бит аңладың, нәрсә әйтергә теләгәнемне?

Рәшит. Син дә аңладың бит?

Фәндәс *(ихлас күңелдән елмаеп)*. Әлбәттә. Безнең хатыннарыбыз кебек әйбәт хатыннар дөньяда юк!

Рәшит *(кулын йөрәк турысына куеп)*. Чыннан да, хатыннарыбызның кадерен белик. Әйдәгез, шуның өчен җибәрик.

Шәйхи. Мин бик шат, ниһаять, бер-берегезне аңладыгыз. Хатыннарыгыз хыянәт итә торган кешеләр түгел икәненә дә төшендегез. Әйдәгез, моның өчен тутырып эчик! *(Рюмкаларны күтәрәләр.)*

Зәйнәп керә. Күз төпләре кара янган. Кулы бәйләнгән. Бераз аксый. Тунын да салмыйча түргә уза.

Фәндәс *(куркып).* Зәйнәп, нәрсә булды сиңа?

Зәйнәп. Рәшиттән сора.

Рәшит *(сикереп тора).* Матурым, җанкисәгем. Бик зур ялгышлык килеп чыкты... Мин хаклы булмаганмын. Без инде аңлаштык. *(Зәйнәпне кочаклап юатмакчы була.)*

Зәйнәп *(Рәшитне этә).* Ненавижу!

Шәйхи. Син ненавижу дияргә ашыкма әле, Зәйнәп. Ситуация монда яхшы якка үзгәрде. Сезнең татулашу стадиясе бара.

Фәндәс. Зәйнәп, монда синең бернинди гаебең юк икәнен дә беләләр.

Зәйнәп. Миңа наплевать!

Шәйхи. Төкерергә ашыкма әле, сеңелем, без монда аңлаштык.

Зәйнәп. Нәрсәне аңладыгыз соң сез?

Шәйхи. Беркем тарафыннан бернинди хыянәт юк икәнлеге ачыкланды.

Зәйнәп. Шулаймы... Ачыкладыгызмы... *(Өстәлдәге рюмканы алып, кинәт эчеп куя.)* Ә хәзер мине тыңлагыз!

Шәйхи. Тыңлыйбыз.

Зәйнәп. Рәшит ял йортында чакта без Фәндәс белән яшәп яттык.

Фәндәс *(кычкырып җибәрә).* Ялган!

Зәйнәп *(Фәндәскә).* Куркак син!

Фәндәс. Ичмаса, син ник алдыйсың?!

Зәйнәп *(мыскыллы елмаю белән).* Саҗидәң турында да ишет. Саҗидә миңа әйтте, Рәшит белән ял йортында бергә булдык, диде.

Рәшит *(акыра).* Неправда!

Саҗидә керә.

Саҗидә. Җыелганнар! *(Чишенмичә генә алга уза, бүреген салып йомарлап тота.)*

Шәйхи *(таләпчәнлек белән).* Саҗидә, әйт тизрәк берәр сүз.

Саҗидә *(каядыр бер ноктага карап).* Нәрсәгә яки кемгә багышлап әйтим сүземне?

Шәйхи. Без инде төенне чиштек дип куанып утыра идек. Хыянәт булмаганны ачыкладык... Ә менә Зәйнәп керде дә...

Саҗидә *(һаман да бер ноктага текәлеп).* Мин шуны әйтә алам: без Рәшит белән ял йортында бергә ял иттек. Без яратабыз бер-беребезне.

Рәшит *(кычкырып).* Юк! Берегезне дә яратмыйм!

Саҗидә *(авызын кыйшайтып).* Яратасың, яратасың!

Фәндәс *(өзгәләнеп).* Ялган!

Рәшит *(нәфрәтеннән ярылырдай булып).* Күралмыйм!

Фатирда шау-шу куба. Ыгы-зыгы. Буран дулый. Кар тула. Бераздан тынлык урнаша. Фатирда коточкыч салкын. Барысы да туннарга, пәлтәләргә төренә. Шулай кукраеп бер-берсенә карамыйча утыралар. Зәйнәп диванга барып ята.

Шәйхи *(сикереп тора һәм кычкыра).* Мин сездән сантехник чагымда ук туйган идем. Сез нәрсә, миннән көләсезме әллә?! Мин сезнең гаиләләрегез исән-имин булсын өчен бөтен булган интеллектымны сарыф итәм, хайваннар! Ну, сколько можно! Болай ярамый бит инде! Инде ничәмә тапкыр коткардым мин сезләрне! Инде хәзер дә аңлаштык, әйбер-кара юк, тфү-тфү, Аллага шөкер, матавык зурга китмәде дип шатланасы урынга... Нинди кешеләр соң сез, ә?! Минем үземнең гаиләм таркалды, яңадан өйләнергә йөрим... ООНга эшкә чакыралар. Гаагадагы трибуналда должность тәкъдим итәләр! Ә мин разный Зәйнәп, Фәндәс, Саҗидә, Рәшитләр белән кәнитилләнеп ятам монда. Болай итәбез! Раз инде сезне игә китереп булмый икән, давайте, Рәшит Саҗидә белән яшәп карасын, Фәндәс Зәйнәп белән.

Рәшит *(сикереп торып тунын салып ыргыта).* Ярар, яшим! Мин үзем дә туйдым бу матавыклардан! Нәрсә, куркыр дип уйлыйсызмы әллә? Яшим!

Фәндәс *(сикереп тора, чәрелдәвек тавыш белән кычкыра).* Миндә дә нервы бар! Мин дә яшәп карыйм, нәрсә! Мин дә алай бигүк куркак зат түгел! Нәрсә, әллә мин Зәйнәп белән яши алмас дисезме?!

Саҗидә *(әкрен генә тора).* Аһ, әле сез шулаймыни?! Ярар, мин риза!

Шәйхи. Зәйнәп, ә син ник дәшмисең?

Зәйнәп *(диванда тунга төренеп яткан урыныннан).* Миңа наплевать! Мине кем кыйнаса да бер түгелмени?!

Шәйхи. Сезне үз урыннарыгызга утыртып, иманыгызны укытып акыл кертми торып, ООНга да, Гаагага да китмим пока. *(Барып портфелен ала. Аннан нинди дер кәгазь бланклар чыгара. Саҗидә арлы-бирле йөри, нишләргә белми. Аптырагач барып телевизорны кабыза. Телевизордан Шәйхи чыгыш ясый.)*

Саҗидә *(Шәйхигә)*. Сүндеримме?

Шәйхи. Сөйләсен, сөйләсен. *(Бланкларга нәрсәдер яза. Бу вакытта ул телевизордан сөйли.)*

Гаиләләрдә тәртип булмый торып, илдә тәртип булмаячак. Кеше хатыны ул — кеше хатыны. Синең хатының — синең хатының. Ләкин заманалар шулкадәре катлауланды ки, буталчыкларның ахыр чигенә кайвакыт чыгу ай-һай кыен. Мәшһүр кешебез, арабыздан бик иртә китеп барган мәрхүм Тәлгать Бариевич әйтмешли, заманасына күрә дуңгызны да җизни диярсең...

Фәндәс *(йөгереп барып телевизорны сүндерә)*. Туктагыз! Әллә ашыкмыйкмы? *(Дер-дер калтырана.)*

Шәйхи *(язуын тәмамлый)*. Поздно уже! Гаагадагы верховный суд бланкларын тутырдым инде мин. Хәзер тыпырчына алмыйсыз! Килегез, кулларыгызны куегыз!

Рәшит. Мин куям. Әллә куймас дисезме?! *(Язуны укый, аннары кул куя.)* Нинди телдә яздыгыз соң сез моны?

Шәйхи. Үзебезнең телдә. Мин инде күптән латин графикасына күчтем.

Фәндәс. Куям. Мин дә кул куям! Мәгез, пажалысты! *(Килеп бланкка кул куя.)*

Саҗидә. Мәгез алайса! *(Кул куя.)*

Шәйхи *(диванда ятучы Зәйнәпкә папка белән бланк алып бара)*. Тәти кулың белән имзаңны сызгала, сеңелем.

Зәйнәп. С удовольствием! *(Кул куя.)*

Фәндәс *(өзгәләнеп)*. Ник әле без кул куябыз?

Рәшит *(тешләрен шыгырдатып)*. Нормально, нормально!

Шәйхи *(Фәндәскә)*. Син Зәйнәп белән яшәп карыйсың, Рәшит Саҗидә белән. Вәт шуңа кул куйдың. Бу документлар белән шаярырга ярамый. Ул сиңа загста кул куешу түгел. Бу хакта бөтен ООНда белеп торачаклар. Ату туйдым мин сездән, панимаешь. Вәт яшәп карагыз. Маегызга чыдый алмагач. Рәшит Саҗидә белән, Фәндәс Зәйнәп белән. Бәлки, кешеләрчә яши башларсыз!

Кинәт буран куба. Күмәк җыр.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә урталай бүленгән. Бер ягында — Рәшитләр фатиры. Анда Зәйнәп көзге каршында бизәнеп утыра. Икенче якта — Фәндәсләр фатиры. Анда Саҗидә өй җыештыра. Сәхнәнең алгы өлешендә Рәшит белән Фәндәс сөйләшеп утыралар. Рәшит зур чемоданына, Фәндәс баян тартмасына утырган. Һәркемнең кырыенда үзенең кирәк-ярак әйберләре. Фәндәс Зәйнәп янына, Рәшит Саҗидә янына барырга әзерләнгән.

Фәндәс *(авыр сулап)*. Мондый сынауга кем чыдасын?!

Рәшит *(көлемсерәп)*. Әле соң түгел.

Фәндәс. Юк шул, документларга кул куйдык бит. Аннары, Шәйхулла Галимуллович кушкач, бернишләп булмый.

Рәшит *(сумкадан аракы чыгара, пластик стаканнар ала)*. Мин синең Саҗидәңнең холкын да белмим, аның белән ничек сөйләшергә икәнен дә чамаламыйм.

Фәндәс. Син, минемчә, һәркем белән бертөсле сөйләшәсең.

Рәшит. Нәрсә ярата ул?

Фәндәс *(үпкәләп)*. Әйтмим.

Рәшит *(стаканнарга аракы сала)*. Әйтмәсәң әйтмәссең. Барыбер яшәп карарга кирәк. Барыбер яшәргә кирәк! Әйдә җибәреп куйыйк. *(Эчәләр.)*

Фәндәс *(пакеттан тиз генә ике алма чыгара)*. Минем алма бар бит. *(Алма ашыйлар.)*

Рәшит. Яшәп карыйк, чынлап та. Ничек тә бит бу матавыктан чыгарга кирәк.

Фәндәс. Нүҗәли башкача чыга алмас идек, ә?!

Рәшит. Чыгалмадык бит, буталып кына беттек.

Фәндәс. Ә алга таба нишләрбез?.. Шулай калсак?..

Рәшит. Алга таба күз күрер.

Фәндәс. Сал әле тагын. Бик әйбәт аракы бу. Син моны минем Саҗидәмә күчтәнәч итеп алып бармакчы идеңме әллә?

Рәшит. Мин бит синнән бер пакет алманы Зәйнәпкә күчтәнәчкә алып барасыңмы дип сорамыйм.

Фәндәс *(күзләрен акайтып)*. Мин куркам, Рәшит.

Рәшит. Нәрсәдән?

Фәндәс. Нәрсәдән түгел, кемнән. Зәйнәптән. Ул бит, малай, гади нәмәрсә түгел, ул — оһо-һо.

Рәшит. Курыксаң бик әйбәт.

Фәндәс. Син дә минем Саҗидәмнән куркырсың дип өметләнәм.

Рәшит. Өметеңне акларымын дип әйтә алмыйм. *(Эчеп куя.)* Кул куелган бит.

Фәндәс *(үзенең өлешен эчеп куя)*. Зинһар, тимә Саҗидәгә.

Рәшит. Нинди мәгънәдә?

Фәндәс. Барлык мәгънәләрдә дә. Үтенеп сорыйм!

Рәшит *(Фәндәсне иңеннән коча).* Мин дә бит үз теләгем белән бармыйм анда.

Фәндәс *(стаканнарга тутырып аракы сала).* Әйдә, бер-беребезгә уңышлар телик.

Рәшит. Әйдә. Уңышлар сиңа.

Фәндәс. Сиңа да.

Эчәләр. Фәндәснең пакетыннан алып алма ашыйлар.

Рәшит *(бераз исерә).* Син Зәйнәпне обижать итмә инде, яме.

Фәндәс *(исерә).* Юк инде, син нәрсә. Син Саҗидәне кыерсытма, яме.

Рәшит. Юк инде, юаш кеше бит мин.

Фәндәс. Шул ук вакытта син Саҗидәнең холкына түз, яме. Ул бераз кырысрак. Алар нәселләре белән шундый. Син аны аңларга тырыш инде, яме.

Рәшит. Ярар. Син дә, пажалысты, Зәйнәпнең киреләнүләренә чыдарга тырыш. Аны үтереп кенә төзәтеп була. Шуңа күрә түз инде капризларына.

Фәндәс. Шулай бик киремени?

Рәшит. Бар инде бераз.

Фәндәс. Мин аңа тәмле әйберләр алып кайтырмын. Ул нәрсә ярата?

Рәшит. Крыжовник.

Фәндәс *(борчулы тавыш белән).* Бәрәч, декабрь азагында мин каян крыжовник табыйм?

Рәшит. Мин таба идем бит әле.

Фәндәс. Син бит ул. Ярар, эзләргә туры килер инде.

Рәшит. Мин сине кызганып куйдым әле.

Фәндәс. Нишләп?

Рәшит. Белмим.

Фәндәс. Ә мин Саҗидәмне.

Рәшит. Ник жәллисең аны?

Фәндәс. Белмим.

Рәшит *(үпкәле тавыш белән).* Ә мин, нәрсә, сиңа жалко түгелмени?

Фәндәс. И Рәшит туган, кызганам сине дә. Без бит икебез дә корбаннар! Гаиләбез корбаннары, хатыннарыбызның корбаннары.

Рәшит. Мин сине элек тә хөрмәт итә идем, хәзер бигрәк тә. Бик җылы күңелле кеше син. Мин бит постоянно җансыз-кансыз кешеләр белән аралашам. Синең белән сөйләшкәндә, уң ягымдагы фәрештәм каршыма төшеп утырган сыман була.

Фәндәс. Алай ук димә инде. Фәрештә минем шикелле аракы эчеп утырмас бит. Тем более уң яктагысы. Ә менә мин сиңа элек тә соклана идем, хәзер дә сокланып туймыйм. Чөнки син — чын ир-егет, маладис син. Сиңа Саҗидә нифига да лаек түгел.

Рәшит. Мин дә шуны уйлап куйдым әле: минем чәчбикамалым, то есть Зәйнәп, сиңа һич кенә дә лаек түгел. Сине кызгануым шуңа минем.

Фәндәс. Ничек кенә булмасын — документ бар инде. Шәйхулла Галимулловичка вәгъдә бирдек. Гаага кәгазьләренә имза куйдык. Аллага тапшырдык инде.

Рәшит. Кузгалабызмы?

Фәндәс. Әллә бергә барыйкмы?

Рәшит. Кая?

Фәндәс. Хет безгә, хет сезгә.

Рәшит. Ә кайда соң ул хәзер «без» һәм дә ки кайда ул хәзер «сез»?

Фәндәс. Әйе шул, тагын бутала башладык. Минем синнән аерыласым килми. Синең белән ничектер тынычрак. Матавыклары да куркытмый син янәшә булгач. Раз мине фәрештәгә тиңлисең икән, әллә кире уң як иңбашыңа менеп атланыйммы?

Рәшит. Юк, юк, мәшәкатьләнмә. Йә икебезне дә психушкага алып китәрләр. Анда инде кем фәрештә, кем шайтан — кайвакыт баш врач үзе дә бутый.

Фәндәс. Нишлибез соң?

Рәшит. Мин киттем Саҗидә янына, син — Зәйнәп кырына.

Фәндәс. Бик рәхәт утыра идек бит.

Рәшит. Караңгы төшә инде.

Фәндәс. Әйе шул. *(Кузгалалар.)*

Рәшит. Ярый, туган, сау бул!

Фәндәс. Хуш, Рәшит! *(каты итеп ирләрчә кочаклашалар.)*

Рәшит. Әйдә, җый сначларыңны. *(Фәндәскә торырга булыша, әйберләрен кулына тоттыра. Теш дәвалый торган кәкре-бөкре җайланмасын муенына аса, баянын тоттыра.)*

Фәндәс. Аллага тапшырдык!

Берсе бер якка, икенчесе икенче тарафка юл тоталар. Музыка.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рәшитләр фатиры. Зәйнәп эчке күлмәктән генә көзге каршында утыра. Битенә ниндидер кремнар сылый. Әйберләрен күтәреп Фәндәс керә. Баянын һәм теш дәвалый торган корылмасын көч-хәл белән күтәреп алып килгән.

Зәйнәп *(Фәндәскә бер карап куя да үз эшен дәвам итә)*. Килеп җиттеңме?

Фәндәс *(уңайсызланып)*. Әйе... ни... килеп җиттем.

Зәйнәп. Уз әйдә, нәрсә кукраеп торасың, экзаменга кергән первокурсник сыман.

Фәндәс *(як-ягына каранып)*. Әйберләрне кая куйыйм?

Зәйнәп. Теләсә кая куй. Малың бигүк күп түгел икән. Ул нинди инструмент?

Фәндәс. Теш дәвалый торган...

Зәйнәп *(битенә крем сылый-сылый)*. Монда пациентлар кабул итеп ятмакчы буласың мәллә?

Фәндәс. Юк инде... Болай гына алдым... на всякий случай.

Зәйнәп. Анысын диван астына тык.

Фәндәс *(әйберләрен урнаштырганнан соң диванга утыра)*. Өегез салкын икән...

Зәйнәп. Шәйхине депутат итеп сайлагач кинәт салкынайды ул. Карале, ул бит синең даими пациентың... Монда килеп йөрер микәнни тешләрен каратырга? *(Көзгедән Фәндәскә таба борыла.)*

Фәндәс. Юк инде... Вакытлыча эшләмим, диярмен. *(Бер-берсенә карап утыралар.)*

Зәйнәп. Син йоклаганда гырлыйсыңмы?

Фәндәс. Белмим. Йоклаганда мин берни ишетмим бит. *(Каушый.)* Карале, без бергә озак яшәрбез микән?

Зәйнәп *(битараф тавыш белән)*. Шәйхиегез кушкач, мәңгедер инде.

Фәндәс. Алай ук түгелдер инде.

Зәйнәп. Нәрсә, куркасыңмыни миннән?

Фәндәс. Куркуын курыкмыйм да... Ни бит... Анда Саҗидә... *(Кыюланырга тырышып.)* Син Рәшитне югалтудан курыкмыйсыңмыни?

Зәйнәп. Ул үзе мине югалтудан курыксын. Аягың тирлиме?

Фәндәс. Бераз тирли. Шәйхулла Галимуллович әйтмешли, үлгән кешенең генә аягы тирләми. Аңа моны мәрхүм Тәлгать Бариевич әйткән булган. Ул гел Тәлгать Бариевичны цитировать итә.

Зәйнәп *(мут елмаеп)*. Безнең нәрсә, медовый месяцмы хәзер?

Фәндәс *(курка)*. Месяц дип... Декабрь хәзер...

Зәйнәп. Шампанскиең да юкмы?

Фәндәс *(Зәйнәпкә озак карап тора)*. Син чын-чынлап сөйләшәсеңме?

Зәйнәп *(үчекләп сөйләшә)*. Бәрәч икән. Без синең белән гаилә төзеп яшәргә тиеш булгач, нәрсәдән башлыйк икән соң?

Фәндәс *(югалып кала)*. Сразу... медовый месяц дип... Син бигрәк... Бит, бер-беребезгә ияләшмәгән килеш... Ни... бер-беребезне якыннан белми торып...

Зәйнәп *(мыскыл итеп)*. Әйдә, алайса, үбешүдән башлыйк.

Фәндәс *(үзен кулга алырга тырышып)*. Алайга калса, иң элек без синең белән подъездда басып торудан башларга тиеш... Төнге урамнарда йөрергә тиешбез... Бер-беребезгә шигырьләр сөйләргә тиеш...

Зәйнәп *(рәхәтләнеп көлә)*. Курыкма, тимим. Шаярам гына мин. Син бигрәк куркак икән.

Фәндәс *(оялып)*. Яши-яши шундыйландым мин.

Зәйнәп. Ну раз безгә бер гаилә булып яшәргә кушылган икән, һәрберебезнең вазифалары булырга тиештер инде.

Фәндәс *(җанланып)*. Әйе... син миңа әйтерсең нишләргә кирәк икәнне.

Зәйнәп *(горур тавыш белән)*. Мин сиңа эш табармын.

Фәндәс. Мин эштән курыкмыйм. *(Киң итеп елмая.)* Ни... Син миңа ашарга пешерерсең...

Зәйнәп *(кинәт кырыслана)*. Пешерерсең дә ашарсың. Хәзер менә, сиңа ашарга пешерермен!

Фәндәс *(чыраен сытып)*. Мин инде ике көн ашамаган.

Зәйнәп. Ач тору файдалы ул. Вакыт инде соң. Хәзер мендәр тышларын үтүклим дә йоклыйбыз.

Фәндәс. Ашап тормыйбызмы инде?

Зәйнәп. Бүген юк. *(Үтүкне кабыза. Үтүктән Шәйхи чыгыш ясый.)*

Шәйхи *(каяндыр үтүк эченнән)*. Без, халык депутатлары, халкыбызның көнкүрешен генә түгел, хәтта аның режимын, ашау рационын да кайгыртырга тиешбез.

Зәйнәп *(куркып үтүкне сүндерә)*. Үтүкне кабызсаң да шул сөйли. Үтүкләп тормыйм инде. *(Караватка урын җәя.)*

Фәндәс *(куркып)*. Йоклыйбызмыни?

Зәйнәп. Әйе.

Фәндәс *(ялварулы тавыш белән)*. Әллә сөйләшеп кенә утырыйкмы?

Зәйнәп. Ник... Аны яткач та сөйләшеп була бит.

Фәндәс. Мин идәндә йоклармын, яме. Мин идәндә йокларга яратам. Файдалы. Буй-сынны төз тотарга файдалы...

Зәйнәп. Миңа димәгәең, хет балконда йокла.

Фәндәс. Кыш көне балконда йоклау бигүк дөрес булмас... Анда бит фатирга караганда да салкынрак.

Зәйнәп. Аның каравы черки юк.

Фәндәс *(калтыравыклы тавыш белән)*. Черки дигәннән... Быел җәй черки илләә дә күп булды, әйеме...

Зәйнәп. Сизмәдем. Миңа чебен-черки кунмый.

Фәндәс. Ник икән?

Зәйнәп. Куркалар. Син дә куркасың бит миннән.

Фәндәс. Мин гомумән курка башладым әле. Ул бланкларны тутырасы калмадымы әллә?

Зәйнәп *(үчекләп)*. Кул куйдың инде, бетте башың. *(Фәндәскә таба бара. Фәндәс курка.)* Нәрсә, кочакламыйсың дамы?

Фәндәс. Ну кочаклармын да... *(Кочакламакчы була.)*

Зәйнәп *(аны этеп җибәрә)*. Пошел вон! *(Көзгедән карап тора.)* Мин матурмы?

Фәндәс *(илһамланып)*. Матур. Ну минем Саҗидәм матуррак.

Зәйнәп. Кайсы төше матур аның. Аягы балтыр турында кинәт кәкрәйгән. Калак сөякләре тун кигәч тә беленеп тора.

Фәндәс *(шундук ачуы чыга)*. Син... давай, чамалап... Үзеңне әйбәтләп кара... Син сылаган хәтле штукатурка сыласаң, сиксән яшьлек карчыктан да снегурочка ясап була.

Зәйнәп *(кулларын биленә куеп)*. Тагын нәрсә әйтерсең?

Фәндәс *(кызып китә)*. Син йөргәндә кыек басасың. Әнә сул аяк киемеңнең үкчәсен кара. Минем Саҗидә турында әйтеп торган була.

Зәйнәп *(нәфрәт белән)*. Хам! Мин сине куып чыгарам!

Фәндәс *(кычкырып)*. Попробуй! Безгә бергә яшәргә куштылар!

Зәйнәп *(яман усал итеп)*. Бу минем өем! Мин пропискада монда. Приватизациядә дә катнаштым!

Фәндәс. Зато синең Рәшитең минем өемдә хәзер.

Зәйнәп. Син нәрсә мине оскорблять итәсең? Я все Шайхи расскажу, нахал!

Фәндәс. Үзең бит башладың.

Зәйнәп. Ничек яшәрбез без синең белән, болай беренче көнне үк талашкач.

Фәндәс. Яшәмәбез.

Зәйнәп *(кычкырып елап җибәрә)*. Мин нәрсә, крем күп сылыйммыни шулай? *(Көзгедән карый.)* Штукатурка-а-а... *(Елый. Ишек катына барып аяк киеменең үкчәсенә карый.)* Мин гомерем буе бер аягымның кыек басуыннан оялып комплексовать итеп яшим! Ник аны әйтәсең... Хатын-кызга разве шулай әйтергә ярый! Колхозник! *(Аяк киемен Фәндәскә ыргыта. Фәндәс иелеп кала.)*

Фәндәс *(үкенеп, уфтанып)*. Зәйнәп, зинһар, гафу ит... Телем агачтан булгач, ялгыш әйтеп ташладым...

Зәйнәп *(караваткка йөзтүбән капланып елый)*. Хамье! Хатын-кыз белән шулай сөйләшмиләр инде.

Фәндәс *(караваṭ читенә барып утыра)*. Зәйнәп, матурым, мин ялгыш әйттем. Штукатуркаң да күп түгел, аякларың да төп-төз. Дөрес басасың... Безнең районда иң дөрес басып йөрүче хатын-кыз — син ул! И вабше, синең кебек матур хатын Идел белән Урал арасында бүтән юк.

Зәйнәп *(торып утыра, елаудан туктый, битен мендәр тышы белән сөртә)*. Минем кебек матур хатын гомумән дөньяда юк.

Фәндәс. Шулай, шулай. Тынычлан. Саҗидә синең хәтле үк түгел. Саҗидәгә аңа синә җитәргә ай-һай. *(Сүзне икенчегә борырга тырышып.)* Мин идәнгә нәрсә җәеп йоклармын икән?

Зәйнәп *(тынычланып)*. Әнә шифоньерның теге ягында иске матраслар, одеяллар. Үзең сайлап алып җәй дә ят.

Фәндәс. Рәхмәт! Сине тынычландырыр өчен бер җыр җырлыйммы?

Зәйнәп *(иреннәрен турсайтып)*. Җырла.

Фәндәс *(кабаланып)*. Хәзер. *(Баянын чехолыннан чыгара.)*

Зәйнәп. Теге, Саҗидәңә багышланган җырныңмы тагын?

Фәндәс. Юк. Икенчесен. *(Мөнәҗәт көенә җырлый. Ул җырлаганда Зәйнәп сабыйларча йокыга китә.)*

Сабыйны юаткан кебек,

Кочаклаган шәһәрне төн,
Йокы татлы булсын өчен
Сөйли серле әкиятен.

Һава тулы уенчыклар —
Саф алтыннан гына койган,
Уянса еламасын дип
Хәтта Ай да элеп куйган.

Шәһәр йоклый...
Төн югалгач
йолдызлыклар арасына,
Килер таң — якты, бәхетле —
Әкият азагы сыман.

*(Фәндәс җыры.)*

Фәндәс *(үзалдына)*. Йокыга китте. *(Зәйнәпнең өстенә юрган яба. Үзе идәндә йокларга җыена. Аяк очларына гына басып йөри. Торымнан-торымга Зәйнәпкә карап куя. Идәнгә матрас җәя. Бер зур һәм озын капчык табып аңа иске чүпрәкләр тутыра да матраска яткырып куя. Өстенә одеял япкач, капчык йоклап ятучы кешегә охшап кала. Шыпырт кына киенә дә чыгып китә.)*

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Фәндәсләр фатиры. Рәшит шапор-шопыр аш ашап утыра, ипине зур итеп каба. Борыч сибә. Рәхәтләнеп ашый. Саҗидә, куркып, аңа читтән карап тора.

Рәшит *(киерелеп)*. Ярыйсы пешерәсең икән.

Саҗидә. Зәйнәбең тәмле пешерми иде мәллә?

Рәшит. Пешерсә дә, пешермәсә дә, хәзер инде ул Фәндәскә пешерә. Фәндәс атна-ун көннән дә артыграк тормас, ачтан ычкыныр, пожалуй. *(Саҗидәгә таба килә.)* Син минем хатыныммы инде хәзер?

Саҗидә *(каушый)*. Нишләп мин синең хатының булыйм?

Рәшит *(серле итеп елмая)*. Кул куйдың бит.

Саҗидә *(тавышы калтырап чыга)*. Бергә яшәп карау әле ул хатының булу дигән сүз түгел. *(Курка.)*

Рәшит *(теш дәвалый торган креслога барып утыра)*. Теш алырга өйрәнергә кирәк булыр. Тешләрне сугып төшерә алам мин, ә менә болай бер дә алып караганым юк, ха-ха-ха.

Саҗидә. Мин синең белән тора алмам.

Рәшит *(үчекләп)*. Ник алай дисең?

Саҗидә. Син бит бетле каз шикелле, бер генә дә тик тормыйсың.

Рәшит. Ир-ат шундый тиктормас булырга тиеш инде ул. Синең Фәндәсең барак көясе сыман булгач, башкалар да аңа охшарга тиешмени?!

Саҗидә *(кызып китә)*. Син Фәндәс турында теләсә нәрсә сөйләмә әле, яме. Мин болай карап торуга дуамал хатынга охшамаган, әмма ләкин ирем турында тагын берәр ямьсез сүз әйтсәң, моннан сине очырып чыгарырга берәр чара табармын.

Рәшит *(тыныч кына)*. Беренчедән, без синең белән хәзер бергә яшәргә тиеш. Икенчедән, син бит үзең мине бетле каз дидең. Мине үпкәләтүдән курыкмыйсыңмы соң син?

Саҗидә. Син ир кеше, үпкәләргә тиеш түгелсең. Пумала башлы Зәйнәбең белән сөйләшерсең дорфа итеп.

Рәшит *(кырысланып)*. Син, давай, Зәйнәпне мыскыл итмә әле, яме. Зәйнәп өчен мин ир кеше икәнемне дә онытырга могу. Ике каш араңа бер генә бирермен.

Саҗидә. О-о-о, ничек торырбыз соң без синең белән?

Рәшит. Менә, мин дә шуны уйлап куйдым әле. Мин, җүләр, аның сумкаларын вокзалдан өенә кадәр күтәреп озатып куйдым бит әле.

Саҗидә. Сез ирләр өч тиенлек яхшылык эшләсәгез, утыз өч тиенлек итеп хәтерегездә саклыйсыз инде. Ике коштабак аш ашады да минем белән ызгышырга тотынды.

Рәшит. Ярар. Әйдә, әйбәтләп кенә яшәп карыйк әле.

Саҗидә. Бүгенгә яшәү шушының белән тәмам, йоклар вакыт җитте.

Рәшит *(елмаеп)*. Чын яшәү шул йокларга яткач башлана инде ул.

Саҗидә. Мин менә бу тахтада йоклыйм, син — диванда.

Рәшит *(диванга карап тора)*. Беренче көнне үк катып беткән диван тәкъдим итәсеңме?

Саҗидә. Бер дә катып бетмәгән. Минем белән талашкач, Фәндәс гел шунда йоклый.

Рәшит *(зур канәгатьсезлек белән)*. Шул өрәгең ызгышканнан соң йоклый торган диванны тәкъдим итәсеңме миңа?! Нинди көнгә калдым мин, ә?!

Саҗидә. Соңгы тапкыр кабатлыйм — авызыңны чамалап ач. *(Йокларга ятарга җыена.)*

Рәшит *(чишенә, трусиктан гына кала.)* Мондый шартларда яшәгән юк иде... *(Ята, одеял ябына.)* Мендәрегез каты... Опилка тутырдыгыз мәллә аның эченә?

Саҗидә. Әйе, пилорамга специәлне бардым. *(Чишенмичә генә караваткa ята, юрган ябына.)*

Рәшит *(ут сүнгәч шыпырт кына Саҗидә янына килеп утыра.)* Переписьта катнаштыңмы?

Саҗидә. Катнаштым.

Рәшит. Мин өйдә булмадым. Мине санамый калдылар инде.

Саҗидә. Бәлки, өйдә булгансыңдыр да, сан алучылар үзләре сине кешегә санамаганнардыр. *(Көлә.)*

Рәшит *(Саҗидәнең кәефе күтәрелүдән файдаланып, юрган астына кермәкче була.)* Саҗидә...

Саҗидә. Кит! *(Тибеп җибәрә, Рәшит идәнгә мәтәлеп төшә.)* Якын килмә! *(Мендәр астыннан ит кисә торган пычак чыгара.)* Ачуым ачу!

Рәшит *(кызып китә, бүлмә буйлап арлы-бирле йөри).* Алайса, болай яшәп караудан ни мәгънә?! Файдасы бармы соң?!

Саҗидә. Көнләшмәссез!

Рәшит. Ә үзең?!

Саҗидә. Хатыннарыгызның кадерен белмисез!

Рәшит. Ә безнең кадерне кем белер икән?!

Саҗидә *(кинәт уйга калып).* Ничек уйлыйсың, анда Зәйнәп белән Фәндәс нишләп яталар икән?

Рәшит. Белмим.

Саҗидә. Ә Зәйнәбең белән Фәндәс йоклап яту ачуыңны китермиме?

Рәшит *(әрле-бирле йөри).* Алай-болай бергә йокласалар, икесен дә үтерәм.

Саҗидә. Нишләп икесен дә?! Нишләп берсен генә түгел?

Рәшит. Берсен генә булса, кайсысын үтерергә тиеш соң мин? *(Лапылдап диванга ята да шундук гырлап йокыга китә.)*

Саҗидә *(Рәшитнең каты гырлавына ачуы килеп).* Бар икән күрәселәр! *(Юрганга төренә. Түземлеген җуеп тора, Рәшит янына барып эндәшә.)* Рәшит! Рәшит, дим!

Рәшит *(сискәнеп сикереп тора да кинәт Саҗидәне кочакламакчы була.)* Ә? Нәрсә? Кил!

Саҗидә *(аның кулларыннан көчкә ычкынып).* Гырлыйсың. Борылып ят.

Рәшит. Ә мин яныма ятарга телисең дип уйладым.

Саҗидә. Хәзер менә! Борылып ят. Син минем идеалым түгел!

Рәшит. Син дә минем одеял түгел. Менә минем одеял. *(Одеялга төренә.)*

Саҗидә. Бик каты гырлыйсың икән. «Восход» мотоциклы тавышы чыга.

Рәшит *(стенага борылып ята).* Ә син каян беләсең «Восход» мотоциклының тавышын?

Саҗидә *(караватына барып ята).* Өйләнешер алдыннан Фәндәснең «Восход» мотоциклы бар иде. Әле йөргән вакытта гел мине утыртып катать итә иде. *(Татлы елмаеп.)* Бар иде бәхетле чаклар. Өйләнешкәч сатты мотоциклны.

Рәшит. Ник?

Саҗидә. Ник... Акча кирәк булгач. *(Елый.)* Без бит бик озак йөрдек өйләнешкәнче.

Рәшит. Мотоциклдамы?

Саҗидә. Мотоциклда да күп йөрдек. Ул мине әллә кайларга алып китә иде. Тау башларына, урманнарга. *(Елаудан туктап көлә башлый.)* Бер тапкыр шундый каты егылдык. Фәндәс мотоцикл астында калды, мин читкә очып барып төштем.

Рәшит. Әйтәм аны күзләрегездә сәерлек бар сезнең. Каты егылган булгансыз икән.

Саҗидә. Әй, теле! Син кайлардан егылып төштең икән — күзеңдә нур бөтенләй юк. Дару эчмичә йоклый алмам инде мин.

Тумба тартмасыннан дару алып каба. Рәшит фатирны дер селкетеп гырлый башлый. Саҗидә аһ-ваһ килеп боргаланып ята. Әкрен генә ишек ачыла. Шыпырт кына Фәндәс килеп керә. Тун якасы күтәрелгән, бүреген батырып кигән. Әле Рәшит ягына, әле Саҗидә ягына карап тора.

Фәндәс *(аяк очларына басып караватянына килә).* Саҗидә!

Саҗидә *(Рәшит дип белеп тибеп җибәрә).* Кит! *(Идәнгә егылган Фәндәсне күреп шакката.)* Фәндәс! Синмени?! Теге дип торам. *(Фәндәскә торырга ярдәм итә.)*

Фәндәс *(пышылдап сөйләшәләр).* Менә... Килдем... Кайттым... Сагындым... *(Кочаклашалар.)*

Саҗидә. Ничек соң анда?

Фәндәс. Читен. *(Рәшит ягына карап.)* Гырлый икән. Кыерсытмыймы?

Саҗидә. Юк.

Фәндәс. Минем ашыйсым килә.

Саҗидә *(сикереп тора).* Хәзер. *(Колбаса белән ипи алып килә.)*

Фәндәс *(колбаса белән ипине ашый).* Яңа елны синең белән бергә каршыламабыз микәнни?

Саҗидә. Юктыр инде.

Кинәт өстә вертолет тавышы ишетелә. Прожекторлар яктырта башлый.

Фәндәс *(куркып)*. Вертолет инде әллә... Бик түбән оча.

Саҗидә. Нинди вертолет булсын. Рәшит гырлый.

Вертолет тавышы якыная. Күктән Шәйхинең сөйләве ишетелә. Аның тавышын ишеткәч, Фәндәс карават астына кереп китә. Рәшит торып утыра.

Шәйхи *(күктән)*. Яңа елга чиста намус белән, биргән вәгъдәләр үтәлде дип керергә насыйп булсын. Без, халык депутатлары гына түгел, һәрбер кеше, эшчеме ул, зыялымы — узган ел заяга үтмәде дип мактана алсын иде.

Бер прожектор Рәшиткә юнәлтелә, икенче прожектор карават астындагы Фәндәсне «капшый».

Халык алдында гына түгел, бер-беребез алдында биргән вәгъдәләргә, антларга тугры булмау нәтиҗәсендә яңадан-яңа фаҗигаләр туа.

Вертолет ерагая, Шәйхинең тавышы да ерактан гына ишетелә башлый. Рәшит ята да тагын йокыга китә. Гырлый.

Еллар уза. Тагын бер ел үтеп китте. Нәрсәне дөрес эшләмәдек, нинди игелекле уй-ниятләребезне гамәлгә ашырмадык — тагын бер утырып уйлыйк әле...

Тынлык урнаша.

Саҗидә *(караватастына эндәшә)*. Син бар инде.

Фәндәс *(караватастыннан чыга)*. Син миңа үзем белән алып китәргә ризык бир.

Саҗидә. Ник, Зәйнәп ашатмыймыни?

Фәндәс. Юк шул. Ачтан үләм мин анда.

Саҗидә. Хәзер. *(Тиз генә пакетка ашамлыклар тутыра.)*

Фәндәс *(пакетны алып)*. Рәхмәт!

Кочаклашалар.

Саҗидә. Смотри анда!

Фәндәс. Ну, син нәрсә инде! Сау бул!

Саҗидә. Хуш!

Фәндәс тынычланып чыгып китә.

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Рәшитләр фатиры. Караңгы. Рәшит керә, шыпырт кына тунын салып элә, бүреген элгеч өстенә куя. Идәндә бөгәрләнеп, башыннан аягына кадәр одеялга төренеп ятучы Фәндәскә карап тора. Аннары караватта йоклаучы Зәйнәпкә карый. Барып сейфны ача. Мылтык ала. Зәйнәп янына килә. Мылтыгын сөяп куеп чишенә башлый. Трусиктан гына кала. Ашыга-ашыга Зәйнәп янына ята.

Зәйнәп *(кычкырып җибәрә)*. Көчлиләр!

Рәшит. Кычкырма! Мин бит бу!

Зәйнәп *(еш-еш сулый)*. Рәшит?! Уф, котымны алдың, тиле! Нишләп йөрисең?

Рәшит. Нишләп йөрмәм мин! *(Идәнгә ымлап.)* Кагылмадымы?

Зәйнәп. Юк, ничек кагылсын ул миңа?!

Рәшит *(кочаклый)*. Кил әле, кил, сагындым үзеңне.

Зәйнәп. Фәндәс ишетә бит.

Рәшит. Ишетсә, аның ни эше бар.

Зәйнәп *(Рәшитне этә)*. Юк, юк, без бит килешү төзедек. Син Саҗидә белән яшәп карыйсың, мин Фәндәс белән.

Рәшит. Бирермен мин сиңа! *(Елмаеп.)* Сагындым!

Зәйнәпне кочаклап үбәргә тотына. Шул вакытны җан өзгеч тавыш ишетелә.

Фәндәс. Алай ярамый! *(Торып утыра.)* Хыянәт!

Рәшит *(мылтыгын алып Фәндәскә төби, Фәндәс одеял астына кача)*. Нинди хыянәт булсын?!

Фәндәс *(одеял астыннан тавышы тонык кына булып ишетелә)*. Ник килдең?

Рәшит. Килмәдем, кайттым. Безнең түбәгә кар күп өелә. Иртәгә менеп көрисе бар. Аннары читен булачак кардан арынуы. Яз көне батабыз алайса.

Фәндәс *(одеял астыннан чыга)*. Алдыйсың. Мине мыскылларга дип, килешүне инкарь итеп килдең син. Зәйнәпне миңа хыянәт иттерер өчен.

Рәшит. Тинтәк!

Фәндәс. Без килешү төзедек, кул куйдык. Болай хыянәт итәргә ярамый. *(Кычкырып.)* Хыянәт!

Вертолет тавышы ишетелә. Прожекторлар яктырта. Шәйхи тавышы яңгырый. Фәндәс үрмәләп шифоньер артына поса. Рәшит диван астына керә. Зәйнәп юрганына төренә.

Шәйхи *(каяндыр күктән кычкыра)*. Мин халык депутаты буларак кына түгел, ЖЭУ начальнигы буларак та түгел, ә кеше буларак әйтәсем килә: биргән вәгъдәләрне үтәмәү — асылда исә ул үз-үзеңә хыянәт итү. *(Вертолет тавышы ерагая. Шәйхинең тавышы да ерактан ишетелә.)* Тагын шуны да әйтәсе килә, җәмәгать... Халык безгә өмет белән карый...

Рәшит *(диван астыннан чыгып әле Зәйнәпкә, әле Фәндәскә карап тора.)* Бер кызыгы да юк моның. Ну, нәрсә бирә безгә мондый кәмит?!

Зәйнәп. Үзең кул куйдың бит.

Рәшит. Тик кенә ят!

Фәндәс. *(шифоньер артыннан чыга)*. Миңа инде ике дөнья — бер морҗа.

Рәшит. Алай димә.

Фәндәс. Әллә нинди халәт — үтереп ашыйсы килә, шундый нык йокы килә, үз өемә кайтасым килә, ә менә... яшисем килми.

Рәшит *(кычкырып)*. Андый сүз әйтмә! Яшәргә кирәк!

Музыка.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Фәндәсләр фатиры. Рәшит гырлап йоклап ята. Саҗидә ашамлыклар күтәреп кайтып керә.

Рәшит *(уяна)*. Кайттыңмы?

Саҗидә. Кайттым.

Рәшит. Кар һаман явамы?

Саҗидә. Аның туктыйсы юк, ахрысы. *(Рәшиткә карап тора.)* Син берәр җирдә эшлисеңме соң?

Рәшит *(киерелеп)*. А как же!

Саҗидә. Кайда? *(Алып кайткан әйберләрен урнаштыра.)*

Рәшит. Син аны барыбер аңламаячаксың. Ашарга нәрсә пешерәсең бүген?

Саҗидә. Нәрсә пешерсәм, шуны ашарсың.

Рәшит *(торып утыра)*. Син минем яраткан блюдоларым турында да сорамадың никтер...

Саҗидә. Фәндәс нәрсә ашаган — син дә шуны ашаячаксың.

Рәшит. Фәндәснең килеш-килбәтенә карап аның ни ашаганын чамалау мөмкин.

Саҗидә. Бик яратып ашый иде әле. *(Бәрәңге әрчергә әзерләнә.)*

Рәшит. Аның иң яраткан ризыгы нәрсә?

Саҗидә *(бәрәңге әрчи)*. Табада кыздырган бәрәңге.

Рәшит. Көчле...

Саҗидә *(татлы елмаеп хатирәләргә бирелә)*. Әле өйләнешкәнче үк... Йөргәндә... Аның общежитиесенә барып бәрәңге пешерә торганыем. Аннан да тәмле нәрсә юк иде. Кара-каршы утырып әлүмин кашыклар белән бер таба бәрәңгене ашап бетерә идек. Бар иде рәхәт, бәхетле чаклар. *(Елый.)*

Рәшит *(авызын киң итеп ачып исни)*. Елама, әлүмин кашык табам мин сиңа.

Саҗидә. Әлүмин кашыкны аны табып булыр... Бәрәңгесен дә өеп пешереп булыр. Тик менә шул общежитиенең кысан гына бүлмәсендәге яктылыкны да, кара ипинең тәмлелеген дә инде мәңге кайтару мөмкин түгел. Бер тапкыр Сигезенче мартка Фәндәс миңа духи бүләк итте. Мин аның хуш исеннән һәм бәхетемнән чак кына аңымны җуймадым. Студент чак... Акча юк. Ә менә шуңа карамастан тамак та тук, киемнәребез дә үзебезгә шулкадәр килешеп тора иде. Бәхет ул һәркемгә килешә, шулай бит... Мин хәзер бернәрсәгә дә кызыкмыйм. Миңа әнә шул Фәндәс общежитиесендәге стаканнан шикәр каба-каба чәй эчү җитми. Миңа бернинди тәм-том кирәкми, мин унсигез яшьлек кыз чагымдагы аның һәр әйткән сүзеннән буыла-буыла көлеп, тончыга-тончыга изрәп пешкән бәрәңге ашавымны сагынам. Миңа бернинди байлык кирәк түгел, миңа яшь чагымда Фәндәс бүләк иткән хушбуй исе генә кирәк.

Рәшит. Минем яшьлегем болай ук катлаулы булмады. Ничектер гадирәк килеп чыкты минеке. Яшь чакта ашаган бәрәңгене никтер сагынмыйм. Тем более, без бит инде хәзер бананга күчтек.

Саҗидә *(бәрәңге әрчүдән туктый, плитә янында кайнаша)*. Ә синең яраткан ризыгың нинди?

Рәшит. Мин рагу яратам. Сандугач телләреннән әзерләнгән рагу.

Саҗидә. Нәрсә?!

Рәшит *(көлеп)*. Рагу из соловьиных языков.

Сажидә. Ул хәтле сандугач каян тапмак кирәк.

Рәшит. Татарда сандугачтан да күбрәк нәрсә юк. Син безнең җырларны гына тыңлап кара. Җырда сандугач дигән сүз катнашмаса, ул чын татар җыры түгел.

Фәндәс керә.

Фәндәс. Исәнмесез!

Рәшит. Аллага шөкер. Мактап кына йөрисең икән — как раз бәрәңге кыздырырга җыена идек. Тик менә, кызганыч, сезнең яшь чагыгыздагы комбижир юк хәзер.

Фәндәс. Минем шаярырлык хәлем юк.

Рәшит. Ә мин шаярмыйм. Нишләп йөрисең? Ни йомыш?

Сажидә. Исәнме, Фәндәс. *(Күзләрен тутырып карап тора.)*

Фәндәс. Сажидә, теге вельвет күлмәгемнең җиңен ямаган идеңме син?

Сажидә. Әйе.

Фәндәс. Бир әле.

Сажидә. Нигә ул?

Фәндәс. Киям.

Сажидә. Иске бит инде ул.

Фәндәс. Булсын. Аны бит син миңа Егерме өченче февральгә алган идең. Сиксән икенче елны.

Рәшит. Ай-яй, хәтер шәп сезнең икегезнең дә.

Фәндәс. Аннары, алмаш-тилмәш трусик кирәк миңа...

Рәшит. Ә трусикларны нинди бәйрәмгә алдылар сиңа?

Сажидә. Рәшит, телеңне тый!

Рәшит *(читкә китеп)*. Шаярырга да ярамый.

Фәндәс *(Рәшиткә)*. Зәйнәп Яңа ел бүләге сорап теңкәгә тия. Үзең шуңа бирәр бүләк алып бир әле. Минем акчам юк.

Рәшит. Хәзер син алырга тиеш аңа бүләкне, дорогой мой! *(Ниндидер җыр шыңшый-шыңшый журнал актара.)*

Сажидә. Ала күрмә!

Рәшиткә сиздермичә генә Фәндәскә ипи белән колбаса бирә. Фәндәс бер пакетка киемнәрен тутыра, икенче пакетка Сажидә биргән ризыкны тыга.

Фәндәс *(пышылдап)*. Ничек хәлләр?

Сажидә. Түзәрлек. Тамагың бик ачканда шылтырат. Паркта очрашырбыз, мин сиңа шунда ашарга алып килермен.

Фәндәс. Ярар. Үзеңнең хәлең ничек?

Сажидә. Ярый инде...

Фәндәс. Сау булып торыгыз!

Рәшит *(үчекләп)*. Чәй эчеп кит инде. *(Фәндәс чыгып китә. Сажидә елый.)*

Сажидә *(тәрәзәдән карап)*. Шул арада коры сөяккә калган.

Рәшит. Ул элек тә трафарет шикелле юка иде инде.

Сажидә. Нинди кансыз кеше син! Һәрбер сүзгә нинди дә булса ямьсез-тәмсез сүзне аркылыга китерәсең дә куясың!

Рәшит. Тынычлан, тынычлан! *(Иңеннән кочмакчы була.)*

Сажидә *(аны этеп җибәрә)*. Кит, якын килмә!

Рәшит *(диванга барып утыра, Сажидә тәрәзәдән тышка карап тора)*. Ачуланма. Шундый кеше инде мин, бернишләп булмый. Әйбәт кеше син. Минем менә шушындый хатыным булсын иде дә бит.

Сажидә. Ник, Зәйнәбеңә ни булган?

Рәшит. Берни дә булмаган. Ул да менә дигән хатын. Дөресен әйткәндә, бик сагындым мин аны. Безнең дә бит гүзәл хатирәләребез бар. Бер тапкыр «Афродита» ресторанында утырганда күрше өстәлдән бер кара гына кеше Зәйнәпкә бик озак карап утырды. Мин бардым да Зәйнәбемә карап утыручының ике каш арасына суктым. Шуннан соң Зәйнәп мәңге минем белән булачагы турында әйтте.

Сажидә. Ә теге кеше нишләде?

Рәшит. Кайсы?

Сажидә. Син ике каш арасына суккан кеше...

Рәшит. Белмим. Аны сөйрәп алып чыгып киттеләр. Ул бүтән кермәде. Ә бер тапкыр Зәйнәп белән икебез генә табигатькә чыктык. Каманың тын гына аккан бер мәле иде. Зәйнәп, дидем мин аңа, телисеңме, синең өчен Каманың теге ягына йөзеп чыгам, дидем. Телим, диде ул. Тик, зинһар, бата

күрмә, мин үзем генә моннан өйгә ничек кайтып җитәрмен, диде. Син миңа шундый кирәк, дип өстәп куйды ул. Шул чагында мин аңладым: чын-чынлап ярата ул мине.

Саҗидә. Каманы аркылыга йөзеп чыктыңмы соң?

Рәшит. Юк. Анда бер бик шикле катер бөтерелеп йөри иде, рыбнадзор булды, ахрысы. Минем йөзгәнне күрсәләр, ятьмә куйган, шуңа йөзә дип уйларлар иде. Мин Зәйнәпкә шулай дип аңлаттым да инде. Ул бит болай карап торуга гына иләс-миләс күренә, ә үзе ул бик аңлаучан, кайвакыт бик тирән аңлаучан хатын. Сагындым мин аны.

Саҗидә *(Рәшит янына йөгереп килә)*. Әйдә сезгә барыйк әле.

Рәшит. Ник?

Саҗидә. Җан тыныч түгел. Үзем генә барсам, әллә ничек.

Рәшит. Үзем генә барыйммы соң?

Саҗидә. Юк, минем үземнең барып аларның тормышын күрәсем килә.

Рәшит. Эт тормышыдыр инде, нәкъ безнеке шикелле үк.

Саҗидә. Әйдә, бергә барып кайтыйк.

Рәшит. Соң, әйдә. Без синең белән, имештер, ир белән хатын буларак аларга кунакка барабыз.

Саҗидә. Әйе, шулай булсын. Алай табигыйрәк килеп чыгар. Кунакка килдек дигән сәбәп белән барыйк.

Рәшит. Киттек. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә тыныч түгел, күңел кыбырсый... Барып кайтыйк.

Киенә башлыйлар. Музыка.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Зәйнәпләр фатиры. Фәндәс трико чалбарының балакларын сызганып, майкасын кыстырмыйча, тузан суырткыч белән идәннән тузан суырта. Зәйнәп кайтып керә. Куллары буш, иңендә кечкенә сумка.

Зәйнәп *(чишенә-чишенә)*. «Идеал» кибетендә шундый матур блузка күрдем. Яңа ел бүләге итеп ал әле миңа шуны.

Фәндәс *(тузан суырткычны сүндереп почмакка илтеп куя)*. Кыйммәтме соң ул?

Зәйнәп. Алты мең.

Фәндәс. О-о-о, минем туннан да кыйммәтрәк бит. Минем андый акчам юк.

Зәйнәп. Хәзерге ирләр шулкадәр саран. *(Көзге каршына килеп.)* Ой, битем яна. Тагын буран купты.

Фәндәс. Рәшит тә саранмы?

Зәйнәп. Күп сорашма. *(Свитерын салып халат кия.)* Син миңа бер бүләк тә алмыйсыңмыни Яңа елга?

Фәндәс. Карарбыз.

Зәйнәп. Рәшит булса болай вакчылланып тормас иде...

Фәндәс *(тузан суыртканда күчергән әйберләрне урыннарына урнаштырып)*. Бүләкне аны сорап алмыйлар. Әлбәттә, бүләксез калдырмам...

Зәйнәп. Ужас, ирләр ничек саран хәзер!

Фәндәс. Хатын-кызы да аның хәзер бигүк юмарт түгел. Син әле миңа чәй дә куеп эчертмәдең.

Зәйнәп. Кстати, чәй куеп җибәр әле, зинһар. Аякларым шундый арыды.

Фәндәс *(чәй куя)*. Алай-болай кунакларың киләсе юкмы бу арада?

Зәйнәп. Ник сорыйсың?

Фәндәс. Кунак-мазар киләсе булса, югалып торырмын...

Зәйнәп. Кунагына карарбыз. Югалып тор, дисәм, күренми торырсың. Бер дә кунак кабул итәсем килми әле.

Рәшит белән Саҗидә култыклашып керәләр.

Саҗидә. Исәнмесез!

Фәндәс *(шатланып)*. Исәнме, Саҗидә!

Зәйнәп *(коры гына)*. Менә кунаклар киләме дигәниең... Озак көттермәделәр. Хуш килдегез!

Рәшит *(күзен Зәйнәптән алмый)*. Кунакка килдек... Парлап... Бер-беребезгә кунакка йөрешсәк ярыйдыр бит, в конце концов.

Зәйнәп. Ужас!

Рәшит *(көлеп)*. Чакырылмаган кунак чакырылганыннан да яманрак. Ха-ха-ха!

Фәндәс *(читенсенеп)*. Юк, юк, без кунакларга бик шат. Ашарга гына бернәрсә дә юк түлке...

Рәшит *(чишенә дә бүлмә буйлап арлы-бирле йөри)*. Ярар, сөйләшеп кенә утырырбыз.

Фәндәс. Зәйнәп, әйдә, кунакларны урнаштыр инде...

Зәйнәп. Алар, нәрсә, мебель что ли урнаштырырга?! Узыгыз.

Саҗидә *(кызганып Фәндәснең кыяфәтен күзәтә)*. Нишлисез?

Фәндәс. Мин табак-савыт юдым, тузан суырттым. Зәйнәп әле генә кайтып керде. Хәзер, күлмәгемне киим әле. *(Күлмәген киеп куя, трико балакларын төшерә.)* Ә үзегез ни эшләр бетереп ятасыз?

Сажидә *(чишенеп түргә уза)*. Мин эштән кайттым. Рәшит йоклый иде.

Зәйнәп. Яңа елны кайда каршыларга уйлыйсыз соң?

Рәшит. Белгән юк әле.

Фәндәс *(куанычлы тавыш белән)*. Әйдәгез, бергәләп каршылыйк!

Рәшит. Аңлыйм: синең ашыйсың килә. Бергә каршыласак, авызыңа ризык керәчәк...

Зәйнәп *(ачуланып)*. Мондый компаниядә утырырга мине кем дип белдегез. Бик матур килеп кердегез парлашып, ике аккош кебек, барыгыз, икегез каршылагыз.

Рәшит. Син чыркылдамый тор әле, яме. Болай да бәгырь телгәләнә. Бозау суйган көнне свежий бавырны телем-телем кисеп табада кыздыралар бит әле... Шуның шикелле.

Фәндәс *(чыраен сытып)*. Син юри мине интектерер өчен кыздырылган бавыр турында әйтәсеңме?

Рәшит. Юк, сине интектерүдән миңа ни файда?

Фәндәс *(хыялланып)*. Бозау суйган көнне бәлеш тә пешерәлә-ә-әр... Их!

Бүлмәнең төрле тарафларына утырышалар. Тынлык урнаша.

Зәйнәп *(тырнагын пилка белән ышкып)*. Нәрсә, берәр уен уйныйк мәллә?

Рәшит. Бу бит аулак өй түгел.

Фәндәс. Шешә әйләндерешле уйнасак кына инде. Без яшь чакта уйный идек.

Сажидә. Әйдәгез, Шәйхигә шылтыратабыз.

Рәшит. Шешә алып кил, дипме?

Сажидә. Якынлашып килүче Яңа ел белән котлап.

Рәшит. Җитешербез әле.

Зәйнәп. Йә, сөйләгез инде, ни эшләр бетереп ятасыз?

Рәшит. Әллә ни кырган эш тә юк инде... Ә үзегез?

Фәндәс. Без төнлә елкага чыгарбыз, ахрысы, шулай бит, Зәйнәп?

Зәйнәп. Посмотрим.

Сажидә. Без чыгабызмы, Рәшит?

Рәшит. Ник, чыгарбыз.

Фәндәс. Гафу итегез, ә сез елканың кайсысына чыгарга җыенасыз?

Рәшит. Ә сез?

Сажидә. Җитте! Бу нинди мәгънәсез сөйләшү соң?!

Зәйнәп. Соң, мәгънәле сүз сөйлә. Без тыңларбыз.

Сажидә. Моның азагы булыр микән?

Зәйнәп. Вряд ли.

Рәшит. Рәхәтләнеп сөйләшеп утырып булмасмы дигән идем, барып чыкмас ахры.

Фәндәс. Мин чәй әзерлим әле. *(Торып табын тирәсендә бөтерелә.)*

Сажидә. Балаларыбыз белми.

Зәйнәп. Нәрсәне.

Сажидә. Безнең болай буталганны.

Зәйнәп. Мин үзем бер дә буталмадым, Аллага шөкер. Безнең кызыбыз кечкенә, аңлатсаң да аңларлык түгел әле. Сезнең улыгыз инде егет кеше — үзе дә мондый кәнитилләрдә катнашырлык. Кайчан өйләнә соң инде?

Сажидә. Иртә әле аңа өйләнергә. Укуын тәмамлыйсы бар. И Ходаем, тиздән каникулга кайтачак бит ул. Фәндәс! Нишләп син шушындый ихтыярсыз соң, ә?!

Фәндәс. Нишлим соң?!

Сажидә. Оят! Хурлык! *(Елый-елый чыгып йөгерә.)*

Фәндәс *(аның артыннан чыкмакчы була)*. Сажидә!

Рәшит *(Фәндәсне туктата да үзе чыгып йөгерә)*. Сажидә, тукта!

Тынлык урнаша.

Зәйнәп. Менә, кунаклар килеп китте.

Фәндәс. Әйе, парлашып кунак булып киттеләр.

Зәйнәп. Хәзер җавап итеп без барырга тиешме инде?

Фәндәс. Кая?

Зәйнәп. Аларга кунакка.

Фәндәс. Белмим. Кунакка йөрешү бар инде ул... Барып кайтырбыз.

Зәйнәп *(елый)*. Кунакка?! Нәрсә, бу спектакль чынга авышып барамыни?! *(Кызып китә.)* Култыклашып килеп керделәр, мин сиңа әйтим! Ненавижу! *(Ярсый.)* Алар чын-чынлап ир белән хатын булып яшәп яталар микән әллә?!

Фәндәс. Тынычлан, Зәйнәп. Нишләп алай булсын.

Зәйнәп *(истерикага бирелеп).* Ә нишләп алай булмасын ди?! Син монда селәгәеңне агызып утыргач та, нәрсә, бөтен ирләр дә синең шикелле дип уйлыйсың мәллә?! Рәшит ул син түгел. *(Кул астындагы әйберләрне төрле якка тотып ыргыта.)* Без синең белән аеры-чаеры ятуын ятабыз, ә анда аларның нишләп ятканнарын белмибез!

Фәндәс. Мин бит үзем барып тикшереп кайттым. Анда барысы да тәртиптә. Үзем күрдем аерым йоклаганнарын.

Зәйнәп. Идиот!

Фәндәс. Син нишләп минем күңелемә дә шөбһә саласың соң әле? Хәзер мин тагын да ныграк курка башладым. Шулай да, Рәшитеңне белмим, но Саҗидәмә минем ышанасым килә.

Зәйнәп. Син бу дөньяга әле яңа гына баздан чыктыңмы әллә?!

Фәндәс. Әйдә, сине дә алып барам. Үз күзләрең белән күрерсең. Шунда мин дә тагын бер кат күреп тынычланырмын.

Зәйнәп. Мин беркемгә дә ышанмыйм!

Фәндәс. Үзем алып барып күрсәтермен. Тынычлан.

Зәйнәп. Хәзер үк барабызмы?

Фәндәс. Төнлә барабыз. Минем ачкыч бар бит.

Зәйнәп. Уянсалар?

Фәндәс. Кунакка килдек, диярбез. Кунакка йөрешү бар бит ул.

Музыка.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Саҗидәләр фатиры. Караңгы. Саҗидә караватта, Рәшит иске диванда йоклап ята. Зәйнәп белән Фәндәс керәләр. Рәшит гадәттәгечә гырлый.

Фәндәс *(пышылдап).* Күрәсеңме, һәркем үз урынында. Яхшы.

Зәйнәп *(пышылдап).* Әйдә, киттек, уятып тормыйк инде. Булды, күрдек — бергә йокламыйлар.

Фәндәс. Юк, юк. Минем үтереп ашыйсым килә. Берәр нәрсә табып капкалыйм инде.

Зәйнәп. Ә мин көтимме сине?

Фәндәс. Бар, күрше бүлмәдә утырып тор. Җылынырсың да. Мин тамак ялгагач китәрбез.

Аяк очларына гына басып күрше бүлмәгә юнәләләр. Фәндәс алдан бара, Зәйнәп аңа иярә. Күрше бүлмәгә кергәндә Фәндәс ялгыш төчкерә. Рәшит кинәт торып утыра. Фәндәс күрше бүлмәгә кереп шыла. Зәйнәп баскан урынында катып кала.

Рәшит *(караңгыда Зәйнәпне танымый).* Саҗидә!

Зәйнәп *(чак кына ишетелерлек итеп).* Ә?

Рәшит. Мин дә болай алмашынып йөрүнең мәгънәсен тапмыйм. Шәйхигә чынлап та шылтыратырга кирәк.

Зәйнәп *(тавышын үзгәртеп)*. Әйе.

Рәшит. Нишләп пышылдап кына сөйләшәсең?

Зәйнәп *(авызын каплап)*. Тешем сызлый.

Рәшит. Мин инде Зәйнәпне элек рәнҗеткәннәрем өчен дә үкенә башладым. Яратам мин аны. Аңардан башка нишләрмен. Мин дә бит инде алай бигүк яшь кеше түгел.

Зәйнәп. Әйе. *(Күрше бүлмәгә таба бара.)*

Рәшит. Туктале, сөйләшик.

Зәйнәп *(авызын томалап)*. Дару теге бүлмәдә. Йокла. *(Кымшанырга курка.)*

Рәшит *(торып утыра)*. Тартып керим әле. Балконга чыгып тартырмын, ахрысы.

Тумбочка өстеннән сигарет белән зажигалка ала. Сигаретын диванда утырганда ук кабыза. Зажигалкасын яндырып тотып тора. Шул саран гына яктылыкта Зәйнәпне күзәтә.

Саҗидә, син нишләп киендең?

Зәйнәп *(авызын кулы белән каплап).* Ни... Чүп түгеп кердем.

Рәшит. Бу вакыттамы? *(Зажигалкасын сүндерә.)*

Зәйнәп *(авызын томалап)*. Чүп чиләгеннән сасы ис килеп тора иде.

Рәшит. Алай икән. Син төчкердеңме?

Зәйнәп. Әйе.

Рәшит. Сәламәт бул.

Зәйнәп. Рәхмәт.

Рәшит. Мин тартып керәм.

Сигаретын суыра-суыра балконга чыгып китә. Зәйнәп шундук икенче бүлмәгә керә.

Саҗидә *(уяна, ыңгыраша-ыңгыраша боргалана).* Уф, сәгать ничә икән?

Бу вакытта Фәндәс күрше бүлмәдән чыгып ашарга эзли башлый. Тапкан бер ризыкны ашый. Караңгыда Саҗидә аны Рәшит дип белә.

Рәшит, нишлисең син?
Фәндәс *(авызын ача алмыйча ашый).* М-м-м...
Саҗидә. Бигрәк күп ашыйсың син.
Фәндәс. М-м-м...
Саҗидә. Рәшит, ә минем бернәрсә дә исбатлыйсым килми. Чөнки минем Фәндәскә бер генә тапкыр да хыянәт иткәнем юк. Хәтта андый уйның башыма да килгәне юк. Шуңа күрә беркемгә бернәрсә исбатламаячакмын.
Фәндәс. М-м-м...

Балконда Рәшит йөткерә.

Саҗидә. Рәшит, балконда кеше бар мәллә?!
Фәндәс *(Саҗидә янына йөгереп бара).* Мин бу — Фәндәс!
Саҗидә. Фәндәс?!

Балкон ишеге ачыла.

Фәндәс. Тс-с-с.

Караватартына кача. Рәшит керә.

Рәшит *(корык-корык йөткерә).* Декабрьдә бу кадәр карның яуганы юк иде.
Саҗидә *(торып утыра).* Һаман явамы?
Рәшит. Ява. Утны кабызмыйммы?
Саҗидә. Юк, юк, мин эчке күлмәктән генә.
Рәшит. Тешең һаман сызлыймы?
Саҗидә. Минем тешемнең сызлаганы да юк. Фәндәс гел карап тора минем тешләремне.
Рәшит. Үзең әйткәниең бит.
Саҗидә. Кайчан?
Рәшит. Әле яңа гына.
Саҗидә. Төшеңдә күргәнсеңдер.
Рәшит *(ята).* Шулайдыр. *(Авыр сулап куя.)* Яңа ел алдыннан беркайчан да быелгы шикелле болай ямансу, күңелсез булганы юк иде.
Саҗидә. Кышы да бит аның башка еллардагыча килмәде.
Рәшит. Әллә үзебез кышка башка еллардагыча кермәдекме?..
Саҗидә. Фәлсәфиләнә башладың әле син.
Рәшит. Монда философка да әверелерсең.
Саҗидә. Никләр чемоданнарымны күтәрешеп кайттың, ә?!
Рәшит. Таныш кешегә ярдәм итү бар бит инде ул. Кем белгән аның болай килеп чыгасын! Кайвакыт кешегә яхшылык эшләү дә ярамый шул. *(Шундук гырлап йокыга китә.)*
Фәндәс *(пышылдап).* Теге бүлмәгә кереп ятып торыйм әле.
Саҗидә. Бар.

Фәндәс шыпырт кына күрше бүлмәгә кереп китә. Рәшит гырлап йоклый, Саҗидә тынгысызланып ята. Аяк очларына гына басып Зәйнәп чыга. Дару эчәргә су эзли. Куллары белән стенаны, өстәлне капшый. Даруын каба да, чәйгүннең борыныннан су эчә. Саҗидә аны Фәндәс дип уйлый. Пышылдап эндәшә.

Фәндәс!
Зәйнәп *(авызындагы суны да йотарга куркып торaташ булып катып кала).* М-м-м...
Саҗидә. Суыткычта пешкән пилмән бар. Салкын килеш тә тәмле бит ул. Алып аша.
Зәйнәп. М-м-м...
Саҗидә. Хәзер үзем алып бирәм. *(Тора. Шыпырт кына килә.)*
Зәйнәп *(котсыз калып).* Мин бу, Саҗидә.
Саҗидә. Зәйнәп?!
Зәйнәп. Әйе.

Рәшит уяна. Ике хатын йөгереп барып Саҗидәнең караватына барып яталар һәм юрган ябыналар. Фәндәс күрше бүлмәдән чыга. Бүлмәгә колак салып тыңлап тора. Фәндәс диван яныннан узганда Рәшит торып утыра.

Рәшит *(караңгыда Фәндәсне Саҗидә дип уйлый).* Саҗидә!
Фәндәс *(читкә тайпыла да баскан урынында катып кала).* М-м-м...

Рәшит. Карале, Саҗидә... Болай булмый. Нәрсә, башка проблемалар беткәнмени?! Шәйхигә барырга кирәк. Җитте, булды! Мин Шәйхигә мөрәҗәгать итмичә генә Зәйнәп янына кайтып китәр идем дә... Фәндәс бар бит. Ул бит сабый шикелле — теге бланкларга чын күңелдән ышана. Үзебезнең тормышны үзебез хәл итәргә тиешбез. Шәйхи дә түгел, аның әллә кайда бастырылган бланклары да түгел. Кеше ул гомер буе үзенә авырлыклар уйлап чыгара. Күрәсең, адәм баласы тыныч кына яши алмый. Беркавым тыныч яшәсә, аңа кичекмәстән нинди дә булса киртәләр калкуы, проблемалар тууы кирәк. Хәсрәт килмәсә, кеше аны үзе уйлап чыгара, үзе чакырып китерә.

Фәндәс *(шатлыктан очып китәрдәй булып утны кабыза).* Рәшит! Әйдә Шәйхигә шылтыратабыз!

Рәшит *(каушап кала).* Фәндәс?!

Фәндәс. Болай дәвам итү мөмкин түгел! Тор әле, тор. Шылтырат Шәйхигә. Син бит сөйләшә беләсең.

Зәйнәп *(яткан җиреннән).* Шылтырат, Рәшит, шылтырат.

Рәшит *(Зәйнәпкә аптырап карап тора).* Син дә мондамыни?!

Зәйнәп. Монда булмый. Кая булыйм мин!

Рәшит *(телефон номерын җыя).* Менә сиңа мә! *(Кат-кат шылтырата.)* Мин йоклап ятам, ә монда переворот булырга тора икән. *(Трубканы куя.)* Алмый.

Фәндәс. Йоклыйдыр. Әйдә, өенә барабыз. Киен, киен, тизрәк. Яңа ел җитә бит инде. *(Киенә.)*

Рәшит *(киенә-киенә)*. Барып нәрсә дибез соң аңа?

Фәндәс. Мине Саҗидә янына, сине Зәйнәбең янына кайтаруын сорыйбыз.

Рәшит. Ник аңардан сорап торырга.

Фәндәс. Кул куйдык бит.

Рәшит. Нинди беркатлы кеше соң син, ә?! *(Чыгып китәләр.)*

Зәйнәп *(сикереп торып киенә башлый).* Мин дә барам!

Саҗидә. Син барып йөрмә инде.

Зәйнәп. Барам, барам. Вдруг ярдәмем тияр.

Тунын иңенә элә дә чыгып йөгерә. Саҗидә тәрәзәдән тышка карап тора. Музыка.

**СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Саҗидә, җырлый-җырлый, күлмәккә сәдәп тагып утыра.

Качкан хәтта иң якты йолдыз да,
Тышта йөри улап буран-җанвар.
Миңа гаҗәп түгел бу матавык,
Минем өйдә инде күптән гыйнвар.

Күптән инде йортны төрле яктан
Ачы җилләр калын бозга төрә.
Тәрәзәләр сине көтә, тик рамнарның
Ярыгыннан һаман салкын өрә.

*(Саҗидә җыры.)*

Елый-елый Зәйнәп керә. Бүреген салып кулына тота. Тунын салмыйча түргә уза һәм урындыкка утыра.

Саҗидә. И Ходаем, ни булды?

Зәйнәп *(сулкылдап)*. Ни булганын беләсең бит.

Саҗидә. Шәйхи нәрсә диде?

Зәйнәп. Өендә юк ул.

Саҗидә. Тегеләр кайда?

Зәйнәп *(елый)*. Эчеп утыралар.

Саҗидә. Кайда?

Зәйнәп *(авызын җәеп)*. Бездә.

Саҗидә. Яңа ел алды бит. Бераз эчсәләр ни булган.

Зәйнәп *(һаман елый)*. Түбәдән карны көрисе бар иде. Ике ир анда чакта көрәсеннәр иде.

Саҗидә. Исерсәләр, көри алмаслар инде. Исерек баштан түбәгә менә күрмәсеннәр. Елама. Эчсеннәр инде.

Зәйнәп *(әкренләп елаудан туктый).* Эчкәннәренә еламыйм ла мин.

Саҗидә. Ә ник елыйсың?

Зәйнәп. Рәшит әйтә: һәркем үз өенә кайтсын, ди, үз хатыны белән яшәсен, ди. Ә Фәндәс курка. Теге Шәйхи тутырткан бланклардан перәме коты алынып тора. Рәшит аңлатып карый ул кәгазьләрнең туфта икәнен. Фәндәс барыбер курка. Рәшит тегене һич күндерә алмый. Аптырагач күп итеп аракы алып

кайтты. Исергәч Фәндәс кыюланыр да, имеш, бланкларга төкерер дип эчәләр дә эчәләр, ә Фәндәс үз киресен сукалый да сукалый: Шәйхи кушты, Шәйхигә ант бирдек, бланк тутырдык дип һаман мәлҗерәп утыра.

Сажидә. Ул гомергә шундый булды. Тынычлан, Зәйнәп, тынычлан.

Зәйнәп. *(беркавым тын утырганнан соң)*. Өегез матур сезнең.

Сажидә. Сезнең дә шәптер. Рәшит бизнесмен булгач...

Зәйнәп. Әй, бизнесмен... Теле генә әйбәт эшли. Аның бизнесменлыгы...

Сажидә *(көлеп)*. Әйтәм җайлы гына котылдың — миңа җибәрдең.

Зәйнәп. Монда түгел, үзебездә утыра бит инде.

Сажидә. Бик әйбәт. Шунда гына утырсын.

Зәйнәп. Ичмаса, фатир алырлык акчабыз да юк бит. Бизнесмен башы белән сносить итәләр дип көтеп ята кайчаннан бирле.

Сажидә. Сезнең фатир шулай начармыни?

Зәйнәп. Сөйләп бетергесез. Ул йортка йөз ел бардыр инде. Түшәме юка гына. Яңгыр яуса да — кайгы, кар яуса да — хәсрәт. Түбәсе дә юк бит. Шәйхи дә... фатир вәгъдә итеп йөри, ә үзе бирми.

Сажидә. Хәзер фатир бирү беткәндер инде ул.

Зәйнәп. Нишләп бетсен. Бирәселәре килсә, бирәләр.

Сажидә. Сносить итәрләр әле.

Зәйнәп. Үзебез белән бергә сносить итмәгәйләре...

Сажидә. Алай бик төшенкелеккә бирелмә.

Зәйнәп. Ни гаҗәп: син шулхәтле тыныч. Бернинди кайгың юк шикелле утырасың.

Сажидә. Күңелгә әллә нинди шатлык керде, Зәйнәп. Яңа ел алдыннан кинәт җан тынычлыгы урнашты. Барыбер начарга таба бармый кеше гомере. Ничек кенә яшәмик, ничек кенә ачуланышмыйк — барыбер яктылыкка илтергә тиеш юл. Башкача мөмкин түгел.

Зәйнәп. Сиңа мондый ышаныч бүген генә килдеме?

Сажидә. Әйе, менә хәзер. Фәндәснең күлмәгенә сәдәп тагып утырганда. *(Зәйнәпкә беркавым карап торганнан соң)*. Әйдә чәй эчәбез.

Зәйнәп. Эчик.

Сажидә чәй куя.

Сажидә. Туныңны сал.

Зәйнәп. Әйе шул. *(Тунын салып элә.)* Мин шуны уйлап куйдым әле: алар тату булгач, нишләп без дошманнар соң?

Сажидә. Кемнәр тату, кемнәр дошман — аңламадым?

Зәйнәп. Нишләп без синең белән дошманнар, ә алар бергә якынлашып килүче Яңа елны каршылап эчеп утыралар?!

Сажидә. Син нәрсә сөйлисең! Нинди дошманнар булыйк без синең белән?! Мин сине дошман итмим. Утырсыннар. Бик әйбәт. Син үзең нишләргә уйлыйсың соң?

Зәйнәп. Белмим. Минем хәтта уйлыйсым да килми.

Сажидә. Син югалып кала торганнардан түгел.

Зәйнәп. Алай димә.

Сажидә. Син бөтен кеше югалып беткән сурәттә дә, берүзең калып, дөньяны айкап йөри торган хатын. *(Көлә.)* Шаярып әйтәм, шаярып. Үпкәли күрмә!

Зәйнәп *(кинәт күңеле йомшара.)* Сажидә! Нишләп мине һәммәсе дә җиңел яшидер, уйсыздыр, һәрбер нәрсә җайлы биреләдер дип саныйлар?! Мин гомерем буе сер бирмәскә тырышып яшим. Эчемдәгенең яктырагын гына чыгарам мин тышка. Анда, үзәгемдәниләр кайнаганын беркемгә күрсәтмәскә тырышам мин. Җан сызлаганда да, төкерәм барысына дигән ясалма кыяфәт белән кыланам бит мин. Тышымдагы кабык буенча гына бәя бирәләр миңа. Җиңел акыллы булып күренәм икән — гаеп үземдәдер. Ләкин эчемдәге ут белән ачуны күрсәтмәскә мин детдомда өйрәндем.

Сажидә. Син балалар йортында үстеңмени?

Зәйнәп. Әйе. Әтием әнине ташлап юкка чыккач, әни шунда илтеп куйган мине.

Сажидә. Алай икән... Ә Самарада кемең бар синең? Кызың шунда әниемдә дигән идең бит.

Зәйнәп. Алдадым. Кызым минем Рәшитнең әнисендә, Зеленодольскида. Мин гомерем буе әнием исән дип алдарга яратам. Чөнки аның исән булуы турында хыялланам.

Сажидә. Ул исән түгелмени?

Зәйнәп. Белмим. Юктыр. Исән булса мине бөтенләйгә балалар йортында калдырмас иде.

Сажидә. Ашыйсың киләме?

Зәйнәп. Юк. Чәй эчәсем килә. *(Бер-берсенә карап елыйлар.)*

Сажидә. Әйдә, матурым, якынрак утыр. Бик тәмле бал бар.

Зәйнәп. Ой, балга минем аллергия. Битем тимгелләнә.

Сажидә. Карлыган вареньесы бар.

Зәйнәп. Крыжовникныкы юкмы?

Сажидә. Юк. Хәзер, өстәге күршеләрдән менеп сорыйм. Аларның бакчасы бик бай, аларда әллә нинди вареньелар бар.

Зәйнәп. Юк, юк, мәшәкатьләнмә, кешеләрне дә борчыма. Менә бит кәнфит бар. Өстә һаман шул СССР тарихын укыткан Гутман яшиме?

Сажидә. Гутманнар узган елны Израильгә киттеләр. Хәзер безнең өстә бөтен инструментларда уйный белә торган прокурор яши. Җелегебезне корыта инде гел бер көйне генә уйнап. То скрипкада уйный, то баянда, то рояльдә, то торбада... *(Чәй ясый.)*

Зәйнәп. Нинди көй уйный соң ул?

Сажидә. Таныш көй түгел. Үзе чыгарган, ахрысы.

Зәйнәп. Бик читендер?

Сажидә. Күнектек инде. Хатыны бик әйбәт аның. Нарсудта судисполнитель булып эшли — алиментчыларның исполнительный листлары белән шөгыльләнә шунда. Син үзең һаман бер җирдә дә эшләмисеңме?

Зәйнәп. Рәшит эшләтми бит. *(Чәй эчәләр.)*

Сажидә. Хәзер хатыннарны эшләтмәү модада инде ул.

Зәйнәп. Син поликлиникадамы?

Сажидә. Әйе. УЗИда мин хәзер.

Зәйнәп. Ой, минем тикшереләсем бар иде.

Сажидә. Теләсә кайсы вакытта кил, читенсенмә. Тикшерәм. Үз полотенцың белән кил түлке.

Зәйнәп. Озак дәвам итәр микән бу матавык?

Сажидә. Белмим. Үзем дә туйдым.

Зәйнәп. Сажидә, алайса, мин синдә куныйм әле. Кайтмыйм мин анда.

Сажидә. Ярар. Бик әйбәт.

Зәйнәп. Синең белән рәхәтләнеп кич утырырбыз. *(Канатланып.)* Мин дә бу кәнитилнең ахыры яхшы булыр дип уйлый башладым әле.

Сажидә. Алла боерса, шулай булыр. Барыбер Фәндәстән башка яши алмыйм.

Зәйнәп. Үзем дә шул җүләр Рәшитемнән башка тормышымны күз алдыма китерә алмыйм.

Сажидә. Сәер шул безнең тормыш...

Зәйнәп. Яңа елны синең белән икебез каршыларбыз микәнни?!

Сажидә. Егетләр чакырмыйкмы соң?

Зәйнәп. Чакырыйк. *(Рәхәтләнеп көләләр.)*

Сажидә. Тегеләргә ачу итеп...

Шәйхи керә. Кыяфәтеннән җитдилек бөркелеп тора.

Шәйхи. Исәнмесез!

Сажидә. Исәнмесез!

Зәйнәп. Менә, бер егет инде бар. Тагын берәү генә кирәк.

Шәйхи *(каядыр түшәмнең ерак бер ноктасына текәлеп).* Кызлар! Сезгә ни кирәктер, белмим. Мин хәтта үземә ни кирәклеген дә шушы яшемә җитеп әле һич кенә дә аңламадым.

Шәйхи җырлый.

Сажидә. Нәрсә булды сезгә? Кинәт үзгәргәнсез. Бөтенләй башка кешегә әйләнгәнсез шикелле.

Шәйхи *(актерланып)*. Минем хисләрем ташкын булып ага. Шуңа килдем мин монда — уй-кичерешләрем белән уртаклашырга. Минем тормышым тагын бер борылыш кичерә.

Зәйнәп. Тәлгать Бариевич кызы белән никахлаштыгызмы әллә?

Шәйхи. Юк! Аның белән никахлашу юк! Бала-чага ул! Мин үземнең хатынымны кире алып кайттым.

Сажидә. Котлыйм!

Шәйхи. Рәхмәт. Ә үзегездә яңалыклар юкмы?

Зәйнәп. Яңалык шул — иртәгә инде Яңа ел башлана.

Шәйхи. Нишләп соң бер дә салат-мазар исе чыкмый әле монда? Син, Сажидә, Яңа елны каршыларга җыенмыйсыңмыни?

Сажидә. Янымда ирем булмагач, бернәрсә эшлисем килми.

Шәйхи. Ә син, Зәйнәп, нишләп монда?

Зәйнәп. Яңа елны Сажидә белән каршыларга булдык.

Шәйхи. Менә сиңа мә! Сез нигә дип минем башны бутыйсыз, ә! То тегеләй, то болай. То талашасыз, то татулашасыз. То тегенең белән, то моның белән! Нормально гына яши алмыйсызмыни соң сез?! Ирләрегез кайда?

Зәйнәп. Бездә. Яңа елны каршылый башладылар инде алар.

Сажидә. Димәк, син үзеңнең хатының белән татулаштың?

Шәйхи. Татулашу дип атап булмый әле... Юмалау стадиясе бара. Минем дә тормыш җиңел түгел. Минем дә гаиләм тотрыклы түгел. Должностьтагы кеше буларак, депутат буларак кына бирешмим бит мин.

Сажидә. Менә, Алла бар ул. Безне татулаштырсаң, үзеңнең дә гаиләң рәтләнер. Яңа ел алдыннан игелекле эш эшләсәң, үзеңә Яңа ел гел иминлек китерә, ди.

Шәйхи. Ну, мин сезнең белән нишләргә дә белмим инде. Үзегез чамалагыз. Бала-чага түгел бит сез.

Зәйнәп. Монда Фәндәс бала-чагадан да хуже!

Сажидә *(елый).* Алып кил аларны монда.

Шәйхи. Ә килмәсәләр?

Сажидә. Сине тыңлыйлар алар. Син бит авторитет алар өчен.

Шәйхи. Алып килсәм, татулашасызмы соң?

Зәйнәп. Татулашабыз.

Шәйхи. Болай гына барып боерсам әллә ничек... Табигый итеп китереп чыгарырга кирәк кавышуыгызны. Уйларга кирәк...

Сажидә. Зинһар, уйлагыз, ярдәм итегез.

Шәйхи. Үземнең дә сезне кавыштырасы да, татулаштырасы да килә. Минем үземнең тормышымда да Яңа ел алдыннан күңелле вакыйга булды бит. Тәк, Яңа елга күп калмады... Ничек китертергә аларны монда?.. Барып отоплениеләрен отключать итим мин. Туңгач, монда килми кая барсыннар. Фәндәснең сантехник булып эшләгән вакыттагы киемнәре исәнме?

Сажидә. Әйе. Темнушкада. Хәзер алып бирәм.

Сантехник киемнәрен алып килә. Зур газовый ачкыч та китереп куя. Шәйхи почмакта өс киемен алмаштыра.

Зәйнәп. Отоплениене отключать иткәч тә алар барыбер киреләнеп килмәсләр, катып үләрләр...

Сажидә. Шәйхулла Галимуллович катып үләрлек итмәс инде.

Зәйнәп. Килерләр микән?

Сажидә. Килерләр.

Зәйнәп. Инде исерешеп беткәннәрдер.

Сажидә. Исерсеннәр, тик Яңа елны гына бергә каршылыйк. Яңа елны бергә каршыламасак, ел буе аеры-чаеры булачакбыз.

Шәйхи *(сантехник киеменнән көзге каршына килеп баса).* Юл уңаеннан ЖЭУга кереп ясалма сакал-мыек ябыштырырмын. Танымасыннар өчен.

Зәйнәп. ЖЭУда сакаллар бармыни?

Шәйхи. ЖЭУда бөтен нәрсә бар. *(Чыгып китә.)*

Сажидә *(шкафтан коньяк ала).* Әйдә, өстәл әзерләп куйыйк. Булган нәрсәләрне өстәлгә чыгарсак, шул җиткән. Бар, суыткычта нәрсә табасың, өстәлгә алып кил.

Тыз-быз килеп өстәлгә ризык ташыйлар. Музыка.

**ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Тышта буран. Рәшитләр фатирында исә җып-җылы. Рәшит билдән тиң шәрә утыра, ә Фәндәс майкадан. Эчәләр. Инде шактый исергәннәр. Ишек катына кар көри торган агач көрәкләр сөялеп куелган.

Фәндәс. Бигрәк нык дулый буран.

Рәшит. Караңгы төшкәнче түбәдәге карны көрәрбез әле, яме.

Фәндәс. Ярар.

Рәшит. Тагын берәр көн яуса, түшәмебез авырлыктан җимереләчәк, валлаһи газим.

Фәндәс. Бүген утыз беренче декабрь. Бүген җимерелмәсен инде ул. *(Дерелди.)* Өең салкынаеп китте түгелме?..

Рәшит. Декабрьдә майкадан утыргач, эссе булырга тиешме?

Фәндәс. Бу майканы миңа Сажидә туган көнгә алгание...

Рәшит. Яңа елны синең белән икәү каршылыйбызмыни инде?

Фәндәс. Ник, начар кеше белән каршылыйсың, что ли?!

Рәшит. Юк, эш анда түгел, дустым. Иске елда гаилә проблемаларын хәл италмый калдык микәнни?!

Фәндәс *(хәсрәтле чырай белән)*. Рәшит!

Рәшит. Ә?

Фәндәс. Мин лутчы асылыныйм.

Рәшит. Тик монда түгел, яме. Әнә, пажалысты, пожарка артында иске алачык бар — анда стенада төрле ыргаклар, кадаклар күп. Теләсә ничек асылына аласың.

Фәндәс. Ә син каян беләсең?

Рәшит. Мин үзем бер тапкыр Зәйнәпкә ачу итеп шунда асылынырга барган идем.

Фәндәс. Ә ничек исән калдың?

Рәшит. Инде элмәкне муеныма кигән идем. Туктале, нишләп мин шул чәчбикамал аркасында бу дөньядан китәргә тиеш дип уйлап куйдым. Дөнья хәтле дөньяны шул сарбай хатынга калдырып китеп барырга мин дурак, что ли, дидем. Шул алачыкта зур хаҗәтемне башкардым да кайтып киттем. Кайткач Зәйнәпне бераз тәпәләдем дә йокларга яттым.

Фәндәс. Что-то бөтенләй туңдыра башлады. *(Барып тунын кия.)*

Рәшит. Җил каршы. Шуңа кинәт суытты.

Фәндәс *(катгый караш белән)*. Мин барыйм!

Рәшит. Кая?

Фәндәс. Алачыкка.

Рәшит. Йөрмә. Караңгы анда. Йә противопожарный инвентарь урларга йөри дип милиция алып китәр үзеңне.

Фәндәс. Үлмиммени?

Рәшит. Нинди үлү! Тем более халык санын алгач. Аны асылынасы булсаң переписька кадәр тәвәккәлләргә идең. Хәзер бит инде сине санга сугып чутладылар. Фәлән миллионның берсе бит син.

Фәндәс. Әйе шул. Әйдә алайса тотып куйыйк берәрне. *(Эчәләр.)*

Рәшит. Инде бик үләсең килсә... *(Стенага сөяп куелган мылтыгына ишарәләп.)* Әйдә, үзем атып үтерәм.

Фәндәс. Юк, юк, минем аркада төрмәгә утыртып куярлар үзеңне. Пычранма минем белән.

Рәшит. Шаярам гына ла мин, Фәндәс туган. Синнән якын кешем юк минем хәзер. Әйдә тагын берәрне... *(Эчәләр.)* Дөресен әйткәндә, Зәйнәптән башка беркемгә күңел ятмый. Яратам икән мин аны. Чак кына аерылышып торабыз һәм шундук яратуымны аңлыйм. Кайвакыт җиңелчә генә кыйныйм да үзем шундук яратуыма тагын бер кат иманам. *(Калтыранып.)* Чынлап та, бүлмә нык салкынайды. *(Барып батареяны капшый.)* Не понял! Батареялар боз кебек салкын. Что такое?! Шәйхулла Галимулловичны депутат итеп шуның өчен сайладык что ли без?!

Шәйхи сантехник костюмыннан керә. Сакал-мыек ябыштырган. Аны танырлык түгел. Тавышын үзгәртеп сөйләшә.

Шәйхи. Якынлашып килүче Яңа ел белән сезне!

Фәндәс. Сезне дә шулай ук.

Рәшит. Син кем буласың? Кыш бабай дисәм, аның киеме мондый түгел инде...

Шәйхи. Мин сантехник. Обход ясарга куштылар.

Рәшит. Син миңа шуны әйт — нишләп батареялар салкын?

Шәйхи. Җылы булмаганга.

Рәшит. Син нәрсә аркылыга сөйләшәсең? Аяклы күсәк?!

Шәйхи. Үзең дә чамалап сөйләш... Әле яңа гына подвалдан мендем. Торба каткан.

Рәшит. Алайса, нишләп монда торасың син тәре баганасы сыман?! Бар подвалга, җылыт торбаны.

Шәйхи. Аны алай җайлы гына җылытып булмый шул.

Фәндәс. Хәзер нишлибез инде? Яңа ел алдыннан катып үләргә тиешме без?

Шәйхи. Барыр җирегез юкмыни бүтән?

Рәшит. Моргтан башка дисеңме? Син Шәйхулла Галимулловичны беләсеңме?

Шәйхи. Белмәскә! Беләм, бик яхшы беләм.

Рәшит. Хайван ул!

Шәйхи. Ыслушай... Син давай, теге... ни...

Фәндәс. Ачуланышмагыз инде... Гафу итегез, сантехник әфәнде, без барыбыз да хайваннар.

Шәйхи. Мин үзем хайван түгел. Ник әле син Шәйхулла Галимулловичны алай мыскыл итәсең?

Рәшит. Синең кебек дуңгызны сантехник итеп токкан өчен.

Фәндәс. Рәшит, алай сөйләшмә инде... Культурно сөйләш. Ул бит торбаны махсус катырмаган.

Шәйхи. Мин маңгаеңа менә шушы ачкыч белән берне тартырга да могу.

Рәшит. Нәрсә! *(Мылтыгын барып ала, Шәйхигә төби.)* Нишләп минем фатирда урамнан да салкынрак?

Шәйхи. Үзең каткан җан булганга күрә!

Фәндәс. Бигрәк тупас хәзерге заман сантехниклары. Рәшит, берүк ата күрмә. Лутчы теге алачыкка барып үзе асылынсын.

Шәйхи. Син мылтык белән шаярма, пажалысты.

Рәшит. Берничә сәгатьтән Яңа ел җитә, ә минем фатирда кыш. Бар, Шәйхигә әйт: әгәр дә минем өйгә Яңа елга кадәр җылылык кермәсә, бүгеннән алып аның гөнаһлы тәненә мәңге җылылык кермәячәк.

Фәндәс. Карале, сантехник туган, Рәшит башка фикер әйтмәкче була. Батарея җылылыгы турында түгел сүз, гомумән, тормыш, гаилә, хатыннар турында сүз катмакчы була ул... Аңлыйсыңмы? Синең башың аз гына булса да эшлиме соң?

Шәйхи. Сез нишләп мине гел мыскыл итәргә маташасыз! Үкенәчәксез бит!

Рәшит. Бар подвалга, торбаны өреп булса да җылыт, йонлы чырай! *(Мылтыгын төби.)*

Шәйхи *(чыгырыннан чыга).* Булды, җитте, туйдым мин сездән! *(Ябыштырылган сакал-мыекларын йолкып ташлый, паригын сала. Рәшит белән Фәндәс Шәйхине танып таң калалар.)* Зинһар, мине азат итегез үзегезнең матавыкларыгыздан!

Фәндәс. Шәйхулла Галимуллович! Сезмени бу?!

Рәшит. Ни фига себе! *(Мылтыктан өскә атып җибәрә. Кычкырып куялар. Түшәмнең уртасы ишелеп төшә һәм фатирга буран кар тутыра башлый.)*

Шәйхи. Тиле мәллә син! Нишләттең түшәмне?!

Фәндәс. Атмаска идең! Рәзве шулай ярый!

Шәйхи. Нишлибез хәзер?

Рәшит. Ишелсен, җимерелсен дөньясы! Мин монда, Зәйнәп тегендә... Шушы авыз врачы белән лях исереп Яңа елга кериммени мин?! Җимерелсен!

Тагын атмакчы була. Шәйхи белән Фәндәс аның өстенә ташланалар, мылтыгын каерып алалар.

Фәндәс. Тынычлан, Рәшит. *(Фәндәсне кочаклый.)*

Рәшит *(истерикага бирелә).* Фәндәс! Атып үтер мине!

Фәндәс. Юк, юк. Авылда чакта тавык та суя алмый идем мин.

Рәшит. Яшисем килми.

Фәндәс. Алай димә!

Рәшит *(елый).* Үлә-ә-әм!

Фәндәс. Юк, яшәргә кирәк, Рәшит туган!

Шәйхи *(мылтык күтәреп арлы-бирле йөри).* Харап итте түшәмне!

Бүлмәгә буран кар тутыра. Көчле музыка.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Саҗидәләр фатиры. Саҗидә белән Зәйнәп бераз коньяк эчкәннәр. Мәлҗерәеп, әкрен генә җыр сузалар.

Зәйнәп. Ни пычагыма безгә андый ирләр?!

Саҗидә. Мин дә шуны уйлап куйдым әле.

Зәйнәп. Алар шунда каршыласыннар Яңа елны, без монда!

Саҗидә. Кәнишне. Алар белән нервы бозып...

Зәйнәп. Бик матур утырабыз. Телевизордан Яңа ел программалары барадыр инде. Кабыз әле.

Саҗидә. Әйе шул.

Барып телевизорны кабыза. Телевизордан Шәйхи Яңа ел алды котлавы белән чыгыш ясый.

Шәйхи *(телевизордан).* Бер-ике сәгатьтән кешелек дөньясы Яңа елга керә. Кешелек дөньясы кергәч, без дә читтә кала алмыйбыз, без дә керәбез. Гадәттә, Яңа елны иң якын, иң кадерле кешеләр белән каршылыйлар. Шулай булгач, тагын бер кат бер-берегезнең күзләренә карагыз, иске елда әйтелгән авыр сүзләр өчен гафу үтенегез. Яңа елда барыгызга да саулык-сәламәтлек, иминлек, гаилә бәхете телим. Үпкә-нәфрәтләр, аңлашмаулар иске елда калсын. Бу елдагы матавыклар шушы елда төшеп калсын. Мәрхүм Тәлгать Бариевич әйтмешли, алай инде бик кирәк булса, араларны киләсе елда тагын бозып була.

Ишек кыңгыравы зеңгелди. Саҗидә ишекне ача. Йончыган кыяфәт белән Шәйхи килеп керә.

Зәйнәп. Ә без сезнең котлауны телевизордан тыңлап утырабыз.

Шәйхи *(телевизордан сөйләвен дәвам итә).* Рөхсәт итегез сезне тагын бер тапкыр якынлашып килүче Яңа ел белән котларга. Яңа елда яңа бәхетләр сезгә! *(Баян уйный. Шәйхи баянга кушылып җырлый.)*

Саҗидә. Ну, нәрсә?

Шәйхи. Сүндерегез әле телевизорны! *(Үзе барып сүндерә. Ишекне ачып кычкыра.)* Керегез!

Бусагада Рәшит белән Фәндәс пәйда булалар.

Саҗидә. Зәйнәп, болар кирәкме безгә?

Зәйнәп. Юк. Алардан башка да бик рәхәт иде.

Рәшит *(өзгәләнеп)*. Өй җимерелде безнең.

Шәйхи *(тынычландырырга ашыга)*. Мин фатир эшлим сезгә. Әлегә монда яшәп торыгыз.

Фәндәс *(сабыйларча елмаеп)*. Саҗидә, мин кайттым.

Саҗидә *(Шәйхигә)*. Нишләп аяк киемеңне салмыйча түргә уздың?

Шәйхи. Гафу ит.

Ишек катына бара. Өч ир шунда кукраеп басып торалар.

Фәндәс. Саҗидә, Шәйхулла Галимуллович бит ул.

Саҗидә. Булсын! Миңа барыбер! Зәйнәп, ну-ка булыш миңа! *(Ирләргә кычкыра.)* Чыгып китегез барыгыз да!

Зәйнәп. Вон отсюда все!

Ирләр каушап торганда, ике хатын аларны этеп-төртеп чыгаралар һәм ишекне бикләп куялар. Ирләр ишекне дөбердәтәләр. Хатыннарны юмалап та карыйлар, куркытмакчы да булалар.

Шәйхи *(тыштан)*. Саҗидә, Зәйнәп! Яңа ел җитә. Минем киемнәрем сездә бит. Сантехник киеме белән өйгә кайтып булмый бит инде.

Зәйнәп. Саҗидә, катлауландырмыйк. Хәзер киреләнәбез дә, аннары үкенәчәкбез...

Саҗидә. Тиз генә бирешәсе килми бит, зараза...

Зәйнәп. Минем бирешәсем килә инде. Арыдым. Сагындым Рәшитне.

Саҗидә. Шәйхулла Галимуллович, теге европейский бланкларны ертып ташла башта, аннары безгә күрсәт. Кеше көлкесенә калдырып йөрмә безне.

Шәйхи. Шунда, минем портфельдә бит алар. Ачыгыз инде ишекне.

Фәндәс. Саҗидә, җаным! Ач!

Саҗидә. Яратасыңмы мине?

Фәндәс. Кемнән сорыйсың?

Саҗидә. Синнән, тинтәк.

Фәндәс. Яратам!

Саҗидә Ышанасыңмы миңа?

Фәндәс. Үземә караганда да ныграк ышанам.

Рәшит. Зәйнәп, мин сине сагындым.

Зәйнәп. Ышанасыңмы миңа.

Рәшит. Фәндәс Саҗидәгә ышанганга караганда да ныграк ышанам. Ачыгыз, катып үләбез бит инде.

Ишекне ачалар. Ирләр кереп батареяга елышалар, дер-дер калтырыйлар. Шәйхи өс киемен алмаштыра.

Шәйхи *(портфеленнән бланклар алып ертып ташлый).* Менә, менә! Теләсә нишләгез!

Бланкларны ерткач, барысы да тып-тын калалар, хәтта кымшанырга да куркалар. Өске каттагы фатирдан скрипка тавышы ишетелә. Моңлы музыка.

Фәндәс *(өскә ымлап)*. Прокурор уйный...

Рәшит. Берүк сезнең түшәм җимерелә күрмәсен.

Фәндәс *(җанланып)*. Булды. Хәзер һәркем үзенең законный хатыны белән яши башлый, шулаймы?

Шәйхи. Давно пора!

Зәйнәп. Минем сезгә бер соравым бар... Хатыныгыз белән тәмам кушылсагыз, Тәлгать Бариевичның кызын нишләтәсез инде? Ташлыйсызмы?

Шәйхи. Бик яшь ул. Мин аны барыбер ташламыйм... Тәлгать Бариевич кызы бит ул... Иң мөһиме — мин үземнең хатынымны сагындым. Ярый, киттем мин.

Рәшит. Юк, юк. Яңа ел хөрмәтенә берәрне тотып куйыйк.

Фәндәс. Саҗидә, тиз генә табынны рәтлә. Әйдәгез, Шәйхулла Галимулловичның гаиләсе төзекләнү хөрмәтенә тост...

Табын янына киләләр.

Шәйхи *(рюмкасын күтәреп.)* Җәмәгать! Рәшит... Зәйнәп... түшәмегез ишелде дип кайгыга батмагыз. Баш исән булсын. Дөрес, кайгырмыйча да булмый... Мәрхүм Тәлгать Бариевич әйтмешли, үлгән кеше генә кайгырмый. Фатир мәсьәләсен Яңа ел башында хәл итәрмен.

Саҗидә. Әлегә бездә яшәп торырлар.

Фәндәс. Бергә-бергә күңелле булыр.

Шәйхи. Сезнең бергә чакта гел күңелле килеп чыга. Шуңа күрә тагын бер тапкыр якынлашып килүче Яңа ел белән барыгызны да!

Эчеп куялар. Музыка. Барысы да җырлыйлар.

Сагыш белән шатлык бүлмә тулы,
Сихри моңнан үзәк өзелә.
Чуар еллар төймә-төймә булып
Гомер дисбесенә тезелә.

Күз карашы оча киләчәккә,
Хыяллар да инде өр-яңа.
Бу тикмәгә түгел: Яңа елда
Җиргә яңа ап-ак кар ява.

Мизгелләрнең яктыларын сакла
Гомереңнең һәрбер елыннан.
Атлый дөнья пакь өметләр белән
Яңа елның ап-ак юлыннан.

Рәшит. Яңа ел белән!

Зәйнәп. Яңа ел белән!

Фәндәс. Яңа шатлыклар, яңа матавыклар белән!

Сажидә. Яңа елда күрәчәкләр белән!

Шәйхи. Шулай да Яңа ел шатлыкларны күбрәк китерсен! Киттем мин. Хатыннан яхшы түгел.

Чыгып китә. Сәгать уникене суга. Тәрәзә артында фейерверклар балкый. Музыка. Барысы да ура кычкыралар, бокал күтәрәләр. Буран уйный башлый. Буран көенә Фәндәс Сажидә белән, Рәшит Зәйнәп белән парлап вальс бииләр.

Тәмам.

*2002*

# КИТӘМ ИНДЕ, КИТӘМ!

*(Ике пәрдәле драма)*

КАТНАШАЛАР:

Ильяс — биюче, 30 яшьтә.
Наил — шофер, 25 яшьтә, эре сөякле, таза ир-егет.
Рәзинә — Наилнең хатыны, 21 яшьтә.
Роберт — философия фәнен укытучы, 50 яшьтә, чандыр гәүдәле,
коры сөякле.
Гүзәлия — Робертның хатыны, китапханә хезмәткәре, 35 яшьтә.
Альберт — продюсер, 30 — 35 яшьләрдә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Берничә гаилә яши торган малосемейка фатирының коридоры. Берничә бүлмә ишеге, кухня һәм бәдрәфкә керә торган урын күренә. Коридор аркылы бау сузылган һәм нәкъ уртада алагаем олы брезент чалбар эленеп тора. Ыгы-зыгы. Рәзинә кухня плитәсе янында мәш килә. Роберт үзләренең бүлмәсеннән чыга һәм баудагы чалбар астыннан иелеп үтәргә мәҗбүр була.

Роберт *(коридордан үтеп барышлый).* Минем сезгә бер үтенечем бар — бу чалбарны монда элмәсәгез иде.

Рәзинә *(иреннәрен турсайтып).* Ә кая элим соң мин аны?

Роберт. Ичмаса, әнә тегендәрәк. Мондый киемне үз бүлмәгездә киптерсәгез дә ярар иде.

Рәзинә *(еламсырап кычкыра).* Наил! Наил, дим!

Наил атылып килеп чыга. Өстендә майка, трико чалбар.

Наил *(әле хатынына, әле күршесенә карап).* Нәрсә? Нәрсә булды?

Рәзинә *(үпкәле тавыш белән).* Чалбарыңны монда элгәнгә ачулана.

Наил *(баудагы чалбарга карап тора).* Ник, ни булган чалбарга! Кемгә кагыла ул? *(Робертка.)* Нишләгән минем чалбар?

Роберт *(бераз каушап).* Бернишләмәгән. Мин ачуланмадым, фәкать үз теләгемне генә белдердем.

Наил *(кыҗрап).* Ник гел безгә бәйләнәсең син, ә?! Әле ботинкамның ишек катында ятуын ошатмыйсың, әле бәдрәфтә озак утырасың дип йөдәтәсең, йә булмаса баудагы керләребезгә бәйләнәсең!

Роберт *(читкә борылып)*. Уф, ник әйттем.

Наил. Вәт шул шул! Әйтмә, ник әйтәсең! Беләсең килсә, минем хатын йөкле, аңа дулкынланырга ярамый. Дөрес әйтәләр икән интеллигент белән күрше булма дип!

Роберт. Ярар, ярар, тора салып минем зыялылыгыма тел-теш тигезмәгез инде! Туйган инде сезнең киемегезне иснәп йөреп.

Наил. Син минем чалбарымнан туйсаң, мин синең үзеңнән менә болай гарык булдым!

Гүзәлия чыга.

Гүзәлия *(борчулы кыяфәт белән)*. Ник шаулашасыз, ни булды?

Наил. Әнә мужигыңа минем чалбарым ошамый.

Роберт *(матавык башланганга нык борчылып)*. Нишләп шулай пырдымсыз сөйләшәсез сез, культурасыз?!

Наил. Чөнки син вакчыл, беҗек кеше, синең белән башкача сөйләшеп булмый. *(Рәзинәгә.)* Ал чалбарны! Чукынып китсеннәр!

Рәзинә. Ярар. *(Җәһәт кенә чалбарны баудан ала.)*

Гүзәлия *(өзгәләнеп)*. Ярарыгыз инде, юк кына нәрсә аркасында шау-шу куптармагыз, болай да баш авыртып тора.

Наил *(тынычлана төшеп)*. Баш, баш... Минем хатын әнә, корсаклы, аңа борчылырга ярамый. Ә бу — чалбар, чалбар!

Гүзәлия *(уртадагы бүлмә ишегенә ишарәләп)*. Менә бу бүлмә кайчаннан бирле буш тора, шуның ачкычын комендантттан алып, киемнәр киптерә торган бүлмә ясарга иде дә бит.

Рәзинә. Ул бүлмәгә яшәргә кеше кертми калмаслар, шуңа күрә сезгә ачкыч кем бирсен!

Наил *(кырт кисеп)*. Ул бүлмә безнеке булырга тиеш!

Роберт. Нишләп сезгә?

Наил. Чөнки минем хатын авырлы, минем гаиләм ишәергә тора.

Роберт *(Наилгә таба атлап)*. Ә мин инде иллегә җитеп киләм, безгә тиеш ул бүлмә!

Наил *(авызын кыйшайтып)*. Минем белән килделе-киттеле сөйләшсәң, син иллегә барып җиталмаячаксың!

Роберт. Хам!

Гүзәлия. Ярар инде, Роберт, күрмисеңмени, бу кеше белән сөйләшүдә мәгънә юк.

Рәзинә. Тынычлан инде, Наил, син дә. *(Кулындагы чалбарны тоткан килеш.)* Батареяга куеп киптерермен.

Роберт *(кул селтәп бүлмәсенә таба китә)*. Ярар, кире урынына элеп куегыз, тик шаулашмагыз гына.

Рәзинә *(үпкәле тавыш белән)*. Йә ал, йә эл. *(Чалбарны янә элеп куя.)*

Гүзәлия *(канәгатьсезлек белән чалбарга карап тора)*. Юк инде, чынлап та, йөрергә комачаулый бит, аны тегендәрәк эләргә дә мөмкин түгелме?!

Наил *(кинәт ярсып)*. Шулаймы! Менә алайса!

Чалбарны баудан йолкып алып, бер балагына аягы белән баса да урталай ерта.

Рәзинә *(йөзенә газап чыга)*. Аһ! Харап итте өр-яңа чалбарны!

Наил *(акырып)*. Мәгез, теләсә кая элегез!

Чалбарның бер яртысын бер якка, икенчесен икенче якка ыргыта.

Гүзәлия *(курка-курка гына Наилгә таба атлый)*. Тынычлан инде, Наил, тынычлан!

Роберт *(күршесенең ярсуыннан котсыз калып)*. Наил, гафу ит инде, бу кадәре тәэсир итәр дип уйламаган идем.

Рәзинә *(елый)*. Наи-и-ил.

Наил *(урындыкка утырып башын куллары белән кыса)*. Якын килмәгез! *(Еш-еш сулый.)*

Рәзинә *(барып чалбарның ике яртысын да ала, әйләндергәләп карый)*. Бүген үк тегеп куям, җөеннән генә ертылган. Наил, ишетәсеңме, хәзер үк тегеп куям... Җөйдән генә киткән. *(Бүлмәләренә кереп китә.)*

Гүзәлия *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Наил, болай ук ярсыма инде, без бит сиңа бернинди ачусызнисез...

Наил *(читкә карап)*. Ярар, ярар.

Роберт *(елмаерга тырышып)*. Моннан соң теләсә нәрсәңне эл шул урынга, без риза...

Наил *(башын чайкап ыңгыраша)*. Саруымны кайнатмагы-ы-ыз.

Роберт *(нәрсәнедер исенә төшергәндәй талпынып куя)*. Хәзер! *(Тиз генә үз бүлмәләренә кереп китә.)*

Рәзинә чыга.

Рәзинә *(ире янына килеп баса)*. Наил, ботка ашыйсыңмы?
Наил *(усал тавыш белән)*. Ашыйм.
Рәзинә *(савытка ботка сала).* Маен күп салыйммы?
Наил *(тавышында кырыслыкны саклап).* Сал.

Роберт үзләренең бүлмәсеннән чалбар тотып килеп чыга.

Роберт *(Наил янына йөгереп килеп чалбарны суза).* Күрше, мәгез, сезгә бер өр-яңа чалбарымны бүләк итәм. *(Ялагай тавыш белән.)* Мине кичереп, шуны кабул итегез, зинһар!
Наил *(авызына ботка капкан килеш аптырап карап тора).* Нәрсә?!
Рәзинә *(көлеп җибәрә).* Сиңа үзенең чалбарын бирә...
Гүзәлия *(елмаеп).* Алыгыз, алыгыз.
Наил *(түзеп торалмый, капкан боткасы белән тончыга-тончыга көләргә тотына).* Миңа... синең чалбарың... Мин бит... илле алтынчы размер киям... ә син — кырык алтынчыны.

Барысы да рәхәтләнеп көләргә тотыналар. Озак көләләр.

Роберт *(уңайсызланып).* Сезнең әрәм булган чалбарыгыз өчен... Мин... гафу үтенеп... *(Үзе дә башкаларга кушылып кеткелдәп көлә башлый.)*
Гүзәлия *(атмосфера үзгәргәнгә чиксез куанып)*. Роберт, әйдә, без дә чәй эчик. *(Табын әзерли башлый.)* Аннары базарга чыгып керербез.
Роберт *(өстәл янына утырып).* Үзең генә барып килерсең инде, минем язасым бар.
Наил *(ботка ашый-ашый)*. Безгә дә һава сулап керергә кирәк булыр.
Рәзинә *(иренең кәефе яхшы якка үзгәрүдән кинәт канатланып)*. Хуҗалык товарлары кибетенә барып килербез. Обой клее кирәк.
Гүзәлия *(сагаеп).* Ә нигә сезгә обой клее?
Рәзинә. Кирәк.
Роберт *(борчулы кыяфәт белән).* Обой клее обой ябыштырырга кирәк инде ул... Ни... Әллә обой ябыштырасыгыз бармы? *(Чынаягын саклык белән өстәлгә куеп катып кала.)*
Наил *(күз кырые белән генә карап)*. Тынычланыгыз, зинһар. Бүлмәбездә обой купты, шуны ябыштырасыбыз бар.
Гүзәлия *(шатланып)*. Ә-ә-ә, алай икән.
Наил *(Рәзинәгә)*. Болар бит менә бу буш бүлмәне дә үзебезгә алырга маташабыз дип курыктылар. Ха-ха-ха...
Роберт *(җитдилек белән)*. Көлмәгез, Наил, бер дә көлке түгел. Мин егерме биш ел техникумда философия укытам, миңа яшәргә уңайрак шартлар кирәк. Әгәр дә киләсе атна эчендә бу бүлмәгә урнашучы булмаса, эшемнән Ходатайство алып, аны үземнеке итәчәкмен.
Наил *(көлемсерәп)*. Юк, булдыра алмаячаксың. Дүшәмбе көнне үк гинекологтан хатынымның йөкле икәнлеге хакында справка юнәтеп, ЖЭКтан бу бүлмәне алам, менә әйткәнне диярсең!
Роберт *(кульяулыгы белән авыз кырыйларын сөрткәләп)*. Ярар алайса, судлашачакбыз.
Наил *(нәфрәтле кыяфәт белән)*. Мин синең белән судлашып тормаячакмын, монтировка белән чигәңә бер генә бирәм, һәм дә ки Министерство просвещения фатир сораучы бер философтан шатланып котылачак.
Роберт *(сикереп тора).* Ничек шушы затсыз, мәнсез хайван янында ашап-эчеп утырмак кирәк!
Гүзәлия *(иренең беләгенә тотынып)*. Тынычлан! Сез нәрсә инде, Наил, аз гына булса да олы яшьтәге кешегә карата үзегезне итагатьлерәк тотарга кирәк.
Наил *(шопырдатып чәй эчә).* Үзе башлады.
Роберт *(ярсып)*. Оятсыз!
Наил *(тыныч кына).* Кычкырма, хатыным авырлы, аңа тавыш ярамый, бигрәк тә синең әче тавышың. *(Чәй эчә.)*
Рәзинә *(ялварулы тавыш белән)*. Наил, җитәр инде.
Гүзәлия *(корылык белән)*. Дөресен әйткәндә, бу бүлмә безгә булырга тиеш.
Рәзинә *(гаҗәпләнеп)*. Сез бит икәү генә. Ә без тиздән өчәү булачакбыз.
Роберт *(тавышын көрәйтеп)*. Суд хәл итәр!

Шул вакытны Альберт килеп керә. Затлы костюмнан, урта бармагында алагаем зур алтын йөзек. Кыяфәте, килеш-килбәте, үзен тотышы бай һәм үз-үзенә ышанучы кеше икәнлеген искәртеп тора. Барысы да тынып калалар. Альберт, беркемгә игътибар итмичә, буш бүлмәгә ачкыч ярата башлый.

Роберт *(коридор почмагыннан)*. Гафу итегез, сез кем буласыз?

Альберт *(ачкычларының әле берсен, әле икенчесен йозак тишегенә тыгып кыштыр-кыштыр китерә)*. Кемгә охшаганмын соң?

Наил *(аңа таба атлап)*. Әллә безнең яңа күршебезме?

Альберт *(Наилгә карап ала)*. Мин шушындый эт оясында яшәрдәй кешегә охшаганмынмыни?

Роберт. Андыйга охшамаганга күрә сорыйбыз да инде без.

Альберт *(Наилгә карап)*. Синең булачак күршеңә охшаганмынмы?

Наил *(усалланып)*. Син бандитка охшагансың. Нишләп йөрисең монда?

Альберт *(елмаеп)*. Кызма, җүләр. Ә-ә-ә, менә, таптым ачкычны. *(Бүлмә ишеген ачып кереп китә.)*

Рәзинә *(куркып)*. Кем бу?

Гүзәлия *(котсыз калып)*. Безнең булачак күршебезгә охшаган.

Наил *(иснәнеп)*. Шушындый тәмле исле әдикалун сипкән кеше мондый бүлмәгә урнашмас.

Роберт. Ачкычы кулында бит.

Наил. Коммерсант булса, шушы бүлмәне склад урынына да тотуы ихтимал. Мафиозник бу. Монда притон урнаштыруы да мөмкин.

Гүзәлия. Аллам сакласын.

Рәзинә. Һәрхәлдә, иманлы кешегә охшамаган инде.

Роберт *(барысын да тынычландырырга ниятләп)*. Таныш түгел кешегә алдан ук бәя биреп куймагыз әле.

Наил. Карак-мазар түгелдер бит?

Гүзәлия. Карак шаһитлар күреп торганда керми инде ул.

Рәзинә. Ышан хәзерге каракларга.

Гүзәлия. Менә бүлмә өчен талашып утыра идегез. Ниһаять, хуҗасы да барлыкка килде.

Наил. Ашыкмагыз, әүвәле монyң кем икәнлеген ачыкларга кирәк.

Роберт *(пышылдап)*. Барыгыз, Наил, сез бит бик батыр кеше, кереп танышыгыз, белешегез — кем ул, нишләп йөри монда, нинди уй-ниятләре бар?

Наил *(шүрләп)*. Үзе чыгар әле.

Рәзинә. Кем икән бу?

Гүзәлия. Аның белән сөйләшкәндә үзегезне кырысрак тотыгыз, кем икәнлеген ачыклаганчы.

Шактый вакыт көтәләр. Ниһаять, Альберт чыга. Барысы да тынып калалар.

Альберт *(коридор буйлап атлый)*. Таракан бармы?

Наил *(горур кыяфәт белән)*. А как же! Аллага шөкер. Малосемейкада ни булырга тиеш, шуның барысы да бар.

Альберт *(стеналарга, түшәмгә күз ташлап)*. Кандала да бармы әллә?

Роберт *(ирония белән)*. Юк, кызганычка каршы, анысы юк.

Альберт. Үзең бөтен нәрсә бар дисең. *(Бәдрәф ишеген ачып карый, чыраен сыта.)* Бәдрәф шушымы?

Наил *(мыскыллы тавыш белән)*. Юк, библиотека.

Альберт *(кыяфәтенә усаллык чыгарып)*. Мин синең белән шаярып сөйләшмим бит.

Наил. Ник, күрмисеңмени бәдрәф икәнен? Сорап тормасаң!

Роберт *(җылы тавыш белән)*. Гафу итегез, сез кем буласыз соң?

Альберт. Альберт.

Роберт. Эш урыныгыз кайда инде?

Альберт. Бөтен җирдә. Альберт мин, Альберт.

Наил *(һаман да кырыс булырга тырышып)*. Альберт дигән сүз әле бернинди ачыклык кертми. Безнең гаражда гына да алты Альберт бар.

Альберт. Анда минем шикеллесе юктыр бит?

Наил *(җитди итеп)*. Юк, мондые юк.

Альберт *(коридор буйлап арлы-бирле йөри)*. Син бик батыр егеткә охшагансың.

Рәзинә ирен арттан чеметә. Альберт моны абайлап ала.

Во-во, хатының үзеңә караганда акыллырак булып чыкты. Авызыңны чамалап ач. Кайсы авылдан син?

Наил. Каенлыдан.

Альберт. Бик әйбәт. Мин, җәмәгать, бүлмәне карарга килдем. Монда минем бер кешем урнашачак. Болай карап торуга яшәрлек бүлмә бугай... Вакытлыча, әлбәттә. Алга таба күз күрер. *(Наилгә якын килеп.)* Бөтен нәрсә вакытлыча бу дөньяда. Шулаймы, Каенлы җүләре?

Наил *(батыраерга тырышып)*. Син, давай, бик нитмә әле...

Рәзинә *(пышылдап)*. Каршы әйтмә инде.

Альберт. Вот, вот, тый син аны.

Роберт *(ялагайрак тавыш белән)*. Монда урнашасы кешегез дә бөтен җирдә эшлиме?

Альберт *(үтә җитди кыяфәт белән)*. Ул бик талантлы кеше.

Роберт. Нинди өлкәдә?

Альберт *(кулын өскә күтәреп)*. Ул — биюче.

Наил. Ә эш урыны кайда?

Альберт. Ул — биюче, профессиональ биюче, аңладыңмы? Аңлатыгыз әле шул Каенлы дебилына.

Наил *(кыҗрап)*. Но-но... Син бик нитмә...

Рәзинә *(иренең җиңеннән тартып)*. Тик кенә тор инде.

Роберт *(сөенеп)*. Димәк, биюче... Яхшы, бик яхшы.

Гүзәлия *(шатлык белән)*. Бик әйбәт, күршебез биюче булачак икән. Күңелле булыр.

Наил *(борчылып)*. Нәрсәсе күңелле булыр? Дөбердәп теңкәгә тиячәк. Минем хатын авырлы, аңа тавыш ярамый.

Рәзинә *(уйга калып)*. Чыннан да, ул монда репетиция ясап тузан куптарыр бит.

Альберт. Ха-ха-ха, вәт проблема, ә! Тузан куптарыр, ха-ха-ха. *(Кинәт җитдиләнә.)* Туктагыз әле, ә сез нишләп эштә түгел?

Роберт *(ашыгып җавап бирә)*. Бүген якшәмбе бит.

Гүзәлия *(елмаеп)*. Ә мин сәгать унга барам эшкә.

Альберт. Кая?

Гүзәлия. Китапханәгә.

Альберт. Аңлашылды. *(Бәдрәфкә күрсәтеп)*. Шушы бит сезнең китапханә...

Гүзәлия *(үпкәләп)*. Юк, мин чын библиотекада эшлим, чын китапханәче булып.

Альберт. Аңлашылды. *(Кинәт көлеп җибәрә.)* Вәт проблема! Тузан куптарыр, ха-ха-ха! *(Көлә-көлә чыгып китә.)*

Наил. Ышанмыйм мин бу кешегә.

Роберт *(битараф тавыш белән)*. Яшәеш өчен синең ышануың белән ышанмавың арасында аерма юк.

Рәзинә *(уйланып)*. Биючеләр бик шук булалар инде алар.

Роберт *(үзалдына)*. Синең Наилең шикелле үк түгелдер әле.

Гүзәлия. Бәлки, кеше буларак яхшыдыр ул.

Роберт. Ярар, фаразлар кылып тормагыз. Кеше буларак... ни буларак... Биюче буларак та, бәлки, начар түгелдер.

Таралышалар.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Икенче көн. Шул ук урын. Йокыдан торып арлы-бирле йөриләр. Кем бәдрәфкә керә, кем газ плитәсе тирәсендә бөтерелә, кем физзарядка ясый.

Гүзәлия *(кухня өстәлен сөрткәләп)*. Төнлә дөбер-шатыр килделәр, әллә биюче килеп тә җиткәнме?

Рәзинә *(тас күтәреп үтеп китә)*. Грузчиклары иде, ахрысы. *(Тасны шалтыратып ванна бүлмәсенә кертеп ташлый.)*

Наил *(ишек катында тәмәке тарта)*. Аңа диван, урындыклар, шкафлар алып килделәр. Тәмәке тартырга торган вакытым иде. Әлегә үзе күренмәде.

Роберт *(кулларын як-якка җәеп зарядка ясый)*. Әйбере күпме?

Наил. Ул бүлмәгә ничек күп әйбер керсен инде. Диван, бер шкаф, ике урындык иде бугай.

Гүзәлия. Әйбер ташучыларның берсе шул булгандыр мөгаен.

Наил. Юк, алар исерекләр иде. Шутниклар! Кайсыгыз биюче дип сораганием, юк, без җырчылар, дип җавап бирделәр.

Ильяс килеп керә. Спорт сумкасы күтәргән, джинсы костюм, кроссовка кигән.

Ильяс *(якты елмаеп)*. Исәнмесез!

Барысы да тып-тын калалар, Ильясны җентекләп күзәтәләр.

Гүзәлия. Исәнмесез!

Роберт. Исәнмесез!

Наил. Сәлам!

Ильяс. Сез барыгыз да шушында яшисезме әллә?

Роберт. Кызганычка каршы, барыбыз да монда торабыз.

Наил *(Ильяска таба килә)*. Ә барыбыз да шушында яшәсәк нәрсә?

Ильяс *(җитдиләнеп)*. Юк, болай гына... Кызык бит.

Наил. Нәрсәсе кызык инде аның?

Ильяс *(бераз аптырап)*. Мин әллә берәр ярамаган сүз әйтеп ташладыммы?

Гүзәлия. Юк, юк, борчылмагыз.

Роберт *(ягымлы итеп)*. Яңа кешедән бераз шикләнү бар бит инде ул.

Ильяс. Алай икән. Шушымы минем бүлмә?

Роберт. Әйе.

Ильяс. Ярар, мин кереп урнашыйм әле. *(Бүлмәне ачкычы белән ачып кереп китә.)*

Рәзинә *(борчылып)*. Бер дә биючегә охшамаган бит бу.

Гүзәлия. Охшаган, охшаган.

Наил *(авызын кыйшайтып)*. Биючелеге шулкадәрле генәдер инде. Шәп биюче булса, бу таракан оясына килеп кермәс иде.

Роберт. Анысы инде кайвакыт кешенең үзеннән тормый. Иле шундый булгач... Әллә нинди затлы кешеләр мескен хәлдә бүген.

Наил. Мәсәлән, сез.

Роберт *(нәфрәтләнеп)*. Ичмаса, иртүк төрттереп сөйләшмәгез. Гаражыгызга баргач пырдымсызланырсыз. Мин бит сезгә караганда да телгә остарак, ләкин әдәпле сөйләшергә тырышам.

Гүзәлия. Әйе, иртә таңнан әйткәләшә башламагыз әле.

Ильяс чыга. Җиңел спорт киеменнән.

Ильяс. Әйдәгез танышыйк. Мин — Ильяс.

Роберт *(кул биреп)*. Роберт абыең булам. Бу минем җәмәгатем — Гүзәлия ханым.

Ильяс *(Наилгә кул биреп)*. Ильяс.

Наил *(теләр-теләмәс кенә кулын суза)*. Наил.

Ильяс *(Рәзинәгә)*. Ә сез?

Наил. Ә бу минем хатыным — Рәзинә, аңа дулкынланырга ярамый, ул йөкле.

Роберт. Сез чынлап та биючеме?

Ильяс. Әйе.

Наил. Кем булып эшлисең соң син?

Ильяс *(көлеп)*. Биюче.

Наил. Аңламадым. Әллә син мине аңламадыңмы... Безнең гаражда бөтенесе бии... эчкәч. Ләкин аларның кайсы шофер, кайсы слесарь, кайсы сварщик...

Ильяс. Мин сварщик түгел, мин — биюче.

Наил. Йә, биеп күрсәт.

Ильяс *(тантаналы тавыш белән)*. Танышуыбыз хөрмәтенә рәхәтләнеп бер бию башкарам!

Музыка. Бию. Барысы да таң калалар. Ильяс күршеләрне биюгә чакырып карый, ләкин барысы да тартыналар һәм биючедән читкәрәк качалар. Наил генә, үзенең кыю икәнлеген тагын бер кат исбатлар өчен, Ильяс каршына чыгып, сәер һәм кәмит хәрәкәтләр белән пыр тузып биеп ала. Наил хәлдән таеп урындыкка утыргач та әле Ильяс үзенең биюен шактый вакыт дәвам итә.

Ильяс *(биюдән туктый, еш-еш сулый)*. Менә шулай...

Роберт *(чын күңелдән сокланып)*. Шәп! Карап торуга болай ук хәтәр бии торган кеше дип уйламассың үзегезне.

Ильяс *(көлә)*. Шулаймы?

Гүзәлия. Браво! *(Кул чаба.)*

Рәзинә *(таң калып авызын ачып тора)*. Әлә-лә-лә-лә.

Наил *(хатынына)*. Яп авызыңны, тинтәк!

Роберт *(кабалана башлый)*. Ярый, кич белән очрашырбыз, мин эшкә киттем. Техникум буфетында капкалармын инде.

Наил *(Ильяска)*. Син хәзер нишлисең соң?

Ильяс. Ник алай сорыйсыз?

Наил. Без менә эшкә китәбез, ә син нишлисең?

Ильяс. Минем бүген беркая да барасым юк, ял итәрмен, бераз йоклап алырмын, китап укырмын. Берүзем каламмыни хәзер монда?

Гүзәлия. Юк, минем ял көнем. Рәзинә дә отпускыда. Без өйдә.

Наил *(Робертны читкә алып китә)*. Хатыннарыбыз янында бу дәртле күркәне калдырырга курыкмыйсыңмы?

Роберт. Наил, сез нәрсә инде, әллә нинди уйлар белән башыгызны кайнатмагыз. Нишләп сез гел кара уй-фикерләр белән йөрисез?! Күрмисезмени аның нинди якты кеше икәнлеген?!

Наил. Беләм мин ул яктыларны!

Роберт. Ярый, кич белән очрашуга кадәр.

Гүзәлия. Роберт, сәгать ничәдә кайтасың бүген?

Роберт. Гадәттәгечә. *(Чыгып китә.)*

Наил *(таләпчән тавыш белән)*. Минем хатын авырлы... Аңа дулкынлану, дөбердәү, тавыш, тузан ярамый. Аңладыңмы?

Ильяс. Аңладым. Ничәдә кайтасыз?

Наил. Вакытында кайтырмын. *(Сагаеп.)* Минем ничәдә кайтуым нигә сиңа?

Ильяс. Кич утырып, якыннанрак танышырбыз. Шуңа сорадым.

Наил. Ә-ә-ә, алай дисәң генә... Киттем мин.

Рәзинә. Наил, кайтуыңа нәрсә пешерим?

Наил. Боткадан башка нәрсә пешерә аласың инде син?!

Рәзинә. Борчаклы аш.

Наил. Ботка пешер! *(Ильяска.)* Чалбарыңны бүлмә уртасына элмә, яратмыйм.

Рәзинә. Наил, ярар инде.

Наил. Ярар түгел. Аннары... ботинкаңны ишек катында калдырма.

Ильяс *(күңелсез елмаеп)*. Аңладым, тәртипле булырга тырышырмын.

Наил. Вот так! *(Чыгып китә.)*

Рәзинә *(еламсырап)*. Ичмаса, чит кешеләр янында ботка гына пешерә аласың димәсә ни булган!

Гүзәлия. Әйтсен. Яшь бит әле син, пешерергә беркем дә өйрәнеп тумый. Яши-яши өйрәнәсең аны.

Рәзинә *(Ильяска)*. Сез Наилнең дорфалыгына карамагыз. Ул бик әйбәт кеше, күңеле андый кырыс түгел аның. Үзен тота гына белми.

Ильяс. Ул миңа бик ошады. Әйбәт егет, бер дә аптырап тормый, турыдан бәрә.

Гүзәлия. Ашыйсыгыз киләме?

Ильяс. Бераз бар.

Гүзәлия. Әйдәгез, утырыгыз, менә коймак белән чәй эчәбез хәзер.

Рәзинә. Тары боткасы яратасызмы?

Ильяс. Яратам.

Рәзинә. Хәзер салып бирәм.

Ике хатын, Ильяс тирәсендә бөтерелеп, ашарга әзерлиләр.

Ильяс. Алайса, мин тиз генә бүлмәгә кереп чыгыйм әле. *(Бүлмәсеннән бер шешә затлы вино алып чыга һәм өстәлгә куя.)* Танышу хөрмәтенә — французский. Ночной клубта биегән өчен биргәннәр иде. Фужерлар бармы?

Гүзәлия. Бар. *(Шкафтан өч фужер алып өстәлгә куя.)*

Рәзинә. Юк, юк, мин эчмим, Наил белсә, бәреп үтерә!

Гүзәлия. Чыннан да, аңа ярамыйдыр. Йөкле бит.

Ильяс фужерларга вино сала, Гүзәлия белән чәкештереп эчәләр. Шуннан соң Ильяс ашарга тотына.

Рәзинә. Мин беренче тапкыр мондый биючене күрәм.

Гүзәлия. Минем дә якыннан беренче мәртәбә күрүем. Сез җыр һәм бию ансамбленнән түгелме?

Ильяс. Юк, мин ирекле биюче.

Рәзинә. Мондый талантлы кешеләр зур-зур фатирларда яшиләрдер дип уйлый идем мин.

Ильяс. Төрлесе бар. Затлы йортларда яшәүчеләре дә бар, минем кебекләре дә шактый... күбрәк булмаса.

Гүзәлия. Гаиләгез юкмы?

Ильяс *(караңгыланып)*. Бар иде. Аерылыштык. Бер бүлмәле фатирыбызны хатынга калдырдым да менә монда килеп эләктем.

Рәзинә. Балаларыгыз бармы?

Ильяс. Өч яшьлек кызым бар.

Рәзинә *(кызганулы тавыш белән)*. И-и-и, ник аерылдыгыз?

Ильяс. Аны болай гына аңлату мөмкин түгел. Әйдәгез, вино эчик.

Чәкештереп вино эчәләр.

Гүзәлия. Ә ата-анагыз исәннәрме?

Ильяс. Юк. Әнием мине тапканда үлгән. Әтигә илле яшь булган мин туганда. Моннан дүрт ел элек җирләдек. Әнием бит мине кырык яшендә тудырырга уйлаган, күз алдыгызга китерәсезме? Менә шундый хәлләр. Әти тагын өйләнеп торды. Үги әнием әтидән күпкә яшь иде, хәзер кайдадыр, белмим.

Гүзәлия. Шулай шул, әллә нинди язмышлар килеп чыга. Тормыш үзе кыйный инде ул... Шуны әйтмәкче булам... Сезнең перспективалар бардыр, мондый талант белән...

Ильяс. Перспективаларын белмим, шулай да планнарым юк түгел.

Рәзинә. Сезгә ничә яшь?

Ильяс. Утыз.

Рәзинә. Ә биергә кем өйрәтте?

Ильяс. Үзем өйрәндем.

Гүзәлия. Үзең белән бергә тумаса, кеше өйрәтеп кенә сәләтлеләнү мөмкин түгелдер инде ул. Әнә минем апамның кызын фортепианода өйрәтеп карадылар, вокал укытып маташтылар, аптырагач гитара алып бирделәр — берсен дә булдыра алмады, ни җырламый, ни уйнамый.

Ильяс *(урындыгында киерелеп)*. Бик тәмле булды. Рәхмәт. Менә тагын тамак туйды. Адәм баласына күп кирәк түгел, кәефләр күтәрелеп китте.

Рәзинә *(балаларча шатланып)*. Тагын биеп күрсәтегез әле.

Гүзәлия. Ашаганнан соң биюе авырдыр ул.

Ильяс. Дөрес әйтәсез. Гомумән, биюче ач тамакка биергә тиештер... Тәкъдиренә шулай язылгандыр, ачлы-туклы килеш биергә. Ә шулай да, сез сорагач, тамагым тук булуга карамастан, тагын биеп күрсәтәм.

Кыска гына бию.

Ильяс *(еш-еш сулый)*. Ничек?

Рәзинә *(кулларын чәбәкләп)*. Искиткеч!

Гүзәлия. Браво! Сезгә ешрак күренергә кирәк — телевизорданмы анда, киногa төшәргәме... Күбрәк тамашачыга чыгарга, киңрәк аудиториягә.

Ильяс. Кирәк нәрсә күп инде ул... Күрдем инде аудиторияләрен дә, тамашачыларын да... Аны кем белгән инде — нишләргә кирәклекне, нишләсәң яхшырак буласын...

Гүзәлия. Мин менә карап торам... Сез нииндидер боек кеше икән.

Ильяс. Ә сез, биюче булгач, ул клоун сыман гел көлеп, шаярып, шамакайланып торырга тиештер дип уйлагансыздыр, шулаймы?

Гүзәлия. Алай ук түгел дә инде... Барыбер талантлы кеше шат, горур, бәхетле булырга тиеш шикелле...

Ильяс. Ярый, мин ял итим әле, бу арада йокы эләкмәде.

Гүзәлия. Рәхмәт сезгә!

Ильяс. Үзегезгә рәхмәт! *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

Рәзинә. Матур бии, әйеме?

Гүзәлия *(нык дулкынлана)*. Матур бии, матур... Их, Рәзинә, йөрәгемне тыңлап карасаң иде, белсәң иде аның ничек типкәнен. Дөньяда әллә кемнәр бар. Әллә нинди кызык кешеләр килеп чыга. Син аның күзләрен күрдеңме соң?

Рәзинә. Әллә тагы.

Гүзәлия. Син аның күзләрендәге моңны абайламадыңмыни? Күңелем тынгысызлана, аның монда килүе юньлегә түгелдер.

Рәзинә *(читкә карап)*. Өстәмә бүлмәдән колак кактыгыз, шуңа күңелегез тынгысызлана.

Гүзәлия *(сөмсере коела)*. Рәзинә, сеңлем, моннан ары миңа бу сүзне катмагыз, зинһар! Дөресен әйткәндә, миңа өстәмә бүлмәләр бөтенләй кирәкми, миңа җан җылысы җитми, җан җылысы. Син бәхетле, синең тиздән балаң туачак, бөтен уй-кайгыларың шул нарасыйга бәйле булачак, сиңа шул тере хәзинәдән башка беркемнең һәм бернәрсәнең кирәге калмаячак. Мин синең киләчәгеңнән алдан ук көнләшеп торам, миңа андый бәхетләр насыйп булмады һәм инде булмас та. Сиңа ул биюче егетнең күзләрендәге сагышны күрү, уку кирәк түгел. Сиңа кеше күңеленең моң-зарлары нигә кирәк, бит сине алда шундый бәхет көтә! Аннары, син икеләтә бәхетле! Беләсеңме ни өчен?

Рәзинә. Ни өчен?

Гүзәлия. Син нечкә күңелле түгел, шуңа күрә. Тирән карый белмәгән кеше бәхетле ул.

Рәзинә *(иреннәрен турсайтып)*. Син мине кыерсытма инде, Гүзәлия апа.

Гүзәлия. Кыерсытмыйм ла инде, сеңлем, ничек бар — шуны әйтүем генә.

Рәзинә. Син минем йөкле булуыма, тиздән бала табачагыма ачу итеп, көнләшеп минем белән кырыс сөйләшәсең.

Гүзәлия *(хисләре ташуын көчкә тыеп)*. Алай түгел, Рәзинә. Дөрес, көнләшүем дә шактыйдыр. Тик мин сиңа әйтер сүземне аңлатып җиткерә алалмам, ахрысы. Гомер үтеп китеп бара, шунысы аяныч. Бер рәхәт күрмичә үтеп китә бит гомер. Әллә нәрсә көтеп, гел киләчәк тормыш турында хыялланып картайганыңны сизми дә каласың. Ачуланма, сеңлем, мин сине яратам. Әле генә әйткән авыр сүзләрем сиңа юнәлтелмәгән, алар минем үземнең күңелемдәге, эчке проблемаларның, җанымдагы капма-каршылыкларның нәтиҗәсе буларак, фәкать болай гына, тышка бәреп чыгалар. Гафу ит мине, сеңлем. *(Елый.)*

Рәзинә *(аны кочаклый)*. Гүзәлия апа, син нәрсә инде!

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ильяс коридорга репетиция ясарга чыга. Музыка яңгырый. Бию. Альберт килә.

Альберт *(кулындагы папканы кухня өстәленә ташлый).* Сәлам!
Ильяс *(кул биреп күрешә).* Сәлам!
Альберт. Ничек?
Ильяс. Беркөе.
Альберт. Йоклап буламы?
Ильяс. Начар йоклыйм дип әйталмыйм, тыныч монда.
Альберт. Кыерсытучы, авыр сүз әйтүче юкмы?
Ильяс. Кем кыерсытсын инде мине монда?! Акчаң юкмы, дип ник сорамыйсың?
Альберт. Булыр, булыр.
Ильяс. Теге ике йөз долларны да һаман бирмисең.
Альберт. Бирермен, бирермен. Ночной клубта биеп алырга кирәк иде.
Ильяс *(чыраен сытып).* Юк, туйдым мин ул ночной клублардан. Тегеләре өчен дә түләп бетермәдең әле.
Альберт. Нинди кеше соң син, ә! Шундый зур эш эшләнергә торганда син тиеннәр чутлап утырасың!
Ильяс. Ашарга-эчәргә, киенергә кирәк бит.
Альберт. Минем Америка проекты белән баш каткан, ә син мине юк-бар белән бимазалыйсың.
Ильяс. Барып чыгамы соң инде ул гастроль, юкмы?
Альберт. Нишләп барып чыкмасын! *(Папкасын алып килә, аны ачып кәгазьләр актара башлый.)* Менә контрактлар төзелеп бетте дияргә була. Кайбер техник якларын гына хәл итәсе калды. Америкада чыгыш ясаячаксың, шуны аңлыйсыңмы син, юкмы?! Лос-Анджелес, Нью-Йорк... Бәхетеңнән җүләрләнмәсәң ярар иде инде.
Ильяс. Уңышка ирешүдән җүләрләнгән кешене күргән юк әле.
Альберт. Менә күрәсеңме бу документларны. Тиздән синең өчен бөтенләй башка дөнья ачылачак.
Ильяс. Син гел вәгъдә итәсең. Теге, ресторандагы чыгышым өчен дә яртысын гына түләдең әле.
Альберт. Барысы өчен дә берьюлы алачаксың. *(Кырысланып.)* Нинди кеше соң син, ә! Минем белән алай сөйләшмә инде. Мин синең продюсерың. Миннән башка ачтан үләсең син.
Ильяс. Үлмим. Илдә чыпчык үлми.
Альберт. Чыпчык булып яшәү рәхәтме соң?! Шушындый талантың белән син чыпчык булып чүплектә казынырга түгел, һавада зур кош булып очарга тиешсең.
Ильяс. Болай да ярты гомер һаваларда очып үтеп китте инде.
Альберт. Ярар, кирле-мырлы сөйләшеп утырма. Хатының белән развод булдымы?
Ильяс. Аерылыштык, законно.
Альберт. Әйбәт булган. Киләсе атнадан костюмнар тектерә башларбыз.
Ильяс *(кәгазьләрне карап).* Барып чыгар микәнни?
Альберт. Әле һаман ышанмыйсыңмыни?
Ильяс. Ул нинди гастрольләр соң? Тагын кемнәр катнашачак анда?
Альберт. Коллектив бигүк зур булмаячак. Син гвоздь программы булачаксың. Мин инде реклама белән шөгыльләнәм. Инде Америкада сине пропагандалау башланды, дурак! Аңлыйсыңмы?
Ильяс *(җанлана).* Ышанасы килә. Бәлки, ялганлыйсыңдыр. Ләкин шул ялганга ышанасы килә. Без бит гомер буе алданып яшибез. Сүзгә, күз карашына, матурлыкка, киләчәккә... Гомумән алданып яшибез. Алай гына да түгел, алданасы килә бит! Дөресен әйткәндә, Америкага барасым килә минем. Анда биеп күрсәтәсем килә, үземнең дөньяда барлыгымны игълан итәсем килә. Ә мин ышанам, анда да бик күпләрне таң калдыра алырмын.
Альберт. Молодец! Менә шулай морально хәзерләнә тор! Оештыру эшләре башланды инде. Сине фотога төшерергә кирәк, берничә вариант, срочно Америкага җибәрергә. Ярый, сау булып тор!
Ильяс. Хуш! *(Альберт чыгып китә.)* Их, бер кайнаштырып аласы иде дә бит! Өермә куптарып алырга иде бер генә тапкыр булса да!

Бию. Гүзәлия чыга, карап тора.

Гүзәлия. Син бәхетле кеше.
Ильяс. Ник алай дисең?
Гүзәлия. Ничек кеше шулай булдыра ала, мин шаккатам. Мин һәрвакыт талантлы кешеләрне гайре табигый күренеш дип кабул итәм. Ходай бирсә бирә инде, тик менә һәркемгә дә бирми бит.

Ильяс. Әй, Гүзәлия, гайре табигыйлек, бәлки, дөрестер, ләкин бәхет турында һич кенә дә килешмим. Бәхет сәләткә карап килми ул. Син нәрсә, елыйсыңмы әллә?

Гүзәлия *(дулкынланып)*. Мин бик шат синең монда килүеңә. Төксе тормышка ниндидер якты төс керттең син. Ә минем күңелем сизеп йөрде синең киләсеңне.

Ильяс *(ягымлы елмаеп)*. Бигрәк сизгер икән күңелең.

Гүзәлия. Кайдан син?

Ильяс. Мин түгелмәгән күз яшьләре иленнән!

Гүзәлия. Андый ил бармыни ул?

Ильяс. Бар.

Гүзәлия. Анда җиләк-җимеш тәмледер, чишмә сулары шифалыдыр, шуңа күрә анда синдәй затлы кеше туадыр.

Ильяс. Юк, анда җан газабы дигән бер генә төрле ризык бар.

Гүзәлия. Әллә нинди куркыныч сүзләр сөйләмә инде.

Ильяс *(елмаеп)*. Син дә куркак икән.

Гүзәлия. Куркыныч бит... Ә син мине биергә өйрәтә алмассыңмы?

Ильяс. Үзең әйттең бит — тумыштан килә торган сәләт, өйрәтү мөмкин түгел, дип...

Гүзәлия. Ә син мине өйрәтеп кара, бәлки, миндә ул сәләт йокыга гына талгандыр.

Музыка. Ильяс белән Гүзәлия биюе.

Ильяс. Өмет бар. Сиңа спорт костюмы яки җиңел, иркен кием кирәк. Мин сиңа дәресләр биргәләрмен.

Гүзәлия *(Ильясның кочагыннан ашыкмыйча гына чыгып)*. Ә мин сине аңлый башладым шикелле...

Ильяс. Нәрсәмне?

Гүзәлия. Синең күңел боеклыгыңның серен чамаладым кебек.

Ильяс. Кирәкми. Кеше күңеленә кереп казыну беркайчан да яхшы тәмамланмый.

Гүзәлия. Гафу ит. Мин казынырга җыенмыйм да.

Ильяс. Син үзең боек.

Гүзәлия. Шулай шул. Боек.

Музыка.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кич. Ильяс бүлмәсе. Ильяс диванда китап укып ята. Наил керә.

Наил *(коры гына)*. Нишлисең?

Ильяс *(китабын тумбочкага куя да торып утыра)*. Китап укыйм.

Наил. Нинди китап? *(Китапны алып чыраен җыера.)* Сур...рин... Киек... Кыек... кирек...

Ильяс. Серен Кьеркегор.

Наил. Ни соң ул?

Ильяс. Ни түгел, кем! Кеше исеме ул. Дания философы һәм теологы, унтугызынчы гасырда яшәгән.

Наил. Бу аның китабымы?

Ильяс. Әйе. «Курку һәм тетрәнү» дигән әсәре.

Наил. Философмыни ул?

Ильяс. Әйе.

Наил *(кат-кат әйләндергәләп караганнан соң тумбочкага ташлый)*. Күршедәге техникум философы гына җитмәгәнмени, чит илнекен укып ятасың. Исемен ничек дисең?

Ильяс. Серен Кьеркегор.

Наил. Мин әйтә ала торган түгел икән. Безнең гараждагы мастерның исеме дөньяда иң катлаулыдыр дип йөри идем, тагын әллә ниндиләр бар икән әле. Ни дип яза инде ул кеше?

Ильяс. Болай гына аңлатып булмый аны.

Наил. Ни турында?

Ильяс. Кеше күңеле хакында.

Наил. Аңлашылды. *(Кырыслык белән.)* Син алга таба нишләргә уйлыйсың?

Ильяс. Яшәвемне дәвам итәргә.

Наил. Синең белән бик җитди итеп сөйләшәсем бар.

Ильяс. Чалбарны коридор уртасына элмәскә, ботинканы ишек катында калдырмаска, ваннага тәмәке көлен коймаска, бәдрәфтә озак утырмаска — шул турыда сөйләшмәкче буласыңмы?

Наил. Юк, җитдирәк мәсьәлә хакында.

Ильяс. Тыңлыйм.

Наил. Минем сүзем менә шушы бүлмәгә бәйле инде.
Ильяс. Сиңа бу бүлмә кирәк инде, аңлыйм. Ә мин нишләргә тиеш?
Наил. Безнең балабыз туачак, без ул кечкенә бер бүлмәдә ничек яшәрбез!
Ильяс. Мин дә бит урамда кала алмыйм. Мин булмаган сурәттә дә сиңа кем бирә әле бу бүлмәне?
Наил. Син килеп чыкмасаң, мин бу мәсьәләне хәл итә ала идем, эштән ходатайство алып.
Ильяс. Мине куып чыгарырга ниятләмисеңдер бит?
Наил. Хатыныңа фатир калдырып киткәнсең бит син.
Ильяс. Әйе, без аерылыштык.
Наил. Ник, бар, гаиләң янына кире кайтып кит.
Ильяс. Син нишләп миңа карата алай дорфаланасың?! Монда килгәннән бирле минем белән аркылы-торкылы сөйләшәсең!
Наил. Ә тагын ничек сөйләшергә синең белән?!
Ильяс. Гаражыңдагы манерада сөйләшмә минем белән, аңладыңмы?!
Наил. О-о-о, синең холкың да хәйран алама икән...
Ильяс *(тәмам ачуы чыга)*. Карале, мин синнән туя башладым. Син дебилмы, әллә кыланасың гынамы?
Наил *(кызып)*. Син нишләп әле миңа койрык күтәрәсең, ә?!
Ильяс. Синең белән бит кешечә сөйләшү мөмкин түгел, синең белән нинди темага һәм нинди телдә сөйләшергә соң?
Наил. Менә мин сине күзәтәм, һич кенә дә аңлый алмыйм — кем син, нәрсә син?
Ильяс. Беренчедән, син мине беркайчан да аңламаячаксың. Икенчедән, мине аңлау сиңа ник кирәк?!
Наил. Син үзеңнең эшсез бер бәндә икәнеңне беләсеңме?
Ильяс. Мин үземнең кем икәнемне бик яхшы аңлыйм. Син, күрше, юкка минем белән мондый тупас мөгамәләгә керәсең. Минем бит сиңа бернинди начарлык эшләгәнем юк, эшләргә дә җыенмыйм.
Наил. Ярар. Мин болайрак әйтәм алайса... Менә, синең кебек эт ялкаулары аркасында рәтле тормыш юк илдә. Кая карама җырчы да биюче хәзер.
Ильяс. Дөньяда синең кебек тупас, дорфа кешеләр генә булса, әллә яшәеш алга китәр идеме? Ул очракта ай-һай караңгы булыр иде дөньялар!
Наил. Ярый, ярый... *(Чыгып китәргә җыена.)* Шуны да әйтәсем бар әле: тагын бер тапкыр хатыным пешергән ботканы ашасаң, ике аягыңны да бот төбеннән суырып чыгарачакмын. Менә биерсең аннары!
Ильяс *(түземлеген җуеп сикереп тора)*. Карале, мокыт, син мине куркытма, мин куркудан узган инде! Монда килгән продюсерны күрдеңме син? Миңа кагылган кешенең ул бугазын чәйнәячәк, башымнан бер генә чәч бөртеге төшсә дә иманыңны киячәк! Миңа тел-теш тигезмә бүтән! Мәетеңне унбиш ел эзләячәкләр, жлоб сраный!
Наил *(күзләрен акайтып)*. Нәрсә?! Үтерәм! *(Ильяска таба ыргыла.)*
Ильяс *(урындык күтәреп)*. Якын килмә, хайван!

Наил аның кулыннан урындыкны каерып ала, шуннан соң Ильясны идәнгә егып сала.

Наил *(кычкырып)*. Тотма чәчтән, козел!
Ильяс *(ыңгырашып)*. Җибәр, дуңгыз!

Шау-шуга Роберт, Гүзәлия, Рәзинә йөгереп керәләр. Сугышучыларны аралыйлар.

Роберт *(кемгә тотынырга белми)*. Җәмәгать, туктагыз әле, болай аралашу непедагогично!
Рәзинә *(өзгәләнеп кычкыра)*. Наил, үтерәсең бит! Сукма!
Наил. Рәзинә, чыгып кит моннан, сиңа дулкынланырга ярамый!
Гүзәлия *(сугышучылар тирәсендә йөгереп йөри, елый)*. Туктагыз, зинһар! Күршеләр! Болай ярамый! Сез бит кыргыйлар түгел!
Роберт *(кычкыра)*. Җәмәгать! Закон бар! Акылыгызга килегез! Канашып беттегез бит инде!

Наилне көч-хәл белән тыялар. Ильяс астан шуышып чыга. Наилне ишеккә таба сөйриләр.

Наил *(ишек катыннан кычкыра)*. Барыбер үтерәм мин сине!
Ильяс *(көчкә сулыш алып)*. Пошел вон! Дуңгыз! Синең ишеләргә үтертеп торам ди!
Наил *(акырып)*. Бүген үк үтерәм! Тыпырдавык! Тунеядец!

Наилне алып чыгып китәләр. Бүлмәдә Ильяс белән Роберт кына калалар. Күрше бүлмәдән шактый вакыт Наилнең сүгенеп кычкырганы ишетелеп тора.

Роберт. Сез бит зыялы кеше, сезгә килешми ул әдәпсез кеше белән бер дәрәҗәгә төшеп матавыклану.

Ильяс *(борынынннан аккан канны кулъяулык белән сөртеп).* Анысы шулай да бит, нишлисең, кайвакыт ычкынып китәм шул үзем дә. *(Караватка утыра, еш-еш сулый, кабыргаларын капшап карый.)*

Роберт *(урындыкка утыра).* Аны бу бүлмә кызыксындыра инде, шуңа эче поша аның. Авылында гына ятсын иде. Авылдан шәһәргә киләләр дә, кешеләр белән ызгышып, талашып, фатир дәгъва итеп йөриләр.

Ильяс *(чыраен сытып).* Алай димәгез инде. Мин үзем дә авылдан чыккан кеше.

Роберт *(уйга калып).* Хәер, мин дә авылда туып үстем бит әле. Ике арада калдым менә — ни шәһәр кешесенә әверелмәдем, ни авылныкы түгел. Без, авылдан чыкканнар, бәхетсезләр.

Ильяс *(кулы белән битен сыпырып)*. Философ кешедән башка сүзләр ишетергә теләр идем.

Роберт. Фәлсәфә ул башка нәрсәләр кебек килә-китә йөри. Чынбарлыкка килеп төртелгәч кәеф күтәренке чактагы уй-фикерләр йә челпәрәмә килә, йә аларның кирәге калмый. Син әле яшь кеше, синең ялгышуларың, алдануларың әле алда. Синең әле тормышыңны үзгәртергә дә мөмкинлегең бар. Мин инде бу бүлмә безгә эләгер дип өметләнеп йөргән идем...

Ильяс. Нәрсә, бу бүлмә эләксә, бәхетегез артыр идемени?

Роберт. Сезнең миңа караганда мөмкинлекләрегез күбрәк. Сезнең химаячегез бар... Аннары, мин хаклы ошбу бүлмәне үзләштерергә. Мин техникумда ничәмә еллар укытып күпме файда китергән кеше җәмгыятькә...

Ильяс. Мине файдасыз кеше дип әйтмәкче буласыз инде?..

Роберт. Алай ук дип әйтергә мин әлегә базмыйм... Ләкин минем белән чагыштырганда... Сез мине дөрес аңлагыз... Әгәр дә уңышка ирешеп тиздән фатир алсагыз, бу бүлмәне берәр ничек безгә тапшырып китәрсез дигән тонык кына бер өметем бар минем...

Ильяс. Күз күрер әле анда...

Роберт. Мин һәрвакыт гаҗәпләнәм: сәнгать кешесе үзенең шөгыленә чынлап та инана микәнни?

Ильяс. Аңламадым?

Роберт. Ничек аңлатыйм икән... Кыскасы, мине сәнгать кешесенең үз сәнгатенә җитди каравы гаҗәпләндерә. Ул хобби булырга тиеш, ә аны ул профессия итмәкче була.

Ильяс. Сез дә бит үзегезнең профессиягезне профессия дип саныйсыз. Күңел ихтыяҗы булгач, аның нәрсә икәнен анализлап торасы килми. Чын җырчыга «син җырлама» дип әйтеп кара инде — ул сиңа җүләргә караган кебек кенә карар.

Роберт. Минем сезне үпкәләтәсем килми, үземнең уй-фикерләрем белән генә уртаклашуым.

Ильяс. Мин сезгә үпкәләмим, сезнең хакыгыз бар теге яки бу сәнгатьне җитди кабул итмәскә, теге яки бу сәнгать кешесен кешегә санамаска.

Роберт. Мин җәмгыятьтәге кешеләрнең илгә, ватанга чын хезмәт күрсәтүләрен телим. Файдалы эш белән тамагын туйдырырга тиеш кеше.

Ильяс. Ә кем үлчәгән кемнең күпме файда китерүен. Мәсәлән, бүгенге көндә мин иректә кеше. Сәләтем белән күпме акча эшли алам, шуңа яшим. Ә бит бюджет акчасына яшәп ятучы сорыкортлар күпме!

Роберт. Миңа төрттерәсезме?

Ильяс. Юк инде. Мин әле бит сезне якыннан белмим.

Роберт. Ярар, бер иркенләп сөйләшербез әле.

Ильяс. Ярый.

Роберт. Наилгә игътибар итмәскә тырышыгыз инде. *(Чигәсенә бармагын тидереп.)* Ул башы белән бигүк тату түгел.

Ильяс. Башы белән татумы-юкмы, анысын белмим, ә менә мокыт икәненә инандым.

Роберт. Аңа каршы әйтмәскә тырышыгыз.

Ильяс *(кыҗрап)*. Мин аңа берәр чара табам, кирәк булса.

Роберт. Ярый, исән-сау! *(Чыгып китә.)*

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ильяс бүлмәсе. Музыка. Ильяс репетиция ясый. Спорт костюмыннан Гүзәлия керә.

Гүзәлия *(үзен бик уңайсыз хис итә).* Нихәл?

Ильяс *(гаҗәпсенеп).* Исәнме!

Гүзәлия. Менә спорт костюмы алдым.

Ильяс. Күрәм. Сиңа бик килешә. Ничек диләр әле... Сылу кешегә солы капчыгы да килешә, диләрме? *(Көлә.)*

Гүзәлия. Капчыкка охшаганмыни?

Ильяс. Юк инде, шаярып әйтәм, шундый сүз бар бит.

Гүзәлия. Дәрес бирәсеңме?

Ильяс. Гүзәлия, гафу ит, мин сиңа дәрес биралмыйм. Роберт абый әллә ниләр уйлар.

Гүзәлия. Нишләп ул әллә ниләр уйларга тиеш?

Ильяс. Сез аның хатыны... Йә көнләшә башлар...

Гүзәлия *(борчылып)*. Әллә берәр сүз әйттеме?

Ильяс *(кинәт кырт кисеп)*. Юк! Ләкин ачуы килү дә ихтимал.

Гүзәлия. Их, Ильяс, белсәң иде ул кешедән ничек туйганымны! *(Пауза.)* Мин япь-яшь кыз идем, аның берөзлексез китап сүзләре белән сөйләвен тыңлап, философларның цитаталарын хәтерләвенә мөкиббән китеп, аның сүз боламыгын ашап гашыйк булган идем. Ул миннән унбиш яшькә олырак. Миңа унсигез, аңа утыз өч яшь иде. Бергә яши башлавыбызның беренче көннәреннән үк аңладым: минем кешем түгел бу, мәхәббәт тә шул арада юкка чыкты. Ә менә унҗиде ел яшәлде бергә — аны ташларга базмыйча, аны кызганып. Безнең балаларыбыз да булмады. Үзем дә фәлсәфи карый башладым — аңа да, үземә дә, тормышыбызга да. Китәргә талпынган чакларым да булды. Тик менә киталмадым. Китү һәркемнең хәленнән килми шул ул.

Ильяс. Дөрес әйтәсең, Гүзәлия, килү җайлы ул һәрвакыт. Китү авыр. Китүнең бәһасе кыйммәтрәк. Елама син. Ул зыялы кешегә охшаган болай...

Гүзәлия. Аның зыялылыгы төче итеп сөйләшә белүдән, дөрес сүзләр әйтүдән генә гыйбарәт бит. Син миңа җирәнеп карыйсыңдыр?

Ильяс. Ник?

Гүзәлия. Сиңа, чит кешегә, үземнең иремне яманлап утырам. Мин үземнән-үзем җирәнеп куйдым әле.

Ильяс. Юк, күңелдәге кайчан да булса, кайда да булса, кемгә дә булса бер түгәргә кирәктер инде ул.

Гүзәлия. Мин сине күрү белән абайладым: сиңа эчке серләрне сөйләргә була, синең белән хәсрәт уртаклашырга да мөмкин — шундый кешегә охшагансың.

Ильяс. Рәхмәт.

Гүзәлия. Гомер заяга узып барганны тоя башладым... Син монда килгәч ул тойгы көчәйде.

Ильяс. Гүзәлия, син бик өзгәләнмә. Бу дөньяда бәхетле кеше юк бит ул. Әллә кемнәр белән аралашканым бар — бае белән, хәерчесе белән, ялгызлар белән, гаиләлеләр белән, начальниклар белән, дворниклар белән... Берсе дә үзен бәхетле санамый. Әгәр туйсаң ireңнән, тот та кит.

Гүзәлия. Кая? Кая китим мин?!

Ильяс. Алайса, шушында гына, шул ireң белән яшә. Монда бит ике генә вариант. *(Елмая.)*

Гүзәлия. Гафу ит мине.

Ильяс. Гафу үтенмә.

Гүзәлия *(күз яшьләрен сөртеп)*. Елагач җиңел булып китә.

Ильяс *(тагын да киңрәк елмаеп Гүзәлияне битеннән үбеп ала)*. Димәк, ешрак еларга кирәк.

Гүзәлия *(елмая)*. Кызык кеше син.

Альберт килеп керә. Гүзәлия тиз генә чыгып китә.

Альберт. Сәлам!

Ильяс. Сәлам!

Альберт *(ишеккә ымлап)*. Бу йонлы баш ник кергән?

Ильяс. Болай гына.

Альберт. Тынычмы монда, комачаулаучы юкмы? *(Кул биреп күрешәләр.)*

Ильяс. Юк, кем комачауласын миңа?!

Альберт *(өстәл янындагы урындыкка утыра)*. Тәк, иртәгә синең белән костюмнар тектерергә барабыз.

Ильяс. Син миңа бераз акча калдыр әле.

Альберт. Ярар. *(Папкасыннан берничә кәгазь акча алып бирә.)* Сентябрь азагында без инде Америкада булырга тиеш. Җәй буе программаны прогонять итәчәкбез. Бөтен бригаданың җыйналуы унынчы майда Химиклар клубында була, онытма.

Ильяс *(җанланып)*. Ярар.

Альберт. Бәдрәфкә барып килим әле мин. *(Чыгып китә.)*

Ильяс сәерсенеп Альбертның папкасына карап тора. Әкрен генә папканы ача, бер кәгазьне алып укый һәм котсыз кала. Шундук кәгазьне үзенең тумбочкасына яшереп куя. Альберт керә. Ильяс берни булмагандай урындыкта утыра.

Альберт *(аптырап карап тора)*. Нишләп битеңнән төс качкан?

Ильяс *(каушый)*. Дулкынланам... Америкада чыгыш ясыйсы бар бит...

Альберт. Шуңа күрә үзеңне психологически әзерләргә кирәк. Бик коелып төшмә инде, син бит инде ничә ел биисең. Син бит профессионал! Ярый, вакыт кысан, киттем мин.

Ильяс. Хуш!

Альберт. Исән-сау тор! *(Чыгып китә.)*

Альберт киткәч, Ильяс кәгазьне алып укып утыра. Кат-кат укый. Кәгазьне идәнгә төшереп җибәрә. Торып арлы-бирле йөри. Тагын кәгазьне ала, өстәлгә куя. Диванга йөзтүбән каплана. Тагын торып утыра. Барып тәрәзәдән карап тора. Шуннан соң диванга барып йөзтүбән каплана. Музыка. Беркавым вакыт узгач ишек әкрен генә ачыла. Рәзинә пәйда була.

Рәзинә *(эндәшергә җөрьәт итмичә торганнан соң пышылдый)*. Ильяс абый! *(Ильяс кымшанмый да ята.)* Ильяс абый! Сугышканда Наилнең джемпер сәдәбе өзелеп төшеп калган, әйдә, шуны эзлик әле. *(Идәннән сәдәп эзли.)* Ильяс абый, син тапмадыңмы саргылт сәдәп? *(Ильяс тып-тын ята.)* Ильяс абый... *(Өстәл астыннан сәдәпне табып ала.)* Аллага шөкер, табылды. Ильяс абый... *(Өстәлдәге кәгазьне күреп ала, укый һәм күзләре акая, котсыз калып, чыгып йөгерә.)* Әни, үләм! Әстәгъфирулла! Әни!!!

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Коридор. Кухня янында Наил белән Рәзинә пыш-пыш сөйләшәләр.

Рәзинә *(пышылдап)*. Милиция чакыртыйк.

Наил. Юк, ашыкмыйк. Мине гаепләүләре бар. Җитмәсә, иң соңгы кергән кеше дә син бит.

Рәзинә *(дер-дер калтырап)*. Бәлки, исәндер?

Наил. Үзең укыгансың бит. Тик менә аңламыйм, ничек шул арада таныклыгы да әзер булган соң аның? Әле генә исән иде бит...

Рәзинә. Кереп кара.

Наил, аяк очларына гына басып, Ильясның бүлмәсенә кереп чыга.

Наил *(күзләрен акайтып)*. Әйе, чынлап та, өстәлендә ята.

Рәзинә *(куркып иренең тельняшка җиңенә ябыша)*. Әллә үләсен белеп яздырганмы ул кәгазьне?

Наил. Белмим. Сугышасы калмады шуның белән. Утыртып куйсалар?..

Рәзинә. Йа Ходаем! Роберт абыйлар шаһитлар, аның бездән исән калуын күрделәр бит.

Наил. Минем аның белән сугышканымны да күрделәр шул.

Рәзинә. Туктале, ничек инде берничә сәгать эчендә... ул документ туарга мөмкин?! Тагын кереп укып кара әле. Бәлки, исәндер дә.

Наил тагын кереп чыга.

Наил. Юк, мышнамый да. Хәзер инде анда аягыбызны да басарга ярамый. Анда берәр ничек Робертны кертергә кирәк. Аның эзләре дә калсын. Ул да бит аның бүлмәсен дәгъвалап йөрде.

Рәзинә. Куркам. Әллә Роберт абыйлар белән киңәшләшикме? Бигрәк гайре табигый хәл килеп чыга бит...

Роберт коридорга чыга. Наил белән Рәзинә котсыз калалар.

Роберт *(күршеләрен абайлап ала)*. Нәрсә булды?

Наил *(башын чайкап)*. Булмады.

Роберт. Чырайларыгыз ап-ак.

Наил. Рәзинә, бар, кереп кит. Сиңа дулкынланырга ярамый. *(Рәзинә тиз генә бүлмәләренә кереп китә.)*

Роберт *(сәерсенеп)*. Бер-бер хәл булмагандыр бит?

Наил. Синең машинкаң бармы?

Роберт. Яза торганмы?

Наил. Әйе.

Роберт. Бар.

Наил *(тавышын күтәреп)*. Димәк, синең эш!

Роберт. Аңламадым, нәрсә минем эш?

Наил. Хәзер. *(Ильясның бүлмәсенә кереп китә һәм шундук кулына кәгазь тотып килеп чыга.)*

Роберт. Нәрсә бу?

Наил. Укы. *(Кәгазьне бирә.)*

Роберт *(укый)*. Ничек инде! *(Күзләрен акайтып.)* Кай арада?!

Наил. Менә мин синнән сорамакчы идем — кай арада?

Роберт. Исәндер бит ул?

Наил. Юк, диванына йөзтүбән капланган да ята, тыны да чыкмый. Синең эш бу.

Роберт *(дулкынланып)*. Нишләп минем эш?!

Наил. Бүлмә өчен син кыбырсып йөрдең түгелме?

Роберт. Миңа караганда сез ныграк темиегезне сузып йөрдегез ул бүлмәгә.

Наил *(күзләрен чекерәйтеп)*. Син алдан ук рассчитать итеп оештыргансың моны! Алдан ук шушы таныклыкны эшләгәнсең, чөнки синең машинкаң бар.

Роберт *(кыза башлый)*. Сез аның белән сугыштыгыз, үзегезнең җинаятегезне миңа сылтарга маташмагыз. Машинканың монда ни катнашы бар?! Бу документ компьютерда җыелган һәм дә принтердан чыгарылган. Машинканың шрифты мондый булмый, надан!

Наил. Барыбер шик икебезгә дә төшәчәк.

Роберт. Мәгез, кертеп куегыз урынына. *(Кәгазьне суза.)*

Наил. Бар үзең.

Роберт. Сез алып чыктыгыз бит, барыгыз кертеп куегыз урынына.

Наил *(усал елмаеп)*. Бу кәгазьдә синең отпечаткаларың да бар хәзер.

Роберт. Куркытмагыз. Минем гаебем юк. *(Котсыз кала.)*

Наил. Минеке дә юк.

Роберт. Барыгыз, кертеп куегыз. *(Калтырана.)*

Наил. Кертмим.

Роберт. Ә-ә-ә, куркасызмы җинаять урынына кире керергә?!

Наил *(җикереп)*. Бир! Үзең дә усак яфрагы сыман лепердәп утырасың! *(Кәгазьне ала һәм Ильяснең бүлмәсенә кертеп чыга.)*

Роберт *(Наил янына аяк очларына гына басып килә)*. Карагыз әле, әйдәгез сүз куешабыз, берни белмибез дип. Рәзинәне дә кисәтегез.

Наил *(як-ягына каранып куя)*. Чыннан да. Безнең монда катнашыбыз юк, дибез дә вәссәлам. Сугышканыбызны да әйтмибез, бүлмәсенә кызыгып йөрүебез хакында да сүз катмыйбыз.

Роберт *(үзен тынычландырырга тырышып)*. Мин кылган җинаять түгел, миңа барыбер.

Наил. Мин дә бу җинаятьне кылмадым!

Роберт. Шулай булгач, ник куркырга?

Наил *(күкрәген угалап)*. Куркыта бит. Син ныграк куркырга тиеш. Шик күбрәк сиңа төшәчәк. Чөнки синең хатының аның белән теге... ни... шухыр-мухыр дип үк әйталмыйм... Тик шулай да алар танцавать иттеләр, валлаһи газим!

Роберт *(чыраена газап төсе чыга)*. Ялган! Ышанмыйм!

Наил. Ышанмасаң, әнә, Рәзинәдән сора.

Роберт. Сорамыйм! Мине терроризировать итмәкче буласыз барыгыз да!

Роберт җил-җил атлап үз бүлмәсенә кереп китә. Наил дә үз бүлмәсенә юнәлә. Һәркем үз бүлмәсенә кереп китә. Шомлы музыка. Күп тә үтми, күршеләр берәм-берәм коридорга чыгалар һәм тып-тын басып торалар. Гүзәлия елый.

Наил *(тонык тавыш белән)*. Нишлибез?

Гүзәлия. Милиция чакыртыйк.

Роберт. Минемчә, иң элек теге продюсерына хәбәр бирергә кирәктер. Ул үзе хәл итсен. Ул безгә караганда яхшырак белер нишләргә кирәк икәнне.

Рәзинә *(еламсырап)*. Ул куркыныч кеше, безнең барыбызны да харап итмәсме?!

Наил. Сиңа дулкынланырга ярамый.

Рәзинә. Ничек дулкынланмыйсың инде! Безне харап итәчәк аның продюсеры. Бездән күрәчәк.

Роберт. Ничек харап итсен, раз безнең гаебебез юк?!

Гүзәлия. Мин аңламыйм, ничек инде үлү белән үк шул кәгазь барлыкка килгән?

Наил. Шуны уйлап куйдым әле, монда ике бүлмә берьюлы бушамагае...

Роберт. Сезнең бүлмәгез дә бушамагае...

Наил. Ни әйтмәкче буласың?

Роберт. Алай-болай сезне төрмәгә утыртсалар дим...

Наил *(гасабиланып)*. Кабахәт! Кемне? Минеме?! Менә сине утыртмасалармы әле!

Гүзәлия *(өзгәләнеп)*. Һаман бүлмәләр бүлешәсез! Монда кеше дөньядан киткән, ә сез!

Рәзинә. Туктагыз әле. Нишләп без бер-беребездән шикләнәбез... Аның янына бит бездән башка да теләсә кем кереп чыга ала. Мин, мәсәлән, аның бүлмәсеннән сөйләшкән тавышлар ишеткәләдем.

Роберт. Чынлап та.

Гүзәлия *(арлы-бирле йөреп)*. Хәбәр итик. Кеше үлгән! Бәлки, «скорый» чакыртырга кирәктер, бәлки, аны терелтергә мөмкиндер. *(Елый.)*

Шул вакытны Ильяс бүлмәсенең ишеге әкрен генә ачыла. Коточкыч кыяфәт белән Ильяс пәйда була. Бите шешенгән, иңенә сөлге аскан. Барысы да куркып качышып бетәләр. Гүзәлия генә аның янына йөгереп килә.

Гүзәлия *(куркып һәм шул ук вакытта шатлык хисе кичереп)*. Ильяс! Син исәнме?!
Ильяс *(аптырап)*. Ник, күрмисеңмени?!
Гүзәлия. Без бит котсыз калдык.
Ильяс. Нәрсә булды?
Гүзәлия. Сине үлгән дип белдек.
Ильяс. Ничек инде?!
Гүзәлия. Анда, имештер, өстәлеңдә үлү турында таныклык ята. Синең үлүеңне раслый торган документ. *(Ильяска якын килергә курка.)*
Ильяс. Ни сөйлисең!
Наил *(коридор почмагыннан)*. Үзем күрдем.
Рәзинә *(кухнядагы суыткыч артыннан)*. Мин дә күрдем.
Ильяс *(гаҗәпләнгән булып кылана)*. Әллә ниләр уйлап чыгармагыз инде.
Роберт *(ачулы тавыш белән)*. Миңа бу спектакль бер дә ошамый әле.
Ильяс *(битарафлык белән)*. Минем үземә дә бу тамашаның кызыгы юк. Мин шулкадәр каты йоклаганмын. *(Ванна бүлмәсенә юынырга дип кереп китә.)*

Музыка.

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Ильяс коридорга чыга. Моңлы музыка. Теләр-теләмәс кенә репетициясен башлый. Гүзәлия чыга, йөгереп килеп Ильясны кочаклый.

Гүзәлия *(канатланып)*. Ә мин сине иртәдән бирле көтеп йөрим! Бүлмәң ишеген дә шакымакчы идем, базмадым. *(Ильясның күзләренә карап тора да кинәт елап җибәрә.)*
Ильяс. Ник елыйсың?
Гүзәлия *(үзе елый, үзе елмая)*. Чөнки син янәшә.
Ильяс *(як-ягына каранып)*. Күршеләр күрер.
Гүзәлия. Күрсеннәр. Алар өйдә юк. Роберт эштә, Наил белән Рәзинә авылларына кайтып киттеләр.
Ильяс. Син нишләп өйдә?
Гүзәлия *(күз яшьләрен уч төбе белән сыпырып)*. Мин отгул алдым. Синең белән иркенләп сөйләшәсем килде.
Ильяс. Кызык кеше син. Китапханәдә эшләүчеләр шулай кызык булалар инде алар. Китап күп укыганнандыр инде ул.
Гүзәлия *(кабаланып сөйли)*. Минем гел синең белән сөйләшәсем килә. Әйе, мин гомерем буе совет чорында чыккан китаплар укыган кеше, шуңа күрә бераз сабыйларчадыр мин. Китаплардан укыган матурлыкны синдә абайладым. Синең үлүең турында таныклыгың барлыкны ишеткәч тә, мин синең үлгәнеңә тәгаен ышанмадым. Мине хәтта синең үлү турында таныклыгың барлыгы да хәзерге минутта гаҗәпләндерми һәм сәерсендерми. Син үзең гаҗәп, син үзең могҗиза.
Ильяс. Китаплар укып, ошаган нәрсәне идеаллаштырырга күнеккәнсең син. Һәрбер кеше могҗиза, Гүзәлия. Һәрбер кеше талантлы.
Гүзәлия. Шулай да миңа аңлата алмассыңмы икән — нишләп син үлде дигән документ дөньяга туган?
Ильяс. Моны мин үзем дә белмим. Һәм бу хакта миннән сорама, яме. Үземне дә тетрәндерде бу вакыйга. Ә башкалар нәрсә уйлый ул документ турында?
Гүзәлия. Әллә нинди фаразлар корып бетерделәр инде. Сине куркыныч кеше диләр, берәр жуликтыр дип тә карыйлар, башка фамилия белән йөрми микән дип тә уйлыйлар, берәрсен үтереп, продюсеры белән берәр афера ясамак булалармы әллә дип тә гөманлыйлар... *(Көлә.)*
Ильяс. Ник көләсең? Каршыңда шундый куркыныч кеше басып тора, ә син көләсең!
Гүзәлия. Син куркыныч түгел.
Ильяс. Кеше үтерүче булмасам да, тере килеш үлү турында таныклык иясе бит мин, ичмаса, шунысы куркыныч булырга тиеш бит.
Гүзәлия. Барыбер курыкмыйм. Әллә син чынлап та тере кеше түгелме?
Ильяс. Ташла, Гүзәлия. Бу дөньяда кем тере, кем үле — үлчәп кара. Гомумән яшәү юк, бары тик үлемнең булмый торуы гына бар. *(Гүзәлияне җентекләп күзәтә)*. Мин сиңа шуны гына әйтәм: матур кеше син.
Гүзәлия *(чиксез җитдиләнеп)*. Мин матурмы?
Ильяс. Матур!

Музыка. Парлы бию. Мәхәббәт.Алар биегәндә Роберт кайтып керә һәм карап тора.

Роберт *(нәфрәте ташып чыга)*. Шәп! Матур! Браво! *(Бүлмәләренә кереп китә.)*
Гүзәлия *(котсыз кала)*. Роберт кайтты! *(Аның артыннан кереп китә.)*

Роберт Ильяс янына атылып чыга.

Роберт *(ямьсез караш белән Ильяска карап тора)*. Ә мин беләм — ни сәбәпле сәнгать кешеләре тарафыннан кайбер кануннар инкарь ителә.

Ильяс *(һич кенә дә аптырамый)*. Ни сәбәпле?

Роберт *(гасаби киеренкелектән тавышы калтырый)*. Чөнки сез барыгыз да үзегезнең дан-шөһрәтегезнең коллары. Дөресрәге, данга омтылу хисенең коллары. Сез уйлыйсыз: без, сәнгать кешеләре, талантлылар һәм безгә башкалар бурычлы, алар безне күтәреп йөртергә тиешләр, теләгән нәрсәне шундук бирергә тиешләр, безне яратырга тиешләр, имеш...

Ильяс *(тыныч кына)*. Кайнарланмагыз әле.

Роберт *(кычкыра башлый)*. Сез барыгыз да зур дәгъва белән йөрисез бу дөньяда. Һәрбер ошаган әйбер сезгә тапшырылырга тиеш дип уйлыйсыз. Сез барыгыз да эгоизмыгызны йөгәнли алмаучылар, сез...

Ильяс *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Бәлки, сез хаклыдыр.

Роберт *(тәмам нәфрәтләнеп)*. Сез, сәнгать кешеләре, сәхнәдән матурлыкка өндисез, тормышта исә сездән дә сансыз, мәнсез кешеләр юктыр.

Ильяс *(гаебен танып)*. Әгәр сезнең каршыгызда гаебем бар икән, зинһар, гафу итегез мине.

Роберт *(бармагы белән төртеп күрсәтеп)*. Ә мин беләм, нишләп үлгәнгә сабышып ятканыңны!

Ильяс *(ачуы кабара башлый)*. Мин үлгәнгә сабышып ятмадым, мин каты йокыга талганмын. Сез мине үлгән дип уйлаганга мин гаепле түгел.

Роберт *(кычкырып)*. Исән килеш үзеңә үлем таныклыгын ник әзерләп куйганыңны да беләм!

Ильяс *(тавышын көчәйтеп)*. Ник?

Роберт *(чыраен төрле ямьсез гримасаларга кертеп)*. Башкалардан ныграк аерылып торыр өчен, башка дөнья кешесе булып күренү максаты белән, даһи икән дип уйласыннар өчен! Избранный, имеш! Тагын да ныграк шаккатырмак булдыңмы тирә-якташыларны!

Ильяс *(нәфрәте кинәт чәчрәп чыга)*. Күземнән югал, чүпрәк!

Роберт *(шаккатып)*. Нәрсә-ә-ә?!

Ильяс *(ярсып)*. Бар, бүлмәңә кереп кит, мескен!

Роберт *(мыш-мыш килеп)*. Сез... алай сөйләшмәгез минем белән!

Ильяс *(акырып)*. Пошел вон, алаша!

Роберт *(чәрелдәвек тавыш белән)*. Хам! *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

Ильяс. Шизик! *(Үзенең бүлмәсенә кереп китә.)*

Гүзәлия елый-елый килеп чыга, Ильясның бүлмәсе янында туктап тора, кухня өстәленә таба китә. Аның артыннан Роберт чыга.

Роберт *(кычкырып)*. Оят! Хурлык! Наил әйткәч, мин ышанмаган идем.

Гүзәлия *(ни әйтергә белми)*. Нәрсә булды соң әле?

Роберт *(кулына чүмеч ала)*. Син... Күпме ел бергә яшәп... хыянәт итәргә...

Гүзәлия *(елый)*. Нинди хыянәт?! Ни сөйлисең син!

Роберт. Мин китәм!

Гүзәлия *(тыныч кына)*. Кит.

Роберт. Әллә китмәс дисеңме?!

Гүзәлия. Синең беренче китүең түгел.

Роберт. Бу юлысы бөтенләйгә китәм. Теге химкомбинатта эшләүче электрик белән паркта йөргәнегезне күргәч, мин сине гафу иттем, ә бу тыпырдавык әтәч белән биюеңне мин мәңге гафу итмәячәкмен! *(Чүмечне читкә ыргыта.)*

Ильяс *(ишектән башын чыгарып)*. Сез бит философ...

Роберт *(чәрелдәп кычкыра)*. Яп ишегеңне, килмешәк, бездельник, хөрәсән ялкавы! Әйткәние аны Наил, юньлегә килмәде бу биюче ата каз монда, дип!

Ильяс. Их сез! *(Ишеген шапылдатып яба.)*

Роберт кычкыра-кычкыра бүлмәләренә кереп китә. Гүзәлия коридорда елап утыра. Наил белән Рәзинә авылдан кайтып төшәләр. Наил бер капчык бәрәңге күтәргән. Рәзинә берөзлексез нәрсәдер чәйни.

Рәзинә. Наил, бәрәңгене әлегә монда гына куеп торыйк.

Наил. Шушында булмый, аны тагын кая куясың. *(Капчыкны гөрселдәтеп идәнгә куя.)*

Рәзинә *(Гүзәлиянең елап утыруын күреп ала)*. Нәрсә булды?

Гүзәлия. Булмады.

Наил. Тагын берәрсе үлмәгәндер бит?
Гүзәлия. Юк. *(Елый.)*

Роберт бер кулына чемодан, икенчесенә бер бәйләм китап тотып чыгып килә.

Наил *(аптырап)*. Исәнме, күрше.
Роберт *(гасабиланып)*. Саубуллашыр вакыт җитте инде. Сау булыгыз, мин киттем. *(Чыгып китә.)*
Рәзинә. Кая китте ул?
Гүзәлия. Каян белим мин.
Рәзинә. Нәрсә булды?
Гүзәлия. Көнләшә. Ильяс белән биегәнемне күрде.
Наил. Биемәссең! Менә күрдегезме. Әйткәниемме!
Гүзәлия. Уф, яшисем килми! *(Елый-елый бүлмәсенә кереп китә.)*
Рәзинә. Бичара!
Наил. Кемне җәллисең?
Рәзинә. Икесе дә кызганыч.
Наил. Әйдә, һәрбер кешенең китүе безгә файдага. Бүлмәләр бушар, бәлки. Ул биюче белән монда әллә ниләр булып бетүе ихтимал әле. *(Йодрыкларын төйнәп.)* Но минем кул астына эләгә күрмәсен түлке. Мин философ түгел, маңкасы бер якка, каны икенче якка чәчрәр.
Рәзинә. Ярар инде, Наил. Берүк тия күрмә!
Наил. Сиңа дулкынланырга ярамый, бар, кереп ят. *(Рәзинә үзләренең бүлмәсенә кереп китә.)*

Наил коридор буйлап арлы-бирле йөреп тәмәке тартканда, Ильяс чыга. Бер-берсенә карап торалар.

Ильяс *(башын аска иеп).* Күңелсез хәл килеп чыкты...
Наил. Малосемейкада кайчан күңелле хәлләр булганы бар?! Ул Роберт урынында булсам, мин сине бәреп үтерер идем.
Ильяс *(чын күңелдән кайгырып)*. Юкка кызды ул, юкка көнләшә.
Наил. Әйтмә дә, үлгән кешедән көнләшеп инде! Син аның хатынына гашыйк булдыңмы әллә?
Ильяс. Әллә тагы...
Наил. Гашыйк булсаң, аның бүлмәсенә күчәсең дә бергә яши башлыйсыз инде... Синең бүлмәң миңа кала.
Ильяс *(чыраен караңгылатып)*. Синдә һаман бүлмә кайгысы.
Наил. Саласыңмы?
Ильяс. Нәрсәң бар соң синең?
Наил. Аракы.
Ильяс. Юк, аракы эчмим. Җиңелрәге юкмы соң?
Наил. Кырык литрлы флягага алма настойкасы куйганыем, әле әзер түгелдер.
Ильяс. Мин кереп ятыйм әле, хәл бетеп китте. *(Бүлмәсенә кереп китә.)*
Наил *(кухня өстәле янына барып утыра).* Хәлең бетәр дә... Акыллы кеше тик торганда биимени?! Бии торган заманамыни! *(Мыгырдый-мыгырдый шешәне ача, стаканга тутырып аракы сала. Эчеп бетерә.)*

Альберт керә. Наилгә карап тора. Наил, аны күргәч, сискәнеп куя.

Альберт *(Наил каршысына килеп утыра, кесәсеннән бер затлы шешә чыгара).* Сәлам!
Наил. Сәлам!
Альберт. Менә минекен эч.
Наил. Нәрсә соң ул?
Альберт. Виски.
Наил. Минем эчкәнем юк аны. Аракымы соң ул?
Альберт. Ул син куа торган самогон шикелле, ләкин күп тапкыр яхшырак.
Наил *(сагаеп)*. Ә син минем самогон куганны каян беләсең?
Альберт *(көлемсерәп)*. Исе килә. Минем сиңа бер соравым бар. Алай-болай берәр документ тапмадыңмы монда? Кәгазьләрем төшеп калган, ахрысы, һич таба алмыйм.
Наил *(башын чайкый)*. Юк, мин берни дә тапмадым.
Альберт. Хатының?
Наил *(пошаманга кала)*. Юк, юк!
Альберт. Теге аяклы күсәк тапмадымы икән?
Наил. Робертмы?
Альберт. Әйе.

Наил *(каушый)*. Белмим. Ул өйдә юк. Китте. Хатынын ташлап чыгып китте.
Альберт. Хатыны өйдәме соң?
Наил. Өйдә.
Альберт. Бар, чакыр әле.
Наил *(йөгереп барып Гүзәлиянең ишеген шакый)*. Чык әле.
Гүзәлия *(чыга)*. Нәрсә?
Наил. Синең белән сөйләшергә телиләр.
Альберт. Син кереп кит. *(Наил үз бүлмәсендә юк була.)*
Гүзәлия. Тыңлыйм.
Альберт *(кесәсеннән браслет чыгара)*. Бу браслет ошыймы сиңа?
Гүзәлия *(браслетка күз ташлап)*. Ошый.
Альберт. Алай-болай берәр документ тапмадыгызмы коридорда?
Гүзәлия. Юк.
Альберт. Чын әйтәсезме?
Гүзәлия. Чын әйтәм. Минем тагын шуны да әйтәсем килә: сез Ильясның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында уйласагыз иде. Белүемчә, сез аның хезмәте белән файдаланып көн күрәсез. Мин әле курка башладым, сез Ильясның башына җитәрсез шикелле.
Альберт. Ни сөйләгәнегезне аңлыйсызмы сез?
Гүзәлия. Сезне нинди документ кызыксындыра?
Альберт. Бернинди документ та кызыксындырмый. Хәтта үзең дә кызыксындырмый башладың инде. *(Браслетны кесәсенә тыгып куя.)*
Гүзәлия *(горур кыяфәт белән)*. Мин бик шат. *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

Наил чыга. Альберт янына йөгереп килә.

Наил *(пышылдап)*. Нинди документ иде соң ул?
Альберт. Әйт дөресен, таптыңмы берәр кәгазь?
Наил. Ни... Мин... күрдем... *(Як-ягына карана.)*
Альберт *(ун доллар бирә)*. Мә хатыныңа тәмле әйбер алырсың.
Наил *(акчага карап тора)*. Нәрсә соң бу?
Альберт. Ун доллар. Безнең акчага әйләндерсәң, хәзер өч йөз сум була.
Наил *(акчаны кесәсенә тыгып куя)*. Мин табуын тапмадым, но шулай да бер кәгазьгә күзем төште.
Альберт *(зур кызыксыну белән)*. Йә, йә! Нинди кәгазь, әйт тизрәк!
Наил *(күзләрен акайтып)*. Үлү турында таныклык! *(Әйтү белән шешәне күтәреп виски йотып куя.)*
Альберт *(таләпчән һәм усал тавыш белән)*. Кайда күрдең? Кемдә?
Наил *(котсыз калып)*. Биюченең өстәлендә. Без аны үлгән дип торабыз. Ә ул тере икән. Үзе исән, ә үлү турында таныклыгы бар.
Альберт *(бер ноктага текәлеп)*. Димәк, Ильяста ул кәгазь... Бу турыда беркемгә дә әйтмә!
Наил. Аны беләләр бугай инде. Ничек алай соң ул?.. Аңлата алмассыңмы икән?
Альберт. Юк белән баш катырма. Син бит ул кәгазьне күргәч сөенгән идең...
Наил. Сөенүен-ниен белмим, минем шул бүлмәне үзебезгә алырга өметем бар иде... Тиздән безнең балабыз туа...
Альберт *(җирәнеп карый)*. Нинди мескенлек! Ат хәтле егет торак мәсьәләсен дә хәл италмый...
Наил. Ничек хәл итәсең аны, заманы шундый булгач.
Альберт. Заманы шундый булгач түгел, баш эшләмәгәч диген! Бу вискины ал, рәхәтләнеп эч. Авызыңны чамалап ач, күп күрмә, күп сөйләшмә.
Наил *(шешәне ала)*. Рәхмәт. *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

Альберт сигара кабыза. Ильяс чыга.

Альберт. Исәнме.
Ильяс *(сынаулы караш белән)*. Исәнме! Нишләп кермисең, монда утырасың?
Альберт. Күршең белән сөйләшеп утырдык. Аннары, менә сигара кабыздым... Ну, ничек хәлләр?
Ильяс *(килеп утыра)*. Ничек дип әйтим...
Альберт. Әзерләнәсеңме?
Ильяс. Нәрсәгә?
Альберт Америка гастрольләренә.
Ильяс *(Альбертның күзләренә туры карап)*. Әзерләнәм.
Альберт. Нишләп кәефсез соң син?
Ильяс *(чыраен сытып)*. Мин кәефсез түгел, фәкать халәтем кинәт үзгәрде.

Альберт *(сагаеп)*. Нишләп алай?

Ильяс. Мин синең ниятеңне аңламыйм.

Альберт. Безнең уртак бер ният булырга тиеш хәзер — Американы яулап алу. Ха-ха-ха. Нәрсә карап торасың?

Ильяс *(Альбертка текәлеп карап тора)*. Син кем?

Альберт *(гаҗәпләнеп)*. Ничек инде «кем»?! Синең продюсерың. Биш ел буена синең чыгышларыңны оештырып йөрүче кеше. Мин булмасам, беткәниең син. Синең кебек ачык авызлар үзләре генә яши алмыйлар бүген. Беләм, миңа үпкәләрең дә бардыр. Продюсер белән артист мәңге тынышмыйлар. Ләкин мин моңарчы сиңа күпме тиеш, шулкадәре түләп килдем.

Ильяс *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Мине акча кызыксындырмый. Мине шунысы гаҗәпләндерә: син шулкадәр көчле кешемени соң?!

Альберт *(ямьсез елмаеп)*. Ник алай дисең?

Ильяс. Син бит гомереңдә бер китап укымаган, бер якты хис кичермәгән кеше, нишләп соң син әллә нинди коточкыч көчләргә ия?!

Альберт *(аптырап)*. Нишләдең син?

Ильяс *(куллары белән башын кыса)*. Туктале, әллә чынлап та мин инде исән түгелме? Үлдемме әллә инде мин?

Альберт. Җүләрләнәсең, ахрысы. Әйт әле, нәрсә булды? Сиңа хәзер үз-үзеңне нык тотарга кирәк. Психикаңны кыйшайтырга һич тә ярамый.

Ильяс *(кинәт башын күтәреп)*. Ә ул кәгазь мине куркытмады. Киресенчә, нindидер яңа караш ноктасын таптым шикелле.

Альберт *(аңламаган булып кылана)*. Нинди кәгазь?

Ильяс *(авызын кыйшайтып)*. Башыңны җүләргә салма! Минем үлемем турында таныклыкны син ясаттыңмы?

Альберт *(көлеп җибәрә)*. Ә-ә-ә, мин аны онытканым да икән әле. Һи, тинтәк, мин бит синең үзең өчен эшләткән идем ул кәгазьне. Алай-болай Америкада төпләнеп калып карьера ясый алсаң, хатыныңа шул документны күрсәтергә. Алиментлар сорап, синең байлыгыңның өлешен сорамасын өчен. Ә мин аптырап утырам, ник болай иза чигә бу дип! Ха-ха-ха!

Ильяс. Ник аны минем белән киңәшләшеп эшләмәдең соң?

Альберт. Син сәнгать кешесе. Андый проблемаларыңны хәл итәрдәй махсус кешең бар — мин. Сине дулкынландырмыйча гына хәл итмәкче идем.

Ильяс *(бераз тынычланып)*. Син чын әйтәсеңме?

Альберт. Әйе. Баегач үзең ярдәм итәрсең хатыныңа да, балаңа да. Ә алимент ул... Алайса суд аша ул синең ярты гонорарыңны алачак.

Ильяс. Чын әйтәсеңме? *(Текәлеп карап тора.)*

Альберт. Сине алдаудан миңа ни мәгънә?! Әзерлән. Тәмлерәк аша. Юк-бар турында уйлама. Кая, теге кәгазьне бир миңа.

Ильяс. Кайсы кәгазьне?

Альберт. Теге үлү турында таныклыгыңны. Кеше папкасында казынуың бигүк әйбәт эш түгел, әлбәттә.

Ильяс. Юк, мин сиңа аны бирмим.

Альберт. Ничек инде бирмисең?

Ильяс. Ул бит минем таныклык. Мин үлгәнне раслый торган документ. Пичәте бар, имзалары бар, фирменный бланкта. Минем исемгә оформлять ителгән.

Альберт. Сиңа нигә ул?

Ильяс. Ә сиңа нигә?

Альберт. Миндә торсын.

Ильяс. Ничек инде миңа багышланган документ синдә торырга тиеш?

Альберт. Нигә сиңа үлү турында таныклык, раз син исән?!

Ильяс. Мин исән булгач, сиңа ник кирәк минем үлүем турында таныклык?

Альберт. Мин сиңа яхшылык эшләмәкче идем.

Ильяс. Яхшылык эшлим дип, бәлки, миңа кабер дә казып куйгансыңдыр инде?

Альберт *(гасабиланып)*. Син миңа ышанмыйсың...

Ильяс *(уйга калып)*. Мин теге кәгазьгә никтер күбрәк ышанам.

Альберт. Бир әле син аны миңа. Йә акылдан язарсың, шуңа карап утырып.

Ильяс. Бирмим. Чөнки миңа ошый ул документ.

Альберт. Тиләләнмә инде, Америкага барыр алдыннан алай загружаться итмә! Ник ясаттым шул таныклыкны. Бир миңа!

Ильяс *(тыныч кына)*. Мин аны инде ертып ташладым.

Альберт. Алдыйсың.

Ильяс. Мин кирәкме сиңа?

Альберт *(киң елмаеп кулларын як-якка җәя)*. Базара нет!

Ильяс. Шулай булгач, аптыратма.

Альберт *(әңгәмә башка юнәлеш алганга куанып)*. Ярар, ярар.

Ильяс *(шактый вакыт карап тора).* Син чынлап та, хатынымны мин үлде дип алдап, мине алименттан котылдырмакчы идеңме?

Альберт. Әйе. Баегач, мөмкинлекләреңнән чыгып, үзең ярдәм итәр идең әле.

Ильяс. Ялганлыйсың, ләкин ышанасы килә. Ышанасым килә, чөнки Америкага да барасы килә бит, зараза!

Альберт. Менә, менә! Шулай, шулай! Тиздән репетицияләр башлана. Менә сиңа пока ике йөз доллар. *(Куенынннан акча чыгарып бирә.)* Үзең алыштырырсың безнең акчага. Яшелчә, фрукты күбрәк аша. Мин иртәгә кереп чыгармын. Өйдә буласыңмы?

Ильяс. Өйдә булырмын.

Альберт. Ярый, исән-сау тор! *(Чыгып китә.)*

Ильяс. Ярый, хуш! *(Коридор буйлап йөри.)* Нигә борчылам соң әле мин? Ничек кенә, нәрсә генә булмасын, язмыштан узмыш юк, диләр. Барыбер әзерләнергә кирәк. *(Канатланып.)* Алда Америка көтә! Бу бит һәрбер кешенең хыялы. Бит шул сәяхәттән соң бөтен тормышның үзгәрүе ихтимал. Миңа анда калырга да мөмкинлекләр туар. Бу сәяхәттән ничек тә файдаланырга кирәк. Барырга кирәк, барырга! Аякка басарга, ныгырга кирәк, ниһаять! Состояться итәргә! Югыйсә бу дөньяда мин беркемгә дә кирәк булмаячакмын. Язмыш миңа шанс бирә, бәлки, соңгысындыр... Китәргә кирәк Америкага, китәргә! Китәргә! Китәргә! Китәргә!

Музыка. Бию. Барлык күршеләре чыгып карап торалар. Барысы да аның биюенә мөкиббән китәләр. Караңгы төшә. Сәхнә яктыртганда Ильяс белән Гүзәлия кара-каршы торалар.

Гүзәлия. Китәсеңме?

Ильяс. Китәм!

Гүзәлия. Китсәң бит син мәңгегә китәсең.

Ильяс. Мәңгегә булса ни!

Гүзәлия. Синең монда кызың кала, хатының. Аерылышкан булсагыз да, ул синең хатының, кызыңның әнисе... Монда мин дә калам. Монда синең балачагың, туган җиреңкала. Монда синең күп нәрсәң кала түгелме?!

Ильяс. Моны син әйтмәсәң дә беләм лә мин. Ләкин нишлим соң? Миңа китүе җиңел дип беләсеңме әллә син?! Минем үземә мең кат сорау биргәнем бар: нишләп мин гаиләмне ташлап, гаиләмне генә түгел, моңарчы гаять кадерле булган төшенчәләрне инкарь итеп каядыр омтылам, ыргылам, талпынам? Мин каты бәгырьле кеше микәнни? Күңелем йомшак түгел микәнни соң минем?! Мин шушы сораулар белән бик озак үземнең бәгыремне камчыладым. Хәзер җавабын беләм шикелле. Мин аны күптән түгел таптым.

Гүзәлия. Миңа бик авыр, Ильяс. Сине югалтудан куркам. Син киткәч бөтенләй ямь калмаячак. Аяныч, бик аяныч... Минем сиңа китмә диюем көлке булып яңгырар, мин алай дип әйтергә дә хаклы түгелмендер. Миңа берәр үтенечең юкмы, мин бит монда калам, бәлки, берәр йомыш әйтеп китәрсең?..

Ильяс. Нинди үтенечем булырга мөмкин инде сиңа?

Гүзәлия. Мәсәлән, үлү турында таныклыгыңны миңа биреп калдыр. Аны бит үзең белән йөртмәссең инде...

Ильяс. Юк, мин аны хәтта сиңа да тапшырып калдыра алмыйм.

Гүзәлия. Үзең белән алып китәсеңмени?

Ильяс. Үзем белән дә алып китәсем килми. Мин аны бүлмәмдә калдырырмын. Тик син бу хакта беркемгә дә әйтә күрмә.

Гүзәлия. Юк, юк, әйтмәм.

Ильяс. Һәм бүлмәмә күз-колак булып тор. Берүк берәрсе кереп ул кәгазьне урламасын.

Гүзәлия. Ярар, анысы өчен борчылма син.

Ильяс. Сәер, әлбәттә, мин анда чакта үлү турында таныклыгым монда ятачак... Ә бәлки, чыннан да, минем ул документтан ерак булуым мәслихәттер.

Гүзәлия. Ә шулай да китү куркыныч түгелме соң?! Кеше килгәндә ныграк куана түгелме? Дөньяга кеше тууы да куаныч... Килүдә түгелме бәхет?!

Ильяс. Кеше дөньяга килгәндә, аның белән булачак язмышы килә, ә анда инде барысы да бар. Бәхет килүдә микән? Кайгы да килә бит. Бәхет кайвакыт кайгының китүендә була. Шуңа күрә килү һәм китү турында озак гәп куертырга мөмкин.

Гүзәлия. Миңа бик авыр синнән бу сүзләрне ишетү.

Ильяс. Килү — китүгә караганда гүзәлрәк һәм илһамлырак күренеш. Килүдә үзеңне-үзең коллыкка илтү чагылышлары күп. Җинүче булып килгән сурәттә дә килү халәте үзеңне башка урын, башка мохит, чит-ят кешеләр белән бәйләнешкә керергә мәҗбүр итә. Бу очракта да син ирекле түгел. Килүдә чарасызлык күбрәк түгелме? Хәтта хәерче дә кулын сузып килә ләбаса.

Китү исә көчле рух ияләренә хас. Бар нәрсәгә төкереп, ирексез итеп тотучы вак-төякне, чүп-чарны җыеп түгеп, араларны мәңгегә өзеп китеп бару — бөек күренеш! Китүдә азатлыкка омтылу һәм өметнең канат җәйгән мизгеле бар! Ә инде вакытында китү — даһи күренеш һәм вакыйга!

Көн саен кем беләндер, нәрсә беләндер мәңгегә хушлашу мәслихәт! Бер урында озак тору, тыгыз элемтәләр кору ярамый. Аерым бер мохиттә казынучы булып, һаман да ниндидер бер көйгә биеп, югалтудан куркып (кемне, нәрсәне?!), вак мәшәкатьләрнең колы булып яшәү үлеп баруга тиң. Эчке үлем бугазыңа таба үрмәләгәнче китәргә кирәк, китәргә, китәргә!

Килсәң дә, китәр өчен килергә кирәк!

Мин килмәдем. Минем үтеп барышым. Сезгә таба атлаганда, бәлки, моны килүем дип аңлагансыздыр. Юк. Бу — киткәндә үтеп баруым. Шул арада сезне күрдем. Аңладым. Һәм, ниһаять, китеп барам. Шушы түгелмени бәхет — сезнең белән калмыйм, китәм, китәм, китәм!

Чөнки минем үләсем килми!

Музыка.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Эфирда инглиз телендә диктор тавышы. Америка. Якты эстрада. Дәртле бию — Ильяс затлы киемнән. Овация. Инглиз телендә җыр.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Малосемейка коридоры. Коридорның нәкъ уртасында Наилнең зур брезент чалбары эленеп тора. Гүзәлия бүлмә белән кухня арасында йөри. Чалбар астыннан иелеп чыгарга мәҗбүр була. Киерелә-киерелә Наил чыга.

Кәстрүлләрне ачып-ачып карый.

Гүзәлия. Рәзинәнең хәле ничек?

Наил. Бүлнистә.

Гүзәлия. Беләм. Барысы да нормальнодыр бит?

Наил. Тәртиптә дип өметләнәм инде. Менә хәзер чәй эчәм дә, аның янына китәм. *(Чәй эчәргә җыена.)* Роберт абый күренми, ә...

Гүзәлия. Күренми.

Наил. Кайда соң ул хәзер?

Гүзәлия *(сөмсере коела)*. Белмим. Техникум общежитиесендә бугай. Мескен, нишләп ятадыр инде ул анда?..

Наил *(көлеп)*. Безнең биючебез ни хәлдә икән? Шау-гөр киләләрдер инде. Безнең яктан да Америкага барып биюче булыр икән, ә!

Гүзәлия *(шомлы тавыш белән)*. Аны анда үтерерләр шикелле.

Наил. Монда үтермәгәнне, анда ник үтерсеннәр аны?! Ул шунда калыр инде, кайтмас. Акыллы кеше Америкадан бу абзарга кайтып төшмәс. Аның бүлмәсе турында профкомыбызда сүз күтәрәм әле.

Гүзәлия *(өзгәләнеп)*. Кагылмагыз инде шуның бүлмәсенә!

Наил. Ул кайтмаячак. Үзең, үтерәчәкләр, дисең әле.

Гүзәлия. Авызыңнан җил алсын!

Наил. Нишләп әле без бер бүлмәдә интегергә тиеш?!

Гүзәлия *(бер ноктага текәлеп)*. Бәхетсез кешеләр без, Наил, бәхетсез. Кеше матур, бөек эшләр өчен килә дөньяга, ә чынбарлыкта исә пычракта казынып, вак мәшәкатьләр белән сәламәтлегебезне бетереп яшибез. Нинди иҗат, нинди алга китеш, нинди үсеш булсын, әгәр без шушы түбәнлектән күтәрелергә теләмәсәк. Ал аның бүлмәсен, ишеген ватып кер, тагын берәрсенекен талап ал, ләкин син үзгәрерсеңме соң? Син бит шуның белән генә канәгатьләнмәячәксең. Бәхетсез кешеләр без барыбыз да. Тормыш үзе безгә түбәнлектән күтәрелергә мөмкинлек бирми. Безнең бит ярты гомеребез торак мәсьәләсен хәл итә-итә үтеп китә.

Наил. Ярый, мин бүлнискә киттем. Әллә ниләр сөйләп эчне пошырма инде, миңа хәзер дулкынланырга ярамый — хатын менә-менә бала табарга тора.

Шул вакытны Роберт кайтып керә.

Роберт *(юаш тавыш белән)*. Исәнмесез!

Наил. Менә бит кайтты! Кая китсен ул! Сыер да ашаган җиренә кайта көтүдән.

Роберт *(ачуын көчкә яшереп)*. Бигрәк шәп чагыштыру.

Наил. Китә-кайта йөргән кешегә матур сүз әйтеп булмый.

Роберт. Ә сез матур сүз беркайчан да әйтә алмаячаксыз.

Наил *(усалланып)*. Син минем белән талашырга дип кайттыңмы?

Роберт *(кырт кисеп)*. Юк.

Наил. Киттем мин бүлнискә. Синең кайтуың начар фал. Кыз туар микәнни?! *(Чыгып китә.)*

Роберт. Гүзәлия, мин кайттым...

Гүзәлия *(читкә карап)*. Күрәм.

Роберт. Син мине дөрес аңла... Көнләшергә сәбәп булса, кеше көнләшә инде ул. Мин тере кеше.

Гүзәлия. Өйдә ашарга утыр. *(Кухня өстәленә таба бара.)*

Роберт. Юк, рәхмәт, минем ашыйсым килми. Мин сагындым сине. Син сагындыңмы мине?

Гүзәлия *(иренә карап тора)*. Дөресен әйтимме?

Роберт *(котсыз калып)*. Дөресен әйт.

Гүзәлия *(коры гына)*. Мин бу юлы сине сагынырга өлгермәдем.

Роберт *(шәлберәеп)*. Димәк, иртәрәк кайтканмын.

Гүзәлия *(газаплы кыяфәт белән урындыкка утыра)*. Күңелдә шундый бушлык — аңлатып бетергесез.

Роберт *(кырын карап)*. Ник, биюче тутырмыймыни бушлыкларыгызны — үзенең бисе, үзенең сәнгате белән?

Гүзәлия. Минем күңелемдәге халәтне биючеләр генә үзгәртә алырлык түгел инде. Ул биюче, кызганычка каршы, минем күңел газабын да, йөрәк сагышын да юк италмый. Монда, гомумән, аның катнашы юк. Үзебезнең бәхетсезлегебездә башка кешеләрне сәбәп итеп алырга маташмыйк инде, Роберт. Ильяс булмаса, башка кеше килеп чыгар иде, кеше килеп чыкмаган сурәттә дә башка төрле сәбәп табылыр иде.

Роберт. Нишләргә соң?

Гүзәлия. Яшәргә кирәк барыбер. Нишләргә? Философ, имеш. Миннән сорап утыра — нишләргә?! *(Иренең өс-башын күзәтә.)* Күлмәк якасы катып беткән. Сал, юам. Әнә теге шакмаклысын ки.

Роберт. Әйе, әйе, хәзер. *(Кабаланып күлмәген сала. Коридор уртасында эленеп торган чалбарга нәфрәт белән карап тора.)*

Гүзәлия *(аның чалбарга карап торуын күреп)*. Бу чалбар мәңге эленеп торачак монда — бернишләтә алмыйсың. Чынбарлыкка сугыш игълан итәргә маташма, хәлең җитмәс барыбер.

Роберт. Син үзең философ хәзер. *(Чиста күлмәк кия.)*

Гүзәлия. Шулайдыр. *(Иренең күлмәген ванна бүлмәсенә илтә.)*

Роберт. Мин иртәрәк кайттым... Бәлки, сагыныр идең мине...

Гүзәлия *(ачуланып)*. Ярар, кайтканың бит инде, нәрсәгә үзеңне бимазалыйсың юк нәрсә белән?! Әллә үзеңне-үзең «ашаган» булып кыланасың гынамы? Дөресен әйткәндә, китеп кире кайтмасаң, сиңа ихтирам күбрәк булыр иде. Хәтта шул ук Наил тарафыннан да. Бер киткәч, кайтмаска кирәктер, минемчә.

Роберт *(башын аска иеп)*. Син үз сүзеңне сөйләмисең.

Гүзәлия. Мин хатын-кыз, шуңа күрә кайвакыт кемнәндер ишеткән сүзләр сөйләсәм дә, гөнаһысы бигүк зур булмас. Безнең тормыш бит китеп яңадан башлый алмыйча заяга узып бара. Без бит поступок ясарга, адым атларга куркып яшибез.

Роберт. Әнә синең биючең дә киткән бит хатыныннан... Китүен киткән, ә барыбер малосемейкада яшәп каңгырап ята. Тавышы ишетелми, өйдә юкмы әллә?

Гүзәлия. Америкада ул.

Роберт *(көлемсерәп)*. Анда да малосемейкалар бар микәнни?!

Гүзәлия. Америкада ул, гастрольдә.

Роберт. Гастрольдә генәме, әллә бөтенләйгә киттеме?

Гүзәлия. Ул китсә, китә торган кеше, мәңгегә киткәндер — мәңгелеккә!

Роберт. Исән килеш кулында үлү турында таныклыгы булган кешенең урыны шул Америкаларда гынадыр инде аның.

Гүзәлия. Син күзгә күренеп әшәкеләнә барасың, Роберт.

Роберт. Син дә элекке Гүзәлия түгел инде. Димәк, Америкада биюче күршебез?!

Гүзәлия. Америкада!

### УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Америка. Дәртле музыка. Инглиз телендә диктор тавышы. Ут уйнавы. Фейерверк. Ильяс затлы киемнән бии.

### УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Малосемейка. Бала елый. Рәзинә куенындагы баласын тынычландыра алмый, коридор буйлап җыр шыңшып йөри. Наил чыга.

Наил. Имездеңме соң?

Рәзинә. Ашаттым. Йокысы бар аның.

Наил. Бир әле үземә. *(Баланы кулына ала.)* Улым, улым, әтиеңне танайсыңмы? Үти-тү-тү. *(Коридор буйлап йөри.)* Елама, улым, елама. Алайса, явыз философ килер дә, алып китәр үзеңне. Техникумга тота да алып китә явыз философ. Ул шундый куркыныч. Ә-ә-ә, ә-ә-ә итә, улым йокыга китә. *(Бала елаудан туктый.)* Менә шулай, син бит егет кеше, улым. Йокла, йокла. *(Пышылдап.)* Рәзинә, йоклады, мә, алып кереп сал урынына. *(Наил саклык белән генә баланы хатынына тоттыра. Рәзинә аны бүлмәләренә алып кереп китә.)*

Роберт чыга.

Роберт. Төннәрен каты елый балагыз.

Наил *(үтә җитди итеп)*. Бала еларга тиеш ул. Димәк, холкы бар дигән сүз. Әйдә, бераз аракы кабып куйыйк әле, күрше. *(Өстәл янына утыра.)*

Роберт *(гаҗәпсенеп)*. Болай итагатьле итеп сөйләшкәнегез юк иде бер дә.

Наил *(кулларын угалап)*. Малай туды бит, малай! Утыр әле, утыр, бер чәкештереп эчик.

Роберт. Нинди исем куштыгыз? *(Өстәл янына килеп утыра.)*

Наил. Әгълиулла.

Роберт. Җайлырак исем таба алмадыгызмыни?

Наил. Әгълиулла матур. Их, күрше, малай бит ул! *(Стаканнарга аракы сала.)* Миңа охшаган бит. Утыр әле минем белән. Сал әйдә! *(Наил эчеп куя. Роберт теләр-теләмәс кенә эчә.)* Күрше, син миңа ачуланмыйсыңмы? *(Кыяр ашый.)*

Роберт *(ипи кисәге каба)*. Сезгә ачуланудан мәгънә юк бит.

Наил. Телисеңме, бу чалбарымны бүтән монда элмим. *(Йөгереп барып баудагы чалбарны ала һәм почмакка тотып ата. Килеп утыра.)* Улым нәкъ үзем инде!

Роберт *(кәефсез генә)*. Әйбәт икән.

Наил. Менә бер-ике көннән бу бүлмәне сорап барачакмын.

Роберт. Ә биюче кайтса?

Наил. Кайтмый инде ул. *(Уйланып утыра.)* Син дә теләмисең бит аның кайтуын...

Роберт. Теләмим. Карале, сезнең балагыз туды, сез болай да бәхетле... Сезгә барыбер кайчан да булса фатир бирми калмаслар... Бу бүлмәне мин үземә сорасам...

Наил *(шундук күршесенең сүзен бүлә)*. Юк инде, күрше, әле кайчан бирәләр ул фатирны безгә?! Юк, алай булмый... Бала белән бер генә бүлмәдә яшәве гаять авыр бит.

Роберт *(тавышын күтәреп)*. Мин беркайчан фатир ала алмаячакмын. Ә сезгә барыбер бирәчәкләр, аңлыйсыңмы! Кешеме сез, юкмы?!

Наил. Син, давай, миңа тавышыңны күтәрмә, яме. Ашказаныңа бер генә бирермен. Минем аракыны эчеп миңа каршы права качать итеп утырасың. Син бит киткәниең, ник кайттың? Аяклы күсәк! Күзле таяк! Мин аның белән әйбәтләп сөйләшеп утырам тагын! *(Идәндә яткан брезент чалбарын яңадан коридор уртасына элеп куя.)* Бу бүлмәне сорап барып та йөрмә!

Шул вакытны Ильяс кайтып керә.

Ильяс *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Хәерле көн! *(Күршеләр, үз күзләренә ышанмый, Ильяска карап торалар.)*

Роберт. Монда хәерле көннең булганы да, буласы да юк. Исәнме!

Наил *(көр тавыш белән)*. Менә американец та кайтып җитте. С приездом! Барыбер кайталар берәм-берәм... Күчмә кошлар, анагызны сатыйм! С приездом, күрше!

Ильяс. Рәхмәт. *(Кул биреп күрешәләр.)*

Наил. Син туп-туры Америкаданмы?

Ильяс. Әйе. Нинди яңалыклар бар?

Наил. Ике зур яңалык бар. Минем малай туды — Әгълиулла.

Ильяс. Котлыйм. Икенче яңалык нинди?

Наил. Менә Роберт абзаң хатыны янына кире кайтты.

Роберт. Тагын бер яңалык бар — Казанга мең ел дип исбатладылар. Дөрестерме, юктырмы, белмим. Ике мең дип тә исбатлап була бит инде аны югыйсә.

Наил. Сиңа илле яшь булганны, Казанга гына мең ел бардыр инде анысы.

Роберт. Юмормы бу, нәрсә бу?

Наил. Утыр әле, утыр, Ильяс. Америкада нинди яңалыклар бар соң?

Ильяс. Аны сөйләп бетергесез, Наил туган.

Наил. Ничегрәк анда?

Ильяс. Американдагыча.
Наил. Аңлашылды. Син миңа шуны әйт: ник кайттың?
Роберт. Мин дә шул сорауны бирмәкче идем.
Ильяс. Бүлмәм бар бит монда, шуны сатасым бар.
Наил. Нүжәли син анда шәп фатирлык акча эшләмәдең?
Ильяс. Таладылар мине. Хәер, алай ук күп акчам юк иде лә минем.
Наил. Һи-и-и, син дә йөрисең инде, мәми авыз!
Роберт. Кайда таладылар? Тегендәме, мондамы?
Ильяс. Тегендә дә, монда да. Тегендә продюсерлар талады, монда кайткач, Мәскәүнең Казан вокзалында. Йокыга киткәнмен, уянсам, акчамны алганнар, чемоданым юкка чыккан. Баш астындагы сумкам калды да, икенче кесәмдәге долларларым исән.
Роберт. Ник кайттыгыз соң сез монда?
Ильяс. Гаиләм монда бит минем, кызымны сагындым. Аннары, мин анда үлә яздым туган җиремне сагынып. Монда чакта туган авылыма еллар буе кайтмый йөрим, ә анда барып төшкән көнне үк туган авылымны сагынып еладым.
Наил. Димәк, син кире китмәячәксең Америкага?
Ильяс. Юк. Наил, менә сиңа акча, бар виски алып кер теге остановкадагы павильоннан. Менә монысы сезгә бүләк булыр — малаең туу хөрмәтенә, йөз доллар. Роберт абый, сезгә дә миннән йөз доллар күчтәнәч урынына булсын. *(Робертка да йөз доллар бирә.)* Бөтен әйберләремне урладылар бит, югыйсә сезгә дигән күчтәнәчләрем дә, бүләкләрем дә күп иде.
Наил. Хәзер, тиз генә чыгып керәм. *(Чыгып йөгерә.)*
Роберт. Алга таба нишләргә җыенасыз инде?
Ильяс. Күз күрер.

Рәзинә чыга, күзләрен чекерәйтеп карап тора.

Рәзинә *(шаккатып)*. Бәрәч, Ильяс абый, синме бу?
Ильяс. Мин. Исәнме, Рәзинә!
Рәзинә. Исәнме!
Ильяс. Бәби үсәме?
Рәзинә. Үсә. Ә Наил кайда?
Ильяс. Ул хәзер керә. Без аны аракыга җибәрдек. Менә сиңа йөз доллар, бүләк урынына булыр. *(Рәзинәгә йөз доллар бирә.)*
Рәзинә *(акчаны ала, аптырап карап тора)*. Нишлим мин аның белән?
Ильяс. Наил белер нишләтергә. Безнең акча белән өч мең сум ул.
Рәзинә. Рәхмәт. Син ник кайттың соң?
Ильяс *(газаплы елмаю белән)*. Бөтенегез шул сорауны бирәсез. Тормыш бик авыр анда, Рәзинә.
Рәзинә. Безнекеннән дә авыррак түгелдер инде.
Ильяс. Юк, миңа анда ошамады. Монда туып үскән кеше монда яшәргә тиеш.
Рәзинә. Алай икән... Наил күптән чыгып киттеме?
Роберт. Хәзер кайта, хәзер кайта.
Рәзинә. Ярар, иртәгә сөйләшербез әле.
Ильяс. Ярар, тыныч йокы, Рәзинә.
Рәзинә. Наилгә күп эчертмәгез. *(Кереп китә.)*
Роберт. Яуладыгызмы соң Американы?
Ильяс. Аны яулыйсы юк, ул инде күптән яуланган.
Роберт. Аннан, ичмаса, баеп та кайтмагач, ник кенә барып йөрдең? Бөтен малыгызны урладылармыни? Әгәренки чын-чынлап баеган булсагыз, счетыгызда акчагыз калыр иде. Бәлки, калгандыр да?
Ильяс. Юк, калмады. Бернинди байлык табалмадым мин анда. Ят кеше мин Америка өчен. Анда беләсезме күпме биюче! Анда сәнгатькә бөтенләй башка караш. Без монда сәхнәгә менеп ялтырарга тырышабыз, тормышыбыз төксе булуга карамастан. Ә аларның анда гомумән тормышлары сәнгати. Урамнары, машиналары, ашханәләре, йорт төзелешләре. Чынбарлыкның кай төшенә генә килеп төртелмә — сәнгати дәрәҗәдәге халәт аңкып тора. Күңел халәте сәнгати аларның. Хәтта гап-гади кешеләренеке дә.

Наил кайта. Ике шешә тоткан.

Наил. Менә алып кайттым. Закуска алмадым, кыяр бар бит. *(Кабаланып шешәне ача, стаканнарга хәмер сала.)*

Ильяс. Әйдәгез, тотып куйыйк.

Наил. Нәрсә өчен эчәбез?

Ильяс. Китү өчен.

Роберт. Әле яңа кайттыгыз бит.

Ильяс. Мескенлектән китү өчен.

Роберт. Мөмкинме соң ул?

Ильяс. Мөмкинлеген мөмкиндер, ләкин безнең илдә кирәк микән чынлап та мескенлектән китү? Бездә хәерчелек, җан газабы иҗатка этәрә. Матурлыкка, бөеклеккә, затлылыкка сусап, яхшылыкка мәдхия җырларга омтылабыз, гәрчә бу омтылыш тормышны яхшыртмаса да, алга этәрмәсә дә. Ә тегендә ничектер башкача — иҗат тормышны яхшыртуга юнәлтелгән, кеше турында кайгыртуга юнәлтелгән.

Наил. Әй, юк белән баш катырмагыз әле. Исән-сау кайтып җитүең белән! *(Эчәләр.)*

Ильяс *(кыяр каба)*. Беләсеңме нәрсә, Наил?..

Наил. Әйе?

Ильяс. Бу бүлмәне сиңа бүләк итәрмен, ахрысы.

Наил. Чын әйтәсеңме?! Мин аны уйлаган идем инде — Америкаларны гизеп, зур сәхнәләрдә биеп кайткан кеше олы җанлыланып кайтачак дип.

Роберт *(кыза башлый)*. Туктагыз әле, ә нишләп Наилгә, ник әле миңа түгел?

Ильяс. Син дә хаклы, Роберт абый. *(Көлемсери.)* Ике кеше нindидер бәхәс белән казыйга килгәннәр, имеш. Берсе үзенең дәгъвасын белдергәч, казый әйткән: син хаклы, дигән. Икенчесен тыңлаганнан соң казый анысына да син хаклы, дигән. Шул вакытта болар янынnan бер кеше узып барган. Ул туктап тыңлап торган да әйткән: казый, алай булмый бит, ике бәхәсче — икесе дә хаклы, ничек алай мөмкин инде?! Казый аңа: син дә хаклы, дип җавап биргән. Менә шулай... Алайса, Наил туган, ашыкмыйк әле. Бу бит чыннан да җиңел генә мәсьәлә түгел.

Наил *(Ильяска күз кысып).* Ничего, җайларбыз, җайларбыз.

Ильяс. Әгәренки чынлап та китсәм, үзегез карарсыз шунда... Тик ул очракта да, ай-һай, белмим... *(Кулын Наилнең иңенә куеп.)* Их Наил, Наил, син уйлыйсың дөньяда буш бүлмәләр барлыкка килер дә, синең кебекләр шунда тулыр дип уйлыйсың. Алай булмаячак. Бу бүлмәгә миннән соң да кемдер килеп керәчәк — биючеме, җырчымы, музыкантмы. Шунысы гына сәер, мин вакытсыз китәрмен, ләкин минем китүем беркемгә файдага булмас һәм үрнәккә файдаланылмас.

Наил. Әйдәгез, тотып куйыйк әле.

Ильяс *(бер ноктага текәлеп).* Ә мин сагындым туган илне. Сагындым. Бигрәк тә туган авылымны. *(Сикереп тора.)*

Музыка. Бию. Күршеләре кул чабып тамаша кылып утыралар.

**УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Гүзәлия кухняда кайнаша. Ильяс чыга — бите шешенгән, көчкә атлый, кыскасы, кыяфәте эчкеченекенә охшаган.

Гүзәлия *(пошаманга калып)*. Нишләдең син?

Ильяс *(ыңгырашып)*. Махмыр.

Гүзәлия *(борчулы кыяфәт белән карап тора)*. Ник кайттың монда?

Ильяс. Мин бу сорауны меңенче кат ишетәм инде.

Гүзәлия *(йөзенә кайгы төсе чыгарып)*. Бу сорауны мин үземә бирәм: ник кайттың син?

Ильяс. Синең миңа әйткәнең бар: имеш, мине аңлыйсың. Дөньяда бердәнбер мине аңлаучы кеше син, шуңа күрә кайттым.

Гүзәлия. Чын әйтәсеңме? Мин бит андый сүзләргә ышанучан хатын. Алай димә, үзәгемне өзәсең. Минем янга кайттыңмы?

Ильяс. Матур кеше син.

Гүзәлия. Алдыйсың. Мин монда булганга күрә түгел синең кайтуың. Син бит үзеңне-үзең алдыйсың! «Килү-китү» турындагы фәлсәфәңне онытттыңмыни?!

Ильяс. Ә мин кайтмадым! Китеп барганда кереп кенә чыгуым бу! Миңа кинәт кызык булып китте: Гүзәлия мине чынлап та аңлый микәнни, мәйтәм! Үзен-үзе тәгаен аңлап бетермәгән кешене ничек нindидер бер китапханәче хатын аңлый ала икән? Ничек аңлыйсың син мине, йә, әйт.

Гүзәлия. Сиңа тиешле бәяне бирмиләр. Гомумән, сәнгать кешесенә тиешле бәя бирелми, төп фаҗига шунда.

Ильяс. Ә тиешле бәя ничек була соң ул? Нинди бизмәндә үлчәмәк кирәк талантны? Шушымы синең мине аңлавың?! Нишләп әле миңа зур бәя бирергә тиешләр?! Юк, юк, син тәфсилләп сөйлә ничек аңлавыңны?

Гүзәлия. Син илаһи зат, син башкача яшәргә, башка мохиттә кайнарга тиеш. Шул ук нәрсәгә кайтам барыбер — сиңа тиешле бәя бирелмәгән.

Ильяс. Юк, Гүзәлия, дөрес аңламагансың син. Юк. Ялгышасың. Син минем тышкы ялтыравыма, хәрәкәтләремә генә карама. Мин — хатынымны, баламны ташлап чыгып киткән кеше. Андый зат илаһи була аламы инде, йә?!

Гүзәлия. Мин, дөресен әйткәндә, синдә бераз разочароваться да итә башладым шикелле. Китүең шул гаиләңнән китү генә булып калмас микән?

Ильяс. Анысы өчен кайгырма, Гүзәлия.

Гүзәлия. Мин сине шулкадәр сагындым. Тик шулай да кайтмаска иде сиңа.

Ильяс. Кайттым шул. Мин дә разочароваться итеп кайттым — океан артындагы тормыштан ваз кичеп.

Гүзәлия. Әле кайдадыр якты дөньялар, кешечә яшәүләр бар дигән өметләр белән ята идек монда. Син кайтып актык хыялларыбызны җимерергә ниятлисең.

Ильяс. Анда да зәп-зәңгәр күк, анда да тормышлар бик катлаулы. Анда да авыртудан елыйлар, анда да бала тапканда хатын-кыз кычкыра...

Гүзәлия. Син әллә нишләп кайткансың... Каты бәгырьлеләнеп.

Ильяс. Мин элек тә шундый идем.

Гүзәлия. Нык үзгәреп кайткансың.

Ильяс. Мин кайтмадым. Минем бу киткәндә тагын бер әйләнеп кереп чыгуым гына.

Гүзәлия. Мин синдә иң беренче тапкыр килеп кергән Ильясны эзлим, ләкин башка кеше утыра шикелле. Мин сине югалта барам кебек.

Ильяс. Юк, син мине элеккечә яратачаксың. Хәзер бер генә биеп җибәрәм — һәм син тагын минеке булачаксың.

Гүзәлия. Ильяс, кырыс сөйләшмә, миңа бик авыр. Сиңа карыйм да ниндидер зур югалту кичереп барам кебек тоела. Ильяс!

Ильяс. Гүзәлия! *(Кочаклашалар.)*

Гүзәлия. Синең хәтта йөзеңнең төсе дә үзгәргән.

Ильяс. Минем йөрәгем авырта. Элек тә авырта иде ул, соңгы вакытта бигрәк каты кыса. Дөресен әйткәндә, Америкадагы гастрольләрдә дә мин көчкә түзеп йөрдем.

Гүзәлия. Алайса, сиңа биергә ярамый...

Ильяс. Миңа биемәскә дә ярамый, Гүзәлия. Гомерем буе кемгәдер үземне, үземнең барлыгымны исбатларга тырыштым. Кеше үзе өчен яшәргә тиеш. Ә без башка кешеләргә үзебезнең сәләтебезне, талантыбызны, ниһаять, үзебезнең кеше икәнлегебезне исбатлап гомер кичерәбез.

Гүзәлия. Гаиләң янына кайтырга уйламыйсыңмы соң?

Ильяс. Мин бит гаиләмә дә үземне аякка бастым һәм ныгыдым, состояться иттем дип тәкъдир итәргә тиешмен. Ник аерылыштык дип уйлыйсың хатыным белән? Мин бит хатыныма үземнең биюче икәнлегемне, сәнгать колы икәнлегемне аңлата алмаган бер мәхлук. Мин бит состояться итеп, кеше булып, дан казанып кайтырга тиеш идем. Юк, юк, мөмкин түгел инде... Ул аңламаячак мине... Син дә аңламыйсың... Синең аңламаганыңны аңлар өчен дә монда кайтып килү ярый... Бу кайту түгел, юк, юк. Киткәндә кереп чыгу... Мин аек акылым белән эчке ихтыяҗыма буйсынып китүгә таба барам, чөнки состояться италмавымны сизәм.

Гүзәлия. Сиңа эчәргә дә ярамый, йөрәгең авырта. Эчмә бүтән.

Ильяс. Бүген генә эчәм дә...

Гүзәлия. Калырга идең ничек тә Америкада. Сине анда язмыш агымына ташламаслар иде. Монда харап булырсың...

Ильяс. Анда тизрәк харап булыр идем мин.

Гүзәлия. Шулай да ник кайттың?

Ильяс. Мең тапкыр кабатлаттырма! Минем китеп барышым!

Гүзәлия. Менә әле монда утырасың түгелме?!

Ильяс. Ярар, дөресен әйтәм алайса! Үлү турындагы таныклыгым шушында бит. Ничек инде монда кереп чыкмыйсың. Үлү турында таныклык ята бүлмәмдә, шул мине тартты монда! Миңа ничектер шул таныклыкның якында булуы җанга тынычлык бирә.

Гүзәлия. Китер аны миңа, ертып ташлыйм.

Ильяс. Юк, ул минем өчен бик кирәк һәм гаять кадерле документ.

Гүзәлия. Ничек ярдәм итим сиңа, ник болай газапланасың? Нишләп шулкадәре сагышлы күзләрең, нишләп битеңнән төс качкан?

Ильяс. Арыдым. *(Кинәт канатланып.)* Гүзәлия, мин өйрәткән биюне онытмадыңмы?

Гүзәлия. Юк.

Ильяс. Кил, биибез.

Музыка. Парлы бию. Биюдән соң караңгылык төшә. Сәхнә яктыртганда Ильяс башын аска иеп утыра. Альберт килә.

Альберт *(усал кыяфәт белән)*. Хәл ничек?

Ильяс. Начар. Өстәвенә таладылар.

Альберт. Ишеттем. Менә, шуның өчен сиңа. *(Бер пачка доллар ташлый.)*

Ильяс. Кирәк түгел миңа синнән акча. Бүтән миңа килмә.

Альберт. Киреләнмә! Гастрольләр начар уздымыни?

Ильяс. Начар узмады.

Альберт. Икенчесендә күбрәк акча эшләрбез.

Ильяс. Кирәк түгел. Күпме булса да акча бәхетле итә алмаячак мине. Башка биючеләрне тап, яшьрәкләрне эзлә. Мин авырыйм.

Альберт. Соң, берәр яхшы санаторийга урнаштырам үзеңне. Телисеңме?

Ильяс. Юк. Бүгенге көндә сәхнәгә чыгып биюемнең мәгънәсен тапмыйм. Продюсерларны баетыр өченме, акырып-сызгырып утыручыларның кәефен күтәрәм дипме?! Җан азыгы булудан туктап бара сәнгатем... Син һәм синең кебекләр гаепле. Сәнгатьне сез коммерцияләдегез, сез конвейерга куеп акча эшләү кәсебенә әвереледердегез. Акча эшләүгә юнәлтелгән һәрбер нәрсә җан азыгы булудан туктый. Сатыла торган нәрсәнең бәясе бөтенләй юк. Бер тиен дә түгел. Сатылмый торган төшенчәләр, сатылмый торган күңел халәтләре бар — шуларның гына бәясе бар һәм югары. Минем исемгә үлү турында таныклык эшләтүеңнең сәбәбенә дә төшендем. Мине куркытып, котымны алып, үзеңә тәгаен буйсындырып тотар өчен оештыргансың син аны.

Альберт. Вәт җүләр, юк инде, хатыныңа алимент түләтмәс өчен, сине кызганып эшләткән идем мин аны. Кая, бир әле ул каһәр суккан кәгазьне.

Ильяс. Юк, миңа кирәк ул, миңа ошый ул. Минеке ул.

Альберт. Җүләр. Давай үзеңне кулга ал да, ял иткәч, яңа проектлар эшлибез.

Ильяс. Мин синнән моңарчы ничектер куркып йөри идем.

Альберт. Хәзер инде курыкмыйсыңмы?

Ильяс. Юк, курыкмыйм. Ләкин син әле бик күпләр өчен хаким булып, көчле, абруйлы саналып йөриячәксең. Новый русский... продюсер... Син куркыныч кеше... Син — кешенең иң изге хисләре белән сату-алу итеп йөрүче җинаятьче. Менә карап торам-торам да аптырыйм — нишләп куркыныч соң син?! Син — надан, хам, оятсыз, имансыз һәм кансыз бер хайван. Ничек шундый түбән кеше куркыныч була ала?! Бит, киресенчә, укымышлы, затлы, нечкә күңелле кеше өстенрәк булырга һәм томаналарны өркетергә тиеш! Менә бу — минем өчен бик зур сорау?! Нишләп синең кебек бер күзәнәкле кабахәттән талантлы кешеләр, акыл ияләре, даһилар өркеп торалар икән?! Нәрсәсе дөрес түгел соң бу кешелек дөньясының?!

Альберт. Беләсеңме, ни өчен мин сине түзеп тыңлап утырам?

Ильяс. Ни өчен?

Альберт. Кызганам мин сине.

Ильяс. Менә шунысы тагын да куркынычрак — синең мине кызганып утыруың. Бит мин сине кызганырга тиеш.

Альберт. Дурак! *(Чыгып китә.)*

Ильяс. Әлбәттә дурак! *(Шешәне күтәреп аракыны эчеп бетерә.)*

Роберт кайтып керә.

Роберт *(карап тора)*. Бик каты исергәнсез.

Ильяс *(мыскыллап)*. Әйе, исергәнбез.

Роберт *(кәстрүлне ачып, ит кисәге ала, ашый)*. Ә сез беләсезме, нишләп шушы көнгә калдыгыз?

Ильяс. Нишләп?

Роберт. Сәнгатьне Алла яратмый, шуңа күрә сәнгать кешеләре, гадәттә, бәхетсез була.

Ильяс *(ирония белән)*. Әйтәм җирле философларның бәхете ташып тора. Күрәсең, Алла философларны үлеп яратадыр, бигрәк тә техникумнарда укытучыларны.

Роберт. Сез Наил кебек сөйләшә башладыгыз. Деградация башланды, шул Наил белән бер дәрәҗәгә төшүегез ихтимал.

Наил кайтып керә.

Наил *(ишетеп ала һәм ишек катыннан ук эндәшә)*. Синең дәрәҗәңә менә күрмәсен, иллегә кадәр малосемейкада яшәр.

Роберт. Ә-ә-ә, үзе кайтты.

Наил. Кайттым шул.

Рәзинә чыгып Наилне ашата, Гүзәлия чыга һәм Робертка чәй ясый. Ильяс читтә утыра.

Ильяс *(инде хәйран исерек)*. Наил, салабызмы?

Наил *(шатланып)*. Вискиең бар мәллә?

Ильяс. Бар. Менә бит. *(Өстәл артындагы тумбочкадан шешә чыгара, стаканнарга әчемлек сала.)*

Наил. Әйдә, аш алдыннан җибәрик.

Эчәләр.

Роберт. Мин әйткәннәрне инкарь итмәгез. Бит инде мәгълүм — бию ул секска чакыру. Хайваннарның самецлары совокупление алдыннан бииләр. Моңлы җыр — җан газабы... Шул хисләрдән ниндидер профессия ясау тамырыннан ук дөрес түгел. Фаҗигагезнең сәбәбен шуннан эзли башларгадыр, бәлки?

Наил. Үзең бии белсәң, алай димәс идең.

Роберт. Мин сезнең белән сөйләшмим, Наил. Ильяс әфәнде белән сөйләшәм.

Наил. Ильяс әфәнденең синең белән сөйләшәсе киләме соң?

Ильяс *(стаканын күтәреп)*. Наил, игътибар итмә мескен кешегә. Әйдә тотып куйыйк.

Роберт. Сез дә мескен хәлдә калдыгыз бүгенге көндә.

Ильяс. Бәлки, шулайдыр... Ләкин хәзер менә биеп җибәрәм һәм мин сезне берничә минутка гына булса да әсир итә алам. Мизгелләр эчендә генә булса да мин сезнең өстән хакимлек итәм. Минем төп омтылышым да, бәлки, шулдыр. Тормыш — үзе бер кыска гына бию. Беркем дә, бернәрсә дә мәңгелек түгел.

Роберт. Мәңгелектә калучылар да бар. Мәсәлән, Сократ. Сократ мәңге яши, гәрчә биемәгән булса да.

Ильяс. Юк, ул үзе яшәми, аның әйткән сүзе генә яши. Аның исеме белән синең кебекләр файдаланып, аның цитаталарын яттан сөйләп яшиләр. Сократ бит ул! Син түгел бит ул! Син үзеңнең исемең турында уйлан. Мең ел элек яшәгән кеше исемен атап тәкәбберләнеп утырма!

Наил. Сократ кем ул?

Роберт. Философ.

Наил. Ул да техникумда укытканмы?

Роберт *(авыз чите белән генә)*. Әйе, энергостроительныйда.

Ильяс. Үз фикере булмаган кеше һәрвакыт даһиларның цитаталары белән сөйләшә.

Роберт. Ни өчен миңа нәфрәтләнгәнегезне беләм.

Гүзәлия *(ихлас күңелдән борчылып)*. Тынычланыгыз! Ильяс, синең бит йөрәгең авырта, сиңа дулкынланырга ярамый.

Роберт. Беләсегез килсә, сезнең Америкадан кайтуыгыз ул — җиңелү билгесе. Димәк, сезне анда танымаганнар!

Гүзәлия. Алай сөйләшмә! Ник алай дисең?!

Ильяс, бүлмәсенә кереп, үлү турында таныклыгын алып чыга.

Ильяс *(гасаби киеренкелеген көчкә йөгәнләп)*. Барыгызга да соңгы тапкыр әйтәм. Мин кайтмадым. Мин китеп барам. Менә бу үлү турында таныклыгымны алырга кайттым. Шул тартты мине монда. Менә, чүпрәк философ, күрәсеңме, минем үлүем турында таныклыгымны?! Синең юк ул. Ә минем бар. Син шулкадәр пүчтәк кеше ки, хәтта үзең үлгәч тә мондый таныклыгың булмавы ихтимал. Ә минем исән килеш бар!

Наил. Кызма, Ильяс туган, ник шул җүләрнең сүзенә игътибар итәсең?! Чыннан да, үзеңне сакларга тырыш әле син.

Рәзинә. Әйе, Ильяс абый, бигрәк йөрәгегезгә якын аласыз әйткән сүзне.

Ильяс. Минем китүем — мескенлектән китәргә омтылуым. Мин инде бүтән кайта алмам. Чөнки кайтсаң, дөрестән дә җиңүче булып кайтырга кирәктер. Состояться итеп. Ләкин мине бер фикер тынычландыра һәм аклый. Мин килмәдем. Минем үтеп барышым. Мин кайтмадым. Бу — киткәндә кереп чыгуым.

Гүзәлия. Үзеңне-үзең бетермә. Җиңүләрең алдадыр әле.

Ильяс. Кызганмагыз мине. Роберт әфәнде әйткән сүзләрдә хаклык бар. Алла сәхнәне яратмыйдыр. Ул гомумән сәхнәне яратмыйдыр. Талант ул бүләк түгел, талант ул җәза, җан газабы. Берәр бәхетле талант иясен күргәнегез бармы? Талант ул — бәхетсезлек. Дар божий дигән булалар, нинди дар божий, талант ул — җәза. Талант иясе хөкем ителгән кеше сыман ул. *(Пауза.)* Сез таралмый торыгыз. Мин хәзер чыгам. Чак кына хәл алам да... Хәл бетеп китте, чак кына ятып торам. Тик сез бер биш минут таралмый торыгыз инде, зинһар. *(Кереп китә.)*

Наил. Син, Роберт абый, давай, Ильяска авыр сүз әйтмә. Мин Ильяс өчен башыңны ашыйм синең.

Рәзинә. Ярар инде, Наил.

Наил. Бар бүлмәгә, анда бала егылып төшмәсен.

Рәзинә кереп китә.

Гүзәлия. Күңелем шомлана минем.

Роберт. Минем күңелем шомланырга тиеш. Минеке! *(Коридор буйлап йөри.)*

Наил. Башта бик яраткан идең бит әле үзен. Шәп, күршебез биюче була дигән идең!

Ильяс затлы киемнән чыгып баса. Горур кыяфәт белән күршеләрен күзәтә. Күршеләр аптырап карап тора.

Ильяс. Ә Рәзинә кайда? Мин бит үтенеп сорадым, таралмагыз дип.

Наил *(кычкыра).* Рәзинә, чык тизрәк!

Рәзинә. Нәрсә? *(Баласын күтәреп чыга һәм, Ильясны күргәч, шыпырт кына барып урындыкка утыра.)*

Ильяс. Леди и джентльмены! Сезнең өчен Америкадан махсус яңа бию алып кайттым.

Музыка. Бию. Барысы да таң калалар. Биюнең уртасында музыка кинәт тына. Ильяс йөрәген тотып егыла. Үлә. Күршеләре нишләргә белми аның тирәли йөгерешә башлыйлар.

**УНӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Күршеләр коридорда тып-тын утыралар.

Рәзинә. Менә бушады бүлмә.

Наил. Бу бүлмәне сатып, акчасын аның хатыны белән кызына бирергә кирәк. Каян табарга икән аларны?

Гүзәлия. Мин беләм адресларын. Ильясның әйткәне бар иде.

Роберт. Сатып торуның кирәге юк, бүлмәне аның хатынына бирергә кирәк тә, вәссәлам. Үзе карасын — сатаргамы, юкмы.

Гүзәлия. Чынлап та, үзе белер нишләтергә кирәклеген.

Роберт. Карале, китте дә барды егет, ә!

Наил. Ул бит әйтте: «китәм» диде. Ул буш сүзле егет түгел иде.

Рәзинә. Нинди талант әрәм булды!

Роберт. Талантлы кешеләрнең язмышы фаҗигале була инде аларның.

Наил. Мыгырдап утырган булма инде. Аңа ниләр әйткәнеңне оныттыңмыни?!

Гүзәлия. Тавышланмагыз! Ник гел тавыш күтәрергә торасыз сез! Ичмаса, бүген тыныч утырыйк.

Шул вакытны бер сәер зат килеп керә, өстендә плащ, якасы күтәрелгән, йөзе күренми диярлек, зур виолончель күтәргән.

Сәер зат. Ильяс, бүлмә сатам, дигән иде.

Наил. Бүлмә ачык.

Сәер зат. Рәхмәт. *(Бүлмәгә кереп китә.)*

Музыка. Виолончель уйный.

Роберт. Ә ул барыбер ничектер матур китте. Китүе матур килеп чыкты аның...

Гүзәлия. Мин ышанмыйм! Ничек китә ала инде ул?! Нишләп ул гомер уртасында китеп барырга тиеш?! Әллә соң алар үзләре китәргә теләгәнгә Күк аларны берәм-берәм үзенә алып торамы?! Ышанасы килми!

Наил. Минем дә ышанасым килми.

Рәзинә. Мин дә ышанмыйм.

Гүзәлия. Менә ишек ачылыр да якты елмаеп ул килеп чыгар төсле! *(Урыныннан сикереп тора.)* Әнә ул!

Бүлмә ишеге кинәт ачыла һәм аннан ап-ак кием киеп Ильяс чыга. Музыка. Бию. Овация!

Тәмам.

*2000*

**ЭЧТӘЛЕК**

ТЕЛСЕЗ КҮКЕ

ГАСЫР МОҢЫ

ЧАПТЫ АТЫМ КАЗАНГА

БИТ

КИЛӘ ЯВА, КИЛӘ ЯВА...

ЯВА КАРЛАР, ЯВА КАРЛАР...

КИТӘМ ИНДЕ, КИТӘМ!

Литературно-художественное издание

***Хаким*** *Зульфат*
(**Хакимханов** Зульфат Зуфарович)

НЕМАЯ КУКУШКА

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Хәким*** *Зөлфәт*
(**Хәкимханов** Зөлфәт Зөфәр улы)

ТЕЛСЕЗ КҮКЕ

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы *А.Р.Хисмәтова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә
салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Г.Г.Зиннәтуллина,*
*С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 27.09.2007. Форматы 84x108 1/32.

Офсет кәгазе. «Peterburq» гарнитурасы. Офсет басма.

Шартлы басма табагы 25,20. Шартлы буяу-оттиск 25,62.

Нәшер-хисап табагы 30,30. Тиражы 2000. Заказ С-1096.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.